# ТЮРКСКАЯ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ: ПРОБЛЕМЫ И ПЕРСПЕКТИВЫ

# ТӨРКИ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ: ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ ПЕРСПЕКТИВАЛАР

# TURKIC LINGUISTIC CULTUROLOGY: PROBLEMS AND PERSPECTIVES

Казань-Казан-Kazan

**ТЮРКСКАЯ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ:**
**ПРОБЛЕМЫ И ПЕРСПЕКТИВЫ**
материалы XII Международной научно-практической конференции
учащихся, студентов и аспирантов
Казань, 19 февраля 2021 года

**ТӨРКИ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ:**
**ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ ПЕРСПЕКТИВАЛАР**
гомуми урта, махсус урта һәм югары белем бирү йортларында
укучыларның XII Халыкара фәнни-гамәли конференциясе
материаллары
Казан, 19 февраль, 2021 ел

**TURKIC LINGUISTIC CULTUROLOGY:**
**PROBLEMS AND PERSPECTIVES**
the proceedings of the XII International Scientific and Practical Conference
for pupils, undergraduate and postgraduate students
Kazan, 19 February, 2021

КАЗАНЬ – КАЗАН – KAZAN
2021

УДК 811.512.1
ББК 81.2
Т98

НАУЧНЫЙ РЕДАКТОР
доктор филологических наук, профессор Р.Р. Замалетдинов

ФӘННИ МӨХӘРРИР
филология фәннәре докторы, профессор Р.Р. Җамалетдинов

SCIENCE EDITOR
Doctor of Philology, Professor R.R. Zamaletdinov

**Тюркская лингвокультурология: проблемы и перспективы:** материалы XII Международной научно-практической конференции учащихся, студентов и аспирантов (Казань, 19 февраля 2021 года) / сост. Р. С. Нурмухаметова. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2021. – 364 с.

**Төрки лингвокультурология: проблемалар һәм перспективалар:** гомуми урта, махсус урта һәм югары белем бирү йортларында укучыларның XII Халыкара фәнни-гамәли конференциясе материаллары (Казан, 19 февраль, 2021 ел) / төз. Р. С. Нурмөхәммәтова. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2021. – 364 б.

**Turkic Linguistic Culturology: Problems and Perspectives:** the proceedings of the XII International Scientific and Practical Conference for pupils, undergraduate and postgraduate students (Kazan, 19 February, 2021). – Kazan: Kazan University Press, 2021. – 364 p.

**ISBN 978-500130-021-2**

В сборник включены материалы исследований участников конференции, связанные с изучением тюркских языков и литератур, взаимоотношения языка и общества, культуры.

Ответственность за достоверность информации возлагается на авторов и научных руководителей.

Җыентыкта конференциядә катнашучыларның төрки телләр һәм әдәбиятлар, тел һәм җәмгыять, мәдәният белән бәйле мәсьәләләрне өйрәнү юнәлешендәге эзләнүләре, фикерләре урын алды.

Материалларның эчтәлеге, фактларның дөреслеге өчен авторлар һәм фәнни җитәкчеләр җавап бирә.

The collection includes materials of research related to the study of Turkic languages and literatures, the relationship between language and society, language and culture.

The authors and academic advisors are responsible for the accuracy of the information.

© Издательство Казанского университета, 2021

**Дорогие участники международной научно-практической конференции “Тюркская лингвокультурология: проблемы и перспективы”!**

От имени коллектива Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета и от себя лично приветствую Вас и желаю успешной работы нашей конференции!

Если взглянуть на карту мира, то можно увидеть, что территория проживания тюрков простирается от внутренних регионов Монголии и Китая на востоке, до Вены на западе, от Сибири на севере и до Багдада, Ливанской границы и внутренних областей Кипра на юге. Тюрки проживают в двадцати пяти находящихся на этой территории странах. Это такие страны, как: Монголия, Китай, Россия, Афганистан, Азербайджан, Туркменистан, Казахстан, Кыргызстан, Узбекистан, Иран, Ирак, Сирия, Турция, Турецкая Республика, Северный Кипр, Греция, Болгария, Югославия, Румыния и Польша. Если Россия является самой большой территорией распространения тюркских народов, то в Турции проживает больше всего тюрков.

На сегодняшний день сложно назвать точную цифру, определяющую количество тюркоговорящих людей во всем мире. Однако по предположениям, эта цифра составляет около 200-250 млн человек. В классификации языков мира, если сравнить группу тюркских языков со всеми ее диалектами с другими языковыми группами, она находится на восьмом месте после группы китайских, индийских, романских, германских, славянских, арабских и индонезийских языков и диалектов.

Казанский университет со дня своего открытия является колыбелью тюркологии в России. Уже по его первому уставу, подписанному 5 ноября 1804 г., на Отделении словесных наук открылась самостоятельная кафедра восточных языков.

Позже, в конце 1828 г. – начале 1829 г., по инициативе в тот период ректора университета Николая Лобачевского создается Восточный разряд, в который вошли 2 кафедры – турецко-татарского и арабо-персидского языков,

сформированные на базе кафедры восточных языков. На кафедре турецко-татарского языка университета работали видные российские тюркологи: Мирза Александр Казем-Бек, Илья Березин, мусульманскую каллиграфию преподавал Мухамед-Галей Махмудов, а с 30-40-х гг. XIX века берет начало Казанская тюркологическая школа как научное направление. Основателями этой признанной во всем мире научной школы являются: Ибрагим Хальфин, Христиан Френ, Франц Эрдман, Александр Казем-Бек, Александр Троянский, Илья Березин, Мухамед-Галей Махмудов, Абдюш Вагабов, Мартеньян Иванов, Салихжан Кукляшев, Каюм Насыри, Николай Катанов, Василий Радлов и др.

С этих пор ученые Казанского университета активно развивают традиции Казанской тюркологической школы, одной из которых является традиция рассматривать содержание и структуру тюркских языков сквозь призму культуры.

Несколько слов скажу и о лингвокультурологии. Главной задачей этой науки является изучение и описание взаимоотношений языка и культуры, языка и этноса, языка и народного менталитета. Она создана на основе «триады» – «язык, культура, человеческая личность», её научный аппарат представляет собой своего рода увеличительное стекло, сквозь которое можно увидеть материальную и ментальную этническую самобытность.

Если вы решите серьезно заняться исследованиями в области тюркологии, лингвокультурологии, ученые-преподаватели кафедры общего языкознания и тюркологии Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета окажут всяческую помощь и поддержку.

Выражаю слова признательности за участие в работе конференции и желаю успехов во всех новых начинаниях!

*Заведующий кафедрой общего языкознания и тюркологии,*
*директор Института филологии и межкультурной коммуникации*
*Казанского федерального университета,*
*доктор филологических наук,*
*профессор* ***Замалетдинов Радиф Рифкатович***

**“Төрки лингвокультурология: проблемалар һәм перспективалар” халыкара фәнни-гамәли конференциясе эшендә катнашучы яшь дусларыбыз!**

Барчагызны да Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты коллективы һәм шәхсән үз исемемнән ихлас күңелдән сәламлим һәм конференция эшендә уңышлар телим!

2010 елдан бирле лингвокультурология мәсьәләләренә багышланып, Халыкара ана теле көне декадасында институтыбызда узучы яшь галимнәр конференциясе быел аерым әһәмияткә һәм мәгънәгә ия: ул Россия Федерациясендә “Фән һәм технологияләр”, моннан тыш, Татарстан Республикасында “Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге” елы планы нигезендә үтә. Конференциябез, һичшиксез, игълан ителгән елның максат-бурычларын уңышлы хәл итүгә, ягъни, төрле илләр һәм җирлекләрдә яшәүче төрки халыкларның ана телен саклау һәм үстерүгә, шулай ук фәнебез үсешен тәэмин итүгә үз өлешен кертер, дип ышанабыз.

Төрки халыклар чагыштырмача төрле телләрдә сөйләшсәләр дә, аларны уртак тел һәм әдәби, тарихи һәм мәдәни мирас берләштерә. Төрки лингвокультурология нәкъ менә шушы һәм, аеруча, бу халыкларның тел һәм мәдәнияте үзенчәлеген өйрәнүне максат итеп куйган фән юнәлеше.

Мәгълүм ки, халык мәдәниятенең бөтен нечкәлекләре аның телендә чагылыш таба. Лингвокультурологиянең төп максаты – тел аша билгеле бер халыкның, безнең очракта, төрки халыкларның менталитетын ачыклау. Бу – шактый катлаулы һәм күп вакыт, төрле дәрәҗәдәге тикшеренүләр уздыруны таләп итә торган процесс. Моның өчен өйрәнү объекты итеп алынган төрки халыкларның телен үзләштерергә, шулай

ук мәдәният, әдәбият, тарих һәм мәгариф системалары белән таныш булырга кирәк. Ышаныгыз: бу искиткеч кызыклы һәм сез тормышка ашыра алырлык мәсьәлә. Сездән бары тырышлык, күп уку һәм эзләнүчән булуыгыз сорала.

Чынлап та, бу юлны сайлап, әлеге эшкә алынырга ниятлисез икән, безнең уку йортының гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы укытучы-галимнәре Сезгә максатыгызга ирешергә ярдәм итәчәк.

Барыгызга да конференция эшендә катнашуыгыз өчен, рәхмәтебезне белдерәм, алга таба да элемтәләр сакланыр дигән өметтә калам!

*Казан федераль университетының*
*гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы мөдире,*
*Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр*
*институты директоры,*
*филология фәннәре докторы,*
*профессор* ***Рәдиф Рифкать улы Җамалетдинов***

# 1 НЧЕ СЕКЦИЯ

## ЫРЫМ ҺӘМ ЮРАУЛАРНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

*Әүхәдеев И., Саба р-ны Шәмәрдән лицее, X сыйныф*
*Җит. – Әүхәдеева А.В.*

Ырымнар “хорафат”, “тылсым” дигәнне аңлата һәм ниндидер гомумтөрки “ыр”тамырыннан ясала [1: 4]. Татар телендә ырым сүзе берничә мәгънәдә кулланыла:

1. Бик борынгы заманнардан калган фантастик ышануларга нигезләнгән гадәт, йола.

2. Аерым күренешләрдә һәм вакыйгаларда нәрсәне булса да алдан хәбәр итә торган тылсым көче бар дип юрау.

3. Борынгы ышанулар буенча җәмгыятькә, гаиләгә, табигатькә йогынты ясый торган тылсымлы чаралар.

Соңгы елларда басылып чыккан материалларга караганда, ырым халык арасында зур булмаган шигъри әсәр формасында йөри. Аны берничә төркемгә бүлеп йөртәләр:

1. Авыл хуҗалыгы эшләрен башкарганда әйтелә торган ырымнар.

2. Тормыш-көнкүреш вакыйгалары белән бәйле ырымнар.Мондый очракта гаилә мөнәсәбәтләрен җайга салу хакында сүз бара. Мәсәлән, янгынны туктату өчен, түбәндәге ырым сүзләре әйтелә: “Ут анасы күк була,Ут анасы сары була, Утның кызы камил була,кызына калгач кызу була” [3: 100].

3. Кайбер ырымнар тирә-як табигатьтәге куркыныч көчләргә яки мифологик явыз рухларга, мәсәлән, Су анасына, Су бабасына каршы юнәлтелгән була.

4. Әмма ырымнарның күпчелеге табиблык функцияләрен башкара.Аларның билгеле бер төркемнәре хакында К.Насыйри тәфсилләп язып калдырган иде. И.Гази “Мәүлия нигә көлде?”әсәре белән ырымга ышанган Мәүлияне көлкеле итеп сурәтли. М.Хәсәнов “Язгы аҗаган” әсәрендә юрау йоласын читләтеп үтми.

Гази, бала вакытында, яз көне аҗаган күрә. “Нәрсә юрасаң, шул булыр”, – дип юкка гына әйтмәгәннәрдер инде.Аҗаган күргәннән соң, Газига юралган язмыш, әлбәттә, аны урап узмый.

Әби-бабаларыбыз элек-электән су белән дәвалау ысулларын белгәннәр. Шәмәрдән бистәсендә яшәгән Хәлимә әби су белән дәвалауны киң кулланган.Аның әйтүенчә, суның файдасын әйтеп бетереп булмый.Мәсәлән, яңгыр суының, болыт белән килеп, яшьнәп яуганы әйбәт. Халыкта да: “Яшенле яңгырда чылансаң,сәламәт

булырсың”, [5: 60] дигән сүз бар.Борынгылар, чынлап та, яшенле яңгырга Күк алласының катнашы бар, дип санаганнар.

Юрамышлар – халыкның мифологик күзаллауларында мөһим урын тоткан жанр.Мәсәлән, “Өй түбәсенә козгын кунса, йортка бәла киләчәк”, – диелгән [2: 50]. Төшләрне юрау борынгыдан кулланылучы ырымнарның берсе булган.“Кыйссаи Йосыф” әсәрендә төш күрүләр, аларны юраулар бик күп. Бервакыт 11 яшьлек Йосыф кояшның, тулган ай һәм унбер йолдызның үзенә баш июен күрә.Төшнең мәгънәсен этисе болай юрый: “Син пәйгамбәр булырсың, зур дәүләт иясе булырсың, унбер туганың да сиңа хезмәт итәр”.

Төш юрау чарасын язучылар әдәбиятның төрле чорларында кулланалар. XX йөз башы әдәбиятында әлеге сурәтләү алымын үзенең “Сүнгән йолдызлар” әсәрендә К.Тинчурин уңышлы куллана. Сәрвәрнең әбисе төшне начарга юрый.Ятимлектә үскән Исмәгыйль әлеге төш тәэсирендә яши башлый.

Ышануларда татар халкының күзаллаулары гәүдәләнә:анда мифология персонажлары мөселман диненә бәйле карашлар белән “бер бәйләмдә бирелә”. Борынгы мәҗүси күзаллауларның ислам таләпләре белән аралашып килүе башка юрауларда да билгеле бер чагылыш таба. Мәсәлән, “Җомга көн кер, идән юарга ярамый” [1: 90]. Чөнки җомга – Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне, мөселманнар өчен изге көн.

Күзәтелә торган ышануларда да төш юрау җитди урын алып тора. Төш юрау йолаларының ерактан килүен нигезләп,кайбер мисалларга тукталыйк: төшеңдә “Агым су аша йөзеп чыксаң, кайгыдан арынасың” [5: 20].

Татар әдәбиятында ырым һәм юраулар киң өйрәнелгән. Бу өлкәдә бигрәк тә профессор М.Х. Бакиров зур көч куйган.

Ырымнар, кызганычка каршы, бүгенге көндә иҗат ителмиләр. Текстларда кулланылган бик борынгы сүзләрнең мәгънәләре бүгенге көндә аңлашылмый. Мәсәлән, “пискәк авыруы”, “кырмазы”, “комачау”, “мөшкәт”, “очан”, “неҗе” кебек авыру атамаларын очратырга мөмкин [5: 15].

Ырымнарны безне кызыксындырган ягы – аларда ялгызлык исемнәренең кулланылышы. Иң күп очраган исемнәрдән Гайшә һәм Фатыйма исемнәре тора [4: 10]. Кайбер текстларда Әйшә – Батман формасы да йөргән [4: 6].

Ырымнар белән бәйле рәвештә яңа исемнәр дә барлыкка килгән. Мәсәлән, Сатый, Сатлык, Саткы, Саткыл исемнәре моның ачык мисалы булып тора [4: 20]. Мондый исемнәрне баланың гомерен саклап калу өчен куша торган булганнар. Киләчәктә бу өлкәдә тикшеренүләр алып

барылыр, ырымнарны, юрауларны тел ягыннан өйрәнгән хезмәтләр язылыр дип ышанам.

**Әдәбият**

1. Бакиров М.Х. Ырымнар. – Мирас, 2003. – 696 б.
2. Мәхмүдов Х. Борынгылар әйткән сүзләр. – Казан: Фикер, 2002. – 432 б.
3. Мәхмүтов Х. Татар халкының афористик иҗаты. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1987. – 288 б.
4. Саттаров Г.Ф. Исемең матур, кемнәр куйган? – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 496 б.
5. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе: 3 том. – Казан: Мәгариф, 2011. – 388 б.

## ТЕЛНЕҢ ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛӘН ҮЗАРА БӘЙЛӘНЕШЕ

*Әүхәдиева Н., Казан, 171 нче мәктәп, X сыйныф*
*Җит. – Гомәрова Г.А., Гарәпшина Л.А.*

Кеше, җәмгыять һәм тел аерылгысыз төшенчәләр. Кешеләр үзара аралашып, берләшеп кенә көн күрә ала, ә аларның аралашу чарасы булып тел тора. Тел милләтне, халыкны һәм аның яшәешен билгеләүче төп күрсәткеч булып тора. Бүгенге алда торган бурычларны хәл итүдә без аңа аеруча игътибарлы булырга тиешбез. Хәзерге көндә кешеләр дөнья мәшәкатьләренә алданып, үткән тарихларын да, киләчәкләрен дә уйламыйча яши бирәләр. Нәтиҗәдә, туган телебез онытыла, ярлылана, бозыла, аның киләчәге дә билгесезлектә кала.

Тел үсеше һәм тел язмышы бүгенге көндә бик актуаль проблема. Бу барыбызны да борчыган мәсьәләләрнең берсе. Ни өчен туган телебез югала? Нигә кешеләр телебезне боза? Бу сорауларга без җавап табарга тырышырбыз. Безнең бүгенге тормышыбыз, уебыз, теләкләребез, гамәлебез бары бер генә максатка – милли телебезне саклау һәм аны үстерегә алып барырга тиеш. Тел ул – бөтен халык казанышы, меңнәрчә, миллионнарча кешеләрнең күпгасырлык иҗат җимеше. Тел төп аралашу чарасы буларак кешеләргә хезмәт итсә, сөйләм төп аралашу ысулы булып тора. Шунлыктан бүгенге көндә һәрбер телне мәдәниятара һәм шәхесара аралашу-аңлашу чарасы буларак укыту иң мөһим мәсьәләләрдән санала. Шуңа күрә дә телгә карата башбаштаклык кылырга, аның белән саксыз эш итәргә, аны үзеңә ошаганча бозарга беркемнең дә хакы юк. Тел – халыкның, милләтнең иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югалачак. Шуның өчен дә туган телне кадерләп саклап калу, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү – зыялы һәр кешенең изге бурычы булып тора.

Бүгенге көндә телебездәге ялгышларның күбесе татарларның, нигездә, ике телле булуы, ягъни туган телләрендә дә һәм рус телендә дә сөйләшүләре, язулары белән бәйле. Рус телендә эш итә торган татар

кешесе еш кына, үзе дә сизмәстән, туган теленә урынсызга рус сүзләре китереп кертә, һәм ул рус телендәге әйтемнәрне, сүзләрне ялгыш тәрҗемә итеп, туган тел өчен табигый булмаган әйтемнәр, сүзтезмәләр куллана башлый. Шулай итеп, татар телендә табигый булмаган, ясалма әйләнмәләрнең саны көннән-көн артып бара. Телнең бозылуы дәвам итә. Телебезгә кагылышлы мондый хәлдән котылу юлы – ике телле кешеләрнең ике телне дә яхшы үзләштерүләренә, һәр телнең үзенә генә хас үзенчәлекләрен белүләренә ирешү. Кызганычка каршы, татар теленең даирәсе кими. Татар бик практик халык. Әгәр дә кеше җәмгыятьтә татар теленә ихтыяҗ кимегәнен сизә икән, ул тиз арада үзенә кирәкле булганын үзләштерә. Бездә кеше кирәкме, юкмы – тел белән эш итәргә күнеккән. Андый караш булырга тиеш түгел. Тел ул – мирас, ата-бабаларыбыздан калган хәзинә, дәүләт эшләрен алып барырга, иҗат итәргә сәләтле корал. Туган телгә, мәдәнияткә мөнәсәбәтне бишектән үк тәрбияләү мөһим. Әгәр дә телгә карашыбызны үзгәртмәсәк, ул югала баруын дәвам итәчәк. Татар теле гаиләдә сакланып калырга тиеш дип билгеләп үтәргә яраталар. Безнеңчә, бар нәрсәне дә гаиләгә генә кайтарып калдырырга һич ярамый, дәүләт күләмендә дә чаралар күрергә кирәк.

Димәк, нәтиҗә ясыйк: иң элек милләттәшебез, бөек шәхесебез Садри Максуди сүзләре белән әйтсәк: “Телебезне өйрәнми башлаган көннән башлап, без бетә башлаячакбыз. Безнең бер милләт булып тора алуыбыз телебезне саклый алуыбызга бәйледер. Икенчедән, татар телен белгән кеше 30 дан артык төрки халык белән җиңел аңлаша һәм аралаша ала. Өченчедән, татарлар инглиз телен тизрәк һәм җиңелрәк өйрәнә, чөнки инглиз телендәге һ, ң, къ, гъ авазлары безнең телебезнең дә байлыгы булып тора. Дүртенчедән, телебезне чит илләрдән килеп махсус өйрәнүчеләр дә шактый бит. Казан дәүләт университетында Татар телен өйрәнү кафедрасы бар. Анда укырга Кытай, Вьетнам, Германия кебек илләрдән киләләр. Татар телен өйрәнү алар өчен төрки телләргә, төрки халыкларга чыгу, тарихны, тел үзенчәлекләрен өйрәнү өчен кирәк икән.

Безнең фикеребезчә, бөтен татар халкы ниндидер бер чик алдында тора. Әгәр без бүген берләшеп, яман сузләрне онытып, милләт язмышы, аның киләчәге турында ныгытып уйланмыйбыз икән, безнең хәлләр бик тә авыр булачак”. Без, туган телебезне, аның гореф-гадәтләрен, традицияләрен сакларга тиеш. Ул безнен төп бурычыбыз. Әгәр дә без туган телебезне яратып, аны ахыргы көннәргә кадәр саклап яшәсәк, димәк, – без бәхетле кешеләр. Ә бәхетле булу иң кирәкле сыйфат.

**Әдәбият**

1. Закирҗанов Ә.М. Яңарыш юлыннан: Хәзерге татар әдәбият белеме мәсьәләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 304 б.
2. Юсупов Р.А. Икетеллек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 223 б.

## ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНДӘ АК/КАРА КОМПОНЕНТЛЫ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР

*Вәлиева Л., Казан, 71нче мәктәп, IX сыйныф*
*Җит. – Гильметдинова А.Д.*

Тел хәзинәсенең мөһим бер асылташы булып фразеологик берәмлекләр исәпләнә. Алар теге яки бу халыкның тормыш-көнкүреш үзенчәлекләрен, аның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен һәм менталитетын чагылдыра.

Фразеологик әйтелмәләр аерым бер милләтнең үзенчәлеген чагылдырган кебек, төсләр дә халыкның дөньяга карашларын, билгеле бер күренешләргә мөнәсәбәтләрен җиткерә ала. Төрле халыкларның телләрендә һәм мәдәниятендә төсләрнең шул халыкка гына нисбәтле символик әһәмияте күзәтелә. Фразеологизмнарда очрый торган төс мәгънәләрен өйрәнү хәзерге тел белеменең актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Шуңа бәйле рәвештә тикшеренү эшебезнең максаты – татар һәм төрек телләрендә ак/кара төс компонентлы фразеологик әйтелмәләрне чагыштырма планда яктырту.

Ак төс иң яхшы, идеаль төс. Ул яктылыкны, сафлыкны, чисталыкны һәм ихласлыкны символлаштыра. Әлеге төс татар фразеологизмнарында бәхет һәм шатлык төшенчәләрен аңлата: ***алдыңа ак көн тусын*** *– теләк, якты киләчәк теләп, алкыш бирү;* ***ак бәхет (теләү)*** *– керсез, тапсыз, якты бәхет*; ***юлларыңа ак җәймә*** *– хәерле юл теләү.* Төрек телендә исә, мәсәлән, ***beyaz sayfa açmak*** *(букв. ак бит ачу)* фразеологик әйтелмәсе үткән тормыштагы күңелсезлекләрне онытып, киләчәккә өмет белән карап, яңа тормыш башлау, дигән мәгънәгә ия.

Татар һәм төрек фразеологизмнарында ак төс сыекча белән ассоциацияләнә: ***ак күмер – beyaz kömür*** *(электр тогы бирү өчен буадан турбинага төшә торган су);* ***ак су*** *– 1) таулардан агып, кардан яки боздан ялралган су, 2) ак аракы;* **beyaz kuvvet** *(букв. ак көч) - су көче.*

Кайбер фразеологик берәмлекләрдә ак төс кешенең уңай сыйфатларын белдереп килә: ***ак күңелле*** *– чиста күңелле, ихлас, саф кеше;* ***ак йөзле*** *– намуслы, керсез, гөнаһсыз, гадел кеше.* Төрек телендә кешенең уңай, күркәм сыйфатларын тасвирлаганда фразеологизмнарда ак төс белән бөтенләй башка образлар кулланылганы күзәтелде: ***alnı ak*** *(букв.маңгае ак) – гадел кеше*; ***iki cihanda yüzü ak olmak*** *(букв. ике*

*җиһанда йөзе ак булу) – дөрес, гадел юлдан тайпылмау*; ***ak süt emmiş*** *(букв. ак сөт имгән) – эчкерсез, саф, ихлас кеше.*

Фразеологизмнар арасында ак төснең тискәре мәгънәләрне белдергән очраклар да юк түгел. Мәсәлән, татар телендә ак төс фразеологизмда авыруны белдерергә мөмкин: ***ак төшү*** *– күзнең ак яры белән каплануы*. Шулай ук ***ак җеп белән генә типшегән*** *( берәр нәрсәне ипсез рәвештә аннан-моннан гына күздән яшереп маташу, яшерүе беленеп, күренеп тору),* ***ак кул*** *(ялкау, эшне сөймәүче кеше)* кебек фразеологик әйтелмәләре дә тискәре семантикага ия. Төрек телендә ак төснең начар, тискәре мәгънә белдерү очраклары: ***ak gözlü*** *(букв.ак күзле) – 1) җирәнгеч, күңел болгандыргыч, 2) каты күзле, күз тидерүчән;* ***ak sadeler giyimek*** *(букв. ак саф кием кию) – үлү;* ***beyaz bayrak çekmek*** *(букв. ак байрак болгау) – авырлыклар алдында җиңелү, югалып калу*. Кара төснең бай семантикасы татар һәм төрек әйтелмәләрендә гаять күп чагылыш тапкан. Кара төс начар төсмергә ия, кеше аңына тискәре йогынты ясый. Мәсәлән, татар һәм төрек телләренең кайбер фразеологик берәмлекләрендә кара төс негатив күренешләрне һәм төшенчәләрне кочәйтеп килә: ***кара гайбәт*** *– бик начар, әшәке гайбәт;* ***кара ачу*** *– хайвани ачу,* ***кара талаш*** *– ямьсез, тупас кычкырыш;* ***кара гүргә керү*** *– үлү*. Төрек телендә, мәсәлән: ***kara sevda*** *(букв. кара мәхәббәт) – җавапсыз мәхәббәт;* ***kara yas*** *(букв. кара матәм) – моң-зар, кайгы-хәсрәт;* ***kara bela*** *(букв. кара бәла) – бәхетсезлек очрагы.* Биредә тулы тәңгәллекле фразеологизмнарны билгеләп үтергә кирәк: ***кара бәхет – kara baht*** *(тискәре тәкъдир, уңышсыз язмыш, җәфалы гомер),* ***кара хәбәр – kara haber*** *(күңелсез хәбәр),* ***кара көн – kara gün*** *(бәхетсез көн, башка бәла төшкән көн);* ***кара болыт булып йөрү – kara bulut gibi geçmek*** *(кара чырай белән ачу күрсәтеп йөрү);* ***араларыннан кара мәче үтү – aralarına kara kedi geçmek*** *(бик каты талашу, дошманлашу).*

Кара төс шулай ук кешенең әхлакый яктан тискәре сыйфатларын, гамәлләрен тасвирлый: ***кара эчле*** *– тыштан яхшы күренеп тә, эчендә яшерен үч һәм ачу сакланган, мәкерле кеше;* ***кара йөрәкле*** *– кешегә начарлык теләүче, сатлык, залим кеше;* ***кара елан*** *– дорфа, мәкерле, имансыз кеше.*

Төрек телендә исә кешенең тискәре сыйфатларын ачыклап килгән фразеологик әйтелмәләр бихисап һәм алар күпкә образлырак. Мәсәлән, ***kara sakız gibi yapışmak*** *(букв. кара сагыз кебек ябышу) – бәйләнчек кеше;* ***kardeş değil kara taş*** *(букв.кардәш түгел кара таш) – мәрхәмәтсез дус;* ***on parmağında on kara*** *(букв. ун бармагында ун кара) – явыз, гөнаһлы кеше;* ***kara ağızlı*** *(букв. кара авызлы) – гайбәтче, яла ягучы кеше.*

Әлбәттә, кара төснең татар һәм төрек фразеологизмнарында уңай яклары да бар. Әйтик, татар телендә кара төс, мәсәлән, бик матур кадерле һәм кыйммәтле мәгънәләрне белдерергә мөмкин: ***тумра кара*** *– елкылдап торган кара;* ***күзем карасы*** *- күреп, сокланып туеп булмый торган кадерле, җаннан газиз ;****кара каш*** *- йөзгә матур;* ***кара ташны как яру*** *– үткенлек, булдыклылык.* Төрек телендә дә уңай коннотациягә ия булган фразеологизмнар күзәтелде: ***kara dağ gibi*** *(букв. кара тау кебек) – көчле, куәтле кеше*; ***kara gün dostu*** *(кара көн дусты) – авыр чакта ярдәм итүче, мәрхәмәтле дус*; ***gözü kara*** *(букв. күзе кара) – батыр, куркусыз;* ***kara gözler için*** *(букв.кара күзләр өчен) – матур күзләре өчен.*

Шулай итеп, нәтиҗә ясап әйткәндә, ак һәм кара төс татар, төрек телләрнең фразеологизмнарында киң кулланылыш алган. Төсләрнең символикасын һәм үзенчәлекләрен тирәнтен өйрәнү безгә мәдәниятне, сәнгатьне, төрле халыкларның милли үзаңын, гореф-гадәтләрен аңларга ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. – 176 б

2. Ахунзянов Г.Х. Фразеология как раздел татарского языкознания // Вопросы татарского языкознания. – Казань, 1971. – С. 76-86.

3. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001.– 335б

4. https://www.dersimiz.com/deyimler-sozlugu/

## ПЕРЕВОД И СРАВНИТЕЛЬНЫЙ АНАЛИЗ ТЕКСТА НА ТАТАРСКОМ РУССКОМ, АНГЛИЙСКОМ ЯЗЫКАХ

*Валиуллин И., Казань, СОШ №171*
*Рук. – Гарапшина Л.А., Закирова Н.Ф.*

В своей работе мы хотим произвести сравнительный анализ языковых особенностей при переводе произведений «Санаулы көннәр» и «Тынычлану» на русский и английский языки. Актуальность данного исследования следует из необходимости изучения проблем перевода художественного текста.Целью данной работы является проведение сравнительного анализа переводческих трансформаций на примере рассказа А. Еники «Тынычлану» («Умиротворение» (в переводе А. Бадюгиной), «Успокоение» (в переводе Р. Кутуя и С. Хозиной) и «Считанные дни» (в самостоятельном переводе). Задачи: определить особенности перевода художественного и публицистического текстов, выявить основные критерии для оценки качества, исследовать особенности вариантов перевода, произвести анализ переводческих трансформаций, используемых авторами переводов. И, опираясь на

уже существующие тексты, сделать собственный перевод. При выполнении данной работы были использованы методы исследования: обработка и анализ научных источников, описательный метод, метод обобщения, метод сравнительно сопоставительного анализа. В ходе исследования произведений мы пришли к выводу о том, что автор использует практически все разновидности изобразительно-выразительных средств языка.

Перевод произведений А. Еники представляет особую трудность. Это связано с тем, что язык писателя колоритен, в нем проявляется все лексическое и стилистическое богатство татарского языка. И хотя произведение «Считанные дни» не является художественным, а публицистическим, здесь так же, как и в художественном тексте «Успокоение», присутствуют эпитеты, метафоры, сравнения, фразеологизмы и олицетворения. Главной особенность художественной литературы является эмоциональность, контраст, использование слов с переносным значением, специальные синтаксические конструкции. Проанализированный нами материал показал, что своеобразие и специфические особенности одного языка глубже раскрываются при сопоставлении с другими языками, анализ позволил выявить как общие черты в устойчивых сочетаниях татарского и русского языков, так и отличительные признаки в их семантике и структуре, что является важным для решения конкретных задач сопоставительного изучения неродственных языков.

Особый интерес представляет вопрос о передаче фразеологических единиц с языка оригинала на русский язык, так как именно они, по справедливому утверждению В.Н. Телия, ассоциируются с культурно-национальными эталонами, стереотипами, воспроизводя характерный для той или иной лингвокультурной общности менталитет. Именно в этом и заключается одна из сложностей передачи фразеологизмов, ведь в переводе важно сохранить национальный способ мышления, его логический процесс. Эти особенности произведения возможно воссоздать лишь глубоко, постигнув национальный характер, что требует от переводчика особых фоновых знаний и специфического подхода к каждому конкретному случаю. Без учёта этих особенностей значение фразеологизма, известное носителям одного языка, может быть совершенно непонятно носителям другого.

**Литература**

1. Еники Ә. Тынычлану // Сайланма әсәрләр. – Казан: Хәтер, 2002. – 41 б.

2. Еники А. Умиротворение // Повести и рассказы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. – 25 с.

3. Зиннатуллина Г.Х. Поэтическая ономастика прозы А.Еники: автореф. дис. канд. филол. наук. – Казань, 2005. – 25 с.

# БАЛТАЧ РАЙОНЫ ЧУТАЙ АВЫЛЫ ТОПОНИМНАРЫНА ФИН-УГЫР ҺӘМ ТӨРКИ ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ЙОГЫНТЫСЫ

*Габделхаков Р., Казан, 90 нчы гимназия, X сыйныф*
*Җит. – Габделхакова Г.Р.*

Туган авылым Чутай Балтач районының иң төньяк өлешенә, Киров өлкәсе белән чиктә, калкулы тигезлектә урнашкан. Олылар сөйләвенә караганда, Чутай авылы якынча 900 еллар элек барлыкка килгән. Башта авыл урынына өч гаилә марилар килеп утырган. Шуңа бәйле рәвештә, академик Гомәр Саттаров Чутай авылының исеме дә мари теленнән тәрҗемә иткәндә “сута”- “яктылык”, “нур” дигән мәгънә аңлата ди. Явыз Иванның яулап алу һөҗүмнәре башлангач, авылга хәзерге Арча районы Хәсәншәех авылыннан уналты хуҗалык татарлар килеп урнашкан. Авылда ике төрле дин барлыкка килгән. Ләкин вакытлар үтү белән, марилар да ислам диненә күчеп, мөселман булып киткәннәр. Чутай авылы 18 гасырның 2 нче яртысында Вятка губернасының Уржум өязенә караган волость үзәге (1797 ел), соңыннан шул ук губернаның Малмыж өязенә кергән волость үзәге (1816) булып тора.

XIX гасыр мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәт тә үзенең “Мөстәфәдел-әхбар фи әхвали Казан фә Болгар” китабында Чутай авылының укымышлы кешеләренә югары бәя биргән.

Авылым халкы электән үк җир эше, игенчелек белән шөгыльләнгән. Чутай халкының күршедәге башка авыл кешеләренекеннән үзгә һөнәрләре булган һәм хәзер дә бар. Авылымда данлыклы һөнәрчеләр: пыялачылар, ташчылар, балта осталары, миччеләр, кыса ясаучылар күп булган. Алар күрше авылларга, чит өлкәләргә чыгып эшли торган булганнар. Таштан салынган келәтләрнең авылда бүген дә дүрт – бише сакланган, бүгенге мәчетебез дә шул заманда салынган. Хәзерге көнгәчә бу биналарның бер җире ярылмаган, бер җире иңмәгән. Заманында Казан шәһәренең Арча янындагы хәрби училище казармаларын да Чутай ташчылары салган. Әле хәзер дә авылда тирә-юнгә даннары таралган мич чыгаручылар, ташчылар бар.

Туган авылым Чутай – гаҗәп кызыклы һәм үзенчәлекле авыл. Ул ике этник дөньяның фин – угыр (марилар) һәм төрки (татарлар) халыкларның “контакт зонасы”. Менә шул ике халыкның теле чал тарих дәвамында безнең төбәкнең үзенчәлекле топонимиясен

тудырган, аларның үзара ныклы керешүләрен, бер -берсенә сизелерлек йогынтысын китереп чыгарган. Шул сәбәпле, безнең авылның географик атамалары да үзенчәлекле. Авылыма кагылышлы тарих сәхифәләрен актарганда, бездә үзебезнең авылдагы топонимнарны өйрәнү теләге туды.

Топонимия географик атамаларны өйрәнә, аларның килеп чыгышын аңлата. Һәрбер җирлектә географик атамаларның гаять кызыклы, бай тарихы, барлыкка килү традицияләре бар. Географик атамаларның барысы да онытылып беткәнче, җыеп туплау иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора.

Безнең төбәк авыллары тиешенчә өйрәнеп бетмәгән, фәнни чыганаклар бик аз. Шуңа да материалны төрле юллар белән тупладык. Авылга чыгып, олы кешеләр белән очрашу, сүзлек, карта һәм башка чыганаклардан файдаландык. Эшне башкарганда Балтач районы Чепья авылында эшләп килүче “Халыклар дуслыгы” музее һәм Нөнәгәр авылындагы “Кәшифә Тумашева исемендәге мәктәп музее”ннан алынган мәгълүматларны кулландык. Шулай ук әлеге өлкәне әйдәп баручы Г.Ф. Саттаров, Ф.Г. Гарипова хезмәтләреннән файдаланылды.

Географик атамалар җәмгыятьнең үсеш законнары белән үзара тыгыз бәйләнеш нәтиҗәсендә туганнар. Чутай авылындагы топонимнар ясалыш чараларының байлыгы, лексик-семантик төркемнәрнең төрлелеге белән характерлана. Г.Ф. Саттаров хезмәтләренә таянып, төбәгебездәге атамаларны ике төргә бүлдек. Табигый географик терминнар (елга, күл, чишмә, инеш, тау, басу, болын атамалары) һәм ясалма географик терминнар (шәһәр, авыл, һәм аларның өлешләрен (урам, тыкрык, очларны белдерә торган атамалар) [4: 440].

Безнең Чутай авылы да ике елга арасына, табигатьнең иң матур урынына урнашкан. Чутай авылы каршында биек тау җәелеп ята, тау кырыенда куе урман, ә тау итәкләре чишмәләргә бик бай. Аларның һәрберсенең үз тарихы бар. Мәсәлән: Ерак чишмә – авылдан ерак урнашканга күрә “ерак чишмә”, – дип йөртәләр. Ялкаулар чишмәсе – авылга бик якын, шуңа күрә анда ялкаулар йөри дип саналган. Икенче төрле Фәттах чишмәсе (Фәттах бабай казыганга) дип тә йөртәләр.

Авыл кырыеннан Кубыр һәм Шушма елгалары ага. Шушма – мари сүзе, инеш мәгънәсен белдерә. Элек безнең тирәдә гел мари авыллары булган. Шуңа бәйле рәвештә, топонимнарда мари сүзләре сакланып калган.

Ерганакларга килгәндә, авылдан ерак түгел Байтирәк елгасы бар. Ярлары тирәккә бай булганга, елга исеме дә шуннан алынган. Ар елгасы – удмурт авылы янында урнашканга шулай атала. Елга буенда печән бик мул үсә. Чутай авылының печән җирләре шунда урнашкан.

Кирәмәт өсте басуы марилар кушкан исем. Ул әле хәзер дә шулай дип йөртелә.

Авылым тирәсендә таулар да шактый. Шул тауларның берсе - Кубыр тавы. Элек бу тауның өстендә бик зур Кубыр исемле урыс авылы булган. Мәктәпкә укырга да, рус телен өйрәнергә дип, шушы авылга йөргәннәр. Хәзерге вакытта бу авыл юкка чыккан. Кубыр авылыннан ерак та түгел Киров өлкәсе Йөрек авылы урнашкан. Шуңа күрә Кубыр тавы янындагы тау Йөрек тавы дип атала. Ә Бакыр тавы итәгеннән бакыр ятмалары табылган. Ләкин әле яшь дип, эзләнү эшләрен туктатканнар, ә тау Бакыр исеме белән аталып калган.

Авылымның берсеннән-берсе матур урамнары бар. Мәсәлән: “Күпер башы” – урамның бер башы елга аша салынган күпергә тоташа. Шуңа бу урамны “Күпер башы” яки “Капка ягы” урамы дип атыйлар. Элек бу тирәдә авыл капкасы булган. Капканы ябып куя торган булганнар. Авылдан рөхсәтсез чыгып китәргә ярамаган.

XX гасыр урталарында документта Чутай авылы урам, тыкрыкларына Салих Сәйдәшев, Пионер, Киров, Комсомол, Габдулла Тукай дигән исемнәр бирелгән. Ләкин авыл халкы сөйләмдә электән килгән, авыл тарихын чагылдырган атамаларны куллана.

**Әдәбият**

1. Балтач районы энциклопедиясе. II том – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 567 б.
2. Гарипова. Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1997. – 234 б.
3. Салихҗан Х.Г. Чутай бабай малайлары. – Казань – ПИК “Идел Прес”, 2020. – 366 б.
4. Саттаров Г.Ф. Татар топонимиясе – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1998. – 440 б.

## М. ЮНЫСНЫҢ “ЮЫЛГАН МӘХӘББӘТ” ХИКӘЯСЕНДӘ ИНТЕРТЕКСТУАЛЬЛЕК

*Гарипов К., Казан, 144 нче мәктәп, VIII сыйныф*
*Җит. – Төхвәтуллина Л. Р., Җиһангәрәева Л.Һ.*

М.Юнысның әдәби мирасын өйрәнгәндә, мәдәниятләр багланышын истә тотып, Л.Н. Толстой иҗаты белән чагыштырырга була. Интертекстуальлекнең берничә формасы бар: цитация, ягъни күп цитата куллану формасы. Гадәттә аны фәнни хезмәтләрдә кулланалар. Башка авторның текстын кыек сөйләм рәвешендә сөйләп бирү. Элек әйтелгән фикерләргә, теория-идеяләргә сылтама бирү. Аллюзия – стилистик фигура, өземтә китерүнең бер төре. Киная ярдәмендә автор тексты һәм чыганак-текст арасында элемтә урнаштыру.

Нәтиҗә ясап, шуны ассызыклау кирәк: һәр текст интертекст булып тора ала. Һәр текст иске цитаталардан тукылган яңа тукыманы хәтерләтә. Әлеге ике әсәрне образлар, сюжет-композициясе ягыннан чагыштыргач, шундый нәтиҗә ясарга була:

1. Ике әсәр дә кыска хикәя жанрында язылган. Авторларның экзистенциаль гомумиләштерүләре һәм автобиографик геройларның истәлекләре бирелгән. Л.Н. Толстойда – Иван Васильевичның яшьлек белән әңгәмәсе, ә М. Юныста – укучы белән Габдрахман Рахманкулов арасындагы әңгәмә.

2. Ике әсәрдә дә композиция шартлы рәвештә ике өлешкә бүленә: вакыйгага кадәр һәм вакыйгадан соң. Л. Толстойда әлеге вакыйгага киртә булып бал тора. Шуннан чыгып, сурәтләнгән күренешләрне ике өлешкә бүлеп карарга мөмкин: балга кадәр һәм балдан соң.

М. Юныста исә әлеге киртә ике тапкыр кабатлана: 1) патрульгә эләккәнчегә кадәрле бәхетле чор һәм эләгүдән соң башланып киткән бәхетсезлек чоры; 2) Ленаның әнисе белән очрашканга кадәрле чор һәм ваннада юынып чыкканнан соң булган чор. 3.Сюжет линияләренең схемасы да охшаган. Төп геройлар менә дигән чибәр кызга гашыйк булалар, ләкин кызның әти-әниләре белән танышу аларның хисләрен сүндерә, өметләре өзелә, күңелләре кайта. 4. Л.Толстой кызның әтисен, аның эш-гамәлен сурәтләсә, М.Юныс аны кызның әнисенә “үзгәртә”. Шул рәвешле, әсәрнең пафосы да үзгәрә. 5.М.Юныс әсәрләрендә Лев Толстой исеме телгә алына, “Балдан соң” хикәясе аллюзия буларак кулланыла. Димәк, Л.Толстой укучыга әдәби код буларак кабул ителә. Толстойның әсәре прототекст буларак кулланылса, М.Юныс хикәясе метатекст санала. Аңлашылганча, ике әсәр дә автобиографик характерда.Ике әсәрне чагыштырсак, шундый әдәби уен күрергә мөмкин:биредә метатекст бары тик кабатлау гына түгел, ә протекстның дәвамы. “Балдан соң” хикәясе качкын татар солдатының тоткарлануы белән төгәлләнә, ә “Юылган мәхәббәт” әсәре татар егете лейтенант Габдрахман Рахманкуловның тоткарлануы белән башланып китә”. М. Юныс үз әсәрендә интертекст, ирония, әдәби уен алымын кулланып, үзен постмодернистик әдәбият остасы итеп күрәтте. Моны аның башка әсәрләрендә дә күрергә мөмкин. Реалист язучы буларак, Л.Толстой кеше өчен нәрсә яхшы, ә нәрсә начар икәнлеге турында уйлана, кеше тормышындагы фаҗигалар, трагик вакыйгалар, мохит кеше язмышын үзгәртә ала дип исәпли ала. Ни өчен соң автор интертекст куллана? Галим В.Е.Халезов фикеренчә, “интертекстуальлек” – күренекле һәм үзенчәлекле [оригиналь] язучылар иҗатының казанышы. Л.Н.Толстойның “После бала” (“Балдан соң”) һәм М.Юнысның “Юылган мәхәббәт” хикәяләрендә интертекстуальлек контекстын караганнан соң, шундый нәтиҗәгә киләбез: 1. интертекст – мөһим әдәби алым, ә укучының бурычы – аның мәгънәсен, функциясен аңлау. Интертекст - язучы белән укучы

арасындагы яшерен диалог ул. 2.протекст булып Л.Н.Толстой әсәре, ә метатекст булып М.Юныс хикәясе санала. Ике әсәр арасында аллюзия – киная ярдәмендә автор тексты һәм чыганак-текст арасында элемтә урнаштыру күренеше күзәтелә. М.Юныс Л.Толстойның әсәрен яхшы белгән, әсәр төзелешендә Толстой алымнарын отышлы, аңлы рәвештә кулланган. Бу сюжет-композиция, идея-тематик, образлар бирелешендә күренә. 3. бер әсәргә карап кына, язучының әдәби методын бәяләп булмый. Тик шуны әйтү зарур: М.Юныснының "Юылган мәхәббәт" әсәрендә постмодернистик әдәбият элементлары күренә, ягъни интертекст, ирония, әдәби уен алымнары кулланыла һәм интертекстуальлекнең берничә формасы (элек әйтелгән фикерләргә, теория-идеяләргә сылтама бирү, аллюзия һ.б.) функциясе (апелятив, поэтик (уен), экспрессив функциясе чагылыш таба. Гомумән, ике язучы да – реалист язучы буларак Л.Толстой да, романтик рухлы М.Юныс та, реалист язучылар буларак, кеше тормышындагы гадәти бер вакыйга, мохит, кеше язмышын үзгәртә ала дип исәплиләр һәм укучыга шуны җиткерәләр.

**Әдәбият**

1. Заһидуллина Д.Ф. 1960-1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр: монография. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. – 383 б.

2. Кузьмина Н.А. Интертекст и его роль в процессах эволюции поэтического языка. – Екатеринбург, Омск, 1999. – 268 с.

## ОБ АВТОРСКИХ ИНТЕРЪЕКТИВИЗМАХ В ТАТАРСКОМ И АНГЛИЙСКОМ ЯЗЫКАХ

*Минегалиева А., Казань, СОШ № 22 – ЦО*

*Рук. – Нигметзянова А.Р.*

Современное общество развивается, а вместе с ним совершенствуется и язык. Лексика каждого языка богатеет. Это же происходит и с междометиями. В «Толковом словаре татарского языка» (2005) можно найти 173 интеръекционные единицы. Но существует группа интеръективизмов, незафиксированная ни в одном словаре, которые называются авторскими. Они являются индивидуальными для каждого автора. Иногда такие междометия могут быть характерной чертой писателя, которая выделяет его среди всех остальных. Количество таких интеръективизмов неизвестно. Так, например, Г. Камал в своем произведении «Бәхетсез егет» употребляет междометие «Пуф», хотя в том же словаре можно найти его эквивалент «уф»: *Пуф! Шунда бер-ике адым җиргә, Иван Фидрычка барырга иренгән бит! Пуф!.. Пуф!* (Г. Камал). Пуф! Пару шагов поленился сделать, чтоб дойти до Ивана Федоровича! Пуф!.. Пуф'. Из этого

примера видно, что междометие «*Пуф*» выражает негодование, раздражительность, так же, как и «*уф*», но автор предпочел изменить интеръективизм, тем самым показал более яркую эмоциональную окрашенность.

Таким образом, писатели, используя авторские междометия, достигают наиболее яркого эмоционального эффекта, усиливая его благодаря дополнительным звукам и в некоторых случаях нестандартного графического строя интеръекционной единицы. Например: *Шифырт, шифырт! Итәкләрегезгә абынып егылмагыз!* (Г. Камал). 'Тсс, Тсс! Не споткнитесь об свои юбки!'. В этом примере междометие «*Шифырт!*» равносильно «тсс», используемое в значении «не шумите», «тихо». Автор привлекает внимание читателя, используя большее количество букв, тем самым фонетически обогащает его. Таким образом, увеличивая количество букв, т.е. звуков в интеръекционных единицах, достигается эффект поддержания внимания читателя, автору удается заинтересовать его еще больше. Отметим, что некоторые междометия могут использоваться как в положительном, так и в отрицательном значениях. Поэтому следует обратить внимание на контекст, ведь иногда без него сложно понять, что хотел сказать автор. Например: *Уһу! Сразу югары менеп китте!* (Г. Камал). 'Ого! Так сразу высоко поднялся!'. В этом примере сложно понять, что именно выражает герой: удивление, огорчение, досаду, радость, разочарование. Следует обратиться к тексту, чтобы понять: *Лоточы: Дүртенче уен, малый – алтмыш, бальшуй – бер сум егерме биш тиен. Кара киемле: Хәзер уенның тәме китте инде... Лоточы: 60! Кәрим: Уһу! Сразы югары менеп китте!* (Г. Камал). 'Ведущий: Игра четвертая, малая – шестьдесят, большая – один рубль двадцать пять копеек. Человек в черном: Сейчас начнется самое интересное… Ведущий: 60! Карим: Ого! Так сразу высоко поднялся!'. Из контекста данного примера интеръективизма можно понять, что автор описывает удивление, неожиданность, он не употребляет междометие «ого», «ах» или «опа», возможно при помощи данного междометия автор хочет создать комичную ситуацию, что возможно это сделать при помощи авторских интеръекционных единиц.

Татарский язык имеет несколько видов диалектов, которые зависят от местонахождения носителя языка. От этого фактора также зависит образование авторских междометий. Например, в ТТАС (1977-1981) нет интеръективизмов на букву Җ, у некоторых авторов же они наблюдаются. Например: *Җә, син, егет, тизрәк бул* (Г. Камал). 'Ну, ты, парень, давай быстрее'. Вместо привычного «йә» автор употребляет «җә», хотя лексически они несут одинаковую нагрузку.

В английском языка также можно обнаружить авторские междометия. Например: *Ar-r, said Jem softly, lifting his foot* (H. Lee). ʽХм, сказал тихо Джем, подняв ногуʼ. Данного интеръективизма нет в толковых словарях английского языка и его значение следует понимать только исходя из контекста. В данном случае он подразумевает растерянность, задумчивость. Отметим и его графическое изображение. Автор удвоил согласную *r* для привлечения внимания и усилил эффект задумчивости. Некоторые авторы предпочитают употреблять диалектные междометия, которые свойственны народу, проживающему на определённой территории. Например: *Sho, there's ticks a-plenty* (M. Twain). ʽТьфу, там много пометокʼ. Междометие «*sho*» равносильно интеръективизму «*pshaw*», однако в словарях их нет. Поэтому, опираясь на контекст, можно определить, что данная интеръекционная единица «*sho*» выражает недовольство, неудовлетворение. Для выражения восклицания в английском языке употребляются такие междометия, как «*Ach!*», «*Ah!*», «*My god!*». Однако некоторые авторы предпочитают употреблять свои авторские интеръективизмы. Например: *Three of 'em! Lordy, Tom, we're goners! Can you pray?* (M. Twain). ʽТрое из них! Боже, Том, мы доходяги! Ты умеешь молиться?ʼ. Междометия «*Lordy*» и «*My God*» семантически несут равную окраску, но в данном случае автор предпочел свой интеръективизм для усиления эмоций и создания более ироничной речевой ситуации, используя на конце междометия букву «*y*». Рассмотрев подробнее варианты междометий, выражающие восклицание, были обнаружены следующие авторские интеръективизмы: *by Jackson* ʽчерт возьмиʼ, *My George* (=*My* God) ʽО Божеʼ, *Dang it* (= *damn it*) ʽОго, блинʼ, *Great guns, great Caesar's ghost* ʽНичего себеʼ, *My kingdom, my souls* ʽсвятой божеʼ, *Goodness sakes, for goodness sake* ʽГосподь с вамиʼ. Например: *My George! It's the beatenest thing I ever struck* (M. Twain). ʽМой Бог! Это самая удивительная вещь, которой я был пораженʼ; *It warn't locked! I hopped in, and shook off the towel, and, great Caesar's ghost!* (M. Twain). ʽОн не закроется! Я вскочил и, встряхнув полотенце, очень удивился!ʼ.

Таким образом, авторские междометия, являясь малоизученным аспектом языка, образуют группу интеръективизмов, которая фонетически и графически различается от наиболее употребляемых интеръекционных единиц. Авторы используют их для создания большей эмоциональной нагрузки для привлечения внимания читателя или слушателя.

**Литература**

1. Смирницкий А.И. Лексикология английского языка. – М.: Наука, 1956. - 260 с.

2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: т.1-4.- Казан: ТӘhСИ, 2015-2018.
3. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. – Казан: Мәгариф, 2006.

## Ә.НҰРМАҒАМБЕТОВТІҢ «БЕС ЖҮЗ БЕС СӨЗ» ЕҢБЕГІНДЕГІ ТАҒАМ АТАУЛАРЫ

*Абибуллаева А., Әл-Фараби атындағы Қазақ ұлттық университеті, ІІІ курс студенті*
*Ғыл. жетек. – филол. ғ. к. Қортабаева Г.Қ.*

«Көне тамырлы этнолексика – халықтың этномәдени тарихы және тілдік процестері мен тілдік шығармашылығы туралы баға жетпес «ақпарат көзі», – деп жазады профессор Ж.Манкеева. [1: 263].

Көнерген сөздер – күнделікті қарым-қатынаста жиі қолданылмайтын, бірақ тілдің сөздік қорында сақталған, көпшілікке түсінікті сөздер. Көнерген сөздер көнелену дәрежесі мен себебі және қолданылу сипатына қарай өзіндік лексика жүйесін құрайды.

Көнеру дәрежесі бойынша: мағынасы түсініксіз сөздер [байыз – байыз табу, кежеге– кежегесін кейін тарту]; мағынасы түсінікті, бірақ сирек қолданылатын сөздер [бәйбіше, қатын, мыстан, алдаспан] болып бөлінеді.

Сөз төркінінің анықтауымен арнайы айналысып, кітаптар жазған тілші ғалым Ә.Нұрмахамбетов те сөз мағынасының дамуының қоғам дамуымен тығыз байланысты екенін айтады. Оның «Сөз сырына саяхат», «Қос сөздердің құпиясы», «Бес жүз бес сөз» аттты еңбектері бар.

«Сөз мағынасының тарихы қоғам тарихымен тығыз байланысты. Дәлірек айтқанда, қоғамның әр дәуірінде дамуына қарай сөз мағынасы да соған сәйкестене отырып, ілгері дами түседі» [2: 3], - дейді ғалым.

Атап айтсақ, қыс бойы негізінен алғанда ет тағамдарымен ғана тамақтану салдарынан организмнің биохимиялық балансы қышқылдыққа қарай ауытқыса, осы сәйкессіздік кейін, ақ молайған шақта сүт өнімдерінен жасалған тағамдар арқылы калыпқа келтіріледі. Демек, алты ай қыста қатал табиғат сынына, өмірі аттың жалы, түйенің қомында жүріп өтетін көшпелінің тұрмыс тауқыметіне төтеп беруге нәрлі де, қуатты ет, сүт тағамдарының негізгі азық болуы – табиғи қажеттілік.

Көнерген сөздердің мағынасын айқындау тарих ғылымы үшін де қажет. Көнерген сөздер көне ақпараттар көзі ретінде белгілі бір тарихи кезеңге қатысты мол мәлімет береді. Бұл орайда тілші ғалымдардың мына пікірі өте орынды айтылған деп білеміз. «Біле білсек, оның тұла бойы тұнып тұрған тарих. Сөз байлығының қат-қабат қойнауларын

тереңірек тексеріп, ақтара зерттесек, олардың өткен өміріміз жайлы берер мәліметі, шертер сыры аз болмаса керек» [3: 81-82].

Дақылдардан жасалатын тағамдар:

***Ботқа***. Күріш, тары т. б. жармадан бөктеріп жасалатын қою тағам. Азғана дыбыстық ауытқулармен бұл сөз осы мағынада *якут, тува* және басқа біршама түркі тілдерінде кездеседі. Э. Севортянның айтуынша, кейбір ғалымдар «ботқа» сөзінің негізі калмақ тілінде «*араластыру*», «*аударыстыру*» мағынасын беретін етістік «***бутхаха***» болар деген жорамалға бой ұрады [3, 1978, 201]. Ә. Нұрмағанбетов «Біздің байқауымызша, «ботқа» сөзінің алғашкы төркіні соны жасайтын дәнді дақыл атымен байланысты болса керек. Тұңғыс-маньчжур тілдерінде «***буда***» сөзінің жарма, ботқа [каша] мағыналарынан басқа «тары» дегенді де ұғындыратындығын көреміз» дейді. [2, 56].

***Тары-талқан***. Қазіргі кезде бұл қос сөз мағынасын тары және оның жармасы, тарыдан жасалған азық, тағам. Қос сөздің бірінші сыңары - «***тары***» туралы талдау жүргізсек, түркі тілдеріндегі оның алғашқы тұлғасы дәл осындай болганымен, мағынасы «себу, егу» дегенді білдірген. Сол дәуірде «***тары***» түбіріне -*ғ* жұрнағы қосылған соң, бірінші мағынасы «дән, астық» түсініктерін берсе, екінші ұғымы қазіргі қолданылып жүрген «тары» мағынасында қалған [4, 537]. Осы күнгі хакас тілінде «***тары***» себу, егу; «***тарығ***» егін болып, ертедегі тұлғасы мен мағына. Қос сөздің екінші сыңары «талқан» қазақ тілінде ерте кездегі мағынасын сол күйінде сақтаған [2, 266].

***Сүмесін***. Аталған сөз мағынасын «сүт, ақ; сүме» деп ұғындырады түсіндірме сөздік. Ал «сүме» сөзіне «сүт өнімі» деген анықтама береді. Қазақ тіліндегі «***сүмесін***» сөзінің «сүт, ақ» мағыналарын беруі – соңғы дәуірдің жемісі. М.Қашқари сөздігінде сума – ащытқы үшін буландыратын бидай немесе арпа [4., 513]. Буландырылған бидай немесе арпадан сөл бөлініп шығатыны өзінен-өзі белгілі. Якут тілінде де "***сүмэсин***" тұлғасы «сөл» мағынасында қолданылады. Мұның тұлғасы қазіргі біздің тіліміздегі сүмесінге өте жақын. Аталған деректерді жинақтай айтқанда, қазіргі сөзінің шыққан төркіні - түркі, моңғол, маньчжур тілдері де, ал тұңғыш мағынасы – «***сөк, нәр, шырын***» [2, 259].

***Ежегей***. Мұның мағынасы майы алынған сүттің қайнатуынан жасалған қышқылтым уақ құрт. Тамақтың бұл түрінің дәмі қышқылдау болып келетінін еске алсак, өз атауын бойына тән осы қасиетіне байланысты алған деуге болады. Сөз түбірі түркі, моңғол тобындағы тілдерге ертеден ортақ болса керек. Тіліміздегі «***ащы***» сөзі якут тілінде «***аһыы»*** туваша «***ажыг***» береді. [2, 82].

Татар тілінде мақалдар: *Сыерның сөте – телендә. Сыерның сөте җиленендә түгел, телендә. Кымыз барда кызык бар. Көн саен майлы ботка булмый. Сөттән ак бул, судан пакь бул. Май ботканы бозмас. Авыз күнгән ачы катык күнмәгән каймактан яхшырак.*

Қазақ тілінде мақалдар: *Қырсыққанда қымыран іриді. Бар мәзір, жоқ жағдай. Қой сүті – қорғасын. Сүтке аузын күйдірген, Қатықты да үрлеп ішер. Жалғыз тары ботқа болмас, Ботқа болса, жұртқа болмас.*

**Әдебиет**


1. Манкеева Ж.А., «Мәдени лексиканың ұлттық сипаты». – Алматы.,1997
2. Нұрмағанбетов.Ә Бес жүз бес сөз. – Алматы., 1994
3. Сыздық Р. Сөздер сөйлейді. – Алматы., 1994
4. Щербак А. М., Боровкова Т. А. Древнетюркский словарь. – Ленинград., 1969.
5. Севортян Э. Этимологический словарь тюркских языков. – М., 1978


## СТУДЕНТТІҢ ӘДІСТЕМЕЛІК ҚҰЗЫРЕТТІЛІГІ ҰҒЫМЫНЫҢ ҚАЛЫПТАСУ ТАРИХЫ


*Абужалитова А., Қазақ ұлттық қыздар педагогикалық университеті, III курс докторанты*

*Ғыл. жет. – ф. ғ. д., проф. Сулейменова Ж.Н.*


Болашақ маманның әдістемелік құзыреттілігі жаһандық өзгерістерге сай түсіндірілгені жөн. «Әдістемелік құзыреттілік» ұғымы Ресей мен Қазақстан ғылымында өзектілігімен ерекшеленеді. В.А. Адольф әдістемелік құзыреттілікті мұғалім тұлғасының бір қыры ретінде таниды. Бұлай пайымдау мұғалімнің белгілі бір пән бойынша білімі, сол пәнді оқыту әдістемесіне сәйкес пайдаланатын әдіс-тәсілдерінің қалыптасқан жүйесі, пән бойынша әдістемелік тапсырмаларды сабақ беру барысында қолдану дағдысы, қабілеті ғана емес, оның кәсіби тұлғалық қасиеті болып саналады. Мұғалімнің әдістемелік құзыреттілігін педагогикалық мамандыққа қарым-қатынасын кәсіби білімі мен іскерлігімен байланыстырып, жеке тұлғаның кәсіби қасиеттерінің жиынтығы ретінде қарастырған [1: 152].

Педагогикалық жоғары оқу орнының түлегінің әдістемелік даярлығының дәрежесін студенттің оқыған мамандығы бойынша білім деңгейін анықтаумен ғана шектелмей, оның білім алу барысында меңгерген құзыреттіліктердің қалыптасу деңгейін бақылаған дұрыс. Әдістемелік пәндер бойынша емтихан, мемлекеттік емтихан барысында студенттердң практикалық сипаттағы кәсіби деңгейін анықтауда талдау жасауды, яғни кәсіби даярлығын бақылау үшін тапсырмаларды орындату арқылы қабілеті мен біліктілігінің, дағдысының жиынтығын көруге болады.

Ғылыми-зерттеу еңбектерде әдістемелік құзыреттілік ұғымы туралы сөз болғанда, алдымен әдістемелік даярлыққа кеңінен тоқталады. Бұл зерттеулердің мазмұнында әдістемелік құзыреттіліктің критерийлерін бағалайтын, даму деңгейлерін анықтайтын көрсеткіштер бар. Ф.Т. Шишкин ЖОО-да педагогикалық бағытта білім алатын физик-студенттердің әдістемелік даярлығы туралы негізгі ережелерді ұсынған. Ғалымның пікірінше, жоғары педагогикалық білім беру жүйесіндегі әдістемелік дайындықтың мақсаты орта мектептің сұраныстарына сәйкес келетін, кәсіби қызметі барысында үнемі дамып отыруға қабілетті, білім саласындағы өзгерістерді ескерген шығармашыл оқытушы болуы, жеке-бағдарлы, жүйелі тәсілдер арқылы әдістемелік білімі мен дағдылары, құзыреттіліктері қалыптасуының нәтижесінде кәсіби қызметке дайындығы болып табылады. Физик-студентердің әдістемелік даярлығының құрамына пәнді оқыту теориясы мен әдістемесі пәні, кәсіби бағдарлы өзіндік жұмыс [2: 17]. Әдістемелік даярлық кәсіби дайындықтың құрамдас бөлігі, студенттер кәсіби іс-әрекет барысында пәндік дайындыққа негізделген білімі мен дағдыларын түрлі пәндерді оқытуда қолдануы қажет. Студенттің әдістемелік даярлығын қалыптастыру кредиттік технологияның мүмкіндіктерін пайдаланумен тығыз байланысты. Әдістемелік даярлық тек пәнді оқыту теориясы мен әдістемесінің мазмұнына байланысты ғана емес, таңдау пәндері, кәсіби пәндер, арнайы курстар нәтижесінде қалыптасады.

Н.В. Моргачева әдістемелік даярлық бойынша, соның ішінде жаратылыстану пәнінің болашақ мұғалімінің әдістемелік даярлығының мазмұны бойынша әдістемелік құзыреттіліктің құрылымына түсінік берген. Когнитивті-ақпараттық компонентін сипаттап, педагогтың игеруге тиісті дағдыларын сараптаған. Болашақ жаратылыстану пәнінің мұғалімінің әдістемелік даярлығының мазмұнына қойылатын талаптарды анықтаған. Осылайша, болашақ жаратылыстану мұғалімінің әдістемелік дайындық мазмұнына қойылатын талаптардың құрылымы келесі элементтерді қамтиды: мақсатқа, мазмұнға, процеске және нәтижеге қойылатын талаптар деп бөліп көрсеткен.

Әдістемелік құзіреттілік мақсатты түрде әдістемелік дайындық мазмұнының құрылымын анықтайтын жеке, танымдық-ақпараттық, операциялық-технологиялық және қызмет компоненттерінен тұрады. Зерттеуде әдістемелік дайындық мазмұнына қойылатын негізгі талаптар ретінде келесі идеялар қарастырылады: интеграция (пәндік пәнаралық, әдістемелік интеграция) және көп деңгейлі. Әдістемелік даярлау процесіне қойылатын талаптар ретінде кәсіптік білім беруде интерактивті білім беру технологияларын қолдану қажеттілігі

қарастырылады. Әдістемелік құзыреттілік болашақ жаратылыстану мұғалімінің әдістемелік дайындығының нәтижесінде қалыптасады деп тұжырымдаған [3: 53].

«Әдістемелік дайындық» ұғымын неғұрлым жалпы анықтаманы В.И. Земцова береді, ол мұғалімнің әдістемелік қызметін және педагогикалық жоғары оқу орындарының студенттерін әдістемелік даярлауды сипаттауға мүмкіндік беретін тұжырымдамалық аппаратты дамытудың заманауи әдістемесінде алғаш рет анықтама берген. Ол: «әдістемелік дайындық – бұл мұғалімнің кәсіби дайындығының ең маңызды бөлігі, ол әдістемелік қызметке (әдістемелік дайындыққа) дайындықты қалыптастырудың үздіксіз басқарылатын процесі және кәсіби дайындыққа қатысты интеграциялық қасиетке ие» деп тұжырымдаған болатын. Сонымен қатар «әдістемелік дайындыққа тән интеграциялық қасиет оны оқу жоспары пәндерін оқу кезінде студенттер алған негізгі білім мен дағдыларды біріктіретін байланыстыратын және педагогикалық практикадан өту кезінде ішінара жүзеге асырылатын және бекітілген жүйе ретінде анықтауға мүмкіндік береді» деп қорытындылаған [4: 42].

Ғалым болашақ мұғалімнің, бакалаврдың оқу-тәрбие процесінде жаңа технологиялар мен әдістемелерді пайдалану құзыреттілігі, білім беру кеңістігіндегі жаңа ақпаратты пайдалана білу құзыреттілігі қалыптасады деп көрсеткен.

Біз сипаттаған дидактикалық құралдардың мүмкіндіктері болашақ мұғалімдердің әдістемелік құзыреттілігін қалыптастырудың құрылымдық компоненттері мен мазмұндық элементтерін қамтиды. Педагогикалық құралдарды оқу процесінде қолдану үздіксіз әдістемелік дайындықты, әдістемелік жүйені қажет етеді.

**Әдебиет**

1. Адольф В.А. Профессиональная компетентность современного учителя. – Красноярск, 1998. – Б. 309.

2. Шишкин Ф.Т. Методическая подготовка студентов-физиков педагогических вузов в современных условиях // Наука и школа. – 2008. – № 1. – Б. 14-17.

3. Моргачева Н.В. Требования к содержанию методической подготовки будущего учителя естествознания // Педагогический журнал. –2017. –Том 7. –№ 2А. – Б. 50-61.

4. Земцова В.И. Формирование методической компетентности студентов по направлению подготовки 05100 Педагогическое образование (квалификация (степень) бакалавр) https://cyberleninka.ru/article/n/formirovanie-metodicheskoy-kompetentnosti-studentov-po-napravleniyu-podgotovki-050100-pedagogicheskoe-obrazovanie-kvalifikatsiya/viewer

5. Игна О.Н. Структура и содержание методической компетентности учителя иностранного языка // Ярославский педагогический вестник. – 2010. – № 1. – Б. 90-94.

## АЧУ ЭМОЦИЯСЕН БЕЛДЕРҮДӘ СИНОНИМЛЫК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

*Әминова Г., КФУ, IV курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд, доц. Денмөхәммәтова Э.Н.*

Эмоцияләр күп еллар дәвамында төрле фән тармаклары тарафыннан тикшеренүләрнең төп объекты булып торалар. Эмоция лингвистикада тереклек ияләренең эчке ихтыяҗларын бәяләү һәм канәгатьләндерү чарасы, кешенең нинди дә булса объектка мөнәсәбәте, субъектның эчке халәтен белдерү формасы буларак карала. Тикшеренү барышында лингвистлар эмоцияләр вербальләшүенең авыр процессы белән очрашалар, чөнки эмоция кеше психикасының феномены буларак гаять күпмәгънәле төшенчә, димәк, аның телдә чагылышы тагын да катлаулырак. Кайбер галимнәр барлык телләрдә дә күпчелек сүзләрнең шатлык яки кайгыны белдергән эмоциональ өлеше булуын танып та, бу өлешнең сүзнең семантикасына кермәвен, ә концептуаль төш эчендә карала торган ассоциация булуын раслап чыгалар. Бу фикер телнең сүзлек составын, теләсә нинди сүз дискурсив һәм эмоциональ булырга мөмкин, дигән факттан чыгып, эмоциональ һәм нейтраль өлешләргә бүлүне алгы планга чыгарган психолингвистларның казанышларына каршы килә.

Эмоция – кешенең хисләре, кичерешләре, тойгылары, дип бирелә аңлатмалы сүзлектә [4: 574]. Чыннан да, эчтәлекләре һәм мәгънәләре ягыннан эмоцияләр һәм хис – кичерешләр бер-берсенә якын төшенчәләр. Эмоцияләр хисләрдән торалар, ә хисләр нигезендә эмоцияләр ята. Аларны белдерү өчен катып калган гыйбарәләр, фразеологизмнар, терминнар, геройның тышкы һәм психологик портретын сурәтләү, метафора, чагыштырулар кулланалар. Шушы чаралар эмоцияләрнең синонимик рәтен хасил итәләр. Матур әдәбият әсәре контекстында сүзләр эмотив коннотация алырга мөмкин дип исәпләнә. Нәкъ менә шул турыдагы уйланулар мәкаләне ачу эмоциясенә багышларга кирәк, дигән фикер уятты.

Аңлатмалы сүзлектә “Ачу – нәфрәтләнү хисе, ярсу тойгысы, ризасызлык, үпкәләү хисе, эчтәге үпкә, нөктә”, дип бирелә [5].

Синонимнар сүзлегендә ачу төшенчәсе:

Ачу – (гнев, злоба, злость, ярость) – ярсу; кайнарлы; каһәр; кинә; кызып китү; үпкә [3:10];

Ачу килү – (гневаться, злиться, сердиться) – ачу кабару; ачулану; ачу чыгу; кабарыну; җен чыгу (кубу); җен кузгалу; зәһәрләнү; зәһәре чыгу; ярсу; җенләнү [3:10] берәмлекләре аша күрсәтелә.

Матур әдәбият әсәрләренең үрнәкләрендә әлеге эмоциягә караган хис – кичерешләр төрле чаралар ярдәмендә җиткерeләләр. Нәбирә Гыйматдинованың “Сәвилә” әсәреннән алынган мисаллар ачу, ярсу эмоцияләрен укучыга бик тирән һәм тулы итеп тапшыруның матур үрнәге булып торалар. Мәсәлән, “*Кыз **чүт кенә** Мәликәнең*

***авызына сугып жибәрмәде”*** [1:68]. Күргәнебезчә, автор ачу чыгуны геройның хәрәкәтләре, бу мисалда сурәтләнгәнчә, нәкъ менә эмоцияләр этәргеч биргән теләкләрен тасвирлау аша күрсәтә.

Геройның эчке халәтенең метафора, фразеологизм, күчерелмә мәгънәдәге сүзләр һәм тойгылы җөмләләр аша сурәтләнеше хис - киерешне тагын да тирәнрәк ачырга ярдәм итә: *“**Сеңеленңне тый!** - диде **күркә сыман кабарынган** Мәликә”* [1:66]. *“**Эчтән көйрәп янган** хатын үз **ялкынында үзе өтелә иде**”* [1:67]. *“**Зәһәр ачуын төен итеп йөрәгенә төйнәгән** Мәликә, ишегалдында **пыр тузынды**”* [1:70]. *Зәһәр ачуын төен итеп йөрәгенә төйнәгән* гыйбарәсе героиняның күңелендәге ачуының иң югары ноктасына җитүенә ишарә ясый, шулай ук эмоцияләрне тагы да көчәйтү максатыннан *пыр тузынды* фразеологизмы автор тарафыннан әсәр тукымасына кертеп җибәрелә.

Марат Кәбировның иҗат җимешләрендә дә кешенең ярсуы, ачы нәфрәте геройның тышкы портреты аша җиткерелә: *“Аннан соң бөтен **тәне көзән жыергандай тартыша башлады, муен тамырлары кабарып, яңаклары бүртенеп чыкты, битенә куе кызыллык йөгерде, күзләре тәгәрәп чыгардай булып түгәрәкләнде, маңгай сырларыннан тир бөртекләре тәгәрәде**”* [2:367].*“Йөзендәге **мускуллары тартышып – тартышып куйды, төйнәлгән кашлары астыннан караган күзләре сагыш, әрнү, нәфрәт чәчте**”* [2:380]. “*Ул **әрнүле нәфрәт** белән докторга төбәлде”* [2:367]. Бу җөмләдә китерелгән *әрнүле нәфрәт, күзләре сагыш, әрнү, нәфрәт чәчте* гыйбарәләре кайгы белән ярсуның бер – берсенә кушылып китеп, кешенең хисләр ташкынын белдерүнең бик матур мисалы булып тора.

***“Шайтан алгыры! Кем әле син миңа күрсәтмә биреп йөрергә?!”*** [2:435]. ***“Фу-у!** Сасыталар подъездны!”* [2:436]. ***“Каһәр суккан нәрсә!”*** [2:441] кебек җөмләләрдә кемгә дә булса ачулану кимсетү, ярсу, канәгатьсезлек, ачулану һәм мифик көчләргә сыгынуга бәйле ымлыклар һәм боерык җөмләләр ярдәмендә тасвирлана.

Гомумән алганда, матур әдәбият әсәрләреннән алынган җөмләләрдә геройның нинди дә булса ситуациягә ачуы килүе, ярсуын белдерү төрле чаралар ярдәмендә сурәтләнә. Эш барышында эмоцияләрнең фразеологик әйтелмәләр, метафора, тойгылы җөмләләр, ымлыклар, чагыштыру, тышкы һәм эчке портрет аша бирелүен мисаллар ярдәмендә тикшердек һәм ачуны, ярсуны чагылдыручы эмоцияләрнең синонимнар ярдәмендә бирелешен ачыкладык.

**Әдәбият**

1. Гыйматдинова Н.М. Повестьлар. Икенче китап. – Казан: Идел – Пресс, 2010. – 479 б.

2. Кәбиров М.Р. Китап: роман, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 463 б.

3. Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер нәшр., 1999. – 256 б.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда: 3 том. – Казан: - Татар. кит. нәшр., 1981. – 832 б.
5. Электронный фонд словарей http://suzlek.antat.ru/fullartR.php?id=315765

# ТАТАР ХАЛЫК ТАБЫШМАКЛАРЫНДА КУЛЛАНЫЛГАН КИЕМ-САЛЫМ, ТУКЫМА АТАМАЛАРЫ

*Әсхадуллина Г., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Хөснетдинов Д.Х.*

Татар халык табышмакларында табылган тарихи сүзләр арасындаэлек кулланылышта йөргән кием-салым, тукыма атамалары аерым урын алып тора. Гадәти өс киеме шактый тотрыклы булып, аның яңаруы-үсеше халыкның үз гореф-гадәтләренә һәм көнкүрешенә яраклашуы төсендә барган. Шуңа күрә кием, гадәттә, кешенең тышкы кыяфәтенә милли төс биргән. Өс кигеменең бик борынгы төрләре, әлбәттә безгә килеп җитмәгән. Килеп җиткән кадәресе генә дә халкыбызның кабатланмас иҗади көчкә ия булуын күрсәтә. Татар халык табышмакларында элекке заманнарда киелгән, кулланылышта йөргән кием-салым, тукыма атамалары шактый очрый: *камзул, чикмән, тун-чикмән, кушак, күшәгә, кистән, камка, көпе, күнчек, зипун.*

Табышмакларда теркәлгән кием-салым атамаларының кайберләрен карап үтик.

*Чикмән* — «калын һәм тупас сукнодан тегелгән өс киеме, шинель» [4: 427]. Әлеге сүз табышмакларда еш очрый. Чикмәнне, гадәттә, крестьяннар гына кигәннәр. Глазов сөйләшендә бу сүз калат-җилән вариантында теркәлгән [5: 156]. «Чикмән ике төрле була: берсе өч билле җылы кием, икенчесе туры аркалы, киң итеп тегелә торган — юл киеме. Беренче төр чикмәннәр XX гасыр башларында керәшен татарларында һәм Чепца елгасының югары агымында яшәүче татарларда очрый. Чикмәннең киң, туры аркалы, зур кайтарма якалы һәм озын итеп тегелгән төре барлык татарларда да юл киеме хезмәтен үтәгән. Кайбер төбәкләрдә фабрика тукымасыннан тегелгән озын буйлы, туры аркалы озын һәм тар кайтарма якалы чикмән ирләрнең көндәлек кием хезмәтен үтәгән»[3: 86].

*Өй каршында чикмәнле солдат.* (Каен) [1: 438]

*Япанча / ябынча* — киң плащ формасындагы борынгы өс киеме [4: 242]. Р.А.Юналеева *ябынча* сүзенең кыпчак теленнән килеп чыкканлыгын дәлилли. М.Кашгарый сүзлегендә japtac — «киездән тегелгән яңгырдан һәм кардан саклану чарасы». М.Фасмер һәм Н.М.Шанский бу сүзне төрек телендәге japunza «капюшонлы плащ» сүзе белән бәйлиләр.*Япанча* сүзе епанча формасында рус телендә дә кулланылган. *Епанча* лексемасы барлык славян телләрендә таралган.

Бу сүз *япончица* вариантында «Слово о полку Игореве» әсәрендә теркелгән.Бу сүз түбәндәге табышмакларда күзәтелә:

*Дүрт япанчыга бер ябынча.*
(Өстәл) *[1: 255]*
*Дүрт япанчы бер ябынча астында*
*Яңгырдан качып утыра.* (Сыер имчәкләре) [1: 3735]

Табышмакларда тукыма төрләре дә урын алган. Мәсәлән, *камка* «кытай ефәге», *китән* «яхшы сыйфатлы җитен сүсеннән сугылган ак киндер тукыма», *кытат* «борынгы вакытта кытайдан кертелә торган тыгыз ефәк тукыма. Соңрак шундый төрдәге мамык тукыманы белдерү өчен дә кулланыла» [4: 113] торган атамалар теркәлгән. Мисалларга игътибар итик:

*Асты камка,өсте камка,*
*Уртасында яшел такта.* (Арыш уҗымы) [1: 797]
*Җил-җил җилә килә,*
Камка *тунын печә килә,*
*Каннан суын эчә килә.* (Камчы) [1: 3453]

Шулай итеп, табышмакларда күзәтелгән кием-салым, тукыма атамалары Идел буеның эре игътисади регион булуын тагын бер кат раслый. Халык хуҗалыгының шундый мөһим тармаклары үсешендә татарларның да билгеле бер өлеше булуын табышмаклар лексикасы ачык күрсәтә һәм халык авыз иҗатының мондый тарихи эзләнүләрдә ышанычлы бер чыганак икәне бәхәссез.

**Әдәбият**

1. Татар халык табышмаклары / Җыючы һәм төзүче Н.Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. – 567 б.
2. Татар халык иҗаты. Табышмаклар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 271 б.
3. Мухамедова Р.Г. Татарская народная одежда. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1997. – 224 с.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – Т.2. – 396 б.
5. Татар теленең диалектологик сүзлеге / Ф.С.Баязитова, Д.Б.Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 459 б.

## ЛЕКСИКА ГОВОРЕНИЯ В НАРЕЧИИ ТАТАР ТОБОЛЬСКОЙ ГУБЕРНИИ

*Барановская Д., ТюмГУ, студент II курса*
*Науч. рук. – докт. филол. наук, проф. Файзуллина Г.Ч.*

XIX век ознаменовался для развития татарской лингвистики выходом в свет лексикографических трудов священнослужителей-миссионеров, среди которых одним из первопроходцев по праву считается учитель татарского языка Тобольского главного народного

училища Иосиф Гиганов. Изучение лексической системы языка татар Тобольской губернии представляется актуальным. Во-первых, данная эпоха характеризуется становлением татарского литературного языка. Следовательно, изучение парадигматических отношений слов на материале местного наречия позволит проследить особенности развития татарского языка в условиях региона. Во-вторых, лексика говорения является одной из центральных и активных тематических групп в языковой системе.

Архивные материалы тех времен доказывают нам, что интерес к языку сибирских татар присутствовал и в XVII в. В трудах русско-немецкого историографа Г.Ф. Миллера обнаружены записи о диалекте западносибирских татарах. Первоначальную идею изучения и рассмотрения с точки зрения науки языка сибирских татар относят к концу XVIII века. Она принадлежала комитету православного миссионерского общества. В 1783 г. вводится преподавание татарского языка, в 1801 г. учителем Тобольского народного училища И. Гигановым создается первая «Грамматика татарского языка». Позже в 1802 г. учитель Саусканской школы Нияз-Баки Атнометов совершает попытку составления учебника на родном языке сибирских татар и издает «Букварь арабского и татарского письма» для учащихся начальных классов сибискотатарских школ. Далее через два года предается огласке вторая книга Иосифа Гиганова «Словарь российско-татарский». Она включает в себя 10 тысяч слов и выражений.

Большое значение в изучении лексики сибирских татар внес академик В.В. Радлов. Его труды, такие как «Образцы народной литературы Тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи: Ч. 4: Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар» (1872) и «Опыт словаря тюркских наречий» стали важной основой для изучения диалектов сибирских татар.

Предмет исследования составляет лексика говорения, функционировавшая в языке тобольских татар XIX века. Под лексикой говорения понимаем слова, обозначающие речевые характеристики человека (имена прилагательные), называющие речевые особенности (имена существительные), а также процесс говорения (глаголы).

Цель исследования заключается в лексико-семантическом анализе слов говорения в языке тобольских татар XIX века. Материалом исследования выступает «Словарь российско-татарский, собранный в Тобольском главном народном училище» учителя татарского языка Иосифа Гиганова (СПб., 1804). Методом сплошной выборки вычленены лексемы в количестве 64 единиц.

В XIX веке для обозначения понятий «слово», «разговор», «произношение» использовались следующие номинации: *сюзь* ‘слово’ (*айтыш сузь* ‘выговоръ’, *сюгуш сюзь* ‘бранное’) [547], *тат*, *бер авоз сюзь* ‘словцо’ [548], *сюзьгеня* ‘словечко’ [547], *кяпляшу* ‘разговор’ [494], *аузанмаклык* ‘произношеніе’ [468]. Процесс говорения обозначается при помощи лексем *діймен, сюйляймен, айтамен* ‘говорю, сказываю’ (*сюзляймен* ‘говорю, сказываю слово’, *гяпляймен, кяпь айтамен* ‘говорю, сказываю речь’, *сюзьляшамен, кяпляшамен* ‘говорю, сказываю вместе’ [96], *цынгылтак сюзьляйде* ‘сиповато говорить’).

В результате анализа были выявлены следующие лексико-семантические группы слов:

1) слова, обозначающие речевые характеристики человека (имена прилагательные): *кяпцил* ‘говорливый’ [96], *сагав // сакав* ‘заикливый’ [169], *сюгуще* ‘бранливый’ [25], *сюзлю* ‘словесный’ [547], *сюзьгя бюткюц, юндам* ‘зговорчивый’ [192], *сюзьгя завок* ‘словоохотный’ [547], *тельсиз* ‘немый’ [320];

2) слова, называющие речевые особенности (имена существительные): *гяпцильлил* ‘говорливость’ [96];

3) слова, обозначающие процесс говорения (глаголы): *айтамен* ‘сказываю’ [538], *айтып уткярамен* ‘проговариваю’ [466], *айтышамен* ‘зговариваюсь’ [192], *айтышамен* ‘разговариваю вместе’ [494], *албургандурамен* ‘уговариваю’ [621], *аузанамент* ‘произношу’ [468], *аузангылаймен* ‘произношу много, часто’ [468], *аузанушамен* ‘произношу вместе’ [468], *гяпляштурамен, сюйляштурамен, сюзьляштурамен* ‘говорить вместе заставляю’ [97], *еслаймен // ешляймен* ‘шиплю’ [665], *загыръкыламен* ‘изъясняю’ [211], *каимлаймен* ‘переговариваю’ [369], *капляшамен* ‘разглагольствую ’ [494], *кирямен* ‘стегаю словами’ [195], *киши устуня сюзь сюйляймен* ‘наговариваю’ [195], *муграймен* ‘мычу’ [288], *сагавланамен, тартышип айтамен* ‘заикаюсь’ [169], *сюгамен* ‘браню, порицаю’ (*сюккялаймен* ‘часто браню, порицаю’) [25], *сюгюшамен* ‘бранюся’ [25], *сюзь кайтарамен* ‘зговариваю’ [192], *сюзь куюшамен* ‘договариваюсь на договор словесно’ [129], *сюзь куюшамен, сюзь куямен* ‘уговариваюсь’ [621], *сюзьляшамен* ‘разговариваю’ [494], *сюйлянул айтамен* ‘выговариваю’ [73], *сюйлятамен, кяплатамен* ‘говорить заставляю’ [96], *сюрюнамен* ‘запинаюсь’ [169], *тартышамен* ‘запинаюсь во речи’ [178], *тилянып сурап аламен* ‘нищенскимъ образом выпрашиваю’ [317], *угутляймен, юрукка тюшюрямен* ‘наказываю словами, щуняю’ [195], *хайхайлаймен* ‘ахаю’ [5], *шартлашамен* ‘договариваюсь на договор’ [129], *шипъшанамен* ‘шепчу’ [664].

В лексикографическом источнике выявлены следующие синонимические ряды: 1) *кяпциль* ‘говорливый’ [96], с*юзьгя завок* ‘словоохотный’ [547]; 2) *сюгамен* ‘браню, порицаю’ (*сюккялаймен* ‘часто браню, порицаю’, *сюгюшамен* ‘бранюся’) [25], *угутляймен, юрукка тюшюрямен* ‘наказываю словами, щуняю’ [195], *кирямен* ‘стегаю словами’ [195]; 3) *сагавланамен, тартышип айтамен* ‘заикаюсь’ [169], *тартышамен* ‘запинаюсь во речи’ [178]; 4) *капляшамен* ‘разглагольствую’ [494], *сюзьляшамен* ‘разговариваю’ [494], *айтамен* ‘сказываю’ [538], *загыръкыламен* ‘изъясняю’ [211]; 5) *айтышамен* ‘разговариваю вместе ’ [494], к*аимлаймен* ‘переговариваю ’ [369]. Отмечен единичный случай антонимии: *тельсиз* ‘немый’ [320], *кяпциль* ‘говорливый’ [96].

Таким образом, нами были выявлены следующие лексико-семантические группы слов: слова, обозначающие речевые характеристики человека (16 %); слова, называющие речевые особенности (5 %); слова, обозначающие процесс говорения (76 %). Кроме того, отмечены случаи парадигматических отношений слов - синонимия (20 %) и антонимия (3 %).

**Литература**

1. Гиганов И. Словарь российско-татарский, собранный в Тобольском главном народном училище. – СПб.: Императорская Академия Наук, 1804.
2. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. – Казань: Хәтер, 1999. – 255 с.

## СИМВОЛ ОРНАМЕНТОВ ТЮБЕТЕЙКИ У КАЗАХОВ И ТАТАРОВ

*Болатова Е., КазНУ им. Аль-Фараби, студент III курса*
*Науч. рук. – к. филол. н., Кортабаева Г.К.*

История тюбетейки уходит в далекое прошлое. Свидетельство о существовании головного убора, подобного тюбетейке, носимого в античные времена, было найдено в скульптуре, нумизматике, стенных картинах, книжных миниатюрах XV-XVI столетий.

С древних времен тюбетейка являлась неотъемлемой частью национальной одежды. Тюбетейка являлась не только простым головным убором, но подчеркивала человека как скромного, благовоспитанного, верующего. Поэтому о человеке, истинно верующем, живущем по правилам Корана, говорили, что «он родился в тюбетейке».

«У восточных народов говорят: покажи мне свою тюбетейку, и я скажу откуда ты родом, каков твой достаток, праздник в доме или горе, сколько в доме детей, семейное положение, профессия, место

жительства и др. — всю информацию несут узоры-символы на тюбетейке. Тюбетейка – *"паспорт"* того, кто ее носит».

Мы обращаемся к самой важной детали – головному убору. Самому важному – потому, что и сейчас остаётся тюбетейка обязательным атрибутом одежды каждого мусульманина на всех наиболее значительных мероприятиях.

Свое название слово «*тюбетейка*» получило от тюркского «*тюбе*», что переводится как «*верх, вершина*». Тюбетейку носят народы Средней Азии, а также в Афганистане, Иране, Турции, в Поволжье татары, башкиры. Наряду с сохранением общих черт, тюбетейку всегда отличает индивидуальный почерк создавших ее мастеров, то есть символов.

Получило также широкое распространение и другое название этого головного убора, но арабского происхождения, употребляемое в двух вариантах – «*токия*» («*такия*») и «*токы*», которое в туркменском языке приобрело форму «*тахя*».

В научной литературе существует версия по поводу «военного» происхождения туркменской шапочки («*такъе*» в переводе с древнетюркского означает «*шлем»*) [1: 104-119].

Российские татары, башкиры носят тюбетейки с плоским или заостренным верхом. Формы тюбетеек разнообразны: низкие, высокие, остроконечные и с плоской верхушкой, с кистью и без нее, в форме цилиндра. Тюбетейки шьют обычно из бархата, вышиваются разноцветными шелковыми нитками, украшаются золотой или серебряной канителью, бусами, блестками, камнями, позже – бисером, стеклярусом, жемчугом.

Мягкие и твердые, с круглым верхом и с плоским, шелковые, бархатные и парчовые - они были чем-то вроде визитной карточки своего владельца, свидетельствуя о его происхождении, месте жительства, роде занятий, благосостоянии.

Каляпуш и такия было время, когда мужчин-татар не могли представить без тюбетейки. По мусульманским обычаям волосы сбривали наголо и одевали тюбетейку. Существуют тюбетейки двух видов - каляпуш и такия. Такия по форме схожа с вязанной шапкой, сшитой из четырёх частей. У татар тюбетейку принято называть каляпуш. Каляпуш – слово фарси: каля – голова, пушидан – покрытие, т.е. [2: 212-270].

Об орнаментах стоит поговорить особо. Практически все они, даже самые простенькие, имели когда-то символическое значение.

«Ою-өрнек, орнамент – әртүрлі заттарды, сәулет ғимараттарын әшекейлеуге арналған, жүйелі ырғақпен қайталанып отыратын әрі үйлесімділікке құрылған өрнек-нақыштар» [3: 101].

Например, волнообразный круговой замкнутый узор означал годовой круговорот, бесконечность жизни, пожелание долголетия. Плетеная "веревочка" – союз, содружество, брачные узы. Растительный орнамент – символ жизни земной, благодарность создателю за красоту и щедрость природы.

Один из основных символов цветочного орнамента тюркских народов, особо любимый татарами, упрощенное изображение тюльпана, воспоминание о далеких степях, символ весеннего возрождения. Орнаменты в виде парных завитков, напоминающие рога баранов, тоже восходят к далекому кочевому прошлому – чтобы у хозяина не переводился скот, был бы он богат и благополучен.

А есть символы, общие для евразийских народов, их символы, например, солярные, солнечные знаки – это обереги, отгоняющие, по поверью, болезни и несчастья [4: 65-78].

В казахских тюбетейках и их орнаментах существует универсальный для всех народов мира комплекс архетипических мотивов и символов, обозначающих стихии мироздания в виде круга, спирали и креста, связанных с культом солнца, земли и звезд, по своему переиначенных и адаптированных к своей культуре. И в то же время, есть неповторимые черты, присущие лишь нашему народу [5: 15-26].

Этот головной убор не потерял своей актуальности и сегодня. Именно поэтому искусство украшения тюбетеек не стоит на месте: каждый мастер имеет свой неповторимый почерк, использует современные материалы и символы для украшений.

**Литература**

1. Шайдуллина Р.Т. Знакомство с татарским орнаментом через традиций и обычай татарского народа. – Казань, 2017.
2. Этнография татарского народа. – Казань: Магариф, 2004. – 287 с.
3. Қортабаева Г.Түркі ономастикасы. – Алматы: Қазақ университеті, 2017.
4. Буреева Ф.М. Орнамент Тарских Татар Конца 19-20 Веков. К Проблеме Этнокультурной Истории, г. Омск, 2011.
5. Ханият Б., Сужикова А. Алматыкітап "Қазақ Халқының Ұлттық Киімдері". – Алматы 2007.

# СИНОНИМИЯ СРАВНИТЕЛЬНЫХ КОНСТРУКЦИЙ В РАЗНОСТРУКТУРНЫХ ЯЗЫКАХ

*Болгарова А., КФУ, студент III курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Болгарова Р.М.*

В связи с внедрением в гуманитарные науки антропоцентрической парадигмы актуальным стало рассмотрение языковых явлений в тесной взаимосвязи с человеком, его сознанием и миропониманием. В современной научной литературе большое внимание уделяется вопросам содержания понятия «языковая картина мира». Исследованию языковой картины мира посвящены труды таких ученых, как Ю.Д. Апресян, А. Вежбицкая, А.А. Залевская, В.В. Красных, Е.С. Кубрякова, В.Н. Телия, Р.Р. Замалетдинов и др.

Единый общий семантический признак сравнений позволяет установить синонимический ряд конструкций, выраженных разными морфологическими и синтаксическими средствами.

Основу всех сравнительных конструкций русского и немецкого языков составляют сравнительные обороты. В обоих языках имеют место два вида сравнительных оборотов: уподобляющего и расподобляющего типа.

Отличием сравнительных оборотов уподобляющего типа в русском языке является наличие множества уподобляющих союзов (*как, будто, как будто, словно* и др.), имеющих различные оттенки сравнения, тогда как в немецком языке обороты строятся с одним союзом *wie*, а дополнительные значения несут в себе различные частицы (*beinahe, fast, ganz, etwa*), употребляемые в сочетании с союзом. Например: *Тотчас из под обрыва начали вылетать стрижи с таким свистом, будто снаряды из маленькой пушки*; *Schwimmen die Robben sehr hastig, so erwärmen sie sich und können sich hernach ebenso schwer abkühlen wie der Kaffee in der Thermosflasche / Плавая очень быстро, тюлени согреваются, а затем остывают также долго, как кофе в термосе.*

Сравнительные отношения в русском и немецком языках выражаются сложноподчиненными предложениями со сравнительной придаточной частью. Как в русском, так и в немецком языке придаточные со значением сравнения способны выражать реальные и ирреальные сравнительные отношения, выражаемые сравнительным союзом и наклонением глагола: *Леса горели на свету, будто их выковали из золота хитрые сибирские кузнецы; Es quiekte, schimpfte, klapperte, raspelte, als ob da ein Sägewerk in Gang wäre / Визжали, ругались, громыхали, царапались, как будто бы тут работал лесопильный завод.*

В русском и немецком языках имеется множество лексических единиц, которые участвуют в языковом процессе сопоставления предметов или явлений и могут самостоятельно или в сочетании со служебными частями речи указывать как на факт сравнения, так и на

результат. Большее распространение компаративные связки находят в русском языке, чем в немецком. Например: *На шее у неё (курицы) была накинута шаль из пестрого пуха, и вся она походила на цыганку; Hinter ihrem Rücken baumeln lange an Stielen befestigte Taschen, ähnlich den Netzen, mit denen Kindern nach Schmetterlingen haschen / На их спинах болтались длинные, прикрепленные к черенкам сумки, похожие на сачки, которыми дети ловят бабочек.*

В русском и немецком языках функционируют словообразовательные компаративные структуры. Если суффиксальный способ образования слов с целью передачи сравнительных отношений характерен для обоих языков: *желтые ирисы с мечевидными листьями; веерообразный хвост; das schluchtartige Tal / долина в виде ущелья; das kugelförmige Nest /гнездо в форме шара*, то особенностью немецкого языка является существование сравнительных конструкций, имеющих структуру «основа существительного + прилагательное»: *spiegelglatte Wasseroberfläche / гладкая, как стекло, поверхность воды; suppentellergroße Schildkröte / черепаха величиной с суповую тарелку*. Данный вид передачи сравнительных отношений довольно распространен в немецком языке.

Развернутые сравнения в немецком языке строятся однотипно: *Bis vor hundert Jahren musste der Mensch sehr bescheiden sein auf dieser Erde. Die Enten konnten besser schwimmen, der Seehund tiefer tauchen, der Vogel rascher fliegen, der Adler schärfer sehen, fast jedes Tier schneller laufen, das Känguru weiter springen, der Dachs besser graben als er (B. Gržimek. Von schnellen und schnellsten Tieren) / Сотни лет человек должен был вести себя очень скромно на этой земле. Утки могут лучше плавать, тюлень – глубже нырять, птица – быстрее летать, орел – зорче видеть, почти каждое животное – быстрее бегать, кенгуру – дальше прыгать, барсук – лучше рыть землю, чем он;*

и отличаются разнообразием в русском языке. Например: *А люди заносятся. Думают, что дружба им одним дадена, чванятся перед всяким живым существом. А дружба – она, брат, кругом, куда ни глянешь. Уж что говорить, корова с коровой дружит и зяблик с зябликом. Убей журавля, так журавлиха исчахнет, исплачется, места себе не найдет. И у всякой травы и дерева тоже, надо быть, дружба иногда бывает.*

В каждом языке существует определенная точка отсчета, через которую преломляется формирование образных представлений у носителей определенного языка. Сам отбор предметов и явлений для создания образов сравнения раскрывает разные стороны исторического

развития народа, его национальной культуры, духовного склада и миросозерцания. При вербальном кодировании обозначение в виде отдельных лексических единиц получает то, что играет важную роль в жизни человека (нации), что является ценностным для него. На этом основании можно говорить об антропоцентричности сравнительных конструкций, и поэтому, анализируя семантику сравнения, можно выявить важные для этнокультурного сообщества сферы.

**Литература**

1. Замалетдинов Р.Р. Теоретические и прикладные аспекты татарской лингвокультурологии. – Казань: Магариф, 2009. – 321 с.
2. Румянцева М.В. Краткий анализ сравнительных конструкций в немецком и русском языках // Научно-методический журнал «Иностранные языки в школах Казахстана», № 6 (24). – Алматы, 2005. – С. 9-12.

## СЕМАНТИЧЕСКАЯ ХАРАКТЕРИСТИКА СПЕЦИАЛЬНОЙ ЛЕКСИКИ В СФЕРЕ ИНФОРМАТИКИ И ВЫЧИСЛИТЕЛЬНОЙ ТЕХНИКИ

(на материале русского и туркменского языков)

*Бурыева Э., БГУИР, студент III курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Петрова Н.Е.*

В современном мире наблюдается стремительное развитие информатики, робототехники, информационных технологий, инфокоммуникационных технологий. Изучение этих сфер науки и техники особенно актуально. Поскольку данные области знаний находятся в постоянной динамике, состав специальной лексики данных сфер также непрерывно меняется. Практически ежедневно появляются новые предметы, технологии в сфере информатики и вычислительной техники, в свою очередь какие-то слова уходят из активного употребления в связи с неактуальностью.

В современном языкознании существует необходимость в описании и упорядочении специальной лексики информатики и вычислительной техники туркменского языка. Если в русском языке есть специальные словари и работы, посвящённые изучению русской лексики в сфере информатики и вычислительной техники, то в туркменском языкознании таких работ недостаточно. Это объясняется в первую очередь тем, что информационные технологии, сфера информатики и вычислительной техники стали развиваться быстрыми темпами в экономике Туркменистана совсем недавно.

Рассмотрим, что такое специальная лексика. Специальной лексикой называется «совокупность слов, употребление которых ограничено специальными сферами человеческой деятельности: наукой, производством, техникой, сельским хозяйством, искусством и

т.п.» [1: 367]. Таким образом, специальное лексика сферы информатики и вычислительной техники объединяет специальные наименования для обозначения различных машин и устройств, используемых в данной области; языков программирования; единиц измерения; наименований различных видов ПО (программного обеспечения); лиц, чья деятельность связана с информатикой и вычислительной техникой; наименований процессов, действий, свойств и др.

Проанализировав современные лексикографические источники в русском и туркменском языках, мы составили небольшой русско-туркменско-английский словарь наиболее употребительных существительных в сфере информатики и вычислительной техники [2: 79]. На основании составленного нами словаря мы проанализировали семантическое наполнение специальных лексем в сфере информатики и вычислительной техники. Наиболее значительными лексико-семантическими группами специальных слов в данной сфере являются:

– названия машин, устройств, технических средств и их видов: *виртуальная машина – wirtual maşyny, компьютер – kompýuter, модем – modem, ноутбук – noutbuk, персональный компьютер – şahsy kompýuter, электронная вычислительная машина (ЭВМ) – elektron hasaplaýyş enjamy (ECM)* и др.;

– названия компьютерных деталей, принадлежностей: *мышь – syçan, клавиатура – klawiatura, клавиша – klawişa, дисплей – ekran, материнская*
*плата – enelik karty* и др.;

– названия единиц измерения: *мегабайт – megabaýt, килобайт – , гигабайт – gigabýte, мегабит – megabit, терабит – terabit* и др.;

– названия действий, операций, процессов: *авторизация – ygtyýarnama, адресация – salgylanmak, выключение – öçürmek, вызов – çagyryş, доступ – dostup, зависание – doňmak* и др.;

– названия лиц, профессий, должностей: *инженер-программист – programma inženeri, администратор – adminstrator, менеджер – dolandyryjy, тестировщик, копирайтер – nusgawy ýazyjy, специалит – hünärmen, разработчик – öndüriji* и др.;

– названия признаков и свойств: *безопасность – howpsyzlyk, релевантность – degişlilik, надежность – ygtybarlylyk, скорость – tizlik, совместимость – gabat gelmek, частота – ýygylyk, яркость – ýagtylyk* и др.;

– термины программирования: *база данных – maglumat bazasy, листинг – sanaw (listing), утилита – utilita, язык программирования – programma dili, объектно-ориентированное программирование (ООП)*

*– obýekte gönükdirilen programmirleme (OOP), наследование, дочерний процесс – miras, çaga prosesi, инкапсуляция – inkapsuirlemek* и др.;

– термины сферы Интернет: *хост – хост Hoster eýesi (host), соединение –goşulmak (baglantmak*), *сайт – sahypa, провайдер – prowaýder, контекстный поиск – kontekst gözleg, домашняя страница – baş sahypa, веб-страница – web-sahypa* и др.;

– названия математических операций, вычислений, чисел, законов: *неравенство – deňsizlik, матрица – matrisa, алгоритм – algoritm* и др.;

– названия наук и учебных дисциплин, связанных со сферой информатики и вычислительной техники: *радиоэлектроника – radio elektronikasy, информатика – informatika, теория вероятности – ähtimallyk teoriýasy, теория информации – maglumat teoriýasy* и др.

Как видно, большинство специальных слов как в русском, так и в туркменском языке заимствованные и пришли из английского языка. Это связано с тем, что в англоязычных странах сфера информатики и вычислительной техники получила наибольшее развитие. В туркменский язык такие лексический единицы пришли чаще всего через русский язык. Иногда при заимствовании из русского языка прибавляется (отбрасывается) аффикс или даже целое слово, слово заимствуется в туркменский язык частично изменённым. В свою очередь, использование внутренних ресурсов туркменского языка также присутствует в терминологии информатики и вычислительной техники.

**Литература**

1. Евсеева И.В. Современный русский язык: Курс лекций. – Красноярск: Сибирский федеральный ун-т, 2007. – 642 с.

2. Бурыева Э.О. Петрова Н.Е. Создание учебных терминологических словарей как интенсивный приём в обучении русскому языку как иностранному в профессиональных целях // Актуальные вопросы обучения русскому языку как иностранному и на русском языке: сборник статей / под ред. Е.Е. Смирновой. – Нижний Новгород: ННГУ им. Н.И Лобачевского, 2020. – С. 75-80.

## ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНДӘ “БЕР” ЛЕКСЕМАСЫНА БӘЙЛЕ УРТАКЛЫКЛАР ҺӘМ АЛАРНЫ РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Вәлиева Л., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Латыпов Р.И.*

Татар теле – иң киң таралган төрки телләрнең берсе, агглютинатив телләр исемлегенә керә. Тел белгечләре тарафыннан төрки телләрнең килеп чыгышын, үсеш-үзгәрешен тарихи җирлектә тикшерүләр даими алып барыла. Соңгы елларда тугандаш төрки

телләрне чагыштырма аспектта өйрәнүгә игътибар артты. Билгеле булганча, татар теленә иң якын телләр – башкорт, нугай, казах, каракалпак, карачай, балкар, комык телләре. Шулай ук уйгур, төрек, гагауз, азәрбайҗан, үзбәк, төрекмән телләре дә татар теленә бик якын торалар [2: 18].

Төрек теле белән тарихи уртаклыкларның чишмә башы Орхон-Енисей ташъязмаларына (V-VI гасыр) һәм борынгы уйгыр язма ядкәрләренә (IX-X гасыр) үк килеп тоташа. Нигезләре уртак Алтай телләре гаиләсеннән булса да, татар теленең кыпчак төркемчәсендә һәм төрек теленең угыз төркемчәсендә формалашуы бу ике телне бер-берсеннән шактый ерагайткан. Татар һәм төрек телләренең чагыштырма-типологик характеристикасында уртаклыклар еш очраса да, үзенчәлекле яклары да күп [2: 36]. Үзара бәйләнештәге телләрне чагыштырып өйрәнү грамматикадагы охшаш һәм аермалы якларны ачыкларга мөмкинлек бирә. Ә ике телне үзара тиңләштереп карау барышында генеалогик яктан ук килгән уртаклыклар дәлилләнә.

Татар һәм төрек телләрендә иң ачык охшаш күренешләрнең берсе сан категориясенә хас. Татар кешесенә төрек телендәге саннарны өйрәнү, аңлау, куллану бик җиңел бирелә. Бу ике телдә саннар тәңгәл килә, аларның әйтелеше охшаш һәм аңлаешлы. Әйтелеш һәм яңгыраш тәңгәллекләреннән тыш, грамматик аспектта да уртаклыклар бар. Әлеге уртаклыкларны татар телендәге “бер” һәм төрек телендәге “bir” лексемасы кулланышы мисалында карыйк. Бу төрдә берничә тәңгәллек ачыкланды. 1) Татар телендә “бер” лексемасының төп мәгънәсе сан категориясенә карый, предметның исәбе буларак кулланыла. “Бер алтын тәңкә бирде дә кереп китте” җөмләсендә алтын тәңкәнең бер данә икәне билгеле. “Бик шәп ике караваt, бер өстәл ясаталар” [4: 116] җөмләсендә дә “бер” лексемасы предмет санын белдерә.

Төрек телендә дә сан категориясе кулланышында татар теленең грамматик табигате белән тәңгәллекләр бар. Төрек телендә әлеге лексеманың санны белдереп килү очракларын төрек әкиятләреннән алынган җөмләләрдән күзәтик. “Bak, benim karnımda on dirhem ağırlığında bir inci vardı”[6: 3] өзегендә кош эчендәге бер данә энҗе бөртеге хакында сүз бара. “bir” лексемасы предмет санын, исәбен ачыклый. Сан категориясенең тәртип саны төрендә куллану да татар теле грамматик формалары белән тәңгәл: “Dinle, birinci öğüdüm şu: “Olmayacak bir söz duyarsan, asla inanma!” [6: 4]. Өзектә “bir” тамырлы тәртип санының -inci кушымчасы белән килә, әкият эчтәлегендә беренче киңәш турында сүз бара. Татар халык әкиятендә “бер” тамырлы тәртип саны кулланышына тәңгәл мисал: “Беренче кораб

кузгалып китә”. Күргәнебезчә, татарча “бер”, төрекчә “bir” саннарының лексик-грамматик табигате тәңгәл.

Рус җөмләсе контекстында конкрет предметлар турында сүз барганда, тәрҗемәдә төрек стилистикасына яраклаштырып, “bir” лексемасы өстәлә: Я хочу выпить чашечку кофе и съесть пироженное – Ben bir fincan kahve içmek ve bir pasta yemek istiyorum. Мисаллардан күренгәнчә, рус телендә саналып киткән предметлар төрек теленә тәрҗемә ителгәндә данәсе ягыннан ачыклап киләләр. Рус теленнән аермалы, татар һәм төрек телендә “бер стакан су” (стакан воды), “бер кашык бал” (ложка меда) кебек сүзтезмәләрдә “бер” лексемасы данәне күрсәтә.

2) Татар телендәге “бер”, төрек телендәге “bir” лексемалары билгесезлек төсмерен белдереп, билгесезлек артикле вазыйфаларын башкара. “Кораб узып китә, кыз янына бер төенчек килеп җитә”[4: 118]. Әкиятнең контекстында “бер” лексемасы суда йөзеп баручы кыз янында ниндидер билгесез төенчек килеп чыгуны аңлата. Бу очракта, контексттагы “бер” сүзе белән төенчекнең саны, бер данә булуы турында сөйләнелми. Җөмләдә “бер” – билгесезлек артикле. Төрек әкиятеннән алынган мисалда да “bir” лексемасы кулланышы үрнәгендә татар телендәге әлеге әлеге күренешкә тәңгәл булуын күзәтик: “Küçük kuş damdan kalkıp yüksekçe bir ağacın dalına kondu ve oradan gökyüzünün boşluğuna doğru süzülürken şöyle bağırdı” [6: 4]. Өзектән күренгәнчә, бәләкәй кош ниндидер билгесез бер агачка барып куна. Тел белеменнән билгеле булганча, бер саны, предметның исәбе буларак кулланылмаганда, предметка билгесезлек төсмере өсти, предметны билгеле булуы мөһим булмаган бер әйбер итеп күзалларга ярдәм итә. [3: 59]. Халык әкиятләреннән алынган мисалларда “bir” лексемасының билгесезлек төсмерен ассызыклавы очраклы хәл түгел. Төрек телендә гадәти сөйләм барышында да әлеге төр бик актив. Ben bır mektup göndermek istiyorum. – Миңа бер хат җибәрергә кирәк. Мисалларда нинди дә булса билгесез хат турында сүз бара. Рус теленә тәрҗемә иткәндә билгесезлек артиклен белдерүче сүз тәрҗемә ителми: Мне нужно отправить письмо. Контекстта билгесезлекне башка чаралар ярдәмендә тәрҗемә итү дә күзәтелә: Aidın Meşe bir okulda öğretmenlik yapıyor. – Айдын Меше работает учителем в какой-то школе. Рус теленнән төрекчәгә тәрҗемә иткәндә, җөмлә эчтәлегендә билгесезлек ассызыкланганда “bir” лексемасы ярдәмендә тәрҗемә ителә: Меня укусило какое-то насекомое – Bir sinek beni soktu.

Нәтиҗә ясап әйткәндә татар телендә “бер”, төрек телендә “bir” лексемалары сан һәм билгесезлек артикле булып кулланылалар. Чагыштырулар нәтиҗәсендә ике телгә дә хас тәңгәллекләр булуы дәлилләнде.

**Әдәбият**

1. Кузнецов П.И. Учебник турецкого языка. Начальный курс. – М.: Муравей-Гайд, 2000.
2. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Пратюркский язык-основа. – М.: Наука, 2006. – 907 с.
3. Татар теле грамматикасы / Өч томда. Т.2. – М: Инсан, Казань: Фикер, 2002.
4. Татар халык иҗаты: әкиятләр: 3 томда. Т.3. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – Б. 115-122.
5. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен д-лек. – Казан: Мәгариф, 2006.
6. Minik Kuşun Öğüdü / Самые лучшие турецкие сказки. – М.:Изд.АСТ, 2020. – 123 с.

# Г. ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ ИҖАТЫНДАҺӘМ ӘСӘРЛӘРНЕҢ РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘСЕНДӘ СИНОНИМИК ПАРЛЫ СҮЗЛӘР

(“Ак чәчәкләр” һәм “Газинур” романнары мисалында)

*Вилданова Ә., КФУ, IV курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Денмөхәммәтова Э.Н.*

Тәрҗемә белеме бүгенге көндә зур үсеш-үзгәреш кичерсә дә, теоретик һәм гамәли яктан камилләшеп торса да, тәрҗемә әсәрләрендә төгәлсезлекләр шактый. Аерым бер сүзне тәрҗемә итү зур кыенлык тудырмаса да, телебездә уникаль булган парлы сүзләрне тәрҗемә итүдә кыенлыклар шактый. Ни өчен дигәндә, парлы сүзләр ике сүздән тора һәм, күпчелек, фонетик яктан охшаш сүзләр була. Шуңа күрә андый сүзләрне тәрҗемә итү бик зур кыенлык тудыра.

Г. Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романы да, “Газинур” романы да иң күп укыла торган әсәрләрдән санала. Әсәрләрдә парлы сүзләр шактый күп кулланылса да, тәрҗемәдә алар бик аз.

Әлеге парлы сүзләр ничек тәрҗемә ителгән соң? “Ак чәчәкләр”дә синонимик составлы парлы сүзне рус теленә дә парлы сүз белән тәрҗемә итү очраклары күзәтелмәде. Ә “Газинур” романында парлы синонимик сүзләрне парлы синонимик сүз итеп тә тәрҗемә итү мисалын таптык. *“Их, советлар союзының киңлеге! – диде Газинур, - күпме вакыт киләбез, һаман **очы-кырые** юк”[4: 256] – “Сколько едем, а всё нет ему **конца-краю**”[2: 219]*. Күргәнегезчә, татар телендәге синонимик парлы сүз рус теленә дә синонимик парлы сүз булып тәрҗемә ителгән. Шунысын әйтергә кирәк, “Ак чәчәкләр” романында да очы-кырые синонимик парлы сүзе бик күп тапкыр очрады, ләкин аны парлы сүз итеп тәрҗемә итү күзәтелмәде. Ә “Газинур” романын тәрҗемә иткән тәрҗемәчеләр мәгънәне дә, форманы да саклап, рус телендә сөйләмдә дә еш кулланыла торган парлы сүз белән тәрҗемә итәләр.

Күп очракта синонимик парлы сүзләр ике синоним сүз өчен дә уртак мәгънә белдергән бер сүз белән генә тәрҗемә ителә: “*Әнә бер*

*хатын көянтә белән **иелә-сыгыла** су алып кайта , әнә ишегалды аркылы сузылган бауга кызыл башлы сөлгеләр кибәргә элгән" [3: 15] – "Вот женщина переходит улицу, **сгибаясь** под тяжестью коромысла"[1: 16]*. Мәсәлән, *Иелә-сыгыла* парлы сүзенең составын синонимик мәгънәле сүзләр тәшкил итә [5: 253]. Парлы сүзнең компонентларын аерым алып карасак, синонимнар сүзлегендә *иелү (нагибаться, наклоняться, согнуться) – бөгелү,сыгылу,иңкәю, янтаю* кебек бирелгән. Ә тәрҗемәдә бирелешенә карасак, ул *сгибаясь* фигыле белән генә алыштырып бирелгән. Шулай ук "Газинур" романында мондый тәрҗемәне күрә алабыз: "***Хәвеф-хәтәр** юкмы?"[4: 87] – "Кажется, миновала нас **беда**?" [2:78]. Хәвеф-хәтәр* парлы сүзен *беда* сүзе белән тәрҗемә иткәннәр, бу тәрҗемәне дөрес дип кабул итәбез, чөнки ул әлеге синонимик парлы сүзнең гомуми мәгънәсен белдереп килә торган сүз. Шунысын әйтергә кирәк, рус телендә сүзләрне кушып парлы сүзләр ясалу төрки телләрдәге кебек продуктив ысул булып саналмый. Составында синоним берәмлекләр булган парлы сүзләрдә төп мәгънәгә ия сүз дип икенче сүз дип карала.

Кайбер очракта парлы сүз составындагы синоним берәмлекләрнең мәгънәсен үзгәртмичә, тиңдәш кисәкләр итеп тәрҗемә ителгән. *"Алар тирәсенә "Красногвардеец"ның башка **хатын-кызлары** җыела"[4: 249] – "Рядом с нею встала Альфия и другие **женщины и девушки** "Красногвардейца" [2: 214]*. Әлеге мисалдан күренгәнчә, *хатын-кыз* синонимик парлы сүзе *женщины и девушки* дип тәрҗемә ителгән. "Ак чәчәкләр" романының тәрҗемәсендә *хатын-кыз* парлы үзен бары тик *женщина* дип кенә тәрҗемә итү күзәтелде. Ә менә "Газинур" романында тиңдәш кисәкләр белән тәрҗемә ителгән. Контекстка бәйле карасак та, әлеге тәрҗемә дөрес, чөнки сүз зур яшьтәге хатыннар турында гына түгел, кыз балалар турында да бара. Һәм мондый тәрҗемә, безнеңчә, бик отышлы.

Шулай ук синонимик парлы сүзне дөрес яки уңышлы тәрҗемә итмәү очракларын да ачыкладык. иде, дип исәплибез. Бер мисал карап үтик. "*Сезнең **хәер-фатихада**, - диде Яңгура шаян гына" [3: 66] – "Вашими **молитвами**,- пошутил Янгура" [1: 64]. Хәер-фатиха* парлы сүзенең тәрҗемә ителешенә игътибар итик. Ул *молитва* дип тәрҗемә ителгән. Сүзлектә исә әлеге сүз *благословение* дип тәкъдим ителгән. Бу очракта *молитва* сүзе белән тәрҗемә итү дөрес түгел дип саныйбыз. Чөнки, аңлатмалы сүзлеккә мөрәҗәгать итсәк, әлеге сүз *"изге теләк, ризалык, юллама"* мәгънәләрендә бирелгән. Һәм аны *"молитва"* сүзе белән генә тәрҗемә итү синонимик парлы сүзнең мәгънәсен тарайта, шуңа күрә бу очракта, сүзлек тәрҗемәсенә битараф булмыйча,

*“благословение, благословлять”* сүзләре белән тәрҗемә ителсә, күпкә уңышлырак булыр иде, дип уйлыйбыз.

Парлы сүзләр, гомумән, тәрҗемә ителмәгән очраклар да күзәтеләде. “*Мансур бар, ләкин кайдадыр бер читтә басып тора, якын да килми, ерак та китми, һәрвакыт шулай: күзгә күренә – сөйләшергә* ***тавыш-өне*** *юк” [3: 14] – “Вроде бы и виден Мансур, но не подойдешь, не поговоришь” [1:16].*

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: татар телендә парлы сүзләр еш кулланыла һәм сүз байлыгының аерылгысыз бер өлеше булып тора. Г. Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” һәм “Газинур” романнарында әлеге караш дәлилләнә. Чынлап та, автор бик күп парлы сүзләр куллана. Аларны тәрҗемә итүгә килгәндә, ике романдагы синонимик парлы сүзләр төрлечә тәрҗемә ителә. “Ак чәчәкләр” романындагы синонимик парлы сүзләрне рус теленә тәрҗемә иткәндә күбрәк тиңдәш кисәкләр белән тәрҗемә ителгән, ә “Газинур” романын тәрҗемә иткәндә күбрәк ике синоним сүз өчен дә уртак мәгънәгә ия булган бер генә сүз белән тәрҗемә итү күзәтелә.


**Әдәбият**

1. Абсалямов А.С. Белые цветы: Роман. / Пер. С татарского К. Горбунова. Художник И. Субаев. – Казань: Татарское кн. изд-во, 1987. – 560 с.
2. Абсалямов А.С. Газинур: Роман / Авторизов. перевод М. Демидовой, М. Чечановского. - Казань: Татарское книжное издательство, 1991. – 384 с.
3. Әпсәләмов Г. Ак чәчәкләр: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 575 б.
4. Әпсәләмов Г. Газинур: Роман. – Казан: Татгосиздат, 1953. – 506 б.
5. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. ─ Казан: Хәтер,1999. – 256 б.


## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СИЗҮ-ТОЮ ФИГЫЛЬЛӘРЕНЕҢ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРДА КУЛЛАНЫЛЫШЫ


*Габделхакова А., КФУ, IV курс студенты*

*Фән. җит. – филол.фән.канд., доц. Сәлахова Р.Р.*


Татар теленең фразеологик фонды бай һәм күпкырлы. Фразеология кеше сөйләмен баетуда, үтемлерәк, көчлерәк һәм үткенрәк итүдә художестволы әсәр стиленә сәнгатьлелек бирүдә, фикерне тулырак ачуда әһәмиятле роль уйный.

Татар телендә фразеологик берәмлекләр күпчелек очракта исем һәм фигыль сүз төркемнәренең кушымтасыннан гыйбарәт. Гомумән, фразеологик берәмлекләрдә фигыльләр хәлиткеч роль уйный.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, татар телендә күпчелек фразеологизмнарны “Кеше” макрогруппасына кергән фразеологик берәмлекләр тәшкил итә. Билгеле, бу төр фразеологизмнарда кешенең сизү-тою мөмкинлекләрен тасвирлаучы фигыльләр кулланыла.

Гомумән, күпчелек галимнәр фикеренчә, лексикологиядә фигыльләрнең лексик-семантик төркемнәре арасында сизү-төю төркеме аеруча киң һәм бай булуы билгеләнә.

Безнең фикеребезчә, татар теленең фразеологик фондында фигыльләрнең әлеге төркеме аеруча актив кулланылышта йөри. Моның сәбәпләре түбәндәгедән гыйбарәт: беренчедән, сизү-тою фигыльләре кеше тормышын сурәтләүдә аерылгысыз элемент булып тора, ә фразеологизмнарның күпчелеге – кешенең гамәлләре, хис-кичерешләре белән бәйле төстә формалашкан. Икенчедән, фразеологизмнарның соматизм дип аталган бер төркеме турыдан-туры кешенең төрле әгъзалары ярдәмендә башкарылган эш-гамәлләре белән бәйле. Шуңа күрә дә татар теле фразеологик фондында сизү-тою фигыльләре куланылышының үзенчәлекләрен, ешлыгын тикшерү эше, безнең фикеребезчә, бүгенге көндә фразеологиядә фигыльнең бу мәгънәви төркемчәсенең ролен ачыклауга булышлык итәчәк.

Татар теле фразеологизмнарында сизү-тою фигыльләренең кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерүне хезмәтебезнең максаты итеп куйдык. Хезмәтнең тикшерү объекты – татар теле фразеологизмнары. Тикшеренү предметы – фразеологизмнарда сизү-тою фигыльләренең кулланылыш үзенчәлекләре.

Фигыль – сөйләмнең нигезен тәшкил итүче сүз төркеме. Фигыльләрсез төзек сөйләм барлыкка килә алмый. Шуның белән бергә әлеге сүз төркеме шактый катлаулы да, кызыклы да. Татар телендә фигыль сүз төркеменең грамматик үзенчәлекләре шактый өйрәнелгән. Шуның белән беррәттән фигыльләрнең лексик-семантик төркемнәренә тиешле игътибар бирелеп җитми. Фигыльнең лексик-семантик төркемчәләре мәктәп программаларында да махсус рәвештә укытылмый.

Фигыль сүз төркеменең мәгънәви төркемчәләре шактый күп. Фәндә фигыльләрнең лексик-семантик төркемчәләре түбәндәгечә аерыла: хәрәкәт, эш-гамәл, процесс, халәт, мөнәсәбәт,үз-үзеңне тоту, яңгыраш, сөйләм, фикерләү, сиземләү һәм күренешне охшатып кабатлау аша белдерүче фигыльләр.

Сизү-тою лексик-семантик төркеменә караган фигыльләр татар телендә шактый бай төркем тәшкил итә. Бу төркемгә караган фигыльләрнең төш семасы “сизү” фигыленнән гыйбарәт. Сизү фигыленең синонимик рәте тою, хис итү, белеп-аңлау лексемаларыннан гыйбарәт. Әлеге лексемалар сизү-тою фигыленең семантик кырын булдыра. Шул ук вакытта, рус телендә бу фигыльгә туры килүче лексемалар саны күбрәк. Әмма татар телендә дә, рус телендәге кебек үк, бу лексемаларның семантикасы бар, еш кына алар бары тик бер сүз белән генә билгеләнә, әмма асылда аның эш-

хәрәкәтне белдерүче формасы аңлашыла. Әлеге үзенчәлек телебезнең компактлыкка омтылуы белән аңлатыла. Шулай ук, татар телендә сизү фигыле аерым бер семантиканы белдерү максатыннан еш кына башка сүз төркеменә караган лексемалар белән берлектә кулланыла. Нәтиҗәдә телебездә сизү-тою фигыле һәм башка сүз төркеменнән булган сүзләр тотрыклы гыйбарәләр – фразеологик берәмлекләр барлыкка китерә.

Татар тел белемендә фразеологизмнар XX йөздә генә өйрәнелә башлый. Башлангыч этапта фразеологизмнарны Л.Җәлил, Ш.Рамазанов, Л.Мәхмүтова, Н.Борһанов, В.Хәкимов, К.Сабиров, Г.Х.Ахунҗанов, Х.Корбатов, Г.Әхәтов кебек галимнәр туплый, системалаштыра һәм төрле яклап өйрәнә. Алга таба татар телендә фразеологизмнар Э.М. Ахунҗанова, Н. Исәнбәт, Х.Х. Ярмөхәмәтов, Х.Ш. Мәхмүтов, З. Нурилар тарафыннан өйрәнелә. Соңгы елларда татар фразеологиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тарафыннан төрле яклап өйрәнелә. Р.Г. Йосыпов, Л.К. Бәйрәмова кебек авторларның хезмәтләрендә фразеологизмнар чагыштырма планда карала.

Татар телендә фразеологизмнарда сизү-тою фигыльләре шактый еш кулланыла. Анализ күрсәткәнчә, 558 соматик фразеологизмның 81ендә сизү-тою фигыльләре кулланылган. Әлеге фразеологизмнарда түбәндәге сизү-тою фигыльләре очрый: карау – 24, күрү – 32, аларту – 4, елау – 1, төелү – 1, кичерү – 7, буылу – 1, чуарлану – 1, кымыржу – 1, төбәү – 1, ышанмау – 1, иyләшү – 1, тую – 1, чалыну – 1, алдау – 1, көтү – 1, күзләү – 1, саклау – 1. Иң еш кулланылучы сизү-тою фигыльләре – ул карау, күрү, кичерү фигыльләре. Мәсәлән: *күзләрен тутырып карау, күзләрен мөлдерәтеп карау, күзләрен батырып карау, күз карап торганым, күзем күрмәсен, күздән кичерү, күзгә күренеп һ.б.*

Нәтиҗә ясап әйткәндә, фразеологиядә сизү-тою фигыльләре еш кулланыла. Шуның өчен дә фразеологизмнарны яхшырак истә калдыру, аларның мәгънәсен аңлау өчен беренче чиратта бу фразеологизмнардагы фигыльләрнең лексик-семантик үзенчәлекләрен өйрәнүне кирәк дип исәплибез.

**Әдәбият**

1. Ахунзянов Г. Х. Татар теленең идиомалары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. – 118 б.

2. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 176 б.

3. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 571 б.

4. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001. – 199 б.

# М. МИРЗАНЫҢ “АДӘМ БАЛАСЫ” ШИГЫРЬЛӘР ЦИКЛЫНДА КӨНЧЫГЫШ ӘДӘБИ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

*Габделхакова С., КФУ, III курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., доц. Йосыпова Н.М.*

Мөхәммәт Мирза, соңгы еллар сүз сәнгатендә барган төп тенденцияләрне әйдәп алып баручы сүз осталарының берсе буларак, шигырь-поэмаларында кешелекнең яшәеш кануннарын аерып чыгарган, кешене олы кыйммәт итеп күтәргән яисә тормыш закончалыкларын тәнкыйть утына алган үзгә әдәби модельне укучы хөкеменә тәкъдим итә. Сәнгати яссылыкта аның иҗаты татар шигъриятенең үз, нигез традицияләрен дәвам итеп, яңартып, көнчыгыш әдәби үзенчәлекләрен заманга яраклы үстереп алып китә.

1980 нче елларның икенче яртысында лирик шигырьләре, җырлары, поэмалары, хикәяләре, әдәби тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләре белән әдәбият мәйданына килеп керсә дә, М. Мирзаның таланты шигърият төрендә ачыла. «Кәккүк тавышын санадым» (1994), «Турайгыр» (1998), «Киек каз юлында» (2003), «Тере су» (2007) кебек җыентыклары басылып, әдәби җәмәгатьчелек һәм тәнкыйтьчеләр тарафыннан хуплап каршы алына.

М.Мирза татар шигъриятенең алга таба үсешен үз, нигез традицияләрне яңартуда, көнчыгыш әдәби үзенчәлекләрен заманга яраклы дәвам итүдә күрә. Шагыйрь шигъриятнең үсешен асыл кыйммәтләрне милләт хәтерендә яңартуга бәйли, шәркый сәнгати алымнарның актуальлеген югалтмавын дәлилли. Бу сыйфат аның шигырьләрендә чагылыш тапкан дөнья сурәтендә, лирик геройның дөньяга карашында яки тәрбияви максатларда гына түгел, сурәтләү чаралары, образлылыкта, жанрлар төрлелегендә яисә шигырь калыбын, хәтта үлчәмен сайлауда да ачык күренеп тора. Аның әсәрләрендә шәркый әдәби сурәтләр шигырь структурасына табигый кереп урнаша, көнчыгыш, ислам фәлсәфи тәгълиматларына хас караш-билгеләр алга чыга, әдәби тасвирда гарәп-фарсы лексик берәмлекләренә урын бирелә, шәркый әсәрләргә охшатып стильләштерү күзәтелә.

Шагыйрь иҗатында бишьюллыклар, аеруча «Адәм баласы» шигырьләр циклы үзенчәлекле, ул «композиция, эчтәлек һәм күләм күзлегеннән карап, аларны миниатюралар») [5:151] «шәрык һәм гареб әдәбиятлары өчен хас дөньяга карашларны, иҗат ысулларын, жанрларны бергә очраштырган, синтезлаган уникаль күренеш, ачыш» ) [1: 35] буларак бәяләнә.

Милли шигърияттә «Туфан строфасы» буларак калыплашкан һәм лирик герой кичерешен, автор фикерен яңгыраш-тәэсир

бөтенлегендә җиткерүгә йөз тоткан бишьюллыкны М. Мирза яңача, чичән шагыйрьләр стилендә табышмак формасында коруга ирешә. Мәкаль-әйтемнәр куллану, шигырь юлларын хикмәтле сүз кебек төзергә омтылу, «шәркый» характерлы, бик нечкә ирониягә, төртмәле кинаягә мөрәҗәгать итү – барысы да аларның оригинальлеген тәэмин итә. Шагыйрьнең осталыгы образларны көтелмәгән мәгънә борылышлары белән баетып, ассоциацияләр тудыра алуда да күренә.

Әлеге циклда урын алган бишъюллыкларны символик эчтәлекле җыелма Адәм баласы образы, философ статусындагы лирик герой һәм фәлсәфи башлангыч бербөтенгә туплый. Лирик герой укучыны кешелек өчен беренчел кыйммәтләр, яшәү мәгънәсе, шәхеснең тормыш-яшәештәге урыны, вазифасы хакында сөйләшүгә алып керә, кешелек һәм кеше турында уй-тойгылары белән уртаклаша. Шагыйрь үзе аларны «уйлы шигырьләр» дип атый: Шушы контекстта Адәм баласы кешелекнең үзе булып кабул ителә башлый.

Бу циклдагы һәрбер шигырь тормыш фәлсәфәсе булып кабул ителә. Поэтик яссылыкта нур образына басым ясала: ул мәңгелек нуры, яктылык нуры, илһам нуры, иман нуры кебек шәрехләнеп, төрлечә аңларга мөмкин булган символ югарылыгына куела: илаһи биеклеккә күтәрелә алганнарның җаны («Адәм баласының / Нурга әверелеп / күрер кайсылары?»), ышаныч, өмет («Кап-кара төннең дә / бар сүрелмәс нуры...»), яшәешне барлыкка китерүче илаһи көч («Бөек яратылышның / даһи иҗатчысы...»), Аллаһ рәхмәте («Адәм баласының / җаны Илаһысы / нурында коенган...»), иман нуры («Ана сөте белән керә, диләр, / Бала күңеленә иман нуры») мәгънәләрендә укыла.

Шагыйрь иҗатында көнчыгыш традицияләренең тергезелүе образлар системасында ачык чагылыш таба. Шәркый шигърияттән яхшы мәгълүматлы М.Мирза көнчыгыш поэзиясендә еш кулланылган образларга яратып мөрәҗәгать итә. Мәсәлән былбыл, гөл кебек суфичылык поэзиясе аша таныла торган образлар тормышка булган мәхәббәтне һәм лирик геройның шушы тормышны бүләк иткән Аллаһка мәхәббәтен тасвирлауга юнәлтелә, лирик герой үз тормыш тәҗрибәсеннән туган караш-фикерләр белән уртаклаша. Символик образларга таяну М. Мирзаның кайбер шигырьләрен суфи текстлар рәтенә куя. Мисал өчен, «Дөнья гел алыш-бирештә, аңла син...», «Кемлегенә карап, сыен куясың...» кебек шигырьләрдә нур образы Аллаһка мәхәббәт, иман мәгънәләрендә кулланыла.

М. Мирзаның фәлсәфи эчтәлекле шигырьләрендә көнчыгыш әдәбиятына хас изгеләштерү дә күзәтелә, шушы фонда шигърият, шигъри сүз еш кына Илаһи нур чагылышы кебек шәрехләнә, шагыйрь образының вазифасы да шуңа бәйле билгеләнә: Шагыйрь – шигырь

язучы чикләрендә генә калмыйча, яшәешнең пульсын алдан сиземләүче, җәмгыятьне рухи яктан төзек, сәламәт тотучы пәйгамбәр, милли юлбашчы кебек күзаллана.

Гомумән, шагыйрь мәңгелек рухи кыйммәтләрне җиткерүгә хезмәт итәргә тиеш дигән фикер М. Мирза иҗатын иңләп бара. Автор фикеренчә, теге яки бу чорга дан җырлаган әдипләрнең иҗат гомере кыска, шагыйрьләрнең гражданлык бурычы милләткә китергән файдасы, аның тормышында тоткан урыны белән бәйләп куела.

**Әдәбият**

1. Ганиева Р. Акыллы сүз белән рухи-әхлакый яңарышка таба // М.Мирза Сайланма әсәрләр: 5 томда. Т. 5. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2018. – 535 б.
2. Заһидуллина Д.Ф. М.Мирза шигърияте: жанр өлкәсендә яңалыклар // М.Мирза. Сайланма әсәрләр: биш томда. Т. 2. – Казан: Мәгариф – Вакыт нәшр., 2018. – 383 б.
3. Йосыпова Н.М. Татар шигъриятендә шәркый традицияләр яңарышы: М.Мирза иҗаты // М.Мирза. Сайланма әсәрләр: биш томда. Т. 1. – Казан: Мәгариф – Вакыт нәшр., 2018. – 335 б.
4. Переяслов Н. Кажущаяся легкость поэтической «школы» Хайяма // Аргамак. – 2011. – № 8. – С. 17-19.
5. Хасанова Ф.Ф. Новый жанр в татарской литературе: «Татарская танка» // Научный Татарстан. – 2009. – № 4. – С. 151.

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЭТНОМӘДӘНИ КОМПЕТЕНЦИЯНЕ ҮСТЕРҮ АЛЫМНАРЫ

*Галеева А., М. Акмулла ис. БДПУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гареева Р.Р.*

Бүгенге көндә ФДББС шартларында белем бирүдә төп игътибар коммуникатив компетенция белән бер рәттән этномәдәни компетенциягә бирелә. Әлеге шартларда укучыларга татар телен ничек нәтиҗәле итеп укытырга? Ягъни замана балаларының ничек этномәдәни компетенциясен үстерергә? Һәр укытучы алдында мондый проблемалы сораулар туа.

Этномәдәни компетенция укучыларда тел белән этник мәдәният арасындагы бәйләнешнең ныклыгы турындагы күзаллауны камилләштерүгә юнәлтелгән. Укучылар тел берәмлекләрендә чагыла торган этник үзенчәлекләрне, төрле тел һәм мәдәниятләрнең уртак һәм аермалы якларын танып белергә; дөнья картинасының чагылыш мөмкинлекләрен аңлау күнекмәсенә ия булырга; этник мәдәниятне саклау һәм үстерү әһәмиятен аңларга; этник мәдәният ирешкән дәрәҗәләрне, мәдәниятләр һәм телләр мөнәсәбәте үзенчәлекләрен күзалларга өйрәнә. Моннан тыш укучы татар халкының теле, мәдәнияте һәм тарихы арасындагы бәйләнешне күзаллый башлый. Татар халкының көнкүрешен билгели торган лексика; искергән сүзләр,

фольклор лексикасы һәм фразеология; татар исемнәрнең этимологиясе белән таныша. Татар мәкаль-әйтемнәренең мәгънәләрен һәм аларны тиешле вакытта кулланырга өйрәнә. Башка телләрдән алынган лексика, аларны үзләштерү үзенчәлекләрен күзаллый.

Укучыларның этномәдәни компетенциясен үстерү аларда иҗади эшләү сәләтен үстерү, тәрбия эшендә югары нәтиҗәләргә ирешү, җәмгыятьтә үз урыннарын таба алырлык толерант шәхес тәрбияләү кебек максатларга ирешергә ярдәм итә [2: 7].

Этномәдәни компетенция җирлегендә телнең мәдәнияттан һәм тарихтан аерылгысыз булуына игътибарны юнәлтү мөһим. Дәрестә тел берәмлекләрендә, аларның мәгънәләрендә миллилек чагылышын күрә белергә өйрәтү, төрле телләрдә уртак төшенчәләрнең һәм берәмлекләрнең кулланылыш үзенчәлеген, алар аша дөньяны танып белүдәге уртак һәм аермалы якларны ачу; тел берәмлекләре аша милли дөнья картинасы ачылу үзенчәлекләрен өйрәтү – бу татар телен укыту процессында этномәдәни компетенцияне үстерүдә мөһим бурычлар булып тора. Бу мәкаль-әйтемнәр, фразеологик берәмлекләр, ономастик лексика, афоризмнарны өйрәнүне таләп итә. Укучылар татар сөйләм әдәби нормаларын өйрәнә. Аларның сөйләм эшчәнлеге үсеше һәм шәхси үсеш-үзгәреше этномәдәни компетенциядә ачык чагыла: тел материалы халыкның мәдәниятен һәм тарихын чагылдыра торган билге буларак бирелә.

Этномәдәни компетенцияләрне камилләштерү милли төбәк компонентын өйрәнүдән башлана. Тел дәресләрендә укучыларны төбәкнең тарихы, мәгарифе, мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән таныштыру, төбәктән чыккан күренекле шәхесләрнең эшчәнлеген өйрәнү, очрашулар оештыру – бүгенге көндә мөһим алымнар булып тора [3: 126].

Билгеле: һәрбер дәрес кысаларында бары тик шушы темаларга гына әңгәмә кору мөмкин түгел, темаларны сайлауда төрлелек булырга тиеш. Шулай да һәрбер сыйныфта бер уку елына 8-10 дәрестә тел белемен халкының этнографиясе һәм тарихы белән бәйләп бирү укучыларның мәгълүмати базасын арттыра ала.

Мондый төр дәресләр үткәрүнең актуальләге бәхәссез. Беренчедән, бүгенге көндә мәктәпләрдә татар халкы тарихы бик аз күләмдә укытыла. Шуңа күрә туган тел дәресләрендә кызыклы этнографик-тарихи темаларны яктырту укучыларга үз халкының үткәне турында күпмедер күләмдә мәгълүмат биреп, аларда татар тарихын өйрәнүгә мотивация булдыра. Икенчедән, бүгенге көн укучыларында татар халкының гореф-гадәтләре, традицияләре турында күзаллау бик шартлы. Бигрәк тә зур шәһәрләрдә яшәүче балалар өлкән буын вәкилләре – әби-бабаларыннан читтә яши, шуңа

күрә аларда татар халкының гасырлар дәвамында формалашкан гореф-гадәтләре турында хәбәрсез булып калуы ихтимал. Өченчедән, мондый тип информация укучыларда милли музейларга һәм аларның экспонатларына кызыксыну уята, укучылар музейга барыр алдыннан да күпмедер күләмдә мәгълүмат ала. Дүртенчедән, укучыларда татар халкының дөнья цивилизациясенең бер өлеше булуын, аның үз милли киенү рәвеше, күзаллаулары, гореф-гадәтләре, рухи һәм материаль байлыгы барлыгы турында фикер урнаша.

Татар телен дәүләт теле буларак өйрәтүнең төп принцибы – коммуникатив принцип [5: 32]. Мондый дәрестә уеннар куллану зур роль уйный. Ул төрле методик алымнар белән эшләргә ярдәм итә. Мәсәлән, уен-эзләнү, рольле уеннар (сатучы, сәяхәтче, табиб), сорау-җавап уены һ.б. Сәяхәт уен да балалар өчен бик кызыклы һәм файдалы. Кирәкле тукталышка барып җитү өчен, татар халык мәкальләрен, табышмакның җавапларын һ.б. табарга тиеш булалар. Аның рус эквивалентын әйттерү телләрнең охшашлыгына дәлил булып килә.

Безнең тормышның тагын бер өлеше – компьютер. Аны укучыларда гражданлык хисләр тәрбияләгәндә куллану мөһим роль уйный. Укучыларга төрле темаларга презентацияләр ясау, проектлар төзү, рефератлар, видеороликлар әзерләү кебек биремнәр тәкъдим итү укытуда зур урын алып тора.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: татар тел дәресләрендә этномәдәни компетенцияне үстерүгә юнәлгән биремнәр куллану мөмкинлекләрен, алшартларын ачыклауны төп юнәлеш итеп алсак, куелган максатларга ирешергә мөмкин. Укытуны коммуникатив нигездә оештыру – укучыларның этномәдәни компетенциягә ия булу шарты.

**Әдәбият**

1. Мозаффарова М. Г. Тәгълим-тәрбия процессын оештыруда милли мәгърифәтчелек идеяләрен гамәлгә кую: гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре өчен тәкъдимнәр. – Казан: ТРМҮИ, 2016. – 56 б.

2. Мөхәммәтҗанова А. Х., Камаева Р. Б. Татар теле һәм әдәбият укытучысына ярдәмгә: ФДББС турында белешмәлек һәм терәк схемалар: методик ярдәмлек. – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 68 б.

3. Харисов Ф. Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 366 б.

4. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Педагогик технологияләр. – Казан: Мәгариф, 2008. – 366 б.

5. Шәкүрова М.М., Юсупов А.Ф., Хөснетдинов Д.Х. Татар урта гомуми белем бирү оешмаларында татар телен укыту методикасы. – Казан: Казан ун-ты, 2015. – 110 б.

## ОСОБЕННОСТИ ПРЕПОДАВАНИЯ ТУРЕЦКОГО ЯЗЫКА В ТАТАРСКОЙ АУДИТОРИИ

*Галиева Г., КФУ, студент III курса*
*Науч. рук. – канд. наук, ст. препод. Гайнутдинова А.С.*

Во время обучения иностранному языку, можно провести некоторые параллели с родным языком. В таком случае, процесс преподавания будет доставлять меньше трудностей. Частенько получается так, что в родном языке не бывает аналогов или же используется по-другому. Во время преподавания турецкий и татарский язык вступают в тесный контакт. Турецкий и татарский языки входят в одну и ту же языковую подгруппу. Из этого следует, что они являются близкородственными языками. Однако, чтобы передать мысль на иностранном языке, недостаточно просто иметь словарный запас, а нужно владеть хотя бы простейшими представлениями о строении предложений и уметь свободно конструировать их.

Метод сопоставления позволяет обнаружить сходства и различия между исследуемыми языками. Языки также сходны и в использовании. В данном докладе будет затронуты некоторые различия способов выражения логической построении мысли и расхождения лексической и морфологической систем.

I. Различия в построении выражений турецкого и татарского языков.

А) В турецком языке, союз ki соединяет две части сложного предложения, при этом главное предложение предшествует придаточному, тогда как в татарском языке нет аналога: Seni seviyorum ki bunca cefaya katlandım. – Мин сине шул кадәр нык яратам, хәтта барлык авырлыкларны кичердем. «Я люблю тебя так, что пережил все эти страдания». [1: 99]

Б) В турецком языке очень часто употребляется простое предложение, которое распространяется за счет группы подлежащего. Например: İstanbul şehrinde okuyan Fetih Kerimi Rusça Arapça Türkçe ve Fransızca öğrenen eğitimli entelektüel. – «Получивший образование в Стамбуле Фатих Карими, был образованным интеллигентом знавший русский, арабский, турецкий и французские языки». На татарском языке из сложного предложения может получится два простых предложений: Фатих Кәрими Төркиянең Истанбул шәһәрендә белем ала. Ул рус, гарәп, фарсы, төрек, француз телләрен белүче укымышлы зыялы була. [1: 100]

II. При рассмотрении морфологических систем татарского и турецкого языков можно увидеть расхождения в структуре морфологической системы, также как и в функционировании форм. [1: 100].

1) -yor в турецком языке является конструкцией глагола настоящего времени, а в татарском языке эта форма отсутствует. Однако в татарском языке а/-ә, -ый/-и приходится формой настоящего

времени, напоминающая форму желательного наклонения в турецком языке. Например, в татарском языке яза на русский переводится как «пишет»; а с турецкого yaza на русский – «напишет», что также похоже по созвучию с татарского [1: 100].

Форма на (-a, -e, -ı, -i, -u, -ü,) -r выражающая в турецком языке настоящее-будущее время (Geniş Zaman). Эта форма часто употребляется в турецких пословицах Sağır işitmez uydurur [2: 284] «Глухой не слышит, а выдумывает», Dilsizin dilinden anası anlar. [2: 10] – «Мать поймёт даже своего немого ребёнка». В родном татарском языке эта форма указывает на неопределенное будущее время [1: 100] .

2) В турецком языке между глаголами в личной форме имеется долженствовательное наклонение с конструкцией -malı/-meli, которое отсутствует в татарском языке. Например: çalışmalıyım «я должен работать» в татарском языке передается при помощи конструкций -рга кирәк или -рга тиеш: миңа эшләргә кирәк/мин эшләргә тиеш [1:100] .

3) А также есть такие различия в моделях образования безличных глаголов:

В турецком языке инфинитив имеет форму на -mak/-mek (gülmek, yapmak) в татарском языке на: -рга/-ргә (көләргә, эшләргә) языке название действия представлено конструкцией -у/-ү: чыгу, тегү и т. д. [1:100].

2. В родственных языках лексическая система распределяется по лексико-семантическим и лексико-тематическим группам. Отметим самых распространенных слов, образующих смысловую основу языка:

gitmek “китү” (уйти), bakmak “карау” (смотреть), düşünmek “уйлау” (думать), göstermek “күрсәтү” (показать), konuşmak “сөйләшү” (разговаривать), sevmek “ярату” (любить), yatmak “яту” (ложиться), gülmek “көлү” (смеяться), oturmak “утыру” (сидеть), gelmek “килү” (приходить). [1:102]

Представленные 10 глаголов, являются тюркскими, полное смысловое сходство этих языков образует 40%; отличается и смысловое построение многих совпадающих слов. (Например: тат. төшенү «убедиться» и тур. düşünmek «уйлау». [1:102]

Однако при этом нельзя упускать из виду, что внешнее сходство этих связей может скрывать за собой семантические расхождения. Выявлением этих расхождений занимается сопоставительное изучение родственных языков. Определение и систематизация семантических, фонетических и других расхождений облегчает преподавание турецкого языка как иностранного языка в учебных заведениях РТ.

Таким образом, турецкий и татарский языки являются тюркскими языками, но входящие в разные подгруппы, которые имеют много общих черт и связи. Выявление данных связей для

сравнительного изучения языков данной группы имеет огромный смысл. Однако нужно иметь в виду, что они могут быть внешне похожими, но иметь разные значения. И определением этих несоответствий, как раз таки занимается сравнительно-сопоставительное изучение родственных языков.

**Литература**

1. Рахимова А.Р. Родственные языки и их сравнительно-сопоставительное изучение (на материале турецкого и татарского языков). – К.: Гум. науки, 2007. - Том 149, кн. 4. – 103 с.

2. Aksoy Ö.A. Atasözleri ve deyimler sözlüğü Bağcılar – İstanbul Maatbacılar Sit. No.: 38, 328 s.

## ИЛЕШ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ-ЙОЛДЫЗҺӘМ ЧИЯЛЕ-ӘТӘЧ АВЫЛЛАРЫНЫҢ МИКРОТОПОНИМИКАСЫ

*Ганиева И., М. Акмулла ис. БДПУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Насипов И.С.*

Илеш районындагы Кызыл-Йолдыз авылы Базытамак авыл советы биләмәсенә керә. Ул район үзәге Югары Яркәй авылыннан төньяк-көнчыгышка таба 35 км һәм Буздяк тимер юлының төньягына 142 км ераклыкта урнашкан [3].

Исеменең килеп чыгышы бик кызыклы (ойконим): тау битендә урнашканга күрә Йолдыз дип аталган. Совет чорында Кызыл берәмлеген кушып куялар. Халкы 2002 елда 106 кеше, 2010 елда 85 кеше тәшкил итә. Башкортлар, татарлар яши, дип теркәлсә дә, авыл халкы тулысынча татар телендә сөйләшә. 20 гасырның 20 нче елларында Бөре кантоны территориясендә Кызыл-Йолдыз авылына нигез салына. Авылга Базытамак авылыныннан чыккан кешеләр күчеп утырган. Ул башта аның бер бистәсе кебегерәк булса, узган гасырның 80 нче елларында аерым мөстәкыйль торак пункт статусын ала. Авыл тарихы буенча рәсми мәгълүмат бик аз теркәлгән.

Авылның топонимик берәмлекләреннән түбәндәгеләрне билгеләп була.

Агыйдел – Башкортстандагы иң зур елга һәм төп су юлы. Агыйдел атамасы “ак” + “идел” моделе буенча ясалган, ягъни ул “ак сулы зур елга” мәгънәсенә ия. Агыйдел елгасы авылның тау астыннан агып ята. Базы елгасы, кечкенә елга. Аның башы районнан читтә. Бу елга исеменнән Базытамак авылының исеме килеп чыккан: “базы” + “тамак”. Елга Кызыл-Йолдыз һәм Базытамак авылларын икегә бүлә. Аның ярларын Кызыл ярлар дип йөртәләр. Алар бәйле күптөрле риваятьләр бар.

Әрәпәс күле исеменең килеп чыгышы әлегә билгесез. Авылда сакланган легендалар буенча, бу күл ярларында Сөембикә-ханбикә туктап, ял иткән. Ул анда ике пар аккош йөзгәнен күзәтеп, сокланып утырган. Бака күле мул сулы, балыклы матур күл иде, дип искә алалар. Күлдә бакалар бик күп булган.

Авыл территориясендә өч чишмә бар: Суфиян, Йолдыз һәм Шәвәли чишмәләре. Икесенең атамасы Суфиян һәм Шәвәли кеше исемнәренә бәйле булса, иң зурысы Йолдыз исемен йөртә. Ул тау өстендә урнашкан, ә тауны (оронимны) Чишмә тавы дип йөртәләр.

Авылда ни бары ике урам атамасы (годоним) бар. Ул – Ленина урамы һәм Яңа урам. Беренче атама кеше фамилиясенә бәйле. Икенчесен халык телендә Байлар урамы дип йөртәләр. Ләкин аны Яңа “новый” атамасы белән рәсмиләштерәләр.

Уфа провинция канцеляриясе указы белән типтәрләр Казан юлында Чияле-Әтәч авылына нигез сала. Тарихи документларга, шулай ук авылның өлкән яшьтәге кешеләренең истәлекләреннә таянып, Әтәч авылы 1697 елда барлыкка килгән, дип фаразлана. Аларда ул Атасево, Чуево исемнәрендә теркәлгән [1]. Авылның төп халкы типтәрләр, марилар, татарлар дип исәпләнгән. 1816 елга кадәр монда мишәрләр теркәлгән, 1865 елга кадәр – марилар. 1795 елда 142 кеше, ә 1865 елда 45 йортта 262 кеше исәпкә алынган.

Халык элек игенчелек, умартачылык белән шөгыльләнгән. 1906 елда шулай ук пароход һәм икмәк пристаньнәре тоткан, 2 бакалея кибете булган. Бүгенге көндә авыл халкы малчылык, умартачылык, игенчелек белән шөгыльләнә. Кайберләре комплексnúmка яисә Базытамак авылының правлениясе, почтасы, кибетләрендә эшлиләр, себер якларында эшләүчеләр дә бар.

Авыл исеменең килеп чыгышы болай аңлатыла. Имеш, тирә-ягы әрәмәлек, чиялек булганга, бу авылга Чияле исеме бирелә. Авылны Агыйделдән баржалар тартучы бурлаклар еш талау сәбәпле, ул хәзерге урынына чама белән XIX гасыр азакларында күчеп утыра. Шуңа күрә авылга яңа исем – Чияле Әтәч атамасы бирелә. Бу атаманың этимологиясе турында ике версия бар. Чуй Әтәч атамасын олылар болай аңлата. Имеш, яңа урынга өч гаилә – Гозәер, Фаткулла һәм Бигмәт нәселләре күчеп утыра. Яңа урында алар кыргый этәч тотып ала, һәм авыл Чуй Әтәч дип тарихка кереп кала. Икенче версия буенча, тау башында урнашканга күрә авылга Әтәч исеме бирелә, ә тау итәгендә чиялек булу сәбәпле, Чияле Әтәч дип йөртелә башлый. Ә инде соңыннан Чияле берәмлеге кыскарып, Чуй Әтәч атамасы барлыкка килә.

Авылда дүрт урам атамасы (годоним) теркәлгән. Алар – Ленин, Ворошилов, Максим Горький һәм Чапаев урамнары. Бу атамлар барсы да Совет чорында билгеле шәхесләрнең исемнәре белән бәйле. Шулай булгач алар шул чорда барлыкка килгәннәр. Элекке атамалары билгесез.

Авыл уртасында Именлек күле бар. Аның исеме Гражданнар сугышы елларыннан килә. Безнең авыл территориясендә аклар белән кызыллар алышканда, шул күлдә бер ничә кеше авызларына курай кабып, су астына качып, исән кала. Шуңа аны Именлек күле яки Именле куак дип йөретә башлыйлар, имеш.

Елгалардан монда да шул Агыйдел һәм Базы елгалары агалар. Агыйдел елгасы элегрәк авылның тау астыннан гына аккан. Вакытлар үткәч, Агыйдел агымын үзгәрткән. Тау астыннан акканын – Агыйделнең элекке агымын халык Иске Идел, яисә Үле Идел дип атап йөртә.

Авылда тау астыннан бәреп чыккан чишмәләр күп. Иң хөрмәтле, иҗтиһатлы авыл картлары чишмәләрне карап, чистартып торганнар, кибәргә ирек бирмәгәннәр. Тау астында Саимә чишмәсе, Шәвәли чишмәсе,  Асыя чишмәсе,Олы чишмә гомер-гомергә авыл халкын гына түгел, күрше авылларны да эчәр су белән тәэмин иттә. Шунысы кызыклы: һәр чишмәнең суы үзенчә тәмгә ия.

Кызкуак күленең атамасы фаҗигале тарихка бәйле. Имеш, ул Явыз Иван чорыннан ук билгеле була. Рус дәүләте татарларны төрлечә кыерсыта, юкка чыгару сәясетен алып бара. Бу хәл безнең авыл тарихында да чагыла. Көчләп чукындырудан качып, христиан динен кабул итмәс өчен, шушы күлдә җиде кыз батып үлә. Элек бу таллык урынында куе әрәмәлек булган. Кешеләр анда еш кына аюны  очрата торган булганнар, шуңа күрә аны Аю әрәмәсе дип исемләгәннәр.

Арабы – Базы елгасы Агыйделгә койган җирдәге ярымутрау. Шушы әрәмәлектә Гражданнар сугышы вакытында аклар, ә Аю әрәмәсендә кызыллар урнашкан. Бүген дә шушы урыннарда еш кына сугыш кораллары табалар. Хәзерге вакытта Арабы – Илеш районының сакланган урыннарның берсе. Анда күп төрле агачлар утыртылган, төрле киек-җәнлекләр очрый.

Авылның иң танылган тәбигый истәлеге – ул Чияле-Әтәч яткылыгы. Ул Базы елгасы үзәгендә (Агыйдел елгасы буенда), Илеш районының Чияле-Әтәч авылыннан 1 км төньякта урнашкан. Авылдан түбәнрәк Агыйдел елгасы террасасында ярда соры балчыклы сланецтан торган төрле үлчәмдәге балык сөлдәләренең эзләре табылган. Ул балыкларның сельд төренә кергәнлеге, Каспий һәм Кара диңгездәге сельдларга охшашлыгы билгеләнә. Ә сөлдә эзләре саклаган яр киселеше Чуй Әтәч яткылыгы атамасын ала.

Галим-геолог Ф.И. Чернышев 1887 елда бу яткылыкны искә ала. Академик А.С. Берг бу урында элек диңгез булганлыгын исбатлый. Атаклы Г.В. Вахрушов исә бу яткылыкны тикшергән. Чуй Әтәч яткылыгы бүгенге көндә табигать һәйкәле булып санала.

Илеш районының Кызыл-Йолдыз һәм Чияле-Әтәч авылларының атамаларын бербөтен система итеп алып, тавирларга тырыштык. Ләкин бу зур эшнең башы гына. Авылларның тарихы турында да мәгълүматны төрле чыганаклардан туплыйсы бар. Авылның топонимик системасын да тиешле дәрәҗәдә барлап, ныклы өйрәнү кирәк.

**Әдәбият**

1. Асфандияров А.З. История сел и деревень Башкортостана и сопределҗных территорий. Справочник. – Уфа: Китап, 2009. – 744 с.

2. Миргасыймова Р. «Тарих ничек языла?», “Алар данга лаеклы кешеләр!”.

3. Нуртдинов Р.К. Илешевский район. Энциклопедия. – Уфа, 2010. – 335 с.

## «КАРАЧАЕВО-БАЛКАРСКО-РУССКИЙ СЛОВАРЬ» В РАЗВИТИИ ТЮРКОЛОГИЧЕСКОЙ ЛЕКСИКОГРАФИИ

*Абайхан М., КФУ, магистрант II курса*

*Науч. рук. – докт. филол. наук, проф. Юсупова А.Ш.*

Наиболее крупным лексикографическим трудом в карачаево-балкарском языкознании стал «Карачаево-балкарско-русский словарь» (Москва, 1989). Авторы – С.А. Гочияева, Х.И. Суюнчев. Подготовлен под редакцией Э.Р. Тенишева и Х.И. Суюнчева. Словарь охватил около 30000 слов современного литературного карачаево-балкарского языка. В словаре приводится значительное количество словосочетаний, фразеологических единиц, пословиц, поговорок, удачно иллюстрирующих семантическую структуру интерпретируемых лексем. Специальная, терминологическая лексика в словаре также занимает важное место. Как первое наиболее крупное собрание и полное квалифицированное, профессиональное описание лексики карачаево-балкарского языка, словарь представляет большой интерес не только для лингвистов-тюркологов, но и для представителей других языковых семей. «Карачаево-балкарско-русский словарь» стал важным шагом к созданию трехтомного толкового словаря, ставшего заметным событием в культурной жизни карачаевцев и балкарцев [4: 7].

В качестве приложения к словарю дан краткий грамматический очерк карачаево-балкарского языка, составленный доктором фил. наук, проф. М.А. Хабичевым. Словарь предназначен для широкого круга читателей: преподавателей и учащихся средней и высшей школы,

переводчиков, работников печати, радио и телевидения. Представляет большой интерес для тюркологов.

«Карачаево-балкарско-русский словарь» подготовлен Карачаево-Черкесским научно-исследовательским институтом истории, филологии и экономики и является первой крупной лексикографической работой, в которой представлен основной фонд лексики карачаево-балкарского языка.

Словарь создан на базе языка карачаевцев, проживавших в Карачаево-Черкесской автономной области Ставропольского края (по переписи 1979 г. численность 131 тыс. чел.), и балкарцев, проживавших в Кабардино- Балкарской АССР (численность 66 тыс. чел.).

«Карачаево-балкарско-русский словарь» составлен сотрудниками КЧНИИ кандидатами филологических наук С. А. Гочияевой (буквы Б, Г, Гъ, Д, Ж, З, И, К, О, П, Р, С, У, Х, Ч, Ю) и Х. И. Суюнчевым (буквы А, В, Дж, Е, Ё, Къ, Л, М, Н, Т, ф, Ц, Ш, Щ, Ы, Э, Я). В словаре отражены расхождения в лексике карачаевцев и балкарцев без претензии на полноту их охвата.

Существует также электронный словарь (http://www.elbrusoid.org/dictionary) и мобильное приложение «Сёзлюк», созданные Фондом содействия развитию карачаево-балкарской молодежи «Эльбрусоид». Это некоммерческая организация, созданная с целью объединения и развития карачаево-балкарской молодежи, формированию у неё ценностных ориентиров на основе современных ценностей и требований современного времени, а также сохранения и приумножения культурного наследия карачаево-балкарского народа.

Словарь постоянно дополняется. Команда разработчиков приглашает принимать в этом участие: если пользователи не находят нужное слово или знают перевод отсутствующих в словаре слов, то они могут написать разработчикам. Чтобы перевести слово, пользователи выбирают направление перевода (Карачаево-балкарско-русский или Русско-карачаево-балкарский), вводят в поле необходимое слово и нажимают перевести.

Словарь создан на основе уже вышеупомянутого «Карачаево-балкарско-русского словаря», а также составленного Карачаево-Черкесским НИИ в 1965 году в Москве «Русско-карачаево-балкарского словаря» под редакцией Х.И. Суюнчева и И.Х. Урусбиева. В словаре представлено около 35000 слов, представляющих наиболее употребительную лексику и фразеологию русского литературного языка, а также наиболее известную научную терминологию, в целом довольно удачно и квалифицированно переданную на современном

карачаево-балкарском языке. К словарю приложен список основных географических названий СССР и мира, а также отдельно по территории Карачаево-Черкесии и Кабардино-Балкарии [4: 6].

В тех случаях, когда балкарский перевод отличается от карачаевского, это отмечается пометой балк. Словарь предназначается для преподавателей и учащихся высшей и средней школы, для переводчиков, работников печати, радио и телевидения, а также для научных работников, занимающихся изучением тюркских языков. Издание словаря явилось крупным событием в культурной жизни карачаевцев и балкарцев. Словарь и по сей день оказывает большую помощь ученым, журналистам, переводчикам, преподавателям, студентам и учащимся в освоении как русского, так и карачаево-балкарского языков.

Значение двуязычных словарей трудно переоценить для дальнейшего развития и совершенствования науки и практики создания словарей в Кабардино-Балкарии и Карачаево-Черкесии. Опираясь на опыт создания этих словарей, многие поколения карачаевцев и балкарцев могут составить новые типы и виды лексикографических произведений.

В настоящее время перед учеными стоят задачи дальнейшего развития и совершенствования терминологической работы, создания энциклопедических словарей, персональных энциклопедий, этимологического словаря, отраслевых словарей, словарей синонимов, антонимов, словаря правильностей/трудностей, словарей языка писателей, словообразовательного словаря и т. д. Следует создавать словари с учетом достижений современной лексикографии, которые позволят удовлетворить многообразные потребности языковой практики карачаевцев и балкарцев, возникающие в процессе жизнедеятельности. Словари должны включать наиболее употребительную лексику и фразеологию современного карачаево-балкарского языка.

**Литература**

1. Карачаево-балкарско-русский словарь: Ок. 30000 слов / Карачаево-Черкес. НИИ истории, филологии и экономики; [С. А. Гочияева, Х. И. Суюнчев]; Под ред. Э. Р. Тенишева, Х. И. Суюнчева. – М. : Рус. яз., 1989. – 832 с.

2. Русско-карачаево-балкарский словарь: Около 35 000 слов / Под ред. Х.И. Суюнчева и И.Х. Урусбиева; Карачаево-Черкес. науч.-исслед. ин-т языка, литературы и истории. – Москва: Сов. энциклопедия, 1965. – 744 с.

3. Аппоев А.К. Роль лингвистических словарей в изучении лексической системы (на материале карачаево-балкарского языка) // Вестник Челябинского государственного педагогического университета. – 2014. – № 3. – С. 210-217

4. Додуева А.Т. Карачаево-балкарская лексикография // Motif Akademi Halkbilimi Dergisi – İstanbul. – 2015. – №2. – Ss. 587-596.

5. Махиева Л.Х. Некоторые проблемы составления «Русско-карачаево-балкарского словаря» // Филологические науки и вопросы теории и практики. – 2016. – № 7 (61). – Ч. 2. – С. 136–138.

# КАЗАН ШӘҺӘРЕ УРБАНОНИМНАРЫНЫҢ СЛЕНГ АТАМАЛАРЫ

*Әбрарова А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Һадиева Г.К.*

Сленг (ингл. теленнән кергән сүз – slang) – ул кабул ителгән әдәби тел нормасыннан читләшкән, эмоциональ һәм экспрессив яктан баетылган сөйләм теле лексикасы. «Сленг» термины инглиз телендә, аеруча Англия һәм АКШ сөйләмнәренә карата еш кулланыла. Сленг еш кына үзгәрешләргә дучар була, бу исә буыннарның аерым үзенчәлеген хасил итә. Әдәби телгә җиңел үтеп кереп, геройларның сөйләм характеристикасы һәм автор сөйләме өчен кулланыла [1: 477].

Инглиз лексикографиясендә «сленг» термины XIX гасыр башында киң таралыш ала. Бу сүзнең этимологиясе бәхәсле. «Сленг» төшенчәсе «диалект», «жаргон», «вульгаризм», «гади сөйләм»төшенчәләре белән туры килә.

Гади сөйләм төшенчәләреннән аермалы буларак, сленгны билгеле бер яшь яки һөнәр вәкилләре актив куллана. Гомуммәгълүм мисал – яшьләр сленгы. Сленг бик тиз арада үсеш ала һәм шулай ук тиз вакыт аралыгында юкка да чыгарга мөмкин.

Урбанистик коммуникациянең төп формасы булып, шәһәр сленгы тора. Ул үз эченә яшьләр сленгын һәм шулай ук төрле иҗтимагый төркемнәр өчен характерлы булган жаргоннарны туплый. Урбаноним – шәһәр эчендәге топографик объектлар (урам, проспект, бульвар, тыкрык һ.б.) атамасы. Теге яки бу урбанонимның атамасы үз эченә төрле мәгънә тупларга мөмкин, ә бу исә, еш куллану сәбәпле, шәһәр халкының аңында кала.

Шәһәр урамнарының сленг атамаларына төрле факторлар йогынты ясый. Беренче чиратта, яшьләр сленгы, компьютер сленгы һәм төрле һөнәр ияләренең сленгы.

Казан шәһәре урамнарының сленг атамаларын берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин: кыскарту ысулы белән ясалган атамалар; ассоциатив юл белән ясалган атамалар; морфологик ысул белән ясалган атамалар; урамнарның элеккеге атамаларын куллану.

Кыскарту ысулы белән ясалган урам атамаларына *Хөсәен Ямашев проспектын* кертергә мөмкин. Шәһәр халкы, бигрәк тә Мәскәү, Яңа Савин, Совет районнарында яшәүчеләр *Ямаш проспекты* сленгын куллана. Шулай ук әлеге төркемгә *Җиңү проспекты* да керә.

Әлеге урбаноним Казан шәһәре халкы телендә *Проспект* буларак гамәлдә йөри. Бередә, тагын бер үзенчәлеккә игътибар итәргә кирәк: Казан шәһәрендә барлыгы алты – *Галимҗан Ибраһимов проспекты, Альберт Камалиев проспекты, Универсиада проспекты, Фатыйх Әмирхан проспекты, Хөсәен Ямашев проспекты* һәм *Җиңү проспекты* бар. Шулар арасында бары тик *Җиңү проспектын* гына казанлылар *Проспект* дип кенә йөртәләр, ләкин бу кыскарту аңлауда бернинди дә кыенлык тудырмый. Моның сәбәбе – *Җиңү проспектының* Казан шәһәренең иң озын һәм шул ук вакытта иң мөһим магистрале булуында. *Сул Як Болак урамын Болак* дип йөртү. Әлеге кыскарту бигрәк тә КФУ студентлары сөйләмендә актив. Болакның сул ягында уку бинасы урнашкан.

Ассоциатив юл белән барлыкка килгән атамалар рәтендә иң популяры – *Бауман урамы*. Әлеге урамны – *Казан Арбаты (Казанский Арбат)* дип йөртәләр. Әлеге атама туристлар арасында аеруча популяр, чөнки Мәскәү шәһәренең күпләргә мәгълүм җәяүлеләр урамы – *Арбат*, Казан шәһәренең *Бауман урамына* охшаш. *Профсоюз урамы* яшьләр сленгында *Бар урамы* (*улица Баров*) буларак мәгълүм. Әлеге ассоциация бу урамда барларның күплеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Казан шәһәренең *Яңа Савин районы* халык телендә *Квартал* буларак билгеле. Басым сүзнең беренче иҗегенә төшә. Дәрвишләр бистәсенең халык сөйләмендә кулланылган икенче атамасы – Дербоград. 1941 нче елда, Бөек Ватан сугышы башлангач, бирегә берничә зур оешма эвакуацияләнә, әлеге исем дә шуннан барлыкка килә.

Морфологик ысул белән ясалган атамалар –га/–гә, –ка/–кә кушымчасы ялгану белән характерлана. Мәсәлән: *Гадел Кутуй урамы – Аделька, Шамил Усманов урамы – Шамилька, Айдаров урамы – Айдарка* һәм *Челюскин урамы – Челюга урамы* буларак билгеле. Әлеге ысул аеруча яшьләр сленгында еш кулланыла. Мәскәү районының төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан *Торак мәйданы* (*Жилплощадка*) микрорайоны *Жилка* дип йөртелә. Басым сүзнең беренче иҗегенә төшә. Авиатөзелеш районында урнашкан *Караваево микрорайоны – Каравайка* буларак билгеле.

Урамнарның элеккеге атамаларын аеруча өлкән буын сөйләмендә ишетергә мөмкин. Әлеге төркемгә кергән урбанонимнар арасында *Эсперанто урамы* (хәзерге *Нурсолтан Назарбаев урамы*) еш очрый. *Компрессорная урамы* да (хәзерге *Халитов урамы*) бүгенге көндә кулланылыштан тулысынча төшеп калмады. Әлеге урам атамаларын, алда әйтеп узганча, күбесенчә өлкән буын вәкилләре

куллана. Берничә елдан соң әлеге төркем, гомумән, юкка чыгачак яки башка урбанонимнар белән алышыначак.

Казан шәһәре урамнарының сленг атамалары күп еллар элек формалашкан һәм бүгенге көндә дә популярлыгын югалтмаган күренеш. Урбанонимнарның сленг атамалары барлыкка килү, беренче чиратта, урам исемнәренең әйтелеше, яңгырашы белән бәйле. Шәһәр халкы күп исемнәрне кыскартып, яңа кушымчалар өстәп әйтү ысулын еш куллана. Казан шәһәре урамнарының сленг атамалары тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән өлкә. Халык телендә урамнарның яңа атамалары барлыкка килү, шәһәр урбанонимикасының һәм шуның белән бергә шәһәр сленгының бербөтенлеген дәлилли торган фактор.

**Әдәбият**


1. Большая советская энциклопедия / глав. ред. А. М. Прохоров. – Москва: Сов. энциклопедия, 1969. – 3-е изд. – 608 с.
2. Саттаров Г.Ф. Ни өчен шулай аталган ? – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – 127 б.
3. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – Т. III. 1 кис.– 536 б.


## ДИПЛОМАТИЧЕСКИЙ ЭТИКЕТ ОБРАЩЕНИЯ КАЗАХСКИХ ПРАВИТЕЛЕЙ РУССКИМ ГОСУДАРЯМ


*Авалиев А.А., КазНУ им. Аль-Фараби, магистрант 1 курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Зубайда Шадкам*


В казахской истории нет работы, специально посвященной истории дипломатии древних и средних веков. Есть лишь исследования, изучающие отношения Казахского ханства с различными странами, а также сборники документов и материалов по международным отношениям.

Во второй половине XVIII века наблюдается рост внешнеполитических и социальных изменений дипломатии Казахского ханства. Ханы и султаны были образованными людьми, с детства обученные грамоте у известных мулл и городских медресе, хорошо владели арабским, чагатайским, реже персидским и русским языками и основами обычного и мусульманского права. [3: 54]

Делопроизводство по вопросам внешних сношений велось в основном на чагатайском языке, а позже и на русском языке. Исходящие документы и материалы по внутригосударственной переписке заверялись ханской или родовой тамгой, которые должны были иметь не только ханы и султаны, также старшины всех основных сегментных групп казахского общества. [1: 16]

Обозначение адресата в посланиях и отдельным монархам соседних государств включает в себя три обязательных компонента:

обобщенную этикетную формулу обращения *һазратларининг ’узма һазрани, һазратлары, һазратыныз*, что с переводе русского обозначает «ваше величество» или «ваше императорское величество», краткий монархический титул главы с прилагаемыми к нему поясняющими определениями и многообразными эпитетами, а также собственное имя данного носителя. Инскрипции писем, адресованных высокопоставленным российским, среднеазиатским и цинским чиновникам, имеют аналогичную форму водную часть текста.

В письмах казахских ханов и султанов, адресованных Петру I, Анне Иоанновне, Елизавете Петровне, Екатерине II, Александру I и некоторым другим монархам Российской империи, типичное для всех этнокультурных групп кочевников того времени мифологизированное восприятие образа чужого и далекого российского государя нашло отражение в таких цивилизационно однородных формах титулования царствующих особ императорского дома, как *ак хан* - «белый царь», *акхан падшаһ* - «белый царь, падишах», *ак ва улуг падшаһ* - «белый и великий падишах», *ак, хан улуг падшаһ* – «белый царь, великий падишах», *ул улуг бек импаратор падшаһ* – «государыня императрица», *ак бипадша* – «белая падишахиня», *шаһиншаһ* – «царь царей».

В приветственном обращении к российским монархам обоих полов ими преимущественно использовались относительно короткие и однообразные формулы: *шавкатлы ва даранда улуг падшаһ билистиклал куллин... Руссиянын һукмдари император... һазратларина ва гайриһум* – «могущественный и державный великий падишах, самодержец всероссийский, его величество государь император»; *импаратор а’зам һазратлары,* или *шаукатлы импаратрича а'зимы ва балколлайа инайатлы падшах һазратлары* – «ваше императорское величество всемилостивейшая государыня»; *билакан ак ва улуг падшаһ һазратларын хузури* – «ваше величество государыня императрица», *шаукатлу ва кодратлу улуг падшахымыз а'зимы импиратритса* – «всепресветлейшая державнейшая великая государыня императрица», либо более лаконично – *ул улуг бек импаратор падшаһи* – «государыня императрица».

В отличие от них для ханских и султанских посланий, адресованных царским наместникам, их ближайшим помощникам и командующим войсками в пограничных со степью российских губерниях, характерна более пестрая и неоднозначная картина. В многочисленных письмах российским министрам, местным губернаторам, их помощникам и командирам пограничных войск, имевшим чин действительного тайного советника или генерал-поручика, казахские ханы и султаны в большинстве случаев указывали

их полные собственные имена, административные должности и звания и употребляли по отношению к ним этикетную формулу обращения – *иззатилмиш 'алиййа мартабали* - «ваше высокопревосходительство», а в посланиях чиновникам среднего звена от бригадира до генерал-майора – *'али габлу джаблу баланд бимматлу* – «ваше превосходительство».

Кроме того к официальным формам обозначения российских государственных деятелей они нередко прибавляли отдельные ремарки уточняющего характера или прославляющие их эпитеты («достойному уважения и почтения, любезному ученому из ученых»; «отличнейшему из министров своею справедливостью и благотворениями» и т.п.). Такие неформальные инскрипции в одних случаях выражали расчетливое стремление авторов писем приобрести особое расположение влиятельных адресатов, а в других – их действительно доброжелательное или даже дружеское отношение к конкретной персоне [2:41] .

Казахское ханство на протяжении своего существования вела мирное дипломатическое отношение с соседними монархами. Несмотря на кочевой образ жизни, дипломатическая переписка степных ханов и султанов показывает высокую грамотность среди кочевых народов. Благодаря активной внутри- и внешнеполитической деятельности именитых ханов и султанов Казахского ханства превратилось в относительно мощное и единое государство.

**Литература**

1. Абусеитов М.Х. Казахстан и Центральная Азия в XV-XVII вв.: история, политика, дипломатия. – Алматы: 1998. – 132с.

2. Ерофеева И.В. : Эпистолярное наследие казахской правящей элиты. Т. – 1, Алматы, «АБДИ»: 2014, 1032 с.

3. Левшин А.И. Описание киргиз-казачьих, или киргиз-кайсацких орд, и степей/ под. общ. Редакцией академика М.К. Козыбаева. – Алматы: 1996. – 656 с.

## Р.Р. АРАТНЫҢ «TÜRK ŞİVELERİNİN TASNIFI» ХЕЗМӘТЕ

*Ахсанова Г., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Юсупова Ә.Ш.*

Тюркология өлкәсенә караган хезмәтләренең берсе – «Türk şivelerinin tasnıfı» («Төрки телләр классификациясе»). Әлеге җыентык 1953 нче елда басылган һәм 80 биттән тора. Җыентык дүрт бүлектән тора: *giriş, türk şivelerinin tasnıfı tecrübeleri, türk şivelerinin tasnıfi tecrübelerinden çıkan neticeler, türk şivelerinin tasnıfının bugünkü durumu.*

Р.Р. Арат үзенең хезмәтендә кавемнәрнең берләшүләренең нигезен тәшкил итүче элемент – тел дип атый. Төрки телләр, диалектлар, сөйләшләр турында сүз алып барганда, кавемнәрнең

берләшү аспекты, телләрне төркемләү кебек, кавем мөнәсәбәтләренә генә ишарә итү җитәрлек түгел, ди ул. Аңлату юлы белән, бөтен бер милләт структурасы һәм аның тарихи үсеше игътибарга алынырга тиеш дип саный.

Коммуникатив уеннар сөйләмне үстерү өчен баланы җанлы сөйләмгә,күмәк сөйләмгә тартырга тиеш. Коммуникатив уеннарны төрле формада үткәрергә мөмкин. Төркемнәргә бүленеп уйнау (әйтик, гаилә, ял итүчеләр), уен – эзләнү (җитмәгән информацияне табу), уен - фантазия (класс бүлмәсе офиска яки кунакханә бүлмәсенә әйләнә). Коммуникатив уеннар балаларга аралашу өчен реаль шартлар тудыра, шулай итеп класс бүлмәсеннән чын реаль тормышка күпер сала. Коммуникатив алым кулланып үткәрелгән дәресләр укучыларга телне аралашу чарасы, дөньяны һәм үзен танып белү, иҗади һәм актив, дөрес итеп аралашырга мөмкинлек бирә.

Коммуникатив технологиянең иң югары өстенлеге укыту процессында сөйләм материалын барлык балаларның да үзләштерә алуы өчен шартлар булдыруда. Коммуникатив технология негезендә укыту цикллыкка корылган. Цикл – текстны укып, аның эчтәлеген диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү. Диалог – тормышта иң еш кулланыла торган табигый сөйләм формасы. Диалогик сөйләмгә, нигездә, сорау – җавап, өстәмә аңлатмалар китерү, ризалашу яки инкарь итү, сөйләм әдәбен саклап сөйләшү хас. Кара-каршы сөйләшү өчен билгеле бер ситуациянең булуы шарт.

Хәзерге укытучының җәмгыятьтә тоткан урыны үзгәрә бара: ул – мәгълүмат бирү чыганагы гына түгел, ә укучыларның фикерләү сәләтен үстерүче, уку, танып белү эшчәнлеген актив оештыручы да

**Әдәбият**

1. Хайдарова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М. Федераль дәүләт белем бирүстандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту. – Яр Чаллы, 2015. – 52 б.

2. Фәтхуллова К.С., .Җәүһәрова Ф.Х. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы // Үрнәк программалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 119 б.

## ОСОБЕННОСТИ ЗАДАНИЙ MULTIPLE-CHOICE CLOZE В ТЕСТАХ

*Валиев И., КФУ, студент II курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук Ашрапова А.Х.*

Задания **Multiple-choice cloze** (Множественный выбор) являются ключевой частью раздела Use of English международных кембриджских экзаменов по английскому языку. Они проверяют знания экзаменуемых в области словарного запаса и словосочетаний.

Данная часть экзамена состоит из текста, за которым следуют восемь заданий с 4 вариантами ответа, которые проверяют понимание содержания и организации текста. В них «делается акцент на детальное понимание текста, включая выражение мнения, отношение, цель, основную идею, детали, тон и суть» [2: 8]. Экзаменуемые также проверяются на способность распознавать смысл из контекста и следовать таким особенностям организации текста, как пример, сравнение и ссылка.

Задания на множественный выбор рассматриваются, как лексические упражнения, основанные на словосочетаниях, фразовых глаголах и устойчивых выражениях.

В заданиях чаще всего встречаются «**collocations** (словосочетания) – пара или группа слов, которые очень часто используются вместе» [3: 4]. Они звучат естественно для носителей языка, но студенты, изучающие английский язык, должны приложить особые усилия, чтобы их выучить. Это объясняется тем, что зачастую словосочетания трудно угадать. Например, прилагательное *fast* используется с *cars*, но не с *a glance*.

Реже можно встретить **«compounds** (составные слова) – сложные слова, образованные из двух или более слов» [3: 6]. Их написание различно: некоторые из них пишутся отдельно, некоторые – через дефис, а другие – как одно слово. Зачастую значение составного слова можно угадать, зная, что значат его составляющие. Некоторые примеры составных слов: *car park, post office, narrow-minded, shoelaces, teapot.*

**«Idioms** (идиомы) – это группы слов с фиксированным порядком, имеющие значение, которое невозможно угадать, зная значение отдельных слов» [3: 6]. Например, *pass the buck* – это идиома, означающая “переложить ответственность за проблему на другого человека, чтобы избежать решения ее самостоятельно”. Идиоматические выражения появляются в текстах контрольно-измерительных материалах с одним пропущенным словом.

**«Phrasal verbs** (фразовые глаголы) – это сочетания слов, которые состоят из глагола и частицы. Частицы – это небольшие слова, которыми выступают предлоги или наречия» [4: 6]. Наиболее распространённые из них: about, (a)round, at, away, back, down, for, in, into, off, on, out, over, through, to, up.

Фразовые глаголы являются одним из самых сложных лексико-грамматических аспектов английского языка из-за своего большого разнообразия и наличия зачастую нескольких лексических значений. Фразовые глаголы время от времени встречаются на экзамене. В данном случае экзаменуемому следует заполнить пропуск глаголом или предлогом фразового глагола.

**Word patterns** (устойчивые сочетания слов) являются неотъемлемой частью любого экзамена на знание английского языка. Они должны рассматриваться в первую очередь. Устойчивым сочетанием слов называется комбинация, состоящая из **слова** и **предлога**. Им уделяется большое внимание на контрольно-измерительных материалах всех уровней (от A1 до C2). Чтобы облегчить запоминание устойчивых сочетаний слов, можно сосредоточиться на группах сочетаний с одинаковыми предлогами.

Для успешного выполнения заданий с множественным выбором наряду со словосочетаниями, устойчивыми сочетаниями слов, фразовыми глаголами, составными словами и идиоматическими выражениями необходимо также знать **синонимы**, т.е. слова, которые имеют почти одинаковое значение. «Несмотря на сходство значений, разница между синонимами английского языка, несомненно, существует. В первую очередь она проявляется именно в смысловых оттенках и характеристиках, выраженных тем или иным словом» [1]. К примеру, слова *cold* (холодный), *cool* (холодный, прохладный), *chilly* (холодный, пронизывающий, бодрящий) и *frosty* (холодный, морозный) имеют схожее значение, но в задании необходимо выбрать один из синонимов, которые наиболее подходит по смыслу.

**Linking words** (слова-связки) – это связующие элементы, которые используются, чтобы переход от одной мысли к другой был логическим. Их использование делает речь и письмо понятным для иностранцев и обеспечивает получение более высокого балла при сдаче любого экзамена. Иначе их называют **discourse markers**, т.е. маркеры беседы, связующие обороты речи.

Таким образом, задания Multiple-choice cloze, являющиеся ключевой частью раздела Use of English международных кембриджских экзаменов по английскому языку, требуют от экзаменуемых владения богатым словарным запасом и словосочетаниями. Кроме этого, им необходимо уметь детально понимать текст и распознавать смысл слов из контекста.

При подготовке к экзамену основное внимание следует направить на изучение и освоение широкого лексического материала. К нему относятся словосочетания, устойчивые сочетания слов,

фразовые глаголы, слова-связки, синонимы, идиомы и т.д. При овладении ими представляется возможным успешное выполнение всех заданий с множественным выбором.

**Литература**

1. Синонимы в английском – определение, примеры. URL: https://lim-english.com/posts/sinonimy-v-anglijskom-yazyke/.
2. First Certificate in English. Handbook for teachers (for examinations from December 2008). – Cambridge: University of Cambridge Local Exams Syndicate, 2007. – 90 p.
3. McCarthy M., O'Dell F. English Collocations in Use Intermediate Book. – Cambridge: Cambridge University Press, 2017. – 190 p.
4. McCarthy M., O'Dell F. English Phrasal Verbs in Use. – Cambridge: Cambridge University Press, 2004. – 208 p.

## ХӘЗЕРГЕ МАТБУГАТТА ӨСТӘЛМӘЛӘР

*Галимбәкова И., КФУ, III курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сибгаева Ф.Р.*

Эмоциональ-экспрессив функция кешенең тел ярдәмендә үз хисләрен, тойгыларын, кичерешләрен тапшыру сәләтендә чагыла. Әлеге функция сөйләүченең шәхесен, аның кәефен интонация, сүз сайлау һәм семантик-синтаксик структуралар ярдәмендә чагылдырырга ярдәм итә. Бу функция адресантның сөйләм предметына карата субъектив психологик мөнәсәбәтен (интонация, ымлыклар, эмоциональ-экспрессив коннотация һ.б.) турыдан-туры белдергәндә гамәлгә ашырыла.

Өстәлмә конструкцияләр җөмләләрне тулыландырып, төгәлләштереп, фикерне тагын да ачыграк итеп әйтү өчен җөмләгә килеп өстәләләр.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, өстәлмә конструкцияләр XVIII гасыр текстларында барлыкка килә, һәм алга таба төрле стиль текстларда арта. Хәзерге матбугатта өстәлмә конструкцияләр шактый киң кулланыла һәм алар структур-синтаксик, функциональ үзенчәлекләргә ия.

Ф.С.Сафиуллина «Татар телендә сүз тәртибе» дигән хезмәтендә өстәлмә конструкцияләрнең мәгънә ягыннан 9 төрен аерып күрсәтә:

– беренче җөмләдәге яисә үткәндә өзелеп калган фикер дәвам иттерелгән очрак;

– әйтелгән фикернең билгесен ачыклау нияте белән өстәлгән конструкцияләр;

– өстәлмә конструкция алда әйтелгән фикерне дөресләп килә, бер төрле аңлашырга мөмкин булган фикерне дөресли;

– өстәлмә конструкция икенче телдәге сүзләр белән алдагы берәр фикерне ачыклап килә;

– өстәлмә конструкция алдагы җөмләдәге бер кисәкнең эчтәлеген ачып бирә;

– өстәлмә конструкциядәге сүзләр тагын да ныграк ышандыру өчен кулланылалар;

– өстәлмә конструкцияләрдә элек «истән чыгып киткән» вакыт, урын, максат, рәвеш, шарт, сәбәп, объект һ.б. төшенчәләре чагыла;

– өстәлмә конструкциядә алдагы җөмләдә телгә алынган берәр затның фамилиясе, исеме, профессиясе белдерелә;

– өстәлмә конструкциядә өстәмә хәбәр килеп алдагы хәбәрне тагын да конкретлаштыра торган төрләре.

Өстәлмә конструкцияләрне, вакытлы матбугатка таянып, тикшергән хезмәтләрдә аларның ике төре аерыла: вербаль булмаган һәм вербаль. Алар үз эчендә берничә тармакка аерылалар.

Вербаль булмаган конструкцияләр:

– тыныш билгеләре ярдәмендә белдерелгән

– саннар ярдәмендә белдереләләр.

*Чир йоктыручылар арасында күбесе – 30-50 һәм 60-70 яшь аралыгындагы кешеләр* ***(22 шәр)*** (Ватаным Татарстан, 2021, №15).

Вербаль конструкцияләр – тел чаралары ярдәмендә белдерелгән, бер сүздән алып, тулы җөмлә ярдәмендә кулланылган төзелмәләр. Алар: лексик типтагы өстәлмә конструкцияләр һәм синтаксик типтагы өстәлмә конструкцияләр.

Лексик типтагы өстәлмә конструкцияләр түбәндәгеләргә аерыла:

– өстәлмә сүз (аерым лексема): *Сәнҗапов Рәшит Шәйхулла улы* ***(фермер)*** *хуҗалыгы башлыгы Сәнҗапов Рәшит Шәйхулла улына...* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

– аббревиатура: *Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы* ***(ВОЗ)*** *белгечләре нәтиҗәлелеге 70 проценттан арткан теләсә кайсы вакцинаны уңышлы дип санаячакларын белдергән иде* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

Синтаксик типтагы өстәлмә конструкцияләр шулай ук 2 төргә аерыла: җөмлә алдыннан куела торган һәм җөмлә ахырыннан килә торган.

Беренче төр конструкцияләр: 1) сүз формасы; 2) сүзтезмәләр: *AZD1222* ***(Оксфорд вакцинасы)*** (Ватаным Татарстан, 2021, №16). *BNT162b2* ***(Pfizer-BioNTech вакцинасы)*** (Ватаным Татарстан, 2021, №16) ярдәмендә белдерелә алалар.

Синтаксик типтагы икенче төр конструкцияләр үз эченә: гади җөмлә ярдәмендә белдерелгән: *Танылган тележурналист Михаил*

***Любимовның (ТНВ каналындагы «7 дней» тапшыруы аша билгеле. – Ред.)*** *шушы көннәрдә «кызыл зона»га 17 нче тапкыр керүе* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

– катлаулы җөмләнең бер өлеше ярдәмендә белдерелгән: *Бу нурлар гемоглобинны үтәли яктырта* ***(ә гемоглобин – кислородны күзәнәкләргә ташый торган аксым ул)*** (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

– катлаулы җөмләр ярдәмендә белдерелгән төрләргә аерылалар: *Муса Җәлил истәлегенә газетабыз гамәлгә куйган ярышларда* ***(шулай ук республика күләмендәге башка бәйгеләрдә дә – балалар, яшьүсмерләр, өлкәннәр арасында үткән һәр бәйгедә бит ул!)*** *чемпион калучыларның абсолют күпчелеге безнекеләр була иде* (Ватаным Татарстан, 2021, №14).

Безнең тарафтан «Ватаным Татарстан» газетасы өйрәнелде. Анализ барышында бер мәкаләдә бердән алып берничә өстәлмә конструкция кулланыла алуын ачыкладык. Алар арасында тыныш билгеләре кулланылган өстәлмәләр очрамады. Саннар ярдәмендә белдерелгән өсәлмәләр 6,6% тәшкил итә. Өстәлмә сүзләр 16,6%, аббравиатуралар 6,6%. Сүз формалары очрамый, сүзтезмәләр 11,6%. Иң күп кулланылган конструкцияләр булып – гади җөмләләр ярдәмендә белдерелгән өстәлмәләрне аерып атап була, алар 35% алып торалар. Катлаулы җөмләнең бер өлеше ярдәмендә белдерелгән өстәлмәләр 11% алып торса, катлаулы җөмләләр ярдәмендә белдерелгән төре бары тик 5%.

Хәзерге матбугат теле күпкә экспрессив. Медиа-текстларның төп стратегияләренең берсе адресатка якынлык стратегиясе булып тора. Бу журналистның «җәмгыять белән бер телдә сөйләшергә» омтылуында тормышка ашырыла.

**Әдәбият**

1. Сафиуллина Ф. С. Текст төзелеше. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 224 б.

2. Типология вставных конструкций в современных СМИ // URL: https://moluch.ru/conf/phil/archive/80/3988/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 18.11.2020 – 29.11.2020).

## ТЕЛНЕҢ ЛЕКСИК СИСТЕМАСЫНДА МИЛЛИ ХАРАКТЕРНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

(татар блогерларының язмалары мисалында)

*Гобәйдуллина Л., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Кузьмина Х.Х.*

Һәр милләт кешесе үзенең дөньяга карашы белән аерылып тора, әлеге үзенчәлекләр аеруча аның телендә чагылыш таба, ягъни һәр тел

дөньяны танып белүнең һәм күзаллауның билгеле бер ысулын, яки “дөньяның тел картинасын” чагылдыра. Борынгыдан һәр халыкның җанлы сөйләмендә афоризмнар, канатлы сүзләр, фразеологизмнар, мәкальләр һәм әйтемнәр кулланылган. Алар барысы да кешенең дөнья турындагы күзаллаулар җыелмасы нәтиҗәсендә барлыкка килгән, аларның һәммәсен дә халык үзе иҗат иткән һәм аның күңел байлыгын күрсәткән. Шуңа күрә телдәге тотрыклы берәмлекләрне өйрәнү телнең милли характерын күрсәтә, чөнки нәкъ менә аларда халыкның көнкүрешенең, мәдәниятенең үзенчәлекләре, аның тарихы чагыла. Әлеге лексик берәмлекләрнең мәгънәсен белми торып, төрле милләт кешеләре арасында тулы аралашу мөмкин түгел.

Татар теленең нормалары үзгәрү процессы нәкъ менә блогосферада актив күзәтелә. Блогерларның теле җәмгыятьтә барган үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнештә. Шул сәбәпле ул тел белеме, социология, иҗтимагый психология чигендә булган процессларның тыгыз бәйләнеше аркасында, тел галимнәре, политологлар, психологлар тарафыннан зур кызыксыну тудыра.

Бүгенге XXI гасыр яңа технологияләр заманында кешеләр китап укуга караганда, интернеттагы мәгълүматка ешрак мөрәҗәгать итәләр. Туган телебезне саклап калуда нәкъ менә татар журналистларының һәм филологларының блоглары зур әһәмияткә ия. Ләкин бүгенге татар блогосферасы фәнни яктан өйрәнелмәгән.

Блогосферада барлык сүзләр дә сурәтле була алмый. Бу хәтта кайбер матур әдәбият әсәрләрендә дә шулай. «Әмма аның һәрберсе, сөйләмдә башка сүзләр белән бергә кушылып, образлылык тудыруга ярдәм итә. Кайбер әсәрләрдә кешегә эстетик тәэсир итү, аңарда тирән эчке тойгылар уяту гаять югары була» [5: 220]. Интернет челтәр постларында да шулай. Гадәттә, әлеге күренеш татар журналистларының шәхси блогларында күзәтелә. Мәсәлән, Эльмира Сираҗи блогы тел-сурәтләү чараларына бай.

Фразеологик әйтелмәләр – халык иҗаты. Аларда халыкның тапкырлыгы чагыла. Алар кыска һәм оста әйтеләләр, гадәттә үткен һәм образлы сүзләрдән торалар. Фразеологик әйтелмәләр сөйләмне баетуда, аны үтемлерәк, көчлерәк һәм үткенрәк итүдә, фикерне тулырак ачуда зур роль уйный.

Стилистик яктан фразеологик әйтелмәләр эмоциональ-экспрессив, төрле стилистик төсмерләргә, субъектив бәяләү элементларына ия булалар. Фразеологик берәмлекләр үзгәрмичә дә кулланылырга мөмкин. Бу очракта фразеологик берәмлек үзенә хас булган мәгънәсендә генә кала. Әмма кайбер очракларда фразеологик берәмлекләр үзгәртелеп, яңа мәгънә, яңа төзелеш белән дә

кулланылырга, яңа эстетик һәм сурәтләү сыйфатлары алып, яңа фразеологизмга әйләнергә мөмкин.

Гомумхалык фразеологизмнар фондын блогосферада түбәндәге юнәлешләрдә үзгәртеп куллануы күзәтелә:

1. Фразеологизмның лексик-грамматик ягы яңара, мәгънәсе һәм төзелеше шул килеш кала. Мәсәлән, татар телендә "ачуым йөземә чыкты" яисә "шатлыгым йөземә чыкты" дигән фразеологизмнар бар. Татар журналисты Ильмира Сираҗи әлеге тезмәне "хисләрем күзләремә чыкты" формасында кулланган. Шул ук авторның блогында "ачуымны чыгара" тезмәсен "җенемне чыгара" формасында күзәтергә була һәм бу очракта ачу хисе тагы да көчәйтелеп бирелә.

2. Фразеологизм, лексик-грамматик бөтенлеген саклаган хәлдә, контекстта яңа мәгънә эчтәлегенә ия була. Мәсәлән, Эльмира Сираҗи үзенең инстаграм битендә икетөрле мәгънәгә ия булган тотрыклы сүзтезмә куллана: "Тордым да, суыткычта әни пешереп җибәргән ярты авыл тавыгы бар иде, шуны тәмләп кенә *бөгеп салдым*." Әлеге мисалда фразеологизм ашау процессын белдерә. Шундый ук бөтенне, ләкин башка мәгънәдә, сторисында да очратып булды: "Йокларга уйламый әле бу, ничек *бөгеп саласы* булыр".

3. Сурәтләү чарасы буларак фразеологизм үзе түгел, ә аның гомуми сурәте һәм эчтәлеге кулланыла. Ильмира Сираҗи блогыннан бер мисал: "Бер зур язучыбыз, халык шагыйре, әле дә хәтеремдә "Үзе баткан сазлыктан үзе чыксын", дип баш тартты". "Үзе баткан сазлыктан үзе чыксын" гыйбарәсе "Үзе егылган еламас" дигән тарихи әйтемгә нигезләнеп ясалган.

Фразеологизмнар телнең үзенчәлекле атау берәмлекләре буларак, төшенчәләрне белдерәләр. Аларны төп мәгънәләре белән өч типка бүләргә мөмкин: а) мәгънәсе атау характерында ирекле булган фразеологизмнар; ә) икенче төркем фразеологизмнарның башка сүзләргә бәйләнеше фразеологик бәйле була; б) өченче төр фразеологизмнарның синтаксик бәйле мәгънәләре була. Ул мәгънәләр теге яки бу җөмлә кисәге (хәбәр) функциясендә генә реальләшә.

Мәкаль-әйтемнәр кеше күңелен тирән фикер, мәгънәле төшенчә, матур хис-тойгы, күркәм сыйфатлар белән баеталар. Ул өйрәтә, киңәш бирә, аңа алдан хәбәр итү, күрәзәлек кылу, магиячелек тә хас. Шул ук вакытта ул сөйләмне дә бизи, тыңлаучыларны көлдерү, күңел ачу максатларына да хезмәт итә. Башкарган функцияләре ягыннан интернет челтәрләрендә очраган мәкальләрне берничә төргә бүләргә мөмкин:

1. Өйрәтү, үгет-нәсихәт бирү функциясендәге мәкальләр: "Яту белән тату булсаң яман" (Рәмис Латыйпов блогыннан). Әлеге мәкаль ялкау булмаска өйрәтә, ялкаулыкның нәтиҗәсе начар булачагына ишарә итә.

2. Киңәш бирү функциясен башкаручы әйтемнәр: “Яхшылык эшлә дә суга сал” (Ильмира Сираҗи блогыннан). Бу әйтем яхшылыкны кычкырып эшләмәскә кирәк, эшләгән яхшылыгыңны кайчан да булса күрерләр дигәнне аңлата.

3. Мәкаль һәм әйтем сөйләмне күркәмләндерү өчен генә түгел, ә тормыштагы теге яки бу вакыйгага, ситуациягә бәя бирү, аңа карата мөнәсәбәт белдерү өчен әйтелә. Мәсәлән: “Үзе баткан сазлыктан үзе чыксын”.

Мәкаль-әйтемнәрнең нигезендә халыкның яшәү рәвеше, тормыш фәлсәфәсе турындагы тирән мәгънә ята. Һәм алар сүз сөйләп өйрәтү, киңәш, үгет-нәсихәт бирү, гыйбрәт алу өчен ярдәм итәләр һәм тәрбия чарасы булып торалар.

Телнең лексик системасында милли характерның чагылышы һәм татар әдәби теленең саф килеш саклануы журналистлар һәм татар тел белгечләренең блогларында күзәтелә. Һәр блогерның үзенә хас язу стиле бар.

**Әдәбият**


1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр. – 1995.
2. Ефимов А.И. Стилистика художественной речи. – М.: Изд. МГУ, 1961.
3. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. – Казан, 1959. – 162 б.
4. Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы. – Казан, 1993. – 220 б.


## ТАТАР ҺӘМ ИНГЛИЗ ТЕЛЛӘРЕН УКЫТУДА МӘДӘНИ АСПЕКТНЫ ЧАГЫЛДЫРУЧЫ ИНТЕРАКТИВ ДӘФТӘРЛӘР


*Гыйләҗева Р., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Әшрәпова А.Х.*


Хәзерге заман мәгарифе иҗади шәхес, аның эчке мәдәниятын формалаштыру, кешене социомәдәни тормышка кертү, әйләнә-тирә дөньяны үзләштерүнең актив процессына кертү механизмы булырга тиеш. Аның төп максаты билгеле бер белем һәм күнекмәләрне үзләштерүдә генә түгел, бәлки укучының иҗади индивидуальлекләрен үстерү өчен шартлар тудыруда, аның эчке потенциалын максималь тулы ачуда да чагыла.

Мәкаләдә инглиз һәм татар телләрен интерактив метод ярдәмендә укыту һәм культурологик аспект мәсьәләләре каралган. Минем фикеремчә, һәр телне өйрәнгәндә җәмгыятьнең милли мәдәни үзенчәлеген исәпкә алу мөһим. Уку-укыту процессында милли-мәдәни аспект телнең мәдәни киңлегенә кертү белән генә чикләнмичә, укучыларның гомуми мәдәни дәрәҗәсе дә арта торган шартлар тудыра.

Заманча укыту технологияләр арасында иң нәтиҗәле ысулларның берсе – интерактив укыту методикасы. Интерактив укыту

– ул танып белү ысулы, шул ук вакытта укучылар бер-берсе белән үзара хезмәттәшлек итә, мәгълүмат белән алмаша, бер-берсенең гамәлләрен һәм үз-үзләрен тотышын бәяли, проблемаларны бергәләп хәл итә, ситуацияне модельләштерә һәм аларга чума [3: 24]. Күрсәтмәлелек булганда, һичшиксез, аңлау җиңеләя, тиешле сөйләм күнекмәләре уңышлы формалаша.

Интерактив дәфтәр – ул укучының дәфтәрен заманча алып бару формасы, ул дәресләрдә актив катнашырга, яңа мәгълүматны анализларга һәм тиз үзләштерергә ярдәм итә. Мондый дәфтәр балага теләсә кайсы вакытта уку материалын өйрәнү, карау, мавыктыргыч рәвештә кабатлау мөмкинлеген бирә.

Интерактив дәфтәр түбәндәге характеристикалар нигезендә дәүләт стандарты таләпләренә җавап бирә:

– мәгълүматлы;
– вариатив, ягъни файдалануның берничә варианты мөмкин;
– күпфункцияле, ягъни баланың иҗаты, фикерләве, игътибары, логикасы һәм хәтере үсешенә булыша;
– укучының сәнгати-эстетик үсеш чарасы булып тора;
– милли-мәдәни байлык турында мәгълүмат бирә;
– укучыларның уен, танып белү, иҗади эшчәнлеген тәэмин итә.

Интерактив дәфтәрләр түбәндәге өстенлекләргә ия:

1) грамматик теория визуальләшә, бу материалны аңлауны бермә-бер җиңеләйтә;
2) балалар мәгълүматны системага салып өйрәнә;
3) балаларның иҗади потенциалы үсә, фәнне өйрәнүгә мотивация арта;
4) интерактив дәфтәрләр ярдәмендә дәресләр җанлана [2: 42].

Интерактив дәфтәрләр грамматика, лексика, сөйләшү бүлекләрен өйрәнүдә кулланылырга мөмкин.

Күпчелек кешеләрдә күрү хәтере өстенлек итүен истә тотып, грамматиканы төрле схемалар сызып, рәсемнәр белән аңлату чыннан да отышлы килеп чыга. Укучы грамматик кагыйдәне яисә нинди дә булса конструкцияне төсле карандашлар, төрле кәгазьләр ярдәмендә мөстәкыйль рәвештә рәсмиләштергән вакытта, ул моны зур кызыксыну белән башкара, чөнки иҗат итү процессы аңа ләззәт бирә. Мондый материал дәреслектәге теләсә кайсы кагыйдәгә караганда яхшырак истә кала. Һичшиксез, үз кулың белән ясаган һәрнәрсә кыйммәтрәк.

Һәр телне өйрәнү өчен зур сүзлек запасына ия булу бик кирәк. Лекцияләрне китап-раскладушкалар аша үзләштерү традицион ятлауга караганда күпкә продуктиврак. Башка сүзләр белән әйткәндә, бала

интерактив дәфтәрне ачканда рәсемле уку материалын күргәч, яңа сүзләрне ассоциатив рәвештә истә калдыра. Өстәвенә интерактив дәфтәрдә яңа лексика тематика буенча бүленгән, ягъни билгеле бер системага салынып бирелә (“Family members” – “Гаилә әгъзалары”, “National food” – “Милли ризык”, “Home” – “Өй”). Әлеге интерактив дәфтәр ярдәмендә өйрәнелгән материал хәтердә озак саклана.

Бөтен кешегә мәгълүм факт: “Телне өйрәнү өчен, барыннан да элек, анда сөйләшергә кирәк”. Бу очракта интерактив дәфтәрнең аерылгысыз өлеше булган рольле уеннарның сөйләшү күнекмәләрне нәтиҗәле үстерүе турында сүз алып бару урынлы дип саныйм. Һәр укучы, билгеле бер роль алып һәм дәфтәрдәге күрсәтмәләрне кулланып, диалоглар төзи башлый, шул рәвешле үзен реаль тормыш ситуациясендә катнашучы дип күз алдына китерә. Балалар “In the shop” – “Кибеттә”, “In the theater” – “Театрда”, “At home” – “Өйдә” уеннарында актив катнашып, үз фикерләрен өйрәнелә торган телдә белдерә башлый. Һичшиксез, укуны уенга әверелдереп, баланың белем алу процессына кызыксынуын җәлеп итәргә һәм яхшы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.

Шулай итеп, интерактив дәфтәр укучының иҗатын, игътибарын, хәтерен, фикерләвен һәм логикасының үсешенә ярдәм итә. Мондый дәфтәрләрне дәресләрдә куллану укыту процессын укытучы өчен дә, укучылар өчен дә кызыклы итәргә ярдәм итә. Интерактив дәфтәр – ул укучының танып белү, иҗади активлыгын үстерергә, дәрестә материалны нәтиҗәле үзләштерергә һәм кабатларга ярдәм итә торган заманча укыту методы.

Тел – ул мәдәниятның бер өлеше һәм аны культурологик белемнәрдән башка өйрәнү мөмкин түгел. Заманча яшәү шартлары теләсә кайсы телне өйрәнүдән функциональлек таләп итә. Телне белү генә түгел, аны шул мәдәният вәкилләре белән аралашу чарасы буларак файдалана белергә дә кирәк. Әлеге төп гамәли максатка ирешү өчен укуда интерактив метод кулланырга мөмкин.

**Әдәбият**

1. Малышева Т.В. Влияние методов интерактивного обучения на развитие коммуникативной компетенции учащихся // Учитель в школе. – 2010. – N 4 – С. 14-16.

2. Райс О.И., Карпенко Е.А. Интерактивные технологии в обучении. Педагогика нового времени Издательство Ridero, 2020. – 80 с.

3. Щукин А.Н. Методы и технологии обучения иностранным языкам. – М.: Икар, 2017. − 240 с.

## БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОНЫНЫҢ УРАЗАЙ АВЫЛЫ МИКРОТОПОНИМИКАСЫ

*Гыйльмиярова М., М.Акмулла ис. БГПУ, II курс студенты*

Һәр авылның үз тарихы, үз атамалары бар. Халык авылның кое-чишмәсенә, елга-күленә, чокыр-басуларына, урман-болыннарына бик матур исемнәр биргән. Ул географик исемнәр белән без балачактан ук очрашабыз һәм ул атамалар кечкенәдән үк безне үзенә тартып тора. «Үткәнен белмәгәннең – киләчәге юк!» – ди халык. Димәк, без авылның үткән тарихы белән кызыксынабыз икән, киләчәгебез дә мәгънәле булыр.

Уразай авылның тарихын, топонимикасын өйрәнү максатынан, мин авылыбызның мөхтәрәм әби-бабайлары белән очраштым, алар сөйләгәннәрне язып алдым. Болардан тыш материалны район архивыннан алдым, вакытлы матбугатта чыккан мәгълүматтан файдаландым, шулай ук район тарихына мөнәсәбәтле башка чыганаклар белән таныштым. Уразай урта мәктәбендә тупланган истәлекләр дә миңа таяныч булды.

Балтач районы – Башкортстан Республикасындагы муниципаль район. Ул Башкортстанның төньяк-көнбатышында урнашып, Тәтешле, Аскын, Борай районнары белән чиктәш. Районның мәйданы 1598 кв/км тәшкил итә. Балтач районы 1930 елда оешкан. 2018 елның 1 гыйнварына халык саны 18981 кеше тәшкил иткән, халыкның 35% район үзәгендә – Иске Балтач авылында яши. Балтач районы территориясендә уннан артык милләт вәкиле – башкортлар, татарлар, марилар, руслар, удмуртлар һ.б. гомер итә. Район җирле 15 авыл советы биләмәсендәге 79 торак пунктны берләштерә.

Уфадан район үзәге Иске Балтач авылына кадәр – 142 чакрым, «Идел» М-7 автомобиль трассасы буенча – 250 чакрым, республика әһәмиятендәге юллар буенча 190 чакрым. Төньяк-көнбатышка таба 70 чакрым ераклыкта Пермь өлкәсенең Куяды тимер юл станциясе урнашкан.

Минем туган авылым – Уразай авылы Балтач районы үзәге Иске Балтач авылыннан 20 чакрым ераклыкта урынлашкан. Моннан күп еллар элек 1500-1550 елларда Сембер губернасыннан Уразай исемле кешене куып җибәрәләр. Ул биш малае һәм берничә иптәше белән кара урман белән уратып алынган елга буена килеп урынаша. Уразай картка кадәр Тимофей дигән рус елганың башына килеп яши башлаган була. Ул авыл Тимофей исеменә бәйле Тимкә дип исемләнә. Авылның төньягында Көнтүгеш авылы була.

Уразай карт бик тырыш һәм эш сөючән кеше була. Яз көне ул биш улына сабан тоттырып сабанга чыга. Көз көне улларын өйләндереп, башка чыгара. Көнтүгеш карт кызын Уразай карт малаена

кияүгә бирәләр. Көнтүгеш карт коры елга буендагы үзәнле җирләрен яшьләргә бүләк итеп бирә. Шуннан Көнтүгешнең җире чигенә чаклы елганы ***Чигелде*** дип атый башлыйлар.

Уразай карт озак кына яшәгәннән соң, үлеп китә. Аны авылның хәзерге көньягына карагайлы зиратка күмәләр. Ул заманына күрә бик зирәк акыллы, зиһенле кеше булган. Шуңа күрә аны халык яраткан, үзе үлгәннән соң авылга Уразай исемен кушканнар.

Уразай авылының алты мең десятина чамасы җире булган. Аның чикләре төньякта яңа Итәвәш (хәзерге Яңа Штәнде) янындагы Сармазы елгасына кадәр, көньякта – Актүбәгә кадәр, ә көнчыгышта – хәзерге чикләргә кадәр сузыла.

Уразай картның ни өчен нәкъ шушында авылга нигез салганы гаҗәп түгел, чөнки бу төбәктә табигать шактый бай булган. Танып елгасына килеп тоташкан Кушчы елгасы авылны икегә бүлеп, чылтырап агып ята. Тирә-юньдә яшәгән кешеләр, бигерәк тә балыкчылар, балыкка бай елгадан ел әйләнәсенә балык тоталар. Тирә-як үтә алмаслык кара урман була. Авыл халкы элек-электән урманчылык белән дә шөгыльләнә. Урманны кисеп, мәчет, магази, хуҗалык йортлары төзегәннәр. Урманнарда бүре, куян, төлке, поши, кабан дугызларын һ.б. бик күп төрле киекләр була.

Авылның тирә ягындагы төрле җирләргә халык төрле атамалар бирә. Туган авылым елга-су атамаларына да бик бай. Аларның һәрберсе кызыклы тарихка ия. Тимкә авылыннан башланган елгага бик күп чишмәләр кушыла. Шуңа күрә бу елга ***Кушчы*** дип атала. Иванай белән Уразай авыллары арасында ***Сарысаз елгасы*** урнашкан. Шул елгадан Уразай җире башлана. Бу елганың суы бик чиста булып, аш-су һәм чәй өчен файдаланылган, ләкин соңрак бозылып, иселәнеп, саргаеп калган. Шуңа күрә авыл халкы бу күлгә Сарысаз күле дип исем кушкан. Юлда китеп барган кешеләрне дә тотып ала икән, дигән легенда да бар. ***Эчкип елгасы*** атамасы кеше исеменә бәйле, дип фаразлана. Ул лагерь буенда урнашкан кипкән елга, Әүлияләр кабере ягыннан агып килә. Аны халык ***Арның теге ягы*** дип тә йөртә. ***Асылташ елгасы*** чакма таш (янәсе, асылташ) күп булганлыктан, шулай исемләнгән. Ташларга чарт-чорт итеп сугып, шырпы кабызып булган. Ләшәдедән Кушчыга кадәр сузылган бу елга. Тимкә белән Уразай авыллары җирләренең чиге санала. ***Бикмәк*** елгасы Богдан имәнлеге буендагы чишмәдән башлана, ләкин аның суы авылга кадәр килеп җитмичә, җир астына кереп китә. ***Чигелде*** елгасы бүген корыган – сусыз елга. Башында күле бар, анда җәйнең эссе көннәрендә аюлар су керәләр икән, дип сөйли авылдашларым. ***Чардаклы*** **елгасы** Ар

елгасының төнъягында урнашкан һәм Иванай белән Уразай җирләрен аерып тора.

***Тегермән күле.*** Бер тегермәнче тегермәненә су кирәк булгач, кешеләр яллый да, чишмә күзләрен ачтыртыр өчен, җир казыта. Бу җирдә күл барлыкка килә. Кызганыч, бүген бу күл кибеп, юкка чыккан. ***Мунчала*** күле Яңа Уразай юлы өстендә. Бу күлнең балыгыннан сасыган мунчала исе килгән, чөнки анда айлар буе мунчала җебеткәннәр. Уразайлар аны *Нефть күле* дип тә йөртәләр, чөнки анда скважина бар. Элек аннан ат арбасын майларга дегет (мазут) агызып алганнар. ***Карьер күле*** Тимкә авылы ягында урынлашкан. Элек торф казып алган булганнар, шул урында күл барлыкка килгән. Аны элек *Карыш куагы* дип тә йөрткәннәр. Элек колхоз агрономы булган Валиев Фәрит, Садыков Гилемхан, Гафуров Гатиф исемле кешеләр күлгә балык җибәргән булганнар. Балыгы әле дә бар. Хәзер аның тирә-ягын каен урманы уратып алган. Күлне икегә бүлеп, уртасыннан шулай ук каеннар үсеп утыра. Бер ягында сары табан балыгы, икенче ягында көзге (зеркальный карась) кебек балыклар бар. Күлнең кырыйларын таллар уратып алган.

Сарысазның аскы ягында ***Кеше баш чишмәсе*** бар. Шулай, бер мәл халык басу эшләреннән кайтканда, чишмәгә су эчәргә туктый. Ләкин чишмәгә кеше башы ташланган була. Соңрак чишмәнең күзе тирәнрәк булсын дип, көрәкләр белән чистартып, астагы ләмне чыгаралар. Ләм белән бергә билгесез кешенең баш сөяге дә килеп чыга. Шушы вакыйга бәйле ул шундый атама йөртә башлый. Соңрак чишмәне барыбер су чыганагы буларак файдаланалар. ***Гата*** чишмәсе Ар елгасы буендагы авыл чишмәләренең берсе. Чишмәне элек Гата исемле абзый чистартып торган булган. ***Мөнәвәрә чишмәсе*** сугыш вакытында геройларча хәлак булган авылдашым Мөнирә исемле медсестрага багышлап исемләнгән. Ул Балтач ягыннан килеп Кушчы елгасының куперен чыккач, уң якта урнашкан.

***Исакай*** – авылдан ерак түгел, Балтач юлы өстендәге баткаклык. 19 гасыр азагында була бу фаҗига. Язгы ташкында басудан көчле су агымы килә. Исакай исемле мари кешесе аты белән бу елгага килеп, батып үлә. Ярдәм сорап кычкырган тавышка килүче булмый.

***Садыйк тугае.*** Элек печәнлек җирләренең иң яхшылары байларга бирелгән. Авылның иң яхшы печәнлекләрнең берсе Колый Балтач улы, старшина Садыйкныкы булган. ***Гаскәр тугае*** *Ар елгасы* буенда урынлашкан һәм элек Галиәскәр Хаҗинең печәнлеге булган. Хазер инде аны тал баскан. Ул иң зур тугайларның берсе саналган. Шулай, көннәрдән бер көнне узып баручы патша гаскәрләре бу тугайда ял иткән, төн үткәргән. Хәтта Урал заводларына китеп барганда,

Салават Юлаевның бер отряды шунда кунган, дип сөйләнелә бер риваятьтә. ***Таллы тугай*** *Гаскәр тугаеннан* соң урынлашкан. Тугайның уртасында зур калын тал агачы үсеп утырганга күрә, ул шулай аталган. Таллы тугайдан соң, Сарысазга таба, Ар елгасы буйлап ***Эчке саз тугае*** һәм ***Тышкы саз тугае*** урнашкан. ***Бирге әрәмәлек*** авылны чыккач, Ар елгасы буенда, ә ***Аргы әрәмәлек*** Эчкиптән соң урнашкан. ***Камышлы тугай*** камышы бик күп булганга шулай аталган. Ул Көнтүгеш белән чик үткән җир. ***Нурый тугае*** Ар елгасының күпереннән чыккач Янбай авылы ягындагы болын. Ул Нурый исемле кешенең печәнлеге булган.

***Ләшәде*** исемен Иске Янбай авылы ягыннан килгәндә, лагерь буендагы бер таудан чыккан елга һәм Уразай белән Көндәшле авыллары арасындагы урман йөртә. Көндәшлеләр урманны ***Түбәтәй*** дип тә йөретәләр, ә безнең авылның олырак кешеләре аны ***Керә*** дип атаганнар. Бу атама җирне бүлү белән бәйләп аңлатыла. Янәсе, бер судья: Бу җир сиңа *керә*, монысы тегесенә *керә,* – дигән икән.

***Җиләк тавы.*** Ферма теге ягында. Тирән Чигелде елгасы һәм Чигелде басуы буенда урынлашкан. Элегрәк *Чебешчелек тавы* дип тә аталган.

***Такыя урманы.*** Такыя тавы өстендәге урман. ***Богдан имәнлеге*** Богдан авылы ягында булганга шулай дип аталган. ***Аюлар куагы*** Көнтүгеш авылы ягында урнашкан. Элек авыл халкы анда аюларны бик еш күргәннәр.

Мәктәп булмаганга, белемгә омтылучы яшьләр читкә мәдрәсәләргә йөреп укыганнар. Фаразлар буенча, алар Югары Карыш авылындгы Батырша мәдрәсәсендә укырга йөрегәннәр. Бу мәдрәсәдә югыры дини белем алу мөмкинлеге булган. Югары Карыш авылында укымышлы кеше, дини кешеләр бик күп була. Шушы мәдрәсәдән кайтканда, буранда адашып, 6 шәкерт тау башында туңып үләләр. Алар үлгән җиргә күмелә, һәм бу җирне халык ***Әүлияләр кабере*** дип исемли. Шәкертләр үлгән урын изге дип саналган, алар истәлегенә каеннар утыртылган.

Җирле атамалар әби-бабаларыбыздан калган кадерле мирас. Һәр атаманы хөрмәт белән өйрәнү бик кирәкле эш. Мин дә туган төбәгемнең атамаларын тагын да җентекле өйрәнермен.

**Әдәбият**

1. РГАДА. Русия Дәүләтенең борынгы актлар архивы. Ф. 350. Оп. 2. Д. 3802.
2. Уразай урта мәктәбендә тупланган истәлекләр.
3. Хазимов Х., Гарипов Р. Уразай һәм уразайлылар. – Уфа: Полиграфдизайн, 2018. – 322 б.

# ЭСТЕТИЧЕСКАЯ ФУНКЦИЯ СРАВНЕНИЙ В КИТАЙСКИХ ЛИТЕРАТУРНЫХ ПРОИЗВЕДЕНИЯХ

*Жун Юй, КФУ, магистрант II курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Болгарова Р.М.*

Сравнение – наиболее распространенное риторическое явление в китайском языке. И такое явление универсальной риторики должно быть реализовано с помощью каких-то грамматических средств. С точки зрения риторики, его использование является своего рода языковым украшением, которое может заставить язык достичь красивых эффектов. С точки зрения грамматики, его построение – это языковая операция, реализующая эстетическую ценность. И процесс операции завершается с помощью определенной грамматической конструкции.

В китайском языке, сравнение（比喻 Би Юй） - это две вещи разной природы, но они похожи друг на друга. Используйте один из них, чтобы сравнить риторику другого. Сравнение обычно состоит из трех частей: субстанция (本体 Бэнь Ти：сравниваемая вещь или ситуация), части сравнения（喻体 Юй Ти） и образного слова (比喻词 Би Юй Цы：знакового слова для сравнения).

Эстетическая функция сравнение в основном отражается в литературных произведениях. Ценное литературное произведение должно быть красивым. Он может вызвать у людей сильное чувство прекрасного и произвести сильный художественный шок; и различные формы выражения в произведениях с таким художественным обаянием, такие как сравнение, также должны быть красивыми. Сравнение пригодятся в литературных произведениях, будь то изображение персонажей, описание окружающей среды, создание художественных концепций и выражение эмоций. Показывает большую эстетическую ценность. Можно сказать, что без Сравнение не бывает настоящей литературы. Его эстетическая функция воплощается в следующих аспектах:

1. 意象美 «И Сян Мэй»

«И Сян» в современных китайских словарях - это «сплав объективного образа и субъективного разума с определенным значением и настроением». В литературных произведениях сравнение создают новое «И Сян», стимулируют воображение зрителей и пробуждают богатые чувства людей. Мы знаем, что сравнение нельзя отделить от словесных символов, а вербальные символы обладают разными качествами при отражении объективного мира. В нехудожественных стилях сравнение используют феноменологически

сходные отношения между «Юй Ти» и «Бэнь Ти» для распознавания предмета. Содержание «Юй Ти» является лишь инструментом и мостом для познания. Содержимое, которое он содержит, является только знакомой информацией об опыте, его не нужно узнавать. Однако в литературных произведениях образ, обеспечиваемый сравнительным «Юй Ти», является непременным содержанием художественного образа и эстетического объекта.

2. 形象美 «Син Сян Мэй»：Образ красоты

В литературном творчестве сравнение часто используются для яркого описания жизненных сцен, вещей, личностей персонажей или настроений лирических предметов. Сравнение могут сравнивать реальную вещь с реальной и могут сделать оригинальные вещи более яркими и яркими. Сравнение также могут сравнивать реальные объекты с нематериальными вещами. Превратите эти нематериальные активы или абстрактные эмоции в конкретные и осмысленные художественные образы.

3. 情感美 «Цин Гань Мэй»:Эмоциональная красота.

Литература и искусство по своей природе склонны к эмоциональному богатству. Эмоции – это жизнь литературы и искусства, а произведения без эмоций ни в коем случае не являются настоящими литературными произведениями; чем сильнее эмоции, тем больше они могут перемещать читателей через границы времени и пространства, и тем дольше будет жизнь. В литературных произведениях сравнения могут не только создавать яркие и живые образы, но и писатели всегда встраивают в этот образ субъективную эмоциональную информацию, чтобы вызвать эмоциональный резонанс читателей.

Сравнения в литературных произведениях часто используют абстрактные сравнение. Подобное абстрактное сравнение часто выражает глубокие чувства писателя, потому что он часто использует сравнения с определенным эмоциональным оттенком, такие как «мечта», «любовь», «печаль».

4. 新奇美 «Синь Ци Мэй»：Новинка.

Чжу Цзыцин отмечал в своей статье «Литература и язык»: «Сравнение является важной частью литературы. Поэты и писатели всегда должны создавать его и преобразовывать его». Все это указывает на то, что сравнение литературных произведений стремится показать новизну и странность. Новизна и красота сравнения отражена и в его модернизации. Развитие общества и прогресс науки будут

отражены в сравнении «Юй Ти» во времени, делое сравнение явно современной.

Таким образом, мы обсудили четыре эстетические функции сравнения в литературных произведениях:«И Сян Мэй», «Син Сян Мэй», «Цин Гань Мэй», «Синь Ци Мэй». Умное использование сравнение позволяет читателям ощутить естественную и художественную красоту статьи. Неуместные сравнения могут сделать людей более неосведомленными о значении статьи и разрушить эстетическую ценность литературных произведений. Только при разумном использовании сравнений можно точно передать изображаемые предметы; только когда они свежи и своеобразны, они могут произвести на людей ясное впечатление.

**Литература**

1.Ван Ливэнь. Внешность человека как объект характеристики в системе устойчивых сравнений русского языка: дис. ... канд. филол. наук / Ван Ливэнь; Московский педаг. гос. ун-т. – М.., 2016. – 347 с.

2.Войцехович И.В. Практическая фразеология современного китайского языка. – Москва: АСТ: Восток-Запад, 2017. – 509 с.

## ЛЕКСИКА ПРОИЗВЕДЕНИЙ ВОЕННОЙ ТЕМАТИКИ В ТАТАРСКОЙ И НЕМЕЦКОЙ ЛИТЕРАТУРАХ

(на материале произведений «Фронтовики» М.Магдеева и «На западном фронте без перемен» М.Э. Ремарка)

*Закирова Я., Курамшина З., РИИ, студенты II курса*

*Науч. рук. – канд. пед. наук, доц. Айдарова С.Х.*

Тема войны является одной из главных в мировой литературе. Ей посвящено множество произведений в самых различных жанрах: это и стихи, и поэмы, небольшие рассказы и объемные романы. Довольно часто авторами этих произведений были писатели, которые сами принимали непосредственное участие в военных действиях.

В рамках этой статьи хочется отметить особую лексику, показывающую все ужасы войны. Нами были взяты известные произведения XX века «Фронтовики» (1983) выдающегося татарского писателя М. Магдеева и «На западном фронте без перемен» (1929) немецкого писателя Э.М. Ремарка, представителя «потерянного поколения».

В романе «Фронтовики» описывается послевоенное время, а именно жизнь людей в маленькой деревне. В центре сюжета два учителя, побывавших на войне – Рушад и Гата. Они – те, кто увидели всю горечь войны, те, кто потеряли своих товарищей на поле битвы.

Роман Эриха Марии Ремарка «На Западном фронте без перемен» – это книга, повествующая о поколении, которое погубила бессмысленная война, о ребятах, которые, не повидав жизни, сразу столкнулись с ее ужасами. Мотивы произведений переплетаются. Рушад и Гата – представители потерянного поколения. В отличие от других произведений на эту тему, в которых, как правило, речь идет о героических подвигах солдат, в романе М. Магдеева и Э.М. Ремарка описываются невероятные трудности и никчемность военных действий, несущих с собой страдания...

Обратим внимание на лексику из некоторых отрывков произведения «Фронтовики». Интересующая нашу тему лексика выделяется. *«После этого началась совсем* ***иная жизнь****... Рушад за эти дни* ***превратился во взрослого человека****,* ***научился курить****, собственными глазами* ***видел торпеды, убившие сотни людей****. Несколько раз* ***встретился лицом к лицу со смертью****»* [1,192]. *«И события, что были в голове, снова всплыли наружу.* ***Смутные, болезненные ночи*** *сменяли друг друга. Лишь одна мысль непрерывно преследовала его –* ***молодость осталась там. Он постарел. Постарел молодым****»* [1,193]. *«Он встал с кровати. Ни радио, ни термометра нет. Нет места, куда бы можно было пойти. Какая-то* ***тяжесть, пустота. Бессмыслица****. Это понимает и мама учительница, у которой уже* ***проступила седина****, которая, ничего* ***не говоря****,* ***переживает*** *всё это со своим сыном»* [1,193]. *«...для народа,* ***благодаря героическому труду*** *которого была выиграна война... Это* ***траурный марш... в честь павших на поле боя солдат****»* [1:304].

Как видно из примеров, они передают психологическое состояние молодых людей, людей потерянного поколения из-за никому ненужной, «никчемной войны». Такой же психологизм произведения несут следующие примеры из отрывка произведения немецкой литературы Э.М. Ремарка «На западном фронте без перемен»: *«Я молод – мне двадцать лет, но все, что я видел в жизни, – это* ***отчаяние, смерть, страх*** *и сплетение нелепейшего* ***бездумного прозябания с безмерными муками****»* [2:1]. *«...Тому, кто в нее попал, приходится,* ***напрягая нервы****,* ***ждать****,* ***что*** *с ним* ***будет дальше****...»* [2: 15]. *«...****Покоряются чужой воле****,* ***не ведая****, что творят,* ***не зная за собой вины****»* [2:15]. *«Мы шутим не потому, что нам свойственно чувство юмора, нет, мы стараемся* ***не терять чувства юмора****, потому что без него* ***мы пропадем****»* [2: 61]. *« ...* ***Все ужасы*** *можно* ***пережить****, пока ты просто* ***покоряешься своей судьбе****, но попробуй размышлять о них, и* ***они убьют тебя****»* [2:94]. *«... Допустим, мы* ***останемся в живых; но будем ли мы жить****?»* [2:97]. *«...* ***Война*** *– это*

*нечто вроде* ***опасной болезни****, от которой можно* ***умереть****, как* ***умирают от рака и туберкулеза, от гриппа и дизентерии****. Только* ***смертельный исход*** *наступает гораздо чаще, и* ***смерть приходит*** *в гораздо более разнообразных и* ***страшных обличьях…****»* [2, 110]. *«И вновь в* ***безумной атаке*** *за* ***выжженный войной кусок земли погибнет тысяча человек****. А к вечеру этот кусок* ***отобьет враг,*** *и* ***погибнет еще одна тысяча ничего не значащих для Империи жизней****. Но* ***в сухих армейских сводках*** *про этот день,* ***полный смерти, ужаса и боли*** *скажут: на западном* фронте… без перемен …» [2:170].

Как видим, каждая строка произведений насыщена лексикой, негативно окрашенной, несущей значение отчаяния, страха, боли, ужаса, потери, смерти.

Была ли надежда на светлое будущее? Смог ли найти Рушад свое счастье? Смог. Счастье предстало перед ним в лице Ляйлягуль: «***Смысл жизни*** *лишь только начал открываться перед Рушадом. Интересно! Надо же вся* ***красота мира, весь её смысл в семнадцатилетней девушке!****»* [1:303]. Именно эта девушка явилась спасительным кругом в темном мире героя, именно она помогла взглянуть на мир другими глазами, ждать её он готов был пять, десять, пятнадцать лет.

Пауль, в отличие от Рушада, не смог испытать эти чувства. О себе и своих друзьях он говорит: *«Мы солдаты, а уж потом, удивительным и* ***стыдливым образом, еще и люди…****»* [2:170]. Именно в этих строках заложена основная концепция романа, сутью которой является мысль о том, что война сделала из вчерашних школьников никчемных людей. Они больше не молодежь, которая стремится жить, узнавать мир, совершенствовать себя, добиваться каких-то высот и открывать что-то новое. Они беглецы, которые бегут от самих себя.

**Литература**

1. Магдеев М. С. Фронтовики: Роман. Пер. с тат. Е.Леваковской. – Казань: Таткнигоиздат, 1983. – 304 с.
2. Ремарк Э.М. На западном фронте без перемен: Роман. Пер. с нем. Ю.Н.Афонькина. – М.: Книга и бизнес, 1992. – 170 с.

## ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ Ф.Г. ХИСАМИТДИНОВОЙ В ОБЛАСТИ БАШКИРСКОЙ МИФОЛОГИИ

*Альмухаметова Г., КФУ, магистрант I курса*
*Науч. рук. – докт. филол. наук, проф., Юсупова А.Ш.*

Профессор Фирдаус Гильмитдиновна Хисамитдинова, научный руководитель Института истории, языка и литературы УФИЦ РАН,

хорошо известна тюркологам своими работами в областях филологии и диалектологии башкирского языка, башкирской и общетюрской ономастики и преподования башкирского языка как иностарнного.

Кроме того, она занимается изучением мифологии башкирского народа. В 2019 году в Башкирском издательстве «Китап» имени Зайнаб Биишевой вышла новая книга Ф.Г. Хисамитдиновой «Словарь башкирской мифологии». Книга подготовлена тщательно и ответственно. Автор проделала большой труд для того, чтобы собрать в одной книге самые интересные сюжеты, символы, персонажи национальных преданий башкирского народа. Книга представляет собой переработанное и существенно расширенное издание мифологического словаря. Не исключено, что данный труд является большим достижением не только для башкирской, но и для общетюркской мифологии.

Мифология башкир, одного из древних народов, населявших южную часть Уральских гор, хранит в себе следы многих эпох. Башкирские мифы воплотились в обрядах и ритуалах башкир, их обычаях, поверьях, приметах. Мифы нашли отражение в эпосах «Урал-Батыр» (Урал-Богатырь), «Акбузат» (Мифический белый конь), «Заятүләк һәм Хыуһылыу» (Заятуляк и водяная красавица).

Ф.Г Хисамитдинова в своем словаре широко охватила тематики мифических и мифологизированных персонажей, животных, растений, явлений природы, отдельных предметов, ритуалов, частей тела, болезней, состояний человека.

Также большую ценность в словаре представляют сведения, которые отражают текст башкирской мифологии, аналогов которых не находят у других народов. Это сюжеты про «Акбузат» (Мифический крылатый конь; божество, покровитель; в эпосе «Урал-батыр» вещий помощник солнечной девы Хумай и Урал-батыра; связан с верхним миром. В то же время связан с озерами Бугадак, Шульган, пещерой Шульганташ, т.е. с нижним миром. *Әбйәлил районының Боғаҙаҡ күлендә Аҡбуҙат йәшәй икән* (БМ). – Говорят, в озере Бугадак Абзелиловского района живет Ак-бузат), «Игэт» (Скот от приданого женщины. Приплод этого скота используется на ежегодных поминках. *Игәт* содержит семантику доли (доли дочери в общем и доли родителей в доле дочери). *Игәт малына йылда атайыма, әсәйемә аят укытам* (З. Ниғмәтуллина). – Каждый год на приплод от игэт провожу поминки по отцу и матери. Слово восходит к общетюркскому *eget* ‘приданое’, ‘надел земли’, ‘скот в составе приданого’), «Ҡытмыр» (Бес. *Ҡытмыр – иң усал бәрей заты*. – Кытмыр – самый злой из бесов).

Деятельность Хисамитдиновой в области башкирской мифологии- своеобразный феномен: лишь небольшая часть персонажей башкирской демонологии встречается и в мифологии соседних тюркских народов. Поэтому можно рекомендовать литературу не только тюркологам и исследователям башкирского народа, но и всем тем, кто интересуется изучением мифологии.

**Литература**


1. Хисамитдинова Ф.Г. Мифологический словарь башкирского языка. – М.: Наука, 2010. – 456 с.
2. Хисамитдинова Ф.Г. Башҡорт мифологияһы. – Өфө: Ғилем, 2002. – 126 б.


## ТАТАР ҺӘМ КАЗАХ ТЕЛЛӘРЕНДӘГЕ [А] АВАЗЫНА ЧАГЫШТЫРМА ХАРАКТЕРИСТИКА


*Гайфетдинова Р., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Саттарова М.Р.*


Төрки телләрне чагыштырма аспектта өйрәнү киң таралыш тапкан. Әлеге метод телләрнең тарихын, үзенчәлекләрен, бер-берсе белән бәйләнешен ачыкларга ярдәм итә.

Н.А. Баскаков классификациясе буенча, татар һәм казах телләре көнбатыш хун тармагының кыпчак төркеменә керәләр. Шулай итеп, бу ике тел аваз системаларының уртак үзенчәлекләре дә бар. Әлеге уртак һәм сөйләмдә чагылган аермалы якларын [а] авазы мисалында карап китик.

Татар телендә авазларны телнең хәрәкәтенә һәм иреннәр торышана карап классификациялиләр, ә казах телендә тагын бер билгене аерып чыгаралар: казналыкның ачык яки ябык булуына карап төркемләү. Ике телдә дә [а] авазы иреннәр үзгәреше буенча иренләшмәгән; тел күтәрелеше буенча арткы рәткә карый, ягъни калын сузык. Казах фонетикасында аңкаулыкның киеренке торышы буенча, татар телендә телнең вертикаль күчешенә мөнәсәбәтле тубән күтәрелеше белән, ачык аваз булып килә. Сузыкларның фәнни тасвирламасына килгәндә, алар икесе дә бертөрле аваз булырга тиеш кебек. Ләкин җанлы сөйләм вакытында һәр телнең үз үзенчәлеге чагыла.

Татар телендә [а] авазының, нигездә, ике төрле әйтелеше бар: ачык [а] һәм иренләшкән [$а^{о}$]. Бу төрлелек диалектларда чагылыш тапкан:

1) көнбатыш диалектында [а] авазын ачык, рус [а] авазына якын итеп әйтәләр. Шуңа күрә аларны *а-лаштыручылар* дип йөртәләр [2: 25];

2) урта диалектта [а] авазын иренләштереп, ягъни *олаштырып* әйтәләр. Шул сәбәпле, әлеге диалект вәкилләрен *о-лаштыручылар* дип йөртәләр [2: 25].

Олаштыру күренеше – очраклы гына түгел, ә тарих белән бик тыгыз бәйләнештә тора. Куп кенә галимнәр төрки телләрне өйрәнгән вакытта бу мәсьәләгә игътибар иткәннәр һәм төрле фикерләр төркәп калдырганнар. Мәсәлән, профессор Н.К. Дмитриев әлеге күренешне төрки телләр арасында татар һәм башкорт телләренә хас дип билгели [1: 8]. Бу урында шуны әйтеп үтәргә кирәк, олаштыру татар теленең урта диалектында гына урын алган. Һәм әлеге аваз сүз башында көчле позициядә тора, алдагы иҗекләрдә акрынлап үз көчен югалтып, сүз ахырында ачык [а] авазы ишетелә.

Л. Җәләй әлеге авазны җентекләп өйрәнүчеләрнең берсе. Ул төрле теоретикларның фикерләрен җыеп анализлый һәм бер тәртипкә җыя. Галим шул материаллар нигезендә иренләшкән [а] авазының барлыкка килүнең берничә сәбәбен аерып чыгара:

1) олашкан [а] борынгы чордагы [о] авазының а-лашып, ачылып бара торган варианты;

2) иренләшмә [а] авазының болгар чоры кабиләләре теленнән килүе мөмкин. Чөнки татар телендәге [а] авазы чуваш телендәге [о] – [у] авазларына туры килә: *табыш (тат.) – тупыш (чув.), тайак (тат.) – тойа(к) (чув.).*

Ә чуваш теле Идел-Кама болгарлары чорындагы бер диалект булган.

3) [а] авазы тел формалашу чорында татар теленең төрле диалектларында төрлечә әйтелештә урын алган. Чөнки бер тел эчендәге диалектларда һәм сөйләшләрдә авазларның ясалышы һәм әйтелеше төрле вариантта очрарга мөмкин [2: 28-29].

Татар теле яшәү тарихында [а] авазының әйтелеш төрлелеге беркайчан да мәгънә аермаган, диалекталь вариантлар булып кына йөргәннәр.

Казах теленә килгәндә, В.В. Радлов ике төрле [а] авазы аерып чыгара. Беренчесе ул төп [а] авазы, икенчесе аңа охшаш, инглиз телендәге [æ] авазы әйтелешле [а] авазын билгели. Ул әйтелеше белән [а] белән [ә] авазлары катышкан сыман әйтелә. Ләкин хәзерге көндә әлеге аваз аерым [ә] авазы итеп билгеләнә [4: 67].

В.В. Радлов әлеге авазны үз классификациясендә ачык (киң), бугаз һәм тешләр ярдәмендә ясалучы аваз дип (денто-гортанный) карый. Аны әйткән вакытта тешләр бугаздан килгән һава агымына чикләр булып торалар, ә иреннәр киң итеп ачылалар һәм катнашмыйлар [4: 71].

В.В. Радловның авазларны төркемләве хәзерге көн фонетистлары өчен күп кенә материал бирә, ул билгеләгән аваз үзенчәлекләре галимнәрнең тикшеренүләре өчен нигез булып тора.

С. Кенесбаев казах теленең [а] авазы рус телендәге [а] белән чагыштырган вакытта ясалу урыны арттарак һәм бу күренешне ул казах телендә [ә] авазының булуы, рус телендә булмавы белән бәйләп карый. Галим сузыкның [ә] фонемасы белән чиратлашып төрле мәгънәдәге сүзләр барлыкка килүен билгели: *ал (возьми) – әл (сила, мощь), сат (продай) – сәт (удача)*[3: 274].

Татар телендә әлеге күренеш сирәк очракларда күзәтелә: *ачы (острый) – әче (кислый).* Ләкин куп очракта авазларның алмашуы мәгънә үзгәреше барлыкка китерми, бары тик диалекталь вариант булып килә ала: *ачкыч – әчкеч.*

Нәтиҗә ясап әйткәндә, ике телдә дә [а] авазы ясалышы ягыннан бер үк төзелешкә ия. Ә инде җанлы сөйләмгә килгәндә яңгырашы ягыннан аермалылыклар күзәтелә. Моны без татар телендә [а] авазының о-лашкан варианты булу һәм казах телендә әлеге аваз бер вариантта гына килүендә күзәтә алабыз.

Шулай итеп, авазларны чагыштырма планда өйрәнгән вакытта, аларның тарихи үсеш-үзгәрешенә, өйрәнелешенә һәм хәзерге көндә җанлы сөйләмдә чагылышына зур игътибар бирергә кирәк.

**Әдәбият**

1. Дмитриев Н.К. Грамматика башкирского языка. – М.: Академия Наук СССР, 1948. – 39 с.

2. Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 108 с.

3. Кенесбаев С. Исследования по казахскому языкознанию. – Алмата: Наука, 1987. – 352 с.

4. Хусаинов К.Ш. В.В. Радлов и казахский язык. – Алмата: Наука, 1981 – 172 с.

5. Щербак А.М. Сравнительная фонетика тюркских языков. – Л.: Наука, 1970. – 204 с.

## ТЕРМИНЫ КРОВНОГО РОДСТВА В ТУРКМЕНСКОМ ЯЗЫКЕ

*Денгизов Д., КФУ, магистрант I курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Замалетдинова Г.Ф.*

Термины родства во многих языках относятся к древнейшему периоду. Сущность терминов кровного родства заключается в том, что в них отражаются важные для жизни и функционирования человеческого сообщества взаимосвязи. Они основаны на истории социальных отношений людей в обществе и их осмыслении этих отношений. Именно поэтому рассмотрение термины кровного родства в лингвокультурологическом плане, имеет важное, значение для понимания структуры определения родства и языковых форм его фиксации. Среди тематических пластов лексики на одно из первых мест по давности происхождения, максимальной устойчивости и

общенародности понятий, обозначаемых ими, следует поставить лексику, которая обозначает именно термины кровного родства.

«Слова, называющие людей, которые произошли от одного общего предка, являются терминами кровного родства (ТКР), а слова, называющие родственников супругов – терминами некровного родства (ТНР)» [1: 258]. Терминология родства – связь членов семьи мужского и женского пола, происходящих от одного общего родоначальника. Один родоначальник – родство называется кровным. ТКР ядро системы родства, как центр, тесно связано с сохранением норм и семейных традиций общества. Оно является прямым родством: дочь – мать, бабушка – внучка, правнучка – прабабушка и т.д.

Большая этническая территория при небольшой численности населения привела к тому, что единого туркменского языка не существует. «То, что мы называем туркменским языком, представляет собой совокупность диалектов и говоров, объединенных общей структурной моделью языка, звуковые элементы которой составляют ряды закономерных соответствий» [2: 43]. Но именно диалекты являются основным источником для изучения истории языка. Туркменский язык состоит из множества различных диалектов. В основном, они могут быть разделены на две группы. К первой можно отнести все наиболее значимые диалекты, а именно: йомудский, текинский, гокленский, салырский и эрсаринский. Во вторую группу вошёл целый ряд мелких диалектов, территориально расположенных вдоль границ с Ираном и Узбекистаном (диалекты нохурли, анаули, хасарли, нерезим и другие) [3: 35].

В нашей статье исследуются термины кровного родства по туркменским диалектам и говорам, которые имели разные значения в разных диалектах и говорах туркменского языка.

Термин *ata* имеется в большинстве современных тюркских языках. В туркменском он выступает в фонетическом варианте *ata*, совпадающем с вариантом этого слова, зафиксированным в древних памятниках. Так, в туркменском языке *ata* употребляется главным образом в выражениях «atalar sözü» ‘пословица’ (досл. ‘слова предков’), «ata ýurdu» ‘родной очаг’ и т. п., а в значении термина родства выступает слово *baba*. В туркменском языке *ata* может обозначать и отца, и деда по отцу, а *baba* – только деда со стороны матери. Для туркменского разговорного языка характерен термин *kaka* («папа»). Нужно отметить, что парное словосочетание «ата-баба» имеется во всех тюркских языках.

Слово *ana* в различных фонетических вариантах имеется почти во всех современных тюркских языках. Имеются и другие

фонетические разновидности этого слова, характерные для отдельных тюркских языков: тат. *әни*, кирг. *эне* ‘мама’, а в туркменском языке *ene* ‘мать’, ‘бабушка со стороны отца’, бабушка со стороны матери обозначается термином *мама*.

Термин «огул» имеется во всех современных тюркских языках. В языках огузской группы слово «ogul» с фонетической стороны близко подходит к его варианту отмеченному в древних памятниках «оүııл» (в турк. ogul). Слово «огул» имеет употребляющееся во многих тюркских языках образование *oglan* ‘мальчик’, ‘юноша’, ‘парень’.

Термин «кыз», так же и «огул», является общетюркским. В туркменском языке озвончается начальный «к»: *gyz;* в туркм., кроме того, гласный [ы] звучит долго: «гыйз». Слово *gyz* как термин кровного родства имеет значение ‘дочь’.

В туркменском языке для обозначения младшего сына или младшей дочери перед терминами ставится в качестве определения слово *kiçi*, а для обозначения старшего сына или старшей дочери перед терминами ставится слово *uly.*

Термином *agtyk* у туркмен называются внуки и внучки. Для обозначения внука перед термином ставится слово огул *ogul agtyk,* а для обозначения внучки перед термином ставится слово *gyz agtyk.*

Деление на отцовскую и материнскую линии проводится в группе слов, обозначающих двоюродных братьев и сестер. Так, для двоюродных братьев и сестер по линии отца употребляется, в основном, термин *doganoglan*, по линии матери – термин *çyqan.*

Поскольку в туркменском языке дифференциация на родство по отцовской и материнской линии проводится не по всем терминам и не во всех диалектах и говорах, мы решили нужным показать это разделение лишь там, где оно происходит. Например, в литературном языке и во всех диалектах, говорах понятия «тётя» и «дядя» строго разграничиваются по отцовской и по материнской линии, а понятия «дедушка» и «бабушка» не во всех диалектах и говорах дифференцируются по принадлежности к отцовскому и материнскому родам. Например, дядя по отцовской линии – *aga, kaka, akga, dede;* дядя по материнской линии – *daýy*; тётя по отцовской линии – *eje, ejeke, eke;* тётя по материнской линии – *daýza, hala, apa*; дедушка по отцовской линии – *ata* (лит.яз), а дедушка по материнской линии – *bava;* дедушка по отцовской и материнской линиям – *bava, buvy* (диалекты эрсары, салыр, сарык).

Также в терминах родства по отцовской линии строго проводится дифференциация по старшинству лет. Так, для «дяди», «тёти», «брата», «сестры» старше говорящего существуют одни

термины, а для «дяди», «тёти», «брата», «сестры» моложе говорящего имеются другие термины. Обратимся к примерам: дядя и брат старше говорящего – *aga* (лит.яз.); *eke, akga, dede;* дядя и брат моложе говорящего – *ini* (лит.яз.); *kiçi gardaş, uke*; тётя и сестра старше говорящего – *eje, ejeke, eke, tota, ekeji, eme*; тётя и сестра моложе говорящего – *uyo* (лит.яз), *bally, jojy.*

Термином *daýy* обозначаются братья матери, сыновья братьев матери, все мужчины со стороны матери старше и моложе говорящего, а термином *daýza (hala)* обозначаются все сёстры матери. В свою очередь говорящий, его братья и сестры по отношению ко всем родственникам и родственницам по материнской линии являются младшим поколением и называются термином *ýegen* независимо от возраста.

Таким образом, в результате рассмотрения основных терминов кровного родства в туркменском языке, наши исследования следует делать следующие выводы:

1) Большинство выделенных нами терминов кровного родства распространено во всех современных тюркских языках и, следовательно, может быть отнесено к общетюркскому словарному фонду;

2) Важнейшие термины кровного родства (ana, ata, ogul, gyz) обнаруживают большую устойчивость в тюркских языках и, безусловно, входят в основной словарной фонд этих языков;

3) По своему происхождению рассмотренные нами термины являются в основном тюркскими или тюрко-монгольскими.

**Литература**

1. Кузнецов С.А. Большой словарь русского языка. – СПб.: Норинт, 2000. – 550 с.
2. Кулиев А. Термины родства в туркменском языке: автореферат дисс. на соискание ученой степени канд. филол. наук / АН Туркм. ССР. Отд-ние обществ. наук. - Ашхабад, 1967. – 15 с.
3. Баскаков Н.А. К истории изучения туркменского языка. – Ашхабад: Туркменистан, 1965. – 35 с.
4. Туркменско-русский словарь = Түркменче-русча сөзлүк / Составители: Баскаков Н.А., Каррыев Б.А., Хамзаев М.Я. – М.: Советская Энциклопедия, 1968. – 832 с.
5. Этимологический словарь тюркских языков. – М.: Наука, 1974. – 767 с.

## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНДӘ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮ АЛЫМНАРЫ

*Зөфәрова Г., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нәбиуллина Г.Ә.*

Хәзерге төрек һәм татар телләрендә кулланылучы мөрәҗәгать итү системасы бу халыклардагы җәмгыять тормышының социаль әһәмиятле аспектлары өлкәсендәге күпкырлы үзгәрешләргә дучар булганнан соң гына кулланылышка керә. Татарларда XIX гасырның

икенче яртысында буржуаз мөнәсәбәтләрнең тамыр җәю билгеле. Бу чорда рус һәм Европа телләре йогынтысында татар теле этикеты да зур үзгәрешләргә дучар була. Ә Төркиядә дәүләт строендагы соңгы үзгәрешләр 1922 нче елга барып тоташа. Бу вакыйга телгә дә тәэсир итми калмый. Ягъни, әлеге күренеш гарәп-фарсы алынмалары белән баетылган иске госманлы теленнән баш тарту, аларны төрек сүзләре белән алмаштыру һәм гарәп графикасыннан латин графикасына күчү омтылышы буларак чагылыш таба.

Күп кенә халыкларда киң таралыш тапкан мөрәҗәгать итү чараларының берсе – *кешенең шәхси исемен кушып дәшү*. Бу алым татарларда да, төрекләрдә дә еш кулланыла. Р.С. Абдуллина фикеренчә, XX гасыр башы татар этикетына, шул исәптән, мөрәҗәгать итү формаларына тагын да зуррак үзгәрешләр алып килә. Галимә әлеге чорга «иптәшләнү» чоры дигән исем бирә. Чөнки олылап дәшү сүзләрен «иптәш» сүзе алыштыра. Шәһәрдә яшәүче кайбер татар гаиләләрендә абый-апаларына исемнәре белән генә эндәшәләр. Ир-хатын бер-берсенә исемнәре белән эндәшү дә таралыш алды [1: 36]. Төрек телендәге кеше исемнәре белән эш иткәндә, беренче чиратта, аларның күләме күзгә ташланырга тиеш. Якынча исәпләүләр буенча, хәзерге вакытта төрек телендә 1800 дән артык кеше исеме бар дип исәпләнелә һәм әлеге сан даими рәвештә арта тора. Төрекләрнең бер яки ике (сирәк кенә өч) шәхси исеме булырга мөмкин. Шуларның берсе *göbek ism-i* (кендек исеме) дип атала, ягъни әлеге исем кешенең кендеген кискәндә кушыла. Әлеге күренеш тамырлары белән шаманизм чорына барып тоташа һәм аның башка халыкларда да күзәтелүе билгеле. 1934 елга кадәр төрекләрдә фамилияләр кулланылмый һәм бу гаиләдәге барлык ир балага да туу белән *göbek ism-i* (кендек исеме) беркетелүгә китерә.

Татар телендә эндәш сүзләргә тартым категориясенең ялгануы үзенчәлекле стилистик төсмер бирә. Татарлар якын кешеләренә мөрәҗәгать иткәндә, ягымлылыгы һәм эмоциональлеге белән аерылып торган сүзләр куллана: «*матурым*», «*акыллым*», «*җаным*» һ.б. (Сөйләмгә ягымлылык төсмере өстәү максатыннан, туганлык атамаларына I зат тартым кушымчалары да өстәлә ала: «*әбием*», «*сеңлем*» һ.б.) Төрек телендә назлап, яратып эндәшү формасы шәхси исемнәргә -cik кечерәйтү кушымчасы һәм I зат тартым кушымчасы ялгану нәтиҗәсендә барлыкка килә. Кайбер очракларда экстралингвистик факторлар йогынтысында кыскартылган шәхси исемнәр вульгар характерга да ия була: *İbo – İbrahim.* Гомумән алганда, төрекләрдә мөрәҗәгать итү формасының әлеге төре сирәк кулланыла.

Татарларда гаиләэчендә һәм туганнарга мөрәҗәгать итү формаларына тукталыйк.

Татар телендә: «Кызым» – сөйләүчедән яше буенча кечкерәк хатын-кызга яки кыз балага һәм кыз җенесеннән булган үз балаңа мөрәҗәгать итү алымы. Төрек телендә: «*kız-ım*» *(кызым*) – сөйләүчедән яше буенча кечерәк булган хатын-кызга мөрәҗәгать иткәндә кулланыла.

Шулай ук, аермалы якны та әйтмичә калырга ярамый, мәсәлән, татар телендә: «*Апа*» – сөйләүчедән яше буенча олырак булган хатын-кызларга карата кулланыла; ә төрек телендә исә: «*abla*» *(апа*) – кагыйдә буларак, сөйләүчедән берничә яшькә олырак хатын-кызларга карата кулланыла, «*teyze*» *(*апа*)* сөйләүченең әнисе белән бер яшьтә булган хатын-кызларга мөрәҗәгать иткәндә кулланыла. Татар телендә туганнарга мөрәҗәгать итүнең диалекталь үзенчәлекле ягын да әйтмичә мөмкин түгел. Мәсәлән кайбер диалектларда түбәндәге мөрәҗәгать итү формалары да кулланыла: «*алма апа*», «*шикәр апа*», «*чәчәк апа*» һ.б. Элегрәк әлеге сүзләр диалектларда гына булмыйча, гомуми кулланылышта да йөргән.

Төрек телендә әңгәмәдәшеңә карата *bay, bey, beyefendi һәм bayan, hanım, hanım efendi* сүзләрен кулланган очракта гына, аңа «*Сез*» дип дәшәргә мөмкин. Beyefendi һәм hanımefendi лексемалары мөрәҗәгать итүнең искергән формалары булып санала. Алар элек халыкның белемле һәм интеллегенция катламына карата кулланылган. Хатын-кызларга карата кулланылучы bayan «ханым» мөрәҗәгать итү формасы XX гасыр башындагы тел революциясе нәтиҗәсендә bay «әфәнде» сүзеннән килеп чыга. Алар мөрәҗәгать итүнең иң рәсми формалары һәм рәсми тел элементлары булып тора. Әлеге лексемалар кеше исемнәре яки исем һәм фамилияләр белән дә яраклаша *(Bay Demirel, Bay Süleyman Demirel)*. Татар телендә исә, элегрәк кулланылышта йөргән түбәндәге мөрәҗәгать итү формалары да кулланылышка кайтты: «*Алия ханым*», «*Фәрит әфәнде*», «*Зәйнәп туташ*» һ.б.

Мөрәҗәгать итү алымнары мәдәни-специфик характерга ия һәм алар әңгәмәдә катнашучылар турында шактый мәгълүмат бирергә сәләтле. Аерым бер телдә иң нейтраль мөрәҗәгать итү чаралары да башка телләргә зур кыенлык белән тәрҗемә ителә, ә әдәби тәрҗемәләрдә транслитерация алымы кулланыла. Мөрәҗәгать итү формасындагы үзгәрешләр иҗтимагый мөнәсәбәтләрдәге үзгәрешләрне дә чагылдыра. Ә иҗтимагый стройны алыштырган очракта, мөрәҗәгатьләр еш кына хакимият тарафыннан төзәтүләргә дучар ителә: «Тел үзгәрешенә китреүче революция һәм башка шундый сәбәпләр аркасында хакимият алышынганда, беренче чиратта, мөрәҗәгать итү алымнары үзгәрә».

**Әдәбият**

1. Абдуллина Р.С. Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. – Яр Чаллы: КАМАЗ, 1997. – 128 б.

2. Исхакова Х.Ф. Личные имена тюрков // Проблемы прикладной лингвистики. – М.: Азбуковник, 2001. – 27–42с.

3. Рылов Ю.А. Аспекты языковой картины мира: итальянский и русский языки. М.: Гнозис, 2007. – 304 с.

# ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНДӘ БӘЯ БИРҮНЕ БЕЛДЕРГӘН ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР

*Исламгәрәева И., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Денмөхәммәтова Э. Н.*

Фразеология үзенең мәгънәсе, төзелеше һәм функциональ үзенчәлекләре ягыннан аерым сүзләрдән һәм гади сүз тезмәләреннән аерылып тора. Фразеология – ул, асылда, бербөтен мәгънә белдерүче, чынбарлыктагы күренешләрне тәэсирле, сурәтле һәм сәнгатьле итеп чагылдыручы, семантик һәм синтаксик яктан тармаклый торган тотрыклы сүз тезмәсе [2: 4].

Татар һәм төрек халыклары – кардәш халыклар. Безнең тарихыбыз, менталитетыбыз, дөньяга карашыбыз, телләребез охшаш. Халык авыз иҗаты үрнәкләре булган фразеологизмнарыбызның да уртак үзенчәлекләре күзәтелә. Аеруча бу бәя бирү фразеологизмнарында яхшы күренә. Мәсәлән:

Татар һәм төрек телләрендә бәя бирүче фразеологизнар “Кеше” макрогруппасына карый. Бу төркем ике телнең дә фразеологик фондында күпчелекне тәшкил итә. Бу аңлашыла да, чөнки фразеологизмнар кешенең эш-гамәлләре, теге яки бу сыйфатларына бәя бирү максатыннан кулланыла. Бәя бирүче фразеологизмнар турыдан-туры характер төшенчәсе белән тыгыз рәвештә бәйле.

Тикшеренүебездә безнең фикеребезчә иң төгәл һәм тулы итеп характер төшенчәсенә аңлатма биргән Т. В. Звереваның билгеләмәсенә таянабыз. Галимә характерны “динамик һәм эчтәлекле якларның бердәмлеге” дип атый һәм аны ике яклы структура булуын ассызыклый. Динамик төшенчәсе астында шәхеснең эш-гамәлләре, ә эчтәлек астында – кешенең шәхси мотивлары аңлана [2: 16].

Барлык телләрдә дә, шул исәптән татар һәм төрек телләрендә дә бәя бирү фразеологизмнарының түбәндәге төркемнәрен аерып карарга мөмкин: 1) кеше характерының тискәре якларын чагылдыра торган фразеологик берәмлекләр; 2) кеше характерының уңай билгеләрен чагылдыра торган фразеологик берәмлекләр; 3) кеше характерының нейтраль бәяләмәсен алучы фразеологик берәмлекләр.

Ике телдә дә кеше характерының тискәре якларын чагылдыра торган түбәндәге база компонентлары булган фразеологизмнардан мисаллар китерик:

1. Күп сөйләшү, мактану, мәсәлән:

– озын телле / uzun dil (күп сөйләшүче, алдан кычкырып йөрүче кеше турында) [3: 1];

– теле сөяксез / Dilin kemiği yok (күп сөйләшүче кеше турында) [3: 488]. Әлеге берәмлекләр кергән фразеологизмнар:

– Һавага сөйли / Havaya söylemek (буш сүз сөйләп йөрүче кеше турында)

– Bütün kirli çamaşırlarını ortaya dökmek; kol kırılır yen içinde kalır anlayışı (бер кеше гаиләсендәге хәлләрне сөйләп йөрү, кешенең серен чишү).

2. Үзен башкалардан өстен кую, мәсәлән:

– олы кылану / kibirli (гади кешенең башкалардан өстен булырга тырышуы, барлык эш-гамәлләре белән шуны күрсәтү) [3: 1].

- эре бәрәңге ашаган (үзен бүтәннәрдән югарырак санаганга күрә башкалар белән сөйләшмәү, исәнләшмәү).

Gökte Allah, yerde ben – (үзен Алла белән тиң санаучы кеше турында).

3. Икейөзлелек, мәсәлән:

– фәрештә булып кылану (үзенең начар гадәтләрен качыручы кеше турында) [3: 1];

– бәрән тиресен каплаган бүре сыман (мәрхәмәтле булып кыланып, үзенең мәкерле эш-гамәлләрен яшерүче кеше турында) [3: 1]; on parmağında on kara (нахак яла ягу, башкалар турында начар сүзләр сөйләүче кеше), kara sürmek (кемне дә булса начар итеп күрсәтергә тырышу, аның турында нахак сүз сөйләү)

4. Саранлык, мәсәлән:

– туймас тамак / duygu ağız (саран, мәкерле кеше турында) [3: 1].

Кеше характерын һәм аның әхлакый сыйфатларын уңай бәяләүче семантик төркемгә караган фразеологизмнардан мисаллар карап узыйк:

1. Намуслылык, игелеклелек, ачык йөзлелек, мәсәлән:

– киң күңелле / Güler yüzlü (ярдәмчел, рәхимле, сизгер кеше) [3: 1];

– алтын йөрәкле / altın taşıyan (мәрхәмәтле, сизгер кеше турында) [3: 1].

2. Нык характерлы, максатчан, мәсәлән:

– үз сүзендә тору / İstediğini yapmak; bildiğini okumak ( ныклы холкы белән аерылып торучы һәм башкаларның сүзенә бирелмәгән кеше турында) [3: 1];

- билен бөгә / Belini bükmek (максатчан рәвештә тырышып эшләү).

Төп компонентлары арасында кеше характерын һәм аның әхлакый сыйфатларын нейтраль бәяләү семантик төркеменә караган татар һәм төрек фразеологизмнарының түбәндәге мисалларын китерик. Бу төркемгә караган фразеологик берәмлекләрнең мәгънәсендә ачык чагылыш тапкан хуплау яки хөкем итү юк, әмма шул ук вакытта аларда кеше холкының уңай һәм тискәре характеристикалары да бар: *татлы телле/ Söz kabiliyeti; konuşma yeteneği; хисап тоту, аек күзаллау / (Bir şeyi) idrak etmek; kendine hesap vermek* [3: 1].

Шулай итеп, татар һәм төрек телләрендә кешегә бәя бирүче фразеологизмнарны чагыштырма планда анализлаганнан соң, ике телдә дә аларың охшаш төрләре күп дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Татар һәм төрек телләрендәге бу төр фразеологизмнар арасында тискәре, уңай һәм нейтраль бәяләү компонентлары булган төркемнәр аерылып тора. Ике телдә дә бу еш кына бу фразеологизмнар синонимнар булып тора.

**Әдәбият**

1. Türk Dil Kurumu. Türkçe Sözlük, Türk Dil Kurumu Yayınları.1988 – Ankara.
2. Зверева Т.Р. Эмоции и характер во фразеологической картине мира русского языка : автореф. дис... канд. филол. наук / Т. Р. Зверева. – М., 2002. – 30 с.
3. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1989. – 571 б.

## УЙГЫР ТЕЛЕНДӘ РИЗЫК АТАМАЛАРЫ
### (бәйрәм табыны ашлары мисалында)

*Каһарман Ө., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*

Халык бәйрәмнәре – шул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була. Алар халыкның милли горурлык, милли хисләр культурасын тәрбияләргә ярдәм итеп кенә калмыйлар, теге яки бу халыкның ерак тарихына күз салырга, гореф-гадәтләрен, йолаларын, рухи ышануларын өйрәнергә дә ярдәм итә. Һәрбер халыкта, бигрәк тә төрки халыкларда, бәйрәм итү, һичшиксез, табын җыю, азык-төлек пешерү, кунак итү һәм кунак булуны күздә тота.

Уйгыр халкының искиткеч күңелле бәйрәмнәре, бай гореф-гадәтләре һәм йолалары бар. Уйгырларда дини һәм йола бәйрәмнәре күп. Еллар үткән саен бу бәйрәмнәр яңара, аларның формалары үзгәрә һәм эчтәлекләре тулылана бара. Һәрбер бәйрәм үткәрелеше, тышкы ягы һәм мәгънәсе белән генә түгел, табыны белән дә үзенчәлекле.

Уйгыр халкы үзенең озын һәм бай тарихында төрле мәдәниятләр, диннәр, халыклар белән кисешә, багланышларга керә һәм башка мәдәниятләргә хас булган иң яхшы сыйфатларны үзенә туплый. Бу төрле тел күренешләренә генә түгел, милли бәйрәмнәргә, гореф-гадәтләргә һ.б. да кагыла. Бу үзенчәлекләр уйгырларның ашау-эчү культурасын башкалардан аерып тора торган күренешләрнең берсен тәшкил итә.

Дини һәм милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр үзенчәлекле ризыклар белән, билгеле бер кануннар, кагыйдәләр буенча үткәрелә. Уйгырларның бәйрәмнәрдә, гает, туйлар, ашларда куела торган ризыклары аеруча милли төскә ия. Шуның өчен бәйрәмнәрдә табын бизәге булган ашамлыкларга соңгы елларда этнография, культурология фәннәре кысаларында игътибар ителә.

***Нәүрүз (Нуруз)*** – уйгырларда электән килгән яңа ел бәйрәме. Нәүрүз һәр елның 21 мартында билгеләп үтелә. Бу вакытта карлар эри, дөнья яшәрә, яшелләнә, гаиләләр, мәхәлләләр җыелышып, бергәләшеп бәйрәм итәләр. Җырлап-биеп, шигырь сөйләп, яхшы теләкләр теләп, Нәүрүз табыны янында үзара кәеф-сафа кору – болар электән килгән гадәтләрнең берсе. Олылар, картлар балаларга һәр елны “Нәүрүз бәйрәмендә зур, бай табын җәеп, күп итеп ашарга пешереп, яңа, иң яхшы киемнәрне киеп, якыннар һәм туганнарны капкадан шатланып каршы алыгыз, бу көнне кунаклар күбрәк булган саен, өегездә бәрәкәт, илдә муллык булыр, һәр шатлык белән башланган эш яхшы тәмамланыр, бәрәкәт китерер,” – дип сөйләргә, нәсихәт әйтергә онытмый.

Бу көнне традицион *Нәүрүз ийше* – нәүрүз ашы пешерелә. Бу ашамлык бодай, кукуруз, дөге, борчак, арпа (маш), ногыт кушып, ягъни җирдә үскән җиде төр ашлыкны җыеп пешерелә. Җиде төр ашлык бер казанда кайнатылу, халыкның да бер казанда кайнап берләшеп, бергәләшеп, бер-берсенә ярдәм итеп, утка да, суга да кереп яшәвен символлаштыра.

Иске календарь буенча ***Гашура ае***нда мул булган ашлыктан, дини кагыйдәләр буенча, кукуруз ярмасыннан *как* яки *гөл кагы* (гөлчәчәк яфракларын изеп, бераз шикәр өстәп кайнатып, бал кушып ясала, сыек желе, яки варенье кебек була) өстәп ботка пешерәләр, һәм шушы гамәлләр белән өлкән ата-бабалар хәтере өчен дога кылалар, коймаклар пешерәләр.

***Мәүлүд ае***нда шулай ук *пылау, коймак* һәм башка милли ризыклар пешереп, ата-бабалар рухына һәм киләчәк буыннарга яхшылык, бәрәкәт теләп догалар кылына.

***Рамазан ае***нда ураза тотканда иртәнге аш һәм ифтар вакытлары өчен иң тәмле ризыкларны пешереп, уразага керәләр һәм авыз ачалар.

Ураза гаете көнне иртән һәрбер гаилә иң яраткан ризыкларны пешереп, уразаны озата. Ураза гаете өчен *сыңза, пичинә (печенье), перәннек, коймак, самбуза,* төрле тәм-томнар, җиләк-җимешләр, чикләвекләр хәзерләнә.

Кешеләр бер-берсенә кунакка кереп, табын хәзерләп, теләкләр теләп үткәрә торган гадәт бар. Рамазан аен һәр гаилә, корбан чалмаса да, үз хәленә карап, сый-нигъмәтләр белән каршылый.

***Корбан гаете***ндә хәле булган бөтен кеше корбан чала, бу көндә беренче булып корбан ителгән бәрәннең бавыры, соңыннан ите ашала. Корбан чалган өйләрнең һәрберсендә *үпкә-исеп* (үпкә-исеп – үпкәгә сөт салынып пешерелә; исеп – бәрән эчәкләренә кыздырылып суган һәм дөге салып ясала) пешерәләр. Корбан чала алмаган кешеләргә, чарасы, малы булмаганнарга һәр бәрән суйган гаилә корбан ите бирә. Шуңа күрә корбан бәйрәмендә бер гаилә дә итсез калмый.

Уйгырларда ***өйләнү, кияүгә чыгу туйлары***н бик зурлап үткәрәләр. Бер мәхәлләдә, урамда туй булса, шул урамда торучылар, үзенең кулыннан килгәнчә, туй үткәргән гаиләгә булыша. Туй көнендә *туй пылавы, курдак* (бәрән ите, бәрәңге һәм кишер белән пешерелә) һәм башка ризыклар әзерләнә. Туйга килгән һәрбер кунак хөрмәт белән каршы алына, туй сыйлары тәкъдим ителә.

***Балага исем кую бәйрәме***ндә (исем туе, ат туе), баланың гомере озын булсын өчен, лагман һәм башка ризыклар пешерелсә, кырык туенда (бала туганнан соң кырык көн узгач) бала өчен кечкенә *токач* пешерелә, мәхәлләдәге балаларга, бала саулыгы өчен дога кылып, яхшы теләк теләүчеләргә таратыла.

***Сөннәт туе***нда күп кунак чакырып, бәрән, сыер суеп, *аш, пылау* пешерелә, аннан кала йомырка ашау гадәте дә бар.

***Кыз-егет туйлары***нда иң төп ризык – *пылау*, аны зур тимер тәлинкәгә салып, өч-дүрт кеше бергә ашый. Туй табыны һәртөрле сый-нигъмәтләр белән тутырыла.

Уйгур туйларында ирләр хатын-кызлардан аерым ашыйлар. Туй көнне башта иртәнге якта ирләр килеп ашый, бәйрәм итә, соңрак хатын-кызлар өчен табын хәзерләнә. Хатын-кызлар өчен хәзерләнгән табын муллыгы белән аерылып тора. Бу хатын-кызларның ашамлыкларны соңыннан алып китүенә бәйле.

Моннан кала, кеше вафатыннан соң ***нәзер чирак*** уздырыла. Үлгән кешене өчен дога кылган һәм килгән кешеләрне сыйлыйлар, шулай итеп вафат булган кешеләрне фани дөньяга озаталар.

Шул рәвешчә, һәрбер халыкның гадәтләре, традицияләре йөзләрчә еллар сакланырга сәләтле. Аларны өйрәнү, барлау бүгенге

глобализация шартларында туклану системасын яңадан карарга этәргеч бирер дип уйлыйбыз.

**Әдәбият**

1. Рахман А. Уйгурларның гореф-гадәтләре. – Урумчи: Урумчи Чинҗан яшләр нәшрияты, 2008. – 266 б.
2. Садек Б. Уйгурларның яңа таамлары. – Урумчи: Чинҗан фән-тыхныка сәхия нәшрияты, 2001. – 214 б.
3. Торсунтухти А. Уйгурларның гореф-гадәтләре. – Урумчи: Урумчи халык нәшрияты, 2013. – 208 б.
4. Хасият И. Уйгур таамлар камуси. – Урумчи: Урумчи Чинҗан халык сәхия нәшрияты, 2007. – 763 б.
5. Хошур Я. Уйгурлар. – Урумчи: Урумчи милләтләр нәшрияты, 1997. – 309 б.

## “ШАЯН ТВ” ТЕЛЕКАНАЛЫНДА ТӘРҖЕМӘНЕҢ РОЛЕ

*Кдрасова Л., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*

“ШАЯН ТВ” – беренче һәм бердәнбер татар балалар телеканалы. Аның төп максаты – татар телен популярлаштыру; мультфильмнар, фәнни-популяр фильмнар, фикерләүне үстерергә ярдәм итүче тапшырулар аша балаларда татар телен өйрәнүгә кызыксындыру.

Телеканалда балалар өчен күп тапшырулар эшләнә. Мәсәлән, “Шаян балалар”, “Кичке әкиятләр”, “Шома бас”, “Уймак” һ.б. Шулай ук Шаян ТВ балаларга төрле мультфильмнарны тәкъдим итә. Алар еш кына рус яисә инглиз теленнән тәрҗемә ителәләр. Мәсәлән, “Лео белән Тиг” (“Лео и Тиг”), “Тылсымчы Псэмми” (“Псэмми. Пять детей и волшебство”), “Акыллы машиналар” (“Умные машинки”) һ.б.

Әлеге мульфильм һәм мультсериалларның аудиториясе 12 яшькә кадәрге балалар, шунлыктан тәрҗемә тулы, аңлаешлы булырга тиеш. Тәрҗемәдә еш кына дубляж һәм липсниг кулланылган.

Липсниг сүзенә онлайн-сүзлекләрдә мондый аңлатма бирелә: а) персонаж өчен сөйләүче актерның артикуляциясен мультипликацион персонажга күчерү; авыз анимациясе; ә) тавыш һәм визуаль рәтләрнең синхрон булуы: дубляжның гади ысулы, биредә фразаның башы һәм ахыры гына туры килә [3].

Дубляж һәм липснигтан тыш кадр арты тәрҗемәсе, ә кайвакыт язулар, субтитралар да очрый. Мәсәлән, “Дино төркеме” субтитрлар белән бирелә.

Тәрҗемәнең “балалар өчен” булу факты ике капма-каршы фикернең тууына сәбәп була. Бер яктан, тәрҗемә югары сыйфатлы һәм тулы булырга тиеш, чөнки бу шарт үтәлмәсә, балаларга мәгълүматны кабул итү кыенлаша, шулай ук персонажлар сөйләмендәге хаталарны

алар үз сөйләмендә кабатларга мөмкин. Икенче яктан, балаларга персонажның ни сөйләве бөтенләй мөһим түгел, аларга экранда эш-гамәлләрне, хәрәкәтләрне күзәтү кызыграк, димәк, тәрҗемәгә игътибар бирелми һәм теләсә ничек тәрҗемә итәргә була [2: 201-203].

Тәрҗемәне кеше башкара, шунлыктан ул төрле факторларны күздә тотып, үзенә кирәкле тәрҗемә төрен сайлап ала. Мультфильмнарны күз уңында тотканда, тәрҗемәче кинотекст белән эш итә. Кинотекст –коллектив сәнгать әсәре, ул үзенә лингвистик (язмача, телдән) һәм лингвистик булмаган (тавышлы – музыка, авазлар һәм визуаль – образлар, табигать) компонентлардан тора [1: 6]. Боларны күз уңында тоткан хәлдә, тәрҗемәче әсәрнең бөтен үзенчәлекләрен исәпкә алырга тиеш.

Кайбер татарча мультфильмнарны күрсәтү алдыннан шундый белдерү бирелә:

“Мультипликацион фильм “2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү” дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында сатып алынды”. Димәк, тәрҗемә итүнең максаты – татар телен үстерү, саклау һәм өйрәнү. Мәсәлән, “Фиксиләр” (“Фиксики” мультфильмының тәрҗемәсе) балаларны фиксиләр белән генә таныштырып калмый, ә төрле электр приборларының, җайланмаларның төзелешен саф татар телендә аңлата. Шулай итеп, балалар терминнарның татарчасын отып кала. Мәсәлән, “Теш щеткасы” сериясендә электрлы теш щеткасының төзелеше аңлатыла: *батарейка, кечкенә мотор, кылларны тоташтыручы җайланма.* Тәрҗемәләр балалар күңелендә төрле сүзләрне отып калырга, сөйләмдә кулланырга да ярдәм итәләр.

Еш кына мультипликацион әсәрләрдә җырлар кулланыла. Татарчага да алар тәрҗемә итеп бирелә:

*Бер дә борчылмагыз, дуслар,*
*Ярдәмгә Гулливер килер.*
*Көчтән башка булмас монда*
*Ташны ул гына күчерер* (Арфа җырлый, “Баллы география” мультфильмыннан).

Еш кына балалар җырларны отып калалар һәм кабатлап йөриләр. Димәк, тәрҗемәләрнең сөйләм телен, балаларның хәтерен үстерүдә дә роле зур.

Тәрҗемәләр татар телевидениесендә эшләүчеләр өчен заман куйган күп санлы сорауларга җавап эзләү генә түгел, ә чор рухын чагылдыру юнәлешендә мөһим тәҗрибә мәктәбе дә. Башка халыкларның үрнәкләренә ияреп төшерелгән тапшыру яисә

мультфильмнарның барлыкка килүе дә шул максаттан туган ихтыяҗ. Шулай итеп, татарча мультфильмнар да төшерелгән. Мәсәлән: “Камыр батыр” мультфильмы ШАЯН ТВда еш кына күрсәтелә.

Тәрҗемәнең профессиональ югарылыкка куелуы сайлап алынган әсәрләрнең сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирә. Безнең фикеребезчә, ШАЯН ТВда күрсәтү өчен тирән иҗтимагый эчтәлеккә ия һәм татар җәмгыяте өчен аеруча актуаль булган мультфильмнар тәрҗемә ителә.

Нәтиҗә ясап, шуны билгели алабыз: башка халыкларның телевизион үрнәкләре белән танышу татар телевидениесенә иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрнең асылына төшенергә булыша, алар яктылыгында үз халкының тарихын аңлау, үсү перспективаларын билгеләү өчен җирлек әзерли.

**Әдәбият**


1. Берди М. «Киноперевод: мало что от Бога, много чего от Гоблина» // «Мосты». Журнал для переводчиков. Выпуск 4 (8). «Валент», 2005. – С. 4-6.
2. Иванова Е.Б. Художественный видеофильм как текст и его категории // Языковая личность: проблемы креативной семантики. К 70-летию профессора И.В. Сентенберг: Сб. науч. тр. / ВГПУ. – Волгоград: Перемена, 2000. – С. 200-206.
3. Что такое липсинг // https://khvorostin.com/word-of-the-day/lip-sync/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 05.03.2021).
4. ШАЯН ТВ // URL: https://shayantv.ru/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 05.03.2021).


## МУЛЬТИПЛИКАЦИОН ФИЛЬМНАРДА ОНОМАТОПЛАРНЫҢ РОЛЕ (татар теле мисалында)


*Нәүмәтова Р., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*


Соңгы вакытта чит ил әдәбиятын тәрҗемә итү белән беррәттән, татар кино һәм видео сәнгатендә рус фильмнарын тәрҗемә итү дә популярлашты. Югары сыйфатлы тәрҗемә халыкның мәдәни үсешенең югары дәрәҗәдә булуын да күрсәтә, фильм караганнан соң туган хистойгыларны да арттыра, һәм, әлбәттә, киноиндустрия өлкәсенең үсешенә дә зур йогынты ясый.

Тел белеме баланың шәхесен формалаштырырга ярдәм иткән, фикерләвенә йогынты ясаган текстлар табигатенә аерым игътибар бирә. Хәзерге заманда балалар өчен иң кирәкле жанрларның берсе буларак анимация фильмнары текстларын атарга мөмкин.

Телевидениедә һәм интернет киңлегендә чит ил мультфильмнарының күплеге анимацион фильмнарның яшь тамашачыларның сөйләм үсешенә йогынтысы турында уйлануларга этәрә. Балалар анимацион дискурсында ономатопларның яки аваз ияртемнәренең еш очравы лингвистикада, аерым алганда тәрҗемә

теориясендә һәм практикасында яңа тикшеренү бурычларын куя. Балаларның сөйләм үсешенә турыдан-туры йогынты ясаучы тел элементы буларак, анимацион дискурста аларның функциональ ролен ачыклау зарур.

Дөньякүләм мультипликациянең жанр-стилистик үзенчәлекләренә килгәндә, персонажның тышкы кыяфәтен, аның сөйләм стилен, үз-үзен тоту һәм дөньяга карашын булдырганда шәхси образны эзләү зур әһәмияткә ия. Асылда, мультипликацион персонаж – илнең типик вәкиле, ул халык тарафыннан төзелгән мәдәни мирастан тыш яши алмый. Балалар анимацион фильмы контекстында ономатопия кечкенә тамашачының фикерләвен, дөньяга карашын чагылдыручы персонаж сөйләменең аерылгысыз өлеше булып тора. Шул ук вакытта чит ил мультфильм геройларының татарча сөйләшү сәләте татар телле тамашачы тарафыннан табигый кабул ителергә тиеш. Экраннарда пәйда булыр алдыннан мультфильм катлаулы тәрҗемә процессы һәм дубляж аркылы үтә.

Нәфис текстны тәрҗемә итүнең гомуми проблемаларына багышланган хезмәтләр күп булуга карамастан, лингвистикада балалар анимацион фильм текстлары тәрҗемәсе проблемасы тиешенчә ачыкланмаган.

Балалар өчен язылган текстлар – бишек җырлары, шигырь һәм әкиятләрнең аваз структурасы туган тел серләрен һәм тирәнлекләрен ачу процессында торган бала өчен бик зур әһәмияткә ия. Нәкъ менә шуңа күрә кабатлаулар, рифма, неологизмнар, кош, җәнлек тавышлары куллану – балалар өчен язылган текстларның типик үзенчәлекләре, алар тәрҗемәчедән лингвистик креативлык таләп итәләр [2].

Шуңа бәйле рәвештә ымлыкларның һәм аваз ияртемнәренең аерым ролен билгеләп үтәргә кирәк, алардан башка балалар аудиториясенә адресланган бер генә сәнгать текстын да күз алдына китереп булмый.

Тел белемендә ономатопларның күп кенә аспектлары С.В. Воронина хезмәтләрендә тасвирлана. Ул аваз ияртемнәренең классификациясен, аларның барлыкка килү, сөйләмдәге функцияләре белән бәйле күп кенә мәсьәләләрне тикшерә. С.В. Воронин билгеләгәнчә, ономатоплар – “лингвистик булмаган авазны <…> сөйләм авазларын хәтерләткән сегментлар комбинациясе ярдәмендә шартлы рәвештә яңгырата торган сүзләр” [1: 22]. Ономатоплар фонетик чараларга карый, алар текстка сәнгатьлелек һәм стилистик экспрессивлык өстәү өчен хезмәт итә. Энциклопедик сүзлектә ономатопларга түбәндәге аңлатма бирелә: “Ономатоп – форма һәм мәгънә арасында экстралингвистик элемтәләр урнаштырып, кеше һәм

башка җан ияләре чыгарган авазларга, шулай ук предметлар һәм табигать күренешләренең тавышларына охшатып ясалган сүзләр" [3: 432]. Алар мультфильмнарда образлылыкка ирешү һәм картинаны күз алдына ачыграк китерү өчен кулланылган иң төп чараларның берсе һәм иң әһәмиятлесе.

Ономатопларны дөрес кулланмау яисә дөрес тәрҗемә итмәү мәгънәне төгәл белдермәүгә һәм сүзнең стилистик кыйммәтен төшерүгә китерә.

Татар телендә ономатоплар составын түбәндәге лексик берәмлекләр тәшкил итә: 1. Аваз ияртемнәре; 2. Образ ияртемнәре; 3. Аваз һәм образ ияртемнәреннән ясалган сүзләр.

Кеше тавышына, хайван һәм кош-корт, бөҗәкләр чыгарган авазларга, һәм төрле җансыз предметлар тудырган авазларга охшатып ясалган сүзләр, ягъни аваз ияртемнәре, ономатопларның үзенчәлекле катламын тәшкил итә һәм бу төр ономатоплар һәр телнең үз үзенчәлекләре нигезендә ясала.

Мультипликацион фильмнарда аваз ияртемнәре еш очрый:

*Кукареку – кикерикүк*

*Гав-гав – һау-һау*

*Тик-так – келт-келт* ("Фиксики" – "Фиксиләр").

Ономатопларның икенче зур семантик төркемен образ ияртемнәре тәшкил итә. Образ тасвирлары шулай ук охшату принцибы буенча, ләкин акустик күренешләр өлкәсеннән кешенең хисси реакцияләре (күреп сиземләү, соматик реакция) өлкәсенә күчерелгән охшату принцибы буенча ясалалар. Мәсәлән:

*"Смотри, Дим Димыч, как* ***капает****" – "****Тып-тып*** *тама, кара, Дим Димыч". "Симка,* ***прыг-прыг-прыг*** *сюда, быстро" – "Симка, кил монда тизрәк,* ***хоп-хоп-хоп****". "Дим Димыч,* ***ха-ха-ха****, ну ты даешь" – "Әй, Дим Димыч, ну сине...* ***Хе-хе-хе****"* ("Фиксики" – "Фиксиләр").

Өченче төркем – аваз һәм образ ияртемнәреннән ясалган сүзләр. "Фиксики" мультипликацион фильмын татар теленә тәрҗемә иткәндә аваз ияртемнәреннән ясалган фигыльләр татар халкының дөньяны кабул итү һәм татар теленең фонетик, морфологик үзенчәлекләре нигезендә трансформацияләнгәннәр: "*Теперь электрические звонки* ***звучат*** *по-разному, одни* ***гудят****, другие* ***трезвонят****, третьи вообще* ***свистят****, как птицы*" – "*Хәзер ишек кыңгыраулары электрон. Алар төрлечә* ***яңгырый****: кайсылары* ***зыңгылдый****, икенчеләре* ***гүли****, өченчеләре кош кебек* ***сайрый****"; "Вот откуда берется* ***звон****"* **– "**Менә кайдан ***чыңлау*** барлыкка килә"; "*Фу, Дим Димыч, как у тебя дверь противно* ***скрипит****"* **– "***Фу, Дим Димыч, синең ишегең бик ямьсез* ***шыгырдый****".*

Мультипликацион фильм персонажларының сөйләмендә кулланылган аваз ияртемнәре аларның холкын сурәтләргә ярдәм итә.

Гомумән алганда, татар анимацион дискурсы шартларында ономатопия күренеше лингвистикада чагылыш тапмый. Еш кына бу татарча анимацион кинодиалог текстларының беркатлылыгы һәм примитивлыгы белән аңлатыла.

Шул ук вакытта, аваз ияртемнәренең һәм ымлыкларның анимацион фильм текстларындагы роле шактый зур: алар мөһим экспрессив тел компоненты булып торалар, шулай ук яшь тамашачының сөйләм үсеше картинасын турыдан-туры чагылдыралар. Ономатоплар эмоцияләр, хис-тойгыларны тапшыру, персонаж һәм табигать күренешләрен тасвирлау, җырларда музыкаль кәефне күтәрү, баланың игътибарын мультипликацион фильм эчтәлегендә аеручa әһәмиятле моментларга җәлеп итүдә катнашалар, мультфильм текстын сурәтләү чаралары белән баеталар, образларны җанлы итеп тасвирларга мөмкинлек бирәләр.

**Әдәбият**


1. Воронин С.В. Английские ономатопы: Фоносемантическая классификация – СПб.: Геликон Плюс, 2004. – 328 с.
2. Жанрово-стилевые особенности мировой мультипликации [Электронный ресурс] // URL: http://notes.tarakanov.net/articles4.htm (дата обращения 15.01.2021)
3. Лингвистический энциклопедический словарь / гл. ред. В.Н. Ярцева. – М.: Сов. Энциклопедия, 1990. – 683 с.


## А. ГЫЙЛӘҖЕВНЫҢ “ӨЧ АРШЫН ҖИР” ӘСӘРЕНЕҢ ТӨРЕК ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘСЕ ТУРЫНДА


*Нәбиева Я., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Денмөхәммәтова Э.Н.*


Хәзерге заман мәдәнияте төрле мәдәни дөньяларның ирекле яшәвеннән гыйбарәт. Илләр һәм халыклар арасындагы мәдәни элемтәләрне киңәйтү тенденциясе төрле фәнни өлкәләр (культурологлар, лингвистлар, психологлар, социологлар) белгечләре игътибары үзәгенә мәдәниятара аралашу проблемасын куя. Коммуникациянең нәтиҗәлелеге, беренче чиратта, коммуникантларның гомуми белем фондына бәйле, ул үз эченә төрле дәрәҗәдәге концептуаль структуралар җыелмасын ала: лингвистик, менталь, мәдәни. Мондый белем фондының нигезе булып һәрвакыт милли тел тора, ә тәрҗемә, арадашчылык төре буларак, телара аралашу гына түгел, ә мәдәниятара аралашу чарасы да булып тора: чит тел үзләштергәндә, кеше яңа дөньяны һәм аның мәдәниятен үзләштерә. Мәдәният багланышларының һәр катнашучысы шуны аңлый: тиешле

чит телне белү үз-үзеңне тоту, тарих, психология, аралашу буенча партнерларның мәдәниятен белү таләп итeлә.

XX гасыр урталарына тәрҗемәнең төп кыенлыклары һәм тәрҗемә процессының бөтен характеры әлеге процесста катнашучы телләрнең структураларында һәм яшәеш кагыйдәләрендә аермалыклары белән аңлатыла дигән фактны аңлау ачык төс ала. Барлык детальләрдә дә мәгълүматны тапшыруны тәэмин итүче тәрҗемә төгәллегенә карата таләпләр үсә, тәрҗемә процессының асылын аңлау һәм ачу, аның барышына һәм нәтиҗәләренә йогынты ясый торган лингвистик, психологик, социаль һәм мәдәни факторларны аерып күрсәтә белү мөһим була. Уңышлы тәрҗемә эшчәнлеген тормышка ашыру өчен, бары тик ике тел (оригинал һәм тәрҗемә теле) белү генә җитмәгәнлекне аңлау, иң төрле дисциплиналар ракурсында тәрҗемәне җитди өйрәнү өчен җирлек әзерләгән. Шулай итеп, заманча социомәдәни процесслар мәдәниятара багланышларның үзенчәлекле үзенчәлекләрен тудыра, теоретик тикшеренүләрнең яңа юнәлешләрен бирә, традицион тикшеренү методларын һәм методологик алымнарны яңадан аңлауга китерә.

Төрки телләр арасында тәрҗемә эшчәнлеге булу да, кардәш халыкларның бер-берсен яхшырак аңлау, гореф-гадәтләрен белү, тану мөмкинлеген тудыра. А.Гыйләҗевның “Бер аршын җир” әсәренең төрек теленә тәрҗемәсе шуның уңай мисалы. Бу әсәр Фатих Кутлу тарафыннан тәрҗемә ителеп, Төркиядә дөнья күрә.

Фатих Кутлу 2000 нче елның апрель аенда Аяз Гыйләҗев белән шәхсән күрешү бәхетенә ирешә. Очрашудагы әңгәмә вакытында Ф. Кутлу автордан: «Кайсы әсәрегезнең төрек теленә тәрҗемә ителүен теләр идегез? » – дип сорый. А. Гыйләҗәв, ике дә уйлап тормыйча: «Өч аршын җирне» – дип җавап бирә [2]. Язучы вафат булганнан соң, Ф. Кутлу әлеге теләкне язучының васыяте буларак кабул итеп, повестьны төрек теленә тәрҗемә итә башлый. Әүвәл ул әсәрне, татар телендәге үзенә таныш булмаган сүзләрнең астына сыза-сыза, сүзлекләргә мөрәҗәгать итеп, дүрт тапкыр укып чыгуы хакында яза, тәрҗемә өстендә ике ел буена эшли: «Укый-укый әсәрнең теленә, рухына, кешенең үз эчке дөньясын кулга ала белү сәләтенә хәйран калдым. Әсәрне бер тапкыр гына уку җитми, кабат-кабат сеңдерәсеңдерә уку кирәк. Укыганда, җөмләдәге һәр сүз нечкә итеп үрелгәнен аңладым. Заман үтү белән, әсәрнең искермәячәгенә ышанам».

Әдәбият белгече П. Топер карашынча, «әдәби әсәрне укып кабул итүче фикере – әлеге тәрҗемә уңышлымы, яки юкмы булуы хакында бәхәсләрдә төп аргумент булып тора. Чөнки нәкъ менә укучы фикере (тәнкыйтьче дә әсәрне укучы) үзе тирәсендә тәрҗемәне бәяләү өчен кирәк

булган, теленең вак кына детальләренә кадәр туры килүе хакында барлык критерийларны туплый, чөнки, ахыр чиктә, тел күренешләре сүзлекләрдән түгел, ә замана кулланучыларының “тере” сөйләше аша кабул ителә» [1]. Төрек укучылары тарафыннан «Өч аршын җир» повесте югары бәяләнеп, ул Ч. Айтматовның «И дольше века длится день» («Елдан озын көн») романы белән бер дәрәҗәдә кабул ителә. 2012 елда А. Гыйләҗев әсәренең тәрҗемәсе Аурразия Язучылар берлегенең төрки телләрдән төрекчәгә иң яхшы тәрҗемә әсәре буларак җиңү яулый. Әсәргә язылган дистәләгән бәяләмәләр шул хакта сөйли. Язучы Назмия Данизер укучыларда туган җиргә мәхәббәт, һәр инсанның туган җире һәм ата-анасы каршындагы бурычы турында искә төшерүгә юнәлтелгән геройларның психологик характеристикасын бирүдә авторның осталыгын ассызыклый. Аның фикеренчә, әсәрнең геройлар тормышын тарихи барыш кысаларында ачуга юнәлтелгән фабуласы уңышлы сайланган. Мәкалә авторы әсәрнең киң яңгыраш алу сәбәбен аның вакыйгаларны бәян итү стилендә күрә. Төрек язучысы татар әдибенең интрига тудыру осталыгын да билгеләп үтә: Аяз Гыйләҗев сюжет линиясен үстерүдә ретроспектив алымын файдалана. Н. Данизер тарафыннан әсәр вакыйгаларының тыгыз үрелгән һәм бөтенлекле итеп оештырылуы төгәл күрсәтелә.

Повестька төрек теленә тәрҗемәдә, алда ассызыкланганча, үзенчәлекле исем бирелә. Фатих Кутлу тарафыннан тәкъдим ителгән «Bir avuç toprak» («Бер уч туфрак») атамасы фикримәгънәви һәм милли-мәдәни эчтәлеге белән повестьның оригинал исеменә аваздаш. Төрек телендә «Бер уч туфрак» «газиз ватан туфрагы, кабер, үлем» дигән тирән фәлсәфи мәгънәле фразеологик гыйбарә, идиома булып тора. «Üç arşın yer» («Өч аршын җир») атамасының сүзгәсүз тәрҗемәсе төрек укучысына гади сүзләр тезмәсе буларак кына яңгырый. Әсәрнең оригиналын һәм тәрҗемә вариантын чагыштырма планда өйрәнү Фатих Кутлуның төрек һәм татар телләрен камил белүен күрсәтә.

Ф.Кутлуның оригинал һәм тәрҗемә телләрнең әдәби формаларыннан тыш, халыкның җанлы сөйләм телен, диалектларын, телнең күп нечкәлекләрен нечкә тоемлап эш иткәне аңлашыла. Тәрҗемә теле дөрес, әдәби нормаларга туры килгән, оригиналдагыча җанлы, бай һәм эмоциональ тәэсирле.

**Әдәбият**


1. Топер П. Перевод и литература: творческая личность переводчика // Вопросы литературы. 1998 – №6. С.61-65.

2. Төрек матбугатында “Өч аршын җир” турында басылып чыккан әдәби тәнкыйть мәкаләләре // URL:http://www.sptatar.ru/index.php?option=com_k2&view=item&id=314: (мөрәҗәгать итү вакыты 12.02.2021).

3. Gıylecev A. Bir avaç toprak / Fatih Kutlu перевод с татарского – Sütun Yayınları. Emniyet Mahallesi Huzur Sokak No: 534676 Üsküdar / İSTANBUL

4. Гыйләҗев, Аяз. Сайланма әсәрләр: 5 томда / – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Т. 5. : Пьесалар. – 448 б.

# ТӨРКИ ТЕЛЛӘРДӘ КУШЫМЧАЛАУ ЫСУЛЫ БЕЛӘН ЯСАЛГАН СҮЗЛӘРНЕҢ ЯСАГЫЧ НИГЕЗЕ БУЛАРАК СОМАТИК ЛЕКСИКА

*Фәйзкәбирова Ә., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сәлахова Р.Р.*

Соматизмнар – кеше әгъзалары атамалары. Алар сүзлек составының иң борынгы катламын тәшкил итә. Соматизмнарның зур күпчелеге бөтен төрки телләр өчен уртак. Мәсәлән, баш, күз, кул, арка, айак, беләк, тубык һ.б. Д.Б. Рамазанова үзенең “Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика” хезмәтендә соматизмнарны ике зур төркемгә бүлеп карый: “1) кешенең физик төзелешен, әгъзаларын белдерә торган сүзләр; 2) кешенең эчке дөньясын белдерә торган сүзләр [4].

Татар һәм төрек телләре агглютинатив төрки телләр булганлыктан, соматизмнарның мәгънәләре һәм кулланылыш үзенчәлекләре, ясагыч нигезләре соматизм булып торган сүзләрнең сүз ясалыш төрләре бердәй. Ләкин, шуңа да карамастан, тикшерелгән сүзләрдә аермалыклар да күзәтелде.

Ясагыч нигезләре соматизм булган сүзләрнең кайсы сүз төркемнәренә караулары ягыннан күзәтү шактый уңышлы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Алар арасында мөстәкыйль һәм модаль сүз төркемнәренә керүче сүзләр бар. Мөстәкыйль сүз төркеменнән – исем, фигыль, сыйфат, рәвеш, ә модаль сүз төркеменнән бәйлекләр урын ала. Исемнәргә килгәндә, биредә җыйма(аяк-кул, баш-аяк, авыз-тел һ. б) һәм конкрет(башлык, аркадаш, беләзек, күзлек)  исемнәр кулланыла.

Соматизмнар һәм ясагыч нигезен соматизмнар тәшкил иткән сүзләр бергә бер синонимик ояда күзәтеләләр(синонимнар), шулай ук бер-берсенә капма-каршы мәгънәләрдә киләләр( антонимнар).

Соматизмнарның зур күпчелеге бөтен төрки телләр өчен уртак. Шунлыктан бу сүзләрдән барлыкка килгән берәмлекләрнең сүз ясалыш ысуллары татар һәм төрек телләрендә туры килә дип әйтергә мөмкин.

Татар телендә сүзьясалышның түбәндәге ысулларын билгеләп үтәләр:

1) фонетик ысул; 2) кушымчалау ысулы; 3) сүзләр кушылу; 4) сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе; 5) Сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе; 6) конверсия  (лексик - грамматик ысул); 7) лексик-семантик ысул; 8) аббревиация (кыскартылмалар ясалышы).

Төрек теленең сүз ясалыш системасын Ж.Б.Никифорва ике төркемгә: кушымчалау ысулы белән ясалган сүзләр (исемнәр ясалышы, фигыльләр ясалышы, хәлләр ясалышы) һәм кушымчалау ысулы белән

ясалмаган (фонетик, лексик-семантик, лексик-морфологик, лексик-синтаксик(нигезләр кушылу, атрибутив сүзтезмәләрнең лексикалашуы, ирекле сүзтезмәләрнең лексикалашуы, нигезләр үсү нәтиҗәсендә кушма сүз ясалу) сүзләргә аера.

Төрек телендә соматизмнардан барлыкка килгән сүзләрнең ясалышын күзәтү өчен, “Татарча-төрекчә сүзлек”кә мөрәҗәгать иттек. Биредә татар телендәге соматизмнардан барлыкка килгән сүзләрнең төрек теленә һәрвакытта да тәрҗемә ителмәве, ягъни мәгънәсе генә аңлатылып киткән очраклар да күренде. Алга таба сүз ясалыш үзенчәлекләрен тикшерергә мөмкин булган берәмлекләрне тәкъдим итәбез.

Татар телендә дә, төрек телендә дә сүз ясалыш ысулларыннан кушымчалауга (аффиксация) зур урын бирелә. Соматизмнардан барлыкка килгән берәмлекләрне күзәткәндә дә без моңа игътибар иттек. Татар һәм төрек телләрендә ясагыч нигезләре соматизм булган сүзләргә күз салыйк:

Татар телендә нигез + -сыз/-сез кушымчасы моделе белән ясалган сыйфатлар – телсез, башсыз кебек нисби сыйфатларны очрый. Шулай ук нигез + -лы/-ле кушымчалары моделе тибындагы башлы, кашлы сыйфатлары кулланыла. Нигез + -лык/-лек моделе белән исем ясалу очрагы – башлык. Колакланса – кушымчалау ысулы белән ясалган берәмлек. Кушымчалау ысулы белән ясалган берәмлек. Исем + лан фигыль ясагыч кушымчасы. Мәгънәсе: ясаучы нигез белдергән затка хас эш-хәрәкәтне белдерә. Колаклан + са шарт фигыль кушымчасы (колак + лан + са). Колакчын – кушымчалау ысулы белән барлыкка килгән. Нигез + чын кушымчасы(колак + чын). Мәгънәсе: ясаучы нигез белдергән нәрсә өчен хезмәт итә торган предметны белдерә. Икейөзле – сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчү ысулы (сан + исем +-ле сыйфат ясагыч кушымчасы ярдәмендә) ясалган. Икейөзле – сан + исем +- ле тибы. Мәгънәсе: тыштан яхшы булып күренеп, эчтән яман уйлы булучы һәм начарлык эшләүче, тыштан дус, эчтән дошман.

Төрек телендә кушымчалау ысулы белән ясалган сүзләр, нигездә, исемнән исем, исемнән сыйфат барлыкка килгән очракларны тәшкил итә. Мәсәлән, исемнән кушымчалау ысулы белән барлыкка килгән исемнәр arkadaş (аркадаш) – arka + daş, başlık (башлык) - baş + lık, gözlük (күзлек) - göz + lük сүз ясагыч кушымчасы. Исемнән кушымчалау ысулы белән ясалган сыйфатлар: ayaklı (аяклы), ayaksız, başlı, akıllı (башлы, акыллы) - baş + lı, başsız, akılsız (башсыз, акылсыз) - baş +sız, yürekli, cesur (йөрәкле, кыю) – yürek + li, yüreksiz (йөрәксез), korkak, merhametsiz – yürek + siz, elsiz, kolsuz (кулсыз) – kol + suz.

Шулай итеп, татар һәм төрек телләрендә соматизмнарны һәм алардан ясалган берәмлекләрне күзәтү шактый кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Соматизмнардан ясалган берәмлекләр җансыз предметлар белән бергә кешегә карата да кулланыла. Күп кенә соматизмнарның мәгънәсе предметка күчеше һәм эчке әгъзаларның кешенең психологик халәтен белдерүе күзәтелә. Без караган мәгълүматларга таянып, шуны әйтергә мөмкин: татар һәм төрек телләрендә соматизмнар ясагыч нигез булып торган сүзләр күпчелек очракта кушымчалау ярдәмендә ясала.

**Әдәбият**


1. Гениш Э. Грамматика турецкого языка. Фонетика, морфология, этимология, семантика, синтаксис, орфография, знаки препинания: Т. 3: Служебные слова, послелоги, союзы, частицы, междометия, аффиксы, предложение, правила орфографии, знаки препинания. Изд. Стереотип. – М.: Ленанд, 2019. – 208 с.
2. Зәкиев М.З., Хисамова Ф. М. Татар грамматикасы. – Казан: ТӘҺСИ, 2015. – Т. 1. – 512 б.
3. Иванов С.Н. Курс турецкой грамматики. Часть 1. Грамматические категории имени существительного. Учебное пособие. – Л.: Издательство Ленинградского университета, 1975. – 100 с.
4. Никифорова Ж.Б. Сопоставительно-типологическое исследование словообразовательных систем бурятского и турецкого языков: автореф. дис. канд. филол. наук. – Изд. Калмыцкого университета, 2008. – 23 с.
5. Рамазанова Д.Б. Татар телендә кешегә бәйле лексика. – Казан, 2013. – 364 б.


## СИНОНИМИЧЕСКАЯ ПАРАДИГМА КАК ОБЪЕКТ ФИЛОЛОГИЧЕСКОГО ИССЛЕДОВАНИЯ


*Ферафонтова А., КФУ, магистрант I курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Денмухаметова Э.Н.*


Язык – постоянно изменяющаяся система, изменению подвергается, прежде всего, словарный состав. В нем отражаются новые явления действительности, новые понятия, что находит выражение в синонимии. В научных исследованиях наблюдается высокий интерес к проблеме синонимии и синонимической парадигмы. Вопросы синонимии разрабатывались в трудах Д.Н. Шмелева, В.В. Виноградова, Ю.Д. Апресян, Л.В. Серебрякова, В.Н. Мигирина, В.А. Звегницева; синонимические словари русского языка создавали В.Н. Клюева (1856), З.Е. Александрова (1968), А.П. Евгеньева (1970), Н. Абрамов (1996), К.С. Горабчевич (1996), Ю.Д. Апресян (2000). В тюркском языкознании вопросы синонимии рассмотрены такими учеными как В.Г. Хангильдин (1940), В. Мескутов (1961), Б.Т. Абдуллаев (1961), Ш. Ханбикова (1961), Ф.С. Сафиуллина (1984) и др.

Согласно «Словарю лингвистических терминов» Т.В. Жеребило (2010), синонимическая парадигма – «синонимический ряд, в котором интегральным признаком является адекватность (тождественность),

близость значений синонимов. Дифференциальные признаки синонимов в синонимичной парадигме – различия в звучании (написании) слов, в их значениях и функционально-стилевом употреблении. В синонимической парадигме выделяется доминанта». Основанием для объединения слов в парадигму служит тождество; лингвист Ф. де Соссюр отмечал, что «весь механизм языка зиждется исключительно на тождествах и различиях, причем эти последние являются лишь оборотной стороной первых» [4: 141]. При этом тождество в языке предполагает многообразие лексическое и грамматическое. Тождество выступает интегральным признаком, определяющим различия языковых единиц. Слова в языке образуют синонимический ряд, в котором слова обладают различными семантическими признаками. Синонимы обозначают одно понятие, каждый из них характеризует это понятие только с определенной стороны, но выполняет различные функции в парадигматическом ряду. Слова с самыми объемными и нейтральными значениями составляют доминанту синонимической парадигмы. Доминантой становится стилистически нейтральное слово, обладающее большой лексической сочетаемостью. Доминанта становится единицей сопоставления синонимов.

Синонимическая парадигма основана на том, что слова образуют группы, объединенные на основе их семантических свойств. В парадигме члены ряда взаимосвязаны, расположены последовательно; это особая система, представляющая собой объект филологического исследования. Между членами парадигмы существует семантическая связь, на основе которой осуществляется составление иерархической структуры синонимической парадигмы.

Значения синонимов не являются тождественными, совпадающими, но между синонимами в рамках парадигматического ряда существует семантическая связь. Члены парадигматического ряда обладают совпадающими и различающимися, дифференциальными компонентами. Дифференциальные признаки определяют существующие сходства и различия между членами синонимического ряда. В синонимический ряд могут быть объединены слова с предельно близкими значениями и минимально близкими значениями. Дифференциация синонимов в парадигме может быть осуществлена по семантике (содержание различных по отношению к доминанте сем), стилистическому признаку (содержание различных эмоционально-экспрессивных коннотаций), по отношению к различным стилям речи. Также производится структурное разделение синонимов (однокорневые, разнокорневые).

Синонимическая парадигма как объект изучения предполагает установление взаимосвязи между ее членами, определение семантики синонимов, степени их близости. Проводится анализ дефиниций по толковым и двуязычным словарям, выявляются дифференциальные признаки, позволяющие построить иерархическую структуру синонимической парадигмы.

В научных работах, проведенных отечественными учеными, широко рассматриваются суть и формы синонимических парадигм. Так, в исследовании О.В. Хоменко [5] исследуется моделирование синонимической парадигмы с доминантой «страх». Волкотруб Г.И. анализирует фразеологические антонимико-синонимические парадигмы современного русского языка [1]. В диссертации Казанцевой Е.А. [2] проводится когнитивно-сопоставительное описание синонимических парадигм с доминантами «to frighten» и «пугать». Однако существует необходимость проведения исследования синонимической парадигмы лексических единиц в башкирском и татарском языках, где монографические работы на сегодняшний день отсутствуют.

Таким образом, синонимическая парадигма, представляющая собой особую систему, в которой элементы объединены семантической связью, представляет собой объект научного исследования. Анализу подвергаются дефиниции слов, компоненты значений членов синонимической парадигмы, определяется тип связи между членами ряда.

**Литература**

1. Волкотруб Г.И. Фразеологические антонимико-синонимические парадигмы современного русского языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук: 10.02.01. – Киев, 1991. – 22 с.

2. Казанцева Е.А. Когнитивно-сопоставительное описание синонимических парадигм с доминантами to frighten и пугать: автореф. дис. ... канд. филол. наук: 10.02.20. – Краснодар, 1999. – 19 с.

3. Словарь лингвистических терминов: Изд. 5-е, испр-е и дополн. – *Н*азрань: Пилигрим, 2010. – *568 с.*

4. Соссюр Ф. Курс общей лингвистики. // Избранные труды по языкознанию. – М.: Прогресс, 1977. – 697с.

5. Хоменко О.Е. Моделирование синонимической парадигмы с доминантной "страх": дис. ... канд. филол. наук: 10.02.19. – Ставрополь, 2006. – 184 с.

## ТӨРКИ ТЕЛЛӘРДӘ ЯСАГЫЧ НИГЕЗ БУЛАРАК САННАР

*Хәкимова Л., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сәлахова Р.Р.*

Сан – бик борынгы тел күренеше. Борынгы кабиләләрдә үк ауланган җәнлекләр санын һәм башкаларны санау ихтыяҗы туган. Саннарның дөнья мәдәниятендә универсаль мәгънәлелеге кешенең дөньяга карашы, аны танып белүендә антропоцентризмның зур роль

уйнавы белән билгеләнә. Кеше дөнья, җәмгыятьнең төзелешен, үз-үзен саннарның сакраль көче аркылы танып белергә омтыла.

Борынгы тел күренеше булу сан исемнәренең башка сүз төркемнәре белән шактый тыгыз мөнәсәбәттә торуына алшарт. Чыннан да, саннар төрле сүз төркемнәрен алыштырырга һәм тулысынча аерымланып, башка сүз төркеменә күчеп китәргә дә мөмкин. Барлык төрки телләр өчен уртак лексика тәшкил иткән саннардан әлеге телләрнең үзенә генә хас булган ясагыч чаралар нигезендә ясалган сүзләренә күзәтү ясау, тюркология өлкәсендә кызыклы фәнни нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирер дип уйлыйбыз. Күп кенә ясагыч кушымчаларның төрки телләрдә уртак ясагыч мәгънәгә ия булуы да эшнең актуальлеген арттыра. Мәсәлән, *-лык/-лек* кушымчасы татар телендә *бер+-лек, беренчелек*, каракалпак телендә *бирлик, биришилик.* Темабызга бәйле рәвештә бер санының сүз ясау мөмкинлекләрен карап үтик.

Бер гомумтөрки санының килеп чыгышы турында төрле фикерләр яшәп килә. Р.Г. Әхмәтьянов аны тамыры белән гомумтөрки бир «бер» сүзеннән чыккан дигән фикердә тора. Р.Т. Муратова галимнәрнең башка төрле фикерләре булуын да искәртә. Мәсәлән, Э.Р. Тенишев аны чыгышы белән barmaq – бармак сүзеннән дип саный, Г. Рамстед аны büri монгол алмашлыгы (бөтенесе, һәркем); Э. Эрнитс bir / bär алмашлыгы (менә шушы) белән бәйлелектә тикшерә.

Ике халыкның да бишек җырларында бер саны билгесезлек төсмерен белдереп, билгесезлек алмашлыгы вазифасын башкарырга сәләтле:

*Яшел чапан кияр бу,*
*Ап-ак чалма чалыр бу.*
*«Остабикә кирәк» дип,*
***Бер** бай кызын сорар бу* [2: 15].

Бер саны төрле формаларда кабатланып, исем яки алмашлык сүз төркеменә якын торган субстантив сүзләр (берсесе) дә ясый. Әлеге очрак татар халык бишек җырларында гына күзәтелде:

*Әлли-бәлли бишеге,*
*Кызыма килер йөз кеше.*
*Кияү булыр **берсесе**,*
*Баш астында йокысы* [1: 16].

Бер саны бердәнбер, бер генәм сүз һәм сүзтезмәләрен дә ясаучы нигез булып тора. Бу сүзләрдә бер саны бердәнбер мәгънәсен белдерә:

*Минең йөрәк бәғерем ул,*
*Ғәзизем ул, **бер** генәм.*
*Ҡыуанысым, шатлығым,*
*Бәү-бәү, минең йән генәм* [2: 16].
*Ай ҙа йоҡлай һиңе күрмәй,*

*Йоҡла, балам, йөрәгем,*
*Уйнап ярһып бөттөң инде,*
***Берҙәнберем**, терәгем* [2: 21].

Бер саны еш кына күләм, әйбернең хисабы ягыннан башка саннарга каршы куела. Шунысы кызык, контрастлыкка нигезләнгән татар һәм башкорт халык авыз иҗаты текстларында бер санына йөз саны еш кына каршы куела:

Әлли-бәлли бишеге,
*Кыҙыма килер **йөз** кеше.*
*Кейәү булыр **берсесе,***
*Баш аҫтында йоҡосо* [1: 29].

Шул рәвешле, татар һәм башкорт телләрендә *йөз* саны күп мәгънәсендәге омоним буларак та кулланыла. Әлеге санның ике телдә дә омонимнары шактый: *йөз (*бит), *йө*з (йөзү фигыленең боерык формасы), *йөз* (предметның алгы планы), *йөз* (ризыкның тышкы кыяфәте). Нигез буларак йөз саны ике телдә дә йөзлек сүзен барлыкка китерә. Бу сүз шулай ук омонимлыкка ия: *йөзлек – йөз* сумлык купюра, *йөзлек* – бала туганда йөзлек белән туа диләр (родиться в рубашке), *йөзлек* – маска мәгънәсендә.

Күп кенә төрки телләрдә сүз ясагыч нигез буларак еш кулланыла торган саннарның тагын берсе –җиде (йете) саны. Мәсәлән, татар һәм башкорт халкы фольклорында, бу сан аеруча еш кулланылуы күзәтелә. Мәсәлән: *җиде кат үлчә – бер кат кис / йете ҡат үлсә – бер ҡат кис; җиде йортның телен бел, җиде төрле белем бел – йете йорттоң телен бел, йете төрлө белем бел һ.б.* Ике телдә дә бу саннан түбәндәге сүзләр ясалган: *Җидегән йолдыз, чишмә – Йетегән йондоҙ, шишмә; җиделек/йетелек – борынгы атна атамасы, дүрт җиделек/ дүрт йетелек – борынгы ай атамасы.*

Шулай итеп, *бер, җиде, йөз* саннары мисалында бер-берсенә тугандаш булган татар һәм башкорт телләрендә ясагыч нигезен саннар тәшкил иткән ясалма берәмлекләрне барладык, аларны,өлешчә булса да,халык авыз иҗаты әсәрләре җирлегендә яктыртуга ирештек. Киләчәктә төрки телләрдә уртак лексиканы тәшкил иткән саннар нигезендә ясалган сүзләрнең уртак һәм аермалы якларын ачыклау сүзьясалышы һәм морфология юнәлешендә кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирер дип ышанып калабыз.

**Әдәбият**

1. Балалар фольклоры: Бала саҡ – уйнап-көләп үҫер саҡ. / Төз. И. Ғәләүетдинов, М. Мәмбәтов, Р. Ураҡсина. – Өфө: Китап, 1996. –176 б.
2. Йомгак таптым: Балалар фольклоры. / Төз. Р. Ягъфәров. – Казан: Мәгариф, 2000. – 157 б.

3. Муратова Р.Т. Символика чисел в мифологических представлениях башкир о мире // Актуальные проблемы истории, языка и культуры: Сборник трудов молодых ученых ИИЯЛ УНЦ РАН. III выпуск. – Уфа, 2008.– С.183.

# ТАТАР ТЕЛЕНӘ ДИСТАНЦИОН ӨЙРӘТҮ РЕСУРСЛАРЫ

*Шиһабеддинова Г., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – пед. фән. канд., доц. Фәтхуллова К.С.*

Без яңача фикерләүгә игътибар бирелгән, тормышта әледән-әле яңа ачышлар ясала торган заманда яшибез. Үсеш-үзгәрешләр уку-укыту, тәрбия процессына да кагыла. Укыту-тәрбия өлкәсендә моңа кадәр билгеле булмаган ысуллар, чаралар гамәлгә керә, таныш булган метод-алымнар үзгәреш кичерә, камилләшә.

Интернетның барлыкка килүе мәгълүмат алу мөмкинлеген тамырдан үзгәртте [5: 275]. Аның ярдәмендә кеше теләсә кайда белем алырга мөмкин. Шулай итеп, традицион белем алу яңа алымнар белән баетылып бара. Яшьләр еш кына белемне дистанцион форматта алырга омтылалар. Дистанцион ресурсларның күп булуы сайлап алу мөмкинлеген тудыра.

Интернетта татар телен өйрәнү өчен ресурслар шактый күп. Аларда татар теленә, татар халкының милли үзенчәлекләренә, мәдәниятенә, сәнгатенә багышланган мәгълүматлар бирелә. Мәсәлән, «Татарнамэ» (www.tatar.com – авторы Сабиров Р.) сайтында татар теленә өйрәтү өчен гипертекстлы дәреслекләр һәм сүзлекләр, электрон китапханә тәкъдим ителә. «Белем.ру» сайты (www.belem.ru – авторы Гатауллин Р.) татар теленә бәйле материалларны, хәбәрләрне үз эченә ала [4]. Шулай ук биредә норматив документлар базасы, татар веб-сайтларының каталогы белән танышырга була, электрон китапханә, форум, чат кебек мөмкинлекләр дә тәкъдим ителә. http://konkurs.belem.ru сылтамасы аша төрле конкурсларда катнашырга мөмкин. Әлеге биттә «Интерактив электрон дәреслек» тә урнашкан. Әлеге электрон дәреслектә Казан университетының татар теле кафедрасы укытучылары тарафыннан төзелгән бай теоретик материал бирелә.

Татар теленә өйрәткәндә, дистанцион ресурслар куллану укучыларда уку, язу күнекмәләрен формалаштыру һәм үстерү, кирәкле материал табу, укучыларның сүзлек запасын баету, татар телен өйрәнүгә мотив булдыру кебек бурычларны үтәргә мөмкинлек бирә. «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе әнә шул мөмкинлекләрне тормышка ашырырга ярдәм итә торган бердәнбер ресурс булып тора. Бу ресурсның максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) киң җәмәгатьчелекне, интернет технологияләре кулланып, татар телен мөстәкыйль өйрәнүгә тарту;

2) татар телен, аның мәдәниятен, тарихын өйрәнүгә кызыксыну уяту [2].

«Әйдә! Онлайн» сайты да татар теленә өйрәтүгә юнәлтелгән дистанцион ресурсларның берсе. Әлеге сайт ярдәмендә татар телен өйрәнү кызыклы да, җиңел дә. Биредә татар телен төрле дәрәҗәдә (башлангыч, дәвам итүче) өйрәнеп була. Дәресләр теориядән генә тормый: рәсемнәр, видеолар тәкъдим ителә, сәяхәт-дәрес кебек формалар да кулланыла. Дәрес системалы рәвештә бирелә: исәнләшү, танышу кебек ситуатив дәресләр морфология, лексикология белән үрелеп бара. Мәсәлән, саннар, кушымчалар, кереш сүзләрне өйрәнү сөйләмгә корылган. Татар теленә өйрәтү аерым темаларны үзләштерүне дә күздә тота. Мәсәлән, антоним һәм синонимнарны, фразеологизмнарны өйрәнү өчен биремнәр урын алган. Алар рәсемнәр белән генә түгел, сүзләрнең аңлатмалары, куллану очраклары, сүзтезмәләр, җөмләләр белән дә тәкъдим ителә.

«Мультимедиа» бүлекчәсе, иң беренче чиратта, нинди гыйбарәләрне өйрәнергә кирәк, татар телендә ничек котларга, табиб янында татарча сөйләшәбез кебек актуаль темаларны, ситуацияләрне үз эченә ала [1].

Дәресне заман таләпләренә туры килгән компьютер программалары, интернет ресурслары белән тәэмин итү – мәгълүмати технологияләрне гамәлгә куюда беренче шарт. Информацион технологияләрне укыту, тәрбия эшендә гамәлгә ашыру укытучыдан фәнни-методик яктан әзерлек белән беррәттән, эшне дөрес итеп оештыра белүне дә таләп итә. Бу – яңа технологияне нәтиҗәле куллануның иң мөһим педагогик шарты.

Дистанцион ресурсларны куллану укучыга тел һәм сөйләм материалын гамәли үзләштерергә ярдәм итә, сүзлек запасын баета. Әлеге ресурсларның өстенлеге шунда: мониторда барлык биремнәр матур, эстетик яктан камил эшләнә. Дистанцион ресурслар ярдәмендә бик күп эшләр эшләп була: мультимедиа презентацияләре, төрле тестлар, схемалар. Әлеге ресурстагы презентация слайдлары яңа материалны аңлатканда да, белемнәрне актуальләштерү этабында да, белемнәрне гомумиләштерү, системалаштыру этапларында да уңышлы кулланылырга мөмкин. Материал фәннилек, аңлаешлылык, күрсәтмәлелек принципларына җавап бирерлек итеп сайланырга тиеш. Дәрес барышында башка эш төрләре дә актив кулланыла: дәреслек белән эш, тактага язу, сүзлекләр белән эшләү. Шулай итеп, презентация материалын күрсәтү башка эш төрләре белән үрелеп бара. Электрон презентацияләр төзү укучыларга өй эше итеп тә бирелергә

мөмкин. Мондый эшләр башкару укучыларга үз фикерләрен төгәл, җыйнак итеп әйтеп бирергә мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, татар теленә өйрәтүне камилләштерүнең чиге юк, фәкать эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк. Әлеге эштә дистанцион ресурслар зур ярдәм итәләр. Дистанцион ресурслар – укытучы өчен алыштыргысыз ярдәм. Бу, һичшиксез, татар теленең эчтәлеген безнең әйләнә-тирәбездәге чынбарлыкка бәйләргә, шул мохиттә шәхеснең үзенең урынын билгеләргә ярдәм итә.

**Әдәбият**


1. «Әйдә! Онлайн» // URL: https://www.azatliq.org/eyde (мөрәҗәгать итү вакыты: 12.02.2021).
2. «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе // URL: http://anatele.ef.com (мөрәҗәгать итү вакыты: 12.02.2021).
3.Эко У. От Интернета к Гутенбергу // Общество и книга:от Гутенберга до Интернета: сб. статей / под общ. ред. А.П. Королевой. Институт философии РАН. – М.: Традиция, 2000. – 279 с.
4. «Белем.ру» // URL: www.belem.ru (мөрәҗәгать итү вакыты: 12.02.2021).
5. «Татарнамэ» // URL: www.tatar.com (мөрәҗәгать итү вакыты: 12.02.2021).


## ТАТАР ЛИНГВОМӘДӘНИЯТЕНДӘ ИР МИКРОКОНЦЕПТЫ


*Юнысова А., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Җамалетдинова Г.Ф.*


Халык югары тел культурасына ия булуны элек-электән үк кешенең иң күркәм рухи-әхлакый сыйфатларының берсе итеп санаган. Фольклор әсәрләрендә дә, язучылар иҗатында да тел (сүз) кешене тану, аны сыйфатлау һәм бәяләү җәһәтеннән төп үлчәмнәрнең берсе итеп алына. Кеше көндәлек тормышта кулланган сүзләр катгый һәм шактый тотрыклы логика төшенчәләреннән үзгә булалар. Төшенчәләр төр буенча түгел, ә формаль гәүдәләнеш тапмаган гомуми сыйфатлар буенча квалификацияләнәләр. Халык яки аерым кеше фикерләвендә төшенчәләр предметлар төркеменә хас бердәй сыйфатларның төшенчәдә берләштерелүе һәм аңлау – төшенелү юлы белән түгел, ә иң элек тел бергәлеге күзлегеннән чыгып караганда иң мөһим дип исәпләнгән билгеләрнең аклануы һәм төшенчәләргә әверелдерелүе аша барлыкка киләләр. Мондый төгәллек концептта чагыла.

Концепт ул – чынбарлыкны милли үзаң аша күзаллау нәтиҗәсендә туган төшенчә. Ул – теге яки бу халык күзаллавында оешкан билгеле бер төшенчәгә хас барлык билгеләр җыелмасы, тулы бер система. Концепция, мәгънәви һәм психологик эчтәлеккә ия булудан тыш, коммуникатив әһәмиятле мәгълүматны да үзендә сыйдырырга мөмкин. Тел белемендә лингвомәдәни концепциянең

мәгънәви компоненты гади бер мәгълүмат кына җиткереп калмый, ул метафорик – образлылыктан һәм кыйммәтилектән тыш эчтәлек тә барлыкка китерергә сәләтле [1: 12].

Хәзерге лингвистикада концепт катлаулы һәм күпкырлы, күпаспектлы төзелмә буларак аңлашыла. Ул билгеле бер мәдәният өчен әһәмиятле була һәм шул тел вәкилләреннең күмәк аңында чагылыш таба, шулай ук чынбарлыкның билгеле бер өлкәсендә урын ала һәм теге яки бу формаларында гәүдәләнә.

Тикшеренүнең предметы буларак без “Ир” микроконцептын алдык. “Ир” концепты “гаилә“ концептының бер өлешен тәшкил итә. Татар телендә “ир” лексемасы күп мәгънәләргә ия, стилистик яктан нейтраль, киң таралган, еш кулланыла.

Күренекле тюрколог Р.Әхмәтьянов “ир” сүзен борынгы төрки телдәге *әр* “ир, герой“ сүзеннән сакланганын искәртә [2: 78].

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә “ир” сүзенең берничә төрле аңлатмасы бирелә: 1. Хатын-кызга капма-каршы җенестәге кеше; 2. Малайлык, егетлек чорын үткән, олыгайган кеше; 3. *с.күч.* Батыр йөрәкле, булдыклы; 4. Хатынның бергә тормыш итә торган иптәше; 5. ирдә – кияүгә чыккан, ирле [3: 191].

Әлегә мәгънәләргә бәйле рәвештә “ир” микроконцептының асылын ачыклыйк. Татар гаиләсендә, мөселманнарда ир-ат, ата – баш, аның сүзен җиргә салып таптау юк. Хатын-кыз, ана кеше үзенең иргә карата мөнәсәбәте, хөрмәте мисалында балаларда да этигә булган җылы мөнәсәбәтне тудыра, аның каршында зур җаваплылык тоярга өйрәтә. Гомумән, “Ир” концепты тормышта һәм шулай ук әдәбиятта киң мәгънәгә ия. “Ир” дигәндә, иң беренче чиратта, гаилә башлыгы, хатын ире, йорт хуҗасы күз алдына китлә. Ул гаилә учагын торгызучы һәм саклаучы, зур бурычлар һәм йөкләмәләр нәкъ менә аның җилкәсенә төшә. Гаиләнең матди ягын кайгырту, йорт-җир булдыру, өйдәге авыр эшләрне башкару да иргә карый. Гаилә бәхетле булсын өчен ир табигатенә хас булган күркәм сыйфатлар күп: ышаныч тудыру һәм үз сүзендә торуы, җаваплылык, хатын-кызга булган хөрмәт, вакыйга һәм хәлләрне объектив, адекват бәяли белү, тугрылык.

Татар халык авыз иҗатында ирләр, гадәттә, батыр, төз һәм нык бәдәнле, тырыш, сукса тимер өзәрдәй, туган җире өчен соңгы тамчыга кадәр көрәшүче, мәхәббәтенә тугры булган итеп сурәтләнә. Мисал өчен, түбәндәге мәкальләргә күз салыйк: “*Ир, башын бөксә дә, тезен чүкмәс”, “Ир-егетнең эчендә игез арыслан булыр”, “Ир-егетнең эчендә иярле-йөгәнле ат ятыр”, “Ир кичмәслек елга юк”, “Ирнең асылы эштә танылыр”, “Тырышкан ир морадына ирешер”, " Илнең эше ир муенында" һ.б.*

Матур әдәбият әсәрләренә мөрәҗәгать итсәк, яхшы яктан тасвирланган, алда санап үткән мисалларга ия булган ир-ат образына еш очрарбыз. Сугыш чоры әдәбиятында бу аеруча нык чагыла. Мәсәлән, Фатих Кәримнең "Ватаным өчен" шигырендә иле өчен гомерен кызганман татар улы сурәтләнә: "*Үләм икән, үкенечле түгел/ Бу үлемнең миңа килүе, / Бөек җыр ул – Бөек Ватан өчен/ Сугыш кырларында үлүе*". Шулай ук Муса Җәлилнең "Егет көче" шигерендә: "*Байрак итеп илгә тугрылыкны, / Утны-суны кичте бу егет, / Автоматы түгел, аты түгел, / Анты белән көчле бу егет*".

Шәриф Камалның "Акчарлаклар" повестендәге төп каһарман – Гариф образы да укучыда бары уңай тәэсирләр генә калдыра. Ул күзгә ташланып торырлык чибәр, уңган һәм батыр егет буларак сурәтләнә. Мулла малае, шулай ук аның батыр-кыю, хәтта тәвәккәл дә булуы, нечкә күңелле, итагатьле һәм хисчән икәнлеге дә ачыла. Укымышлы башы белән мулла булмыйча кара эштә йөрүе, тормыштан нәрсәдер эзләнүе башкаларда кызыксыну уята. Гарифның ягымлылыгы, чыдамлылыгы, чигенмичә алга баруы – аны үз кеше итә, аңа хөрмәт күрсәтергә куша. Ул иптәшләре арасында зыялыгы белән аерылып тора, акылын җуймый, яклашуны туктата.

Әдәби әсәрләрдән мисалларны шактый китерергә мөмкин. Тискәре образлар юк түгел, ләкин гадәттә әсәрнең төп каһарманы – уңай яклары белән аерылып торучы ир-ат.

"Ир" микроконцептын анализлап, асылда, ир-атның – милләте, Ватаны, гаиләсе өчен җан атып торучы көчле йөрәкле зат икәнен күрәбез. Әсәрләрдә ир образы батыр, тырыш, иленең горур улы буларак гәүдәләнә. Аны җәмгыятьнең киләчәге, нәселне дәвам итүче, буыннар арасындагы бәйләнешне тәэмин итүче рәвешендә күрәбез.

**Әдәбият**

1. Сибгаева Ф.Р. Концепт "Мәхәббәт" в татарской языковой картине мира. – Казань: Ихлас, 2010. – 112 с.
2. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

## TATAR TÜRKÇESİ VE TÜRKİYE TÜRKÇESİNDE EŞANLAMLI ATASÖZLERİ

*Языджы Ф., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Латыпов Р.И.*

Son yıllarda Türk dilleri ile ilgili karşılaştırmalı çalışmaların sayısı hızla artmaktadır. Bu çalışma Tatar Türkçesi ile Türkiye Türkçesinde yazılı ve sözlü olarak mevcut olan eşanlamlı atasözlerini (Аталар сөзу)

içermektedir. Her iki Türk Dilinin de içerisinde birçok eşanlamlı atasözleri mevcuttur. Bazı dönemler yaygın eserler arasında başköşeye oturmuş olan atasözleri Türk dillerinin adeta kelam abidelerilerdir. Toplumsal ve düşünsel hafızalarımız bu sözlü aktarımlarda saklanmaktadır. Bunlar ise hayat denen şu kısacık zaman diliminde en acı öğretmen olan tecrübe tarafından yetiştirilmiş insan unsurunun ürünüdür.

Atasözleri hakkında ilk somut kaynaklar arkeoloji alanında yapılan çalışmalar sonucu elde edilmiştir. Bilinen en eski atasözlerinin Tevrat ve Zebur'u kapsayan Museviliğin kutsal kitabı olarak kabul edilen Tanah'ın Ketuvim bölümünde (Süleyman Meselleri/Özdeyişleri) yer aldığı kabul edilmekteydi. Daha sonraları Mısır Hiyerogliflerinde dünyanın en eski atasözlerinin olduğu kabul edilmiş. Günümüzde ise 1934 yılında İtalyan Arkeolog Edward Chierra'nın Sümer tabletleri (M.Ö. 17. Yüzyıl) üzerine yaptığı derleme aslında en eski atasözlerinin Sümer tabletlerinde olduğunu göstermektedir [4].

Bir örnek:

*Çöl matarası insanın hayatıdır* *Сосуд с водой в пустыне – это жизнь человека*
*Pabuç insanın gözüdür* *Обувь – глаза человека*
*Karısı insanın geleceğidir* *Жена – будущее человека*
*Oğul insanın sığınağıdır* *Сын – убежище человека*
*Kız insanın kurtuluşudur* *Дочь – человеческое спасение*

Türk kültürü yazılı eserleri içerisinde bulunan atasözlerine ise ilk olarak Orhun Yazıtları, Dîvânü Lugati't-Türk, Dede Korkut Hikayeleri ve Kutatgu Bilig'de rastlanmaktadır [3]. Atasözleri İlk örneklerde "sav", sonraları "mesel ve darbı mesel" isimleri ile geçer. Anadolu'daki Türk kültürü açışından incelendiğinde Divan edebiyatında "Pend-nâme"ler Halk şiirinde ise "nasihat destanları" atasözleri içermektedir [2].

Türk atasözleri sadece Türk kültürü üzerinde bir etki yapmamıştır. Yaygın Türk kültürü zamanlarında (Osmanlı Devleti) Türk atasözlerine batılı devletlerde de rastlanmaktadır.

Tatar atasözleri gerek anlam gerek ise söyleniş açısından Türkiye Türkçesi atasözlerine çok yakınlık gösterir. Bu alanda Tatar alimleri de çok kıymetli çalışmalar yapmışlardır. Tataristan'ın başkenti Kazan'da basılan (1982) "Mekaller hem Eytimner" isimli kitapta on binden fazla atasözüne yer verilmiştir. Tatar atasözleri hakkında yapılan çalışmalar sonucunda değişik varyantlarıyla beraber bugün atasözlerinin sayısı elli bine yaklaşmaktadır [1].

Tatar Türkçesi ve Türkiye Türkçesinde mevcut olan atasözlerinden birkaç örnek:

*Ашыгыч эшкә шайтан катыша.* *Acele işe şeytan karışır.*

*Ач аю уйнамый.* *Aç ayı oynatamaz.*

*Тел кылычтан үткенрәк.* *Dil kılıçtan keskindir.*

*Ач тамагым тыныч колагым.* *Aç başım, dinç kulağım.*

*Акыллы сүз – телдән чыккан алтын.* *Akıllı söz, dilden çıkan altındır.*

*Акыллы кешедән акыллы сүз чыга.* *Akıllı kişiden akıllı söz çıkar.*

*Ачуның теле әче.* *Kızgınlığın dili acıdır.*

*Акылы кысканың теле озын.* *Aklı kısanın dili uzundur.*

"Köklü ve zengin bir kültür birikimine sahip Türkler'in atasözleri hakkında literatüre bakıldığında kimisinin sadece derleme kimisinin çeşitli veçhelerle tahlile dayalı olduğu yerli-yabancı, akademik-popüler ciddi bir eser yekûnunun mevcudiyeti göze çarpmaktadır" [5].

**Kaynaklar**


1. Alkaya, E. (2001). Tatar Türkçesindeki Dil ve Söz İle İlgili Atasözleri Üzerine Bir Değerlendirme. Fırat Üniversitesi Sosyal Bilimler Dergisi, 55-76.
2. Atasozleri. cokbilgi. com. (2021, 02 15). Atasözlerinin Tarihi Gelişimi. atasozleri.cokbilgi.com: https://atasozleri.cokbilgi.com/atasozlerinin-tarihi/#:~:text=T%C3%BCrk%C3%A7e%20ilk%20atas%C3%B6z%C3%BC%20%C3%B6rneklerine%20Orhun,nasihat%20destanlar%C4%B1%22%20atas%C3%B6zleri%20ile%20olu%C5%9Fur.
3. Gönen, Y. (2015). Türk Atasözlerinde Sözlü İletişim Unsurlarının Sunumu. İzmir: Ege Üniversitesi, Sosyal Bilimler Enstitüsü, Halkla İlişkiler ve Tanıtım Anabilim Dalı.
4. Torun, V. (2021, 02 16). Sümerlerde Atasözleri ve Özdeyişler. arkeofili.com: https://arkeofili.com/sumerlerde-atasozleri-ve-ozdeyisler/
5. Tuncer, M. (2020). Batı Kültüründe Türk Atasözleri. RumeliDe (Dil ve Edebiyat Araştırmaları Dergisi), 737-740.


## СПЕЦИФИКА ИЗУЧЕНИЯ РУССКОЙ АНТРОПОНИМИЧЕСКОЙ СИСТЕМЫ В ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКОМ АСПЕКТЕ НА ЗАНЯТИЯХ ПО РКИ


*Чжао Ян, КФУ, аспирант II г.о.*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Ахметзянова Л.М.*


Особое внимание к изучению русских антропонимов на занятиях по РКИ обусловлено тем, что это является одной из основ при изучении иностранных языков, без которой невозможна успешная коммуникация. Антропонимика – это раздел ономастики, изучающий собственные имена людей (антропонимы), их происхождение, изменение этих имён и социальное функционирование, а также структуру и развитие антропонимических систем. Антропонимом называется любое имя собственное, которым зовётся человек: имя личное, отчество, фамилия, прозвище, псевдоним, клички [1: 35]. Русские антропонимы отражают традиционные представления, верования, мировоззрения русского народа. Так невозможно

представить культуру вне языка, как невозможно рассматривать язык без культуры. Поэтому перед преподавателями РКИ не только стоит задача обучить русскому языку, но также необходимо уделять достаточное внимание изучению культуры и объяснению коннотации имён собственных.

Трёхчленная формула имени (личное имя + отчество + фамилия) – важный компонент русской антропонимической системы, а также является важнейшим воплощением русского языка и культуры.

История развития русской антропонимической системы показывает, что наименования являются древним элементом, несущим в себе информацию об отсутствии универсальных закономерностей в структуре имени собственного, о его семантике и определяет следующие характеристики в лексическом плане:

1. Русские имена подразделяются на мужские (имя существительное мужского рода) и женские (имя существительное женского рода), а также род имени можно определить по окончанию и суффиксу: *Олег / Ольга, Светлан / Светлана, Виктор / Виктория, Юлий / Юлия и т.д.*

2. Личные имена в основном употребляются в единственном числе. В редких случаях употребляется множественное число, например, если в одном месте находится несколько человек с одним и тем же именем: *«В одном классе несколько Светлан»; «В детском доме было шесть Валентин».*

По словам О.В. Чумаченка, «антропоним сам по себе вбирает в себя культурные коннотации, за счет чего формируются ассоциативные лексические значения» [5: 108]. К примеру, имя *Галя* означает «спокойствие, безмятежность»; Андрей означает «мужественный, храбрый»; Евгений – «благородный»; Иван – «помилованный Богом» и т.п. Кроме того, некоторые христианские имена переводятся с других языков на русский с тем же значением, что и существующие русские апеллятива, например, *Лев, Надежда, Вера, Любовь* и т.д.

Для того чтобы иностранные студенты правильно понимали взаимоотношения собеседников во время общения на русском языке при любых обстоятельствах, необходимо знать, что отчество образуется от имени отца при помощи суффиксов *-ович, -евич, -ич* (для мужчин) и *-овна, -евна, -инична* (для женщин): *Иван – Иванович / Ивановна, Игорь – Игоревич / Игоревна, Илья –Ильич / Ильинична.* Отчество является неким индикатором положения в обществе и взаимоотношений между людьми. Сочетание имени-отчества возникло как знак уважения к адресату, в некоторых случаях представляет собой

признак социальной зрелости. При этом в официальном стиле общения нужно использовать имя и отчество. Как по словам Н.И. Формановской, «давно и хорошо знающие друг друга люди, которые в обиходно-бытовой обстановке обращаются по именам, в официальных условиях употребляют форму обращения имя-отчество» [3].

Фамилия, как наследственное родовое имя, передаётся по мужской линии и содержит в себе следующие мотивированные внутренние значения: а) фамилии произошли от личных имён: *Иванов, Петров, Ильин*; б) фамилии произошли от топонимов: *Варшавский, Львовский*; в) фамилии произошли от профессии и рода занятий: *Кузнецов, Сапожников, Швецов*; г) фамилии произошли от прозвищ: *Воронов, Белозубов, Медведев*. При вступлении в брак женщина берёт фамилию мужа.

Таким образом, по мнению Н.И. Формановской, «в русском социуме формулы имён обладают национальной спецификой по следующим параметрам: 1) множество форм имён, которые принадлежат одному человеку; 2) множество суффиксальных образований; 3) наличие «имени-отчества» [4: 30].

Однако, как отмечает Л.С. Головина, «анализ ряда востребованных учебников РКИ показал, что их авторы не ставят и не могут ставить своей целью лингвокультурологическое комментирование каждого онима при решении других учебно-методических задач» [2: 86]. Поэтому, нам кажется, что в практике преподавания русского языка как иностранного, преподавателю стоит обратить внимание на весь спектр форм русских имён, детально изучить специфику русской антропонимической системы в лингвокультурологическом аспекте на занятиях РКИ с иностранными учащимися через призму их родного языкового сознания.

**Литература**

1. Антропонимика / Под ред. В.А. Никонова и А.В. Суперанской. – М.: Наука, 1970. – 360 с.

2. Головина Л.С. Этнокультурная семантика антропонимов и её репрезентаия иноязычному адресату // Известия волгоградского государственного педагогического университета. – 2012. – № 8. – С. 86-89.

3. Формановская Н.И. Имя-отчество как русский национальный обычай и современные СМИ [Электронный ресурс] // URL:http://literary.ru/literary.ru/readme.php (дата обращения: 09.08.2018).

4. Формановская Н.И. Социокультурное пространство русского личного имени и современные средства массовой информации // Русский язык: исторические судьбы и современность. II Международный конгресс исследователей русского языка. – М.: Изд-во МГУ, 2004. – С. 30-31.

5. Чумаченко О.В. Культурная коннотация антропонимов // Вестник Казахстанско- Американского свободного ун-та. – 2008. – № 2. – С. 108-112.

## ТАТАР ТЕЛЛЕ ЧАТЛАРДА ВИРТУАЛЬ АНТРОНОМИКОННЫҢ БИРЕЛЕШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Яруллина А.С., КФУ, I курс аспиранты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Галиуллина Г.Р.*

Телнең антропонимик системасы халыкның аңын, үзаңын ачу, билгеле бер милләткә яки регионга караган кешеләрнең психологиясен һәм характерларын аңлау өчен нигез материал булып тора. Антропонимның катлаулы табигатькә ия булуы, чорның мәдәни һәм социаль контекстына бәйле, бу җәмгыять үсешенең борылыш чорларында сизелә, әлеге лексик берәмлек лингвистик позициядән өйрәнелә алмый, шуңа күрә антропонимнар когнитив лингвистиканы өйрәнү объекты булып тора. Исем барыннан да элек халыкның мәдәни мәгълүматын саклаучы, ул төрле, шул исәптән экстралингвистик факторлар йогынтысында формалаша. Моннан тыш, ул дөньяны кабул итүгә бәйле һәм аны күпмедер дәрәҗәдә чагылдыра. Бу планда төрки телле халыкларның антропонимиконнарын өйрәнү аеруча зур кызыксыну уята.

Татар антропонимикасы мәсьәләләренә Саттаров Г.Ф., Шәйхулов А.Г., Йосыпов Г.В., Әхмәтҗанов М.И., Субаева Р.Х., Җәләлиева М.Г., Куприянова Ф.М., Мәҗитова Ф. Л., Галиуллина Г.Р., Ваһапова Ф.Г., Тимканова Г.К. һ. б. хезмәтләре багышланган.

Хәзерге лингвист-ономатологларны ономастик, аерым алганда, антропоним, лексика һәм халык мәдәнияте үзара бәйләнеше мәсьәләләре күбрәк җәлеп итә. Шуның белән бәйле рәвештә XX гасыр ахырында күп санлы эшләр барлыкка килә, аларда антропонимнар мәдәният контекстында тикшерелә. Яңа тикшеренүләрнең теоретик нигезләре Никонов В.А., Суперанская А.В., Подольская Н.В., Введенский Л.А., Мурзаева Э.М., Рут М.Э., Смольников С.Н., Голомидова М.В. һәм башка фәнни эшләрдә чагыла.

Антропонимик лексиканың үзенчәлеген, аның барлыкка килүе һәм яшәешенең татар халкының һәм социумның мәдәни традицияләренә бәйле булуын исәпкә алып, әлеге лексиканы өйрәнү өчен яңа алымнар эзләү зарурилыгы бар. Әлеге мәкаләнең темасы да шуңа багышланган.

Теләсә кайсы телнең шәхси исемнәре мәдәният тарафыннан билгеләнә торган төркем һәм милли аңны өйрәнү чарасы булып тора. Эш интернет-дискурсның билгеле бер жанры – виртуаль чат коммуникациясе материалында виртуаль антропонимикон үзенчәлекләрен (шәхси исемнәр җыелмасы) чагыштырмача өйрәнүгә багышлана. Әлеге жанр һәм интернет-аралашу үзенчәлеген өйрәнү

актуаль булып тора, чөнки чат-коммуникация виртуаль аралашуның иң динамик үсүче формаларының берсе булып тора.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурыч куелды: татар телле чатларда антропонимик берәмлекләрдә чагылдырылган милли шәхеснең дөньяви үзенчәлеген күрсәтү.

Әлеге эш объекты булып татар телле чатларның виртуаль антропонимиконы тора. Тикшеренү предметы – татар телле чатларда антопонимиконнар яки никонимнарның гомуми һәм үзенчәлекле закончалыклары. Тикшеренүнең максаты: татар теле чатларда никонимнарның бирелеш үзенчәлекләрен ачыклау.

Татар телле чатларны күбесенчә яшьләр тәшкил итә, бу, барыннан да элек, татар антропонимиконнары чаттерларның яшь үзенчәлекләре белән бәйле булуын күрсәтеп тора. Коммуникантларының үзләренең аермалы характеристикаларын турыдан-туры исемдә ачарга омтылышы, шул ук вакытта татар никонимнарда табу максатын билгеләү беренче дәрәҗә булып тора.

Шуннан чыгып, без татар чатларында катнашучыларның яшь, характер һәм мохит сайлау үзенчәлекләре виртуаль исемнәрендә чагыла икәнен әйтә алабыз. Бу аларның шәхси үзенчәлекләрен, томышка карашларын күрсәтеп тора. Татар телле никнеймлар коллективизмны, татар натурасының киңлеген, ваклык һәм исәп-хисаплылыкның булмавын күрсәтә. Чатларның антропонимик системасын караганда, татар телле җәмгыять вәкилләренең виртуаль исем сайлауда ирекле булуы һәм аны саклап калырга омтылулары ачык күренә. Виртуаль исемнең нигезендә чаттер образын тудыручы һәм аны конкурентлар рәтенә бүлеп бирергә тиешле билгеле бер концепция ята. Шуңа бәйле рәвештә, түбәндәге антопонимнимконнар сайлау үзенчәлекләрен бүлеп чыгарып була:

1) оригиналь һәм уникаль булырга.

2) коммуникантларда билгеле бер ассоциацияләрне чакырырга. Ассоциацияләр нигезендә никнеймалар ясап, кеше үзенә битлек киеп, ниндидер рольдә чыгыш ясау мөмкинлегенә ия була.

3) кулланучыларның игътибарын җәлеп итәргә, истә калдырырга һәм аларда уңай яки тискәре хисләр уятуны максат итеп исемнәр куела... Чаттерларның теге яки бу мәсьәләгә мөрәҗәгать иткәндә башка никка әлеге кулланучы белән берничә тапкыр элемтәгә керү теләге барлыкка килергә тиеш. Чатта позитив әңгәмә корырга теләгән кешеләргә реаль исемне сайлаудан тоелырга кирәк, чөнки чат киңлегендә мондый исемнәр игътибарга лаек түгел. Чатларда татар исемнәре күп сүзле булырга тиеш түгел һәм катнашучыларның билгеле

бер максат белән утырганда (эш, мәхәббәт мөнәсәбәтләре өчен һ.б.), әлеге максатны күрсәтү мәслихәт.

Шулай итеп, кешелекнең баштан ук ике исем системасы кулланыла. Узган йөз елда Аралашу формасы телдән булса, компьютер белән аралашу яңа меңьеллыкның доминанты булды. Шуның белән бәйле рәвештә, никоним кебек ясалма номинациянең яңа формалары барлыкка килә. Бүген компьютерда эшләү өчен вакытны аз гына өзеп торучы һәр кешенең үз исеме бар, аның белән ул интернет-коммуникацияләргә дә тәкъдим ителә.

**Әдәбият**


1. Галиуллина Г.Р. Татарская антропонимия в лингвокультурологическом аспекте: автореф. дис. ... доктора филол. наук : 10.02.02. – Казань, 2009. – 43 с.
2. Аникина Т.В. Сопоставительное исследование виртуального антропонимикона англоязычных, русскоязычных и франкоязычных чатов: автореф. дис. ... канд. филол. наук : 10.02.20. – Екатеринбург, 2011. – 24 с.

## 3 НЧЕ СЕКЦИЯ

### ТАТАРЧА ОНЛАЙН АРАЛАШУДА СМАЙЛИКЛАР

*Денмөхәммәтова Ә., Казан, 149 нчы лицей укучысы*
*Җит. – Миргалеева Д.Р., Хөснетдинова Р.Р.*

Хәзерге вакытта беркемгә дә СМС, чат, скайп, вацап сүзләренең мәгънәләрен аңлату кирәкми. Боларны кечкенәләр дә, карт әби һәм бабайлар да яхшы белә, күбесе аларны онлайн аралашуда файдалана. Онлайн аралашуда кулланыла торган чараларның тагын бер төре – смайликлар яки стикерлар җибәрү. Телефон аша килгән төрле рәсемнәр, елмайган яки борчулы йөзләр, яисә төрле-төрле символларны һәркемнең күргәне һәм кулланганы бар. Ә татарча СМС язганда, яки watssap аша кыскача хәбәр җибәргәндә без аларны нәрсәдән чыгып сайлыйбыз? Ни өчен бер үк мәгънәне аңлатканда төрле рәсемнәр җибәрәбез? Смайлик һәм стикерларның мәгънәләрен дөрес аңлыйбызмы? Ни өчен татарча языла торган текстларга инглиз сүзләрен кыстырабыз? Безнең өчен бу сорауларга җавап эзләү кызыклы тоелды, шуңа күрә аны тикшерү-өйрәнү кирәклеген күрдек.

Тикшерүнең объекты – СМС һәм вацаптагы татарча кыска текстлар. Аларны сыйныфташларым, дусларым, укытучыларым, туганнар, шул исәптән өлкән яшьтәге апа-абыйларның телефоннарыннан җыйдык. Билгеле, телефонга килгән барлык кыска текстларны да тикшереп бетерү мөмкин түгел, әмма без бу эшне башкарганда 300дән артык текст белән эш иттек, аларның кулланылыш үзенчәлекләрен тикшердек.

Максат – татарча язылган онлайн кыска текстлардагы смайликларның һәм инглиз гыйбарәләренең кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерү иде.

Бу теманы өйрәнгәндә, шуны ачыкладык: чит ил һәм рус галимнәре виртуаль сөйләмдә смайликларны куллану буенча төрле фәнни монографияләр, мәкаләләр язсалар да (мәсәлән, Скотт Фалман, Майк Джонс, Р.М. Фрумкина һ.б.), татар сөйләмендә аларның кулланылышы турында хезмәтләр әлегә юк икән. Татар сөйләм этикеты турында без Ф.Сафиуллина, Н.Шарыпова, О.Агаракова, И.Низамов, Р. Йосыпов хезмәтләреннән таныштык.

Тикшерү методлары. Тикшерү эшендә күзәтү, анализ, анкета үткәрү, чагыштыру, тасвирлау кебек метод һәм алымнар кулланылды.

*Смайлик* сүзе инглиз телендәге smile – елмаю, елмаерга дигәннән барлыкка килгән. Башлангыч чорда смайликлар алфавитның төрле символлары, саннар һәм тыныш билгеләре ярдәмендә эчке хис-

кичерешләрне белдерергә ярдәм иткәннәр. Ә беренче смайликлар нинди булганнар? Ничек барлыкка килгәннәр соң?

1963 нче елда Америка Кушма Штатларында шундый хәл туа: берничә зур иминият компаниясе кушылу сәбәпле, аларның клиентларының кәефе төшә, хезмәткәрләрнең эшлисе килми башлый. Кешеләрнең алдагы көнгә ышанычлары бетә, ә бу исә бизнеска зарар сала. Шул вакытта компания җитәкчелеге Харви Болл исемле рәссамга заказ бирә. Ул бик тиз арада кешеләрне көлдерә, елмайта һәм кәефләрен күтәрә торган гади рәсемнәр ясарга тиеш була. Рәссам озак уйлап тормый, ун минут эчендә безгә таныш булган сары түгәрәк, ике нокта рәвешендәге күзләр һәм елмаюны белдергән дуга сыман кара сызыктан торган рәсем сызып куя.  Үз эше өчен 45 доллар ала.

Берничә елдан соң Харви Болл World Smile Corporation дип аталган хәйрия  оешмасы оештыра һәм һәр елның 1нче октябрендә Халыкара елмаю көне үткәрә башлый. Инглизчә бу көн World Smile Day дип атала. Соңрак, XX гасыр ахырында, смайликлар яки икенче исемнәре белән әйтсәк эмотиконнар (инглизчәдән emoticon) Интернетта һәм SMSларда актив кулланыла башлыйлар. Хәзер исә алар – һәркемгә таныш һәм һәркем тарафыннан яратып кулланыла торган кәеф күтәрә торган рәсемнәр.

Рәсемле (график) смайликлар барлыкка килгәнче, түбәндәге тамгалар кәефне белдерү чарасын үтәгәннәр. Аларны төрле тыныш билгеләре белән белдергәннәр. Әлбәттә, мондый тамгалар тәртибен белү җиңел түгел. Аларны һәркем истә дә тота алмый. Шуңа күрә сүзләрне кыскартып яза башлаганнар: *спс “спасибо”; дв “до встречи”, отл “отлично”* һ.б. Шунысы кызыклы: мондый төр язмалар хәзер татарча  аралашуга да килеп керде. Кыскача язылган *рхм “рәхмәт”, хш “хуш” һ.б.* кебек кыскартулар СМСларда, чат һәм шәхси кыска язмаларда бик күп.

Татарча аралашу вакытында смайликлар һәм рус текстларына паразит кебек килеп кергән инглизчә гыйбарәләр активмы соң? Без сораштыру үткәрдек. Сораштыру 3 төркемдә узды. Бер үк биремнәр 10-17 яшьләрдәге укучыларга, 30-50 яшьләрдәге урта буын вәкилләренә һәм 60-75 яшьлек өлкәннәргә бирелде. Һәр төркемдә 25-30 кеше катнашты. Алар 10 смайликны кайчан файдалануларын күрсәтергә һәм нинди мәгънә белдерүләрен аңлатырга тиеш иделәр. Шуннан соң инглиз гыйбарәләрен татарча ничек файдалана алуны язарга тиеш иделәр. Тикшеренү дән шул билгеле булды: 1) беренче һәм икенче төркемдәгеләр инглизчә гыйбарәләрне яхшы аңлыйлар, үз СМСларында, күбесенчә инглизчә файдаланалар, әмма өлкән яшьтәгеләр исә бу гыйбарәләрне белмәве һәм кулланмавы ачыкланды.

Ә менә смайликларны һәркем файдалануы ачыкланды. Шунысы да кызыклы: урта һәм өлкән яшьтәге сораштырылучылар милли смайликлар булса, аларны ешрак файдаланыр идек һәм татарча сөйләшүебез аерылып торыр иде дигән теләк тә белдерделәр.

Нәтиҗә ясап, шуны искәртергә мөмкин: гади сөйләмдә без күп вакытта жестлар ярдәмендә фикерләрне белдерсәк, онлайн аралашуда моңа смайликлар аша ирешәбез. Бу уңайлы һәм тиз. Әмма моның тискәре яклары булуны да истән чыгарырга ярамый. Мәсәлән, кирәк вакытта сүз таба алмый башлыйбыз (сүзлек запасыбыз кими); язуда хаталар китә; тыныш билгеләрен куймыйбыз яки хаталы куябыз һ.б. Шуңа күрә эмоцияләрне язма сөйләмдә дә белдерә алу бик яхшы, әмма рәсем белән генә түгел, ә сүз белән дә, кешене рәнҗетмичә, уйлаганнарыбызны җиткерә белергә өйрәнергә кирәк.

**Әдәбият**


1. Беликов В.И. Жестов языки // Лингвистический энциклопедический словарь / Гл. ред. В.Н. Ярцева. – М.: Сов. энциклопедия, 1990. – С. 153.
2. Низамов И. М. Матбугатның тәэсирле сүзе. (Газета лексикасы мәсъәләләре). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 144 б.
3. Сафиуллина Ф. С. Татар телендә сүз тәртибе. – Казан.: Тат. кит. нәшр., 1974. – 151 б.
4. Юсупов Р. А. Икетеллек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар кит. нәшр., 1978. – 223 б.


## ХӘЗЕРГЕ УКУЧЫНЫҢ ТЕЛЕНДӘ ЖАРГОННАР


*Закирова А., Саба р-ны, Шәмәрдән лицее, Х сыйныф*

*Җит. – Закирова Ә.М.*


Хәзерге вакытта кесә телефоннары, SMS аралашулар, электрон почта һәм интернет-чатларның актив кулланылуы мәктәп укучылары сөйләменә зур йогынты ясый. Белгәнебезчә, билгеле бер дәрәҗәдәге бу ясалма тел әдәби тел нормаларын бозуга китерә. Укучылар телендә жаргоннар һәм сленглар, сүзлек запасын тәшкил иткән башка сүзләрдән аермалы буларак, киң катлам вәкилләре теленә тиз арада үтеп керә һәм шул рәвешле телебездә чит элементлар таралуга, телебезнең табигыйлегенә елдан ел зыян китерә.

Жаргон (жаргонизм) – француз теленнән кергән сүз, бердәй профессия, көнкүреш шартларында, уртак кызыксынулар белән бергә вакыт үткәрүче бер төркем кешеләр сөйләмендәге үзенчәлекләр.

Жаргон лексика, нинди иҗтимагый катламда куллануга карап, ике төргә аерыла:

1) киң катлам кешеләр телендә кулланыла торган сүзләр (яшьләр, студентлар, мәктәп укучылары телендә). Мисал өчен, телик – телевизор, картлар – армиядә приказ көтүче солдат, шпора – шпаргалка һ.б.

2) тар, ябык коллективларда башкаларга аңлашылмаслык итеп, конспирация максатыннан кулланыла торган жаргоннар

Арго сүзләр – башкаларга сүзнең мәгънәсен аңлашылмаслык итеп сөйләү алымы. Арго сүзләр һөнәр серен саклау алымы да булганнар [Сафиуллина, 2006: 88]. Күп очракта, әлеге сүзләрне тормышлары яшерен эшкә, намуссызлыкка корылган караклар куллана дигән фикерләр бар. Әлеге күренеш балалар, мәктәп укучылары сөйләмендә дә бик актив. Алар башкаларга аңлашылмасын өчен төркемнәргә бүленеп, ниндидер бер яшерен сөйләм уйлап табалар. Һәр иҗеккә бер төрле иҗек кушып сөйләшүләр, сүзне кире яктан уку, шулай ук, гади генә сынамышлар, уен сүзләре дә арго сүзләргә мисал булып тора ала.

Билгеле булганча, жаргон һәм арго сүзләр куллану кешенең интеллектын һәм культура дәрәҗәсен төшереп кенә калмый, әдәби нормаларны бозуга, телнең ямьсезләнүенә, тупаслануына китерә. Хикәяләүне чынбарлакка якынрак итү, вакыйгаларның кайсы чорда булуына ишарә ясау өчен язучылар һәм журналистлар, еш кына, жаргон һәм арго сүзләрен үзләренең әсәрләренә дә кертеп җибәрәләр.

Иң актив кулланылышта булган жаргоннарны якынча берничә төркемгә бүләргә мөмкин.

1) Исем сүз төркеме:

А) кешеләргә карата кулланыла торган сүзләр:

братан – якын дус; ихтирамга лаеклы; училка – укытучы; махера – кыз кеше; батаник – акыллы, белемле укучы.

Б) кешегә карата кулланыла торган тискәре сүзләр:

лох – ялганнарга ышана торган укучы; тормоз – озак фикер йөртүче.

В) тән әгъзаларын белдерүче сүзләр:

ласты – аяклар; локаторлар – колаклар; хавка – авыз; зенка – күз.

Г) төркемнәрен ачыкларга кыенлык тудырган сүзләр җыелмасы:

угар – кызык; хавчик – ашамлык; рамс – талашу; чирик – 10 сум; капуста, кәбестә – акча; изге – уңай җавап;

2) Фигыльләр һәм фигыль сүзтезмәләр: вали – кит; двигай – тизрәк кит; селкен – кит; йөгерәм – әйтелгән үтенечне үтәмәвен белдерү; прикинь – күз алдыңа китер; стучать – нәрсәнедер җиткерү.

3) Мәгънәләре буенча рәвешләргә якын булган сүзләр: класс, клево, ништяк – артыклык дәрәҗәсендәге билге, сыйфат, пять сек – бик тиз; точняк – дөрес.

4) Сыйфатлар: крутой, классный – нәрсәнеңдер югары сыйфаты; стремный – начар, кайсыдыр җире килмәгән кеше; беспонтовый – начар, кирәксез әйбер.

Мәктәп хезмәткәрләренә, укытучыларга, аларның аерым бер сыйфатларына багышланган жаргоннар бер төркем хасил итәләр. Әлеге жаргоннар бик үзенчәлекле, алар укыта торган фән исеме белән һәм дәрескә кагылган сүзләр ярдәмендә барлыкка килгәннәр:

Фән исеменә нигезләнеп барлыкка килгән сүзләр: *англичанка – инглиз теле укытучысы, биологичка – биология укытучысы, завучка – укыту эшләре урынбасары һ.б.*

Дәрескә кагылышлы предметларга нигезләнгән сүзләр: *колба – химия укытучысы, кисточка – рәсем сәнгате укытучысы, молекула – физика укытучысы, карандаш – черчение укытучысы, принтер – информатика укытучысы һ.б.*

Укытучылар турында жаргон сүзләр белән сөйләшү, укытучыларга карата начар мөнәсәбәт, ихтирам булмау турында сөйләми. Мәктәп укучылары вакытны бушка сарыф итмәскә тырышалар. Шуның өчен әлеге сүзләрне кулланалар.

Мәктәп тормышын дәреслектән башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Әмма укучылар өчен ул кирәкмәгән мескен бер әйбер буларак кабул ителә. Ул еш кына өйдә кала, югала, сумкадан чыкмый, яисә гомумән китапханәдән алынмаска мөмкин. Дәреслекләргә һәм дәрес исемнәренә карата да үзенчәлекле сүзләр кулланыла: *матан, матеша, матика*– математика, *лаба* – лаборатор эш, *физра* – физкультура, *пеша* – җыр дәресе, музыка, *рашен* – рус теле дәресе, *инглиш* – инглиз теле һ.б.

Тикшеренүчеләр фикере буенча, мәктәп укучылары куллана торган жаргоннар – телебезнең авангарды яисә яңалыгы. Әлеге лексик катлам берничә елдан сүзлекләргә керергә мөмкин. Мәктәп укучылары куллана торган жаргоннарның һәм сленгларның көче, аларның бүгенге көнгә бәйле булулары белән аңлатыла.

**Әдәбият**


1. Абдуллина Р.С. Сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 527 б.
2. Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 93 б.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.


## ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДА ЧАГЫШТЫРУЛАР


*Зәкиева А., Казан, 124 нче мәктәп, IX сыйныф*

*Җит. – Мөслимова К.У.*


Татар халкының җыр чишмәсе чал гасырлар түреннән агып килә. Юлында карурманнар, биек таулар очраса да туктамаган ул чишмә, үзенең сихри моңнарын, тылсымлы авазлары белән кешеләргә куаныч, юаныч, дәрт биреп һаман аккан, һаман җырлаган, тормыштан матур аһәңнәр алып, ул чишмә бүген дә чылтырап ага.

Халык җырларының мәгънәви байлыгына һәм шигъри матурлыгына татар мәдәнияте һәм әдәбиятының күренекле вәкилләре һәрвакыт сокланып, ихтирам белән караганнар. Халык җыры, халык көе алар өчен бай илһам чишмәсе булып тора, халыкчан рух белән сугарылган нәфис әсәрләр иҗат итү өчен шифалы бер чыганак булып хезмәт итә.

Татар халык җырларына яшәү көче, билгеле ки, аның төзелешендә, аның сурәтләү чараларында. Шундый сурәтләү чараларының берсе – чагыштыру. Ә чагыштыруның нигезендә предмет яки күренешләрне бер-берсе белән тиңләштерү, аларның тиңдәш якларын күрсәтү ята. Татар халык җырларында чагыштыруларның эзлекле үсеш юлын күреп була. Эчтәлек белән дә, формасы белән дә, күләме белән дә чагыштырулар төрле булырга мөмкин. Безнең көннәргәчә килеп җиткән борынгы татар халык җырларында батыр егетне лачын, матур кызларны карлыгач кебек табигатьнең иркә кошларына һәм мәк чәчәге, алсу чәчәк, ак чәчәкләргә охшатып карауны бик еш очратырга мөмкин:

Ян тәрәзә төпләрендә
Чәчәк атты төн гөлем,
Син сандугач, мин карлыгач,
Өметем син былбылым.

Яшь кызларның идеалы булган батыр егетләр бетмәс көчкә, куәткә ия, гаять гуманист табигатьле, гаделлек сөюче ир-егетләр булып сурәтләнәләр; чөнки халык яхшылык һәм явызлык төшенчәләренең чигендә көрәшеп килә. Ирлек, батырлык, сәләтне куркаклык, ялганлык кебек түбән сыйфатларга контраст куеп, аларның өстенлеген, дөреслекнең җиңүен тели. Халыкның лачындай егетләре һәр эпохада аның мактанычы һәм горурлыгы булып тора. Менә шуңа күрә дә яшь кызның намуслы йөрәк тибешендә лачын егет, батыр егет урын ала:

Җәйгә чыксам иркен сулап
Йөрим су буйларында.
Лачын кбек батыр егет
Син минем уйларымда.

Аерылышу сагышларын, кавышу шатлыкларын биргәндә дә халык үз тирәсендәге предмет һәм күренешләрне янәшә куеп карый, лирик геройның кичерешләрен, хисләрен гади күренешләр, күзәтүләр, чагыштырулар ярдәмендә күрсәтә:

Сандугачлар басып сайрап,
Сындырган гөлләремне
Сынган гөлләргә охшатам
Аерылган көннәремне.

Кеше үзенең уй-теләкләрен, кайгы-куанычын, сөю шатлыгын үтемле итеп, хисләргә манып, образлы итеп бирү сәләтенә ия. Лирик җырларда образлы сүз тезмәсе – чагыштыруларның төрле формалары халыкның шушы талантын ачып бирә дә инде. Еш очрый торган чагыштырулар ике буынлы була. Алар чагыштыргыч һәм чагыштырылмыш дип йөртелә. Икенче бер предмет яки күренеш белән чагыштырылучы әйбер чагыштырылмыш була, шул предмет яки күренешне чагыштыручы әйбер чагыштыргыч дип атала:

Сандугачлар идем бит илемдә,
Кайтсам сайрар идем бит илемдә;
Сандугач кебек сайрый-сайрый
Саргайдым бит йөргән җиремдә.

Биредә лирик герой – "мин" – чагыштырылмыш, сандугач – чагыштыргыч.

Гади чагыштырулар җырларда күп очрый. Алар тематикасы ягыннан бай һәм күптөрле. -дай,-дәй, -тай, -тәй кушымчалары гади чагыштырулар ясыйлар. Чыбыктай, лачындай сүзләре җырларда мәгънә төсмерен баетып, киңәйтеп җибәрәләр, нәфислек өстиләр.

Чагыштыруның төп кисәкләре - чагыштырылмыш һәм чагыштыргычны бәйләүдәге *кебек, төсле, шикелле, кук, гүя, сыман* һәм башка бәйлекләр әһәмиятле урын алып торалар. Гади чагыштырулардан аермалы буларак, катлаулы чагыштырылмышлар берничә кисәктән тора. Бер төп чагыштыру катлаулы фикернең ясалуын, эстетик фикерләүнең үсешен чагыштыра, билгели. Чагыштырулар хис, кичерешләрне тагын да тирәнәйтүгә хезмәт итәләр. Лирик геройның психологик дөньясын сурәтләүдә чагыштыруларның роле зур. Бәйлексез чагыштырулар да характерлы бер форма гына тәшкил итәләр. Мондый очракта чагыштырылмыш белән чагыштыргыч арасында бөтенлек мәгънә бәйләнеше ярдәмендә туа. Чагыштырулар башка троплар белән дә килергә мөмкин: метафоралар, метонимияләр. Чагыштырулар шулай ук шартлылык ярдәмендә дә ясалалар. Үзара бәйләнештә булган предмет яки күренешләрнең берсенең мәгънәсен икенчесенә күчерү төрлечә булырга мөмкин. Аның конкрет очраклары:

1. Эчке хәлне тышкы күренеш белән якынайту;
2. Предметка кеше портретын янәшә куеп карау;
3. Хәрәкәт белән аерым предметның үзара якынлыгы;
4. Хәрәкәт белән хисләрнең янәшәлеге.

Димәк, җырларның нигезендә чагыштыру ята дип карау хакыйкатькә туры килә. Чагыштырулар белән килгән җырларның үзенчәлеге

психологизмга бай булуында, эчке дөньяның зигзаглы хәрәкәтен, үзгәрешләрен гаҗәеп тирәнлек, нәфислек белән тасвир итүләрендә.

Татар халык җырлары – мәңгелек җырлар. Композиторларыбызның һәм шагыйрьләрнең халык иҗаты нигезендә туып, киң таралган җырлары халыкның җыр хәзинәсен баеталар, җыр мәдәниятенә уңай йогынты ясыйлар.

## ХӘЙ ВАХИТ ИҖАТЫНДА ТАБИГАТЬ ҺӘМ КЕШЕ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

*Камалова З., Буа р-ны, Түбән Наратбаш мәктәбе, Х сыйныф*
*Җит. – Шәрәфетдинова Л.Г.*

Кеше тормышы һәрвакытта табигать белән бәйле. Табигать темасы әдәбиятта мәңгелек тема, туган як, Ватан төшенчәләре белән бербөтен, аерылгысыз. Ул әсәрләрдә кеше образын тудыру өчен актив кулланыла.

Биектау төбәгеннән татар халкының мәшһүр әдипләре, шагыйрьләре, галимнәре һәм хезмәт сөйгән талантлы башка бик күп вәкилләре чыккан. Биектау төбәге Солтан Габәши, Әхмәтһади Максуди, Гали Мәхмүдов, Салих Сәйдәшев, Хәй Вахит, Рафис Корбан, Солтан Шәмси һ.б. бөек шәхесләрне биргән.

Бу хезмәтебездә язучыларыбыз әсәрләрендә пейзаж – табигать һәм кеше күңеленең бердәмлеге хакында язарга уйладык. Язучылар табигатьне үз күңелләре аша үткәреп, үзләре ничек кабул итә, шулай сурәтлиләр, ә әдәби геройлар шул табигать тасвиры нәтиҗәсендә ачыла. Әдәби әсәрләрдә тасвирлау формалары бик күп. Пейзаж шуның бер төре булып тора, һәм әсәрдә ул тирән мәгънә эчтәлегенә ия. Әсәрләрендә язучылар туган авыллары, андагы кадерле авылдашлары хакында шул кадәр җан җылысы белән, өзелеп сагыну хисләрен табигать күренешләре аша бәйләп бирәләр.Әйтерсең табигать үзе дә сагына бу авылдашларны. Безнең йөрәккә әнә шуңа бик көчле тәэсир итә ул сагыну хисе. Язучылар гаҗәеп зур осталык белән шуны укучыга җиткерә белгәне өчен дә аеруча яратып укыйбыз без аларның иҗатын.

Эшебезнең максаты – язучыбыз Хәй Вахит әсәрләрендә кеше һәм табигать мөнәсәбәтләрен ачыклау.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

1) язучыбыз әсәрендә пейзажның ролен ачыклау;
2) укучыларны фәнни-тикшеренү эшләренә җәлеп итү;
3) туган төбәк әдипләренә кызыксынуларын арттыру.

Җирле шагыйрьләребезнең иҗатын барлау, өйрәнү, алар белән әдәби кичәләр үткәрү әдәбиятны тирәнәйтеп өйрәнүгә ярдәм итә.

Аларның иҗатында тирә-юнь гүзәллеген ачучы әсәрләр зур урын алып тора. Табигать темасы әдәбиятта мәңгелек тема, туган як, Ватан төшенчәләре белән бербөтен, аерылгысыз. Ул әсәрләрдә кеше образын тудыру өчен актив кулланыла. Биредә кеше табигатьнең бер өлеше итеп карала, аның холык-фигыле һәм эчке халәте табигатьтәге үзгәрешләр аша күрсәтелә.

Кеше табигатьтән башка яши алмый. Табигатькә чыгып, без ял итәбез, кошлар җырын тыңлыйбыз, хуш исле үләннәр, чәчәкләр иснибез, күңелләребезне сафландырабыз.

Әсәрләрендә Х. Вахит туган авылы, андагы кадерле авылдашлары хакында шул кадәр җан җылысы белән, өзелеп сагыну хисләрен табигать күренешләре аша бәйләп бирә. Әйтерсең табигать үзе дә сагына бу авылдашларны. Безнең йөрәккә әнә шуңа бик көчле тәэсир итә ул сагыну хисе. Язучы гаҗәеп зур осталык белән шуны укучыга җиткерә белгәне өчен дә аеруча яратып укыйбыз без аның иҗатын.

Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле. Хәй Вахит күп кенә әсәрләрендә табигатьне саклау – милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, рухи һәм тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки туган тел, әдәби һәм тарихи мирас газиз җиребездә барлыкка килгән. Шуңа күрә балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Х.Вахит үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган әсәрләре белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче.

Үзенең драматургик иҗатын асылда яшьлек темасын яктыртудан башлаган Х.Вахит бу темага алга таба да турылыклы булып кала һәм аның төрле якларын һәм мәсьәләләрен гәүдәләндерә. Моңа мисал итеп аның тагын «Соңгы хат» (1966) һәм «Туй алдыннан» (1969) драмаларын китерергә була. Бу әсәрләрдә яшьлек темасының аерылгысыз бер өлешен тәшкил иткән дуслык һәм иптәшлек мәсьәләсе, табигать чагылыш таба.

“Яз! Яз галәмәте! Бар нәрсә уяна, терелә, бөреләнә. Иҗат итә. Шулай, йөрәкләр дә уяна. Хисләр кабына. Хәерлегә булсын.

Яз айлары, яз айлары
Яшелләтә кырларны.
Яз айлары хәтерләтә
Онытылган җырларны...

диләр бит җырда да (“Туй алдыннан”).

Яңгыр, чык, кырау, буран, җил, кояш, ай, яз, көз, җәй, кышның – һәрберсенең үзенчәлекле билгеләре турында шигъри ачышлар ясап, укучы күңеленә җиткерә.Х. Вахит табигатькә, укучыны дөньяга гаҗәпләнеп карарга, матурлыкны күрә белергә өйрәтә.

Әсәрләреннән күренгәнчә, Х.Вахит нинди генә темага алынса да, аны ныклы өйрәнеп, ягъни үзен чолгап алган дөньяны, гомумән, тормышны өйрәнеп, бигрәк тә табигать күренешләренә мөрәҗәгать итеп, шулар аша кеше күңеле, кичерешләре белән бәйле хәл-вакыйгаларны сурәтләргә, гади генә шул хәл-вакыйгаларга олы мәгънә салырга ярата.

Туган җир табигате турында кайгырту – үз балаларыбызның һәм оныкларыбызның киләчәге турында кайгырту ул. Шуңа күрә кешенең кул хезмәте белән тудырылган бу хозурлыкны саклау өчен барыбыз да тырышсак, чишмә тирәләрен чистарту өмәләрендә катнашсак иде. Әйләнә-тирә табигатькә сак мөнәсәбәт безнең яшәү рәвешенә әйләнсен иде.

## МИРЗА МӘХМҮТОВ – КҮПКЫРЛЫ ГАЛИМ

*Корбанова Р., Казан, 184 нче мәктәп, X сыйныф*
*Җит. – Хафизова И.М., Әхмәтова Г.А., Җиһангирова А.Х.*

Без укый торган 184 нче мәктәп Казан шәһәренең Совет районында урнашкан. 2018 нче елда гына ачылган бу яңа мәктәп Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов исемен йөртә. Тарихка кереп калырлык әлеге тантаналы линейкада мин дә катнаштым. Белем бәйрәменә килгән кунаклар Мирза Мәхмүтовның күренекле шәхес булуы һәм мәгариф өлкәсендә күп хезмәтләр куюы турында бәян иттеләр. Тормыш иптәше Диләрә апа Мансуровна аның күпкырлы эш алып баруы, Татарстанда гына түгел Рәсәйдә, хәтта дөньякүләм масштабта билгеле галим булуы турында да әйтеп китте.

Чыннан да, кем булган соң ул Мирза Мәхмүтов? Мәгариф өткәсенә нинди яңалык алып килгән, нинди фәнни хезмәтләре бар? Ни өчен мәктәпкә аның исеме бирелгән? Бу сорауларга җавап табу теләге төрле эзләнүләргә этәрде.

Мирза Мәхмүтов – көнчыгышны өйрәнү белгече, СССРның педагогика фәннәре академиясе академигы, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, педагогика фәннәре докторы, профессор. Көнчыгыш телләр лексикологиясе өлкәсендәге хезмәтләре белән танылган, гомуми белем һәм профессиональ мәктәптә проблемалы укыту теориясен һәм практикасын эшкәртүче галим. Аның «Хәзерге дәрес» (М.,1985) дигән монографиясе Н. Крупская исемендәге премиягә лаек була, 500 дән артык фәнни хезмәте дөнья күрә.

М. Мәхмүтов 43 фән кандидатын һәм 11 фән докторын әзерләп тәрбияләп үстерә. ЮНЕСКОда 13 ел буена дөньяда укый-яза белмәүне бетерү буенча халыкара комитет әгъзасы, эксперт булып тора. 1996 елда фән өлкәсендә Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты була. Ул Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм Октябрь Революциясе орденнары, шулай ук төрле медальләр белән бүләкләнә. Аның исеме «Россиянең таныклы кешеләре» дигән энциклопедиягә керә һәм 2005 нче елны М.И. Мәхмүтов Россия буенча «Ел кешесе» булып таныла.

Милли тәрбия бирү, милли мәктәпләрне саклап калу өлкәсендә дә зур эшләр алып бара. Хәтта гаепләнүләргә дә дучар була. Арчада татар мәктәбендә укучы балаларның ата-аналары өлкән классларны русча укытуга күчерүне таләп итеп Мәскәүгә, партия Үзәк Комитетына «Министр Мәхмүтов балаларны русча укытудан тыйды», дип 5-6 телеграмма җибәрә. Мирза Мәхмүтовны Мәскәүдә бөтен дөнья теле булачак рус теленең ролен түбәнсетүдә «гаеплиләр». Ләкин ул үз кыйбласын югалтмый. Эш барышында, моңа дәлил булырлык кызыклы гына һәм көтелмәгән бер мәгълүматка тап булдык. Укытучым Әхмәтова Гөлнара Ахкәм кызының әнисе Рәхилә апа Җәләловага министр Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов белән очрашу насыйп булган икән. Бу хәл 1964 нче елда Балык Бистәсенең Котлы Бөкәш урта мәктәбендә була. 9 нчы рус сыйныфына укырга килгән укучылар алдында чыгыш ясаган министр: ”Рус мәктәбендә укыйм дип, татар телен онытмагыз! Татар телен белү – нур өстенә нур ул!” – дип, яшь буынга үзенең фатихасын бирә.

Әлеге сүзләр, Россиянең мактау грамотасына лаек булган, 43 ел подагогик хезмәт юлы үткән рус теле укытучысы Рәхилә апа Хасимовна күңелендә тирән эз калдыра! Шулай булмаса, бүгенге көнгә кадәр – 54 ел буена, ул аларны сүзен сүзгә күңел түрендә саклар идеме икән?

Татарстанда Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтовның исемен мәңгеләштерү буенча да эшләр алып барыла:

2018 нче елда Казан шәһәре Совет районында ачылган без укый торган яңа 184 нче мәктәп аның исемен йөртә;

2017 елда М.И.Мәхмүтов исемендәге Татарстан дәүләт премиясе булдырыла;

2016 нчы елда Алабуга педагогика институтында М.И.Мәхмүтов музее ачыла, алтынчы мәртәбә Мәхмүтов укулары уздырыла;

КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институтында М.И.Мәхмүтов музее ачыла;

“Сәләт” яшьләр оешмасының ике проекты: “Фәнсар” мәктәбе һәм "Фәнсар" мәктәбенең Республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе Мирза Мәхмүтов исемен йөртә.

Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтовның фәнни хезмәтләрен, тормыш һәм иҗади юлын барлап чykkaннан соң гаҗәпкә калдым: шушы кадәр эшне бары тик бер кеше генә башкарганмы? Мәктәпкә ни өчен Мәхмүтов исеме бирелүе миңа ачык аңлашылды: соравыма җавап табылды. Күңелемдә соклану һәм горурлык хисләре туды. Бу хисне мәктәбебезнең һәр укучысы да кичерсен иде.

**Әдәбият**


1. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре / К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сәйфуллин. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1965. – 792 б. (гарәп грамматикасы өлеше)
2. https://ziteli.info/kazan
3. http://selet.biz/tat/projects/proekty-2015-2016/f-nsar-m-kt-be/


## ТЕМА РОДНОГО КРАЯ В ТВОРЧЕСТВЕ РИФАТА САЛАХА


*Козлова Ж., Буинский р-он, Больше-Фроловская школа, X класс*

*Рук. – Исмагилова Г.Т.*


Родной край – понятие очень широкое. Через всю жизнь люди проносят любовь к родному краю. С особым чувством они относятся к тем местам, где родились, где протекало их детство и юность, где проходят годы сознательной жизни.

Многообразна жизнь родного края. В родном краю все важно: и события общественной, хозяйственной и культурной жизни, и благородные дела, поступки и успехи земляков, и окружающая природа. Она полна очарования не только сама по себе. Она колыбель человеческих судеб и деяний. Это она, природа Буинска, вдохновляла Р.Хариса, А.Рашита, Р.Салаха, Г.Айзетуллову, Б. Урманче.

Рифата Салаха знаем не только как автора множества произведений, но и как бессменного члена жюри Независимой литературной премии «Глаголица».

Как и мы, когда-то Рифат Салах изучал родной язык, литературу, писал сочинения, участвовал в олимпиадах и занимался в литературном кружке. С детства шел к своей мечте, – стать писателем, и исполнил ее! Теперь у него множество читателей, не только в Татарстане и России, но и за рубежом.

Рифат Салах – татарский поэт. Родился он 8 июля 1987 года в деревне Яңа Чәчкап (Новые Чечкабы) Буинского района в семье

учителя. В 2004 году закончил с отличием школу. В 2004-2009 годы учился на юридическом факультете Казанского государственного университета.

В творчестве Рифата Салаха особое место занимает образ родного края. Во многих произведениях можно заметить бережное, осторожное отношение к родному краю. Автор всегда подчеркивает: «туган җир», «туган як» или «Чәчкабым».

Туган авылым, Яңа Чәчкап,
Гөрләп торасың микән?
Чит җирләргә чыгып киткәч,
Сагындырасың икән.
Бик сагындым, туган авылым,
Ямьле Лашчы буйларын.
Еракка китеп барсам да,
Һәрчак синдә уйларым.
Уңган-булган халкың белән
Җиһанга нур чәч тагын!
Син һәрвакыт күңелләрдә, –
Җырга көчтең, Чәчкабым. (Стихотворение “Яңа Чәчкап”)

Для Рифата Салаха родной край – это «вдохновление», «могущество», «гордость».

Сиңа кайттым әле, сагынылган.
Болыныңа чыктым кичкырын.
Мин яратам сине, туган ягым,
Бик яратам, диеп кычкырдым.
Кемдер, бәлки, ишеткәндер мине...
Миңа җитә, үзең ишетсәң.
Туган ягым, мин тирбәлеп ятам
Күккә элгән яшел бишеккә.
(Стихотворение “Туган авылыма”)

Его творчество пронизано любовью к родной школе.

Хуш, мәктәбем, сау бул, туган йортым!
Хушлашуы авыр бигрәк тә.
Бүтән кайтмасак та бу елларга,
Хатирәләр калыр йөрәктә.
Һәр дәреснең алтын булганлыгын
Хушлашканда гына аңлыйбыз,
Бәхетле һәм гүзәл мизгелләрне
Тик кайтарып ала алмыйбыз.
(Стихотворение  “Хуш, мәктәбем”)

Стихи Рифата Салаха переведены на русский язык.

**Родной земле**

Я спешу за рассветом, ища красоты –
Лишь полынь, да репейника заросль.
Мои алые, лучшие в мире цветы
Отцвели и вдали потерялись.
Там, где ягоды зрели, дорога пылит,
А вокруг только тени и тени.
Потерявшее родину сердце болит
И не может найти утешенья.
Где лекарство сыскать, чтобы боль одолеть? –
Сколько снадобий в мире – увы, но
Ни одно не спасёт от тоски по земле,
Куда капала кровь пуповины. (Перевод Галины Булатовой)

Таким образом, мы убедились, что концепт «родной край» играет немаловажную роль в творчестве Р.Салаха.

## ТАТАРСТАН СПОРТ КОМАНДАЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ-МӘДӘНИ НИГЕЗЕН ТӘШКИЛ ИТҮЧЕ СИМВОЛЛАР

*Заһретдинова А., Идел буе дәүләт физик тәрбия, спорт һәм туризм академиясе, I курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Мотигуллина Ә.Р.*

Милли мәдәният кеше тормышының төрле өлкәләренә үтеп керә. Ул тормыш-яшәешне чагылдырып, фәнни тәгълиматны ачучы фәлсәфә, тарих, политология, этнология, психология, икътисад, педагогика, сәнгать, лингвистика (этнолингвистика) һ.б. өлкәләрне яктырта. Мәдәният, сәнгать өлкәсе безнең яшәешебезнең аерылмас өлкәсе булган спорт дөньясын да читләтеп үтми. Спортның сәнгать юнәлешендәге төрләре булып бию (акробатик рокн-н-ролл), фигуралы шуу, нәфис гимнастиканы кертә алсак, Татарстанда киң таралган күмәк спорт төрләре хоккей, футбол, баскетбол да киенү, аерым тамгаларны ясаганда сәнгатькә мөрәҗәгать итә. Бу спорт төрләренең символикасы тарихына күз салсак, бик күп кызыклы фактларга юлыгабыз.

Нәфис гимнастика, фигуралы шуу осталарының махсус тамгаларын Олимпия уеннарында, чемпионатларда бүләкләү вакытында гына күрәбез. Ә менә Татарстанның футбол, баскетбол, хоккей командалары даими рәвештә аерым логотиплар, эмблемалар белән чуарланган, фамилияләре язылган махсус киемнәр белән чыгыш ясыйлар.

Татарстандагы хоккей төркемнәренең эмблемалар тарихы белән хронологик тәртиптә танышып китик. Беренче команда 1956 елда Казанда “Машстрой” исеме белән барлыкка килә. Ул вакытта

төркемнең махсус киемнәре булмаган, ләкин сызыклы свитер һәм әлеге шлем урынына башлык (шапка) кия торган булганнар. Ә 1980 елларда хоккей командасы зур эмблемалар куллана башлый, аларны кием өстендә “канатлы” трафарет белән ясаганнар.

Менә 1987 елдан төркемнең символы булып дракон – Зилант калкып чыга. Хоккейчы җилкәсендә Казан Кремле (бигрәк тә Сөембикә манарасы) урын алып тора. 1990 елда хоккей клубы исемен үзгәрткәч тә, элекке символлар сакланып кала һәм әлеге формаларда уен дәвам иттерелә. 1995 елдан башлап “Ак Барс” клубының символы “Зилант” түгел, ә ак барс була.

Англиялеләрдән килеп кергән футбол уены Татарстанда да киң тарала. Алай гына да түгел бүгенге көндә үз исемен күптөрле ярышларда, чемпионатларда фидәкарь уены белән яулаган футбол командасы “Рубин” бар. Күп кенә җанатарларның күңелен яулап алган команда Советлар Союзы вакытында төрле төсле формада чыгыш ясап килә: чиста актан алып сары-көрән, зәңгәр һәм кара төсләргә кадәр. Әмма һәрвакыт төркем формасы төсендә кызыл яки караңгы-кызыл (Рубин) төс өстенлек итә.

Төркем беренче тапкыр футбол кырына «Рубин» язуы белән 1965 елда, клубның исеме үзгәргән елда чыга. Төркем майкаларында эмблема соңрак пәйдә була. 1970 елда команда символына ракета рәсемен «Спортклуб Рубин» язуы белән каймап алалар. Футбол клубы СССР таркалганчыга кадәр әлеге символ астында чыгыш ясый.

1996 елда эмблема Казан рәссамы В.Петров тарафыннан эшләнгән яңа формага ия була. Логотип «РУБИН» дигән традицион язулы калкан, үзәктә Зилант Драконы рәсеме, Татарстан флагы һәм «Футбол клубы. Казан. 1958» була.

2012 елның урталарында Казан дизайнеры А.Сәлмәнова яңа логотипны латин графикасында язылган каноник геральдик калкан рәвешендә эшләгән, команданың төп төсләрен саклап калган һәм төп график элемент сыйфатында Зилант сурәтен урнаштырган.

2013 елның июлендә «Рубин» эмблемасы астында яңа логотип тәкъдим ителә, көнчыгыштан көнбатышка таба – Зилант Драконы, эчендә – рубин ташы, ә тирә-юнендә – «1958 РУБИН Казан»рус телендә язылган. Логотипны булдыру белән "Interbrand" Италия компаниясе шөгыльләнә.

2014-2015 сезонында команда, традицион Рубин комплекты белән бергә, берничә матчта кара-алтын төсендәге формада уйнады. Җанатарларның фикерен исәпкә алып, соңгы исәптә команда классик экипировкага әйләнеп кайтты.

2016 елның 24 июлендә "Рубин" яңа эмблеманы тәкъдим итте. Ул Sellout Sport System компаниясе һәм танылган Казан арт-директоры Артем Ермолаев тарафыннан эшләнгән. Яңа логотип команданың беренче тарихи эмблемасын, 1996 елгы эмблемасын, клубның иң мөһим казанышларын, шулай ук командага нигез салыну вакытындагы классик футбол тубын үз эченә ала.

Хәзерге вакытта логотип якты яки кара фонда булу-булмауга карамастан, Зилант ак төстә калды. Ак төс, чисталык символы буларак, гадел һәм тәртипле булуны, үз-үзеңне тоту принципларын үтәү мөһимлеге турында сөйли.

Логотипның Рубин төсе – төп һәм бердәнбер. Рубин төсе клубның исеме белән бәйле. Төснең мондый концепциясе тулысынча клуб җанатарлары карашларын хуплый, алар үзләрен «Рубин»дип атый.

Тагын бер логотипның төсе – яшел. Мондый төс рубин төсе белән бик килешеп тора. Әлбәттә бу төсләр уенчыларның формаларында, клуб атрибутикасында һәм сувенирларында кулланыла.

Шул рәвешле, Татарстандагы спорт командалары милли-мәдәни символларга бай. Бигрәк тә футбол һәм хоккей командаларының эмблемалары һәм логотипларының тарихы ерак гасырларга барып тоташа. Шуңа күрә дә дәүләт символларын хөрмәт итәргә, аларны кадерләп сакларга кирәк.

**Әдәбият**


1. Макаров Д.А. Рубин (Казан): тарих һәм статистика 1958-2000. – Казан: РИЦ «Титул», 2001. – 224 б.
2. Харисов Р.М. Татарстан символлары. – Казан.: Мәгариф, 2005. – 62 б.
3. Интернет ссылка: https://ru.wikipedia.org/wiki/Рубин_(футбольный_клуб)
4. Интернет ссылка: https://www.sports.ru/tribuna/blogs/hockey_logos/545053.html


## РӘДИФ СӘГЪДИ ДРАМАТУРГИЯСЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ
## (“Гүзәл Аппаксылу” җыентыгы буенча)


*Зәйдуллина А., КФУ, II курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Минһаҗева Л.И.*


Рәдиф Сәгъди – бүгенге татар әдәбиятын милли рухтагы әсәрләр белән баеткан, балалар әдәбиятына зур үсеш керткән әдипләребезнең берсе. Аның драматургиясе үзенчәлекле: ул балаларны кызык, мәзәк сүз белән, шаян маҗара белән генә мавыктырмый, ә бәлки милләт язымышы, милләт тарихы, мифологиясе, тарихы белән бәйләнгән серле дөньяга алып керә. Бу дөнья – кызыклы булса да, балалар дөньясы кануннары буенча гына түгел, кырыс чынбарлык кануннары буенча яши.

Хезмәтнең максаты – Р. Сәгъдинең балалар драматургиясенең конфликт үзенчәлекләрен билгеләү ("Гүзәл Аппаксылу" җыентыгы мисалында).

Хезмәтнең фәнни-теоретик нигезләрен драматургия теориясен һәм татар әдәбият фәнендә Рәдиф Сәгъдинең иҗаты өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләре (Ә. Закирҗанов, Д. Гыйммранова, Р. Хәмид, Р. Зәйдулла) тәшкил итә.

Рәдиф Сәгъдинең тикшерү объекты итеп алган "Гүзәл Аппаксылу" җыентыгын конфликт үзенчәлегенә бәйле анализлап, түбәндәге нәтиҗәләргә килдек.

Рәдиф Сәгъдинең балалар драматургиясендә җитди проблемалар күтәрелә, автор балаларга экиятләрдән, мифлардан, легендалардан яхшы таныш образларга мөрәҗәгать итә, әмма алар аркылы замана проблемаларына да кагыла. Ул иҗат иткән балалар әдәбияты дөньясы шактый катлаулы, чөнки олылар тормышындагы мәрхәмәтсез уеннар, олылар дөньясындагы нәзәкәтле проблемалар бу дөньяга да кагылган. Рәдиф Сәгъди артист булганлыктан, шушы өлкәдә шактый эшләп тәҗрибә туплаган кеше буларак, ул сәхнә кануннарын яхшы белә. Драматургның сәхнәгә куелган әсәрләреннән "Гүзәл Аппаксылу" (Казан Яшьләр театрында куела) пьесасын да атарга мөмкин. Соңрак әдип олылар әдәбиятына караган детектив, фантастик әсәрләр дә иҗат итә, әмма балалар драматургиясе дә иҗатының гүзәл өлеше, әдәби хәзинәбез буларак яшәвен дәвам итә. "Рәдиф Сәгъди бүгенге көнгә күчерә, гади генә бер сюжет төзеп, вакыйгаларга тарих күзлеге һәм юмор күзлеге аша карый – чорыбызның рухи халәтен сурәтли. Бу пьесада әхлакый, тәрбия мәсьәләләре күтәрелә, балаларга әйбәт акыл бирелә" [1: 128]. Бу сүзләрне "Гүзәл Аппаксылу" пьесасына гына карата түгел, шул исемдәге җыентыкка кергән һәр әсәргә карата әйтергә мөмкиндер. "Соңгы Шүрәле" әсәрендә экологик проблема күтәрелә; "Гүзәл Аппаксылу" пьесасы чын һәм ялган матурлык көрәше турында бәян итә; "Алсу томан" моңсу драмасы XX гасырының икенче яртысындагы фиҗигаләр, әхлаксызлык арту турында бәян итә, әлеге әсәрдә сурәтләнгәннәрнең күбесе бүгенге көндә дә актуаль яңгырый. "Гүзәл Аппаксылу" дип аталган пьесалар җыентыгы тулаем яшүсмерләргә, сабыйлык хисләрен җуеп өлгермәгән, әмма өлкәннәрчә фәлсәфә кору белүче балаларга атап язган" [3: 5].

Рәдиф Сәгъдинең балалар өчен иҗаты күбрәк халык иҗаты белән тыгыз бәйләнгән. Драмаларда шүрәле, дию, образлары еш очрый. Автор балаларга түбән мифологик зат яки кара персонаж итеп кенә тәкъдим итми, халык ышануларына таяна. Габдулла Тукай әсәрләрендә тискәре герой Шүрәле уңай яктан ачыла. Драматургның экият-

тамашалары нигезендә кечерәк, башлангыч яисә урта мәктәптә укый башлаган укучыларга адреслана. Шундыйлардан “Могҗизалы Яңа ел”, “Иске курчакларда Яңа ел” кебекләрне атарга була. Биредә геройлар буларак Кыш бабай, Кар кызы, Барби һ.б.лар атала. Мондый әсәрләрдә каршы көч катнашмый. Иске курчаклар кирәксез балласт хәлендә калганнар. Әмма автор чарасызлык аркасында килгән таркаулыкны инкарь итә: курчаклар Казбикә белән оста Клоун ярдәмендә үзләре өчен гаҗәеп шоу оештыралар. Тамаша беткәндә конфликт беткән була инде, алар кеше кулында уенчык булуга караганда, үз язмышың өчен җаваплылыкны үзеңә алуның әһәмиятен аңлыйлар, әле кайчан гына үзен кирәксез тойган, ә асылда һәркайсы нинди дә булса талантка ия булган курчаклар сәләтләрен бар дөньяга күрсәтергә әзер торалар.

Балалар драматургиясе булуга карамастан, автор үлем образын, үлем белән бәйле мотивлар белән еш эш итә. Шул ук вакытта болар – замана балалары телевидениедән күрергә күнеккән мәгънәсез үлемнәр, үтерешләр түгел. Һәр үлем ниндидер хакыйкатьне ачыклау өчен хезмәт итә. Бу яктан драматургның “Ана күңеле балада...” әсәре дә игътибарга лаек. Легенда буенча, егет, сөйгәненең теләген үтәү максаты белән, анасын үтерә һәм йөрәген шул сөйгәненә бүләк итәргә җыена. Ашыгып барган чагында, егет абынып егыла, шул вакытта аның кулындагы йөрәк телгә килә: “Авыртмадымы, улым?”. Пьесада да охшаш күренеш.

Рәдиф Сәгъди драмаларында конфликт явызлык белән каршылык арасында бара. “Соңгы Шүрәле”, “Гүзәл Аппаксылу” кебек әсәрләрдә бу аеруча ачык чагыла. “Ана күңеле балада...” пьесасында ул геройның эчке каршылыгы белән дә катлауландырыла, әмма Бәбкәч эчендәге изгелек, намус сүзенә игътибар итмичә, сихер капкынына эләгә, аны Ана һәм сөйгәненең мәхәббәте генә коткарып кала. “Кыргын” пьесасында конфликт шактый катлаулы: ил, халык һәм милләт алдындагы бурычмы яисә саф мәхәббәт җиңә аламы? Авторның моңа катгый гына җавабы юк. Ул да, укучы да каршылык, көрәш артыннан читтән күзәтеп тора. Драмада фаҗигале мотивлар яңгыраш ала: гашыйк булган җаннарның берсе үләт чиреннән, икенчесе – кануннарны бозып, үләт вакытында илдән чыгып китеп йөргән өчен уктан атып үтерелә, үләт авырулы кеше янында булучы һәркем – ыру өчен куркыныч чыганагы санала. Шулай да ыру ярдәмчесез калмый, озак сугыштан соң би дә өенә кайтып җитә. Ә менә Рәдиф Сәгъдинең тамаша жанрына караган әсәрләрендә конфликт катлаулы түгел, гомумән ике як көрәше күренми диярлек. Беркадәр үпкәләүләр бар, әмма алар җиңел хәл ителә.

**Әдәбият**

1. Гыймранова Д. Театрга гашыйк булыгыз! // Казан утлары. – 2003. – №2. – Б.

124-129.
2. Сәгъди Р. Гүзәл Аппаксылу: пьесалар, әкият-пьесалар, әкият. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 287 б.
3. Хәмид Р. Мәчесе дә җыр чыгара // Сәгъди Р. Гүзәл Аппаксылу: пьесалар, әкият-пьесалар, әкият. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 5-7.

## ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ФӘННИ-ТЕХНИК ҮСЕШ

*Ибраева З., Казан элемтә техникумы, I курс студенты*
*Җит. – Шириева Г.М.*

Белгәнебезчә, телебезнең киләчәк графикасын билгеләүче аерым бер символлар системасы тел дип йөртелә. Һәр тел үзенә генә хас булган тарихка ия, чөнки ул халыкның борынгы заманнан алып хәзерге көнгә кадәр сакланган зур бер хәзинәсе.

Элек-электән үк инде тел җәмгыять белән бәйле үсештә карала. Аралашу, мөгамәлә кору, мәгълүмат туплау һәм тарату ихтыяҗы булмаса, тел дә үсә алмас иде. Ләкин җәмгыятьтә төрле үзгәрешләр кичерелү сәбәпле, тел дә үзгәрә, өр-яңа сүзләр яшәешебездә шактый урын ала, бигрәк тә соңгы гасыр читтән килеп кергән сүзләргә бай. Димәк, тел, мәдәният һәм җәмгыять төшенчәләре аерылгысыз. Тел – яшәешнең бөтен байлыгын үзенә ала, мәдәниятны да без тел ярдәмендә тарихка кертәбез. Юкка гына телне социаль үсешнең барометры, дип әйтмиләр.

Туган телебез бай, матур, һәркемгә якын, моңлы булуына карамастан, көннән-көн яңа сүзләр кулланабыз, чөнки без фәнни-техник үзгәрешләрнең алга киткән чор шаһитлары. Заман алга барган саен көнкүрешебездә әһәмиятле урынны заманча технологияләрнең берсе булган компьютерлар технологиясе алып тора. Яшәешебезнең тарихында үзгәрешләр төрлечә чагылыш таба: һәр тармак үзенә хас булган аерым сүзләр булдыра. Бүген бер генә белгечлекне дә аннан башка күз алдына китереп булмый.

Язучы М.Колесников фикеренчә: «Без булачак эшченең яңа социаль төренең формалашуын күзәтәбез. Матур әдәбият һәм инженер фикерләү кысаларында яңа поэтика формалаша, ягъни бернинди чикләүләрсез сөйләмгә «сәнәгать лексикасы» килеп керә».

Шәхсән мин үзем Казан шәһәренең элемтә техникумында веб-мультимедия кушымталар эшләүче белгечлек буенча белем алам, шуңа күрә элеге тармакка бәйле сүзләрне карап китәсем килә.

Әлеге белгечләр эшләрендә текст, график, мультипликация, рәсем ясау, тавыш һәм видеоматериалларны, шулай ук башка интерактив чараларны берләштергән веб сайтларны һәм кушымталарны тикшерә, анализлау, бәяләү, проектлау,

программалаштыру һәм үзгәртү өчен дизайнер һәм техник белемнәрен берләштерә. Шуңа күрә читтә барлыкка килгән яңа техник әсбаплар, алар белән бәйле яңа сүзләргә игътибар итми һич мөмкин түгел.

Мәсәлән, әлеге һөнәргә турыдан-туры бәйле булган инглиз теленнән килеп кергән веб, веб-сайт, контент, дизайн, мультимедия һәм башка татар һәм рус эквивленты булмаган еш кулланыла торган сүзләр әһәмиятле урын алып тора. Алар барлык чит телләрдә дә киң таралган, шушы өлкә белгечләренә генә түгел, барлык аралашучыларга да билгеле булган төшенчәне белдерә, хәтта сүзтезмәне яисә җөмләне алыштырырлык, элек телдә булмаган төшенчәне ачыклаучы бердәнбер исемнәр. Шуңа күрә мондый сүзләр әүвәлгечә, үзгәрешсеш кулланыла.

Мисал өчен, веб-сайт сүзенә якыннанрак игътибар итсәк, ул веб-дизайн, бит макетын әзерләү, программалаштыру, конфигурацияләү һ.б. төшенчәләрне үз эченә ала. Димәк, мондый сүзләр фәнни-техник терминология эшенең асылын төгәлрәк чагылдыра һәм һөнәрнең абруен күтәрүгә ярдәм итә. Бу сүзләрне алыштыру, тәрҗемә итү мәгънәсез.

Ләкин замана үзгәрүе киң адымнар белән алга бара. Киләчәктә компьютер читтән торып кеше ирененнән укырга өйрәнер, дигән фикерләр дә йөртәләр. В.С.Стрелецкий тикшеренүләре нигезендә, 22 нче гасырда кеше аңы, телепатик техника һәм виртуаль чынбарлык симбиозына юл ачучы «Теленет» катлаулы телепатик челтәр булдырылачак. Һәркем планетаның теләсә кайсы кешесе, Ай һәм җирдәге сәнәгать орбиталы комплекслары белән аралаша алачак, шулай ук кешелекнең теләсә нинди мәгълүмат ресурсларына тоташа алачак.

Димәк, сүзләрнең телдән телгә күчү мөмкинлекләре тагын да артачак. Бәлки, туган татар телебез дә бөтенләй икенче яктан үзенең кирәклеген исбатлар. Мәсәлән, сайтлар, кушымталар әзерләгәндә IT белгечләре программалаштыру теле буларак татар теленә дә игътибар итми калмаслар, чөнки сөйләм барышында гына түгел, мондый текст өстендә эшләгән вакытта та лингвистик чараларны саклау принцибы өстенлек ала. Татар теле агглютинатив тел буларак әлеге кысалар эчендә яши, кирәкле мәгълүматны туплау, саклау, җиткерү барышында күпкә аз вакыт сарыф ителә, мәгълүмат йөртүче җайланмаларда да күләм шактый кыскара. Димәк, саф татар сүзләре чит телләргә үтеп керер, дигән фаразлар күңелемне били һәм горурлык өсти.

Сер түгел, бүгенге көн – төрле роботлар заманы. Бәлки, киләчәктә нәкъ алар телнең нык үзгәрүенә дә төп сәбәпче булыр. Бу исә алда карап үткән фаразларның урынлы икәнлегенә дә дәлил.

Республикабызда соңгы елларда WordlSkills хәрәкәте нык үсеш ала. Әлеге юнәлештә элемтә техникумы студентлары да үз элешләрен кертә, уку йортыбызның абруен арттыра. Төрле чемпионатларда

катнашып мактаулы урыннар яулыйлар. Димәк, киләчәктә яңа ачышлар чит ил, чит телләр белән генә бәйле булмас. Яңа үрләр яулау нәтиҗәсендә телебез дә киң таралыш табар.

Ләкин монда икенче җитди сорау барлыкка килә: телләр үзенең милли чикләрен, үзенчәлекләрен югалтмасмы? Лингвист К.С. Горбачевич моңа болай җавап бирә: «Техник алгарыш яңа тел барлыкка китерми. Терминнарның үтеп керүе һәм халыкара кулланылыш тапкан сүзләрнең артуы милли чикләрне юкка чыгармый», – дип яза [1: 79].


**Әдәбият**

1. Горбачевич К.С. Русский язык. Прошлое. Настоящее. Будущее. – М., 1984. – 108 с.
2. https://cont.ws/@slavikapple/1270417
3. http://genling.ru/books/item/f00/s00/z0000021/st002.shtml


## УКУЧЫЛАРНЫ АРАЛАШУГА ӨЙРӘТҮ ЧАРАСЫ БУЛАРАК СӨЙЛӘМ СИТУАЦИЯСЕ


*Ибраһимова Э., КФУ, IV курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Галиуллина Г.Р.*


Сөйләм теле кешелек җәмгыятендә әһәмиятле урын биләп тора. Аның төп вазифасы буларак кешеләрнең көндәлек аралашуын тәэмин итүне билгелиләр. Кодификацияләнгән әдәби телдән аермалы буларак, ул барлыкккa килүе һәм кулланылышы ягыннан беренчел санала. Шуның өчен телдә барлыкка килгән үзгәрешләр, беренче чиратта, сөйләм телендә урын ала [1: 28-29]. Аралашуның гадәти шартларында әзерлексез башкарылган, стильара лексикадан бераз түбән стильдә саналган сүзләр сөйләм теле лексикасын тәшкил итәләр. Сөйләм теле тотрыклылыкка, диалекттан өстен булуга, күп функциональлек үзенчәлекләренә ия.

Хәзерге методистлар сөйләм ситуацияләренең берничә тибын аералар, әмма бүгенге көнгәчә аларның универсаль типологиясе эшләнелмәгән. Сөйләм ситуацияләренең фәндә булган классификацияләренә игътибар юнәлтик.

Е.И. Пассов һәм А.М. Стояновский ситуация типларын коммуникантлар арасындагы үзара мөнәсәбәтләр төреннән чыгып аералар [2: 18-22]. Әлеге галимнәр фикеренчә, теләсә кайсы ситуациянең төп компоненты булып үзара мөнәсәбәтләр тора. Авторлар тарафыннан түбәндәгеләр аерыла:

1) социаль статуска бәйле үзара мөнәсәбәтләр ситуацияләре;
2) рольле үзара мөнәсәбәт ситуацияләре;
3) эшчәнлекле үзара мөнәсәбәт ситуацияләре;

4) әхлакый үзара мөнәсәбәтләр ситуацияләре.

Авторлар фикеренчә, беренче төр ситуацияләрдә коммуникантларның аралашу характерына һәм алар алдында торган коммуникатив бурычларга бәйле төстә доминант үзара мөнәсәбәтләрне нәкъ менә социаль статус билгели. Мондый типтагы сөйләм ситуацияләрендә укучылар иҗтимагый катламнар, һөнәри төркемнәр, иҗтимагый һәм сәяси оешмалар, яшь төркемнәре һ. б.ларның вәкилләре булып чыгалар.

Билгеле бер хокуклар һәм вазифалар белән характерланучы статусның функциональ ягы булып роль тора. Моннан чыгып, коммуникантлар арасында рольле үзара мөнәсәбәт барлыкка килә.

Эшчәнлекле үзара мөнәсәбәт ситуацияләре нигезендә эшчәнлекнең үзендә, коммуникатларның үзара тәэсир итешүе процессында формалашучы үзара мөнәсәбәтләр ята.

Әхлакый үзара мөнәсәбәт ситуацияләре тудыру аралашуны стимуллаштыруның иң нәтиҗәле ысулларының берсе булып тора, чөнки аларда “ситуагенлык” аеруча да көчле.

В.Л. Скалкин тулыландырыла торган, проблемалы, күзаллаулы һәм рольле ситуацияләрне бүлеп чыгара [5: 40] һәм кыенлык дәрәҗәсенә бәйле рәвештә түбәндәге тәртиптә тәкъдим итә:

1) Тулыландырыла торган сөйләм ситуацияләре яңа мәгълүмат өстәүне, нәрсәнең дә булса тасвирын тәмамлауны, нәтиҗә формалаштыруны күздә тота.

2) Системалы рәвештә һәм алдан уйланылып тудырыла торган проблемалы ситуацияләр әзерлексез телдән сөйләмгә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия һәм гипотезалар, фаразлар чыгарырга, укучыларның фикерләү, сөйләм эшчәнлеген активлаштыруга ярдәм итә. Проблеманың дөрес куелышы сөйләм һәм фикерләү эшчәнлеген активлаштыру өчен башлангыч стимул вазифасын башкара.

3) Күзаллаулы сөйләм ситуацияләре аралашуда катнашучыларның күзаллавына, хыялына нигезләнә. Мисаллар булып бәхәс һәм дискуссия тора.

4) Рольле ситуацияләр укучыларның билгеле бер социаль рольләргә керүен һәм сөйләшү темасын мөстәкыйль рәвештә билгеләвен күздә тота. Еш очраучы рольләр тибыннан түбәндәгеләр аерыла: социаль һәм психологик рольләр. Социаль рольләр социаль вазифаларны чагылдыралар, мәсәлән, сатучы, сатып алучы, укытучы, укучы, полиция хезмәткәре һ. б. Психологик рольләр психологик халәт буларак кичерелә (олы кеше, бала, дус, дошман һ. б.).

Е.Н. Соловова ситуацияләрнең өч тибын аера:

1) Реаль ситуацияләр укыту шартларында укытучы һәм укучы рольләре белән чикләнгән. Нигездә, алар укытучы белән шәхси аралашу яки сыйныфта дәрес вакытында аралашу белән бәйле.

2) Проблемалы ситуация тудыру өчен төрлечә җавап бирү мөмкинлеге калдыручы, ә кайвакыт фикерләр бәрелешенә китерүче проблемалы сорау кую.

3) Шартлы ситуацияләр реаль аралашу ситуацияләрен модельләштерү ысулы булып торалар. Алар коммуникатив уйнала торган рольләрнең спектрын киңәйтү хисабына укучыларның социаль тәҗрибәсен баетуга ярдәм итәләр.

Укыту процессында теге яки бу сөйләм ситуациясе, аңлаешлылык, ягъни гадидән катлаулыга таба гомумдидактик принцибына ярашлы рәвештә кулланылырга тиеш.

Дәреслекләрдә аралашу ситуацияләренә караган сөйләм теле лексикасын өйрәнү үзенчәлекләрен ачыклау өчен эшебездә рус мәктәпләренең татар төркемнәрендә белем алучыларга атап төзелгән дәреслекләр анализланды. Күзәтүебез шуны күрсәтте: Р.К. Сәгъдиева дәреслекләрендә аралашу ситуацияләрен тасвирлаган текстлар шактый еш тәкъдим ителә, әмма аларда биремнәрнең тәкъдим ителүендә бертөрлелек күзәтелә [3: 29].

Бирем, гадәттә, түбәндәгедән гыйбарәт: “Укы, партадашыңа текст белән бәйле сораулар бир, ә ул җавап бирсен. Рольләрегезне алмашырга онытмагыз”. Сирәгрәк очракта аерым сүзләрнең рус теленә тәрҗемәсе бирелә, кайбер очракларда бу сүзләр арасында гади сөйләм лексикасы да урын ала. Мәсәлән, 7 нче сыйныфта “Коймадагы кояш” тексты белән эшләгәннән соң, *шапырынырга – хвастаться, каңгылдык – кричащий* сүзләренең мәгънәсенә тәрҗемә аша төшенәләр [3: 197].

Укучыларның аралашу ситуацияләре, гадәттә, мәктәп, гаилә, яшьтәшләр белән чикләнә. Гаилә аралашуы ситуациясенә караган кызыклы күнегү тугызынчы сыйныф укучыларына тәкъдим ителә. Укучыларга мондый бирем тәкъдим ителә: “диалогны гади сөйләм теленә туры килерлек итеп үзгәртеп сөйләшегез” [4: 97]. Укучыларга сүзлек белән эш тә тәкъдим ителә: ““Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә гади сөйләм шартлы билге белән күрсәтелгән. Шуннан ун сүз сайлап ал һәм, аларны кулланып, сөйләмә стильгә караган текст төзе” [4: 97]. Әлеге эшне парларда башкару, безнең фикеребезчә, тагын да уңышлырак булыр иде. Укучылар, беренчедән, кирәкле сүзләрне тизрәк табачаклар, икенчедән, сөйләм сүзләрен гадәти шартларда – аралашу ситуациясендә кулланып, диалог төзи алалар.

Күренгәнчә, дәреслекләрдә сөйләм лексикасы түбәндәге юл белән өйрәнелә: рус теленә тәрҗемә аша мәгънәсен аңлату, гади

сөйләм лексикасы кергән текстларны уку, сүзлек белән эшләү. Нәтиҗәдә шуларга игътибар юнәлтеп үтәсебез килә: төрле галимнәр тарафыннан сөйләм ситуацияләренең бүленеше төрлечә булса да, ахыр чиктә, алар бер-берсен тулыландырып торалар һәм берникадәр дәрәҗәдә кабатлыйлар да. Шулай ук, безнең карашыбызча, Е.И. Пассов һәм А.М. Стояновский тарафыннан ситуацияләрнең дүрт тибын аерып чыгару өчен алынган нигез – үзара мөнәсәбәтләр типлары, үзара тыгыз бәйләнгәннәр һәм практикада ситуацияне теге яки бу типка кертеп карауда кыенлыклар барлыкка килә.

**Әдәбият**


1. Галиуллина Г.Р. Хәзерге татар сөйләм телендә лексик интерференция күренеше // Tatarica. 2018. № 1 (10). – 22-35 б.
2. Пассов Е.И., Стояновский А.М. Ситуация речевого общения как методическая категория // Иностранные языки. – 1989. – № 2. – С. 18-22.
3. Сәгъдиева Р.К., Харисова Г.Ф. Татар теле. Рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 7 нче сыйныф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2017. – 215 б.
4. Сәгъдиева Р.К., Кадирова Э.Х. Татар теле. Рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 9 нчы сыйныф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2017. – 143 б.
5. Скалкин В.Л. Коммуникативные упражнения на английском языке. – М.: Просвещение, 1983. – 128 с.


# ГӨЛНУР АЙЗЕТУЛЛОВА ИҖАТЫНДА ТУГАН ЯК ОБРАЗЫ


*Исмәгыйлев И., Буа ветеринария техникумы, I курс студенты*
*Җит. – Исмагилова Г.Т.*


Табигать безгә – балаларына гаҗәеп хәзинәләр биргән. Сыйнигъмәтләр белән туендыручы кара туфрак, сулар һава, эчәр су. Болар – бәяләп бетергесез байлык: берсе генә булмаса да, җирдә тормыш юк. Шушы матурлыкны шигырь юлларына салучы мөгаллимәләребез дә бар. РФ нең мәгариф отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе иясе Гөлнур Айзетуллованың Буа ягына багышланган шигырьләре шактый. Шагыйрә матур-матур җырлар авторы буларак танылды. Җырларда туган як, мәхәббәт темасы үзәк урынны алып тора.

Шигырьләрендә, авыл баласы буларак, җәмгыятьне табигать белән бәйләргә тырыша. Милли-мәдәни чараларда еш була. Ул әле милләтпәрвәр дә. Ләкин күбрәк мәхәббәт турында яза. Игътибарлы, ихлас күзәтүчән дә ул.

Кеше гомере буе бәхетле булып яшәү турында хыяллана, шуңа омтыла... Гөлнур апа иҗатында да бу фикер ачык күренә. Шигырьләре, җырлары да шул хакта. Аларда якташларымның язмышлары, туган җиребезнең матурлыгы.

Яңа шигырьләре белән дә даими танышып барырга мөмкин. Интернет челтәренә барысын да көнендә үк куярга өлгерә ул. Хикәяләрендә безгә таныш булган кешеләрне күрәбез. Билгеле, туган якка булган мәхәббәт – үзеңнең җиреңне ярату, халкыңны ихтирам итү, аның күренекле кешеләрен искә алу һәм хөрмәт итүдән башлана.

Гөлнур Айзетуллова – популяр җырлар авторы. Ул язган җыр текстлары эчтәлекле, җанга үтеп керерлек, ихлас булуы белән аерылып тора. Аның һәр җырында бер яңалык, бер фикер. Берсе ерак балачакка алып китсә, икенчесе табигатькә чакыра. Берсе күңелләрне айкап, үткән елларга нәтиҗә ясарга әйдәсә, икенчесе, ялгышлардан саклап, дөрес юл сайларга өйрәтә. Иҗаты елата, юата, туган якны ярattыра.

“Бәхетле бул” дип аталган дискында 62 җыр урын алган. Алар арасында туган якка багышланганнары да бар. “Туган авылым” җырында да үзенең туган авылын яратканлыгы күренә.

Еракларданатуган авылым,
Сагындыра гел балачагым.
Кем уйлаган шул ялан тәпи
Чапкан чак истә калачагын,
Мине озата барачагын.

Г.Айзетуллованың «Яшә, Буам» җырында шәһәребезгә соклану чагыла.

Зәңгәр күгең аяз булсын,
Капламасын болытлар!
Синдә йөргән сукмакларның
Якынлыгын онытмам.
Буа! Буа!
Җырлар туа
Сине зурлап, сине мактап.
Яшә, Буам!
Озак еллар
Син халкымның данын саклап.

«Буам минем» җырында горурлану хисен табарга була.

Буа туфрагына
Кем басса да,
Бу мөхтәрәм дуска ни әйтим?
Күп гасырлык
Акыл сандыгының
Үз хуҗасы минем милләтем.
Буам – минем – изге туфраккаем,
Күңелемнең моңлы бишеге!
Кояш сыман балкып каршы ала

Үзенә килгән һәрбер кешене.
Бәрәкәтле безнең
Буа җире! –
Сокланырлык рухлы халкы бар,
Гүзәл илен
Ашлы-сулы итеп
Яшәтергә биргән анты бар!

Гомумән, Г.Айзетуллова Буа турында күп яза.

Буа! Буа!
Минем туган ягым,
Газиз җирем, туган шәһәрем!
Шушы җирдә тамган
Кендек каным,
Монда тамган
Тәүге яшьләрем.
(«Буа» шигыре)

Гөлнур Хәлиловнаның иҗат кичәләрендә мин дә катнашканым бар. Шигырьләрен зур сәхнәләрдә сөйләп, уңышларга да ирештем. Шуңа да аның иҗаты миңа якын һәм кадерле.

## ХАТЫН-КЫЗ ХАРАКТЕРЫН ТАСВИРЛАУЧЫ МӘКАЛЬЛӘР

*Кадыйрова Г., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Җамалетдинова Г.Ф.*

Соңгы елларда бөтендөнья интеграция процесслары яктылыгында төрле халыкларның милли-мәдәни менталитет үзенчәлекләрен өйрәнү аеруча актуаль булды. Монда лингвистика зур урын алып тора.

Бу планда җитди кызыксынуны халык авыз иҗаты, аерым алганда, аның жанрларының һәм паремияләренең төрләрен өйрәнү уята. Фольклор мәгълүматлары халыкның менталь асылын яхшырак аңларга, аларның структурасын (стереотиплар, архетиплар, мифологемалар) һәм вербаль эчтәлеген (стереотиплар, мифологемалар) күпкә киңрәк күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Паремия ул, лингвистик терминнар сүзлегендә бирелгәнчә, фольклорның кечкенә жанрлар тибы: әйтем, мәкаль, табышмак, сынамыш, тапкыр сүз, теләк, тизәйткеч һ.б. Халыкның тәҗрибәсен, дөньяга карашын чагылдыра, кыскалык һәм форма тотрыклылыгы белән характерлана. Безнең эшебезнең максаты – әлеге берәмлекләрдә хатын-кыз образының бирелеш узенчәлеген ачыклау.

Мәкальләрдә хатын-кыз образының бирелеше үзенчәлекле. Нәкъ менә алар ярдәмендә мәдәниятта хатын-кызның тоткан урыны, һәм хатын-кызга булган мөнәсәбәт, фикер, аларга хас булган характер үзенчәлеге ачыклана. Без эшебездә татар халык мәкальләрендә хатын-кызларга хас характер үзенчәлегенең бирелешен тикшердек. Әлеге тикшерү нәтиҗәсендә, мәкальләрне берничә төркемгә бүлеп карадык:

1. Хатын-кызның рольләренә бәйле рәвештә:

Хатын-кыз – килен. *Килен кеше – ким кеше, ялчы белән тиң кеше.*

Хатын-кыз – ир хатыны. *Атың начар булса да, хатының яхшы булсын.*

Мәкальләрнең күбесендә хатын – явыз, усал, хәйләкәр, күп сөйләргә яратучы, уңмаган́ булдыксыз итеп бирелә. *Алты хатын – бер базар.*

Хатын-кыз – әни. *Кояш янында – җылылык, ана янында – изгелек.*

Хатын-кыз – каенана. *Килен булдым – каенанага ярамадым, каенана булдым – киленгә ярамадым.*

2. Хатын-кызның характерына бәйле. Татар халыкында, һәр заманга хас үзенчәлекләрне истә тотып, хатын-кызның холкын, көнкүрештә тоткан урынын ролен билгеләгән мәкальләр бик күп. Аларда хатын-кызның күргәннәре дә, зирәк акылы да чагыла. Татар хатыны исә авыр язмышына күнегеп яшәргә өйрәнгән өчендерме, мәкальләрдә иренә караганда тугъры, иргә нык бирелүчән һәм иреннән дә шуны ук таләп итүчән; аның холкында кызык кына каршылыклар бар: ул үзе күндәм булса да, шактый озын телле; сабыр булса да аны холкыннан чыгаруга илтеп җиткерергә ярамый, бер тәртәгә тибеп буйлап китсә, арбаны ватып-кырып бетерергә дә кыйбат алмый.

Һәрбер кыз үзенең намусын, пакълеген, сафлыгын сакларга тиеш. Бу аларның тормыштагы иң төп вазыйфаларның берсе. Һәм алар өчен иң мөһиме дә шул. Без моны мәкальләрдә дә күрәбез:

*Би белеген бирер, кыз намусын бирмәс.*

*Чибәр кызның үлгәне – намусына тап төшкәне.*

Белгәнебезчә, элек-электән татар кызы ул – тыйнак һәм оялчан́ мөлаем, сабыр һәм күркәм холыклы.

*Хатын-кызны бизәктән дә бигрәк әдәп-нәзакәт бизи.*

*Оялчан кыз – сөйкемле кыз.*

Ләкин бөтен мәкальләрдә дә хатын-кыз әдәпле, тыныч, тыйнак холыклы булып тасвирланмый. Сирәк очракта кызларның туры сүзлелеге, күз яше белән алдалавы, ышанычсыз, урынсыз кыланчык булулары турында да мәкальләр очрый:

*Хатын-кыз көче – күз яшендә.*

*Хатын-кызның күңелендә ни – телендә шул.*

Ир-егетләрнең төп вазыйфасы – өйгә ризык алып кайту, гаиләне тук итү, калган барлык вазыйфалар да – ир алып кайтканны тота белү, өйдә чисталык тоту, терәк булу – хатын-кыз өстендә.

*Ир-ат булса, йорт-җирен макта; хатын-кыз булса, аш-суын макта.*

*Ир –келәт, хатын – йозак.*

3. Йортта хатын-кызның урыны. Хатын-кыз элек-электән үк гаилә учагы, йорт тотучы, балалар тәрбияләүче буларак саналган. Мәкальләрдә дә шулай сүрәтләнә:

*Ипи тәме тоз белән өйнең яме кыз белән.*

*Кыз бала – өй зиннәте.*

Әлеге төркемләүдән чыгып, без, хатын-кызга төрде мөнәсәбәт булганын күрәбез. Кайбер очракта ул хатын-кызның статусы белән бәйле. Әлбәттә әниләргә һәм кыз балаларга мөнәсәбәт яхшы, аларны хөрмәт итәләр, саклыйлар, ә инде килен һәм кайнана статусында булганда хатын-кызга башка төрле мөнәсәбәт күрәбез. Ләкин ничек кенә булмасын хатын-кыз ул – өйнең күрке.

**Әдәбият**


1. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясенең нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 220 б.
2. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Өч томда. – Казан: Тат. кит. нәшр, 1959. – Т. 1. 913 б.; Т. 2. 1963. 959 б.; Т. 3. 1967. 1013 б.
3. Мугтасимова Г.Р. Татар халык мәкальләре лексикасы. – Казан: 2005. – 190 б.
4. Юсупова Ә.Ш., Нәбиуллина Г.Ә., Денмөхәммәтова Э.Н., Мөгътәсимова Г.Р. Татар паремияләренең теле. – Казан: Ихлас, 2010. – 320 б.


## ИЗУЧЕНИЕ КОНЦЕПТА «СНЕГ» КАК ФОРМА ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКОГО ОБРАЗОВАНИЯ


*Каримова А., Стерлитамакский филиал БГУ, студент III курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Мигранова Л.Ш.*


Одним из основных требований к обучению русскому родному языку Федеральный государственный образовательный стандарт определяет лингвокультурологическую компетенцию, под которой понимается система знаний о культуре, воплощенной в национальном языке, личностные качества, приобретаемые в процессе освоения системы культурных ценностей, выраженных в языке и регулирующих коммуникативное поведение носителей языка [1: 320].

Исследованием национально-культурных явлений в языке занимается лингвокультурология. Отметим, что наиболее емкой единицей описания явлений языка и культуры считается концепт. Согласно В.И. Карасику, концепт – это «национальный образ (идея, символ), осложнённый признаками индивидуального представления» [2: 16].

Соизучение языка и культуры формирует и проявляет особое национальное самосознание каждого народа. Язык, отражая особенности проживания народа, является одним из важнейших способов существования знаний человека о мире, в нем запечатлено и воплощено то, что в лингвистике называется «языковой картиной мира». В качестве одной из основ формирования русской культуры обычно отмечают наличие особой связи национальной ментальности с природой, с движением годового цикла, со спецификой времен года. Особая красота русская природа отложила свой отпечаток на характере человека, оказала влияние на его менталитет. В нём уживаются покорность и бунтарство, безудержное веселье и тихая грусть, активная деятельность и созерцательность.

Концепт «зима» является базовым концептом и составляет особый фрагмент в русской и татарской национальной картине мира.

В России зима занимает особое место, она неповторимая (в других странах она не такая снежная и морозная, как у нас). Зима – это как живая душа, живой человек. Русские, татарские и башкирские писатели и поэты не раз обращались к этому образу, и нужно отметить, что для каждого из них зима имеет индивидуальный характер. К примеру, в славянской культуре зима представлялась косматой седой старухой, если не ведьмой: «жаль зимы-старухи», обычно недоброй и коварной; «зима недаром злится, взбесилась ведьма злая» (Ф.И. Тютчев); или же являлась сказочной волшебницей: «вот сама идет волшебница-зима» (А.С. Пушкин), «чародейкою-зимою околдован лес стоит» (Ф.И. Тютчев). Для многих авторов зима была символом чистоты, непорочности, умиротворенности. У С.А. Есенина читаем: «Белая береза / Под моим окном / Принакрылась снегом, / Точно серебром»... У татарского и башкирского народов это понятие раскрывается благодаря употреблению языковых единиц, которые обозначают лицо мужского пола: бабай (дед, дедушка). Приведем в качестве примера один из фрагментов текста: Син, Кыш бабай, бик усал! / Туңдырасың суларны. / Карың белән каплыйсың ник / Яланны, басуларны? (С. Сүнчәләй «Кыш»).

Главный помощник зимы, это, конечно же, снег. В наших краях снег играет огромную роль. Снег и порошит, и кружит, и летит, и падает, и даже танцует. Образ снега помогал писателям выражать свои чувства и эмоции. Например, И.А. Бунин в стихотворении «Первый снег» показал красоту зимней природы, ее особое очарование.

Наши народы испокон веков занимаются земледелием и для них важно, чтобы зима была снежная. Ведь если будет достаточно снега зимой, то весной земля будет плодородной. В связи с этим у

татарского, башкирского и русского народа появилось много примет, пословиц, поговорок. К примеру, такие пословицы как «Зима без снега – лето без хлеба», «Карсыз кыш – җәй иписез»; «Готовь сани летом, а телегу – зимой, санаңды йәй әҙерлә; «Летом не соберешь, зимой не найдешь», «Кар өҫтөндә ҡарға тиҙәге лә табылмай» и др.

В русской, татарской и башкирской языковой картине мира концепт «снег» выступает ключевым концептом: образ зимы и снега уникален, ярок, самобытен, неповторим, в каждой культуре можно выделить его специфичные черты.

Итак, изучение языка в лингвокультурологическом аспекте, изучение народной культуры, традиций и обычаев, пословиц и поговорок, грамотное культурологическое преподавание всех разделов языка способствует нравственному и эстетическому воспитанию современной языковой личности.

**Литература**

1. Воробьев В.В. Лингвокультурология: (Теория и методы). – М.: Изд-во Рос. ун-та Дружбы народов, 1997. – 331 с.

2. Карасик В.И. Антология концептов. – Волгоград: Парадигма; 2005. – 352 с.

3. Маслова В.А. Лингвокультурология: Учеб. пособие для студ. высш. учеб, заведений. – М.: Издательский центр «Академия», 2001. – 208 с.

## КОЛОРИСТИКА ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ТӨС АТАМАЛАРЫ

*Маннапова А., М. Акмулла ис. БДПУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Насипов И.С.*

Кешелек мәдәниятендә төс атамалары мөһим алып тора, чөнки алар фәлсәфи һәм эстетик дөньяны күзаллау белән бәйле. Төсләр төрки телләрдә борынгы чорда ук – V-VII ыгасыр язма истәлекләрдә теркәлгән булса да, тулысынча ул якынча XI-XII гасырларда формалашкан, дип фаразлана. Хәзерге вакытта төсләр мәгънәсен тикшеренүнең түбәндәге актуаль юнәлешләрен аерып алырга мөмкин: чагыштырма, эволютив, психолингвистик, семантик, когнитив аспектлар. Төсләрне өйрәнү юнәлешләре шартлы рәвештә билгеләнә, чөнки һәр тикшеренү үз эченә бар юнәлешләрне дә алырга мөмкин, шулай, төсләр семантикасы төрле аспектларда тасвирлана.

Төс мәгънәсен чагылдыра торган сүзләр, төсләр атамалары җыелмасы – ул колоратив лексика дип атала. Колоризм дип семантик яки этимологик рәвештә төскә бәйле морфемик берәмлек чагылышын аңлыйбыз. Ә колористика – төсләрне өйрәнүче фән өлкәсе.

Төсне тасвирлаучы лексика күбесенчә туры мәгънәдә, шулай ук өстәмә образлы булырга да мөмкин. Татар халкында борынгы чордан ук килгән кием-салым, савыт-саба төсләренең палитрасы бихисап

булуын беләбез. Борынгы чор ядъкарьләрдә төсләр ярдәмчел роль уйный: мисал өчен, төсләрне символик рәвештә куллану, төсләр белән бәйле эпитетларны куллану (*Акбузат, Аксакал*). XVII йөзләрдә төсләр белән кызыксыну арту күзәтелә: төсләрнең төрләре һәм аларның үсеше тикшерелә. Бу гасыр ахырында инде төс атамалары тулысынча формалашып җитешә һәм хәзерге составында була, сәнгатьтә һәм әдәбиятта төсне сәнгати куллану башлана [2: 31].

Эволютив аспекта төсләр мәгънәви күзлектән каралып, аларның килеп чыгышы, әһәмияте һәм куллану дәрәҗәсе ачыклана. Бу яктан тикшеренүчеләр актив рәвештә диалекталь материаллардан файдаланалар, төсләрнең һәм аларның атамаларының килеп чыгышы, төс атамаларын куллануның закончалыклары күзаллауларыбызны баета.

Психолингвистик тикшеренүдә исә мөһим урынны төсне күрә белү, һәм төсләр телен аңлау проблемалары ачыклана. Төс кешенең рухи иҗаты буларак карала, шуңа күрә аерым алынган төсләр һәм ассоциатив-семантик кырларга аңлатма бирү генә түгел, ә конкрет төсләрнең яки төс кушылмаларының кешегә йогынтысы өйрәнелә. Психолингвистик аспект кысаларында А.И. Белов [2], Р.М. Фрумкина “төсләр дөньясы”, “төсләрнең исемнәре”, төс атамаларының семантик кырлары картиналары, “төс мәгънәләре” әһәмиятен өйрәнәләр. Психолингвистик эшләрдә төсләрне аңлату тикшерүнең системалы-структур ысулларыннан баш тарту тенденциясе күзәтелә, бирედә беренче планга эксперимент чыга. Атау вазифасын тикшергәндә, категорик ягы да ачыклана, Р.М. Фрумкина төсләрнең исемнәрен аңлату мәсьәләсен тикшерә [5].

Когнитив юнәлештәге тикшеренүчеләрне социаль, этник һәм менталь җайлашу мәсьәләсе кызыксындыра. Когнитив тикшеренүдә төп категория булып дөньяның тел картиналары һәм төсләре-прототип төшенчәләре тора. Мәсәлән, А. Вежбицкая: “Сары төс өчен прототип булып Кояш тора”, – дип яза [3: 17].

Төсләрне кабул итүне өйрәнгәндә, лингвистлар төсләрне ике төркемгә – төп (абсолют) һәм төрле төсләргә бүләләр. Атауның абсолют төсе, үз чиратында, салават күпере спектрының (кызыл, куе сары, сары, яшел, күк, зәңгәр, шәмәхә) җиде төсе һәм ахроматик (кара, ак, соры) дип аталучы хроматик төрләргә бүленә. Барлык калган төсләрне төсләрнең төсмере (оттенок) дип атыйлар. Алар төрлечә язылып, төрле яңгыраштa була.

Төс символының килеп чыгышы, аның эчтәлеге, кешеләр тормышындагы теге яки бу күренешләргә һәм вакыйгаларга мөнәсәбәте, төс символикасында мәдәниятара аермалар – бу төсләрне тикшерүдә төп мәсьәләләренең берсе.

Төс белдерүче сүзләр белән еш кына тотрыклы сүз тезмәләр – фразеологизмнар барлыкка килә. Моннан тыш, телдәге төс атамалары хис-кичерешләр белдерүче ирекле сүзтезмәләрне дә бирә ала.

Һәр халыкның төсләргә үз мөнәсәбәте була. Ул аның үткәне, дини карашлары, җәмгыятьнең нинди үсеш баскычында торуы, ырым һәм ышанулары белән бәйле сыйфатлый. Мәсәлән, һәр халыкның үз яраткан, аерым бер изге мәгънә ия булган төсләре була.

Татар халкында иң кадерле һәм изге төсе булып – *яшел* төс санала, чөнки бу төс барлык мөселман халыкларында аерым хөрмәтләү билгесе, хәтта монгол-татарлар яулап алган күп кенә җирләрдә христианнарга яшел төстәге кием кияргә ярамаган булуы да билгеле. Ул гармонияне, яшьлек, табигать белән бердәмлекне символлаштыра һәм татар халык иҗатында да еш кулланыш таба. Бу төс бигрәк тә яшь хатын-кызларга карата еш кулланыла. *Ак* төс шулай ук ислам диненең төп төсләренең берсе булып санала һәм традицион рәвештә чисталык, сафлык буларак күзаллана [1]. *Кара* төс исә кайгы белән бәйләнгән, *сары* төс – хәсрәт, сагыш билгесе.

Төсләр тормышта бик әһәмиятле роль уйный, элек-электән халкыбыз төсләр аша уй-хисләрен белдергән, һәр төскә нинди дә булса мәгънә салган. Шуңа кешенең кигән киеме, тормышында аны уратып алган төсләр палитрасы аның күңел халәте турында күп нәрсәне сөйли алган.

Шулай итеп, татар телендә төс атамалары борынгы чорда ук формалашкан. Төс атамалары югары дәрәҗәдә оешканлык һәм система барлыкка китерүче сүзләр төркеме. Татар телендә барлык төс атамаларына да сиволик мәгънәгә ия, шунлыктан алар еш кына фразеологик берәмлекләрдә, мәкаль-әйтемнәрдә һәм әдәби әсәрләрдә чагылыш таба. Хәзерге вакытта төс атамаларын чагыштырма, эволютив, психолингвистик, семантик, когнитив аспектларда тикшерерләр.

**Әдәбият**

1. Акулина Л.В. Использование цветообозначений в качестве художественно-изобразительных средств в языке татарской и удмуртской художественной литературы // Историческая и социально-образовательная мысль. – 2014. – №4. – С. 227-230.

2. Белов А.И. Цветовые этноэйдемы как объект этнопсихолингвистики // Этнопсихолингвистика. – М.: Наука, 1988. – С. 49-58.

3. Вежбицкая А. Обозначения цвета и универсалии зрительного восприятия // А. Вежбицкая. Язык. Культура. Познание. – М.: Русские словари, 1996. – 416 с.

4. Фахретдинов Р.М. Некоторые особенности цветовосприятия во французском и татарском языках // Казанский лингвистический журнал. – 2018. – Т. 1. – № 3 (3). – С. 32-42.

5. Фрумкина Р.М. Цвет, смысл, сходство. – М.: Наука, 1984. – 176 с.

## ТӨРЛЕ ХАЛЫКЛАРНЫҢ КӨРӘШ СӘНГАТЕ

*Мифтеев Р., Идел буе дәүләт физик тәрбия, спорт һәм туризм академиясе, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Мотыйгуллина А.Р.*

Төрле халыкларның тормыш-көнкүреше, яшәеше аерым юнәлешләрдән тора. Элек-электән халыклар үз каралты-кураларын бизәгәннәр, шартларны үзгәрткәннәр, саклаганнар. Әлбәттә, саклау беренче чиратта корал тотып яклауны күздә тота. Әмма кайбер халыкларда көч туплау, алдан әзерлек эшләре дә барган. Бу исә көчне арттыру, кирәкле вакытта файдалану өчен күнекмәләр булуны таләп иткән. Башка уеннар белән беррәттән көч арттыру, үз көчеңны сынау кебек ярышлар, бәйгеләр барлыкка килә. Шуңа күрә көрәш төрле милли үзенчәлекләр ала, төрләнә.

Барлык халыклар да көчле кешеләрне хөрмәт иткәннәр. Аларның саны арткан саен чагыштыру өчен сынау төрләре, бәйгеләр уйлап табылган. Шулай итеп халыкның көчле каһарманнары барлыкка килгән. Аларны пәһлеваннар дип тә атый башлаганнар. Рус халкында алар былина геройлары (Илья Муромец, Добрыня Никитич, Алеша Попович) булып киткәннәр, татарларда көчле кешенең Дию пәриен җиңү турында әкиятләрдә язылган. Соңгы исәптә физик көчкә ия булган кешене пәһлеван дип атап йөртәләр.

Безнең хезмәтебезнең максаты төрки халыкларда һәм Көнчыгыш халыкларындагы милли көрәш төрләренә күзәтү ясау. Чыннан да, тора-бара көч кулланып оештырылган төрле бәйгеләр акрынлап спорт төрләре буларак таралыш ала. Шул рәвешле, төрки халыкларның үзләренә хас булган милли көрәш төрләре барлыкка килә.

Нигездә көрәшне иң борынгы спорт төрләреннән берсе дип исәпләргә мөмкин. Аны үзбәкләрдә, кыргызларда, Монголия халыкларында таралганы татар көрәшенә охшаш. Ләкин аларда аяк чалырга рөхсәт ителә, ә татар көрәшендә тыела. Татар көрәшендәгечә кул көчен кулланып, көндәшне әйләндереп аркасына салу исә аларда юк. Әзербайҗан халкының милли көрәше гюлеш дип атала. Көрәшчеләрнең милли киемнәре нык чалбар-шароварларны киң каеш белән әләктереп куюдан, аякларына йомшак аяк киемнәре киеп көч сынашудан гыйбәрат. Көрәш кагыйдәләре көндәшне гәүдәсеннән әләктереп алып, аркасына салу була. Казахларның милли көрәше курес, кыргызларныкы күреш, таҗикларныкы Бохара гөштие, татарларда милли көрәш, туваларда күреш, төрекләрдә гүреш  якынча шул ук кагыйдәләргә буйсына. Көрәш Россиядә милли спорт төрләре исемлегенә кертелгән. Бөтен Россия ярышларында җиңүчеләргә спорт остасы, Халыкара

дәрәҗәдәге спорт остасы дигән исемнәр бирелә. Татар, башкорт һәм башка төрки халыклар арасында таралган көрәш бил алышуга бәйле. Шуңа күрә аны билбау көрәше, милли көрәш дип йөртәләр.

Мондый төрдәге көрәшне Көнчыгыш халыклары арасында да очратабыз. Аларны көрәш дип атаудан бигрәк бердәм көрәш төрләре рәвешендә атап йөртү таралыш алган. Хәрби сәнгатькә каршы куелган Көнчыгыш сугыш төрләре кагыйдәләре, сугышу үзенчәлекләре, алымнары белән аерылып тора. Көнчыгыш сугыш төрләре вакытлар узу белән бер-берсен тулыландыра, алымнар төрләндерә. Шулай итеп, дөнья күләмендә популярлаша.

Хәзер Россиядә киң таралган Көнчыгыш халыклары көрәш төрләреннән самбо, айкидо, карате, ушу, тхэквондо һәм башкаларны очратырга мөмкин.

Самбо – спортның хәрби төре булып санала. Ул үзенә һөҗүм итүнең төрле алымнарын берләштерә. Шул ук вакытта самбо халыкның мәдәни байлыгын үз эченә алып, әхлак принципларына да нигезләнә.

Айкидо – Япониядәге саклау системасына нигезләнгән. Борынгы техника нигезендә көрәшнең барлык хәрәкәтләре бик матур, нәзәкатьле, күпмедер дәрәҗәдә элегант булырга тиеш. Айкидо белән шөгыльләнү вакытында җәрәхәтләнүдән сакланырга, уйлап хәрәкәт итү һәм фикерне бер тирәгә туплау сорала.

Дзюдода сугу булмау кызларга да шөгыльләнү мөмкинлек бирә. Аны камилләштерү өстендә бик күп осталар хезмәт куя. Ул кагылмыйча гына саклану сәнгате булып тора. Ә менә каратэның туган җире булып Япония санала. Андагы хәрәкәтләр механика законнарын куллануга корылган. Кагылуларсыз гына үткәрелә торган уен булып тора. Аның белән гомуми сәламәтлекне саклау, организмны чыныктыру өчен дә шөгыльләнергә мөмкин.

Көнчыгыш халыкларның көрәш төрләреннән каратэга якын торган төре - тхэквондо. Әмма ул үзенең кагыйдәләре, кулланыла торган алымнары белән аерылып тора. Россиядә тхэквондо чагыштырмача яшь спорт төре булып исәпләнә. Мәгънәсе ягыннан “тхэ” – аяк, “квон” – кул, “до” – сәнгать дигәнне аңлата. Аның максаты аяк һәм кул хәрәкәтләрен камилләштерү. Сппаринг уен урыны 12х12 метр урында 3 раудтан торган уен. Арадагы тәнәфес вакыты 60 секунд.

Әлеге уенның тарихы кызыклы. Корея халкында киң таралган хәрби сугыш сәнгате буларак барлыкка килә һәм камилләшә. Туган җирендә аның тарихы ике мең ел белән исәпләнә. Ә тхэквондо исемен уйлап табу 1955 нче елда гына була.

Шул рәвешле, Көнчыгыш халыкларында таралган самбо, айкидо, карате, ушу, тхэквондо һәм башкалар төрки халыкларның милли көрәше һәм көрәш төрләре кебек үк камилләшә, төрле алымнар белән тулылана, сәнгать төре буларак дөнья мәйданында үз урынын яулый.

**Әдәбият**


1. Гавриков А., Масюков Ю., Зенько Л. Боевое дзюдо. – Рига: 1991
2. Есин Е.Н. Невидимое оружие. – Нижний Новгород: 2002.
3. https://ru.qaz.wiki/wiki/History_of_martial_arts
4. http://www.libma.ru/sport/samooborona_priemy_realnoi_ulichnoi_draki/p2.php.


## СЕМАНТИКА СЛОВА «КӨК» В КАЗАХСКОМ И ТАТАРСКОМ ЯЗЫКАХ


*Муратбекова М., КазНу им. аль-Фараби, студент III курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук Кортабаева Г.К.*


Целью статьи является определение происхождения названия цвета көк / kök в казахском и татарском языках, проследить развитие данных лексем на общетюркском фоне, выявить особенности употребления цветообозначений.

Феномен цвета, цветовосприятие и цветовидение, цветовая символика издавна привлекали внимание представителей различных научных областей. Интерес к изучению слов-цветообозначений в современной науке поддерживается тем, что понятие «цвет» связано, с одной стороны, с многообразием окружающей среды, а с другой – с мышлением человека и его представлением о языковой картине мира.

В тюркологии цветообозначения также исследовались и продолжают исследоваться в лексическом, сравнительно-историческом и др. аспектах такими учеными как Кононов; Габышева, Кормушин, Майзина, Жаркынбекова, Саматов и др. В татарском языке различные характеристики цветообозначений и словообразование колоративной лексики рассматривали: Х.Р. Курбатов, В.Х. Хаков, Ф.С. Сафиуллина, В.А. Костенко, Э.Ю. Хайруллина, Р.Р. Закиров.

«Синий цвет у многих народов мира наделяется высоким переносным значением: он символизирует вечность и бесконечность, истину и веру, преданность, чистоту и целомудрие, духовную и интеллектуальную жизнь. У тюркских народов синий цвет также издревле считался символом верности, вечности и постоянства.

Тюркский колороним kök – в физическом аспекте цвет неба и травы – ассоциировался кроме того с божественной субстанцией, с

прародителем рода. Значения ‘голубой, синий, сизый’ выявляются у слова kök абсолютно во всех древнетюркских памятниках.

Семантика синего цвета в культуру татарского народа пришла из языческих верований: синий – цвет неба, Тенгри, в татарской поэзии его использование часто олицетворяет собой образы красоты, счастья, мечты, богатого внутреннего мира – как правило, чаще встречался в одежде представителей знати.

Түркі халықтарының түсінігінде өзгелерінен бөлектеніп тұратын ірі денелі, шоқтығы биік, уйір бастаған, өте батыл сияқты қасиетімен ерекшеленетін арлан қасқырды көкжал деп атайды.

Көкжал – дәстүрлі ортадағы қасқырдың арланына қатысты айтылатын эвфемистік атау. Мұндай қасқырларды көкжал деп атауының себептері туралы түрлі пікірлер кездеседі. Ел арасында «ықты да айбарлы қасқырдың желкесінен жонына дейін созылған жал болады,сондықтан оны Көкжал қасқыр деп атайды» деген түсінік бар. Сонымен қатар жылқыны жығып жеп, қойды арқалап әкететін әккі мықты бөріні қазақта көк жалды бөрі деп айтудан көкжал бөрі және Көкжал деген атау қалыптасқан деген пікірлер де кездеседі.Өйткені қазақта жал, жалдылық-мықтылықтың, күштіліктің, белділіктің белгісі болып саналады.

А.Н. Кононов отмечал, что kök «в современных тюркских языках известно преимущественно в следующих значениях: 1) «синий», «голубой», «лазурный», «светло-зеленый», «сизый», «цвет молодой зелени», «серый», «сивый»; 2) «небо», «молодая трава», «зелень», «луг»; 3) «Бог».

Слово кöк употребляется как первый компонент: 1) в личной ономастике: Кöк таш, Кöк бори; 2) в этнонимах: Кöк турк и др.; 3) в географических названиях (гидронимы и оронимы): Кöк~Гöк-су (название многих рек в Средней Азии и других местах); Кокчетав (Кöк+ че - тау «Синеватая, Голубоватая гора»); 4) в названиях птиц, животных и растений

Э.В. Севортян в «Этимологическом словаре тюркских языков» выделил следующие значения kök (гöк): 1) ‘небо’; 2) ‘голубой’, ‘лазурный’, ‘лазоревый’ ‘синий’, ‘небесный’, ‘темно-синий’, ‘темно-голубой’; 3) ‘зеленый’, 4) ‘незрелый’; 5) ‘цвет молодой зелени’, молодая трава’, ‘зелень’, ‘луг’; 6) ‘серый’, ‘сизый’, ‘сивый’ ‘чалый’, ‘седой’; 7) ‘багровый’, ‘черный’,‘ночь’; 8) «Бог».

«Синий в символизме – это цвет сакральный, напоминающий нам о времени и мимолетности жизни, о вечности суе-ты и прошедших мгновениях счастья. Этот цвет увлекает нас в прошлое, а также дает силу и духовное просветление» [6]. Таким образом, изучение

семантики с компонентом цвета позволяет более объективно оценить историческое и культурное наследие тюркских народов, что важно для решения проблем межъязыковой и межкультурной коммуникации.

**Литература**

1. Абжапарова М.Д., Широбокова Н.Н. Развитие и семантика колоронимов көк и kök в казахском и алтайском языках // Вестник НГУ. Серия: Лингвистика и межкультурная коммуникация. 2020 Т. 18, № 4.

2. Кононов А. Н. Семантика цветообозначений в тюркских языках // Тюркологический сборник, 1975. – М.: Наука, 1978.

3. Севортян Э. В. Этимологический словарь тюркских языков. – М.: Наука, 1974. – 349 с.

4. Сравнительно-историческая грамматика тюркского языка. Лексика / Отв. ред. Э.Р. Тенишев. 2-е изд., доп. – М.: Наука, 2001 822 с.

5. Ситдыкова А.Ф. К вопросу определения базового концепта «төс» и его семантического поля на примере цветообозначений в татарском языке.

6. Парамонова Л.Ю. Сапфирность неба» и «отсвет голубой»: семантика синего цветав лирике старших символистов // ВІСНИК ДНІПРОПЕТРОВСЬКОГО УНІВЕРСИТЕТУ ІМЕНІ АЛЬФРЕДА НОБЕЛЯ.Серія «ФІЛОЛОГІЧНІ НАУКИ». 2013. No 2 (6).

## «ГАИЛӘ» ТЕМАСЫНА КАРАГАН МӘКАЛЬЛӘРНЕҢ СЕМАНТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Мөбарәкшина Д., КФУ, IV студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Мөгътәсимова Г.Р.*

Халкыбызның зирәклеге һәм рухы мәкальләрендә чагыла, ә шуны аңлау телне тирәнрәк белүгә генә түгел, ә халык характерын, фикер сөрешен ачыкларга ярдәм итә. Мәкальләрдә халыкның бай тарихи тәҗрибәсе, хезмәт эшчәнлеге, көнкүреше һәм мәдәнияте белән бәйле күзаллаулар чагылыш тапкан. Мәкальләрне дөрес һәм урынлы куллану – сөйләмебезнең кабатланмас үзенчәлеге.

Мәкаль халык авыз иҗатының галимнәр өйрәнә торган иң кызыклы жанры булса да, әле һаман үзендә күп кызыклы белемнәр саклый. Мәкальләрдә аерым кешеләрнең фикере түгел, ә халык бәясе, халык акылы гәүдәләнә. Ул халыкның рухи йөзен, омтылышларын һәм идеалларын, тормышның төрле яклары турында фикерләрне чагылдыра. Мәкаль сөйләмдә яши, бары тик шунда гына ул үзенең төгәл мәгънәсенә ия була.

Алга таба без гаилә мөнәсәбәтләрен чагылдыручы мәкальләрдә халык характеры сыйфатлары, үзара аңлашу үзенчәлеге, образлы ассоциацияләрнең үзенә бер төрлелеге чагылыш табуын карарбыз. Мәкальләр гаиләнең барлык үсеш стадияләрен күзәтергә мөмкинлек бирә, мәсәлән, гаилә төзү (никахлашу), бала һәм оныклар туу, аларны

тәрбияләү, балалар белән ата-ана, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәт һәм башкалар.

Элек-электән гаилә тулы канлы тормыш итү һәм имин картлыкның бердәнбер формасы булып торган. Башка төрки халыклардагы кебек үк татарларда да гаиләле булу хөрмәт ителгән, ә никахлашу зарури шарт кына түгел, мөселманнар өчен Ходай хакына башкарылучы изге гамәл дип тә саналган. Өйләнешүгә булган уңай мөнәсәбәт мәкальләрдә дә чагылыш тапкан: *Өйләнү – көйләнү; Өйләнми картайганнан акыл сорама; Өйләнмәгәннең тамыры корыр; Өйләнү – җаныңа җавап, башыңа савап; Өйләнү белән өй салуга Алла юнь бирә* һәм башкалар. Татар халкы өйләнгән кешенең тормышы жайга салына дип уйлаган. Татарлар яратып кына кияүгә чыгарга киңәш иткәннәр: *Мәхәббәтсез семья — тамырсыз агач; Ашны ачыкканга бир, кызны гашыйгына бир*.

Татар мәдәниятендә никахның кешеләр тормышында бик мөһим булуы әйтелә. Мәкальләрнең дөнья сурәтендә гаилә – бәхетле тормыш нигезе. Моның нәкъ шулай икәнен *Семья – бәхет ачкычы* мәкале дә дәлилләп тора.

Кияү һәм килен турында да мәкальләр бар. Алар кияү һәм килен сайлауга караган киңәшләрне чагылдыралар. Татарларда килен мондый булырга тиеш: *Аш бул да таш бул!; Балыкның – ике күзе, киленнең бер күзе сукыр; Килен кеше – ким кеше, Алабай белән тиң кеше; Килен кеше – чит бавыр; Килен килбәтсез була* һәм башкалар.

Мәкальләрдә кияү турында болай язылган: *Кияү – ат шикелле: караңгы товар; Кияү – камчат бүрек; Кияү – кеш тун; Кияү көл астыннан; Кияү каениш туфрагыннан; Көзге көннең акылы – кияүләр акылы* һәм башкалар.

Татарларда хатынның һәм ирнең гаиләдәге урынын билгели торган мәкальләр шактый күп. Алар гаилә тормышының үзәген тәшкил итәләр. Мәкальләрдә алар һәрвакыт бергә. Алга таба без аларны берничә төркемчәгә бүлеп карарбыз.

Беренче төркем – хатынның һәм ирнең бер бөтен булуын күрсәтүче мәкальләр. Мәсәлән, *Бизмән белән гер бергә, хатын белән ир бергә; Ир белән хатын арасына кыл да сыймый; Ир белән хатын – бер җан, бер тән; Ир белән хатын –икесе бер камырдан; Ир белән хатын икесе бер чыбыктан сөрелгән; Ир белән хатын керешеп беткән; Ир белән хатын куш тирәк, төбер бер дә тамыры бер; Ир белән хатын — игезәк җан* һәм башкалар. Рухи бергәлек ир белән хатын арасындагы бәйләнешнең ныклыгын күрсәтеп тора. Гаилә проблемалары бергә хәл ителүе турында сөйли. Мәкальләр ир белән хатын арасына чит кешеләрнең кысылмавын киңәш итә:; *Ир белән*

*хатын арасына кергәнче, кылыч белән кылыч арасына кер; Ир белән арасына кергәнче, утка кер.*

Икенче төркем – гаиләдәге бәхәсләр турындагы мәкальләр. Бу турыда татар халкы болай ди: *Атына ачуланган хатынын кыйнаган; Ахмак хатыны белән булашыр; Ир белән хатын талашыр, түшәгендә ярашыр; Ир какканны ил кагар; Ирне үзеннән чыгарма!* һәм башкалар.

Өченче төркем – гаиләдә ирләрнең баш булуы турындагы мәкальләр. Мәсәлән, *Ир — баш, хатын — муен; Ир – ат, хатын – арба; Ир – аяк, хатын – олтырак; Ир – беләк, хатын – терәк; Ир – келәт, хатын – йозак, Ир хакы – тәңре хакы* һәм башкалар. Мәкальләрдә ир кешенең гаиләдә баш булуы уңай дип каралса, хатыннарның баш булуы – бик тискәре күренеш: *Заман ахыры булганда, һәркем хатын сүзе белән йөрер имеш; Ире басынкы булса, хатыны дуамал булыр; Ир кеше үз вазифасын белмәсә, аңа хатыннар баш була, ди.*

Дүртенче төркем – хатыннарның гаилә терәге булуы турындагы мәкальләр. Чыннан да, гаилә учагын саклауда хатын-кыз аерым урын тота: *Йорт тоткан да хатын, йорт бетергән дә хатын; Начар гармун көй бозар, начар хатын өй бозар; Хатын булмый, өй булмас; Хатынсыз йорт – ел кебек* һәм башкалар.

Мәкальләрдә ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәт тә ачык чагыла. Әлбәттә, монда әнинең роле бик зур икәне ачыклана. Кыз яки хатын белән чагыштырганда, ана гаиләдә бик зур йогынты көченә һәм абруйга ия. Бу, әлбәттә, халык авыз иҗатында да чагылыш таба: *Ана хакын уч төбендә тәбә кыздырып ашатсаң да кайтара алмассың; Ананың бер догасы җиде мулла догасына җитә; Кояш янында – җылылык, ана янында – изгелек; Ана җылысы – кояш җылысы; Җәннәт аналарның аяк астында* һәм башкалар. Монда анасын кадерләгән, хөрмәт иткән кеше генә бәхеткә лаек була алуы турында ассызыклана.

Шулай итеп, гаилә кешенең үз-үзен тотышында мөһим бер юнәлешне тәшкил итә. Гаиләнең роле милләт өчен бик зур. Төрле-төрле мәкальләрдә теркәлеп калган гаиләгә караган билгеләрне ачыклап, без кызыклы нәтиҗәләргә килдек. Татар теленең паремиологик фонды, һичшиксез, кеше тормышының төрле өлкәләрендә үз-үзеңне тоту нормасы, тормыш һәм әхлак энциклопедиясе булып тора.

**Әдәбият**

1. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Өч томда. Казан: Татар. кит. нәшр., Т.1. —1959. — 913 б.; Т.2. 1963. — 959 б.; Т.3. 1967. — 1013 б.

*Alşeyho G., KPFU, II kurs öğrenciler*
*Bilim. Yön. – Denmuhametova E.N.*

Giriş, Arapça'nın Türkçe üzerindeki etkisini ve dilin etkisini incelemektedir. Arapça konuşmayan Müslüman halkların, birçok nedenden ötürü Kuran'ın dilinden güçlü bir şekilde etkilendiği bilinmektedir; bunların en önemlisi, İslam'ın öğretilerini anlamak için Arapça öğrenmektir. Bu çalışmanın amacı, yazının aktarılmasından sonra modern Türk dilinin Arapça'da ne kadar modern olduğuna, Arapça harflerden Latin harflerine çevrildiğine ve özellikle Osmanlı döneminde Arapça'da Türk diline (Osmanlı) yerleşmiş olan çalışmadan nasıl etkilendiğine ışık tutmaktır. Osmanlı dili, ülkenin resmi dili haline geldiği için arapça'yı da etkiledi.

Arapça ve Türkçe arasındaki etki ve dilsel etkisi.

Tanrı, Arapça'yı vahiy dili olarak, cennetin dili olarak seçti, ve Yüce Tanrı'nın yeryüzündeki halefiyle arapça dilinde konuştu. Tanrı, ilahi hikmet için arap dilini tercih etti. Arapça, Kuran'ın dilidir. Arapça'nın diğer diller üzerindeki etkisi açıktır. Bu, Irak ve Mısır gibi Arapça ile değiştirilen bazı dillerin ortadan kalkmasına yol açtı. Halklar ve dilleri arasındaki doğrudan ve dolaylı temas, Arapça kelime dağarcığının İspanyolca, İtalyanca, Yunanca, Türkçe, Farsça, İngilizce ve Fransızca v. b. gibi diğer dillere aktarılmasına yol açmıştır. (1978., إبراهيم أنيس )

Türkçe ve Arapça arasındaki etki ve dilsel etki.

Türklerin İslam'a geçişi, karahanlar (932-1212) sırasında başladı, ve bu süre zarfında Türk dilinde Arapça harfleri kullandılar. Arapça, yavaş yavaş Farsça ile değiştirilmeden önce 13. yüzyıla kadar bu şekilde kaldı. 15. ve 16. yüzyıllarda Osmanlı Devleti, Suriye, Lübnan, Filistin, Mısır ve Hicaz bölgesini ikinci Sultan Bayezid (1481-1512) yönetimine kattı. Yukarıdakilere dayanarak, Araplar ve Türkler, ortak bir İslam kültürüne dayanan derin tarihsel ve kültürel bağlara sahiptir. Arap-Türk ilişkilerine baktığımızda, Türk dilinin birkaç aşamadan geçtiğini söyleyebiliriz: Türk dili eski ve modern dönem olmak üzere iki temel aşamadan geçmiştir, antik dönem, dilin başlangıcından MS 12. ve 13. yüzyıllara kadar başlar. Daha sonra, dil yapısının değiştiği, yeni gramer kurallarının ortaya çıktığı ve alfabenin değiştiği modern aşama başlar.(2012.,أوغلى) Modern Türkçe, Türkiye Cumhuriyeti'nin ilanının (Modern Türkçe) aşamasında, bu aşamada Türkçede pek çok dönüşüm yaşanmış, Arap harflerinin yerini Latin harflerine bırakmış ve Osmanlı dilinden eskisi gibi bahsedilmemiştir.

Yaşar Avcı tarafından 2005 yılında Türk Dil Kurumu Sözlüğü'ne dayalı olarak yapılan bir çalışma, Türkçeye farklı dillerden geçen kelime sayısını şöyle göstermektedir; Arapça'dan 6463, Almanca'dan 85, Ermenice'den 23, Farsça'dan 1347, Fince'den 2, Fransızca'dan 4974,

İbranice’den 9, İngilizce’den 583, İspanyolca’dan 583, İtalyanca’dan 632, Japonca’dan 7, Korece’den 1, Latince’den 147, Macarca’dan 19, Moğolca’dan 13, Norveççe’den 2, Portekizce’den 4, Rumca’dan 14, Rusça’dan 40, Slavca’dan 24, Sağdca/Sağdakça’dan 24 ve Yunanca’dan 399 kelime geçmiştir. 2005 yılı için Türkçe sözlüğü kullanarak ve önceki tabloyu gözden geçirerek, Arapça kelimelerin en yüksek yüzdesi (6463), sonrası Fransızca (4974), Farsça (1347). Tablo, Osmanlı İmparatorluğu'nun genişlemesine ve İslam dünyasının geniş alanları üzerindeki kontrolüne rağmen Türk dilinin zayıflığını göstermektedir. Edebiyat ve siyaset dili olmasına rağmen, Fars dilinin etkisinin Fransızcadan daha az olduğu da belirtilmektedir. Bu ayrıntılı araştırma gerektirir.

Arap dilinin Türkçedeki etki alanları: 1-Arapça kelimeler Türk diline aynı telaffuz ve anlamla girmiş, bunların: ebedi أبدي, Ekber أكبر, Allah ﷲ, Tevassül توسل, Terbiye تربية, Hikaye حكاية, Hâl حال (2004.,Dağarcık), çevirinin birçok Arapça kelime içerdiğini göstermektedir, bu Arap dilinin sadece dini değil, aynı zamanda canlı olduğunu da doğrulamaktadır. 2-Türk diline aynı telaffuz ve farklı anlamlarla girmiş kelimeler: Ayyaş, Türkçe manası içkiye düşkün Arapça manası خباز أو بائع الخبز, Fakat, Türkçe manası lâkin, ama, Arapça manası فحسب، وتقترن بالعدد حتى لا يزداد عليه, Misafir, Türkçe manası zayıf Arapça manası خرج للارتحال,(2004.,Dağarcık) Türkçeye giren, telaffuzlarını koruyan ve anlam bakımından farklılık gösteren bazı Arapça kelimeleri göstermektedir. Belki de bu, Arap dilinin etkisinin başlangıcı ve Arap dilinin erken başlangıçlarında genişlememesi ve Arapça anlamını kontrol etmeden insanlar arasında dolaşmaya başlaması nedeniyledir. 3- Arapçadaki bazı kelimeler çoğuldur ve Türkçede çoğul olduklarında çoğul ekin (lar) tekrar eklendiğini fark ederiz: Akraba(LAR)أقرباء Elbise(LER)ألبسة Eşya(LAR)أشياء Talebe(LER) طلبة (2004.,Dağarcık). Arapça çoğul formda (çoğul erkeksi Salem, çoğul kadınsı Salem, Çoğul Taksir), bu çoğul formları farklı formlarda Türkçe'ye girdi, Türkler bir kez daha çoğul sonek (lar) ekledi,böylece kelime iki kez, bir kez Arapça ve bir kez Türkçe olarak toplandı.

Türk dilinin Arapçadaki etki alanları, Osmanlı İmparatorluğu'nun 400 yıldan fazla bir süredir Arap devletlerinin yönettiği ve elbette Arap dilinin Türk dilinden etkilendiği ve Akmladdin oğlu, Arapların o zamanlar kullandıkları bu Türkçe kelimeleri topladığı bilinmektedir: Bulgur بُرغُل, Pastırmaبَسْطرما Teneke تَنَكَة Bahşiş بَقْشِيش Burgu بُرغي (2004.,Dağarcık). Bu dönemde, insanların birbirleriyle karışması sonucu olarak bir dil hazinesinden diğerine kelime girmesi normaldir ve bugün bile Arapça'da bazı Türkçe kelimeler kullanılmaktadır.

Sonuç olarak, her devletin diğerinden farklı olan kendi dili vardır, dil kültürün aynasıdır, insanlar tarafından edebiyat ve düşünce dilini ifade

etmek için kullanılan bir araçtır. Arapça, Kur'an-ı Kerim'in dili olduğunu bildiğimiz için Türk Dili üzerinde büyük bir etkiye sahipti.

**Edebiyat**


1. ابراهيم أنيس. من أسرار اللغة العربية: القاهرة، 1978. – 332 ص.

2. أكمل الدين إحسان أوغلى. التلاقح بين اللغة العربية ولغات المسلمين الأخرى. 2012
http://www.wata.cc/forums/showthread.php?94481

3. Serdar Mutçalı. Dağarcık TÜRKÇE – ARAPÇA SÖZLÜK . İstanbul, 2004, s1046


## ТАТАР МАТБУГАТЫНДА СПОРТ ЖУРНАЛИСТИКАСЫНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮ ТАРИХЫ


*Галәветдинова Л, КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Хөснетдинов Д.Х.*


Массакүләм мәгълүмат чараларында да спорт темасы аерым урынны алып тора. Махсус спорт темасына багышланган басмалардан кала барлык газет һәм журналлар да спортка кагылышлы мәгълүматны яктырталар. Телевидениядә спорт редакцияләре эшләп килә, спорт яңалыкларын гына хәбәр итүче каналлар да әз түгел. Әлеге фәнни эшебездә без татар матбугатында спорт журналистикасының барлыкка килү тарихын өйрәндек.

Татар матбугатында спорт журналистикасы соң формалаша. 1905 нче елны революцион көрәш нәтиҗәсендә, Россиянең төрле төбәкләрендә, татарлар яши торган зур һәм кечкенә шәһәрләрдә татарча газета һәм журналлар нәшер ителә башлый. Галимнәр фикеренчә, 1905 нче – 1917 нче еллар аралыгында татар телендә төрле 120дән артык газета һәм журнал басылган. Шуңа да карамастан, спорт темасына багышланган махсус газет һәм журналлар теркәлмәгән.

Инкыйлаб чорына кадәр нәшер ителгән матбугатта спорт мәсьәләләре күбесенчә чиктәш темаларга бәйле рәвештә басылып килгән. Татарларның күбесенчә авылда яшәүләре һәм авыл эшенең физик күнегүләр өчен җитәрлек булуы татарларда профессиональ спорт һәм гомумән спорт темасын бик соң гына мәйданга куя. Ләкин спорт темаларын яктырткан язмалар аз түгел.

Чөнки ат чабышы, көрәш кебек спорт төрләре бик борынгы заманнардан ук халыкны кызыксындыра, 20 нче гасырда Россиягә бокс, футбол, хоккей, теннис кебек спорт уеннары үтеп керә. 1874 нче елгы хәрби реформадан соң хезмәт итү вакыты кыскартылып булачак солдатларның физик яктан үсешенә һәм хәрби әзерлекләренә игътибар арта. Рус уку йортларында гимнастика дәресләре шуннан соң кертелә башлый. Гимнастика дәресләре җәдит мәдрәсәләренең уку программаларына да кертелгән. 1907 нче елда Сембер шәһәрендә фабрикант Акчуриннар ачкан ирләр мәктәбендә, 1912 нче елдан

Уфадагы “Галия” мәдрәсәсендә укучылар физкультура белән шөгыльләнә башлый. Кышын “Галия” шәкертләре мәдрәсә шугалагында тимераякта шуганнар. “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе янында да шундый шугалак булуы билгеле. Әлеге барлык вакыйгалар заман газеталарында теркәлгән [1].

Спорт темасын иң беренче күтәреп чыгучылар җәдидчеләр дияргә мөмкин. Мәдрәсәләрне ислах кылу, укыту программаларын үзгәртү, мәктәпне көнбатыш системасына таба юнәлтү юлында яңа дәресләр, яңа тәрбия мәсьәләләре дә килеп керә. “Хифзы сыйххәт”, “тәрбия бәдәния”, ягъни, сәламәтлекне саклау, тәнне тәрбияләү төшенчәләре нәкъ җәдид мөгаллимнәре күтәргән төшенчәләр. Шуңа күрә бу тема иң беренче шуларның матбугатында күтәрелеп чыга.

Исмәгыйль Гаспралы нәшер иткән “Галәми Сыбьян” журналы, балалар тәрбиясенә караган журнал буларак, балалар өчен физик күнегүләр турында мәкаләләр бастыра. Мәсәлән, 1912 нче елның 24 нче санында “Бәдән тәрбиясе яки гимнастик” дигән мәкалә урнашкан. Әлеге язма автор ата-бабалардан калган “хәрәкәттә бәрәкәт” мәкален докторларның “хәрәкәтсезлек хәятнең иң бөек дошманыдыр” дигән сүзе белән бәйләп, гимнастика турында кыска гына мәгълүмат бирә. Ул гимнастиканың организм өчен булган бик күп файдаларын санап чыга: “итләр куәтләнер, зиһен ачылыр, йөрергә җәсарәт (активлык) килер, тәнәффес (сулау) вә һадм (ашказаны эшләү) низам вә тәртип буенча эш күрер”. Автор гимнастиканың рәвешен аңлата, аны әкрен генә башларга тиеш икәнен билгеләп үтә. “Гимнастиканың иң бөек үрнәге – намаз” дигән җөмләсе белән, автор “Шура” журналында бәхәс уятып җибәрә, чөнки аның бу сүзенә каршы әлеге журналга төрле хатлар килә.

Татар матбугатында спорт турында язмалар сирәк булса да, сабан туе ярышлары турында репортажлар еш очрый. Мәсәлән, “Кояш” газетында 1913 нче елгы сабан туе ярышлары турында белеп була. Сабан туеның беренче көне иске стиль белән 10 майда (я.с. 23 май) шәһәр ипподромында үткәрелгән. Спорт төренә караган ярышлардан “ат чабышулары, велосипед узышлары, җәяүле йөгерешләре” кулланылган. Килгән халыкның саны 2500 артык булган, ипподромга кермичә “тыштан билетсыз караучылар да байтак күп” булган.

Сабан туеның программасын караганда, ул башта балалар көрәше белән башланган. Батырга 10лап бала чыккан, аларга кәләпүшләр, “Ак юл” журналларын, китаплар бүләк иткәннәр һәм бу балалар “рәсемнәрен фотограф белән алынды”. Икенче бәйге – зурлар көрәше. Корреспондент әйтүенчә “көчле көчле агайларның татарча оста көрәшүләре шактый озак һәм күңелле үтте. Җиңүчеләргә акчалар өләшенде. Батырга күптәннән бирле көрәшүче Бәрәзә көрәшчесе Хафиз исемле егет калды һәм зурлар

көрәшенә беренче приз итеп тәгаен кылынган 3 сумлык талон бирелде. Бу көрәш шактый тәртипле үтте”. Әгәр “Ак юл” журналының шул ук елда чыккан июнь саннарын карасак (4, 5 нче саннар), без анда сабан туендагы көрәштән фоторепортаж күрәбез, һәм бу нәкъ Казан сабантуенда төшерелгән сурәтләр дип әйтергә җирлек бар. “Беренче көн узган өченче бәйге – француз көрәше, ләкин ул “бик зәгыйфь үтте, мондый французча көрәш булганчы, булмаса да, халык гаепләмәс иде”, дигән фикердә кала автор. Дүртенче бәйге – 3 чакрымлык арада велосипедистлар узышы”.

2009 нчы елда татар матбугатында махсус спортка багышланган “Безнең спорт” газетасы дөнья күрә. Аның баш мөхәррире Илназ Фазуллин була. XX гасыр ахырыннан алып бүгенге көнгә кадәр спорт темасы матбугаттагы төрле газет һәм журналларда яктыртыла. Мәсәлән: “Татарстан яшьләре”, “Мәдәни җомга”, “Ватаным Татарстан”, “Акчарлак”, “Ирек мәйданы” һ.б.

Бүгенге көндә спорт җәмгыятьнең бер өлкәсе генә булып калмыйча, ә күпчелек халыкның кызыксынулар өлкәсенә әверелде. Спорт журналистикасы өлкәсендә күптөрле тикшерүләр үткәрелгән, китап, монографияләр басылган, диссертацияләр якланган. Спорт журналистикасының барлыкка килү һәм үсеш-үзгәреш тарихын күзалларга мөмкинлек туа.

**Әдәбият**


1. XX гасыр башында татарлар арасында спорт. [Интернет-ресурс] // http://shahrikazan.ru/index.php/news/sport/xx-gasyir-bashyinda-tatarlar-arasyinda-sport (мөрәҗәгать итү вакыты: 4.03.2020).
2. Харрасова Р.Ф. Татар матбугаты: бүген һәм иртәгә. – Казан: РИЦ “Школа”, 2010. – 258 б.


## ТНВ ТАПШЫРУЛАРЫНДА СӨЙЛӘМ ТОЛЕРАНТЛЫГЫН БЕЛДЕРҮНЕҢ ЛЕКСИК ЧАРАЛАРЫ


*Галиева Д., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нәбиуллина Г.Ә.*


Толерантлык – социологик термин, дөньяны башкача кабул итүгә, яшәү рәвеше алып баруга, башка төрле тәртип һәм йолаларга түземлелек. Толерантлык битарафлылыкка тиң түгел. Шулай ук башкаларның тормыш-яшәү рәвешен кабул итү дә булмый, аның мәгънәсе – башкаларга үз карашлары белән яшәү хокукы бирүдә [1: 37].

Сөйләм толерантлыгы – ул толерантлык принцибының сөйләмдә саклануы, ул конфликтларны алдан күреп, булдырмый калуга юнәлдерелә.

Сөйләм толерантлыгының морфологик, лексик, синтаксик чараларын аералар. Әлеге фәнни мәкалә кысаларында без ТНВ

тапшыруларында сөйләм толерантлыгын белдерүнең лексик чараларын өйрәндек. Шул уңайдан “Ком сәгате” тапшыруында лексик чараларны анализладык.

Сөйләм толеранлыгының төп лексик чараларыннан эвфемизация санала. Эвфемизм (грекча eu + phemi, ягъни “яхшы сөйлим” дигән мәгънәне белдергән), нәзакатле, үтә әдәпл сөйләмне аңлата. Тупасрак тоелган сүзне, үз исмеме белән әйтмичә, йомшартып, икенче сүз белән белдерүне эвфемизм дип атыйлар [3: 120].

“Ком сәгате” тапшыруындагы журналист сорауларына игътибар итик: *Тарихка күз салсак, 1950 еллар авыл хуҗалыгын торгызу, шәһәрләрне торгызу, сәнәгатьне үстерү, авыл хуҗалыгын үстерү еллары. Барыбер әле ул чорларда безнең халык ачлы-туклы яшәгән, өстенә кияргә киеме җитәрлек булмаган, дип әйтик инде...* [2].

Әлеге юлларда журналист илебездәге сугыш афәтеннән соң тормышны бик йомшак итеп сурәтли. Мәсәлән, *өстенә кияргә киеме җитәрлек булмаган, дип әйтик инде...*

Әлеге тапшыруның кунагы – Рахман Шәфигуллин. Аның этисенең тормышы турында, кулак ителүе турында сораулар биргәндә, алып баручы толерантлы булырга тырыша: *Әйтергә кирәк,* ***сезнең язмалардан күренә ул****, сезнең авыл халкы , менә бу колхозлашу сәясәтен бик ура кычкырып кабул итмәгән.*

Биредә алып баручы язучының фикерләренә таяна һәм билгеле бер күләмдә теләктәшлек тә белдерә, *сезнең язмалардан күренә ул* җөмләсе әңгәмәдәшкә икеләнергә урын калдырмый.

Үз соравына туры һәм төгәл җавап алыр өчен журналист сорауны кабатларга мәҗбүр, әмма ул сорауны сүзен-сүзгә кабатламый, ә бүтәнчә формалаштыра һәм Рахман Шәфинуллинга җавап өчен ике вариант тәкъдим итә: *Менә ул колхозлашу сәясәте, сезнең, мәсәлән, шәхсән сезнең җирлеккә, сезнең авылга ул* ***прогрессив алып килдеме үзгәрешләр, әллә ул барыбер авылны бетерүгә нииндидер юнәлеш булдымы****?*

- *Ни өчен авылдан чыгып киттегез?* ***Мәҗбүр булдыгызмы? Киләчәгегезне күрмәдегезме? Нәрсә сәбәпче булды? Нәрсә мәҗбүр итте?***

Лексик чаралардан без чагыштыруларны да билгели алабыз. Мәсәлән: *Мәктәптә укыган елларыгызда, бала-чагыгызда, тагын да үсә төшкәч, нәсел-нәсебегезнең, чыгышыгызның, янәсе, кулак династиясе булуыгызны ничектер искә төшереп торучылар булдымы? Менә шундый нәселән бит ул! Кулак! Ул вакытта бит инде зур тамга!* ***Кара койрык шикелле*** *сөйрәлеп йөргән!*

Әлеге юлларда чагыштырудан тыш, журналист риторик өндәүләрдән актив файдалана, дәлилләүләр китерә: *Ул вакытта бит инде зур тамга!*

Әңгәмәдәш тә сөйләм толерантлыгын саклый. Аның җавапларында эвфемистик антонимнар аерым урын биләп тора. Алар капма-каршылыкны йомшарталар, сөйләмне әдәпсез, вульгар сүзләрдән арындыралар. Мәсәлән, *ялган* сүзе урынына *дөрес түгел, алай түгел, яман – яхшы түгел, явыз – мәрхәмәтсез, суык – җылы түгел, ямьсез – матур түгел һ.б.* сүзләр куллана алу моңа ачык мисал.

Тапшыруга игътибар итик: *Минем уйлавымча, инвесторларны кертү, минемчә ул безнең эчке сәясәтнең **дөрес булмавын** әйтергә кирәк.* Язучы *хата булуын* диясе урынга йомшак итеп, *дөрес булмавын* ди.

Инвесторларның ни өчен илгә кирәк булмавын болай аңлата: *Безнең авылда "Кызыл Шәрыкъ" ширкәте эшли. Алар көнбагыш үстерә. Алар гектарына анда кырыкмы-сиксәнме килограм минерал ашлама кертәләр дә, көнбагыш үстерәләр. Менә җирнең теге көче беткәчтен, табыш беткәчтен, алар калдырып китәчәкләр*.

Биредә язучының җавабы шактый толерант килеп чыккан, инвесторлар турында алдан, алар, табыш, акча турында гына уйлый дип әйтә, аларның кайчан һәм ни өчен җирләрне ташлап китүен дә шактый тыныч аңлата. Автор биредә шик тә юк, мин шулай дип уйлыйм дигән сүзләрне кулланмый, ә киләчәк заман хикәя фигыль ярдәмендә үз фикерен ачык һәм туры белдерә.

Лексик чаралардан әйтем һәм мәкаләләр куллану да сөйләм толерантлыгына ярдәм итә: *"берни бирми – икене алып булмый"*.

Шулай итеп, ТНВда чыгып килүче "Ком сәгате" тапшыруында сөйләм толерантлыгына урын бар. Тапшыру эчтәлегенең үтемлелеге, әлбәттә, аның темасының укучы өчен якын һәм кызыклы булуы белән, эчтәлегенең аңлаешлылыгы, фикер эзлеклелеге, мантыйкый бәйләнешләрнед төгәл булуы, теленең гадилеге белән бәйле. Шул ук вакытта тапшыруның тәэсир көчен арттыру өчен махсус текст чаралары да бар. Алар – сөйләм толерантлыгы чаралары. Боларны куллану мөһим, чөнки бу алып баручының, тапшыруның йөзен, әхлакый сыйфатларын, этикасын күрсәтеп тора.

**Әдәбият**

1. Жмырева Е.Ю. О gонятии толерантность и ее видах // Вестник Тамбовского государственного технического университета. – 2006. – Том12. – №4Б. – С. 1265-1269.
2. Ком сәгате // ТНВ. – 2021. – 13 февраль.
3. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. – Казан: Раннур, 2002. – 352 б.

## ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Гәрәева А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – пед. фән. докт., проф. Харисов Ф.Ф.*

Фразеологизмнарны телнең җәүһәрләре дип йөртәләр. Алар телнең милли колоритын, үзенчәлеген билгеләр һәм, кагыйдә буларак, телнең үз байлыгы нигезендә барлыкка киләләр.

Лингвистик сүзлекләрдә фразеологизмнарга мондый билгеләмә бирелә: “Бердәмлеге, таркалмавы, компонентлары арасында мәҗбүри бәйләнеш булуы, бөтенлеге, сөйләмгә әзер килеш килеп керүләре белән аерылып торган сүзтезмәләр – фразеологизм дип атала” [2: 196].

Рус телендә фразеологик берәмлек булып семантик яктан бәйле сүз һәм җөмлә кушылмаларының гомуми атамасы буларак билгеләнә, алар, синтаксик структуралардан аермалы буларак, сөйләм оештырганда сүзләрне сайлап алуның һәм комбинацияләүнең гомуми законнарына туры килми, ә сөйләмдә семантик структураның һәм билгеле бер лексик-грамматик составның беркетелгән чагыштырмасында кабатлана [1: 68].

Фразеологик әйтелмә мәгънәсе белән бер сүзгә синоним булып тора ала, дигән фикер яши, һәм күпчелек бу фикерне раслый, мәсәлән: *авыз еру – көлү, тел йоту – дәшмәү, баш вату – уйлау, сай йөзү – белмәү, тел йотарлык – тәмле һ.б.* Рус телендәге мисалларны да китерик. Мәсәлән: *братья наши меньшие – хайваннар, вгонять в краску – каушату, во всю прыть – тиз, войти в историю – данлану, греть душу – шатландыру һ.б.*

Дөрес, кайберләренең күчерелмә мәгънәләрен бер сүз белән генә белдереп булмый, сүзтезмә яки җөмлә ярдәмендә аңлатырга кирәк була, мәсәлән: *авыз ачып йөрү – игътибарсыз булу; күз күрер – вакыты җиткәч; нишләргә икәне билгеле булыр; грош цена – грош иң кечкенә акча берәмлеге (тиен), димәк, бик юнь, бушлай диярлек; дошла как до жирафа – бик акрын аңлаучы* кешегә карата әйтелә.

Бер төркем рус галимнәре, фразеологик әйтелмәләрнең башка берәмлекләрдән аерып торучы төп билгесе итеп аларны башка телләргә тәрҗемә итеп булмауны күрәләр (Л.А. Булаховский, А.А. Реформатский). Чыннан да, кайбер фразеологизмнар башка телләргә турыдан-туры тәрҗемә ителми. Мәсәлән: *Кызыл кар яугач (яуганда) – Когда на горе рак свистнет* [3: 175]. *Имәндә икән чикләвек! – Вот где собака зарыта! / Вот в чем дело!* [3: 106]. *Балтасы суга төшкән (кеше) кебек – Как в воду опущенный* [3: 45].

Фразеологик әйтелмәләрнең төп өлеше, ирекле сүзтезмәләрнең метафорик мәгънәдә кулланылуы нигезендә барлыкка килә: *алтын кеше; бәлеш авыз; бугазыннан тотып алу; түшәмгә төкереп яту; сукыр тавык; тавык йөрәк; тавышы таш яра; таш маңгай; таш күңел; озын куллы; пычрак авыз; сәнәктән көрәк булган; тукмак*

*борын; чиләгенә капкачы; кара эчле; колагы – ишек, авызы – капка һ.б.* Рус теленнән мисаллар китерик: *чему Ваня не научился, того Иван не выучит, ни в зуб ногой толкнуть не может, Алеха сельский, цыплята курицу не учат һ.б.*

Кайбер составлы терминнар фразеологик әйтелмә булып китәләр. Бу очракта алар, үзләренең туры мәгънәләрен югалтып, күчерелмә мәгънәдә кулланылышта йөриләр, образлылык, сурәтлелек, экспрессивлык кебек билгеләргә ия булалар. Мәсәлән: *кызыл юл; нәсел агачы; салкын сугыш; тел алу; йөз сиксән градуска әйләндерү; фундамент салу; сару кайнау; тавык күзе; троянский конь.*

Татар халык мәкальләре, кыскартылып, фразеологизм буларак кулланыла башлыйлар, мәсәлән, *ата малы улга йокмас; йөрәккә боз булып утыру;авыз пешү;баш бетү; бүрәнә аша бүре күрү;күз чыгу;акка тук яшәү; ботка пешмәү; маңгай йолдызлы булу; ике тәкә башы; кан тарту; чанасына утыру кебек* берәмлекләрнең чыганагы булып *Үзебез тапкан мал түгел, атай тапкан җәл түгел; Маңгайдан аккан ачы тир табанга җитсә тоз булыр, колактан кергән ачы сүз йөрәккә җитсә боз булыр* мәкальләре санала.

Рус телендә дә мондый фразеологик берәмлекләр шактый. Мәсәлән: *гоняться за двумя зайцами* фразеологизмы *за двумя зайцами погонишься – ни одного не поймаешь; как с гуся вода* фразеологизмы *как с гуся вода, небывалые слова; мокрая курица* фразеологизмы *пьяному море по колено, а лужа по уши* кебек мәкальләрдән алынган.

Фразеологизмнарның шактый өлеше халык авыз иҗаты әсәрләреннән алынган, мәсәлән, татар, рус һәм бүтән халык әкиятләреннән телгә түбәндәге тотрыклы сүзтезмәләр үтеп кергән: *су анасы; акбүз ат; алаймы булган, болаймы булган; алтмыш колач алайгыр; кәкре каенга терәтү; башын алса, койрыгы ябыша; койрык бозга бату; кабы я была царица, во лбу звезда горит, у разбитого корыта, принцесса на горошине, а король-то голый һ.б.*

Фразеологизмнар барлыкка килү – катлаулы тарихи һәм мәдәни процесс. Халыкның үткәне турында борынгы кулъязмалар, кабер ташлары, тарихи язмалар, сәнгать әсәрләре аша гына түгел, ә шул халыкның теле буенча да белеп була.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: фразеологизмнарның төп үзенчәлекләре мәҗбүри бәйләнеш булу, бөтенлеге, сөйләмгә әзер килеш килеп керү, структур яктан тотрыклы булуы белән характерлана.

**Әдәбият**

1. Ройзензон Л.И. Лекции по общей и русской фразеологии. – Самарканд, 1973. – 223 с.

2. Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов / под ред. Ф.И. Тагировой и Ф.Ф. Гаффаровой. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – 248 с.
3. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001. – 335 б.

## ХӘЗЕРГЕ АВТОР ҖЫРЛАРЫНЫҢ ТЕЛ-СТИЛЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Җиһаншина М., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – фил. фән. докт., проф. Минһаҗева Л.И.*

Җыр – халык лирикасының һәм язма поэзиянең киң таралган төре, сүз-текст белән көй-музыканың үзара үрелүенә нигезләнгән, җырлап башкаруга исәп ителгән жанр [2: 3].

Җыр – халык лирикасының иң таралган төре, сүз белән көйнең үзара үрелүенә нигезләнгән, җырлап башкарыла торган шигъри-музыкаль әсәр, яки, киң мәгънәдә алганда, шундый төр әсәрләрне белдерә торган жанр. Җырның төп функциясе – халыкның һәм шәхеснең рухи дөньясын, фикер һәм кичерешләрен чагылдыру. Шунлыктан хәзерге вакытта автор җырларының тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәнү бик мөһим.

Әлеге эш өчен без соңгы елларда яңгыраган автор җырларын алдык. Мәсәлән, “Яшәргә өйрәт, йөрәк” җырына күз салыйк. Җырның сүзләре һәм көен Зифа Нагаева язган. Җырның сүзләренә игътибар итик. Автор җырны язуда бик күп кабатлаулар кулланган. Мәсәлән:

***Бер ягымда** кыя, **бер ягымда** упкын,*
*Йөрәккә кадалган очып үткән угы.*

Әлеге очракта кабатлау капма-каршылыкны белдереп килә. Шулай итеп, тыңлаучыга йөрәктә каршылык барлыгын белдерә.

***Арыды** йөрәк, **арыды**, миннән **арыды,***
*Йотып зар-утны, җыеп бар укны.*

Бу юлларда кабатлау котылгысызлыкны аңлатып килә. Тыңлаучы әлеге юллардан югалту, бушлыкны кичерә.

*Мин сиңа кирәкмен бүген, син миңа кирәк,*
*Яңадан яшәргә өйрәт, яңадан, йөрәк!*
*Жәлләтмим, көтмим ярдәмнәр ят тарафлардан.*

Кушымтада кабатлаулар бирелә: *Мин сиңа кирәкмен бүген, син миңа кирәк.* Әлеге кабатлаулар антитеза хасил итә һәм тыңлаучыга йөрәк белән кешенең аерылгысыз булу фикерен җиткерә.

Шулай ук автор синонимнарга да мөрәҗәгать итә: *җәлләтмим, көтмим ярдәмнәр* сүзләре контекстуаль синонимнар хасил итә. Җырда алар образ һәм сөйләм мелодикасын тудыру өчен хезмәт итәләр.

*Кисәкләп җыйдым шатлыкларны да,*
*Бәхетләрне дә җыйдым кисәкләп.*

Әлеге юлларда автор тагын кабатлауларга мөрәҗәгать итә. Биредә анэпифора кулланылган. Анэпифора (анафора + эпифора) – сүз, җөмлә башта яисә ахырда кабатлану. Анэпифора нигездә персонаж сөйләменә хас, автор сөйләмендә дә катнаша [3: 156].

Шулай ук җырда фразеологизм да бар:

*Рәнҗетмәгез кеше җанын – **кала күңелдә,***

*Бүген синдә бәхет куна, иртәгә – миндә.*

“Белә идең” җырының авторлары: Айгөл Вәлиуллина сүзләренә Гүзәлия көй язган. Шулай ук җырларга хас булганча, кабатлаулар төп урынны алып тора:

*Белә идең бит син, барын белә идең,*

*Татлы иренеңне назлап үбә идем.*

*Сине сөйгәнемне күздән күрә идең,*

*Кем дип яшәвеңне күптән белә идең.*

Һәр юл “идең” сүзе белән тәмамлана. Димәк, автор кабатлауның эпифора төренә мөрәҗәгать иткән.

Шулай ук җырның өч дүртьюллыгы да “белә идең” сүзләре белән башлана, ә соңгысында “белә идем” диелә.

***Белә идең** бит син сиңа талпынганны,*

*Мәхәббәтнең тәмен синдә татыганны.*

***Белә идең** бит син сине сагынганны,*

*Җылы эзләп җаным сиңа сарылганны.*

***Белә идем** бит мин серле күзләреңне,*

*Минем юлларыма гөлләр тезгәнеңне.*

Җырда стилистик чаралардан чагыштыру бар:

***Күләгәдәй** сине куып йөргәнемне,*

*Иркә күңелеңне хискә төргәнемне.*

Автор шулай ук эпитетлардан киң файдалана: *иркә күңел, татлы ирен, серле күзләр.*

Бу мисаллар билгеле бер поэтик күренешне тасвирлауда иң төгәл, иң кирәкле сүз буларак катнашканлыктан, образлы яңгырый, җырда сүз-сурәт булып килә.

Тагын бер без карап үткән шигырь туган йорт турында. Ул Резеда Шәрәфиева репертуарыннан, авторлары: Зөфәр Вәлитов сүзләре һәм Флера Шәрипова көе. Җыр салмак көй белән башкарыла. Сүзләренә килгәндә, лексик һәм стилистик чаралар, эндәшүләр, кабатлаулар кулланылаган.

Мәсәлән, лексик чаралардан синонимнар бар:

*Бар туганнар бергә җыелганда*

*Газиз йортның җылы түренә,*

*Киләчәккә барыр юлларыбыз*

***Якты, туры, ачык*** *күренә.*

Әлеге синонимнардан *якты* һәм *ачык* сүзләре тел синонимнары һәм бу сүзләргә карата *туры* сүзе контекстуаль синоним. ***Якты, туры, ачык*** сүзләренең кулланылышы контекстка турыдан-туры бәйлелек булганга күрә файдаланылган.

Стилистик чаралардан метафора да бар:

*Туган йортта бергә җыелганда*
*Юктыр кебек бездән бәхетле.*
*Гомеребез буе онытмабыз*
***Әткәй-әнкәй корган тәхетне!***

Күренешләр һәм төрле предметлар арасындагы бәйләнешләр ярдәмендә күчерелмә мәгънә барлыкка килә. Бу образлы фикерләү тудыруга, зур һәм катлаулы күренешләрне җыйнак кына бер сүз белән әйтеп бирергә ярдәм итә. Җырлар метафорадан башка бик ярлы булырлар иде, чөнки алар образлы сурәтләү өчен хезмәт итәләр.

Җырларда уңышлы файдаланылган поэтик алымнарның тагын берсе – лирик эндәшләр:

*Беркайчан да тәхет сатылмаган,*
*Ул сатылса ил дә сатыла.*
*Саклыйк,* **дуслар,** *туып-үскән йортны,*
*Әткәй-әнкәйләрнең хакына.*

Гомумән алганда, җырларда урын алган гаҗәеп бай образлар системасы, ул образларның күптөрле мәгънәгә ия булуы халыкның күзәтүчәнлеге, табигать һәм тормышның һәр күренешеннән матурлык, шигърият эзләве турында сөйли, җырлардагы сүз сәнгатенең гасырлар дәвамында формалашуын һәм камилләшүен күрсәтә. Ә шушы сүз сәнгатен чагыштырма планда тикшерү төрле халыкларның яшәү рәвеше, дөньяга карашы, фикерләвендәге уртаклыкларны күрергә һәм милли үзенчәлекләрне ачыкларга ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
2. Миңнуллин К. Җырларның шигъри табигате. – Казан: Мастер Лайн, 1999. – 107 б.
3. Татар җырлары // URL: http://erlar.ru/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 19.01.2021)
4. Фәттахов И.Ф. Әдәбият теориясе нигезләре: журналистика факультеты студентлары өчен “Әдәбият теориясе нигезләре” дисциплинасыннан уку ярдәмлеге. – Казан: КФУ нәшр., 2011. – 210 б.

## ТӨРЕК ТЕЛЕНЕҢ ФРАЗЕОЛОГИК ФОНДЫНДА “ИКМӘК” КОНЦЕПТЫ

*Закирова А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*

Телдәге төшенчәләр бер сүз белән генә түгел, ә катып калган, таркалмый торган сүзтезмәләр белән дә белдереләләр. Мондый сүзтезмәләр фразеологизмнар дип атала. Грекчадан *phrasis* – тәгъбир, сөйләм әйләнмәсе, *logos* – өйрәнү дигәнне аңлата. Халык тәҗрибәсен чагылдырган тел берәмлекләре буларак, алар билгеле бер күренешне тасвирлауны җиңеләйтә. Аларның әһәмияте дә шунда: фразеологизмнар берничә җөмлә белән генә әйтеп була торган фикерне җиткерү сәләтенә ия. Фразеологизм ул, асылда, бербөтен мәгънә белдерүче, чынбарлыктагы күренешләрне тәэсирле, сурәтле һәм сәнгатьле итеп чагылдыручы, семантик һәм синтаксик яктан таркалмый торган тотрыклы сүз тезмәсе.

Фразеологик әйтелмәләр телдә гаять әһәмиятле роль уйный. Алар халыкның дөньяга карашын, әйләнә-тирәне күзаллау, бәя бирү үзенчәлекләрен, менталитетын күрсәтүче тел җәүһәрләре. Гади сүз һәм сүзтезмәдән аермалы буларак, фразеологизмнар төшенчәне, фикерне сурәтле, бизәкле, тәэсирле итеп белдерәләр, димәк, коммуникатив вазифа башкарудан тыш, эстетик бурыч та үтиләр. Кеше үзенең сөйләмендә фразеологик берәмлекләрдән ни дәрәҗәдә мул һәм уңышлы файдаланса, аның фикере башкаларга шул дәрәҗәдә җиңелрәк, тизрәк һәм күркәмрәк булып барып җитә, аларның хисләренә ныграк тәэсир итә. Шул ук вакытта телнең фразеологик фондында шул телдә сөйләшүче халык мәдәниятенең “эзләре” ята: гореф-гадәтләре, традицияләре, көнкүреше, тарихи фактлар һәм халыкның матди мәдәнияте чагылыш таба. Икенче төрле әйткәндә, фразеологизмнар теге яки бу халыкның мәдәниятен тану чыганагы да, ягъни алар “телнең мәдәни трансляторы ролен үтиләр” [1: 11]. Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, “икмәк” концептының фразеологик берәмлекләрдә чагылышын өйрәнү әлеге фразеологик берәмлекләрнең нигезендә яткан мәдәни мәгълүматны ачыкларга ярдәм итә. Күп кенә тикшеренүчеләр фикеренчә, фразеологик берәмлекләр мәдәни-милли эталоннар, стереотиплар, мифологемалар, символ-детальләр ярдәмендә теге яки бу халыкның менталитетын чагылдыра [5: 62].

Төрек телендә “икмәк” концепты – кешенең яшәешен, көнкүрешен билгеләүче төп концептларның берсе. Әлеге концептның фразеологик берәмлекләр составында реальләшүен карап үтик. Төп компоненты икмәк концепты булган фразеологик берәмлекләрдә *ekmek* лексемасы еш очрый.

1. Икмәк/Ekmek лексемасының “ашамлык” мәгънәсендә кулланылган ФБләр: *ekmek çarpsın (ki), ekmek gözüme (değsin)* – үз сүзераслыгына иң авыр ант, ягъни ялган әйтсәм, төп ризыгым булган икмәксез калып, ачтан үлим; *ekmek gözüme (değsin)* [7: 272] – сүзенең

раслыгына аны танык итеп, аны тотып ант итү. Ягъни әгәр кеше алдаласа, ул төп кәсепсез һәм ризыксыз, ач калуын белдергән.

Әлеге төркемчәгә кергән ФБ арасында тискәре мөнәсәбәттә кулланылганнары да очрый. Мәсәлән, *kuru ekmek vermek* – аш-сусыз, коры икмәк тә су белән ризыкландыру; *ekmek çarpar, Allah çarpar* [7: 273] – аш-сый, хөрмәткә каршы яманлык иткән кешегә карата каргап әйтем. Икмәк борынгыдан бирле иң олы ризык саналудан, икмәкне Алла урынына куеп, төп кодрәт иясе итеп ант итү.

2. Кешене характерлаучы ФБләр: *ekmeğini yemek* – бушка ашап ятучы, әрәмтамак, исрафчы; *ekmeğine yağ sürmek* – тәлинкә тота, тәлинкәсен ялый, куштанлык итә, аны яклый, яраклана, ялагайлана; *ekmek düşmanı* – гаиләдә яшәү өчен акча тәэмин итүдә катнашмый торган кеше; *ekmeği dizinde* – гамьсез; *tuz ekmek düşmanı* – яхшылыкны белмәгән кеше; *ekmek düşmanı, kepçe kuyruk* – икмәк бүресе, икмәк көясе, икмәк череткеч; *ekmek düşmanı olmak* – икмәк черетеп яту; *ekmediği yerden biter* [7: 272] – көтелмәгән һәм теләмәгән урында очраучылар өчен кулланыла торган бер сүз.

Тупланган фразеологик берәмлекләрдән күренгәнчә, кешенең тискәре сыйфатларын белдерүче берәмлекләр уңай сыйфатларны чагылдарган берәмлекләргә караганда күбрәк. Бу кешенең тискәре сыйфатлары игътибарны җәлеп итүе,  халыкның тискәре сыйфат өстендә “көлә”, аны аерып күрсәтергә теләве белән бәйле.

3. Өченче төркемгә *икмәк/ekmek* лексемасының “яшәү чыганагы, эш хакы” мәгънәсендә кулланылган ФБләр керә: *ekmek kaygısı* – акча эшләргә омтылыш; *ekmek kapısı* – акча тәэмин итә торган эш урыны; *ekmek kavgası* – тормыш итәргә акча эшләргә тырышу; *ekmeğini kazanmak* – яшәү өчен акча белән тәэмин ителү; *ekmeğini çıkarmak* – эшләгән эшендә тормыш итү өчен җитәрлек табыш алу; *ekmeğinden olmak* – тормыш өчен акча эшли торган эштән азат ителү; *ekmek parası* – тормыш итү өчен акча яки керемнәр; *ekmeğini taştan çıkarmak* – тормыш итү өчен акча эшләүдә бик тапкыр булу, хәтта иң катлаулы шартларда да табыш тәэмин итү; *ekmeğini eline almak* – тормыш итәр өчен акча эшләү; *ekmeğinden etmek* [7: 273] – эшеннән куу.

4. Төрле ситуацияләрне характерлаучы ФБ: *eken biçer, konan göçer* - һәр тәртибе табигый нәтиҗәгә килә; уңыш чәчкән уңыш ала; *ekmeden biçilmez* – көтелгән нәтиҗәгә хезмәтсез генә ирешелмәс; *ekmeğin büyüğü, hamurun çoğundan olur* – нәтиҗәлелек материалның мул кулланылуына бәйле; *ekmek istemez su istemez* – бернинди чыгымнары булмаган; *ekmeğini kana doğramak* [7: 273] – зур күңелсезлекләргә һәм кайгыга түзү.

*Икмәк* концептлы ФБләрнең күп булуы төрек халкы мәдәниятендә «икмәк – ризык» дигән төшенчәнең доминанта булуын исбатлый торган дәлил. Төрек дөнья тел картинасында *Икмәк* төп урынны алып тора. ФБләр составында очраган икмәк кунакчыллыкны гәүдәләндерә, дуслык мөнәсәбәтләрен билгели, төп ризык булуын ассызыклый. Шулай ук *икмәк* лексемасы тирәсендә оешкан ФБләр кешенең төп яшәү чыганагы; икмәктән башка калу җәза буларак аңлашыла, кешене төрле яклап характерлау мәгънәләрендә дә кулланыла. *Икмәк* концепты кергән фразеологик берәмлекләр мәдәни һәм иҗтмагый кыйммәткә ия, төрек лингвомәдәниятендә мөһим урын тота.

**Әдәбият**


1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләре сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 176 б.
2. Борһанова Н.Б., Мәхмүтова Л.Т. Русча-татарча фразеологик сүзлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 180 б.
3. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 495 б.
4. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. 2 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 365 б.
5. Стернин И.А. Методика исследования структуры концепта // Методологические проблемы когнитивной лингвистики. – Воронеж, 2001. – С. 58-65.
6. Телия В.Н. О специфике отображения мира психики и знания в языке // Сущность, развитие и функции языка. – М., 1987. – С.67-75.
7. Erdal Şahin Tatar Türkçesi - Türkiye Türkçesi/ Eş anlamlı deyımler sözküğü (A- Y). Haarlem, 2016. 272-273.
8. Фелицына В.П., Мокиенко В.М. Русские фразеологизмы. – М., 1990. – 220 с.


## “ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН” ГАЗЕТАСЫНДА СОҢГЫ ЕЛЛАРДА ЧЫККАН МӘКАЛӘ АТАМАЛАРЫНДА ҖӨМЛӘ ТӨРЛӘРЕ


*Закирова Ә., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сәгъдиева Р.К.*


Бүгенге көндә татар матбугатында газета-журналлар күп. Аларның һәркайсысы татар матбугатын баетуга гасырлар дәвамында үз өлешен кертә. “Ватаным Татарстан” иҗтимагый-сәяси газетасының 100 еллык тарихы бар. Бу мәкаләдә без “Ватаным Татарстан” газетасының соңгы елларда чыккан мәкалә атамаларына тукталдык.

“Ватаным Татарстан” газетасында соңгы елларда чыккан мәкалә атамаларында җөмлә төрләрен билгеләү өчен без 2019 нчы һәм 2020 нче елда чыккан гыйнварь-май басмаларына тукталдык. Һәр җөмлә төрләрен мисаллар белән дәлилләп, еш кулланыла торган җөмләләрне ачыкларга тырыштык.

2019 нчы елгы басмалардан инкяр җөмләләргә мисаллар: *“Кайбыч районы башлыгы Альберт Рәхмәтуллин: “Авыл булмаса, ил*

*юк", "Яндырдың да, бетте түгел", "Араның ерагайганы юк"* һ.б. 2020 нче елгы басмалардан инкяр җөмләләргә мисаллар: "*Кунакка йөрер вакыт түгел","Нигә миңа бернинди ярдәм юк?", "Игелекле эшнең иртәсе-киче юк: ничек волонтер булырга?"* һ.б.

Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, өлешчә инкяр җөмләләрнең саны тулы инкяр җөмләләрдән бик аерыла, аларның саны шактый аз. 2019 нчы елгы басмалардан өлешчә инкяр җөмләләргә мисаллар: *"Йорт җире түгел, башкасы кирәк", "Аларны төрмә түгел, ирек куркыта"* һ.б. 2020 нче елгы басмалардан өлешчә инкяр җөмләләргә мисаллар: *"Бирешә торган халык түгел", "Ерак түгел булган хәл"*. 2020 нче елгы саннарда мәкалә атамасы исемендә өлешчә инкяр җөмләләрнең саны 2019 нчы елга караганда кимрәк.

Әйтү максаты буенча жөмлә төрләренең барысы да мәкалә атамаларында кулланылалар. Шулай да хикәя һәм сорау җөмләләр саны күп. 2019 нчы елгы газет саннарыннан мисаллар. Хикәя җөмләләр: *"Милли моң аксакалы", "Мөселман кинофестивале: вакыты үзгәрсә дә, мәгънәсе шул ук", "Яшәү – яхшы, яхшы яшәү тагы да шәп"* һ.б. Сорау җөмләләр: *"Нишләтәләр сине, авыл?", "Бүләкне кемнәр алыр?"* һ.б. Боеру җөмләләр: *"Урманнарны саклыйк!", "Экология министры: "Күрми калырлар, дип өметләнмәгез"* һ.б. Тойгылы җөмләләр: *"Чүп бәясен язып саныйлар?!", "Картаймый тор, йөрәк!"* һ.б.

2020 нче елгы саннардан мисаллар. Хикәя җөмләләр: *"Туган тел – безне бер гаилә итә торган байлык", "Алдан язылмаган кешеләргә чебиләр җитми дә әле"* һ.б. Сорау җөмләләр: *"Өйдә балалар белән нинди уеннар уйнарга мөмкин?", "Пенсиягә чыккач, бирелми калган акчаны ничек алырга?"* һ.б. Боеру җөмләләр: "Эшләрегезне вакытлычы калдырып торыгыз", "Пандемиянең халык кеременә, мәшгульлегенә начар йогынтысын киметергә кирәк" һ.б. Тойгылы җөмләләр: *"Помидор үсентеләре нык булсын өчен аларны "кытыкларга" кирәк?!", "Лимон – әҗәл даруы?"* һ.б. Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләренең кулланышы ике елгы саннарда да тигез дәрәҗәдә.

"Ватаным Татарстан" газетасының мәкалә атамаларында тулы җөмләләр кулланыла. Шуңа да карамастан, ким җөмләләргә дә мисаллар бар. 2019 нчы ел: *"Яңа ел белән", "Яңа ел, Яңа ел, безне бик", "Тиздән", "Ничек башладыгыз?"*. 2020 нче ел: *"Кайларда икән?", "Өлгерәсе иде..", "Нишләргә?"*.

Мәкалә атамаларында җәенке җөмләләр күбрәк кулланылалар. Чөнки җәенке җөмләле мәкалә атамасы укучыга мәгълүматны тулырак бирә. 2019 нчы елгы газета саннарыннан мисаллар: *"Укучылар укыйлар", "Вакыт җиткән", "Кошлар кайтты"*. Җәенке җөмләләр:

*“Үткәннәргә кайтып килим дисәң...”, “Авылда хезмәт хакы шәһәрнекеннән ким булмаска тиеш”* һ.б.

2020 нче елгы җәенке җөмләле мәкалә атамалары**:** ***“****Яшәгез әле, ветераннар: Бөек Ватан сугышы ветераннарына 100 меңе дә, торагы да, медале дә һәм башка төр ярдәме дә булачак”, “Буыннар сызлаганда үги ана яфрагы белән әрекмәнне искә алырга кирәк”* һ.б. Җыйнак җөмләләр: *“Банан файдалымы?”, “Су булырмы?”, “Аш пешерәбез”.*

2019 нчы һәм 2020 нче елгы җәенке һәм җыйнак җөмләле мәкалә атамаларында аерма юк. Ике елга караган газета саннарында да җәенке җөмләләр саны күп, җыйнак җөмләләр бик аз.

Алга таба без гади кушма җөмләләрне тикшердек. “Ватаным Татарстан” газетасында аналитик иярчен җөмләләргә караганда синтетик иярчен җөмләләр саны күбрәк. 2019 нчы елгы газет саннарыннан синтетик иярчен җөмләләргә мисаллар: “*Ул-бу чыкса, телефонга яздырасызмы?*”, “*Бәясе арткач, сыйфат та яхшы булсын!”, “Файдасы булса, яхшы*” һ.б.

2020 нче елгы газет саннарыннан мисаллар: *“Җәен тәмлесен һәм эресен ашыйм, дисәң җиләкне ничек “тәрбияләргә?”, “Яңа телне ансат һәм җиңел генә өйрәнү өчен чит телдә генә сөйләшүче кешегә гашыйк булыгыз!”* һ.б. Мисалларга игътибар итсәк, синтетик иярчен җөмләләр күбрәк баш җөмләләргә сүз бәйләүче кушымчалар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, янәшә тору чаралары белән ияргәнен күрәбез.

2019 нчы елгы басмалардан аналитик иярчен җөмләләргә мисаллар: *“Кайда телисең, шунда яшә”, “Кем беренчелекне ала, шуны данлыйлар”* һ.б. 2020 нче газет саннарыннан аналитик иярчен мәкалә атамаларына мисаллар: *“Шул чишмә янында әтием көтеп утырадыр төсле”, “Шулай булыр дип уйламаган да идек”* һ.б. Нәтиҗәләр күрсәткәнчә, “Ватаным Татарстан” газетасының 2019 нчы елгы мәкалә атамаларында аналитик иярчен җөмләләргә мисаллар 2020 нче елгы саннарга караганда күбрәк кулланылган. Иярчен җөмләләр баш җөмләгә ялгызак мөнәсәбәтле сүз, бәйлек һәм теркәгеч сүзләр ярдәмендә иярә.

Йомгаклап әйткәндә, “Ватаным Татарстан” газетасының мәкалә атамаларында төрле җөмлә төрләре кулланылган. Билгеле бер кагыйдәләргә һәм формаларга гына таянып төзелгән җөмләләр юк.

**Әдәбият**

1. Зәкиев М.З. Татар синтаксисы: югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.

2. Ибраһимов С.М. Сандугач теле кирәк: Синтаксик стилистика: Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.

## “КАРГА” АТАМАСЫ КУЛЛАНЫЛГАН МӘКАЛЬЛӘРГӘ ЛИНГВОМӘДӘНИ АНАЛИЗ

*Ибраһимова А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Саттарова М.Р.*

Мәкальләр фольклор жанры буларак традицион мәдәниятнең аерылгысыз өлеше булып торалар. Фольклор милли мәдәниятләрне тергезүдә, үсеш-үзгәрешендә һәм үзара баетуында катнаша, аның интенсификациясенә булышчылык итә. Җәмгыять билгеле бер чорда, үзен мифларда, легендаларда, экиятләрдә, сәнгатьтә, фольклорда һәм әдәбиятта чагылдыра [2: 2].

Төрле милләттә үзләренә хас мәкальләр була. Мәкальнең иң зур күпчелеге һәр халыкның иҗтимагый-тарихи тормыш тәҗрибәләреннән һәм ышануларыннан, аның үз теленең иҗат һәм сурәтләмә мөмкинлекләренә таянып барлыкка килә [3: 1].

Татар халкында кош атамалары кулланылган мәкальләр зур урын алып тора, аларда халыкның тормыш кагыйдәләре, киңәшләре, үгет-нәсыйхәтләре күрсәтелә. Әлеге фәнни эшебездә "карга" һәм башка кош атамалары кулланылган татар халык мәкальләренә лингвомәдәни анализ ясау өчен Нәкый Исәнбәтнең җыентыгын кулланылып 35 кош атамасы кергән шундый 355 мәкаль барладык, арада төрдәшләре дә бар. Башка кошлар белән янәшә карга атамасы мәкальләрдә иң еш очрый, андый 70 мәкаль бирелә. Мәкальләрдә карга карчыга атамасы белән 14, каз белән 11, козгын һәм күке белән 7 тапкыр очрый һ.б.

*Карга* сүзе этимологик яктан гомумтөрки *қарға, қарғай* сүзләреннән килеп чыккан, *кар* имитатив, каркылдау авазын белдерә, *-гай, -кай (-га, -ка)* күп кенә кош атамаларында күзәтелә [1: 371]. "*Карга*" сүзенең аңлатмасы исә түбәндәгечә бирелә: 1) козгыннар семьялыгыннан елтыр кара яки шәмәхә кара каурыйлы урта зурлыктагы кош; 2) күч. башкалар исәбенә яшәүче, әрсез кеше; 3) күч. тиешсезгә нәфес сузучы кеше [4: 138].

*Карга* халыкара мифологиядә сирәк кенә уңай, нигездә тискәре персонаж буларак чагылыш таба. Карганың уңай сыйфаты язмада беренче тапкыр Коръәндә телгә алына, анда ул Кабилгә мәетне җиргә күмергә кирәклеген искәртә. Тагын бер уңай сыйфаты экиятләрдә чагылыш таба: башкорт экиятләре "Алтын алма"да һәм "Незнай"да ул ярдәм итүче персонаж буларак бирелгән. Искәртелгәнчә, башка очракларда карга нигездә кире эшләр, күңелсез хәбәр һ.б. шундыйларның символы булып килә [5: 137-138].

Нәкый Исәнбәт җыетыгындагы [3] карга һәм карчыга булган мәкальләргә тукталыйк. Үз урыныңны белү, һәрнәрсәнең үз ише дигәнгә мисал буларак түбәндәге мәкаль бирелә:

*Карга, нихәтле канатын кыеп очса да, карчыга булмас.*

Көчен җитмәстәй белән көрәшмә, үз чамаңны белергә кирәк дигәнне әйтергә теләп халыкта мондый мәкаль бар:

*Әҗәлле карга карчыга белән уйнар.*

Башкаларда нәрсәдер яхшырак күренсә дә, ул әле алай дигән сүз түгел:

*Күрше авылның карчыгасы –*

*Үз авылыңның каргасы.*

Һәркем үз илендә кадерле, хөрмәтле, башка җирдә чит була дигәнгә ишарәт итеп түбәндәге мәкаль күрсәтелгән:

*Чит илнең карчыгасын үз иленең каргасы талый.*

Каз атамасы белән янәшә килгәндә үз чамаңны белүгә мисал буларак әлеге мәкаль бар:

*Казга иярәм дип, карганың боты сынган.*

Никадәр көчле булсаң да, ялгызың гына эш итсәң, җиңелүче тарафта булырга мөмкинсең дип әлеге мәкаль әйтелә:

*Аерылган каз тупланган каргага җим булыр*.

Ел фасылының үзенчәлекләренә бәйле рәвештә дә мәкальләр бар. Казны яз белән, карганы кыш белән бәйләп, символлаштырып күрсәтелә:

*Карга карылдаса, кышны чакырыр;*

*Каз каңгылдаса, язны чакырыр.*

Карга белән козгын янәшә килгән мәкальләргә килгәндә, кемнәрдер сүзгә килгәнне көтеп, шуннан файда табучылар була дип халык әлеге мәкальне уйлап тапкан:

*Ике карга талашса,*

*Бер козгынга җим төшәр.*

Алда биреләчәк мәкаль үзендәге гаеп белән башка кешене гаепләүгә карата әйтелә:

*Козгын карганы «кара!» дип хурлаган.*

Күке белән янәшә килгәндә карга уңай яктан тасвирлана кебек. Андый мәкальләрдә ул тиз ышанучан образ буларак бирелсә дә, читне үз янына сыендырып, тәрбия бирүче ролендә күрсәтелә:

*Күке гыйшык тота,*

*Баласын карга карый.*

Әмма никадәрле тәрбия итсәң дә, чит барыбер чит булып кала, үз тиңдәшен сагына, рәхмәтле булмый, дип әйтергә теләгән халык:

*Карга күке баласын күпме ашатса да, «кәк-күк» дип кычкырыр.*

Шулай итеп, татар халык мәкальләрендә башка кошларга караганда *карга* атамасы иң еш кулланыла, башка кошлар белән янәшә дә иң еш очрый. Бу татар халкының менталитеты, яшәеше белән бәйле.

Фольклорда карга образы сирәк кенә уңай, күпчелек тискәре яктан ачыла. Карга һәм башка кош атамалары белән килгән мәкальләрдә халык чагыштыру алымнарын кулланган, каргага караганда карчыга, каз, козгынны көчлерәк, әһәмиятлерәк итеп, күке белән килгәндә карганы хәйләсез, тиз ышанучан итеп сурәтли. Гомумән, әлеге мәкальләрдә халык үз урыныңны, үз чамаңны белергә кирәк, һәрнәрсәнең үз ише була, чит җирдә чит буласың, бергә-бергә көчле булып, ялгыз булсаң җиңеләсең дип әйтергә тели сыман, шулай ук начарлыктан да файда табучылар булуы турында кисәтә, үзеңдәге гаеп белән башкаларны гаепләмәскә өнди.

**Әдәбият**


1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I том. – Казан: Мәгариф, Вакыт, 2015. – 543 б.
2. Җамалиева Л.Ф., Мотыйгуллина Ә.Р. Татар фольклоры һәм әдәбияты багланышларын өйрәнү тарихыннан. URL: https://kpfu.ru/staff_files/F427626187/Statya_Zamalieva__Motigullina_KFU__KAZAN.pdf.
3. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: өч томда. I том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2010. – 622 б.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: III том. – Казан: ТӘhСИ, 2017. – 744 б.
5. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе: экциклопедик сүзлек: өч томда. II ом. – Казан: Мәгариф, 2009. – 343 б.


## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТЕОРЕТИК ТӨШЕНЧӘЛӘРНЕ ӨЙРӘТҮДӘ ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕҢ РОЛЕ


*Ибраһимова Д., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., доц. Юсупова Н.М.*


Әдәбият белеме күп еллар дәвамында бик зур үзгәрешләр кичерә. Билгеле булганча, әлеге үзгәрешләр әдәбият укыту методикасында да үз эзен калдыралар. Филолог, сәнгать тарихчысы Ф.И. Буслаев – рус теле һәм әдәбиятын укытуның методикасына фәнни нигез салучы. Методика фәненә карашлары аның “О преподавании отечественного языка” (1844) хезмәтендә урын тапкан. Әдәби әсәрне өйрәнү индукция методына нигезләнә: классик әдәби әсәр мөстәкыйль укыла һәм аңа филологик анализ ясала. “Филологик анализ, үз чиратында, теоретик төшенчәләрне өйрәнүгә нигез була. Алар язмача күнегү башкарганда үзләштерелә (тәрҗемә, инша, реферат һ.б.)” [1: 29].

Саналып үтелгән ысулларга күзәтү ясагач, шуны әйтергә мөмкин. Тәкъдим ителгән “һәр өч метод та күпмедер дәрәҗәдә укучыларда теоретик белем булуны сорый, чөнки алар әсәрне анализлауга кайтып кала” [2: 125-126]. Билгеле булганча, әдәби анализ берничек тә коры сүзләр ярдәмендә алып барылмый, укучы инде нәзари төшенчәләр белән эш итә белергә тиеш була.

Рус телле аудиториядә татар әдәбиятын укыту тарихында соңгы берничә ел эчендә үзенең фәнни-методик фикере эшләнде һәм әлеге өлкәдә укыту тәҗрибәсе үзләштерелде. Күрсәтелгән процесс узган гасырның 90 нчы елларында иҗтимагый үзгәртеп корулар шартларында аеруча активлашты. Бу уңайдан А.Г. Әхмәдуллинның, Ф.М. Мусинның, Ф.Г. Галимуллинның, С.Г. Исмәгыйлеваның, А.Г. Яхинның, Д.Ф. Заһидуллинаның, З.Н. Хәбибуллинаның, Ф.Ф. Исламовның, А.М. Закирҗановның һ.б. эшләрен аерым билгеләп үтәргә кирәк.

Бүген дәүләтебез тарафыннан телне укыту һәм яклау буенча законнар кабул ителгән. Ул законнарны тормышка ашыру максатыннан министрлык тарафыннан мәктәпләр өчен уку планнары эшләнгән һәм ул уку планнарында туган телләрне укыту дигән өлеш бар. Элегрәк укытучы яңа теманы бик матур итеп сөйли, ә укучы бары гади үзләштерүче ролен үти иде: бүген исә, укучы яңа теманы үзе эзләүче, тикшеренүче сыйфатында үзләштерергә тиеш дип карала. Хәзерге шартларда, мәгълүматның күләме тиз үскән вакытта, кирәген сайлап ала белергә, тәртипкә китерергә, бәләкәй генә ачыш ясап куана белергә өйрәтү, юл күрсәтү – уку-укыту өчен авыр эш. “Мәктәптәге традицион, бер төрле үткәрелгән дәресләр арасында, гадәти булмаган дәресләр үткәрү укучыларның хәтерендә ныграк кала. Ялыктыргыч эш төрләрен һәр дәрестә кат-кат башкаруга караганда кызыклы ачышлар булганы укучының күңеленә тәэсир итә, аң-белемен киңәйтә, иҗади эзләнүгә теләк тудыра. Шуңа да соңгы вакытта укучының белем сыйфатын күтәрүдә, иҗади сәләтләрен үстерүдә яңа технологияләрне өйрәнү һәм дәрестә куллану турында күп сөйләнелә, языла” [3: 1].

Әдәбият дәресләрендә теоретик материалны өйрәнгәндә кайсы метод-алымнарны куллану уңышлы һәм эффектив булуын билгеләү өчен заманча дәресләрнең төзелешенә һәм таләпләренә игътибар итәргә кирәк. Беренче чиратта, дәресләр коры теория генә корылырга тиеш түгел. Шулай булган очракта да, дәресләрнең ирекле формада үтүе, дәрес материалын уен форматында үзләштерү күпкә продуктив була. Икенчедән, ФГОС таләпләре буенча укытучының роле дәрестә чикләнгән. Ул бары тик укучыларга юнәлеш бирергә һәм аларны уку барышында әйдәп барырга тиеш. Бу юнәлештә заманча технологияләрнең роле бик зур.

Проблемалы укыту – укытучының укучылар белән берлектә проблемалы ситуацияне хәл итү юлларын эзләү процессы. Балаларның фикерләү сәләте камилләштерелә, ныклы белем һәм күнекмәләр формалаша. Проблемалы укыту технологиясен кулланып укыткан укытучылар саны көннән-көн арта. Проблемалы укыту процессында

укытучы уку-танып-белү эшчәнлеген фактларны анализлау нигезендә укучылар нәтиҗә һәм гомумиләштерүләр ясарлык итеп оештыра.

“Компьютер – укучы белән белемнәр системасы арасында арадашчы, белем алу чарасы. Компьютердан файдалану укыту эшчәнлеген баета, укыту процессын кызыклы, нәтиҗәле һәм иҗади итеп оештырырга мөмкинлек бирә. Компьютер сыйныф тактасын да, тарату материалын да, дәреслекләрне дә алыштыра ала” [3: 1]. Аны куллану дәреснең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итә. Һәр укучының белем үзләштерүгә сәләте төрлечә була. Кайбер укучыларның ишетеп истә калдыру дәрәҗәсе өстенлек алса, күпчелек укучыларда күреп истә калдыруы өстен чыга. Шул вакытта компьютер ярдәмгә килә. Чөнки мониторда барлык биремнәр матур, эстетик яктан камил эшләнә.

Белем бирүдә заманча технологияләрне куллану ул – әхлаклы кеше тәрбияләү, педагогик технологияләр булдыруда фәннең роле арту, өйрәнгәнне тормышта куллана белү һәм башкалар. Инновацион технология буенча татар әдәбиятына өйрәтү – уку-укыту процессын яңача оештыруны аңлата. Бу вакытта укыту процессы төп нәтиҗәгә – укучының актив коммуникатив эшчәнлеккә омтылуын алдан сизүгә, баланың хисси һәм интелектуаль мөмкинлекләрен файдаланып аралашуга юнәлтелә.

Татар әдәбиятын укытканда, аның теориясен бирүдә укытучының үз методикасын булдыру зарур. Ләкин бу бер методика буенча гына укыту дигән сүз түгел. Көннән-көн яңа технологияләр уйлап табыла торган заманда яшәү сәбәпле, гел яңалыкка омтылырга, үз өстеңдә эшләргә кирәк, һәм дә инде иң мөһиме – яңа мәгълүматны укучыларга җиткерү.

**Әдәбият**


1. Коханова В.А. Технологии и теория обучения литературе: учеб. Пособие / под.ред В.А. Кохановой. – М: ФЛИНТА: Наука, 2011. – 250 с.
2. Поварисов С. Мәктәптә әдәби әсәрнең телен өйрәнү. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 320 б.
3. Татар теленең киләчәге / Л.Р. Сабирова. – Электрон чыганак: infourok.ru


## ТАТАР КОММУНИКАТИВ КУЛЬТУРАСЫНДА ИСӘНЛӘШҮ ҺӘМ САУБУЛЛАШУ ӘДӘБЕ


*Илиясы С., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нәбиуллина Г.Ә.*


Сөйләм культурасы – гомумкешелек кыйммәтләренең, ахыр чиктә цивилизация культурасының әһәмиятле билгесе буларак, тел чаралары ярдәмендә үзара аралашу этикеты ул. Аннан конкрет вакытка, урынга һәм башка шартларга бәйле рәвештә дөрес итеп

файдалану, җәмгыяттә кабул ителгән ул кагыйдәләрне төгәл үтәү – хәзерге татар теле стилистикасының, сөйләм культурасының актуаль мәсьәләсе булып кала. Һәм бүген иң борынгы телләрнең берсе булып саналган ана телебез үзенең куллану даирәсен, аралашу дәрәҗәсен киңәйтеп барган хәлдә, аның сөйләм этикеты берәмлекләрен өйрәнүгә дә игътибар нык көчәйде.

Белгәнебезчә, сөйләм этикеты формалары сөйләм, яисә аралашу барышында гына төзелми, барлыкка килми, ә бәлки телдә һәрбер ситуация өчен халык тарафыннан еллар, гасырлар буена әзерләнеп чарланган, вакыт сынавын узган, кем әйтмешли, үзгәртеп булмый торган “корычтай” нык тәгъбирләр була. Алар шәхес тарафыннан балачактан ук ата-ана, гаилә тәрбиясе тәэсирендә үзләштереләләр, күңелләрдә уелып калалар. Татарларның сөйләм этикетындагы аерым чит сүзләр ислам дине йогынтысы белән дә аңлатыла. Мисал өчен, гарәп телендәге «Әссәламәгаләйкүм» белән «Вәгаләйкемәссәлам» кебек үзара сәламләшү гыйбарәләре безнең татар теленә озак еллар аша, татар халкы мөселманлыкка күчкән чордан килә. Аның берсе татарча «Сезгә сәламәтлек булсын!» дигәнне аңлатса, икенче сүз гарәпчәдән «Сезгә дә тынычлык, иминлек телим» мәгънәсендә. Кайчандыр дин әһелләренә, картларга гына хас булган бу күренеш хәзер бөтен халык арасында киң кулланышка керде.

Безнең зыялы, укымышлы халкыбызда ихлас итагатьлекне, кече күңеллелекне, әдәплелекне чагылдырган мондый затлы сүзләргә тагын шуңа охшаш сәлам бирү, саубуллашу, рәхмәт әйтү, үтенү, гозерләү, киңәш-табыш итү, котлау, гафу үтенү һ.б. сөйләм гыйбарәләре дә керә. Әйтергә кирәк, сөйләм этикетлары гыйбарәләре милләттәшләр үзара мөнәсәбәткә кереп, исәнләшкән һәм саубулашкан вакытта да, телне чит тел буларак өйрәткәндә дә, туган телне өйрәнгәндә дә аеруча әһәмиятле урын били.

Татар коммуникатив культурасында исәнләшү һәм саубуллашу әдәбе аралашуның төп элементы булып санала. Аралашуның билгеле бер кагыйдәләре, нормалары бар. Әңгәмәдәше белән тыгыз элемтә урнаштыру: исәнләшү, хәл-әхвәлен белешү, саубуллашу әдәбе дә – аралашу кагыйдәләренең берсен тәшкил итә. Сәламләү һәм хушлашу сүзләре кешеләр арасында эчкерсез җылы, дустанә мохит урнаштыруга булышлык итәләр, сөйләүченең гәптәшенә карата булган ягымлы мөнәсәбәтен белдерәләр. Исәнләшү гыйбарәләренең семантик нигезе ике төрле: хәл сорап исәнләшү һәм яхшы теләк белдереп исәнләшү. Исәнләшү ул – кешенең хәзерге халәтен сорашу, аңа яхшы теләк белдереп, сәламәтлек теләү билгесе булса, саубуллашу этикеты шулай

ук кешегә исәнлек теләү, рәхмәт әйтү, яхшы теләкләр җиткерү кебек үзенчәлекләрдән гыйбарәт.

Шунысын да искәртик: ачык йөз белән сәламләп исәнләшү – сүз башлап җибәрү, яисә яңа кеше белән танышу өчен ачкыч хезмәтен үти, саубуллашу йоласы исә сөйләүченең тыңлаучыга аралашуның ахырына якынлашуын искәртә, шулай ук саубуллашу ярдәмендә алга таба да аралашу ихтималын белдерә.

Исәнләшү-саубуллашу лексикасына тәфсилле күз салсак, анда исәнләшү һәм саубуллашу гыйбарәләренең, сүзләрнең синонимик оясы шактый зур булуын күрергә мөмкин.

Исәнләшкәндә хәл сорау гыйбарәләре дә бай синонимик ояны тәшкил итә. Татар телендә «Исәнмесез», «Исәнме» сүзләре аеруча киң таралган. «Нихәл?», «Саумы?», «Саумысез?», «Сәлам» кебек сәламләүнең беркадәр гади һәм фамильяр формалары да еш кулланыла. Сәламләү гыйбарәләре арасында зур урынны сорау җөмләләр алып тора. Очрашкан вакытта кешенең сәламәтлеге, тормыш-көнкүреше турында сораулар бирелә: «Исәнлек, саулыкмы?», «Исән-сау гына йөрисезме?» һ.б.

Саубуллашу гыйбарәләрнең дә синонимик оясы шактый киң. Хушлашканда, татарлар «Сау бул» – «Сау булыгыз»; «Исән бул» – «исән булыгыз», «Хуш» – «Хушыгыз», диләр. Әңгәмәдәше киткәндә, «бигайбә», «гаеп итеп калмагыз»; «хәерле юл»; «юлларыгыз уң булсын», «ак юл сезгә» кебек сүзләр әйтелә. Олы буын кешләренә дини теләкләр теләү хас: «Хозыр Ильяс юлдаш булсын», «Исән йөреп, сау кайтырга насыйп булсын»,«Алла ярдәм бирсен» һ.б.

Исәнләшү һәм саубуллашу формалары диалог формасында бара. Этикет кагыйдәләре кешенең исәнләшү һәм саубуллашу сүзләренә җавапсыз калырга мөмкинлек бирмәгәнлектән, сөйләм гыйбарәләре парлы формула булып яшәп килә. Монда сөйләшүне башлау өчен информатив булмаган характердагы сораулар, сөйләшүне дәвам итү өчен төрле кисәкчәләр, модаль сүзләр зур роль уйный. Галимнәр фикеренчә, алар шулай ук аерымү сүз белән дә, фразеологик әйтелмәләр, мәкальләр һәм әйтемнәр белән дә, җөмлә һәм текст аша да белдерелә алалар. Саубуллашканда да бер як теләкләр әйтсә, икенче як та аларга үз мөнәсәбәтен ачык белдерергә тиеш.

Исәнләшү һәм саубуллашу сүзләрен әйткәндә аралашу ситуациясенең рәсми булубулмавы, әңгәмәдәш белән мөнәсәбәтнең характеры, кешенең яше, иҗтимагый статусы, белем дәрәҗәсе һ.б. факторлар да әһәмиятле. Әйтик, яшь кеше үзеннән олыларга катгый төстә “исәнмесез” дип, “сез” формасын гына кулланырга тиеш; аның рөхсәте белән генә “син”гә күчәргә мөмкин. Очрашуларның һәм саубуллашу мизгелләренең ешлыгына карап (сирәк, көн саен, көнгә

берничә һ.б) исәнләшү, саубуллашу тоны да, сүзләре дә аерыла, шул ук вакытта ымлыклар һәм интонация зур роль уйный. Бу эмоциональлек *и-и-и, ай, әй, ой, бәй, абау, ә-ә-ә, бәлеш, пәрәмәч, чү* һ.б. ымлыклар ярдә-мендә ирешелә.

Шулай итеп, татар сөйләм культурасында халыкның күпгасырлык традицияләре, гореф-гадәтләре, йолалары, бай тәҗрибәсе чагылган. Сөйләм этикетын, җәмгыятьтә кабул ителгән үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белү телне халыкның тарихы һәм мәдәнияте белән бергә бәйләп өйрәнергә мөмкинлек бирә. Телебезнең нәфислеген, камиллеген саклап калу өчен, бар көчен куеп эшләгән галимнәребез дә шул фикердә тора.

## КОММУНИКАТИВНАЯ ЛЕКСИКА ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

*Динаэзр ХХХ, КФУ, аспирант II г.о.*
*Науч. рук. – докт. филол. наук, проф. Юсупова А.Ш.*

Принцип деления на тематические группы − один из наиболее оптимальных методов исследования истории лексики конкретного языка при изучении словарных единиц в их непосредственной связи с природно-климатическими условиями и историко-общественной средой, в которых проходила жизнь народа, а также его основных занятий, особенностей хозяйства, жилища, древнейших верований, общественно-политического устройства. Всё это отражено в названиях предметов, понятий и явлений.

Несмотря на большой лексических состав и семантическое разнообразие, коммуникативная лексика татарского языка не изучена в качестве отдельной тематической группы.

Под коммуникативной лексикой подразумевается совокупность фразеологических и лексических единиц, обозначающих процесс общения, формы общения и характерные особенности коммуникации. Это одна из самых объемных группировок в татарской лексической системе, которая включает в себя языковые единицы разных частей речи и фразеологические единицы различного типа.

В толковых, двуязычных, диалектологических и синонимических словарях татарского языка зафиксировано довольно большое количество слов, которые обозначают ту или иную единицу коммуникации. Например: «сүз» – «слово», «җөмлә» – «предложение», «әңгәмә» – «беседа», «сөйләм» – «речь», «гәп» – «речь», «гайбәт» – «сплетня», «ялган» – «ложь», «әйтү» – «сказать», «язу – «написать», «каршы сөйләү» – «перечить», «әйткәләшү» – «пререкаться», «кимсетү» – «унижать», «мактау» – «хвалить», «әрләү» – «ругать», «чакыру» – «приглашать»,

«өйрәтү» – «учить», «сөйләшү» – «разговаривать», «серләшү» – секретничать», «әрләшү» – «ссориться», «фикер алышу» – «обсуждение», «хәбәрләшү» – «поддерживать связь», «танышу» – «знакомство», «язышу» – «переписываться», «кайгы уртаклашу» – «соболезновать», «тиргәшү» – «ругань», «талашу» – «ругань», «акыру» – «кричать», «бакыру» – «кричать», «сорау» – «вопрос», «җавап» – «ответ», «сохбәт» – «беседа», «хөтбә» – «проповедь», «әләк» – «донос».

Некоторые слова данной тематической лексики находят свое отражение в составе татарских народных пословиц и поговорок. Например: «Үзе тавышчан, изгелеккә авышчан» [1: 111]. «Ызгыш зурайса, эш бәләкәя» [1: 111]. «Аз эш күп сүздән яхшырак» [1: 364]. «Буш сүз карын туйдырмас» [1: 364]. «Ахмак сүзгә җавап юк» [1: 368]. «Белгәнеңне сөйләмә, ни сөйләгәнеңне бел» [1: 369]. «Сөйләшә белмәгән кешедән өрә белгән эт артык» [1: 369). «Акыллы сүзгә кул кукй, акылсызга юл куй» [1: 373]. «Эшнең асылын белмичә сөйләмә» [1: 375]. «Яхшының сүзе – каймак, яманның сүзе – тукмак» [1: 375]. «Кешенең сүзе – акылның бизмәне» [1: 375]. «Аз сөйләгән кешенең күңеле рәхәт булыр» [1: 376]. «Күп белеп аз сөйләү – егетлек һөнәре»[1: 378]. «Аңламый әйтмә, чәйнәми йотма» [1: 381]. «Берне сөйләгәндә бишне уйла» [1: 383], «Таяк иттән үтәр, сүз сөяктән үтәр» [1: 387]. «Әйтсәм җаным көя, әйтмәсәм, җиһан көя» [1: 387].

Надо отметить, что слова, входящие в данную тематическую группу в основном являются тюрко-татарского происхождения, но встречаются и лексические единицы, которые вошли в татарский язык из арабского и персидского языков. К примеру, слово «җөмлә» вошло в татарский язык из арабского языка. В арабском языке оно обозначает 1) грам. предложение. 2) Совокупность, все, сумма, итог. 3) пара, некоторое количество, счет [2: 780].

Корнем слово «хәбәрләшү» является лексема хәбәр, которая тоже является арабизмом и обозначает 1) известие, весть, сообщение. 2) Новость, слух. 3) грамм. сказуемое [2: 669].

«Сохбәт» в арабскм языке обозначает общение, дружбу [2: 510].

«Хотбә» в арабском языке имеет два значения, которые входят в темматическую группу коммуникативной лексики и обозначают 1) речь. 2) проповедь [2: 665].

Интересную картину представляют синонимические ряды коммуникатвной лексики. В словаре синонимов татарского языка даны следуюәие синонимические ряды: Сүз – кәлимә [3: 87]; әйтү – дию, сөйләү [3: 19]; әйтеп ташлау – әйтеп җибәрү, әйтеп салу, ычкындру, ычкындырып ташлау, ычкындырып җибәрү, кирәкмәсне сөйләү, тиешсезне ычкындыру, тиешсезне сөйләү, серне ачу, әйтеп җибәрү [3:

19]; әләк – яла, донос, шым, гайбәт, шымчылык [3: 19]; әңгәмәдәш – утырдаш, гәптәш, сөхбәтче, мәҗлестәш [3: 19]; бәхәс – сүз көрәштерү, низаг, моназара, дәгъва, орыш-талаш, тавыш, бәхәс-талаш, тавыш, бәхәс-низаг, тартыш, тартыш-талаш, шау-шу, дискуссия, аңлашу, дебат, полемика, диспут, спор, бәхәсләшү, сүзгә килү, игътираз [3: 19].

Стоит отметить, что синонимический ряд лексемы «аралашу» продолжает активно обновляться, особое влияние на данное обновление оказывают социальные сети. Интернет-общение обогощает исследуемое поле такими лексемами, как «лайк кую» – «поставить лайк», «комментарийлар язу» – «комментировать», «почтага хат җибәрү» – «скинуть письмо на почту», «вебинарда катнашу» – «участие в вебинаре» и т.д.

Таким образом, основную часть коммуникативной лексики татарского языка составляют стилистически нейтральные единицы, однако среди лексем также имеются разговорные и просторечные слова. Но исследования данных единиц является задачей наших следующих научных работ.

**Литература**

1. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләр җыелмасы: 3 томда. – 2 нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.

2. Хамзин К.С., Махмутов М.И, Сайфуллин Г.Ш. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965.

3. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999.

## «МОРАЛЬДЫ-ЭТИКАЛЫҚ ҚҰНДЫЛЫҚТЫҢ» ҚАЗАҚ ЖӘНЕ АҒЫЛШЫН ТІЛДЕРІНДЕГІ МАҚАЛ-МӘТЕЛДЕРДЕ РЕПРЕЗЕНТАЦИЯЛАНУЫ

*Даутбаева Қ., Қазақстан, Нұр-Сұлтан, Л.Н.Гумилев атындағы ЕҰУ, 1 курс докторанты*

*Ғыл. жет. – ф.ғ.д., проф. Дүйсекова К.К.*

Тіл идея жеткізуші ғана емес, оны жасаушы да болады. Аталмыш этносты лингвомәдени қауымға сәйкестендіретін этностың әлемдік бейнесі тілде ұлтық және өзге де мәдени прескрипцияларды жүзеге асыратын құрал деп атауға негіз бар. Мәдениет аясында адамның миында өмір сүретін әлемді ой объектісі ретінде қарауында интеллектуалды және эмоционалды-бағалауыштық қатынасы көрінеді.

XX ғ. аяғында лингвисттер арасында когнитивті процестер мен тіл арасында байланыс және мәдениет пен әлемді тану тілдің типтерінің ара жігін ажырату мәселелері туындап, талқыға түсті. Г.В.Колшанский әлемді тіл арқылы бөліп, «тіл әлемін» жеке дара бөліп жару негізсіз дейді. Тіл «ойды жеткізеді», бірақ оның материасында

көрініс табатын ой байлығы мен мазмұны және адам санасында қалыптасқан әлем түсінігін тілмен жеткізу мүмкін емес деген ой түйеді. Бұл ойға Л.С. Выготский, М.Коул кері пікір айтты. Олардың ойынша адам затты немесе белгілі бір ойды түсінерде тікелей және жанама күш көмегіне жүгінеді дейді. Тура деген сөз түсінікті ұғым, ал жанама деген бұл жерде ол мәдениет арқылы деген ойды меңзейді.

XX аяғы мен XXI басында тілді ғылыми білімнің антропологиялық парадигма ясында зерттеу белең ала бастады. Бұл зерттеу басында когнитивті лингвистика жүрді. Антропологиялық парадигма ретіндегі лингвомәдениеттанудың методологиялық негізі мәдениет тілмен тең, яғни ол да адамның көзқарасы мен санасын сипаттайды.

Когнитивті лингвистиканы зерттеуде Қазақстан линвист ғалымдарының да еңбектері зор. К.К.Дүйсекова концепт турасында оның адамның ойлау процесінде тәжірибесі мен білімін, әлемді тануын көрсететін негізгі мағынадан тұратындығын айтады [3: 35].

Концепт – қоршаған орта немесе ұғымдар туралы индивидтің немесе адам тобының эмоционалды-танымдық тәжірибесінің сана бірлігі. Осы мақалада қазақ және туыстығы алшақ ағылшын мақал мәтелдеріндегі концептосфераны құраушы фрагмент «моральді-этникалық құндылықты», аксиологиялық вербализация ерекшеліктерін сөз ететін боламыз.

Тіл мен мәдениет арасындағы құндылық мәселесі адамның санасындағы оның іс-әрекетін реттейтін құндылық жүйесіне тәуелді болады. Мақал-мәтелдерді семантикалық талдау жасау концептосфера фрагментінің интерпретациялық алаңын сипатауға мүмкіндік береді. Қазақ және ағылшын тілдері туыстығы алшақ тілдер болғанмен, ондағы мақал-мәтелдердің моралді-этикалық концептілерін қарастырғанда жанр мен тілдік функционалдық қызметі және мақал-мәтелдердегі құндылық мәселесінің төңірегіндегі ұқсастықтар мен айырмашылықтарға кездестік.

Мақал-мәтелдер – өзінің толық мағынасы бар, алдыңғы толқын ағалардың тәжірибесі нәтижесінен алынған, тәрбие беру мақсатында қолданылатын ұлттық нақыл сөздер жиынтығы. Ол өмірдегі құбылыстарды сүзіп, ықшамдап беретін, екі тармақтан тұратын, алдыңғы жолы пайымдап, кейінгі жолы қорытып отыратын халықтық поэтикалық жанр түрі. Мәтел – өзінің түйінін кесіп айтпайтын, қорытындысы тұспалы келетін қысқа, нақыл сөз [1].

Мақал-мәтелдер тәрбие аксиомасы негінде құралады. Тәрбие танымдық мәтіндерде қоғамның негізгі құндылықтары негізімен жазылады. Мақалдарды сүзгіден өткізген кезде, олардағы көп

кездесетин аксиома «ақылдылық» аксиомасы болып шықты. Мысалға: *Алтын алма, білім ал. Адамды білім сақтайды. Ақыл – мың оқудың бастауы. It is best to be on the safe side* [Қауіпсіз болған жақсы].

Моралді-этникалық құндылығы имплицитті түрде берілген мақал-мәтелдер екі тілде де өте көптеп кездеседі. Мысалы *Сырын білмеген аттың сыртынан жүрме немесе Better bend than break* [Сынғанннан иілген жақсы] деген мақалдарда абайлау концептісі сөз етілгенмен, концепт атауына тура көрсеткіш сөз жоқ. Концептінің имплицитті нысанын зерттеу үшін интерпретативті талдау жасалды, яғни мағынаның тура аудармасын анықтау арқылы оның жасырын тұрған мағынасын аштық. Сонымен қатар, осындай жасырын мағыналарды анықтау үшін осы әдіс түрі өте пайдалы екені анықталды.

Белгілі-бір қасиетке пейоративті баға беруде оған қарама-қарсы мағынасына мелиоративті баға беріледі. Мына мақалдарда ол айқын бейнеленеді: *Қазанға не салсаң, шөмішіңе сол ілінер.* Бұл мақал мағынасы қазан мен шөмішке қатысы жоқ, «қазан» дегенде автор еңбек немесе оның қарама-қарсы мағынасы мағынасы «еріншектікті» айтады, яғни қалай еңбектенсең, солай пайда көресің деген мағынада қолдануға болады. *A tattler is worse than a thief* [Сөзшең ұрлықшыдан жаман] деген ағылшын мақалында пейоративті бағаға «сөзшеңдік» ие болып, оның қарсы мағынасы «сөзіне беріктік» жақсы бағаланып тұр.

Ағылшын мақал-мәтелдерінде әлем мен адамдарға мынадай принциптер ұсталады: 1*) Man does not live by bread alone* [Адам нанмен ғана өмір сүрмейді]; *2) Live and let live* [Өз өміріңді сүр, басқасын жайына қалдыр]. Қазақ мақал-мәтелдері «дұрыс өмір» принципіне негізделеді: *Доссыз өмір тұл, Махаббатсыз өмір тұл. Таспен атқанды аспен ат.* Мақал-мәтел принциптеріне келгенде екі тілдегі өмірге көзқарас принциптерінің алшақ екендігін көруге болады.

Осы мақалдарды зерттей келе британ мақалдары нағыз өмірге бейімдесе, қазақ мақалдары идеал өмір қасиеттерін насихаттайтынын көреміз.

**Әдебиет**


1. Қазақстан: Ұлттық энциклопедия / бас ред. А.Н. Нысанбаев. – Алматы, 1998.
2. Беркнер С.С. Универсальное и национально-культурное в афоризмах и пословицах (на материале английского и русского язьпсов / С.С. Беркнер, А.В. Субботина // Житниковские чтения: Динамический аспект лингвистических исследований: материалы всерос. науч. конф. (Челябинск, 21-23 апр. 1999 г.). – Челябинск, 1999. – Ч . 1. – С. 64-69.
3. Зыкова И.В. Концептосфера культуры и фразеология // Теория и методы лингвокультурологического изучения. – М.: Ленанд, 2014. – 375 с.
4. Современные направления лингвистической науки: коллективная монография / под ред. д.ф.н. проф. А.Е. Бижкеновой. – Нур-Султан: ЕНУ им. Гумилева, 2015. – 360 с.

5. Субботина А.В. Лингвокогнитивный, лингвокультурологический и лингвоаксиологический подходы к сопоставительному изучению афоризмов и пословиц // Языковая система – текст – дискурс: категории и аспекты исследования: материалы всерос. науч. конф. (Самара, 18-19 сент. 2003 г.). – Самара, 2003. – С. 106-111.

# XIX ЙӨЗДӘ ДӨНЬЯ КҮРГӘН РУСЧА-ТАТАРЧА ҺӘМ ТАТАРЧА-РУСЧА СҮЗЛЕКЛӘРДӘ СӘЛАМӘТЛЕК ТЕРМИННАРЫ

*Закирҗанова Г., КФУ, I курс аспиранты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Юсупова Ә.Ш.*

Күпчелек телләрдә лексикография тарихы иң элек тәрҗемә сүзлекләрдән башлана. Аларны өйрәнү тарихы сүзлекләр һәм төрки телләрнең чагыштырмалы тарихи сүзлекләрен төзү өчен ышанычлы чыганак хезмәтен үти, бигрәк тә телнең сүз байлыгы үсеш-үзгәрешен күзәтү өчен кыйммәтле лексик материал булып торалар. Сүзлекләрдә урын алган соматизмнарны анализлау татар теленең соматик лексикасының барлыкка килү һәм үсеш-үзгәреш тарихын күзалларга ярдәм итә. XIX гасыр тәрҗемәи сүзлекләрдә теркәлгән сәламәтлек өлкәсенә караган берәмлекләрне һәм тән төзелешенә караган атамаларны туплау, тикшерү исә шул чордагы әле формалаша башлаган гына медицина терминологиясен өйрәнүдә гаять актуаль бер мәсьәлә буларак яңгырый.

Татар медицина терминологиясе – татар әдәби сүз байлыгының бер өлеше. Аның формалашу процессы бик борынгы дәвердә башланып китә, гәрчә аның фәнни үсеше турында бары тик XIX гасырдан башлап кына сөйләргә мөмкин. Аны өйрәнүдә шул чорга караган лексикографик материалның күп санлы басмалары төп чыганак булып торалар. Шул исәптән Л. Будагов, И. Гиганов, А. Троянский, С. Кукляшев, Н. Остроумов, А. Воскресенский, К. Насыйри һәм М. Юнысовның ике телле сүзлекләре татар сәламәтлек терминологиясен барлыкка китерүдә мөһим роль башкарганнар.

Тикшерү барышында сәламәтлек өлкәсенә караган 1228 берәмлек тупланды. Шуларның якынча 240ы даими рәвештә һәр сүзлектә кабатланып килә. Һәм бу гадәттә анатомия-физиология атамаларын, кешеләрнең физиологик халәтен һәм төрле авыру-хаста исемнәрен белдергән лексик берәмлекләр.

XIX гасыр татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрендә теркәлгән сүзләрне аерым тематик төркемнәргә аерырга мөмкин. *Анатомия-физиология атамалары:* кюксә [2: 107], кюкрякъ [2: 107] (грудь), бухуртакъ [2: 221] (кадык), бәдән [3: 24] (тело), бөйрәкъ [2: 437] (почка), агыз [2: 516] (рот), әл [2: 517] (рука), мүца [2: 613] (туловище), бала йаткылык [4: 227] (матка), чәшм [4: 467] (глаз); *физик*

*җитешсезлекләр, дәвалау ысуллары атамалары:* инһраф [5: 15] (болезнь), зянге [5: 69] (цынга), чячяк чыгару [1: 179] (оспопрививание), тәшрих кылмак [4: 5] (анатомировать), *һәм чаралары:* балтакъ [2: 246], таяк [1: 111] (костыль), ягма [2: 272], майлый торган дару [4: 76] (мазь), зянбүль [2: 318] (носилки), айнякъ [2: 361], күзлек, (очки), хәбб [4: 126] (пилюля), *тире чирләре:* кабару [2: 280], кабарчык [4: 35], тимрәү [4: 35] (лишай), кырмызы [1: 324] (сыпь), цирешъ [2: 283] (морщина); *физиологик халәтне белдергән сүзләр:* кумаръ [2: 22], макморъ [2: 22] (болезнь от пьянства), дямъ [2: 334] (одышка), күзкү [2: 511] (рвота), *зарарлы организмнар исемнәре:* борчя [5: 60] (блоха), бет [1: 29] (вошь), чыуалчан [1: 45], суалчан [1: 45], эчтәге корт [4: 30] (глиста), серкя [1: 45] (гнида).

Сүзлекләрдә сүзләрне аңлату юлы белән тәрҗемә итү күренеше аерым игътибарга лаек. Теге яки бу терминның татар телендә төгәл мәгънәсен белдерү өчен тәңгәл сүз табылмаса, сүзлек авторлары аларны аңлату юлы белән тәрҗемә итәләр. Бу күренеш аеруча К. Насыйри сүзлегенә хас. Алынма терминнарның шул рәвешле сүзлектә бирелүе аларның тиз арада таралу һәм үзләштерелү процессларына зур этәргеч була. Шул рәвешле, К. Насыйри алдынгы медицина фәненең атамаларын актив пропагандалаучы галим буларак таныла. Ул күп кенә халык массаларына аңлашылмаган гарәп-фарсы чыгышлы терминнарны татар теленә тәрҗемә итә һәм татар теленең үз сүзләре белән алыштыра. Аның кайбер атамалары бүгенге көн медицина терминологиясендә дә аерым терминнар буларак яңгырыйлар.Мәсәлән: адамово яблоко – бугаз төене [4: 227]; апоплексия – кан саву [4: 6]; спазма – сеңер тартуы [4: 194].

Тикшерелгән сүзлекләрнең лексикасы татар телендә шул вакытта ук төрле телләрдән күчкән алынма сүзләр булганлыгын раслый. Мәсәлән, гарәп чыгышлы сүзләр: димаг – мозг; шифа – лекарство; бәдән – тело, әл – рука; истиска – водянка; дәм – дыхание; сәламәтлек – здоровье; табип – лекарь; җәрәхәт – рана һ.б. Шуны әйтергә кирәк, гарәп-фарсы алынмаларының күп кенә сүзләре бүгенге көндә сәламәтлек термины буларак нормалашкан һәм актив кулланылышта йөри: дару, шифаханә, табиб, җәрәхәт. Терминнар рәтендә телдә актив кулланылган рус алынмалары да теркәлгән. Бу сүзләр, нигездә, фонетик яктан татар теленә яраклаштырылып бирелгән. Мәсәлән: балсян – бальзам; ликар – лекарь, врач; пластыр – пластырь; пляш – плешивый; фершал – фельдшер; чакутка – чахотка; зянге – цынга һ.б.

А. Воскресенский, Н. Остроумов үз хезмәтләрендә рус алынмаларын башка сүзлекләргә караганда күбрәк теркәгәннәр. Бу

күренеш аларның төп эшчәнлекләре, миссионерлык хәрәкәте вәкилләре булу белән бәйле булырга мөмкин. И. Гиганов, Н. Юнысов сүзлекләрендә рус алынмаларның татар телендә үзләштерелгән, ныклап урнашкан берәмлекләре генә бирелгән.

Бүгенге көндә шул чор сүзлекләрендә кулланылган сүзләрнең, бигрәк тә рус теленнән кергән һәм интернациональ терминнарның, шулай ук кеше әгъзаларын, төрле авыруларны, физик халәтләрне белдергән атамаларның күбесе татар әдәби телендә бер үзгәрешсез сакланып калган. Һәм алар телдә актив кулланылышта йөри. Күп кенә алынма һәм диалекталь сүзләр, мәгънәләре тараю яки киңәю процессын кичергән кайбер берәмлекләр бөтенләй кулланылыштан төшеп калган.

Ләкин пассив лексикага караган кайбер сүзләрнең бүгенге көн медицина терминологиясе составына керергә мөмкинлекләре бар. Бу хәзерге татар әдәби теленең термин дәрәҗәсендә кулланырлык үз сүзләре булмау мәсьәләсе белән бәйле.

**Әдәбият**


1. Воскресенский А. Полный русско-татарский словарь. – Казань, 1894. – 370 с.
2. Гиганов И. Словарь российско-татарский, собранный в Тобольском народном училище учителем татарского языка, священником Иосифом Гигановым и муллами юртовскими свидетельствованные. – СПб.: Тип. АН, 1804. – 682 с.
3. Насыри К. Полный русско-татарский словарь, с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины. – Казань, 1892. – 263 с.
4. Троянский А. Полный русско-татарский словарь: В 2 т. – Казань, 1833. – Т. 1. – 629 с.; 1835. – Т. 2. – 340 с.
5. Остроумов Н. Татарско-русский словарь. – Казань: Тип. ун-та, 1892. – 46 с.

## 4 НЧЕ СЕКЦИЯ

### ОСОБЕННОСТИ ОТРАЖЕНИЯ ГЕНДЕРНЫХ СТЕРЕОТИПОВ В ЯЗЫКАХ

*Марданов Б., Казань, лицей-интернат №2, X класс*
*Рук. – Камалов А.Г.*

Общество постоянно меняется, и вместе с ним меняется и язык. Последние изменения в германских и романских языках, произошедшие под влиянием феминизма и стремления к гендерному равенству, представляют собой яркий пример истинности этого.

Одним из самых широко известных изменений такого рода является значительное учащение использования местоимения *they* в значении *he or she (он или она)* в английском языке. Например, *No one has to go if they don't want to.* Вообще, *they* использовалось в этом значение уже с XIII в., но в середине XIX в. английские грамматисты, находясь под влиянием латыни, постановили, что употребление местоимения *they* в ед. ч. неправильно, и что вместо него следует непременно употреблять *he,* которое прежде использовалось параллельно с *singular they*. Несмотря на грамматическое табу, *singular they* не полностью вытиснилось из языка и продолжало своё существование в разговорной неформальной речи. В минувшее десятилетие это табу было почти полностью снято, и теперь многие предпочитают *singular they* андроцентристскому *generic he* из своих моральных, этических и политических убеждений. Оно употребляется даже в официальных документах, словарях и т.д.

Укоренение в шведском языке нового местоимения, которое выполняет те же функции, что *singular they* в английском, было в некотором смысле языковой революцией, ведь оно противоречит представлению о местоимениях как о закрытом классе. Итак, традиционно в шведском существует два местоимения в третьем лице и ед. ч., употребляемые для обозначения человека: *han* и *hon* – для мужчины и для женщины соответственно. *Han* традиционно используется также в значении *han aller hon (он или она).* Однако в 1966 г. шведский лингвист Рольф Дунос предложил использовать местоимение *hen* в этом значении. Предположительно, *hen* происходит от финского местоимения *hän*, которое может использоваться как для женщины, так и для мужчины. Однако это предложение оставалось почти нисколько не замеченным в течение нескольких десятилетий. Некоторую популярность *hen* стало набирать в начале нынешнего века в феминистской среде. А в 2012 г. оно внезапно вызвало резонанс в

связи с тем, что его использовали в детской книге. За несколько лет это местоимение приобрело большую популярность, и в 2015 г. оно было добавлено в официальный словарь швед. языка. Сейчас оно используется повсеместно: в бытовой речи, в СМИ, в учебных заведениях, судах и т.д.

Изменения происходят, разумеется, не только в местоимениях, но и с существительными. Л.Л. Заменгоф ещё 1907 г. писал: «〈…〉 благодаря тому, что стиркой белья обычно занимаются женщины, вы в каждом языке имеете слово для выражения понятия «прачка»; но если *мужчина* захочет заниматься стиркой белья, вы в очень многих языках стоите уже беспомощно и не знаете, как назвать такого человека, потому что названия мужчины, который занимается стиркой белья, вы никогда не слышали! Лечением до сих пор занимались лишь мужчины; но когда начали появляться врачи-женщины, или женщины, имеющие какой-то научный ранг, для них в большинстве языков не нашлось слова! Для выражения их звания приходилось уже выкручиваться с помощью описательного использования нескольких слов, и когда вы ещё из их титула хотите сделать прилагательное, глагол и т.д. – это уже вообще невозможно!» [1]. Эта проблема была вызвана гендерными ролями, которые отражались в языке, ограничивая его выразительность. По этой причине в 1960-ые в английском стали постепенно укореняться абсолютно гендерно- нейтральные альтернативы мужских слов на *-man*, обозначающих род деятельности; например, *firefighter, fisher, police officer* и *chairperson* являются недвусмысленно нейтральными (т.е. их можно использовать для обоих полов) альтернативами слов *fireman, fisherman, policeman* и *chairman* соотв. В тот же период в феминистских кругах появилась тенденция избегать слово *man* в значении *человек*, хотя традиционно оно, в зависимости от контекста, может значить как *человек,* так и *мужчина.* В значении *человек* стали предпочитать употреблять *human (being).* Соответственно, вместо *mankind – humankind.* В нидерландском языке есть группа слов на *-man* и *-vrouw* (о мужчине и женщине соотв.), обозначающих род деятельности. Когда речь идёт о смешанной группе лиц, традиционно употребляют муж. форму во мн. ч., но в последнее десятилетие всё чаще и чаще можно встретить нейтральные формы на *-mens*. Напр., *brandweermensen* вместо *brandweermannen* для смеш. группы пожарных.

Очень часто в испанском языке муж. слово и соответствующее женское оканчиваются на *-o и -a* соотв. (напр., *deputado, deputada*). Для того чтобы говорить о смешанной группе людей традиционно используют мужскую форму (напр., *deputados*). В последнее время в

некоторых странах Латинской Америки появилась тенденция использовать *-e* вместо *-o* в таких случаях. В Аргентине такие нейтральные слова разрешены в академических публикациях в определённых университетах, Центральный Банк включает их в официальных обращениях, а президент Альберто Фернандес использует их в своих речах.

Такие тенденции есть также в немецком, португальском и других языках.

Стоит заметить, что многие языки являются почти полностью гендерно- нейтральными и не создают проблем, которые верно приметил Заменгоф. Например, в татарском языке нейтральной является не только основная масса тюркских слов, но даже слова, которые происходят из арабского и имеют в нём мужское значение (напр. *варис, вәкил, галим, мөгаллим, мөдир, мөхәррир, рәис, табиб, шагыйрь, хаҗи*). Однако в последнее время иногда можно встретить феминитивы этих слов, образующихся путём прибавления *-ә*. Это идёт наперекор с духом языка и против всемирной тенденции к гендерной нейтральности.

**Литература**


1. Zamenhof L.L.. Esenco kaj Estonteco de la Ideo de Lingvo Internacia // Fundamenta Krestomatio. – Roterdamo, Nederlando, 1968. – p. 253-297.
2. Marcos Cramer. La efektiva uzado de seksneŭtralaj pronomoj laŭ empiria esplorstudo // Lingva Kritiko, 2020.


## МӘКАЛЬ-ӘЙТЕМНӘРДӘ ЯЛГЫЗЛЫК ИСЕМНӘР


*Миннеханова А., Түбән Кама, 13 нче гимназия-интернат, X сыйныф*
*Җит. – Ишмөхәммәтов И.Ш.*


Бу дөньяда исеме булмаган бер әйбер дә, күренеш тә юк. Исем ул кеше, предмет, күренеш белән бергә барлыкка килә һәм аны гомер буе озатып йөри.

Телдәге исемнәр исә гомумилекне яки аерымлыкны белдерүләре ягыннан бер-берсенә каршы куела торган ике зур төркемгә аерылалар. Бер төрдән булган әйберләрнең барысы өчен уртак, гомуми атамасы – аларның күмәклек исемен (кеше, елга, шәһәр, һ.б), бары тик берсен генә белдергәне – шәхси, ялгызлык исем барлыкка китерә (Алсу, Айназ, Арча, Кабан, Болак һ.б.). Ялгызлык исемнәренә кеше, ыруг, кабилә, халык; мифологик образлар һәм аллалар; газета-журналлар; предприятие һәм учреждение исемнәре; төрле әйбер, товар атамалары һ.б. керә [1: 16]. Алар үзләренең даимилеге һәм чагыштырмача аз санлы булуы белән аерылып тора.

Ялгызлык исемнәрне өйрәнү белән ономастика шөгыльләнә. Кеше исемнәрен, кушамат, отчество һәм фамилияләрне антропонимия фәне өйрәнә, ә географик төшенчәләрне топонимика өйрәнә һәм үз эченә оронимика (урын исемнәре), гидронимика (су чыганакларының исемнәре), ойконимиканы (торак урыннарының исемнәрен) ала. Космонимика күк җисемнәре исемнәре белән эш итә [2: 129].

Ялгызлык исемнәрнең безне кызыксындырган ягы – аларның мәкаль һәм әйтемнәрдә кулланылышы. Без тикшергән мәкаль-әйтемнәрдә, нигездә, кеше исемнәре, фамилияләре, шәһәр, авыл, елга, тау, ил, күк җисемнәре һәм календарь бәйрәм исемнәре очрады.

Татар телендә мәкаль һәм әйтемнәр теле турында шактый гына хезмәтләр бар. Әлеге темага галимнәр Г.Ә.Нәбиуллина, Э.Н.Федорова, И.Г.Закирова һ.б.ларның гыйльми хезмәтләре бар. Шулай булуга карамастан, мәкаль-әйтемнәрдә ялгызлык исемнәр кулланышы аерым алып өйрәнелмәгән. Бу безнең тикшеренүебезнең актуальлеген билгели.

Теманы ачу өчен без Нәкый Исәнбәтнең “Татар халык мәкальләре” өчтомлыгына мөрәҗәгать иттек һәм аннан ялгызлык исемнәр кулланылган 214 мәкаль-әйтемне аерып алдык.

Аларны, нинди ялгызлык исем белдерүләренә карап, 6 төркемгә бүләргә мөмкин: 1) составында кеше исемнәре һәм фамилияләре булган паремияләр (85, 64е ир-ат исемнәре, 28е хатын-кыз исемнәре белән); 2) составында шәһәр-авыл һәм ил-төбәк исемнәре булган паремияләр (40 мәкаль һәм әйтем); 3) составында елга-күл исемнәре булган паремияләр (56 мәкаль һәм әйтем); 4) составында тау исемнәре булган паремияләр (7 мәкаль һәм әйтем); 5) составында күк җисемнәре исеме булган паремияләр (18 мәкаль һәм әйтем); 6) составында календарь бәйрәм исемнәре булган паремияләр (8 мәкаль һәм әйтем).

Мәкаль һәм әйтемнәрендә кулланыла торган кеше исемнәре – татар мәдәниятенең бер өлеше, халкыбызның рухи мәдәнияте белән аерылгысыз бәйләнгән.

Без тикшергән мәкаль-әйтемнәрдә Абдулла (3), Габдрахман (3), Алып Мәмшән (Алпамша, Алпамыш) (3), Хуҗа Насретдин (Хуҗа) (3), Сөләйман (3), Мәнди (3), Мәҗнүн (3), Йосыф (3), Гыйләҗи (3), Сәхибулла (Сәхип) (2), Мөхәммәт (2), Ачамай (2), Мити (Мифтахетдин) (2), Мөлтәки (2), Бирәхмәт (2), Ычтапан (Степан) (2), Хәмит (1) – Сәхип (Сәхибулла) (3), Бикмүш (2) – Әхмүш (2), Әкәли (2), Халикъ (1) – Малик (1), Миһери (1), Вәли (1) – Гали (1), Әмәк (1) – Шәмәк (1), Сәкыйм (1) – Мөстәкыйм (1), Әхмәтша (1) – Мөхәммәтша (1), Гыйбадулла (1) – Гобәйдулла (1), Мәмәт (1) – Шәмәт (1), Зариф (1), Мәрхәт (1), Таһир (1), Коркыт ата (1), Мөхәммәт Әмин (1), Хисами (1), Зәйнетдин, Искәндәр (1), Ишмөхәммәт (1), Җәгъфәр (1), Чутай (1),

Мәрхәб (Мәрхәбулла) (1), Ишмәт (1), Иши (Ишбулат) (1), Шани (1), Шахмамай (1), Шогай (Шогаеп) (1), Маннаф (1), Җәләлетдин (1), Ибан (Иван) (1) кебек ир-ат исемнәре һәм Бурнай (Бурнашев) (1), Бохари (1), Пушкин (1) кебек фамилияләр кулланылган (җәяләр эчендә ялгызлык исемнәрнең кулланылу ешлыгы күрсәтелде).

Мәкальләрдә билгеләп үтелгән татар халкының иң популяр һәм яраткан хатын-кыз исемнәре: Ләйлә (3), Зөләйха (2), Мәһикамал (2), Зөһрә (1), Гөләп (1), Зәбидә (1), Бәдигол (1), Фатыйма (1), Җәмилә (1), Майсафа (1) – Миңсафа (1), Мәһирә (1) – Таһирә (1), Мәрви (1) – Сәрби (1), Сәкинә (1), Караҗәмәк (Җәмәк) (2), Моглифә (1), Гандәлия (1), Мөнирә (1), Зәкия (1), Тәгъзимә (1), Өмме Рәһан (1), Маруся (1).

Мәкаль-әйтемнәрдә табылган топонимнарның үзләрен берничә төркемгә бүләргә була: 1) *гидронимнар* – (су чыганаклары): Идел (40), Агыйдел (10), Чулман (Кама) (5), Нократ (3), Җаек (3), Казан суы (2), Йөрүзән (Үзән) (2), Иртыш (1), Ука (Ока) (1), Ык (1), Зөя (1), Зәй (1), Инзәр (1), Әй (1), Ашказар, Кабан (1), Байкал (1); 2) *оронимнар* – (кыя, оч, тарлавык һ.б. җирле рельеф элементлары атамалары): Урал (4), Бaшташ (1), Һималай (1), Кыз тавы (1), Йөрәк-тау (1); 3) *ойконимнар* – (торак пункт, шәһәр, авыл, төбәк, ил атамалары): Бохара (5), Мәскәү (4), Әстерхан (3), Сембер (2), Мәккә (2), Әлдермеш (2), Рум (Рим) (2), Кырым (2), Казан (1), Самара (1), Чистай (1), Баку (1), Алаш (1), Шәмәрдән (1), Киндер күл (1), Мәңгәр (1), Мөндеш (1), Мишәүкә (1), Бәрәзә (1), Бәхтияр (1), Кәшер (1), Балтач (1), Чәкәнеш (1), Себер (3), Һиндстан (1), Йәмән.

Космонимнардан мәкаль-әйтемнәрдә Чулпан (7), Җидегән йолдыз (7), Зөһрә (4), Тимерказык (4) кебекләре очрый.

Күрүебезчә, халык авыз иҗаты үрнәге булган мәкаль һәм әйтемнәрдә ономастик лексиканың актив кулланылышы күзәтелә. Семантик яктан алар төрле төркемнәрдән гыйбарәт. Аларда кешенең үз-үзен тотышына яки аның холкындагы үзенчәлекләренә бәя бирелә. Шәһәр атамалары шәһәрнең җитешсезлекләренә күрсәтү, я булмаса абруена басым ясау, чагыштыру өчен кулланыла. Ялгызлык исемнәрнең кайберләре паремияләрдә рифма буларак, я авазлаш чара итеп кулланылган.

Үткәрелгән тикшеренү мәкаль һәм әйтемнәрдә кулланылган ялгызлык исемнәрнең исемлеге чикле булуын күрсәтте. Тагын шунысы да бар: барлык исемнәр дә бер үк ешлыкта кулланылмый.

**Әдәбият**

1. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? – Казан: Раннур. – 1998. – Б. 16.
2.Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. – Казан: Хәтер. – 2001. – Б. 20-30.

## МИЛЛИҺӘМ ДИНИ БӘЙРӘМНӘР

*Музафарова Ә., Бөгелмә, лицей-интернат, IX сыйныф*
*Җит. – Юнысова С.Г.*

Бөек татар халкын, бай тарихын,
Гасырлардан килгән мирасын,
Калдырасы иде яшь буынга,
Һәрбер кеше барлап соклансын!
Гореф-гадәтләрне,җыр- биюне,
Сабан туен, Җыен, Нәүрүзен,
Белсен иде җирдә һәрбер бала
Әнисеннән алган үз телен!
(Эльмира Зарипова)

Гасырлар дәвамында табигатьтәге еллык үзгәрешләргә, бабаларыбызның хуҗалык эшләренә һәм тормыш-көнкүрешенә бәйле рәвештә күп төрле йолалар барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчеп камилләшкән, искергәннәре кулланыштан чыккан. Халкыбыз гомер-гомергә бәйрәмнәр уздырган, гореф-гадәтләрен, йолаларын үтәп килгән. Бу бәйрәмнәр арасында корбан бәйрәме аерым урын тота. Бу бәйрәм бигрәк тә авыл җирлегендә яшәгән халык өчен изге бәйрәм булып саналган. Безнең күбебезнең нәсел җепләре авылга килеп тоташа. Мөселманнарның зур бәйрәмнәренең берсе – Корбан гаете. Ул Ураза бәйрәменнән соң 70 көн узгач, Зөлхиҗҗә аеның 1нче көнендә билгеләп үтелә. Гарәп теленнән Корбан сүзе карубә, ягъни якынаю дигән сүз. Шәригатьтәге мәгънәсе гамәл гыйбадәт белән Аллаһыга якынаю, димәк, без намаз укуыбыз, Корбан чалуыбыз белән Аллаһыга якынаябыз. Бәйрәм ир кешеләр өчен госел алып, чиста-пакь киемнәрне киеп, мәчеткә гает намазын уку өчен бару белән башлана. Гадәт буенча, мәчеткә барганда тәкбир әйтелә. Гает намазыннан соң корбан чалына. Аннан соң туганнарны, танышларны зиярәт кылу, табыннар әзерләү, бүләкләр тарату кабул ителгән.

Ураза хиҗри календарь буенча бер ай – Рамазан ае буе тотыла. Ураза тоту мөселманнарга фарыз санала. Рамазан аеның беренче көненнән башлап Гает намазына кадәр фитр сәдакасы бирү фарыз. Фитр сәдакасының күләме – 3260 грамм хөрмә яки 3260 грамм арпа (гадәттә диния назәрәте аның акчалата күләмен билгели). Рамазан аеның тәмамлану уңаена багышланган җәмәгать белән кылына торган бәйрәм, ике рәкәгать бәйрәм намазын (Гает намазын) уку белән билгеләнә. Ураза вә Корбан бәйрәм намазларының укылуы – динебездә важиб эшләрдән санала. Бәйрәм намазлары беткәч, мөселманнар бер-берләрен бәйрәм белән тәбриклиләр, хәерле теләкләр телиләр. Гает

намазы иртәнге намаздан соң, кояш чыгып ярты сәгать чамасы вакыт үткәннән соң укыла. Рамазан аенда эшләнгән яхшылыкларның сәвабы башка көннәргә караганда җитмеш мәртәбә артыграктыр.

20-21 март көннәренә яз бәйрәме Нәүрүз туры килә. Аны Иран һәм төрки халыкларда Кояш календаре буенча Яңа ел бәйрәме буларак билгелиләр. Нәүрүзне язын төн белән көн тигезләшкән чорда бәйрәм итү кояш календаре барлыкка килү белән бәйле. Ул Урта Азия һәм Иран халыкларында 7 мең ел элек, ислам дине барлыка килгәнче үк булган. Нәүрүз – Җир йөзендәге иң борынгы бәйрәм, ул яңа тормыш тууын гәүдәләндерә. Фарсы теленнән тәрҗемә иткәндә “нәүрүз – яңа көн” дигәнне аңлата. Аны табигать уянуы, җылыту һәм авыл хуҗалыгы эшләре башлану белән бәйлиләр. Һәрбер илдә бу бәйрәм төрлечә аталган.Аны японнар – “риссон”, кытайлар – “чуньцзе”, славяннар – масленница”, төрки халыклар – “нәүрүз”,фарсылар – “яңа ел “дип атаганнар.

Бәйрәм итүнең гореф-гадәтләре, йолалары буыннан-буынга күчеп, безнең заманнарга хәтле килеп җиткән. Бәйрәмдә бер-берeңне татлы ризык белән сыйлау – төп кагыйдәләрнең берсе булган. Бу – тормыш гел шулай баллы булсын дигәнне аңлаткан. Тормыш гөлләр кебек күркәм булсын дип, чәчәкләр бүләк иткәннәр. Уңыш яхшы булсын дип, бер-берсенә су сибешеп уйнаганнар. Бу көнне буй-буй итеп, 7 төрле кыяк үсемлек утыртканнар. Аларның ничек үсүенә карап,булачак уңыш турында фикер йөрткәннәр. Бу көнне малайлар белән кызлар, һәр өйгә кереп, хуҗаларга такмаклар-такмазалар әйткәннәр, аларны бәйрәм белән котлаганнар.

Халкыбызның иң популяр, иң күңелле язгы бәйрәмнәренең берсе –һичшиксез, карга боткасы. Борын-борын заманда кешеләр нилектән яз булганын белмәгәннәр. Алар ямьле язны җылы яктан кара каргалар алып килә икән, дип уйлаганнар. Шуның өчен карлар эреп сулар ага башлагач, гөрләвекләргә таба, яңаруга-яшәрүгә йөз боргач, каргалар килү хөрмәтенә бәйрәм ясый торган булганнар. Аны “Карга боткасы” дип атаганнар.

Бу көнне балалар матур итеп киенгәннәр, йомырка җыйганнар. Хуҗаларга рәхмәт әйтеп, изге теләкләр теләгәннәр. Халыкны бәйрәмгә чакырганнар. Шулай авылны урап үткәннән соң, ярма, май, сөт алып, табигатьнең иң күркәм җиренә-кардан ачыла башлаган су буйларына, ялан-кырларга яки тау битләренә җыелганнар. Учак тергезеп, казан асканнар, ботка пешергәннәр. Ботка пешкәнче, төрле уеннар уйнаганнар, җырлар җырлаганнар, такмаклар әйтешкәннәр. Аннан соң, бергәләп, ботка ашаганнар. Ботканы балалар үзләре генә ашап

бетермәгән, анының күп өлешен, каргаларга дип ялан өстенә сибеп калдырганнар. Чишмә суына корбан иткәннәр.

Нәүрүз бәйрәме язның башы булса, Сөмбелә көзне түгәрәкләү ае, чөнки бу вакытта урып- җыю эшләре һәм уҗымга сөрү төгәлләнә, ашлык сугылып келәт-амбарларга тутырылган. Нәрсә аңлата соң «Сөмбелә»? Сөмбелә ул 23 нче сентябрьгә туры килгән көн-төн тигезлеге, ягъни көн белән төннең вакыты бер озынлыкта булган көн. Сөмбелә («сары башак» дигән сүз) – татар халкының йола бәйрәме. Ул, урып-җыю эшләре беткәч, көн белән төн тигезләшкән көнне үткәрелгән. Халык «Сөмбелә» бәйрәмен, шатланып, яхшы кәеф белән каршылаган. «Сөмбелә» табыны камыр ашларына бай була, муллык билгесе булган бавырсак пешерелгән. «Сөмбелә» гомер-гомергә уңыш бәйрәме булган.

Авыл халкы сары чәчле бер матур кызны Сөмбелә итеп киендергән һәм, аны уртага алып, биегән, җырлаган, күңел ачкан, Кызлар такыя үргәннәр һәм Сөмбеләнең башына кидергәннәр, чөнки кешеләр Сөмбеләне сары толымлы кыз дип уйлаганнар.

Бәйрәмнәр– тәрбия чыганагы. Мөселман бәйрәмнәре кешедә саф күңеллелек, чисталык, пөхтәлек, миһербанлылык, игелеклелек кебек иң матур һәм кирәкле сыйфатларны тәрбиялиләр. Милли бәйрәмнәребезне саклап калыйк!

**Әдәбият**

1. Баязитова Ф. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. – Казан: Татар кит.нәшр., 1995.

2. Татар дини календаре, 2007.

## ТАТАР КУРЧАКЛАРЫ

*Нәҗметдинова Д., Казан, 181 нче мәктәп укучысы*

*Җит. – Вәлиуллина Ә.Ф.*

Мин дәү әниемнән еш кына матур әйберләр күрсә, аны курчак белән чагыштыруына аптырый идем. Матур кызларны еш кына курчак кебек матур, дип әйткәннәрен ишетергә туры килә, ә менә “курчак өе”кебек авыл өе, “курчак күлмәге”, “курчак букчасы”, “курчак төймәсе”, “курчак чәче” кебек чагыштырулар ишеткәч күз алдыма әнием бүләк иткән матур курчагым килеп баса. Әнием бүләк иткән курчак чынлап та бик матур шул, шуңа күрә матурлыкны дәү әнием курчак белән тиңли дип уйлыйм. Дәү әниемнең миңа җырлап курчак уйнарга өйрәтүе әле дә күз алдымда.

Безнең курчак бик иркә ,
Башларында кәсинкә,
Күлмәгедә сәрпинкә,

Аягында бәтинкә,
Алтын чәчле, зәңгәр күзле,
Коеп куйган кәртинкә.
Безнең курчак уянды,
Чиста итеп юынды.

Башлангыч сыйныфта татар теле укытучысының физкультминут вакытында өйрәткән шигырен әле дә хәтерлим:

Бигрәк шаян курчак син!
Тик тормыйсың берчак син!
Чүгәлисең, торасың
Башың уңга борасың.
Аннан сулга карыйсың
Һәм сикерә башлыйсың.
Башың артка ташлыйсың,
Әйләндерә башлыйсың.
Кулларың күтәрәсең,
Аннары төшерәсең.
Шул арада син иелеп
Басарга өлгерәсең.
Тирән итеп сулыйсың да
Ял итәргә туктыйсың.

Курчак – планетада иң беренче булып барлыкка килгән уенчыкларның берсе. Борынгы заманнарда аларны төрле материаллардан ясаганнар, һәр уенчыкка тирән мәгънә салынуы турында да әйтергә кирәк. Моннан күп гасырлар элек яшәгән кешеләр курчакларның сихри көчкә ия булуына һәм төрле бәла-казадан, авырулардан саклавына ышанганнар. Хәзерге вакытта кибетләрдә нинди генә курчаклар юк... Дөньяның бар кыйтгаларыннан килгән курчакларны ата-аналар балаларына сатып ала. Төркиягә ял итәргә баргач, әнием белән уенчыклар сатыла торган зур кибетләрдә булдык. Гаҗәп, төрек милли киемнәре кидеретелеп ясалган курчакларның нindиләре генә юк... Күңелемнән генә нигә бездә дә шулай ясамыйлар икән, дип уйладым. Казанда милли киемле курчаклар саталар, ләкин алар күп төрле түгел һәм кыйбат та. Төрек курчаклары милли киемнән генә түгел, ә менә төрекчә дә җырлый, сөйләшә, хәтта бии дә. Бала кулына эләккән андый уенчык белән шул телдә сөйләшеп теле ачыла. Казанга кайткач интернет челтәреннән татар курчаклары ясаучылар турында мәгълүмат эзләдем. Игътибарны җәлеп иткәне Питрәчтә яшәүче һөнәрче Эльза Хөснетдинова булды. Беренчеләрдән булып татарча курчаклар тәкъдим иткән. Бу курчакларны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та хуплаган. Эльза үзенә күрә

тәҗрибә дә уздырган. Мөселман курчакларын тыңлаган балалар берничә көн эчендә Коръән сүрәләрен өйрәнгән. Шуңа да татарча сөйләшә торган курчаклар ана теленә өйрәтә алыр иде, дип саный ул. “Татар телен саклау бүген мөһим, актуаль мәсьәләләрнең берсе. Балаларда мәдәнияткә, телгә мәхәббәтне кечкенәдән өйрәтергә кирәк. Алар үзләре теләп, кызыксынып туган телләрен өйрәнсеннәр иде”, – ди Эльза. Эльзаның идеясен тормышка ашыру максатында, быел Республиканың мәдәният министрлыгы бу курчакларны күпләп җитештереп, балалар бакчаларына таратырга булган. Курчакларны ясау буенча тендерны Киров өлкәсендәге уенчык фабрикасы откан. Татарча сөйләшә торган Гөлбикә белән Гомәр исемле курчаклар коңгырт чәчле, көрән күзле, 40-43 сантиметр озынлыкта, сөйләшә торган җайланма белән тәэмин ителгән, милли киемнән. Кием дигәннән, монда таләпләр шактый катгый булган, татарларга хас булганча, курчакларның ыштаннары озын, кызның башында ак яулык, егеттә – түбәтәй, камзул. Аяк киемнәрендә дә миллилек чагыла. Бер курчак 40ка якын җөмлә әйтә. Курчакларны балалар үзләре тавышландыра. Бу да сабыйларга якынрак булыр өчен эшләнгән. Курчаклар исәнләшергә, саубуллашырга өйрәтә. Төрле уеннар, җырлар, такмаклар белән таныштыра. Төсләрне, һөнәрләрне, милли ризыкларны белергә ярдәм итә. Татар мәкальләрен әйтә. Уенчыклар экологик чиста материалдан эшләнгән. Заманыбыз болай да интернетлашкан заманда балаларга аралашу җитми. Алар өйгә кайткач та шул гаджетлар белән утыра, хәтта экиятне дә телефоннан гына тыңлаталар балаларга.

Чыннан да, уенчыкларны сайлау мөмкинлеге күп, әмма араларында мәгънәле уенчыклар, татарча сөйләшә торган курчаклар күбрәк булсын иде.

**Әдәбият**

1. Интертат https://intertat.tatar/news/culture/20-08-2018/tatarcha-s-yl-sh-torgan-kurchaklar-yasauchy-elza-h-snetdinova-berenche-tatar-kurchagyn-r-st-m-nurgalievichk-k-rs-t-sem-kilde-5026153

## М. ҖӘЛИЛ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ПОЭТИК БИЗӘКЛӘР

*Нигмәтҗанова Д., Саба р-ны Шәмәрдән лицее, XI сыйныф*

*Җит. – Галиҗанова Д.И.*

М.Җәлил фикер ачыклыгы, кискен капма-каршы куеп чагыштыру, шигъри интонация һәм әсәрнең эмоциональ-экспрессив көчен арттыру максатыннан антитеза һәм кабатлау кебек поэтик алымнардан киң файдаланган. Аның Моабит циклындагы күп кенә әсәрләре шул алымны куллануның ачык мисалы.

Антитезаларның бер өлеше антонимнарга нигезләнеп ясала. Алар шагыйрьнең тирән кичерешләрен сурәтләү өчен хезмәт итә. Аерым очракларда шагыйрь ут – эш, балчык – тимер, фил – чыпчык, көчлелек – кешелек [3:440], тигәнәк – ал гөл [3:435], кояш – җир асты [3:419], җиңү – үлем [3:418], шәм – көянтә [3:372], утлы – җилле [3:419] кебек контекстуаль яки иҗади индивидуаль антонимнар белән дә эш итә. Мәсәлән:

Мин котлыйм кояшны,
Мин хурлыйм җир астын [3:419].

Шагыйрь мөстәкыйль сүз төркемнәренең һәркайсына карый торган антонимнарны да куллана. Әйтик, җиңү – үлем [3:391], татлы – ачы [3:310], үләчәк – көн күрәчәк [2:6], алар – без [3:385], авыр – рәхәт [3:349], беренче юл – икенчесе [3:373] әнә шундыйлар.

Күренешләрне кискен чагыштыру максаты белән дә ул антитезага мөрәҗәгать итә. Мәсәлән:

Авыр булды аннан аерылу,
Ни әйтсәң дә күңел – күңел шул!
Авыр булды аннан аерылу,
Рәхәт булыр кайткач күрешү! [3:349]

Антонимнар һәм антитезалар лирик геройның эчке кичерешләрен, уй-фикерләрен төрле яклап ачуда мөһим роль уйныйлар. Моның ачык мисалын М. Җәлилнең «Төрмәдә төш» дигән шигырендә күрергә мөмкин. Анда шагыйрьнең төштә күргән чәчәк диңгезе, яшәү, сөю, якты, иркен җир йөзе күренешләренә төрмә, богау, кайгы кебек төшенчәләр каршы куеп сурәтләнә.

Автор үзенең философик фикерләрен сатирик планда тасвирлау өчен дә гиперболик антитезалардан файдалана. Мәсәлән:

Кем сокланмас көчкә, тимер сынса,
Һәм су чыкса баскан эзеңнән.
Тик ни файда, көчең филдәй булып,
Эшең булса, чыпчык тезеннән [3:440].

М. Җәлил иҗатында эмоциональ-экспрессив характердагы фразеологик антонимнарга нигезләнгән антитезалар да очрый. Еш кына шагыйрь үзе дә антоним сүзләрдән тирән эчтәлекле, оригиналь формалы антитезалар ясый. Мәсәлән:

Бер кайгырсам, ике шатланам:
Һәр тамчысы хәләл сөтемнең; Илдә мәңге үлмәс ат белән
Үлә белгән уллар үстердем [3:394].

Поэтик әсәрләрдә аерым сүзләрнең кабатлануы да үзенә бер сурәтләү алымы тәшкил итә. «Алар художестволы сөйләмнең эмоциональлеген, экспрессивлыгын көчәйтүдә һәм сәнгатьчә

яңгырашлы итүдә әһәмиятле стиль чарасы булып торалар»[4:120]. Кабатлауларның формалары бик күп. Шагыйрь аларның төрле формаларын куллана. Түбәндә шуларның берничәсен карап үтик.

1. Гади кабатлау. Ул аерым лексик берәмлекләрнең кабатлануыннан гыйбарәт. Мәсәлән:

Күктә бер кош оча
Югары, югары! [3:382].

2. Поэтик эндәш формасындагы кабатлау.

Бу очракта сүзләрнең мәгънә төсмере үзгәрми, әмма кабатлау эмоциональлекне көчәйтү вазифасын башкара. Кабатланып килә торган сүз төрле сүз төркемнәренә дә карый: а) исемнәр кабатлана:

Юллар, юллар! Мине туган йорттан
Аерып ерак алып киттегез! [3:396]

Шунысы характерлы: М. Җәлил, гадәттә, сүзләрнең тирән мәгънәгә, символик эчтәлеккә ия булганнарын, обстановкага, үзенең рухи халәтен чагылдыруга аеруча туры килә торганнарын кабатлый. Мисаллардагы юл, урман сүзләрен кабатлау ярдәмендә, мәсәлән, үз фикерләренең юл кебек ачык, очсыз-кырыйсыз, хис һәм кичерешләренең урман кебек серле булуына ишарә итә.

Әсәрнең эчтәлегенә, образлар системасына ярашкан хәлдә, кешегә мөрәҗәгать иткән мондый кабатлауларның кайберләре юмор һәм ирония чарасы ролен дә үти. Мәсәлән: Әй, Хәдичә, Хәдичә! Кичегеп кайтты кичә [3:373].

б) фигыль һәм алмашлыклар да кабатланып килә:

Нишлим, нишлим, соңгы минутымда
Пистолетым итте хыянәт! [1:56]

3. Шигъри әсәрләрдә кабатлауларның бер төре булган анафора алымы да актив кулланыла. Тасвирлана торган вакыйгаларның эмоциональ көчен арттыру максаты белән, М. Җәлил андый кабатлауларга еш мөрәҗәгать итә. Мәсәлән:

Ул сайрый, егетнең
Алдына ук кунып,
Ул сайрый, нәрсәдер
Сөйләгәндәй булып [2:10].

Кайбер очракларда тулы җөмләләрдә (рефрен) кабатланырга мөмкин. Бу вакыйганың әһәмиятен тагын да калку итеп күрсәтү өчен эшләнә. Мәсәлән:

Мин озаттым аны сугышка,
Йөрәгемнең сүнмәс кояшын.
Мин озаттым аны сугышка,
Мәхәббәтем булсын юлдашы [3:349].

Аерым сүзтезмәләрнең строфада һәр юл саен кабатлануы (анафора) сурәтләнә торган вакыйгаларның бер үк дәрәҗәдә әһәмиятле булуын ассызыклый.

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем! [1:50].

4. М. Җәлил шигырь юлының соңгы сүзен, икенче юлда кабатлап, шуның белән башлау (ялгау) алымыннан да файдалана. Мәсәлән:

Син онтырсың гөлләр арасында
Гөрләп үткән исем бәйрәмен,
Бәйрәмеңне котлап өстәлеңдә
Дулкынланган чәчәк бәйләмен [3:383].

Әсәрләрдәге сурәтләү чаралары поэтик сөйләмнең аһәңен күтәрүдә, фәлсәфи фикерләрне шигъри поэтик телдә аңларга мөмкинлек бирәләр.

**Әдәбият**


1. Агыла да болыт агыла: Татар һәм рус мәктәпләренең 6-7 сыйныфларында укучылар өчен өстәмә әдәбият./ Төзүчесе З.М.Гыйниятова. – Казан: Мәгариф, 1993. – 256 б.
2. Җәлил М. Сандугач һәм чишмә. – Казан: Татар. кит. нәшрияты, 1985. – 15 б.
3. Җәлил М. Сайланма әсәрләр.Шагыйрь турында истәлекләр./ Төзүчесе Ф.Г. Галимуллин – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2004. – 575 б.
4. Хаков В. Мәктәптә стилистиканы өйрәнү. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1970. – 126 б.


## Г.АЛПАРОВ ГРАММАТИКАСЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ


*Павлова З., Саба р-ны Шәмәрдән лицее, X сыйныф*
*Җит. – Мулласалихова Г.Г.*


Минем эзләнү эшемнең темасы «Г.Алпаров грамматикасының үзенчәлеге» дип атала. Максатым: XX гасырда татар телен фән буларак үстергән галим Гыйбадулла Алпаров грамматикасының морфология бүлегендәге сүз төркемнәренең үзенчәлеген күрсәтү. Бурычлар: галимнең фәнгә алып килгән яңалыгын күрсәтү; хезмәтләрен өйрәнүнең әһәмиятен күрсәтү; эзләнү эше барышында алган белемнәрне башкаларга җиткерү.

1926 нче елда Гыйбадулла Алпаров Ленинградка укырга китә. Зур белгеч булып Казанга кайта. Г. Алпаровны тел галиме буларак дөньяга таныткан хезмәте – «Шәкли нигездә татар грамматикасы» дигән монографиясе.

Хезмәт дүрт бүлектән гыйбарәт: кереш, фонетика, морфология һәм синтаксис. Галим бу хезмәтен татар, башкорт, казах, кыргыз, төрекмән, үзбәк, уйгур телләрен янәшә куеп, чагыштырып яза һәм ул

гомуми тюркология күләмендә фәнни грамматика тудыруда иң уңышлы тәҗрибә була.

Морфология бүлегендәге кайбер мисаллар бүгенге грамматик чаралардан аерылып торалар. Мәсәлән, ясалма сыйфатлар таблицасында түбәндәге мисаллар үзләренә җәлеп итәләр: тамыр һәм нигез фигыльләрдән ясалган сыйфатларны якынлык сыйфатлары итеп бирә: *күтәренке, төшенке, узынкы, сузынкы, ятынкы, тартынкы* [2:35] кебек сүзләрне кертә. Шушы ук юл белән ясалган тиешлек сыйфатларына *аяныч, кызганыч, имәнеч, көленеч, куркыныч,таяныч, куаныч, җирәнеч* [2:38] сүзләрен мисалга ала. Теләк сыйфаты дип аталганнарына шулай ук игътибар итәргә кирәктер: *чәнчелгере, төшкере, булгыры, суккыры* һ.б. Ә артыклык сыйфатларына түбәндәгеләрне кертә: *алгыр,сизгер,булгыры,тапкыр,белгер, чапкыр* [2:46]; шулай ук эшчән, язучан, килешүчән, күлмәкчән, сүзчән сыйфатларында шул төркемгә куя. *Тимерче, эшче, аучы,язучы,укытучы,төрләнмәүче, ашамакчы, килмәкче, тагылмакчы* [2:48] кебек сүзләрне кәсеп-профессия сыйфаты итеп күрсәтә. Болар тамыр һәм нигез исемнәрдән ясалган кушма сыйфатлар итеп карый. Бу юл белән ясалган сыйфатларга уртаклык сыйфаты итеп карап, түбәндәге мисаллар китерә: *юлдаш, иптәш, авылдаш, көндәш, казандаш* [2:51] һ.б. Беренче,икенче һ.б сүзләрен саннардан ясалган тәртип сыйфаты итеп бирә. Саннардан ясалган бүлем сыйфатына түбәндәге сүзләрне кертә:берәр, икешәр һ.б.

Болардан башка сыйфат ясаучы мәгълүмрәк кушымчаларны түбәндәге мисаллардан күрергә мөмкин: *җитез, миңгерәү, саңгырау, калдык, баткак, җирәнчек, йонлач, картлач, бөтен, җыйнак, чабышкы, сөзгәк, тинтәк, җыентык, килмешәк, елдам, күндәм, телдәр* [2:53]. Боларның күбесе берничә сүздә генә сакланып калган.

Исемнәрнең кайбер килеш төрләренә -гы/-ге кушып ясалган – дагы -дәге (да+гы, дә+ге), -ныкы -неке (-ның+кы,-нең+ке) кушма кисәкләр, фигыльләрнең кайбер заман төрләренә лык-лек кушып, мөмкинлек мәгънәсен аңлата торган -арлык- әрлек, -ырлык- ерлек, ә юклык төрендә –маслык -мәслек кушымчалары һәм саннарда чама аңлату өчен йөргән -лап -ләп кисәкләре кушма көенчә үк сыйфат ясаучы кушымчалардан саналырга мөмкин. Мәсәлән, *авылдагы,бездәге, күптәнге, алдынгы, безнеке, Галинеке, ашарлык, көләрлек, белмәслек, бирешмәслек, төшенерлек, унлап,йөзләп* [2:61].

Фигыль, исем, һәм сыйфатларның -ла-лә,-лык-лек,-лы-ле,-сыз-сез, -чы-че, -гы-ге, -кы-ке ясагычлары белән бер-берсеннән кабат-кабат, яңадан ясалулары да мөмкин. Бу вакыт, азаккы кушымчага карап, сүз төркемен билгеләргә тиеш. Мәсәлән, *яхшылык, яхшылыклы,*

*яхшылыклану, яхшылыкланучы, артыклык, артыклыклы, тимерләнгәнлек, матурлаучылык, күренерлекле, эшчеләштерү, крестьянлашканлык* [2:84].

Бу мисаллар Алпаров грамматикасында бирелгән.

Бүгенге грамматика белән чагыштырып караганда, галимнең исем фигыльләрне күрсәтүендә дә аерма бар. «Исем фигыльләр, башка фигыльләр шикелле, безнең телебездә өч төрле булалар: 1) үткән, 2) киләчәк, 3) җавап.

Боларның һәрберсе нигез төрендәге фигыльләрнең азагына үзенә махсус беренче рәт заман төрлекләре кушылу төрләнәләр.

1) Үткән (заман)исем фигыльләр. -ган/-гән, кан/-кән төрлекләре кушып әйтелә: килгән, булган, кайткан, киткән, тазартылмаган,ялтыратылган.

2) Киләчәк (заман) исем фигыльләр. Бу фигыльләр ачак-әчәк, ячак-ячәк кушымчалары кушып ясала. Киләчәк, булачак һ.б.

3) Җавап исем фигыльләр. Җавап исем фигыльләре, яки хәзерге исем фигыльләр, нигез төрләренең азагына «барлык» нигезләрендә -ыр-ер, -ар-әр-р төрлекләре кушып, «юклык»та – төрлеге кушып ясала: *янар, агар, күрсәтер, калыр, үтмәс, алмас, ишетелмәс»* [2:103].

Г. Алпаровның фәнни-теоретик карашлары әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Әгәр галимнең татар орфографиясенә нигез салучыларның берсе булуын, совет чорында да бу өлкәдә әйдәп баручылардан булып калуын искә алсак, әлеге мәсьәләне өйрәнүнең гомумән татар әдәбият белеме тарихын фәнни яктырту өчен бик мөһим икәнлеге ачыклана. Икенче яктан, Г.Алпаровның әдәби-теоретик карашлары һәм күзәтүләре язу тарихын һәм теориясен чын нигездә өйрәнү өчен дә файдалы.

**Әдәбият**

1. Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр – Казан: Татгосиздат, 1945. – 164 б.
2. Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр. – Казан: Мәгариф. 2008. – 287 б.
3. Җәләй Л. Фәнни кыюлык // Казан утлары. – 1978. – №12.

## ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНДА НУМЕРАТИВ САННАР КУЛЛАНЫЛЫШЫ

*Сәлахов Д., Казан, 2 нче лицей-интернат, X сыйныф*
*Җит. – Кәримова Р.Г.*

Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, нумератив сүзләр дип йөртелгән һәм предметларны, әйберләрне санаганда, аларның исәбен күрсәткәндә киң кулланылган бер төркем сүзләр бар [2: 127]. Әлеге сүзләр көндәлек тормышта еш очрый һәм безнең халыкның гореф-гадәтләре, фольклоры, милли традицияләре белән тыгыз

бәйләнгән. Әйтик, халыкның күпьеллык тәҗрибә-күзәтүләрен чагылдырган мәкаль-әйтемнәрнең шактый өлешендә күләм төшенчәсен чагылдырган лексика урын алган. Мәсәлән: *Бер тамчыдан диңгез булмый; Бер тамчы су белән йотарлык; Диңгездән бер* ***тамчы****; Идел суы илле* ***батман****; Артыңнан бер* ***чиләк*** *ком; Төн карыны бер* ***колач*** [3: 23, 34, 82, 109, 121, 134].

Татар халык авыз иҗатында озынлык, авырлык, җир үлчәмен һ.б. белдерә торган бер төркем ачыклагыч сүзләр кергән мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар да байтак. Аларның кайберләре инде искергән, архаизмга әйләнгәннәр:

**а) озынлыкны үлчәү**: *метр, аршын (=0, 711м.), сөям (1/4 аршын), карыш (1/4 аршын); адым, сажин (3 аршын), таяк (3 аршын); чакрым; колач, кара (бер метрга якын), каре (терсәк алып бармак очларына кадәр булган озынлык)* [1: 68-69]. Мәсәлән: *Аршынлы түгел, потлы түгел, һәркемдә дә бар (табышмак); Көн буена утыз аршын өскә күтәрелә, әмма төн буена егерме аршын аска төшә (табышмак); Алтмыш адым атлаганчы, алты тапкыр артыңа кара (мәкаль); Мең чакрымлык юл, бер адымнан башлана (мәкаль)*

**ә) авырлыкны үлчәү**: *грамм, кило,тонна* сүзләре белән беррәттән , *кадак (400 гр.), гөрәңкә, герамәңкә, пот (< рус.), подаука (< рус.), почык һәм бочык (ике пот һәм ике пот сыешлы савыт)* [1: 70]. *Кырдагы борай алтмыш пот, кайткач-суккач – алты пот; Кеше кешене таныганчы бер пот тоз ашый ди (әйтем);*

**б) күләмне үлчәү**: *бер чеметем тоз, бер кабым ипи, бер йотым суз, ике телем ипи, бер уч тоз, ике кушуч он, өч тотам сүс, бер саплам җеп, бер киләп җем, ун кат тун, бер бөртек: Уңган кеше кулына бер уч туфрак алса, алтын итәр (мәкаль); Җиде кат үлчә, бер кат кис (мәкаль); Кечкенә генә сары карт, кигән туны тугыз кат (табышмак); Аяксыз-кулсыз мең кат кигән (табышмак); Җиде кат җир астына керсә дә эзләп табар (әйтем); Күп сөйләгәнче бер телем ипи аша (мәкаль); Бер телем икмәк бөтен дөньяга җиткән (мәкаль); Бер чеметем тоз ашның тәмен китерсә, бер мәкаль сүз ямен китерер (мәкаль);Эшләп ашасаң, бер телем арыш икмәге дә тәмле (мәкаль);Бер бөртек шырпы бер авылны бетерер (мәкаль); Ослан тавы хәтле тау җиңел булды, бер уч туфрак авыр булды (әйтем);Хәерченең бөртек чәен җил очыра (мәкаль);Бәхетле чучка борынында бер өем тизәк белән туа, ди (әйтем).*

**в) сыек әйберләрне үлчәү**: *литр, ярты литр, чирек литр* сүзләре белән берәттән, *аяк, чынаяк, дустаган һәм тустаган, кашык* сүзләре сан ачыклагычы булып кулланганнар: *Кырык төштән билен буган, ун литр аш ашый (табышмак); Бер чынаяк чәйнең кырык ел*

*хәтере бар (мәкаль); Бер кашык су белән йотарлык (әйтем); Яман кешедән ярты кашык аш кала (мәкаль).*

Нәтиҗә ясап әйткәндә, фольклор әсәрләрендә әдәби әсәрләреннән һәм матбугат язмаларыннан аермалы буларак, сыек җисемнәрнең күләмен белдергән *литр, миллилитр* кебек сүзләр актив кулланылмый. *Литр* сүзен без бары табышмакларда гына очрата алдык, ләкин анда да актив кулланылышта түгел: *кырык төштән билен буган, ун литр аш ашый (кисмәк).* Шулай ук татар халык авыз иҗатында каты предметларның, сибелүчән, вак бөртекле әйберләрнең, сыек җисемнәрнең һәм газсыман матдәләрнең күләмен белдерү өчен бай лексик материал файдаланыла. Алар арасында төп урынны татар теленең борынгыдан килгән үз сүзләре алып тора. Күләмне белдергән нумератив сүзләр арасында тамыр исемнәр дә *(уч, кап, йөк, бура һ.б.)*, ясагыч кушымча ярдәмендә ясалганнары да бар *(телем, кыерчык, учма, төргәк һ.б.)*.

Татар халык авыз иҗатында совет чорында үтеп кергән кайбер рус-европа алынмалары нумератив функциядә урын ала алмаганнар, ягъни *порция, процент, гектар, сутый* кебек метрологик берәмлекләр фольклор үрнәкләрендә кулланылыш тапмаганнар.

Әйтелгәннәрдән чыгып, татар халык авыз иҗатында күләм мәгънәсен белдергән нумератив сүзләр белән күбрәк тормыш-көнкүрешкә караган әйберләр, ашлык, яшелчә, җиләк-җимеш, азык-төлек атамалары ачыкланган, чәй һәм су күләмнәре белдерелгән, һава күләмен белдерә торган берәмлекләр сирәк кулланылган дигән нәтиҗәгә киләбез.

**Әдәбият**

1. Беркутов В.М. Бизмәннәрдә вакыт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 80 б.
2. Татар грамматикасы. – Т.II. М: “Инсан”, К: “Фикер”, 2002. – 448 б.
3. Татар халык иҗаты: Хрестоматия.// Төз. Урманче Ф., Миңнуллин К. – Казан: Мәгариф, 2004. – 479 б.

## ИЗУЧЕНИЕ КОНЦЕПТА «ДОЖДЬ» КАК СПОСОБ ФОРМИРОВАНИЯ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКОЙ КОМПЕТЕНЦИИ

*Нурутдинова А., Стерлитамакский филиал БГУ, студент II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Мигранова Л.Ш.*

Федеральные государственные образовательные стандарты формулируют основные требования к обучению русскому языку, одним из которых является формирование культуроведческой компетенции у школьников. Концепт – это национально-культурная

ментальная сущность в сознании человека, представленная языковыми и речевыми значениями.

«Культуроведческая компетенция – это осознание языка как формы выражения национальной культуры, взаимосвязи языка и истории народа, национально-культурной специфики русского языка, владение нормами русского речевого этикета, культурой межнационального общения» [5:22].

Реализация культуроведческого подхода предполагает использование базовых компонентов культурологической направленности, которые в последнее время все чаще упоминаются в методике преподавания русского языка. Одним из них является культуроведческий концепт, который осмысливается как сугубо национальный специфический образ культуры, воплощенный в слове. Он отражает особенности сознания нации, вызывает определенные чувства, ассоциации. Рассмотрим на примере концепта «дождь».

Концепт «дождь» многослоен. Согласно Толковому словарю русского языка С.И. Ожегова и Н.Ю. Шведовой, дождь – это «атмосферные осадки в виде водяных капель, струй»[4:117].

И в славянской и тюркской культуре дождь – всегда личность. Каждый дождь обладает своим собственным характером и даже имеет собственное наименование. Например: грибной дождь (в татарском языке «гөмбә яңгыры»), ливневый (в татарском языке «койма яңгыр»), снежный (в татарском языке «карлы яңгыр»), моросящий, слепой, полосовой дождь и т.д. Но одно дело – знать умозрительно, а другое дело – испытать эти дожди на себе и понять, что в каждом из них заключена своя поэзия, свои признаки, отличные от признаков других дождей. Тогда все эти слова, определяющие дожди, оживают, наполняются выразительной силой.

Рассмотрим образ дождя в пословицах, поговорках, произведениях поэтов и писателей.

У каждого автора, в произведениях которого «гостил» дождь, данный образ представлен по-разному. Например, Б.Л. Пастернак в романе «Доктор Живаго» описал нежный, трепетный дождь: «Моросил бисерный дождь, такой воздушный, что казалось, он не достигал земли, и дымкой водяной пыли расплывался в воздухе». У М. Гафури дождь в одноименном стихотворении представлен весёлым, радующим каждого – и взрослого, и малого. От него даже укрываться не хочется, ведь все знают, что он никому не желает зла и тем более простуды, а всего лишь хочет позабавиться: «Вот веселый, дробный ливень // хлынул, душу веселя, // А еще через минуту // мокрой стала вся земля». Но образ дождя бывает и злой, напористый, который назойливо бьется

в окно, «хлещет» такой дождь у А.С. Пушкина в поэме «Медный всадник». Поэт наделил его чертами человеческого характера: жестокостью, беспощадностью.

И славяне, и тюрки, как известно, были земледельцами. Они всегда относились к дождю с уважением, ведь от него напрямую зависела урожайность, соответственно и благополучие людей. И, безусловно, в их фольклоре много произведений устного народного творчества, посвященных дождю.

Дождь – одухотворенная сила, способная помочь в беде. Люди верили в волшебную силу слова, они обращались к дождю через заклички, которые можно разделить на 2 вида.

Первый вид: на начало дождя и его усиление. В таких обращениях люди просят плодородия земли и хорошего урожая: «Дождик, дождик, пуще, // Дам тебе гущи, // 〈...〉 Дам и хлеба каравай – // Сколько хочешь поливай!» Есть схожие заклички и в татарском языке: «Яңгыр яу, яу, яу! // Кара сарык суярмын, // Ботын сиңа куярмын 〈...〉» Это стихотворное обращение использовалось во время жертвоприношения.

Второй вид: на прекращение дождя. Так, в русском языке: «Дождик, дождик, перестань, // Куплю тебе сарафан! // Останутся деньги —// Куплю тебе серьги 〈...〉»В татарском языке: «Кояш чык, чык, чык! // Янгыр кач, кач, кач! // Без уйнарбыз җылыткач!»

Лексема «дождь» широко представлена и в народных приметах. Главное, на что стоит обратить внимание – временная ориентация. Можно выделить 4 подгруппы:

1. Связь с определенным временем года: Если зима выдалась снежной, лето будет дождливым; Җәй көне яңгыр болыты аксыл күренсә, боз явар.

2. Связь с определенным месяцем: Если в мае было много дождей, то в сентябре их будет мало, и наоборот; Майда яңгырлар күп булса, арыш уңар.

3. Связь с конкретным временем суток: Если ночью не было росы, днём будет дождь; Кояш баеганда яңгыр ява башласа, тиз туктар.

4. Связь с определенным днём месяцеслова: Если на Петров день идёт дождь, сенокос будет мокрый; Симән көнне яңгыр яуса, көз пычрак килә.

Частенько образ дождя использовался для характеристики человека, его чувств и поведения. Например, болтливому человеку говорили: «не карканьем вороны вызывается дождь».

Итак, концепт «дождь» занимает важное место в сознании славянских и тюркских народов. Дождь – это и вестник урожая,

достатка людей, он связан и с внутренним эмоциональным миром человека, с его переживаниями. Человек может относиться к дождю как к преграде, а может и радоваться дождю.

**Литература**

1. Быстрова Е.А. Какую компетенцию мы формируем// Русская словесность. – 2003. – №1.

2. Русский фольклор: хрестоматия для студентов вузов, обучающихся по спец. «Филология» / Т. В. Зуева, Б. П. Кирдан. М.: Флинта; Наука, 1998. – 479 с.

3. Татарский фольклор: монография / Марсель Бакиров; М-во культуры Республики Татарстан, Респ. центр развития традиционной культуры, Казанский (Приволжский) федеральный ун-т. – Казань: Ихлас, 2012. – 399 с.

4. Толковый словарь русского языка: 72500 слов и 7500 фразеологических выражений / С. И. Ожегов, Н. Ю. Шведова; Российская АН, Ин-т рус. яз., Российский фонд культуры. – 2-е изд., испр. и доп. – Москва : Азъ, 1994. – 907 с.

5. Федеральный компонент государственного стандарта общего образования.// Вестник образования России. – 2004. №12.

## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «КАЗАК КЫЗЫ» РОМАНЫНДА КАЗАХ ХАЛКЫНЫҢ ТОРМЫШЫН СУРӘТЛӘҮ

*Рамазанова А., М.Акмулла ис. БДПУ, V курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Насипов И.С.*

Соңгы елларда халыкның үз үткәне, тормышы, мәдәни байлыгы, көнкүреше, туган теле белән кызыксынуы арта. Фикеренең үзгәрүе нәтиҗәсендә, моңа кадәр күренми яткан тел катламнарының ачылуы тарихи вакыйгаларны, тел күренешләрен, әдәби әсәрнең эчтәлеген өйрәнүгә яңача карарга мөмкинлек бирә. Татар әдәби-эстетик һәм иҗтимагый фикерендәге яңа юнәлешләр һәм яңарыш идеяләре әдәби әсәрне башкачарак тикшерү критерийләренә юл ачты. Гомумән алганда, мәдәни, әдәби-эстетик фикер үсешен, тел үзенчәлекләрен өйрәнү халык тарихын аңлау өчен дә бик мөһим. Һәм без бу кечкенә мәкаләдә Галиҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы мисалында әсәрдә казах халкының тормышын сурәтләүдә авторның осталыгына игътибар юнәлтергә булдык.

Галимҗан Ибраһимов гаҗәеп бай әдәби һәм фәнни мирас калдырган шәхесләрнең берсе. Аның «Казакъ кызы» романы − татар прозасының иң яхшы үрнәкләреннән берсе, һәм ул язучының татар теле ярдәмендә башка халыклар тормышына да үтеп керә алуын дәлилли торган әсәре. Романда язучы казакъ даласының гүзәллеген, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, көнкүреш һәм мәхәббәт күренешләрен зәвыклы һәм бай тел белән ачып бирә. Ул татар укучысын төрки кардәшләребезнең 100 ел элек ничек яшәве, тормышы үзенчәлекләре һәм нинди хисләр дөньясында кайнавы белән гаҗәеп оста таныштыра.

Бу әсәр 1923 елның көзендә төгәлләнгән булса да, языла башлау тарихы әле революциягә кадәрге чорга ук карый. Г. Ибраһимов аны 1909 елның җәендә Уралда Миас заводы поселогында яшәгән чагында яза башлап, 1911 елда Казанда тәмамлый. Ләкин роман шул ук елда Оренбургтагы «Вакыт» нәшрияты тарафыннан басарга кабул ителсә дә, дөньяга чыга алмый кала. Кульязма типографиягә бирелгәч, тентүләр вакытында жандармерия тарафыннан конфискацияләнә. 1912-1913 елларда Г. Ибраһимов аны кулында калган караламасы буенча яңадан язып чыга, ләкин әсәр тагы бәлагә тарый: шул ук елның язында Киевта язучы кулга алынган чакта, китаплары һәм барлык кульязмалары белән бергә ул яңадан охранкага эләгә. Бу әсәрне әдипкә бастырып чыгару бары тик 1917 елдан соң гына насыйп була − 1924 елда гына дөнья күрә. Нәшриятка бирер алдыннан әдип аны, табигый, яңадан карап, төзәтеп чыга.

«Казакъ кызы» романы XIX йөз ахыры − XX йөз башы казакъ халкы тормышының сәяси-иҗтимагый, әхлакый каршылыкларын үз эченә алган үзенчәлекле образ-характерларга бай әсәр. Романда вакыйгалар ике сюжет сызыгы буенча бара. Берсе Карлыгач-Арысланбай мәхәббәтенә бәйле, икенчесе ыруглар арасындагы власть өчен көрәшне чагылдыра. Г. Ибраһимов «Казакъ кызы» әсәрендә казакъ кызы язмышы мисалында инкыйлабларга кадәрге казакъ тормышын сурәтләүне максат итеп куя. Анда сурәтләнгән вакыйгалар, романда китерелгән кайбер тарихи мәгълүмәтлардан аңлашылганча, XIX гасыр ахыры-XX гасыр башларындагы чорга карыйлар. Ул вакытта инде Казахстанны Россиягә буйсындыру тәмамланган була. Дала тормышына капиталистик мөнәсәбәтләр дә үтеп керә башлый. Киң далада җир өчен, власть өчен ыруглар арасында тарткалаш китә. Чөнки җир казакъ халкы өчен иң кирәк нәрсә, иң зур байлык булып санала [1, 11]. Шушы изге җир аларның малларын тукландыра, җир юмарт булганда гына казакъ үз тормышының иминлеге, муллыгы өчен борчылмый.

Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романындагы казак халкының тормышы искә алынган тарихи вакыйгалар һәм әсәрнең этнолексикасын бирү аша сурәтләнә. Чөнки тел системасының мөһим дәрәҗәсе буларак лексика буыннан буынга милли дөнья үзенчәлекләре турында булган мәгълүмәтне саклый һәм күчерә. Тел һәр халыкның тарихын, мәдәниятен, әдәбиятын, гореф-гадәтләрен, дөньяга карашын һәм көнкүрешен тулысынча чагылдыра. Шуңа күрә халыкларның рухи тормышы һәм бүтән өлкәләре төрле лексик системаларда тәкъдим ителгән.

Г. Ибраһимов романындагы казах халкының тормышын, көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, табигатен билгеләүче этномәдәни лексика – милләтнең тарихы һәм үсеше турындагы мәгълүмат

чыганагы. Сәнгать әсәрләрендә кулланыла торган этноатамалар милли колоритны һәм этник үзенчәлекләрне күрсәтә. Көнкүреш предметларын атаган этнолексика казахларның тормышын һәм көнкүрешен характерлый. Мәсәлән (калын шрифт белән бирелгән сүзләр көнкүреш этнолексикасына карый):

*Колыннар белән эшләрен бетереп* ***тирмәләргә*** *килгәндә, тукал* ***самавыр*** *куя, берсе сөт белән, берсе* ***киез*** *басар өчен су белән тулы ике зур* ***казанның*** *астына* ***тизәк*** *салып, янмаганга өреп азаплана, ялчы хатын Каләмпер, уң яктагы* ***кара өйдән*** *капчык-капчык* ***куй җоннары*** *чыгарып, шуларны җирдәге* ***камыш чыпта*** *өстенә аударып азаплана иде* [1].

*Арада хаклары икедән утыз сумгача торган төрле төстә байтак* ***чапаннар****, берничә кыйммәтле* ***палас*** *дүртәр аршиннан биш кисәк кара* ***постау*** *бар иде* [1].

*Өстендә буй-буй сырып тегелгән яңа* ***көпе****, башында бәрхет тышлы, кызыл төлке эчле, чите* ***камалы очлы бүрек****, билендә кара алтын белән бизәлгән көмеш* ***кәмәр****, кулында* ***камчы*** [1].

*Зиннәтле зур бай* ***тирмәсенең*** *ишеге төбендәге* ***сабадагы*** *кымызны* ***пешкәк*** *белән шапырып тора иде* [1].

*Бикә кечкенә* ***турсыкка кымыз*** *салдырды, кечкенә бер* ***казылык*** *белән майлы* ***ял*** *алды да авыруның хәлен белергә, авыл читендәге* ***тирмәгә*** *таба китте* [1].

Китерелгән мисалларда аша гына да казахларның тормыш-көнкүрешен, эшчәнлек төрләрен, азык-ризыкларын күз алдына китерергә мөмкин. Алар көнкүрештә кулланыла торган күп кенә традицион предметларны терлек йонынннан, кыргый җәнлекләрдән, кош каурыйларыннан әзерләгәннәр, шулай ук төрле үсемлекләрдән файдаланганнар.

«Казак кызы» романында казак халкының тормышын ачып салучы тел чарасы булып әсәрнең ономастиконы хезмәт итә, чөнки кеше типик вакыйгалар җирлегендә сурәтләгәнлектән, бу әсәрдә ялгызлык сүзләр гаять оста кулланылган һәм алар романдагы төрле күренешләр җирлеген, вакыйгалар тыгызлыгын, мөнәсәбәтләрнең киренкеле көчешен тәэмин итә, казах тормышының, халыкның милли үзенчәлекләрен ачып сала. Әйткәндәй, алар арасында түбәндәгеләрне билгеләргә кирәк:

– **антропонимнар:** *Ак патша, Алтынчәч (бикә: Карлыгач-Сылуның әнисе), Арыслан, Арысланбай (танабуга иленең Магҗан хаҗи баласы), Биремҗан аксакал, Бүребай (Әбелхаернең кардәше), Мостафа (кәрван башы)* һ.б.

Кеше исеме – аерым бер кешене башкалардан аера һәм индивидуальләштереп күрсәтә торган атама. Мәсәлән, *Карлыгач*

исеменең мәгънәсенә күз салсак, казах телендә ул кош исемен – «ласточка» мәгънәсен бирә. Казахлар өчен *карлыгач* борынгыдан ук яхшы хәбәрләрнең чыганагы булган, бу җитез кошчыкның очып килүе яз килүен һәм кар эрүен белдергән, матурлык һәм зыйфалык билгесе саналган. Әсәрдәге *Карлыгач* та яхшы энергетикага ия, матурлыкны тоя, азатлык өчен көрәшә белгән герой. Ир-ат исеме *Арслан* хәзерге телләргә борынгы төрки халыклардан килгән һәм «арыслан», «кыргый җәнлек» дигәнне аңлата. Ул Көнчыгышта киң таралган исем. Ул элек-электән батырлык, горурлык, бәйсезлек символы. Гомумән алган, әсәрдәге кеше исемнәренең барсы да казах антропонимнары.

– **топонимнар:** *Алтын-Күл, Арал диңгезе, Балукаш диңгезе, Коргак-Күл, Диңгез-Күле, Пешпәк чүле, Мафышлак чүле, Тургай чүле* – гидронимнар; *Актүбә, Атбасар, Әхмәт авылы, Җылкы-Баткан (Сарсымбай авылы), Зарафшан буйлары, Кече йөз, Күкчәтау, Кустанай, Кызыл-Ком, Кызылъяр, Олы йөз, Өмбер, Петрбург, Яман-Кала*– ойконимнар һ.б.

Казакъстан топонимиясенә урынның үзенчәлекләрен һәм билгеләрен төгәл тапшыру хас. Бу үзенчәлек казахларның меңнәрчә еллар буена далада шартларында терлекчелек белән шөгыльләнүенә бәйле. Далада һава торышының кырыслыгы, рельефның – тауларның, үзәнлекләрнең, чокырларның, үткелләрнең терлекләрне үрчетүгә йогынтысы, җәйләүләрне һәм көтүлекләрне җентекләп сайлау – барсы да алдан уйлап башкарылырга тиешлеген, озак тупланган тәҗрибәгә таянып хуҗалык итүне таләп итә. Шуңа күрә Казакъстан топонимиясендә еш кына *күл, тау, сай, олы, сылу* компонентлары очрый.

Романда шулай ук без тереклек атамаларына (зоонимнар *Байчобар (ат), Толпар* һ.б.), бигрәк тә этнонимнарга (*Дүрткара ыруг, Алтын ыруг, Кара-айгырлар, Кызылкорт, Найман, Сарманнар, Танабуга ыруг, Кыпчаклар*) игътибар бирергә тиешбез. Алар барсы да укучыга казах тормышының үзенчәлекләре турында сөйли. Географик атамалар, кеше исемнәре, нәсел-ыру атамалары тулысынча казах тормышын, герой-персонажларның эчке һәм тышкы сыйфатын чагылдыра. Этномәдәни лексика халыкның эстетик күзаллауларын, әйләнә-тирә дөньяны танып-белү үзенчәлекләрен чагылдыра. Этнолексика миллилекне белдерүче тел чарасы булып санала.

**Әдәбият**


1. Ибрагимов Г.Г. Казакъ кызы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 191 б.
2. Насипов И.С., Рамазанова А.Р. Ономастика в романе Г. Ибрагимова «Дочь степи» // Духовный мир мусульманских народов. Гуманистическое наследие просветителей в науке, культуре и образовании: материалы Международной научно-практической конференции (XV Акмуллинские чтения) 14-15 декабря 2020 Том II. – Уфа: Издательство БГПУ им. М. Акмуллы, 2020 – 338 с.

3. Садыков Т.С., Жумекенова Д.Е. К вопросу об особенностях происхождения топонимов в истории Казахстана // Молодой ученый. – 2017. – № 11 (145). – С. 396-398. – URL: https://moluch.ru/archive/145/40773/ (Дата обращения: 14.02.2021).

# ОСОБЕННОСТИ ОБУЧЕНИЯ ДЕЛОВОМУ ИНОСРАННОМУ ЯЗЫКУ В РАМКАХ КУРСА ИНОСТРАННОГО ЯЗЫКА

*Сабиров И., КФУ, студент II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Ашрапова А.Х.*

В настоящее время XXI век определил иностранный язык – как инструмент общения, на международной арене и он объединяет в себе разные культуры.  Но все больше и больше иностранный язык функционирует в сфере делового общения.

Термин «деловой иностранный» может охватывать множество понятий и его часто называют и бизнес-иностранным. Когда кто-то говорит, что он преподает деловой иностранный или изучает деловой иностранный, вполне возможно, что говорящий и слушающий могут по-разному понимать этот термин. Мы понимаем, что изучающие деловой иностранный язык – это потенциальные менеджеры, предприниматели и лидеры отраслей на национальном и международном уровнях. В связи с этим шагать в ногу со временем и не отставать ведущих стран мира, где живут носители иностранного языка в основном контролируют мировую экономику, науку, технику и коммерцию, и поэтому перед стоит задача приобрести навыки международной коммуникации с помощью иностранного языка как средства коммуникации. В то же время мы понимаем, что изучение делового иностранного языка – это вопрос престижности и успешности для каждого человека. И наверное, можно утверждать, что успешность состоит в том, насколько быстро люди и общество в целом умеют ориентироваться и подстраиваться под мировые стандарты. И в данном случае деловой иностранный язык является одним из приоритетов в изучении конкретного направления языка.

Деловой иностранный – это отдельный аспект изучения иностранного языка, включающий в себя, в первую очередь, изучение профессиональной лексики в различных деловых сферах. В настоящее время в связи с развитием международных экономических и коммерческих отношений и растущей потребностью в деловом общении на английском языке, знание делового иностранного языка для многих специалистов, предпринимателей и сотрудников международных компаний становится жизненно важной необходимостью.

Существует спрос на деловой иностранный, который, по-видимому, растет, потому что учащиеся все яснее понимают, для чего они хотят использовать иностранный язык. Для обучающихся в образовательных учреждениях бизнес иностранный нужен для того, чтобы в будущем при поступлении на работу либо на любом другом собеседовании вести себя политкорректно и соответствовать требованиям установленным международными стандартам деловой сферы. Также бизнес иностранный показывает уровень образованности, интеллигентности. Бизнес иностранный еще является способом продвинуться в деловую сферу. Нельзя не затронуть тот момент, что деловой иностранный дисциплинирует людей их стиль внешнего вида, манеру общения и поведение в обществе в целом.

Изучая иностранный язык мы затрагиваем азы делового иностранного языка, например, рассматриваем такие темы, как лексикон в сфере бизнеса, общие правила проведения и организация совещаний и конференций.

Как уже описывалось ранее деловой иностранный имеет широкий круг лиц, изучающих его как отдельный навык и умение для достижения своих целей в будущем. В школе нет предмета, изучающего деловой иностранный, но его иногда можно проследить в общем английском. Мы считаем, что преподавание бизнес иностранного нужно начинать со школы, так как требования современного мира все больше ориентируются на молодежь. Занятия деловым иностранным можно ввести как в общий курс иностранного языка, так и организовать факультативы.

Самым важным аспектом воспитания является собственный пример учителя. Например, если Вы сами будете соблюдать деловой этикет внешнего вида и манеру общения, а также вести себя так, как в конечном итоге должны вести себя студенты в соответствии с нормами делового иностранного, то это кардинально будет отличаться от уроков, проводимых там, где нельзя создать вышеперечисленные условия.

Несомненно, для усвоения делового и иностранного языка мы должны владеть азами общего иностранного языка, знать лексису, как минимум уровня B1, грамматику, лингвокультурологические особенности. Поэтому изучение делового иностранного языка в школе – это вполне реальный процесс. Это можно совмещать или проводить параллельно с изучением общего иностранного языка, добавляя моменты из делового английского языка, четыре вида деятельности: говорение, аудирование, письмо и чтение.

Но все же мы должны помнить, деловой английский – это больше помощь обучающимся в развитии их навыков английского

языка в деловом контексте: эффективно отвечать на телефонные звонки, писать более последовательные электронные письма, организовывать деловые встречи, уметь выступать перед аудиторией, делать презентации и т.д.

И в то же время обучающийся понимает, с какой целью он изучает иностранный язык, освежает навыки беглости, соотносит «ожидания» и «реальность» и др. Изучая деловой иностранный язык и приобретая навыки в этой сфере, одновременно вырабатываются такие навыки пунктуальность, профессионализм и компетентность, которые имеют решающее значение не только в деловой, но и в обычной жизни.

В заключении можно сказать, что деловой иностранный язык один из приоритетных ответвлений общего иностранного языка. Преподавание и изучение делового иностранного необходимо начать как можно раньше еще со школьной скамьи. Обучение деловому английскому может быть очень интересным и полезным. Хотя требует разнообразных навыков и приемов, оно в основном сводится к хорошей подготовке и профессиональному подходу.

**Литература**

1. Nickerson, C. and B. Planken. 2016. Introducing Business English. London: Routledge.

2. Koester, A. 2010. Workplace Discourse. London: Continuum.

3. Rainer, F. 2017. 'The history of the language of economics and business' in G. Mautner and F. Rainer (eds.). Handbook of Business Communication: Linguistic Approaches. Berlin: Mouton de Gruyter.

4. Anthony, S. and B. Garner. 2016. 'Teaching soft skills to business students: an analysis of multiple pedagogical methods'. Business and Professional Quarterly 79/3: 360–70.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СОМАТИК ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР

*Сабирҗанова Э., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Җамалетдинова Г.Ф.*

Туган тел һәр халыкның, һәрбер милләтнең тарихи үткәне, бүгенге яшәеше һәм киләчәк язмышы өчен гаять әһәмиятле факторларның берсе. Телдәге һәр күренешне өйрәнү, аның асылына төшенү халыкның туган теле һәм мәдәнияте арасындагы бәйләнеш дәрәҗәсен билгеләүдә дә мөһим роль уйный.

Татар тел белемендә фразеологизмнар шактый тирәнтен тикшерелгән. Моңа карамастан, татар тел картинасын формалаштыруда зур урын тоткан соматик фразеологзмнар бераз читтәрәк калган. өйрәнгән эшләр юк.

Соматизмнар – кеше яисә хайван тәненең тән өлешен аңлата торган сүзләр. Әлеге термин еш кына биология, медицинада кулланыла

һәм ул “кеше тәне белән бәйле булган”лыкны аңлата. Бу диалектларга да, сөйләм теленә дә хас күренеш.

Соматик сүзләр телнең төп лексик фондына карый һәм алар арасында бик борынгы чорларга караганнары да, соңрак барлыкка килгәннәре дә бар. Татар тел белемендә соматизмнар аерым аспектларда бик аз өйрәнелгән. Татар телендә кеше, кеше тәненең әгъзалары темасы Д.Б. Рамазанова тарафыннан “Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика” (2013) дигән хезмәтендә синхроник һәм диахроник планда, башка телләр белән чагыштырылып махсус тикшерелә. Галим соматизмнарны ике зур төркемгә бүлеп карый:

1) кешенең физик төзелешен, әгъзаларын белдерә торган сүзләр;

2) кешенең эчке дөньясын белдерә торган сүзләр [1].

Татар халкының тел картинасында соматизмнар арасында “баш” лексемасы үзәк урыннарның берсен алып тора.

“Аңлатмалы сүзлек”тә “баш” төшенчәсенең 31 мәгънәсе билгеләнә. Без берничәсен генә атап үтәбез: ми, чәч, йөз, күзләр, авыз, борын (яки танау), колаклар урнашкан кеше яисә хайван әгъзасы [2].

“Баш” компонентлы соматизмнарның бер зур төркемен эмоциональ-физиологик хәлдә белдерүче экспрессив берәмлекләр тәшкил итә. Мәсәлән: *баш алгысыз* – тыгын, ерып чыккысыз, тынгысыз. *Баш алмастан* – бик нык, бирелеп дигәннән.

Фразеологик сүзлектә *авыз* сүзе белән түбәндәге берәмлекләр очрады: *авыз ачып калу* – күрә торып кирәк эшне кулдан ычкындыру; *авызда сүз тормау*- сер саклый белмәү; *авыз тутырып әйтерлек түгел*- бик мактарлык түгел [2].

“Борын” соматикасы белән ясалган фразеологизмнар татар телендә шулай ук күп. Мәсәлән: *борын асты кипмәгән* – яшь-җилкенчәк, тәҗрибәсез малай-шалай; *борын астыннан киту* – кулга кергәндә ычкыну, эләкмәү [2].

Күз соматизмы белән бирелгән фразеологизмнар бик күп төрле мәгънәләргә ия.

“Күз” лексемасы физиологик төшенчә, күрү сәләтен белдерә. Мәсәлән: *күзгә йокы кермәү* – бер дә йокламый төн чыгу, йоклый алмау, йокы качу. *Уң күз белән сул күз булу* – икәве бер иштән, бердәм булу; гореф-гадәтләргә, йолаларга бәйле: *башлы-күзле булу* – өйләнү, гаиләле булу; эчке хис-кичерешләр белән бәйле булган төшенчәләр: *Ачу күзе белән карау* – ачуын телдән әйтмичә, күзе белән әйтү [3].

Фразеологизмнарда “колак” төшенчәсеннән ясалган берәмлекләр дә күп. Мәсәлән, *колакка яту, колакка ятышсыз, колакларын шомарту, колакны яра, колагына кермәү.* Фразеологик берәмлекләрдә “колак” соматизмы түбәндәге мәгънәләрне бирә:

*Колагы да күренми* – бөтенләй бурычка яки мәшәкатьле эшкә, гаиләгә баткан. *Колагына аю баскан* – музыкага хиссез, моң һәм аһәң тыюдан мәхрүм кешегә карата [3].

Димәк, татар телендәге фразеологизмнарда соматик берәмлекләр зур роль уйный һәм төрле мәгънәләрне белдерергә сәләтле. Бу төр сүзләр телдә күп гасырлар дәвамында формалашкан төп сүзлек байлыгына карый һәм кешеләрнең тирә-як дөнья турында мәгълүмат биреп кенә калмый, ә аларның үзләре, үз организмнары турындагы белемнәрен дә чагылдыра.

**Әдәбият**

1. Рамазанова Д.Б. Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика. – Казан: ИЯЛИ, 2013. – 364 б.

2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I том: А-В. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 712 б.

3. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: Ике томда. Т. 1: А-К. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 495 б.

4.Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: III том: К. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 744 б.

## БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИЛЕШ РАЙОНЫНЫҢ МӘНӘВЕЗ АВЫЛЫ МИКРОТОПОНИМИКАСЫ

*Сагабиева Л., БГПУ им.М.Акмуллы, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Насипов И.С.*

Илеш районының Татар Мәнәвез авылы микротопонимикасын тикшерү бик актуал, чөнки бу төбәкнең географик атамалары бүгенге көнгә чаклы махсус фәнни тикшерелмәгән. Ә инде билгеле бер торак пунктына карган топонимик берәмлекләрне өйрәнү, бу төбәктәге халыкның тарихын һәм тел үзенчәлекләрен барларга да ярдәм итә.

Илеш районы Башкортостанның төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. Ул Чакмагыш, Дүртөйле, Кызыл Кама, Бакалы районнары һәм Татарстан Республикасының Актаныш районы белән чиктәш. Чикләрнең гомуми озынлыгы 332,5 километр тәшкил итә. Ул элекке Уфа губернасы, хәзерге Башкортстан Республикасында, аксыл сулы гүзәл Агыйделнең таулар һәм киң болыннар буйлап боргаланып агып килгән җиренә, аның кушылдыгы булган Базы елгасы киңлекләренә урнашкан. Район үзәге Югары Яркәй авылыннан төньяк- көнчыгышка таба 26 чакрым ераклыкта, Базы елгасына коя торган Мәнәвез елгасы буена утырган безнең авыл.

Авылның кайчан һәм ничек барлыкка килүен, беренче нигез ташын салучылар кемнәр булганын, нинди ыру халкы яшәгәнен, ни өчен ул Татар Мәнәвезе дип аталганын, халкының язмышын белер өчен, беренче чиратта, Башкортстан тарихы турындагы фәнни хезмәтләргә мөрәҗәгать итү урынлы. Аннан район архивында, Илеш

тарих-туган якны өйрәнү музеенда, Башкортстан Республикасының Милли архивында, Русия Дәүләтенең борынгы актлар архивында (РГАДА) сакланган кайбер тарихи материаллар кыйммәтле мәгълүмәт бирә. Шулар белән бергә авыл аксакалларының истәлекләре дә зур таяныч була ала.

Профессор Ә.З. Әсфәндияров “История сел, деревень и сопредельных территорий” дигән фәнни хезмәтендә (2009 елда басылган) Мәнәвез авылының барлыкка килүе турында болай дип язган: “При одноименной речке возникло поселение Менеуз, впоследствии получившее название Татарский Менеуз. Основанием для этого послужил договор 1777 г. данный тептярям башкирами – вотчинниками Еланской волости”.

Шуңа бераз өстәмә бирик: 1777 елга кадәр үк, 1762 елда, өченче халык исәбен алуда Кыр-Елан волосте җирендә Татар Мәнәвезе авылы катнашкан. Ул елларда авылда 13 ир-ат яшәгәне билгеле. Моны Русия Дәүләт архивында (РГАДА) сакланган ревизская сказка дәлилли.

Бу типтәрләр Агыйдел елгасы буендагы Аткүл авылыннан күчеп килгәннәр. Бу чынбарлыкка туры килә шикелле, чөнки еллар үтү белән, су басу сәбәпле, Аткүл авылының башка урынга күченеп утыруы хак. Шуны да искә алырга кирәк: Аткүл авылы белән Мәнәвез халкы арасында һәрчак бәйләнеш була. Бөек Ватан сугышына кадәрге чорда да Аткүл белән Татар Мәнәвезе арасында аралашу бик тыгыз булган, кыз ярәшү, кияүләп йөрүләр кабатланып торган. Ә Мәнәвез авылында туып, шунда гомер иткән Шәрифуллин Әнгам Шәрифулла улы икенче төрле легенда да сөйләде. Агыйдел елгасы буйлап йөргән бурлаклар елга буенда яшәгән халыкка һич тынгылык бирмәгән. Азык, кием сорап даулаша торган булганнар. Бирмәгәннәрне кыйнап, хәтта үтереп киткән очраклар да булган. Шунлыктан, Аткүл авылыннан кайберәүләр китү җаен эзләгән. Әмма бу турыда төгәл генә дәлилләр юк әлегә.

Язылганнардан чыгып, Татар Мәнәвезе авылының нигез ташын Аткүлдән күчеп килгән Гәрәй ыруы кешеләре – дәүләт крестьяннары салган дию урынлы булыр.

Авылда һәм аның тирә-юнендә географик берәмлекләрнең саны бихисап. Аларның кайберләрен атап үтик: *Җан чишмәсе, Мәнәвез елгасы, Сәбкәй ермагы, Галим ермагы, Әмәди карт яры, Әүлия кабере, Олы куак, Кул буе, Елга агачлыклары, Ваһап җире, Корбан җире* һ.б.

*Җан чишмәсе* – Мәнәвез авылының төньяк өлешендә Сәбкәй тавы янындарак урнашкан. Авылда яшәүче 89 яшьлек Шарифуллин Әңгам бабай болай дип сөйли: “Иң электән бирле бу чишмә Мәнәвез авылында бердәнбер булган, шуңа күрә авыл халкы аны үзләренең җаны кебек саклаганга шундый атама биргәннәр”.

*Мәнәвез елгасы* – Мәнәвез авылының төньяк-көнбатыш һәм төньяк-көнчыгыш өлешендә Җан чишмәсе янында урнашкан. Ул елга бик сай, базы елгасына барып тоташа. Авылда яшәүче 89 яшьлек Әңгам бабай болай сөйли: “Мәнәвез елгасы дип атама кушканнар, чөнки бу елга Мәнәвез авылында урнашкан”. Безнеңчә, гадәттә авылга исемне ул урнашкан елга атамасыннан чыгып биргәннәр

*Сәбкәй ермагы* – Мәнәвез авылының төньяк өлешендә Җан чишмәсенең сул ягында ике түбән тау арасында урнашкан. Авылда яшәүче картлар болай дип сөйли: “Мәнәвез авылы барлыкка килгән вакытны, 1777 елда шул ермакка ерак түгел генә җиргә Сәхибгәрәй дигән кеше килеп утырган булган. Шул вакыттан бирле ул ермакны Сәбкәй ермагы дип йөртәләр”.

*Галим ермагы* – Мәнәвез авылының төньяк өлешендә Мәнәвез елгасыннан ерак түгел генә урнашкан. Авыл халкы аның эчендә бөтерчек бар, дип сөйли. Ул бөтерчеккә кереп китеп үлгән кешеләр бик күп булган. Авылда яшәүче картлар болай дип сөйли: “Мәнәвез авылы барлыкка килгән вакытны 1777 елда шул ермакка ерак түгел генә җиргә Галим дигән кеше килеп утырган. Шул вакыттан бирле ул ермакны шулай дип йөртәләр”.

*Әмәди карт яры* – Мәнәвез авылының төньяк өлешендә Мәнәвез елгасы аккан җирдә буйдан-буйлап урнашкан. Авылда яшәүче Рәзифә әби болай дип сөйли: “Авылда элек елга аркылы сарык фермасы бар иде, Әмәди дигән кеше, төнгелеккә сарык фермасына эшкә барган вакытта, юлны күрмичә шул ярга килеп төшкән булган. Шул вакыттан бирле ул ярны Әмәди карт яры дип йөртәләр”.

*Әүлия кабере* – Мәнәвез авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә Әмәди карт ярыннан ерак түгел калкулыклар кырындарак урнашкан. Әүлия исемле яп-яшь кыз эшкә барган вакытта шул чокырга егылып төшеп үлгән. Янәсе, шуңа чокырны шулай атаганнар. Тагын, имеш, кыз баланы шушы чокырга гына күмгәннәр икән, дигән легенда да авыл халкы хәтерендә сакланган. XX гасыр урталарында Әүлия кабере чокырын авыл яшьләре чокып та караган булганнар, имеш, тик бернәрсәдә тапмаганнар.

*Кул буе* – Мәнәвез авылының төньяк өлешендә урнашкан. Ул Ташкичү авылы белән Мәнәвез авылын аерып тора. Анда җир-җиләге үсә, печәнлек җирләре бар, ак каен белән юкә агачлары үсеп утыра, май ае җиткәч халык шунда милнек җыерга бара. Авыл халкы аны элек-электән шулай дип йөрткән, чөнки Кул буе якын гына – кул җитәрлек җир булган.

*Ваһап һәм Корбан җире* – Мәнәвез авылының төньяк өлешендә урнашкан. Авыл картлары болай дип сөйли: “Иң элек Мәнәвез авылы

барлыкка килгән вакытта, Ваһап белән Корбан исемле ике кеше өйләрен шул тигезлек җиргә салган булганнар, ә хәзер инде анда үлән белән кыр чәчкәләре генә үсеп утыра”.

Шулай итеп, Татар Мәнәвезе чал тарихка ия борынгы авыл. Аның тарихын өйрәнү бик зур әһәмияткә ия. Бу бигрәк тә яшь буында туган якка мәхәббәт тәрбияләү өчен кирәкле. Шуңа күрә мондый җирле тарихны мәктәптә туган тел, тарих дәресләрендә үтемле укыту-тәрбия чыганагы буларак файдалану отышлы.

**Әдәбият**


1. Асфандияров А.З. История сел и деревень Башкортостана и сопределенных территорий. – Уфа: Китап 2009. – 744 с.
2. РГАДА. Русия Дәүләтенең борынгы актлар архивы. Ф. 350, Оп. 2. Д.3802.
3. Илеш районы архивы. Ф 6 Оп. 2 – 16. Хуҗалык китабы. 1952-1954 елларда авылдагы шәхси хуҗалыклар.
4. Татар Мәнәвезе халкы тарафыннан телдән-телгә күчеп килгән легендалар.


## ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ ФОНЕТИК ЧАРАЛАР


*Камалова Д., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Йосыпов А.Ф.*


Фонетик чаралар – авазларның яңгырашына карап, сүзләрне махсус сайлау ярдәмендә хасил булган әдәби күренешләр алар. Әсәр телен аерым авазлар мөмкинлекләреннән файдаланып оештыру, текстның көен, музыкасын табу фоника дип тә атала [1: 203].

Хәзерге татар әдәбиятында фонетик чаралардан еш кына кабатлаулар – анафора, эпифора, ялгаулар килә. Мәсәлән, Г.Гыйльманов иҗатына күз салыйк.

*Әйе, әйе, бөтен җире*
*Әтиемнеке төсле,*
***Әтием кебек*** *бие-е-к ул,*
***Әтием кебек*** *көчле* [2: 188].
*Иң элек курайда туа*
*Һәр аткан таңның көе.*
***Курай ул*** *тылсымлы әйбер,*
***Курай ул*** *– моңның көе* [2: 192].

Кабатлау – әдәбиятта иң күп очраучы чара. Ул – әдәби әсәрдә сүзләр, гыйбарәләр, җөмләләр һәм кисәкләрнең, нинди дә булса кагыйдәгә нигезләнмичә, ирекле кабатлануы [1: 178]. Кабатлау әсәрнең тәэсирлеген, андагы мәгънәви һәм хисст кыйммәтне көчәйтү, язучы теләгән урыннарга укучының игътибарын юнәлтү, яңгыраш-аһәң гармониясен тудыру кебек вазифаларны башкара.

Әдәбият кабатлауга нигезләнгән бик күп стилистик чаралар белән эш итә. Аларның кайберләре, мәсәлән анафора, эпифора, ялгау фонетик чаралар буларак та билгеләнә.

Р.Миңнуллинның шигырьләрендә иң күп кулланылганы – кабатлаулар. Шагыйрь үз әсәрләрендә кабатлауларның күп кенә төрләрен куллана.

Күп кенә әсәрләрендә шагыйрь композицион анафораның төрле формаларын яратып куллана: ул шигырьнең буеннан буена һәр строфаның ахырында беренче строфаның соңгы юлын кабатлап бару. Мәсәлән:

***Башкортстан** – язмышлары,*
***Башкортстан** – Ватаннары!*
*Монда туды, монда үсте*
***Башкортстан татарлары.***
*Шушы илдә, шушы җирдә*
*Шатлыклары, аһ-зарлары.*
*Ни күрсә дә монда күрде*
***Башкортстан татарлары*** [3: 23].

Шагыйрьнең әсәрләре арасында кабатлауның икенче бер төрен эпифораны (шигырь юлларының ахырында бер үк сүзләрнең кабатланып баруы) куллануга да матур мисаллар очрый. Менә, мәсәлән, “Без дә яшәгән булабыз” шигыре:

*Без дә яшәгән **булабыз,***
*Гомер иткән **булабыз:***
*Алай иткән **булабыз,***
*Болай иткән **булабыз,***
*Иген иккән **булабыз,***
*И интеккән **булабыз,***
*Тир дә түккән **булабыз,***
*Җәфа чиккән **булабыз,***
*Ат та җиккән **булабыз...*** [3: 57].

Эпифора ярдәмендә автор мәгънәви тирәнлеге белән аерылып торган әһәмиятле сүз-гыйбарәне билгели, калкытып куя, аның яңадан-яңа төсмерләрен ачыклауга мөмкинлек тудыра.

Аналепсис – шигырь юлларында янәшә торучы сүзләрнең охшаш яңгыравы [1: 204].

Р.Фәйзуллин иҗатында аналепсислы шигри юллар бик күп:

***Канунсызлык канун** икән –*
*булмас Кеше кадере* [4: 175].
***Каркылдый карга** ашыкмый гына...*
*Очына күбәләк онытылып!*

*... Үлеп киткән, йөрәге тотып,*
*утыз яшьлек геронтолог* [4: 176].

Р.Фәйзуллин иҗатында паронимларга да хас булдык. Парономия – охшаш яңгырашлы сүзләр, кушымчалар белән “уйнау” ярдәмендә мәгънә тудыру [1: 204].

***Чайкала-чайкала***
*Иделдә* ***ай кала***
*Безне озата баралар*
*Яшь кыз чишенеп кала!* [4: 190].

Кайчакта Р.Миңнуллин рифма өчен бик сирәк кулланыла торган сүзләрне файдалана, яки үзе үк яңа, әмма халыкчан сүзләр барлыкка китерә. Мәсәлән:

*Туган җиргә кайтсам – китсәм,*
*Юлым* ***Актаныш аша.***
*Шуңа микән, кайткан саен*
*Җаным* ***актанышлана*** [3: 146].

Шул рәвешле без татар шигъриятендәге фонетик чараларны билгеләдек, үзенчәлекләрен ачыкладык. Фонетик чараларның барысына бер уртак принцип хас: алар шигырьдәге мәгънәле, уңышлы кулланылган сүз, сүзтезмәләрне ассызыклый, аларны көчәйтә һәм ныгыта.

**Әдәбият**

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
2. Гыйльманов Г. Көмеш тарак: Пьесалар, шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 207 б.
3. Миңнуллин Р.М. Әсәрләр: 7 томда, 2 т.: шигырьләр, җырлар, эпиграммалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 591 б.
4. Фәйзуллин Р. Сайланма әсәрләр: 6 томда. 1 т.: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.– 495 б.

## КРАСНЫЙ ЦВЕТ В ЧУВАШСКОЙ ЛИНГВОКУЛЬТУРЕ

*Кудрявцева К., КФУ, магистрант II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Замалетдинова Г.Ф.*

Каждый народ имеет культурное наследие, богатство, что для лингвокультурологии дает большую ценность. Одной из жемчужин тюркского народного культурного искусства является семантика цветообозначения, которая скрывает тайны и открывает новые знания про народ и его язык. Семантика цвета возродилась с древних времен, однако свои знания открыла только в советское время.

В данной статье мы обратимся к чувашскому народу: орнаменту, фольклору и народным промыслам. О значениях красного цвета в народе мы знаем так мало, она таит в себе массу загадок,

которую можно разгадать лишь глубоким исследовательским проникновением.

Значение цвета, композиция, состоящее из разных оттенков, доносят до нас воззрения и мысли древнего человека, его понимание реального мира. Так же композиция цвета передает мировоззрение и религиозные представления, которые передавались из поколения в поколение.

Заслуженный артист чувашского драматического театра И.И. Иванов определяет молодую науку «цветосемантика» как древнейшую загадку народа, способом передачи истории и знания своему поколению [1:2-3].

Чувашский орнамент скрывает глубокую тайну цвета. Красный цвет является преобладающим цветом в вышивке. При этом оттенки красного цвета имели широкий диапазон использования: от темно-бордового цвета до светло-алого цвета. Известно, что красный цвет символизирует жизнь, отвагу, радость, источник счастья, огонь, солнце и плодородие. Чувашская вышивка отличается дисциплинированностью, приучает к гармоничному расположению цветов, используя их минимальный набор жесткой выдержанной структурой. По утверждению этнографа И.Н. Смирнова для чувашской вышивки «…характерно такое разнообразие приемов шитья, которое не знает ни один народ России» [2:32-33].

Цвет оберега в чувашской вышивке для детей всегда был красный. Женщины, вышивая этим цветом, молились о защите своего чада, обращалась к матери-земле, к солнцу. По старинным обычаям женщины всегда должны были заниматься рукоделием, украшением одежды. Данному искусству обучали девочек с 7-8 лет, передавая им знания по колористике.

Чувашский пояс – еще одна особенность чувашской одежды, который тоже был красного цвета. Пояс защищал всех представителей чувашского народа от злых духов, нечистых сил и порчи. Мужчины для придачи большей защиты на дальние дороги носили маленький мешок плодородной родной земли «*тăван çĕр*». Женщинам же пояс служил как оберег от бесплодия.

Наверняка все видели флаг Чувашской Республики: в центре полотна располагается пурпуровые эмблемы древних чувашей «Древо Жизни» и «Три Солнца». В геральдическом толковании эти эмблемы сандалово-красного цвета означают достоинство, мудрость, мужество и силу. «Древо Жизни» на основе рунического письма напоминает силуэт почитаемое чувашами дерево дуб – могучее, долговечное и стойкое в природных ненастьях. Эмблема «Три Солнца», состоящее из

восьмиконечной звезды, символизирует солнечный свет, дарящий жизнь и оберегающий благополучие, а троекратное повторение звезды означает чувашское народное понятие «*Пулнă, Пур, Пулатпăр*» (Были, Есть, Будем).

В мифологии красный цвет имеет негативный характер. Например, чувашская легенда «О красной корове» («*хĕрлĕ ĕне*»), рассказывает историю Волжской Булгарии. По легенде, «красная корова» съела чувашскую книгу, которая хранила всю историю чувашского народа. Красная корова символизирует огонь и уничтожение. Эта легенда описывает историю, которая произошла в 1236 г. Тогда Золотой Ордой была уничтожена великое государство – Волжская Булгария. Тогда сгорела самая большая в Европе библиотека того времени, которая хранила экземпляры редких книг. Г.Г. Ильина неоднократно упоминает это в своей книге «Несказочная проза в системе жанров чувашского фольклора» [3:145-157].

Исследуя «красный» цвет, нельзя оставить фразеологизмы – этот цвет издревле знаменуется цветом солнца, огня, плодородия, власти и силы. Данный цвет в чувашском языке фразеологизм *хĕрлĕ йытă* (красная собака) используется со значением огонь, пожар, война.

Так же красный – *хĕрлĕ*, встречается в обычаях, например праздник *хĕрлĕ çыр* (красная черта) – черта перехода от смерти к жизни. *Хĕрлĕ çыр* символизирует период половодья, как некую черту между жизнью и смертью.

В постсоветское время красный цвет имел широкое распространение. Тогда истинное значение красного цвета утратила свое настоящее значение.

Таким образом, цветосемантика указывает и на место проживания человека и на образ жизни. Полыхающие красные тона вышивки – это и центральная черноземная полоса России, и кочевой характер, стремящийся к обновлению и переменам в жизни.

**Литература**

1. Иванов И. И. Халăхăмăра савăнтарас килет: [автобиогр.] // Тăван Атăл. – 2010. – № 7. – С. 1-8.

2. Вышивка в быту казанских татар [Электронный ресурс]. – Режим доступа: http://www.1000kzn.ru/article/ ru/146/77/

3. Ильина Г. Г. Несказочная проза в системе жанров чувашского фольклора: дисс. к фил. н. – Ижевск, 2006. – 226 с

## СТРУКТУРНАЯ ХАРАКТЕРИСТИКА ОККАЗИОНАЛИЗМОВ В ДЕТСКОЙ ПОЭЗИИ М.Д. ЯСНОВА

*Ли Биньжун, КФУ, магистрант I курса*

*Науч. рук. – докт. филол. наук, проф. Гилазетдинова Г.Х.*

В лингвистике для обозначения такого языкового явления, как окказионализмы, существует множество терминов: химерические образования, слова-однодневки, индивидуально-авторские слова, авторские неологизмы, вечные неологизмы и т.д. Подобное разнообразие терминологии «объясняется тем, что каждый исследователь кладёт в основу изучаемого предмета признак, который, по его мнению, является наиболее ярким» [1]. Окказионализмы не только показывают, как можно использовать словообразовательные возможности языка, но и развивают воображение и фантазию ребёнка. Именно поэтому некоторые тексты, содержащие окказионализмы, включены в упражнения учебников по русскому языку для начальной школы.

Окказионализмы часто встречаются в произведениях Михаила Яснова, особенно в поэтических текстах для детей. Поэт сочетает языковую игру с детскими стихами. Это также имеет определенную связь с характеристикой окказионализмов, которые уникальны и новы.

Михаил Яснов создает окказионализмы в основном способом контаминации и путем добавления к словам (преимущественно к существительным и прилагательным) суффиксов. Так образовался окказионализм *пуделица* со значением «пудель женского пола» от полной основы существительного пудель + суффикс -иц-: *С тобою костью поделиться? Спросила гостью пуделица* [3: 52]. В стихотворении «Кисуня и Крысуня» выявлены окказионализмы *крысуня* и *кисуня.* Так, *кисуня* произведено от слова *киса* + суффикс -ун-, подобным образом создан окказионализм *крысуня*: *А мимо Кисуни Крысуня бежала* [2: 83]. Существительное *печалесть* со значением отвлеченного признака или состояния образовано при помощи суффикса -есть от полной основы существительного *печаль*, хотя традиционно данный суффикс прибавляется к основе имени прилагательного.

Суффиксальным способом образованы существительные *паукан* (полная основа сущ. паук + -ан-), *паренье* (усеченная основа глагола парить + -енj-), *магазинец* (полная основа сущ. *магазин* + -ец-), *скрипачонок* (полная основа сущ. *скрипач* + -онок-), *медведик* (полная основа сущ. медведь + -ик-), *доберманша* (полная основа сущ. *доберман* + -ш-), *муравьяне* (полная основа сущ. *муравьи* + -ян-), *канатоходица* (усеченная основа сущ. *канатоходец* + -иц), *хорошка* (полная основа прил. + -к-) и др.

Суффиксальный способ образования использован и при создании нескольких окказиональных прилагательных. Так, окказионализм *разгрызочный* со значением «признак по действию»

возник путем присоединения к основе глагола *разгрызть* суффикса -очн-. Прилагательное *румянцевый* строится по модели «полная основа существительного румянец + суффикс -ев-». Авторский неологизм *моросячий* образуется от усеченной основы глагола *моросить* с помощью суффикса -яч-. *Да здравствует жизнь поросячья! Погода стоит моросячья!* [2: 46].

Контаминация также отражена в стихах Яснова, например: *Туфляндия, Свитерляндия, Шляпляндия*. Эта контаминация образована в результате слияния названий одежды на русском языке (туфли, свитер, шляпа) + усеченная часть существительного Финляндия. Ср.: *Проснувшись, крикнул маме я: – Прощай, моя Пижамия! Да здравствует Туфляндия!* [3: 8].

Усечение первого слова встречается при образовании существительных *счастливень* (усеченная основа сущ. *счастье* + целое слово *ливень*), *веселютик* (усеченная основа сущ. *веселье* + целое слово *лютик*). Кроме того, выявлено достаточное количество окказионализмов, состоящих из полного слова и одного усеченного слова, ср.: *хвостаствуйте* – хвост и здравствуйте, *берлогово* – берлога и логово, *абрикосень* – абрикос и осень, *чудетство* – чудо и детство и др. Встречаются также окказионализмы, синтезированные двумя стандартными словами и инфиксом: *дикобратия* – дикая и братия + интерфикс «о».

Таким образом, в результате исследованиям структурных особенностей окказионализмов в стихотворениях Михаила Яснова было выявлено, что ведущим способом образования окказиональных слов является суффиксация и контаминация.

**Литература**

1. Костина Е.В. Авторские новообразования в языке отечественной детской литературы: функциональный и словообразовательный аспекты: диссер. на соискание ученой степени канд. филол. наук. – Орел, 2007. – 260 с.

2. Яснов М.Д. Детское время: Стихи. – СПб.: 2012. – 128 с.

3. Яснов М.Д. Дружунгли. Играем в стихи!: Стихи. – М.: Изд-во ОНИКС-ЛИТ, 2017. – 72 с.

## РАШАТ ГАЙНАНОВНЫҢ ТЕКСТОЛОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ Г.ТУКАЙ БАСМАЛАРЫ

*Минемуллин Р. КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гыйлаҗев Т.Ш.*

Габдулла Тукай әсәрләренең фәнни нәшере турында сүз алып барганда, үз гомерен әлеге шагыйрьнең иҗатын өйрәнүгә, аның әдәби-публицистик мирасын туплауга багышлап, әдәбият фәнендә тирән эз

калдырган галим Рашат Гайнановны искә алмау һич мөмкин түгел. Галим-текстолог олуг шагыйрь иҗатын өйрәнүче галимнәргә фәнни эшләре өчен ныклы системага салынган нигез әзерләп калдырган.

Үзенең дүрттомлыгы белән әдәбият һәм сәнгать әһелләренә, укучыларыбызга олы бүләк ясаган галим Тукай әсәрләренең әле моның белән генә бетмәгәнлеген, тагын да табылачагын күңеле белән сизгәндер, күрәсең. Ул эзләнә, Тукай иҗатын бөртекләп туплавын дәвам итә һәм аның фидакарь хезмәте көтелгәннән дә артыграк нәтиҗә бирә: шагыйрь әсәрләренең тагын бер томлыгы өчен яңа материал туплый. Иң сөендергәне шул: биштомлыкта моңарчы дөнья күргән басмаларда урын алмаган тагын 125 әсәр кертелгән. Фәнни басманың дүрттомлыгы чыкканнан соң, С. Хәким “Тукайны укыйм...” мәкаләсендә, шагыйрьнең моңарчы билгеле булмаган әсәрләре табылуга сөенеп, болай дип яза: “Шатландым һәм әрнедем. Соң булса да табылуына шатландым... Мин инде Тукай өйрәнелеп бетте, иҗаты буенча диссертацияләр язылып бетте, шагыйрь үзенә җитәрлек фән докторлары әзерләде, дип йөри идем. Артык ышанганмын” [4]. Сибгат Хәким ихлас күңеленнән шушындый бәхеткә ирештергән Рашат Гайнановка рәхмәт әйтә, аңа бурычлы булуыбызны белдерә.

Яхшы текстолог берьяклы гына эш йөртми. Ул табылган материалларга әдәби-эстетик яктан да, сәяси яктан да бәя бирә алырлык ныклы әзерлекле галим булырга, тарихны, төрле чыганаклар белән эшләү системасын һәм технологияләрен яхшы белергә тиеш. Р. Гайнанов текстологик эшчәнлеге әнә шундый сыйфатларга ия. Галим Ф. Урманчеев биштомлыкка рецензия буларак язылган “Кадерлерәк була бара” мәкаләсендә текстологның тулы бер системага салынган хезмәтенә, гомумән, биштомлыкка тәфсилле бәя бирә. Мәкаләдән күренгәнчә, Р. Гайнанов туплаган барлык материаллар да – Тукай замандашлары тарафыннан язылган истәлекләр, әдипнең үзенең хатлары “бөек шагыйрьне шәхес буларак күз алдына китерергә ярдәм итәләр”. Басманың һәрбер томында зур урын алган “Искәрмә һәм аңлатмалар”га бәя биреп, Ф. Урманчеев: “Һәрбер әсәрнең кайчан һәм нинди шартларда язылуы, беренче тапкыр кайда басылуы, шагыйрьнең кайсы күптомлыгына кертелүе турында искәрмәләр бай мәгълүмат бирәләр. Еш кына алар шагыйрь әсәреннән берничә тапкыр зуррак булып чыгалар,” – дип искәртә [3: 161].

Тукайның һәр хезмәтенә, шигыренә, публицистикасына язылган искәрмәләрендә Тукай яшәгән чор бөтен тулылыгы белән чагыла. Күренекле шәхесләр турында да, татар тормышының сәяси-иҗтимагый, әдәби тормышы хакында да мәгълүмат табып була. Бу материаллар зур төгәллек белән тикшерелеп анализланган, башка

чыганаклардан алынган материаллар белән чагыштырып баетылган. Һәр искәрмәнең әдәби-тарихи тикшеренү эше нәтиҗәсе булуы бәхәссез. Әнә шундый кыйммәтле материалларны туплаган биштомлык гыйльми басмасы энциклопедия дәрәҗәсенә тиң.

Г.Тукайның алда дөнья күргән дүрттомлыгы да бай мәгълүматка ия булуына карамастан, Р. Гайнанов бер китаптагы материалны икенчесенә күчереп кую белән генә шөгыльләнмәгән. Элеккеге искәрмәләрнең эчтәлеге тагын да ныграк баетылган, күләм ягыннан да артыграк булып чыккан.

Тукай томнарында ул яшәгән чорның күренекле шәхесләре белән беррәттән, җәмәгатьчелеккә билгеле булган кайбер реакцион затлар, иҗтимагый тормыш, басмаханәләр эшчәнлеге һәм башка күп нәрсәләр турында да материал җитәрлек. Алар турындагы искәрмәләрнең дә эчтәлеге бик бай. Мәсәлән, Тукайның “Бозау кадәрле зур фәлсәфә” мәкаләсе турындагы искәрмәдә Р. Гайнанов аның нинди тәхәллүс белән кайсы басмаларда ничә тапкыр басылуы турындагы мәгълүматлар белән генә чикләнмичә, шагыйрь санап кына киткән 57 газета-журнал турында бик зур материал биргән. Галим-текстолог бөтен Россия буенча таралган бу басмаларның һәркайсын карап-күзәтеп, аларның кайчан һәм кайсы шәһәрләрдә чыгуы хакында тикшереп, дөрес мәгълүмат бирә.

Тукай әсәрләренең күптомлыкларын төзү юнәлешендә, Р. Гайнановның эзлекле фәнни-тикшеренү эшләре алып баруын галим Ф. Галимуллин да ассызыклый. Аның биштомлыкның ике томы чыгу уңаеннан язылган “Һаман да якыная” мәкаләсендә болай диелә: “Г. Тукайның әдәби мирасын ачыклау эшен... алып баручы бу галимебез башкарган эш үзенең камиллеге, киң кырлы булуы белән игътибарны җәлеп итә. Искәрмәләр генә дә 120 биткә якын, аларның кайберләрен... фәнни әһәмияте булган мөстәкыйль мәкалә дип исәпләргә мөмкин” [2].

Р. Гайнанов эзләнүләренең тагын бер нәтиҗәсе түбәндәгедән гыйбарәт. Тукайның әсәрләре басылган барлык гәзит-журналлардан ул шагыйрьнең утыздан артык яңа тәхәллүсен (псевдонимын) ачыклый. Кайсы әсәре нинди тәхәллүс белән чыкканлыгын биштомлык искәрмәләрендә дә күрсәтеп бара. Тукай тәхәллүсләренә ни рәвешле тап булуын галим үзенең “Билгесезлектән – яңа томга” мәкаләсендә ачык күрсәткән. Тукайның тәхәллүсләре күп булган. Шулардан иң таралганнары – “Җен”, “Сөңге”, “Хәйләсез”, “Чапансыз”, “Мылтык”, “Шүрәле”, “Адвокат”, “Догачы”, “Каз”, “Хәсрәт”, “Кырмыска” һ. б. Галим аларны Тукай язышкан күпсанлы гәзит-журналлардан эзләп тапкан. “Чыннан да, бу газета-журналлардагы псевдонимнарны,

имзасыз шигырь һәм мәкаләләрне җентекләп тикшерү, чагыштыру – гомумән, киң планлы текстологик эш нәтиҗәсендә Тукайның өч дистәгә якын яшерен имзасы ачылды,” – дип яза галим үз мәкаләсендә [1]. Рашат Гайнанов Тукай турында күбрәк материаллар туплап калуны халкыбыз өчен иҗтимагый һәм милли яктан әһәмиятле дип саный.

Йомгак ясап әйткәндә, Габдулла Тукай әсәрләренең фәнни басмаларын төзүгә Р.Гайнанов үзеннән зур өлеш кертә. Халык шагыйренең киләчәктә академик һәм иң югары дәрәҗәдәге энциклопедик басмаларын әзерләүгә нигез һәм әдәби-гыйльми җирлек салып калдыра.

**Әдәбият**


1. Гайнанов Р. Билгесезлектән – яңа томга // Соц. Татарстан. 1976. 20 май
2. Галимуллин Ф. Һаман да якыная // Соц. Татарстан. 1985. 12 октябрь.
3. Урманчеев Ф. Кадерлерәк була бара // Казан утлары. 1987. №4. Б. 161-165.
4. Хәким С. Тукайны укыйм // Соц. Татарстан. 1975. 28 октябрь.


## ВЗАИМОСВЯЗЬ МЕНТАЛИТЕТА И ЛЕКСИЧЕСКОЙ СИСТЕМЫ ЯЗЫКА В ПРОЦЕССЕ ФОРМИРОВАНИЯ ЯЗЫКОВОГО СОЗНАНИЯ И КОММУНИКАТИВНОГО ПОВЕДЕНИЯ ЛЮДЕЙ


*Миннибаева Л., КФУ, магистрант II курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Бастриков А.В.*


Взаимодействие языка и культуры играет значимую роль при становлении национального характера. Именно в языке находят отражение такие составляющие национальной культуры, как мировосприятие, мировоззрение, менталитет, социальная культура. Исследователь С.Г. Тер-Минасова в книге «Язык и межкультурная коммуникация» приводит следующее определение: «Язык – это исторически сложившаяся система звуковых, словарных и грамматических средств, объективирующая работу мышления и являющаяся орудием общения, обмена мыслями и взаимного понимания людей в обществе» [3: 112].

С данным определением трудно не согласиться, поскольку язык – прямjq инструмент культуры: именно он хранит накопленный народом социально-культурный опыт («интеллектуально-духовные гены»), который передается будущим поколениям. Культурную наполненность языка легко отследить на примере устойчивых единиц: фразеологизмов, прецедентных феноменов, пословиц и поговорок. Многовековой культурный опыт скрыт именно в лексическом составе языка. Н.Д. Бурвикова и В.Г. Костомаров предложили называть единицы этого слоя «логоэпистемами» [1: 10].

У каждого народа имеются свои характерные особенности, напрямую связанные с историей, бытом, социальными отношениями этноса. На мой взгляд, пословицы и поговорки являются отражением народного опыта познания окружающего мира, которые отчасти влияют на коммуникативное поведение носителей разных культур. Рассмотрим в качестве доказательства часть лексического состава языков на примере русских и турецких устойчивых выражений.

| | |
|---|---|
| *«Ağaç kökünden yıkılır» (Дерево гниет с корня)* | *Рыба гниет с головы* |
| *«Hastanın halini sağ bilmez» (Здоровый не поймет больного)* | *Сытый голодного не разумеет* |
| *«Kürkü orak vaktinde, orağı kürk vaktinde» (Меховую одежду покупай во время серпа, а серп покупай во время меховой одежды)* | *Готовь сани летом, а телегу зимой* |
| *«Akşam oldu kon, sabah oldu göç» (Наступил вечер – ложись спать, наступило утро – отправляйся в путь)* | *Утро вечера мудренее* |
| *«Sözün doğrusunu çocuk söyler» (Правду говорит ребенок)* | *Устами младенца глаголет истина* |
| *«En güzel deniz henüz gidilmemiş olanıdır» (Самое красивое море то, куда еще не ездили)* | *Хорошо там, где нас нет* |
| *«Borçtan korkan kapısını büyük açmaz» (Тот, кто боится долгов, дверь широко не открывает)* | *Волков бояться – в лес не ходить* |
| *«Kürkçünün kürkü olmaz, börkçünün börkü» (У меховщика не бывает шубы, а у шляпника – шапки)* | *Сапожник без сапог* |
| *«İyi dost kara günde belli olur» (Хороший друг проявляет себя в черный день)* | *Друзья познаются в беде* |

Итак, как мы видим из рассмотренных выше примеров, у турецких и русских устойчивых выражений кроме семантических соответствий наблюдаются незначительные различия в количественном составе и степени проявления экспрессивных свойств фразеологических единиц, что является следствием национальных картин мира.

Язык любого этноса представляет собой ресурс, который хранит в себе фрагменты его культуры. Национальный характер (менталитет) и язык гармонично дополняют друг друга. Язык является подтверждением национального характера, он хранит тот самый

социально-культурный пласт, который бережно передается народом из поколения в поколение.

В современном мире, охваченном глобализацией, изучение языкового сознания и коммуникативного поведения людей, носителей разных менталитетов, является, как никогда, актуальным.

Существует мнение, что главной причиной непонимания при межкультурном общении является не различие языков, а различие национальных сознаний коммуникантов [1: 73].

Основными факторами, способствующими изучению языкового сознания, которое закрепляет культурно-коммуникативный опыт, являются:

– открытость к познанию иных культур;

– адекватность восприятия политических, социальных и психологических межкультурных различий;

– умение и желание преодолевать созданные стереотипы;

– умение извлекать и дифференцировать информацию из различных культурных источников;

– толерантность и уважение к другим культурам;

– верный выбор стратегии коммуникативного поведения.

Таким образом, коммуникативное поведение, как один из механизмов межкультурного взаимодействия, должно стать связующим компонентом культурно-языковых пространств. Развитие коммуникативного поведения личности напрямую связно с желаемым результатом выбранных ею тактик в межкультурной коммуникации.

**Литература**

1. Костомаров В.Г. Старые мехи и молодое вино: Из наблюдений над русским словоупотреблением конца XX в. / В.Г. Костомаров, Н.Д. Бурвикова. – СПБ.: Златоуст, 2001. – 72 с.
2. Тарасов Е.Ф. Языковое сознание – перспективы исследования // Языковое сознание: содержание и функционирование. XIII Международный симпозиум по психолингвистике и теории коммуникации. Тезисы докладов Текст. / Москва, 1-3 июня 2000 г. – М., 2000. – 288 с.
3. Тер-Минасова С.Г. Язык и межкультурная коммуникация. – М.: Букинистика, 2008. – 264 с.

## СЕМАНТИКА ЦВЕТОВЫХ ПРИЛАГАТЕЛЬНЫХ В ТАТАРСКИХ ПОСЛОВИЦАХ

*Мугтасимова З., КФУ, магистрант II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Сибгаева Ф.Р.*

В лексико-семантической системе татарского языка выделяется достаточно компактная группа наименований цвета, относящаяся к наиболее древним атрибутивным словам. Вырабатываемые языковым

сознанием, они принимают активное участие в репрезентации окружающей действительности, одновременно характеризуя особенности мировосприятия и лингвокреативного мышления татарского народа.

Статья посвящена исследованию пословиц татарского языка с компонентами цветообозначений. В работе выявляется специфика и закономерности употребления цветовых слов в контексте пословиц, анализируются семантические особенности цветовых прилагательных.

Пословицы – ценнейший источник сведений о культуре и менталитете народа. Большинство пословиц отражает стереотипы народного сознания. Являясь сжатыми по своей форме, пословицы представляют не только систему морально-этических норм, но и заключают в себе сумму знаний о внешнем порядке вещей и внутреннем мире человека.

При анализе слов в фольклорных текстах следует учитывать особенности лексической коннотации, а именно то,что вообще свойственно слову и за пределами народного творчества, а также «ассоциативный тезаурус», обусловленный всей системой фольклорного мира и его языка.

Прилагательное «кара», выражающее черный цвет, в татарском языке является полисемантическим. Основными семантическими признаками являются негативные: злой, страшный, тяжелый, мрачный, жестокий и т.д., и порой сложно определить, которые из них являются доминирующими.

Прилагательное «кара» может иметь смысловой оттенок «злой, злостный». В этом значении мы можем встретить следующие паремии: *Йөзе ак дип алданма, эче кара булмасын.*

В паремиях, характеризующих индивидуальные свойства человека, черный цвет используется для передачи негативной коннотации: *Су һәр нәрсәне агарта, йөз карасын агарта алмый; Казан карасы китәр, намус карасы китмәс.*

В татарских пословицах при описании женской красоты прилагательное «кара» употребляется в положительной коннотации: *Кара кызның дәрте бар; Кашы кара, күзе кара, карасам күзем кала; Ак матур – чак матур, Кара матур – бик матур.*

Как и в других жанрах устного народного творчества прилагательное «кара» является постоянным эпитетом к существительному «җир»: *Кара җирне яманлама, керә торган җиреңдер; Җир кара да, үлән үстерә, кар ак та, эт чылата; Кара җиргә кар яуса, карны күрү бер зәвык; Кара җирдән кар китсә, җирне күрү бер зәвык.* Таким образом, мы видим, что по отношению к слову

«җир» функция прилагательного «кара» является, скорее, качественной, нежели цветовой его определяющей.

Прилагательное «кара» в татарском языке символизирует народ и реализует значение «простой, незнатный», которое часто употребляется по отношению к простому, неименитому человеку. Анализ исследуемого материала показывает, что «кара» с семантикой «простой, незнатный» в дальнейшем приобретает значение «необразованный, непросвещенный, неграмотный»: *Кара халык – кара сарык.*

Прилагательное «кара» обозначает масти животных и птиц: *Итче ак сарыкны да, кара сарыкны да суя; Кара җир астында кара елан да туйган.*

Белый цвет используется в пословицах, характеризующих индивидуальные свойства человека, для передачи положительной коннотации: *Кулы ачыкның йөзе ак; Кулың пакъ булса, йөзең ак булыр; Сүзе акның йөзе ак; Ак сөйгәнне, хак сөйгән.*

Несмотря на то что красный цвет не столь распространен в быту и окружающем среде человека, как белый и черный цвета, он достаточно широко используется в пословицах татарского языка. Но в количественном отношении паремиологические единицы с компонентом «кызыл» уступают пословицам, содержащим белый и черный цвета.

В своем прямом номинативном значении ‘красный цвет’ слово «кызыл» отражает цветовой признак предметов объективной реальности: *Чулманның төбе чалчык, ярлары кызыл балчык; Кызыл яулык кызга килешә; Кыланган кызыл кияр, яранган яшел кияр.*

В составе рассматриваемых паремиологических единиц лексема «кызыл» выражает красный цвет языка, непрерывно мелькающего во рту говорящего. В переносном же смысле он связан с красноречием, остроумием, пустословием и фразерством, а также с таким индивидуальным качеством личности как болтливость и красноречие. Именно эти обстоятельства отражены в татарских паремиях: *Кыз авызында кызыл тел; Һөнәр алды – кызыл тел; Кызыл телемне тыялмадым, кызымның өенә керә алмадым.*

Результаты исследования показывают, что возникновение многих переносных значений слов-цветообозначений обусловлено определенной цветовой символикой. Так, в татарских пословицах символика черного цвета неоднозначна. Здесь черный цвет не является абсолютным олицетворением негативного, как, например, в европейских культурах, а содержит более сложную смысловую нагрузку.

Белый цвет олицетворяет божественное начало, чистоту, мудрость, святость, поэтому большинство переносных значений прилагательного «ак» имеют положительную коннотацию.

В семантической структуре слова «кызыл» выделяются значения, выражающие положительную коннотацию, обусловленные символикой красного цвета: красноречие, остроумие.

**Литература**

1. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Өч томда. Казан: Татар. кит. нәшр., Т.1. —1959. — 913 б.; Т.2. 1963. — 959 б.; Т.3. 1967. — 1013 б.

# МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР НӘТИҖӘСЕ БУЛАРАК ТЕЛДӘ АЛЫНМА ЛЕКСИКА БАРЛЫККА КИЛҮ

*Насыйбуллина К., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*

Күпмилләтле Россиядә яшәүче халыклар арасында гасырлар дәвамында барган мәдәни һәм телара багланышлар барлык телләрдә дә чагылыш тапкан. Аларның үзара тәэсир итешүләренең иң борынгы күрсәткече – бер телдән икенчесенә лексик берәмлекләр үтеп керү. Әлеге процесс, билгеле булганча, төрле тарихи чорларда төрлечә барган. Мәдәниятара багланышлар шул рәвешчә телара мөнәсәбәтләрдә үз эзен калдырган. Бу күренешләрне анализлау тел һәм мәдәниятнең җәмгыять яшәеше белән тыгыз элемтәсен күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Мәгълүм булганча тел – милләтнең иң көчле күрсәткече. Ул милли мәдәният, милли аң формалашуда һәм аның үсешендә мөһим урыннарның берсен били. Шунлыктан, иҗтимагый күренеш буларак тел җәмгыять тормышында барган сәяси, икътисади, мәдәни һәм башка үзгәрешләрдән читтә кала алмый. Ә бу үзгәрешләр үз чиратында телнең сүзлек составында ачык чагылыш таба.

Гаять зур киңлекләргә таралып гомер итүче төркиләр элек һәм хәзер янәшәдәге күрше булып торган халыклар белән үзара төрле элемтәләргә кергәннәр. Төрки халыкларның башка халыклар белән багланышларын ачыклау фәнни-гамәли яктан ике як тел өчен дә бик мөһим. Бу нисбәттән төрки халыклар аеруча үзенчәлекле шартларда яшәгән: нигездә алар тугандаш халыклар белән генә аралашканнар, Европада яшәүче башка халыклар белән аларның турыдан-туры контактлары булмаган диярлек.

Төрки телләрнең дөньядагы башка телләр белән багланышларын гомуми рәвештә карарга кирәк. Фәндә моңа кагылышлы шактый материал тупланган. Төркиләрнең чит телле халыклар белән багланышларга керүе, беренче чиратта, лексикада – төрки телләрнең башка телләрдән сүзләр алуында һәм төрки сүзләрнең чит телләргә үтеп керүендә чагылыш таба.

Мәгълүм булганча төрки телләр лексикасында охшаш лексик элементлар бик күп: исемнәрдә – кеше һәм хайваннарның тән төзелешенә караган кайбер сүзләр, күк җисемнәре атамалары, төп табигать күренешләре һ.б.; алмашлыкларда – зат һәм күрсәтү алмашлыклары, кайбер сорау алмашлыклары; гади саннар – берәмлекләр, кайбер дистәләр, йөзләр, меңнәр; сыйфатларда – төп төсләрне, сыйфатларны һәм билгеләрне белдерә торган сүзләр; фигыльләрдә – төп хәрәкәтләрне һәм торышны белдерә торган сүзләр, хис белән кабул итүне атый торган берәмлекләр һ.б.

Төрки телләрдәге охшаш лексика әлеге сүзләрнең бер баба телдән килү нәтиҗәсе булмаска да мөмкин. Аларның шактые төрле төрки телләрнең күрше өлкәләр белән тарихи бәйләнешләр нигезендә барлыкка килүе дә ихтимал.

Дөньяда сүзлек составы үз сүзләре белән генә чикләнгән бер генә тел дә юк [1: 139]. Һәрбер телнең лексикасында тел багланышлары нәтиҗәсендә үтеп кергән чит сүзләр аз түгел. Башка халыклар белән бәйләнешкә кергәндә телгә алынмалар үтеп керү – теләсә кайсы халык тормышында котылгысыз күренеш. Тел багланышлары нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр барлык телләр тарихында да булган һәм булачак. Гасырлар буена тирә-юнь тәэсиренә бирешмичә, күршеләрдән тулысынча аерымланган хәлдә яшәгән телләрнең әле тарихта булганы юк. Теләсә кайсы телдә төрле кардәш һәм кардәш булмаган телләр һәм диалектлар катнашуыннан эзләр кала.

Шул рәвешчә, чит телләрдән сүзләр алу – телләр үсешендә табигый һәм зарури процесс. Алынмалар телне баеталар һәм, гадәттә, аның башка телләрдән аерылып торган төп үзенчәлекләренә зыян салмыйлар, чөнки телнең үз сүзлек байлыгы саклана, грамматик төзелеше үзгәрми, телнең эчке үсеш закончалыклары бозылмый.

Нигездә, чит телләрдән матди мәдәният предметларын (техника, кием-салым, җиһазлар, аш-су һ.б.) белдергән аерым сүзләр үтеп керә. Алынмаларның телдә ныгып калуы аларның кеше тормышындагы роле, халыкның үзаңы, җәмгыятьтәге иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр һ.б. белән бәйле була. Шунлыктан телнең лексик катламында алынмаларның күләме һәм чыганагы төрле дәвердә төрлечә була. Шулай ук төрле чорларда чит тел берәмлекләренең лексик-семантик төркемнәргә нисбәте дә аерыла.

Билгеләп үтелгәнчә, кайсы гына телне алсак та, ул даими рәвештә үсеп-үзгәреп тора. Алынмалар һәм аларның лексик берәмлекләрдәге роле турында күпсанлы хезмәтләр булуга карамастан, телдә һәрвакыт ниндидер яңалык булып тора, архаизмнар телдән югала, ә аларга алмашка килгән яңа сүзләр тел составында үз урыннарын таба.

Шулай итеп, тел һәрвакыт хәрәкәттә яши, аның үсеше халык тарихы һәм мәдәнияте белән тыгыз бәйләнгән. Һәр буын кешеләр, һәр чор үзе белән иҗтимагый тормышка гына түгел, телгә дә ниндидер яңалык алып килә. Әнә шул яңалык телнең лексикасында чагыла да инде.

Үзгәрешләр телдә, аның яшәешенең барлык чорларында даими булып торганнар. Болар барысы да тел яшәешенең ачык һәм чуар, әмма закончалыклы һәм аңлаешлы, динамик һәм интенсив процесслар белән бара торган картинасын чагылдыралар.

**Литература**

1. Реформатский А.А. Ведение в языковедение: Учебник для вузов / А.А. Реформатский; Под ред. В.А. Виноградова. – 5-е изд., испр. – М.: Аспект Пресс, 2004. – 536 с.

2. Жилкубаева А.Ш. Лексика питания в тюркских языках (лингвокультурологический аспект). Научная монография. – Усть-Каменогорск: Издательство ВКГУ им. С.Аманжолова, 2012. – 204 с. – URL: https://docplayer.ru/58348905-A-sh-zhilkubaeva-leksika-pitaniya-v-tyurkskih-yazykah-lingvokulturologicheskiy-aspekt.html (дата обращения: 07.01.2021).

3. Тарасова Ф.Х. Паремии с компонентом «пища» в татарском, русском и английском языках: лингвокультурологический и когнитивно-прагматический аспекты: монография. – Казань: РИЦ, 2012. – 304 с.

4. Җамалетдинов Р.Р., Нурмөхәммәтова Р.С. Тел белеме нигезләре. – Казан: Ихлас, 2014. – 240 б.

## ТЕМАТИЧЕСКИЕ ГРУППЫ ТЮРКИЗМОВ
## (на материале произведений Н.С. Лескова)

*Нуэрбатиси Б., КФУ, магистрант II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Исламова Э.А.*

В любом языке мира есть заимствованные слова. Как известно, в русском языке выделяется довольно значительный пласт заимствований тюркского происхождения.

Тюркизмы исследовались в работах Н.А. Баскакова, Г.Я. Романовой, Г.Р. Муратовой, К.Р. Бабаева, Р.З. Киясбейли, Б.Б. Джапаровой, Р.А. Юналеевой, К.Р. Галиуллина и других лингвистов. Одним из богатейших источников последних десятилетий является издание «Тюркизмы в русской литературе» Р.А. Юналеевой (2005) – словарь с текстовыми иллюстрациями, составленный на материале произведений восемнадцати русских классиков XIX столетия.

В ходе нашего исследования мы сделали выборку тюркизмов из произведений Н.С. Лескова и распределили их по следующим тематическим группам.

1. Названия построек, сооружений, помещений: *амбар, амбаришка, амбарушка, амбарчик, амбарный, башенка, башня, караульня, каланча, сарай, чулан, шатёр, юрта.*

2. Наименования орудий труда, инструментов: *бурав.*

3. Названия сосудов и емкостей: *артель, бадейка, бадья, казан, казанок, ковш, корчага, лохань, стакан, таз.*

4. Названия одежды и деталей одежды: *азям, азямчик, архалук, армяк, бахилы, башмак, бешмет, бурка, бурнус, епанча, ермолка, зипун, каблук, казакин, кафтан, халат, чекмень, чепан, шаровары.*

5. Названия драгоценных камней и т.п.: *алмаз, бирюза.*

6. Наименования тканей, материалов: *атлас, атласный, бархат, кумач, миткаль, тафта.*

7. Наименования пищи: *балык, балычок, баранина, изюм, калач, калачик, рахат-лукум.*

8. Названия напитков: *вишневка, калгановка, кумыс.*

9. Названия предметов оружия, воинских доспехов: *булат, кистень, темляк.*

10. Наименования музыкальных инструментов: *балалайка, барабан, дудка, накры.*

11. Административно-экономические термины: *барыш, деньги, деньжата, деньжонки, товар, тюрьма, ярлык.*

12. Наименования денежных единиц: *алтын, пятиалтынник, пятиалтынный.*

13. Наименования людей по роду деятельности, по должности и т.д.: *атаман, барабанщик, богатырь, боярин, казначей, караульщик, мулла, султан, товарищ, толмач, хан.*

14. Названия частей тела: *кадык, туша.*

15. Цветообозначения: *алый, аленький, буланый, бирюзовый, бурый, вишневый, изумрудный, карий, кармазинный, лазурь, шафран.*

16. Названия явлений природы и географических понятий: *балка, буерак, буран, туман, яр.*

17. Названия представителей животного мира: *аргамак, баран, баранчик, барашек, бык, вол, газель, кобыла, кабан, лошадь, обезьяна.*

18. Названия растений: *арбуз, кавун, камыш, вишня, вишенка, кишмиш, ревень, хмель.*

Исследованная нами лексика очень разнообразна. Традиционно тюркизмы представлены в большинстве своем бытовой лексикой, однако представлены также и наименования людей по роду деятельности, по должности, административно-экономические термины, названия представителей животного и растительного мира и др.

Подробнее остановимся на названиях одежды и ее деталей. В этой тематической группе зафиксировано очень большое количество устаревших слов. Приведем их определения по словарю Р.А. Юналеевой «Тюркизмы в русской классике».

*Армяк – «Крестьянская верхняя одежда из толстого сукна в виде кафтана»* [2: 469].

*Бахилы – «Разного вида обувь: кожаная или плетеная из бересты (в виде сапожек), охотничьи сапоги вроде толстого чулка»* [2: 473].

*Бурнус – «Род женской верхней одежды»* [2: 477].

*Епанча – «Старинная верхняя одежда в виде широкого длинного плаща»* [2: 481].

*Зипун – «Старинная верхняя крестьянская одежда в виде кафтана без воротника, обычно из грубого самодельного сукна»* [2: 482].

*Казакин – «Старинное мужское верхнее платье в виде короткого кафтана на крючках, со сборками сзади»* [2: 484].

*Кафтан – «Старинная долгополая мужская одежда, обычно из сукна»* [2: 488].

*Чекмень – «Верхняя с длинными полами одежда у казаков; крестьянский кафтан»* [2:513].

*Чепан – «Крестьянский верхний кафтан»* [2: 513].

*Шаровары – «Широкие штаны особого покроя, обычно заправляемые в сапоги»* [2: 516].

Таким образом, произведения Н.С. Лескова содержат интересный и разнообразный материал для исследования тюркизмов.

**Литература**

1. Лесков Н. С. Собрание сочинений в 3 томах. – М.: Художественная литература, 1988.

2. Юналеева Р.А. Тюркизмы в русской классике: словарь с текстовыми иллюстрациями / науч. ред. К.Р. Галиуллин. – Казань: Таглимат, 2005. – 752 с.

## ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ «АНТ/ВӘГЪДӘ» ТӨШЕНЧӘСЕНЕҢ ВАРИАНТЛАРЫ ҺӘМ КУЛЛАНУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Рахматуллина Ф., КФУ, 2 курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нәбиуллина Г.Ә.*

Татар һәм төрек телләре лексик-семантик яктан охшаш. Әлеге охшашлыкны без «ант/вәгъдә» сүзләренең тотрыклы сүзтезмәләрдә, мәкаль-әйтемнәрдә кулланылган төрле вариантларын чагыштыру методын кулланып тикшергәндә күзәтә алабыз. Бер үк сүз ике телдә дә кулланылып, төрле семага ия була ала. Бу халыкның менталитеты һәм

яшәү рәвешенә бәйле. Төрек халкының әлеге сүзләргә булган мөнәсәбәтен ачыклау максатыннан, интернетта сораштыру үткәрелде.

Төрек телендә булган «ант/вәгъдә» сүзләренең вариантларыннан куллану ешлыгы ачыкланды, бу сүзгә карата булган мөнәсәбәтләре күрсәтелде. Электрон этимологик сүзлек нәтиҗәләреннән чыгып, алдагы сүзләр «ант, вәгъдә» («Yemın») төшенчәләре белән уртак семалары булуын ачыкладык:

*Yemın (йәмин):* «Yemin» сүзе гарәп телендәге «ymn» тамырыннан килеп чыккан. Уң кул яки уң кулны күтәреп әйтелгән ант дигәнне аңлата. (Өстәп: әлеге сүз арамей, сирия, иврит телләрендәге «yamīn» сүзләренә ошаган).

*Ahit (ахит):* Гарәп телендәге ahd (عهد) тамырыннан килеп чыккан. Йөкләмә (обязательство), ант, вәгъдә мәгънәсен белдерә. Мондый фигыльләр белән бергә йөри: тану, үз өстеңә алу, кабул итү.

*Eyvallah (әйваллаh):* Татар телендә куллангылышта йөргән «валлаhи» сүзенең төрек телендә кулланыла торган варианты. «Әйе + ант итәм» сүзләре кушылып – «әйе, сүзем ант»лы мәгънәсен ала.

*Istisna (истисна):* Төрек телендә бу сүзнең «искәрмә» дигән мәгънәсе бик киң таралган. Төрек теленең этимологик сүзлеге әлеге сүзне «Yemın» сүзенә семантик яктан бәйле дип күрсәтә. Бу сүзнең икенче мәгънәсе дә бар: килешүне юридик яктан таркату өчен барлыкка китерелгән шарт. Шулай ук гарәп теленнән кергән.

*Kasem (касем):* Гарәп телендәге «ḳasam» сүзе «ḳsm» тамырыннан килеп чыккан. Ике мәгънәсе билгеле: 1) бүленеш, үлчәм, билгеләмәнең атамасы; 2) ант - «yemin, ant» сүзләренә синоним буларак кулланыла.

*Meymenet (мәймәнәт):* Бу сүз шулай ук гарәп телендәге «ymn» тамырыннан килеп чыккан. «Уңыш» дигәнне аңлата; «уң кул» сүзтезмәсе белән бәйлелеге дә бар (тамырлары охшаш).

*Muahede (муаhәдә):* Гарәп телендәге muāhadat сүзеннән килеп чыккан. «Уртак сүзгә килү, килешү, сүз бирешү, сүз беркетү»не аңлата. Бу сүз шулай ук җаваплылык алу, ант итү, вәгъдә бирүне күзаллый.

*Şehadet (шәhадәт):* Татар телендә дә әлеге сүз кулланыла. *Шаhәдәт* – шаhитлык, гуаhлык (тану), таныk булу. - Карт берничә тапкыр шаhәдәт кәлимәсен әйтте дә, нәрсәгәдер бик нык сөенгәндәй, елмаеп куйды. (Ф.Бәйрәмова) *Шаhәдәт бармагы* – баш бармак янындагы бармак, имән бармак. - ...англичан адмиралы Уокерның 3 шаhәдәт бармагына карап, аның...(Г.Исхакый) *Шаhәдәт бирү* – гуаh (шаhит, таныk) булу, шаhит булу, раслау. – Кайбер мәсьәләләр буенча, мәсәлән, шаhәдәт бирү (шаhит булу, раслау) һәм мирас итеп калдыру мәсьәләләре буенча, Әбу Йосыфтан сылтама алып фәтва чыгарырга

була. (Татарстан Республикасы Мөселманнарының Диния Нәзарәте") Төрек телендә дә, татар телендә дә кулланылган әлеге сүз гарәп теленнән кергән. 1) күрсәтмә, җавап (показания); 2) шаһит (свидетель). «Судта шаһит булу» кебек контекстларда кулланыла.

*Peyman (пейман):* Фарсы теленнән кергән paymān сүзе: 1) үлчәм, шкала; 2) аек акыл белән уйланган эш, сүзеңдә тору, ант. Борынгы фарсы теленнән килгән сүз – «күзгә-күз карап» дигән мәгънәне белдергән.

Әлеге сүзләр белән төрек телендә мәкаль-әйтемнәр дә шактый. Vaat – вәгъдә сүзе белән: *Bu vaatlere karnım tok.* – Бу вәгъдәләрең белән тамагым тук. Yemin – ант.*Yemin etsem başım ağrımaz.* – Ант итсәм, башым авырмас. Anlaşma – сөйләшү, килешү, аңлашу. *İnsanlar konuşa konuşa, hayvalar koklaşa koklaşa anlaşır.* – Кешеләр сөйләшә-сөйләшә, хайваннар ис иснәп бер-берсен танырлар. Anlaşma – договор.

Сораштыруда Измир, Истанбул, Анкара, Измит, Денизли шәһәрләрендә яшәүче дистәдән артык 18 дән 31 яшенә чаклы ир-ат һәм хатын-кызлар катнашты. Нәтиҗәдә, иң актив сүзтезмә буларак - *«yemin ederim», «söz veriyorum»,«söz veririm»,* шулай ук *«Yemin», «söz», «anlaştık», «valla, vallaha, vallahi, valla billa (vallahi billahi)»,* кебек сүзләр кулланылуы ачыкланды. Искергән сүзләр - istisna, kasem, meymenet, muahede, velfajri , peyman. Измит шәһәрендә *«İstisna»* вариантын да кулланырга мөмкиннәр, тик калган сүзләрне бу шәһәрдә яшәүче яшьләр, искергән сүзләр төркеменә кертеп карыйлар. Истанбул шәһәрендә «*İstisna»* сүзен безгә кирәкле мәгънәдә кулланмыйлар, әлеге сүз «искәрмә» буларак бик актив. «*Vallahi»* сүзенең аеруча күп кулланылуын Анкарада яшәүче искәртеп үтә. «Muahede» – «antlaşma» (*«договора»)* сүзенең иске варианты булып килә. Шулай ук актив. «Velfeçri» гади сөйләмдә актив түгел, ләкин Коръәндә күп очрый.

Төрек халкы сүз бирсә, нәрсәдер вәгъдә итсә, аны җиренә җиткереп эшләргә тырыша. Әгәр дә көченнән килми икән, аның бөтен гаиләсе һәм якыннары арасында дәрәҗәсе төшә, ышаныч кими. Сорашуда катнашучылар уйлавынча – һәр милләтнең сүзендә торучылары да, кире кайтучылары була дигән фикер әйтелә.

**Әдәбият**


1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 6 томда. – Тулыл. һәм төзәт. 2 нче басма. – Татар. кит. нәшр., 2020.
3. Төрек теленең электрон этимологик сүзлеге – https://www.etimolojiturkce.com/
4. Төрек теленең электрон аңлатмалы сүзлеге – https://sozluk.gov.tr/


## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР МАТБУГАТЫНДА ПРЕЦЕДЕНТ ИСЕМНӘРНЕ ТӨРКЕМЛӘҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

*Рахимова А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Галиуллина Г.Р.*

«Прецедент» төшенчәсе шактый өйрәнелгән өлкә. Терминны Ю.Н. Караулов керткән. Ул элек булган хәлләргә нигезләп һәм дәлилләп һәм кеше ышандырырлык итеп бирелгән гыйбарә, сүз дигәнне аңлата. Кызганычка каршы, әлеге төшенчә татар тел белемендә өйрәнелмәгән диярлек. Әмма шуңа карамастан ул шактый кулланыла. Мәсәлән, матбугат, реклама текстларында.

Прецедент исемнәрнең тематик төркемнәрен ачыклаганда аларны чыганаклары ягыннан тикшерергә булдык. Әлеге эшне башкару өчен «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан», «Татарстан яшьләре», «Безнең гәҗит» газеталарына, «Безнең мирас», «Сәхнә» журналларына, «Матбугат.Ру», «Татар-информ» сайтына мөрәҗәгать иттек.

Хәзерге этапта прецедентларның чыганаклары буларак түбәндәге төркем онимнарны бүлеп бирәләр: 1) антропонимнар; 2) топонимнар; 3) сәнгать яки башка әсәрләрнең исемнәре; 4) хрононимнар; 5) бизнес объектлары исемнәре; 6) кораблар исемнәре; 7) хайваннар кушаматлары [1: 85-99].

Без тапкан прецедент исемнәрне чыганаклары ягыннан түбәндәге төркемләргә бүлдек:

- Прецедент исемнәрнең чыганаклары буларак әдәбият. Әлеге чыганакларны кулланган язмалар рәсем, әдәбият, музыка, кино, ягъни сәнгать һәм философия өлкәсенә карыйлар. Әмма араларында криминаль хроника, дөнья хәбәрләре, төрле вакыйгалардан репортажларда да очрарга мөмкин. Мәсәлән: *Тол хатыннар арасында шактый абруйга ия* ***Дон Жуан*** *Наталья Зиннурова янына барып керә* (Вахитов Н. Ютазының явыз кызы // Безнең гәҗит. – 2018. – 7 март). Хатын-кызларны артык яратучы кешеләрне шулай атыйлар, Мольер әсәре герое.

*Кремльдәге бүгенге көн* ***маниловлары*** *барып чыкмаячак, баштан ук печелгән модернизация йөген, чыгымнарын да халыкка аударып куймагайлары* (Шәрифуллин Н. «Печелгән проект» яки Бүгенге Маниловлар // Ватаным Татарстан. – 2016. – 10 сент.). Манилов – Н. Гоголь герое, алпавыт. Биләмәсендә биек манара корып, шунда чәй эчә-эчә Мәскәүне (мең чакрым ераклыктагы) манзара кылырга хыялланган. («Үле җаннар» әсәреннән).

- Прецедент исемнәрнең чыганаклары буларак антик әдәбият һәм мифология: *Без барыбыз да –* ***Одиссейлар (****Янсуар Л. Кичәге «Калеб»тән ФОТОрепортаж // http://matbugat.ru/news/search/?keyword= (Мөрәҗәгать итү вакыты: 18.04.2018). Одиссей – борынгы грек

мифологиясе персонажы, акыллы һәм хәйләкәрлеге белән аерылып тора. Әлеге сүзләр еш кына әдәбиятчылар белән интервьюларда, әдәби чаралардан репотажларда очрый.

- Прецедент исемнәрнең чыганаклары буларак дин: *Алар морзаны **Христос** нуры белән нурлаганнар* (Баттал Ф. Тәхетле җәллад // Безнең мирас. – 2016. – №12). Әлеге эпитет бөек җан дигәнне аңлата.

- Прецедент исемнәрнең чыганаклары буларак халык иҗаты: *Бу кощейлар дөньясы җиңмәсен өчен кирәк, иң мөһиме – үзеңне белән алган **кощейны** юк итү өчен өчен,–дип чакыра Сергей Безруков.* (“Татар-информ” мәгълүмат агентлыгы. // Источник: http://tat.tatar-inform.ru/(Мөрәҗәгать итү вакыты: 26.01.2021)).

- Прецедент исемнәрнең чыганаклары буларак кинофильмнар: *Әле Рөстәм үзенең кем буласын да аңлап бетерә алмый. **Джеймс Бонд** булырга да тели, шаярта да. Байбулат та шаярырга тели, ләкин булып чыкмый. Байбулат кайгырса да, Рөстәм аңа кайгырып тормый* (Кыямова М. Байбулат Батулла: Көлә-көлә Мәскәүгә барыр идем! // http://matbugat.ru/news/?id=7756 (Мөрәҗәгать итү вакыты: 15.04.2018).

- Прецедент исемнәрнең чыганаклары буларак иҗтимагый-сәяси вакыйгалар, тарихи шәхесләр: *Даһилар әз йоклаган диләр бит, **Наполеон** да дүрт кенә сәгать йоклаган* (Шиһапов И. Айгөл Хәйруллина Наполеоннан калышмый // Шәһри Казан. – 2016. – 15 гыйнв.).

*Ил башлыкларының үлемнәрен дә йә кырык көн, йә җиде көн алдан күрдем. **Л.Брежнев** – ерак сәфәргә җыенып**, Б.Ельцин**: «Урыным шул», – дип, исерек килеш сазда аунап төшемә кергән иде. Озак тормый дөньялыктан китеп бардылар. **Сталин**-тиранның төше дә хәерсез икән: авылның бер урамында шинелен киеп йөргән иде, шул урамда янгын чыгып, терeләй янып үлүче булды, тора-бара бу урамда яшәүче бетте, буш йортлар гына утырып калды. **Ленин** бабайны, ни хикмәт, төшемдә бер дә күрмәдем. Җәсәде күмелмәгәнгә, бәлки, җаны күк белән җир арасында тилмереп йөридер...* (Әхмәтов Р. Төшемә үләсе һәм үлгән кешеләр еш керә // Татарстан яшьләре. – 2018. – 14 февр.).

- Прецедент исемнәрнең чыганаклары буларак географик объектлар тора: *Әмма мин **Африкага** китмәдем, үз Ватанымда калдым бит* (Гарифуллина Ч. Нәфисә Хәйруллинаны Алексей Воробьевка һәм Эмиль Талиповка «кияүгә» бирделәр. Ә чынлыкта... // Ватаным Татарстан. – 2018. – 30 март).

Шулай итеп, татар матбугатында прецедент исемнәрнең чыганаклары буларак әдәбият, антик әдәбият һәм мифология, дини шәхесләр, халык иҗаты, кинофильм геройлары, иҗтимагый-сәяси вакыйгалар, тарихи шәхесләр исемнәре кергән төркемнәргә бүленә.

**Әдәбият**

1. Нахимова Е.А. Прецедентные онимы в современной российской массовой коммуникации: теория и методика когнитивно-дискурсивного исследования. – Екатеринбург: ГОУ ВПО «Урал.гос. пед. ун-т», 2011. – 276 с.

## “КӨМЕШ КЫҢГЫРАУ” ГАЗЕТАСЫНДА ҺӘМ “ЯЛКЫН” ЖУРНАЛЫНДА КЕШЕ ШӘХЕСЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ АТАМАЛАР

*Сабирова Н., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Нуриева Ф. Ш.*

Без мәгълүмат мәйданы искиткеч зур һәм бай булган заманда яшибез. Елның-елында әлеге мәйданда берсеннән берсе яңа газеталар һәм журналлар, электрон мәгълүмат чаралары: аудио, видео язмалар пәйда булып тора. Бу шулай ук кече яшьтә укучылар өчен язылган матбугатка да карый.

Матбугат теле, әдәби телнең аерым бер кулланылыш шәкелләреннән булган публицистика стиленә карый. Әдәби тел – телнең үз нормаларына салынып эшкәртелгән кулланышы.

Функциональ-стилистик күзлектән чыгып караганда, үзенең күпкырлы максат-бурычларына бәйле рәвештә, публицистик стиль иң катлаулы стильләрдән санала [Гомуммилли телнең яшәеш формасы буларак әдәби тел һәм аның функциональ стильләре // Фәнни Татарстан. – 2017. –№2].

Матбугать битләрендә кеше эшчәнлеге белән бәйле атамалар зур урынны алып тора. Сәбәбе – кешенең дөньядагы тоткан урынын күрсәтү белән бәйле булу. Хезмәт әлеге юнәлештә башкарылды. Анализ ясау өчен без кече яшьтәге укучылар өчен язылган “Көмеш Кыңгырау” газетасына һәм “Ялкын” журналы материалларына мөрәҗәгать иттек, андагы мәкаләләрдә урын алган лексик берәмлекләргә күзәтү ясадык.

*Исегездәме, моннан берничә ел элек федераль каналдан барган «Голос» проектында* ***Сәйдә Мөхәммәтҗанова*** *татар җыры башкарып безнең күңелләрне һәм тамашачы мәхәббәтен яулаган иде* [“Татар җыры белән җиңеп була” // Көмеш кыңгырау– 2020. –14 май]. Әлеге мисалда безнең исем + фамилия кулланылып килгән. Еш очракта авторлар үзләренең язмаларында иҗат белән бәйле шәхесләрне әлеге конструкция аша бирәләр.

*Фильмда* ***Җәмил ролен Уфа малае Арслан Крымчурин, Оксана ролен Мәскәү кызы,*** *инде танылып өлгергән* ***актриса Марта Тимофеева*** *башкара.* «Сеңелкәш» фильмының яшь актерлары белән танышабыз [“Сеңелкәш фильмы” // Көмеш кыңгырау– 2020. –14 май]. Әлеге мисалда без шәхес атамасын да, кешеләрнең профессиясен ачыклаучы атамаларны да күрәбез. Танылган кеше булуларына

карамастан, иҗат белән бәйле эш булганлыктан китерелгән мисалда да исем + фамилия кулланылып килгән.

*«Россия» каналыннан барган «Зөләйха күзләрен ача» фильмында Зөләйханың улы Йосыф ролендә безнең Казан егете, 171нче мәктәпнең 4нче сыйныф укучысы Исмәгыйль Низамиев та уйный* [“Йосыф булу – җиңел түгел” // Көмеш кыңгырау– 2020. –21 апрель]. Алдагы мисалда шәхес атамасының ике төрле кулланылу очрагы бар. Беренчесе – кешене исеме белән атау, бу очракта тарих аша безгә билгеле шәхесләр булса, икенчесе – исем фамилиясе кулланылган очрак, бу иҗат белән бәйле рәвештә килә. Шулай ук туганлык атамалары булган сүзне дә күрәбез: ул. Кешенең җәмгыятьтәге статусы – укучы. Яше ягыннан үзенчәлеген ачкан мисал – егет.

*Г.Тукайның әкиятләрен уку, алар буенча театраль өзекләр күрсәтү, әти-әниләре белән бергә мультфильмнар карау балалар күңеленә бик якын килде* [Габдулла Тукай әкиятләренә багышланган «Башваткыч» уены // Көмеш кыңгырау– 2020. –21 апрель]. Әлеге мисалда татар укучысы өчен билгеле шәхес Габдулла Тукай китерелгән. Язучы буларак аның исемен тулысынча язмыйча, баш хәрефен генә куеп нокта куйсалар, фамилиясе тулысынча язылган.

*Мондый идеяне Казанның мәктәп укучысы Алия Минһаҗи тормышка ашырган. Абыйсы да ярдәмгә килгән аңа. Озак та үтми абыйлы-сеңелле Минһаҗилар бу эшкә керешкән. Шунысын да әйтеп узыйк: Айзат Төркиянең Инстанбул шәһәрендәге Мимар Синан Гүзәл Сәнгатьләр Университетының сәнгать тарихы бүлегендә 3нче курсында укый. Алия Казанның 4нче гимназия-интернатының 10нчы сыйныфын тәмамлый* [http://yalkyn.ru/news/bu-tema/sogy-kygyrau-kichsen-shigyrblr-kotlaular]. Әлеге мисалда шәхес атамалары күп яктан ачылган: а) туганлык атамалары – абыйсы – 2 нче зат тартым белән кулланылган, абыйлы-сеңелле – җенесе ягыннан аера, шулай ук парлы туганлык атамсы; ә) җәмгыятьтәге статусын күрсәтүче – укучы; б) атаманы исеме һәм фамилиясе белән – Алия Минһаҗи, исемен генә – Алия, Айзат, фамилиясе – Минһаҗилар.

*Кадерле, балалар! Әле башланып кына килүче олы тормыш юлында сезгә уңышлар телим! Шуны онытмагыз: укытучыларыгыз сезне ярата, сагына һәм көтә! Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Р.Т. Борһанов* [http://yalkyn.ru/news/belmi-kalma/rafis-boranovny-uku-ely-tmamlanu-uaennan-kotlavy]. Әлеге мисалда да шактый гына шәхесне атаучы сүзләр кулланылышка кергән, төрле бүленешне күрсәтәләр: а) яшь ягыннан үзенчәлек – балалар,

профессиясе ягыннан – укытучыларыгыз, министр, шәхеснең фамилиясе генә кулланылган очрак – Борһанов.

*Әмма моңа кадәр Тәслимә, улы Илназ өйдә булган көннәрдә талымлап тормый, башын мендәргә тидерүгә үк йоклап китә. Бүген улы юклыктан шулай боргалана инде ул* [http://yalkyn.ru/news/ijat/anyny-birs-d]. Әлеге мисалда шулай ук исеме генә кулланылган, чөнки алдагы мисалдагы кебек үк телгә алынган шәхесләр бер круг эчендә генә билгеле булып торалар. Туганлык атамасы ягыннан да бүленешне күрәбез: улы.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, без шәхес атамаларының яшь укучылар өчен язылган матбугат битләрендә дә бик еш кулланылуына һәм аларның бик күп категорияләр буенча ачып бирелгәнлегенә тап булдык: яшь үзенчәлеге, җәмгыятьтәге һәм профессиясе ягыннан статусы.

**Әдәбият**

1. Б.К. Миңнуллин. Гомуммилли телнең яшәеш формасы буларак әдәби тел һәм аның функциональ стильләре. – Фәнни Татарстан, 2017.- 31 б.

2. Гафарова В.Р. Текстка грамматик анализ ясау /Уку-укыту әсбабы/ В.Р.Гафарова. – Казан: Отечество, 2016. – 85 б.

3. Низамов И.М. Уем – тел очында / И.М.Низамов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 287 б.

4. “ Җаныңны бирсәң дә...” http://yalkyn.ru/news/ijat/anyny-birs-d

## АНАЛИЗ ПОСЛОВИЦ О ЛОШАДЯХ НА ТУРЕЦКОМ И ТАТАРСКОМ ЯЗЫКАХ

*Саде Б., КФУ, магистрант II курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Мугтасимова Г.Р.*

Пословицы один из важных элементов, которые играют роль в передаче культур будущим поколениям, занимают чрезвычайно важное место почти в каждой культуре. Пословицы не только позволяют нам видеть выводы, которые сделали наши предки на основе своего жизненного опыта, и извлекать уроки из него, они также передают нам культурные накопления, которые лежат в нашем прошлом, которые мы не можем испытать лично, но которые делают нас такими, какие мы есть, и формируют наше общество.

Турецкий и татарский народ связаны прошлым и настоящим и имеют схожие культурные особенности. Одно из таких культурных схожеств – это лошади. И для турок, и для татар лошадь рассматривается как нечто большее, чем просто животное. Лошади никогда не рассматривались исключительно как средство передвижения как для турок, так и для татар. Его считали товарищем, другом, даже божественным существом. Это, конечно, очень естественное и понятное событие, что общества, которые веками

пережили войны и кочевой образ жизни, так заботятся о лошади и делают ее важной частью своей культуры. Неизбежно, что это животное, которое принимает участие во всех сферах жизни, от государственной сферы до социальной, присутствует в пословицах. Более чем в 200 пословицах на турецком языке упоминается имя лошади Трехтомник «Татар халык мәкальләре» Н. Исанбета, использованный нами в качестве источника, содержит более 600 пословиц о лошади. Остановимся на некоторых: Буласы ат тайдан билгеле; Уртак аттан тай артык; Айгыр ашкынса, ат булыр; Атның хакы олы, айгырның даны олы; Иясез атны ил алыр; Карт атын мактаган юлда калыр; Кеше түгел, дүрт аяклы ат та абына; Сынамаган атның артыннан барма; Эш аты саламда, буш ат солыда; Үз атыңны сынар өчен кеше атына утыр; Алтынияр алама атны яхшыртмас; Уңмаган ат тәртә сындыра; Арык ат симерсә, җир казып чабар; Атың арык булса, бер чап, утының аз булса, бер як; Йөгерек атка менгән тәңресен оныгыр. Приведенные пословицы являются доказательством вышесказанного. Образ лошади использовался не только для демонстрации трудолюбия, усердия, свободы, но и в пословицах, подходящих к любой жизненной ситуации.

Использование образа лошади в турецком фольклоре также имеет переносное значение. Мы решили условно разделить эти пословицы на несколько тематических групп.

1. Лошадь – символ силы, свободы: Ata arpa yiğide pilav; At, adımına göre değil, adamına göre yürür; Ata dost gibi bakmalı, düşman gibi binmeli; Ata eyer gerek, eyere er gerek; At arıklıkta, yiğit gariplikte; Atın dorusu, yiğidin delisi; At ölür meydan (nalı) kalır, yiğit ölür şan (namı) kalır и др.

2. Лошадь – символ труда: Aç (arık) at yol almaz, aç (arık) it av almaz; at beslenirken, kız istenirken; atına bakan ardına bakmaz; at yedi günde, it yediği günde (belli olur, semirir).

3. Лошадь – символ верности: At binicisini tanır (bilir); atım tepmez, itim kapmaz deme (atın tepmezi, itin kapmazı olmaz); at sahibine (ağasına, biniciye) göre eşer (kişner); bir sürçen atın başı kesilmez.

4. Лошадь – символ богатства, изобилия, благодати: Aptal ata binerse bey oldum sanır, şalgam aşa girerse yağ oldum sanır; at almadan ahır dikme; atın varken yol tanı, ağan varken el tanı.

Как мы можем понять из приведенных выше примеров пословиц, место и значение лошади в обеих культурах неоспоримы. Пословицы обычно имеют положительную коннотацию. Причина в том, что лошадь считается ценным даже священным животным в обеих культурах.

Мы видели, что на обоих языках есть бесчисленное множество пословиц о лошади, хотя иногда они используются одинаково, иногда одинаково, иногда очень по-разному.

Приведем примеры пословиц, которые звучат одинаково на обоих языках:

Arık ata kuyruğu da yüktür. = Арык атка койрыгы да йөк.

Atlar nallanırken kurbağa ayağını uzatmaz. = Ат дагалаганда бака ботын кыстырмый.

At at oluncaya kadar sahibi mat olur. = Ат ат булганчы хуҗасы мат булыр.

Canı yanan eşek atı geçer. = Җаны янган ишәк аттан йөгерек булыр.

Sen dede ben dede bu atı kim tımar ede? = Син мулла, мин мулла, атка печән кем сала?

Yumuşak huylu atın çiftesi pek yavuz olur. = Юаш атның типкесе каты булыр.

Находки примеров подобного рода свидетельствуют о том, что культуры в некоторой степени пересекались. Как видно из примеров, название лошади использовалось не только для обозначения трудолюбия, старательности, силы воли, но и подходящих к любой жизненной ситуации.

Сегодня хотя и место лошадей в нашей жизни уменьшилось по сравнению с прошлым, они по-прежнему остаются частью нашей культуры и социальной жизни. Место этого особенного животного в наших культурах останется неизменным. С помощью пословиц поколения передавали и будут передавать друг другу эти ценностные установки.

**Литература**

1. Albayrak N. Türkiye türkçesinde atasözleri. – Istanbul: Kapı yayınları, 2009. – 1140 s.

2. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Өч томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., Т.1. – 1959. – 913 б.; Т.2. 1963. – 959 б.; Т.3. 1967. – 1013 б.

3. Çobanoğlu Ö. Türk dünyası ortak atasözleri sözlüğü. – Ankara: Atatürk Kültür Merkezi Başkanlığı yayınları, 2004. – 519 s.

## ТАТАР ТЕЛЕН САКЛАУДА МИЛЛИ ЙОЛАЛАРНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

*Сәйфетдинова Д., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – пед. фән. канд., доц. Габдрахманова Р.Г.*

Халкыбыз: «Үгет-нәсыйхәт – бездән, әдәп белү үзеңнән», – дип, бик дөрес әйткән. Иң асыл рухи-әхлакый кыйммәтләр, дөрес яшәү кануннары һәм татар халкының тәрбия тәҗрибәсендә тупланган. Әнә шул изге мирасны – бәһасез кыйммәтләрне – үзләштереп, яшь кеше үзенең рухи тормышын, әдәп-әхлагын, чынбарлыкка карашын һәм

гамәлләрен уңай якка үзгәртсә, үзенең яшәү рәвеше, тормыш, итү кагыйдәләре итеп кабул итә алса, андый инсан киләчәктә үзенә дә, гаиләсенә дә, әйләнә-тирәдәгеләргә дә иманлы, бәрәкәтле яшәү үрнәкләре күрсәтә алачак. Ләкин бу  гаять катлаулы проблеманы хәл итү белән бәйле процесс.

Һәр бала үз гаиләсенең, туган җиренең тарихын белергә, шуның аша халыкка якынаерга тиеш. Һәр милләт үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган. Тормыш-көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык милләтләргә дә хас. Ул әлеге милләт мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Гореф-гадәтләр борын-борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны үз эченә ала. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә, алардан башка халык тулы кыйммәтле тормыш белән яши алмый. Кыскасы, безнең максатыбыз туган телебезне, тарихыбызны, рухи байлыкларыбызны, гореф-гадәтләребезне өйрәнеп, буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру, бөек милләт булып яшәвебезне дәвам итү. Татарстан халыкларының үзара дус, тату яшәве – бөтендөнья өчен толерантлык үрнәге булып торуын да күрсәтә. Халыклар арасында дуслык бәйләнешләрен ныгытуда бәйрәмнәрнең роле зур, чөнки алар аша халыклар бер-берсенең мәдәниятен, яшәү рәвешен, гореф-гадәте, йолаларын өйрәнә һәм шулар аша бер-берсенә хөрмәт тәрбияли, үз итә, дуслыгын ныгыта.

Бүгенге көндә милли бәйрәмнәребезне, йола, гореф-гадәтләребез яңадан торгызылып, яңартылып, заман төсмерләре биреп үткәреләбашлады. Аларны халык белә, хөрмәт итә икән милләт яши, милләт яшәгәч, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә. Безнең халкыбызда бик тирән мәгънәле бер әйтем бар: “Тел –ананың теләге, тел –ананың баласына иң кадерле бүләге”. Ана телен саклау, аны буыннан-буынга җиткерү – әниләребезне ярату-хөрмәт итү билгесе һәм аларның безгә васыяте! Бу васыятьне һәркем кабул итәргә һәр үтәргә тиеш.

Үткәне юкның – киләчәге юк, ди халык. Бу гыйбарәләр буш урында тумаган. Ул – үткәнгә хәер хаклы һәм сак мөнәсәбәт, үткән буынга олы рәхмәт хисе хакында сөйли, үткәнен белгән, узган сәхифәләргә хөрмәт белән караган, аларны кадерләгән халыкның гына киләчәге барлыгы хакында кисәтә.Милли мирас билгеле бер халыкның җәмгыять үсеше барышында туплаган бай тәҗрибәсен, гореф-гадәтләрен, әхлагын үз эченә ала.

Бүгенге көндә укытучылар алдында торган бурычларның иң мөһиме – балаларга максатлы рәвештә – үз туган телен өйрәтү, шулай ук аларны халкыбызның сәнгате, гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, йолалары, милли әдәбияты белән таныштыру.

Балаларга ана телен өйрәтүдә төп бурычларның берсе – халкыбызның әдәби байлыгына, фольклор мирасына, аның гореф гадәтләренә таяну. Үз телен яратучы, милләтен хөрмәтләүче кешене тәрбияләүне халык педагогикасына таянып эш итү зарур. Җор телле халкыбыз иҗат иткән табышмаклар, санамышлар, такмаклар, әкиятләр, бәетләр, моңлы бишек җырлары – тел өйрәнүдә иң бай чыганак.

Халык уеннары, гореф – гадәтләре, бәйрәмнәре, буыннан буынга яңарып, халыкның гасырлар буена сыналган барлык рухи хәзинәләрен үзләрендә саклап киләләр, кешенең гармонияле үсешен тәэмин итүдә табигый юнәлеш бирүче мөһим рольне үтиләр. Билгеле бер йолалар системасы оешкан җәмгыять кенә тотрыклы була, аңардан башка җәмгыять тулы канлы һәм тулы кыйммәтле тормыш белән яши дә алмый.

## РАЗЛИЧИЯ КУЛЬТУРНЫХ КОННОТАЦИЙ ФИТОНИМОВ

*Се Юэ, КФУ, магистрант II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Болгарова Р. М.*

Как известно, со времён античности весь органический мир принято было делить на два царства: царство растения и царство животных. И до сих пор царство растений занимает очень важное место для человечества. В настоящее время система растений членится более дробно.

Фитонимы в узком смысле – это собственные наименования растений. При таком понимании интересующего нас термина фитонимами являются только такие слова, как алиготе – наименование винограда, апорт – наименование яблок. В широком смысле фитонимы – это имена нарицательные, которые являются названиями растений.

Культурная коннотация – это важный аспект для изучения национальных языков. В целях интерпретации культурной коннотации особую важность приобретают стереотипы как культурно-маркированная единица ментально-лингвального комплекса, формируемая инвариантной совокупностью валентных связей, репрезентирующих образ, стоящий за данной единицей.

Говоря о различном статусе культурного компонента в смысловой структуре коннотативно значимых слов, мы имеем в виду следующие ряды лексико-семантических явлений.

Первый ряд составляют слова, в том числе имена собственные, коннотация которых опирается на ассоциации. При этом важно различать ассоциации, в основе которых лежат традиционные, социально-исторически обусловленные осмысления определенных реалий, присущих только носителям данного языка, и ассоциации литературного происхождения.

На базе образа, всегда национально обусловленного, рождается национальный символ как стереотипизированное явление культуры (берёза – поэтический символ России) и национальный эталон, характеризующий образную подмену свойств человека или предмета какой-либо реалией, которая становится знаком доминирующего в них свойства. Русская берёза является символом родины, женственности, любви и др. Она стройная, кудрявая, тонкая, белая, весёлая, представала девушкой и всегда положительным героем.

В современной научной литературе давно ведется дискуссия о том, что же является определяющим началом в исследовании национальной идентичности: кровь и почва, или язык и культура. И, хотя большинство исследователей обращают внимание на язык и культуру, тем не менее, национальный генотип и природно-климатические условия имеют прямое отношение к формированию качеств и свойств национального характера.

С точки зрения языка и культуры изучение культурной коннотации фитонимов в русском языке имеет большое значение. Потому что каждая страна, и каждый народ имеют свои любимые растения. Эти растения обязательно и тесно связаны со своей культурой, отражают глубокое чувство национальной самобытности.

**Литература**

1. Пуцилева Л.Ф. Культурно детерминированные коннотации русских зоонимов и фитонимов (на фоне итальянского языка). – Санкт-Петербургский государственный университет. – 2009. – С.7.

## СПЕЦИФИКА ТРАКТОВКИ РЕЛИГИОЗНОЙ ЛЕКСИКИ В СОВРЕМЕННОЙ ТАТАРСКОЙ ЛЕКСИКОЛОГИИ

*Мухаметова И., КФУ, аспирант III г.о.*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Юсупов А.Ф*

В современной лингвистике лексический фонд рассматривается не в качестве совокупности слов, которые передают знания об объектах окружающего мира, но и в качестве целостности понятий, которые позволяют воспринимать мировоззрение народа. Мировоззрение, в первую очередь, является системой знаний о действительности и о человеке. В современном обществе принято

классифицировать религиозное, естественно-научное, социально-политическое и философское мировоззрения, которые базируются на соответствующих убеждениях. С целью передачи содержания таких мировоззрений особую важность представляет наличие в языке определенных лексических единиц [3: 24].

В истории формирования и становления татарского народа, и, следовательно, татарского языка, присутствовали разнообразные исторические события, которым отводилась немалая роль. Стремление к получению знаний позволили в полной мере принять и освоить исламское религиозное мировоззрение. Религия, представляя собой неотъемлемую часть образа жизни, со временем стала рассматриваться в качестве причины формирования характерного восприятия мира, увеличения словарного запаса и поведенческой культуры населения в целом.

Современный татарский язык состоит из большого пласта разнообразной сакральной лексики, в которой содержатся определения различных исторических периодов: язычества, христианства и ислама. На сегодняшний день большая часть татар старается жить, в соответствии с исламскими канонами. Соответственно, в толковом словаре татарского языка фиксируется достаточно большое число лексических единиц, которые, так или иначе относятся к исламу. Также необходимо также подчеркнуть, что, кроме того, религиозная лексика присутствует и в диалектологических словарях.

При анализе словарного материала становится достаточно понятно то, что лексические единицы, активно употребляемые в повседневной жизни, так или иначе, содержат в себе отражение этнокультурных особенностей татар. Национальные и религиозные мышления татарского народа об окружающей действительности довольно интересны и многообразны. Несмотря на то, что восприятие окружающей действительности через призму религии, прежде всего, направлено на удовлетворение духовных требований человека, существует также и значительное количество лексических единиц, которые называют предметы, строения, одежду, пищу, напрямую связанные с религиозными традициями, обычаями.

Соответственно, можно говорить о том, что изучение сакральной лексики в качестве части словарного запаса татарского языка в самых различных проявлениях способствует лучшему пониманию особенностей восприятия окружающей действительности, взаимовлияния и эффективности контактов представителей разных культур и национальностей [2: 123].

Таким образом, на основе вышеизложенного можно сделать вывод, что лексический фонд языка, который в настоящее время

является предметом многочисленных исследований лингвистов, необходимо рассматривать не только в качестве совокупности слов, присутствующих в языке, но и в качестве целостного понятия, отражающего культуру и менталитет народа. История становления татарского народа, так или иначе, связана с формированием определенного религиозного мировоззрения, которое, со временем, стало оказывать влияние не только на культуру поведения татар, но и на словарный запас татарского языка. В связи с этим, в настоящее время большинство лингвистов сходятся во мнении, что религиозные лексические единицы татарского языка отражают также и этнокультурные особенности татар, что также обуславливает важность их подробного изучения.

**Литература**

1. Нурмухаметова Р. С. Основные тенденции развития лексики татарского литературного языка первой половины XX века: автореф. дисс. ... к. филол. н / Р.С. Нурмухаметова. - Казань, 2005. - 26 с.

2. Нурмухаметова Р.С. Отражение в языке духовной и материальной культуры татар (на материале лексики связанной с культурой питания) / Р.С.Нурмухаметова, М.Р.Саттарова // Наука и образование в XXI веке: сборник научных трудов по материалам Международной научно-практической конференции 30 сентября 2013 г. – Тамбов: Изд-во ТРОО «Бизнес-Наука-Общество», 2013. – С.121-129

3. Саттарова М.Р. Религиозная лексика в языковом сознании татар / М.Р. Саттарова // Вестник Казанского Приволжского федерального университета. – 2015. - №6. – С. 24-39.

## 5 НЧЕ СЕКЦИЯ

### ДӨНЬЯ ТОТКАСЫ ХАТЫН-КЫЗ КУЛЫНДА

*Тимерханова З., Казан, 181 нче мәктәп, IX сыйныф*
*Җит. – Вәлиуллина А.Ф.*

Һәр кешенең яраткан шөгыле була. Без интернет заманында яшәүче буын вәкилләре буларак, үзебезгә ошаган, күңелгә хуш килердәй шөгыльләрне интернет челтәре аша табып, сайлап ала алабыз. Сыйныфташларым, дусларым, танышларым нәрсә белән генә шөгыльләнми... Ә мин китап укырга яратам. Әллә инде шул китаплар арасында яшәгәнгә, әллә инде әти-әниемнең һөнәрләре китап дөньясы белән бәйле булганга...

Миңа хокук белгече һөнәре бик ошый. Бәлкем, киләчәгемне шул һөнәр белән бәйләрмен. Аның өчен бик күп укырга кирәклеген анык аңлыйм. Мине тарих фәне дә бик кызыксындыра. Татар кызы буларак, халкымның бай тарихын мин тирәннән белергә тиешмен, дип саныйм. Мин егерме беренче гасыр баласы гадәттә безнең заман балаларын бернәрсә белән дә шаккатырып булмый. Мине егерменче йөз башында татар хатын-кызларының үз хокукларын яклап съезд үткәрүләре, алардагы кыюлык, үткенлек, белемгә омтылулары, көчле шәхес буларак башкаларны да ияртеп бара алулары сокландырды, тирән хөрмәт хисе уятты. Эш барышында мин Ауропаның иң атаклы университеты – Сорбоннода белем алган татар кызларының да булуын белгәч, тирән дулкынлану хисләре кичердем.

Нәрсә ул хокук? Хатын-кыз хокукларын яклау темасы кайчан, кайда күтәрелә башлаган? Үз хокукларын яклауда кыюлык, тәвәкәллек күрсәткән татар хатын-кызлары турында мәгълүмат җиткерүне бурыч итеп алдым.

Татарстанда хатын-кызларны берләштерүче берничә оешма бар: Татарстан Дәүләт шурасы рәисе урынбасары Татьяна Ларионова җитәкләгән депутат хатын-кызларның «Мәрхәмәт-Милосердие» берләшмәсе, Казан Кирмәне музей-тыюлыгы җитәкчесе Зилә Вәлиева рәислек иткән «Русия хатын-кызлары»ның республикадагы иҗтимагый оешмасы, Кадрия Идрисова җитәкчелегендәге Дөнья татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы. 1917 елның 24 апрелендә беренче тапкыр Бөтенрәсәй мөслимәләренең Казанда Тинчурин театры бинасында беренче корылтае үткән. Бүгенге көн өчен дә әһәмиятен югалтмаган тәкъдимнәр керткәннәр, биредә кабул ителгән карарлар түбәндәгедән гыйбарәт:

- *ир белән хатын-кыз бертигез танылсын;*

*- хатын-кызларга иҗтимагый;*

*- сәяси эшләрдә катнашырга хокук бирелде, димәк сайлауларда да катнаша алалар;*

*- күп хатынлылык рөхсәт ителмәсен;*

*- 8 яше тулган һәр балага уку мәҗбүри булсын һәм кызлар өчен урта һәм югары мәктәпләр ачылсын;*

*- хатыннарга йөзләрен ачып йөрү тыелмасын;*

*- уку яшенә җитмәгән балалар өчен бакчалар һәм тәрбия йортлары ачылсын;*

*- шәһәрләрдә һәм авылларда аналарны саклау (охрана материнства) җәмгыятьләре ачылсын.*

Карарлар бер тавыштан кабул ителә һәм 1 нче майда Мәскәү шәһәрендә уздырылачак Бөтенроссия мөселманнары съездына кую өчен тәкъдим ителә. Шунысын да әйтеп үтик, татар хатын-кызларында зур съездлар уздыру тәҗрибәсе булмаса да, мәркәз бюро һәм җитәкче оешмалар өсләренә алган эшне уңышлы башкарып чыга алганнар. Алар, чыннан да, ирләр белән мәгарифтә дә, оештыру эшләрендә дә тигез икәнлекләрен күрсәткәннәр. Матбугатта съезд эше югары бәя алган. Димәк, без хәзерге заман хатын-кызлары күрсәтә алмаган кыюлыкны, 1917 нче елда татар хатын-кызлары күрсәткән икән. Казанда 2017 елның апрель аенда бишенче тапкыр «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызларының форумы булган. Калфаклы ханымнар татарлар гомер иткән һәр җирлектә милли мәгарифне үстерү, милли мәдәни мирасны саклау һәм тәрбияви проектлар тормышка ашыру турында секция утырышларында фикер алышкан. Татар хатын-кызларының «Ак калфак» оешмасы рәисе Кадрия апа Идрисова «Дөнья тоткасы зирәк хатын-кыз кулында шул. Балачактан ук, ана кеше баласына тиешле оеткыны сала, тәрбияви җирлекне булдыра ала икән, димәк, бездән соң дәрәҗәле буын калачак. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, проблемалар җитеп ашкан – бәби туйларыннан башлап, йоласын-тәртибен җиренә җиткереп туй уздыруларга кадәр гореф-гадәтләребез җуелып килә. Төрле чаралар үткәрергә кирәк. Май башында Казанга пешекчеләр җыйналса, ай ахырында Салават шәһәрендә шәҗәрә бәйрәме булачак. Аннан соң Сабада васыятьнамә язу буенча тәҗрибә уртаклашу көтелә. «Орчык бәйрәме», «Бәби туе»... Эш алымнарының нindиләре генә юк... Әлеге оешмаларның утырышларында әле моңа кадәр гаиләдә хатын-кызларга *көч куллануны* туктату турында сөйләшкәннәре, нindидер чаралар күрүне хәл иткәне булмады. Ни кызганыч, мөслимә хатын-кызлар оешмалары да хатын-кызларның хокукларын яклау мәсьәләсенә катышмауны хуп күрә. Статистикага карасаң, гаиләдә *көч кулланудан күпме хатын-кыз җәфа*

*чигә.* Татарстандагы хатын-кызлар оешмалары күпчелек калфак, аш-су, мода мәсьәләләрен генә күтәрә.

100 ел элек татар хатын-кызлары җыенда ирләр белән бертигез хокукта булу, сайлауларда катнашу, югары җитәкчелектә эшләү мөмкинлекләре булдыру кебек проблемнарны күтәреп чыккан булса, Казанда узган V Татар хатын-кызлар форумында төп мәсьәләләр телне һәм татар гаиләсен саклау булды.

Туфан абый Миңнуллинның шундый гыйбарәсе бар: «Иң матур хатын-кыз – бала җитәкләгән хатын-кыз». Тик менә дөньяга тормыш бүләк иткән әлеге матурлык ияләре өчен бик күп йөк өелә тора. Безнең хатын-кызлар җәмгыятьтә дә, эштә дә, өйдә дә, бала тәрбиясендә дә өлгерергә, шул ук вакытта һәрдаим матур, зәвыклы булып кала да белергә тиеш. Сүземне «Дөнья тоткасы хатын-кыз кулында» дип бетерәсем килә.

**Әдәбият**


1. Бөтенрусия мөселманнарының 1917 елда 1-11 майда Мәскәүдә булган гомуми съездының протоколлары. – Петроград, 1918. – Б. 354-357.
2. Йолдыз, 1917, 26 апрель; Гасырлар авазы-Эхо веков, 2007, – №2, – Б. 148-149.
3. Мөселман хатыннарының тавышлары // Сөембикә, 1917. – № 9. – Б. 142.
4. https://realnoevremya.ru/articles/58136-kaya-gyna-barmasyn-tatar-hatyn-kyzlary-irlar-yardamen-toep-ukyp-chykannar


## МИФОЛОГИЯ ҺӘМ ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНЫҢ МАТУР ӘДӘБИЯТ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЧАГЫЛЫШЫ


*Хәлиуллина Д., Казан, 121 нче лицей, X сыйныф*

*Җит. – Вәлиуллина Р.Х, Миңнуллина А.И.*


Һәрбер халыкның әдәбиятында кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәт хакындагы әсәрләр шактый. Табигатьнең зарын, моңын әдип йөрәге тизрәк, җиңелрәк аңлый. Мондый очракта авторлар җанлы һәм җансыз табигать вәкиленә кешедәге сыйфатларны бирәләр.

Фәнни эшнең максаты – халык авыз иҗаты һәм язучыларыбыз әсәрләрендәге бүре образының бирелешен өйрәнү, әсәрләр белән тирәнтен танышу.

Кешелек барлыкка килгәннән алып, ул табигать белән гармониядә яшәгән, аны изгеләштергән. Кешеләр өчен табигатьтәге иң изге җан ияләренең берсе – бүреләр булган. Халкыбыз аны әкиятләренә, риваятьләренә, әдәбиятыбызның башка жанрларына да керткән.

Күпгасырлык татар әдәбияты гына түгел, кыргыз, рус, чит илләр әдәбияты да халык мифологиясеннән килә торган бүре образына

мөрәҗәгать итә. Аларда бүре образы яратып, зур хөрмәт һәм күңел җылысы белән сурәтләнә.

Бүре – Җир йөзендәге һәммә нәрсәнең, табигать һәм кешенең бер-берсен яратып яшәргә тиешлеген исбатлаучы образ буларак тасвирлана. Вакыйгалар барышында кешеләргә хас кимчелекләр, җирдәге явызлыклар, усаллыклар бүредәге шәфкать хисе белән каршы куела.

Әкияттәге Ак бүре – бик тә үзенчәлекле зат. Әкият каһарманнарына хас хас булганча, үз теләге белән, төрле кыяфәтләргә керә ала. Илаһи Бүре образы, татар-болгарлардан һәм Себер татарларыннан тыш, безнең ут күршеләребез башкортларда, хакасларда, алтайлыларда, казакъларда, монголларда һ.б. халыкларда киң таралган. Соңгыларында Соры бүре үз заманында ярты дөньяны яулап алып, калтыратып торган, соңгы унъеллыкларда исеме тагын бер тапкыр аеруча популярлашып киткән Чыңгызханның нәселен башлап җибәрүче итеп сурәтләнә.

М. Җәлилнең «Бүреләр» исемле (1943) шигырьнең нигезендә, кешеләр үзләренең вәхшилекләре белән хәтта ерткыч хайваннардан да уздыралар, дигән фикер ята.

Ф. Шәфигуллин әсәрләрендә дә бүреләр кешеләргә начарлык кылмый, үзләрен дә нәкъ кеше шикелле, еш кына хәтта кешедән акыллырак, “кешелеклерәк” тоталар.

Ч. Айтматовның романы күңелсез вакыйгаларга нигезләнгән, исеме «Ахырзаман» булса да, повестьта бүре булып бүреләрнең яшәеше матур хисләр калдыра. Бүреләр кайберт кешеләрдән мәрхәмәтлерәк. Кешеләрнең явызлыгы аларны да явызлыкка этәрә.

Бу роман – җан авазы, кешеләрне мәрхәмәтлелеккә чакыручы әсәр. Кешеләр бөтен галәм алдында җаваплылык тоярга тиешләр. Роман бүреләр семьясын тасвирлаудан башлана һәм кешеләр гаебе белән юкка чыккан Моюнкум фаҗигасе белән тәгәлләнә: коралланган кешеләр вәхшиләрчә саваннага һөҗүм итәләр. Алар һәр нәрсәне – даладагы бар матурлыкны юкка чыгаралар, бүреләрне, сайгакларны рәхимсез рәвештә аталар. Аларның күзенә бернәрсә күренми, бары ит планын үтәү турында гына уйлыйлар. Ак бүренең кешеләр белән көрәше трагик тәмамлана.

Романда бүреләр кешеләргә караганда мәрхәмәтлерәк, аерым әхлак сыйфатларына, горурлыкка ия итеп сурәтләнгән. Ана бүре Акбүре һәм ата бүре Ташчәйнәрдә кешеләрнең яхшы сыйфатлары сынландырылган: балаларын ярату, аларны сагыну. Болар инстинкт кына түгел, аңлылык белән барлыкка килгән сыйфатлар. Бер-берсенә тугрылык, бирелгәнлек бар Акбүре һәм Ташчәйнәр образларында. Акбүре бигрәк тә әхлаклылыгы белән аерылып тора. Аның ыруына,

нәселенә бәла килә, беркайчан бозылырга тиеш булмаган әхлак кануннары бозыла. Саваннага һөҗүм булганчы, Акбүре даладагы ярдәмчесез кешеләр очраса да тимәгән. Вәхшилек кылган кешеләр белән ул көрәшергә тотына. Кызганычка каршы, Базарбай гына түгел, бер гаепсез бала да һәлак була. Акбүре алдында Бостонның шәхси гаебе булмаса да, Базарбай өчен, бер көндә Моюнкумны юкка чыгарган Кандалов өчен җаваплылык тоярга тиеш. Айтматов Кандаловның вәхшилеген югары, әйтергә кирә, дәүләт дәрәҗәсенә куеп сурәтли. Бу бер кешенең генә түгел, ә гомумхалык фаҗигасе, социаль проблема. Хөкүмәт җитәкчеләре тарафыннан Кандаловның вәхшилеге гаепләнми, киресенчә, хезмәткә намус белән караучы, ит планын үтәүдә зур тырышлык куючы итеп бәяләнә. Әсәрнең трагедиясе шунда да инде.

Бүреләр Н. Гыйматдинова әсәрләрендә дә төп персонаж булып тора. Без берничә әсәр мисалында табигатьтәге җан ияләре – бүреләр, аларның кешеләргә никадәр якын, шул ук вакытта ничек ерак икәнен дә күрдек. Язучыларыбыз халык авыз иҗатын үзләренә өлге итеп алганнар дип әйтергә була.

Әйе, бүреләр – ерткычлар. Табигать аларны шулай яраткан. Бүреләр табигать кануннарына буйсынып яшиләр. Ә без? Кешеләр? Акыл ияләре?! Без табигать кануннарына буйсынып яшибезме? Юк, без табигатьтән ерак киткәнбез. Аңа кире әйләнеп кайта алырбызмы? Табигать-Ана белән уртак тел табу көчебездән килерме? Менә шундый аяусыз тормыш фәлсәфәсе.

Гүзәл табигатьнең дошманы – кеше үзе дигән фикер якынлаштыра бу әсәрләрне. Әдипләребез әлеге әсәрләре белән табигатьне, тирә-якны, аның иминлеген яклап аваз салып, җәмәгатьчелекне сискәндереп җибәрде, яшәешебез өчен нинди куркыныч алып килүен искәртте.

**Әдәбият**

1. Айтматов Ч. Плаха. – Москва: изд. Азбука-классика, 2006.
2. Гыйльманов Г. Албастылар. Хыялый кыйсса. – Казан, 2003.
3. Гыйматдинова Н. Бүре каны. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998.
4. Гыйматдинова Н. Икебезгә дә авыр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.
5. Заһидуллина Д. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы . – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

## ТЕЛЛӘР БЕЛҮ – ЗУР БАЙЛЫК

*Чинар К., Бөгелмә, лицей-интернат, VII сыйныф*
*Җит. – Юнысова С.Г.*

Татар теле... Тугач та, иң газиз кешедән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, 7 миллион халык сөйләшкән, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, утларга-суларга салсалар да, чукындырсалар да, ассалар-киссәләр дә исән калган, кимсетүләргә түзгән, сынмаган-сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле. Шушы телдә сөйләшә, укый-яза, фикер йөртә, аңлаша, аралаша алуым белән чын күңелдән горурланып яшим. Мин үзем катнаш гаиләдә туганмын. Әнием Гүзәл – милләте буенча татар, әтием – Латыйф, төрек милләтеннән. Безнең гаиләдә аралашу татарча һәм әтиемнең туган теле булган төрек телләрендә бара. Мин – Мостафа Өнҗәл исемендәге лицей укучысы. Лицейда татар, рус, инглиз телләре белән беррәттән, төрек, француз телләре дә укытыла. Татар теле белән төрек теле алар тугандаш телләр, ә инглиз һәм француз телләре – алар минем киләчәгем. Француз телен бу уку елында гына укый башлау сәбәпле, мин бу телдә әле иркен аралаша алмыйм.

Дөресен әйтергә кирәк, мин үз туган телем аша гына гына башка телләрне тиешле дәрәҗәдә үзләштерә алуыма ышандым һәм кардәшырулык атамаларының башка телләргә ничек тәрҗемә ителүе белән кызыксына башладым. Менә аларның кайберләре:

татарча-русча-инглизчә-төрекчә-французча

*әт – папа – fathe – baba – un père*
*әни – мама – mother – anne – une mère*
*әби – бабушка – grandmother – babaanne/anneanne – une grand-mère*
*бабай – дедушка – grandfather – dede – un grand – père*
*малай – мальчик – boy – oğlan – un garçon*
*кыз – девочка – girl – kız – une fille*
*егет – парень – guy – delikanlı – un gars*
*ир – муж – husband – koca – un mari*
*абый – брат, дядя – (elder) brother – ağabey – un frère*
*апа – сестра, тетя – (elder)sister – abla – une sœur*
*эне – братишка – (younger brother) – (erkek)kardeş – un petit frère*
*сеңел – сестренка – (younger)sister – (kız) kardeş – une petite sœur*
*кияү – жених – groom – damat – un fiancé*
*кәләш – невеста – bride – gelin – une fiancée*
*кода – сват – co father in law – dünür – un marieur*
*кодагый – сватья – co mother in law – dünür – une marieur*
*каенана – свекровь – mother in law – kayınvalide – une belle-mère*
*каената – свекор – father in law – kayınpeder – un beau – père*
*хатын-кыз-женщина-woman- kadın – une femme*
*үги әни – мачеха – stepmother – üvey anne – une belle – mère*
*үги әти – отчим – stepfather – üvey baba – un beau – père*

*үги кыз – падчерица – stepdaughter – üvey kız – une belle – fille*
*үги малай – пасынок – stepson – üvey oğul – un beau – fils*

2021 нче ел президентыбыз тарафыннан «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы» дип игълан ителде. Телләр өйрәнү ул дәвамлы эш, һәр укучы үз алдына максат куеп, гореф-гадәтләребезне саклап, телебезне өйрәнсен, күз карасыдай кадерләсен иде.

Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә, туганлык атамалары бик борынгы заманнарда ук нәсел һәм гаиләдәге кешеләрнең бер-берсенә карата үзара мөнәсәбәтләрен билгеләү, белдерү өчен барлыкка килгәннәр һәм бүгенге көндә дә без аларны сөйләмдә уңышлы кулланабыз.

## ТАТАР МИЛЛИ РИЗЫКЛАРЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Шакирова Л., Басыйрова Э., Казан, 182 нче политехник лицей, X сыйныф*
*Фән. җит. – Хайрутдинова Л.Н., Гатауллина А.С.*

Санап кына бетерерлек түгел
Каюм бабабызның хезмәтен.
Без белгәне – диңгездән бер тамчы,
Бер тамчының меңдер хезмәте.
Э. Шәрифуллина

Татар халкы бик борынгыдан ук аш-су әзерләргә оста булган, тәмле ашлар пешергән. Милли ашларның үзенчәлеге халыкның тормыш рәвешенә бәйле булган. Татар халкы үз милли ашлары белән бик бай һәм бөтен дөньяга үз ризыклары белән дан казанган. Татар аш-су осталары бик күп төрле ашамлыклар уйлап тапканнар. Без моны төрле сайтларны һәм әдәбиятны өйрәнү барышында ачыкладык. Бүгенге көндә интернет челтәрендә татар милли ашларына багышланган сайтларның күп булуы татар халык ашларының күпләр тарафыннан яратып кулланылуы турында сөйли. Бер үк төрле ризыклар төрле-төрле рецептлар буенча әзерләнә, үзенчәлекле ризыклар барлыкка килә. Югарыда китерелгән фактлар «Татар милли ризыклары» темасының *актуальлеген* билгели. Интернет челтәрендә дә, әдәбиятта да әлеге тема тулысынча яктыртылмаган, чөнки һәр төбәктә, һәр гаиләдә бер үк исемле ризыклар төрле рецептлар белән әзерләнәләр.

Татар халкының милли традицияләргә бай ашлар әзерләү осталыгы бик күптәннән килә. Күп гасырларга сузылган тарих дәвамында милли оригиналь ашлар барлыкка килгән, алар үзләренә генә хас сыйфатларны әлегә кадәр саклаганнар. Аларның үзенчәлеге

халык тормышының иҗтимагый, икътисадый, табигый шартларына, аның этник тарихына бәйле.

Татар халкының милли ашлары үз этник традицияләре нигезендә генә үсмәгән, аңа күрше халыкларның – руслар, мари, удмурт һ. б., шулай ук Урта Азия халыкларының, аеруча үзбәк һәм таҗикларның ашлары йогынты ясаган. Татар халкы ашларына пылау, хәлвә, ширбәт кебек ашамлыклар, шулай ук рус милли ашамлыклары бик күптән килеп кергән. Шул ук вакытта башка халыкларга хас ашларны әзерләү, азыкларның төрләрен ишәйтү татар ашларының төп этник үзенчәлекләрен үзгәртмәгәннәр.

Без татарларның нинди ризыкларны яратуын ачыклау максатыннан шәһәрдә яшәүче берничә кеше белән очраштык. Әңгәмә барышында аларның яше, гаиләсе, кунак сыйлау әдәпләре, иң еш пешерелә торган милли ризыклары турында сорашып белештек. Барлык сорашучылар да татар милли ризыкларының бик тәмле һәм файдалы икәнен ассызыкладылар. Алар бик күп төрле милли ризыклар пешерәләр. Тикшеренүләр нигезендә без Сабада яшәүче татарларның ин яраткан милли ризыклары булып күзекмәк, гөбәдия, чәкчәк, бавырсак, бәлеш, пәрәмәч, чәй булуын ачыкладык.

Тикшеренүләрнең бер көнендә без Гөлназ апа һәм Хәким абый Әгъләметдиновлар гаиләсендә булдык. Бу гаилә дә инде 30 ел бергә яшиләр. Өстәлләрендә һәрчак милли ашлар була. Хәким абый күзекмәк ярата. Гөлназ апа табынга һәр көнне милли аш әзерли. Ул безгә күзекмәк турында сөйләде.

Күзекмәк(кыстыбый) иң борынгы һәм гади ризыклардан санала. Кыстыбый өчен табада төче камырдан юка итеп җәеп тышлык пешерелә, аның эченә бәрәңге, тары боткасы яисә төйгән киндер орлыгы салына. Баштарак ул камыр эченә төрле ярмалардан пешерелгән боткалар салып әзерләнгән. Әгәр татар халкының элек-электән игенчелек белән шөгыльләнүен искә төшерсәк, бу гаҗәп түгел. Бәрәңге Россиядә, шул исәптән татар халкында XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында гына ныклап урнаша. Кыстыбый да бәрәңге эчлеге белән XIX гасыр азагыннан гына әзерләнә башлый [branclub.narod.ru]. «Кыстыбыйның эчлегенә карап, төрле төбәкләрдә бәрәңге кыстыбые, орлык кыстыбые, тары кыстыбые кебек атамаларны очратырга була” – дип сөйләде безгә йорт хуҗабикәсе Гөлназ апа.

Тикшеренү барышында без түбәндәге сорауга да җавап аласыбыз килде: районнарыбызда туклану урыннарында нинди татар милли ризыклары сатуда бар микән? Моны ачыклау өчен берничә кибеттә һәм кафеда булдык. Кибетләрдә чәкчәк һәрчак сатуда бар. Сатып алучылар әлеге татлы ризыкны бик теләп алалар. Шулай ук

кибетләрдә без күзекмәк, пәрәмәч, өчпочмак, вак бәлеш, бәлеш, гөбәдия кебек ризыкларның да булуын искәрттек.

Татар ашлары күптөрле. Татар ашларын татарлар гына түгел, чит илләрдә дә яратып ашыйлар. Аш әзерләүдә кулланылучы продуктларның күптөрле булуы татар милли ашларының үзенчәлеге булып тора. Татарларда ит, бәрәңге, йомырка, ярма, он ризыклары, бал бик күп кулланыла. Тикшерү вакытында милли ризыклардын бавырсак, гөбәдия, бәлеш, пәрәмәч, чәкчәк кебек ризыкларның күп кулланылуын ачыкладык. Эшебездә төп тикшеренү объекты булып камыр ашлары булды. Аларны ачыклау өчен без куелган максат буенча татар халкының милли ашларын өйрәндек, үзенчәлекләрен таптык; милли ризыкларның халыкларны берләштерү чарасы буларак хезмәт итүен ачыкладык. Татар милли ашлары төрле милләт халыкларын якынайта һәм берләштерә торган чара икәненә төшендек. Эш барышында фәнни, әдәби һәм матбугат материаллары белән эшләдек, өлешчә эзләнүле методы кулландык. Татар милли ашлары өйрәнү өчен бай чыганаклардан санала. Моны өйрәнүне дәвам итәргә кирәк.

**Әдәбият**

1. Баязитова Ф. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1995.
2. Татар халык ашлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.
3. Каюм Насыйри. Китаб–эт-тәрбия. –Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. –144 б.
4. watan.su, igelek.ru
5. beztatarlar.ucoz.rumuslim-info.com

## ФАТИХ КӘРИМНЕҢ ШИГЪРИ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ СЫНЛАНДЫРУЛАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

*Шакирова Ф., Буа р-ны Әлки мәктәбе, X сыйныф*
*Җит. – Исмәгыйлева Г.Т.*

Әдәбият дәресләрендә Ф. Кәримнең тормыш юлы, иҗаты, гаиләсенә, иҗатташ дусларына язган хатлары, Ләйлә ханымның әтисе турында язган истәлекләре белән таныштык, безне ялкынлы да, моңлы да, үз Туган иленең патриоты булган шагыйрь язмышы кызыксындырды: аның турында күбрәк беләсе килде һәм эзләнә башладык...

Шагыйрь әсәрләрен язганда лексик, стилистик, чагыштырулар һәм троплар кебек төрле сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итә. Бу юлы без Фатих Кәрим иҗатындагы тропларның берсен – сынландыруларны (җанландыру) тикшерергә булдык. Эзләнү эшебезнең максаты – Фатих Кәрим иҗатын өйрәнү һәм шигырьләренең стиль үзенчәлекләрен ачыклау.

Әйтелгән максаттан чыгып, түбәндәге бурычлар куелды:

- Фатих Кәрим иҗатын өйрәнүгә кызыксыну уяту;

- Фатих Кәрим шигырьләрендәге тел үзенчәлеген тәшкил иткән сынландыруларны ачыклау;

- тупланган материалны киң катлау укучыларына тәкъдим итү.

Фатих Кәрим иҗатында сынландырулар бик күп. Мисалга түбәндәге юлларны китерә алабыз:

*Биргән антыбыз ай булды*
*Кара төнле юлларда;*
***Канат җилпеде ишкәкләр,***
*Кузгалып киттек ярдан.*
*Ярышып килгән дулкыннар*
*Сулыштан беләләрме,*
*Әче сагыш хисе белән*
***Үбәләр көймәләрне*** (Днепр дулкыннары).

Сынландыру табигать күренешләрен, тере булмаган әйберләрне җанлы әйберләргә хас сыйфатлар белән сурәтләүдән гыйбарәт.

Сынландырулар әдәби текстта сурәтләнә торган предметка җанлылык бирү өчен дә кулланыла. Түбәндәге мисалларны карап китик:

*Өс-баш юеш. Күрәкләргә*
*Үзле балчык сылаша;*
*Кабер казыйбыз тынлыкта,*
***Җил генә ыңгыраша.***
***Кайгыдан каралып торган***
***Яшь-яшь нарат төбенә***
*Яшь-яшь иптәшне күмгәнне*
***Күрә бары төн генә*** (Сибәли дә сибәли).

Табигатьтәге төнге җил, көзге яңгыр кайгы хисен тагын да тирәнәйтә.

Автор, сугышның гадәти бер күренешен тасвирлап, ул алып килгән фаҗигане ача, шул рәвешле укучының хис-кичерешләрен кузгата. Сугыш башлаучыларга нәфрәт тудыра һәм тормышның, тынычлыкның кадерен белергә, аны сакларга чакыра.

Фатих Кәримнең поэмаларында да сынландырулар күп очрый.

*Авыл яна,* ***ургый күк төтен,***
*Шартлап яна төнге салкында;*
*Болытларга җиткән ялкында*
***Куркып артка чигә кышкы төн.***
***Михнәт бавы сөйрәп килә көн,***
***Килә канлы үлем өләшеп.***

*Ак кар кунган куак астыннан*
***Тәрәзәне кага төнге җил.***
***Җил хәбәрен тыңлап үтә төн.***
***Тагынниләр алып килә көн.***
***Җил ерактан хәбәр китергән,***
*Тыңла, Гөлсем, тыңла сөйләсен.*
***Таң талпынып күккә үрелә.***
*Кемдер каера бикле ишекне* (Гөлсем).

Югарыда китерелгән өзекләрдә эчтәлекне образлы итеп ачу өчен “төн”, “көн”, “җил”, “таң”, “җир”, “ут” төшенчәләре кешеләргә хас үзенчәлекләр белән җанландырылып сурәтләнгәннәр.

Шагыйрь фашизмның нәфрәтен дә җанландырып бирә. Мисалларга мөрәҗәгать итик.

*Офицерда* ***ачу куерды:***
*“Колхозчылар имде сөтеңне,*
*Ә без инде ашыйк итеңне”, –*
*Маңгаена ата сыерның.*
*Чыга доктор, куырып җилкәсен,*
*Күзлегеннән* ***чәчри явызлык*** (Гөлсем).

Шулай итеп, Фатих Кәрим иҗатында сынландыруларны кеше хисләрен чагылдырганда аеруча күп куллана, шагыйрьнең төрле поэтик бизәкләргә мөрәҗәгать итүе аның шигырьләренең югары сәнгать әсәре булуын күрсәтә.

**Әдәбият**


1. Фатих Кәрим. Сайланма әсәрләр: 2 томда. – Казан, 2009. – 218 б.


## XXI ГАСЫР МӘГЪРИФӘТЧЕСЕ – РАВИЛ БОХАРАЕВ


*Шәйдуллин И., Казан, 181нче мәктәп, IX сыйныф*
*Җит. – Вәлиуллина Ә.Ф.*


Татарстанда 2021 елны «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы» дип игълан иттеләр. 2020 нче елда Татарстан Республикасы оешуга 100 ел тууга күп кенә чаралар каралган иде. Пандемия булу сәбәпле, аларның кайберләре дистант, кайберләре (халык күп җыела торганнары) уздырылмыйча да калды. Туган телләр турында сөйләшкәч, минем күз алдына Тукай, Һади Такташ, Гаяз Исхакый, Сәлих Сәйдәшев, Муса Җәлил кебек бөек шәхесләр килеп баса. Татар халкы өчен шул кадәрле күп хезмәтләр куйган XXI гасырда да мондый шәхесләребез бармы? Кемнәр алар? Без аларны беләбезме?

XIX гасырда аларны мәгърифәтчеләр дип атаганнар. Шул сорауларга җавап эзләүне туган тел дәресендә һәм интернет

челтәреннән эзләргә керештем. Игътибарымны милләтебез горурлыгы булган Равил Бохараев җәлеп итте. Фәлсәфәче, язучы, публицист, инглиз, венгр телләрендә иҗат итә икән әлеге шәхес белән укытучым таныштырды. Миңа аның тормыш юлы да, тормышка карашлары да, иҗаты да бик кызыклы тоелды. Интернет челтәрендә мәгълүмат күп дип әйтеп булмый, аның хезмәтләренең тулысынча өйрәнелмәгән булуы бик гаҗәпләндерде. Равил Бохараев турында татар телендә язылган мәгълүматның бик аз булуы сәбәпле, күбрәк рус телендә язылган чыганакларга таянырга туры килде.

Мәкаләнең максаты – Равил Бохараев туында мөмкин кадәр мәгълүмат туплап, аның эшчәнлеге белән тирәннән танышу. Аның турында күбрәк белгән саен, күңелемдә әлеге шәхескә карата горурлык хисе артуын сиздем.

Равил Бохараев математиклар гаиләсендә туган. Әтисе Рәис Бохараев Казан кибернетиклар мәктәбенә нигез салган кеше – зур галим. Әнием Найра Халитова – Казан кызы. Шулай ук гомере буе университетта математика укыткан. Равил Бохараев Казандагы махсус математика мәктәбендә укыган. Бер үк вакытта махсус музыка мәктәбендә дә белем алган. Кибернетика буенча Мәскәүдә аспирантура да тәмамлаган. Ләкин, нишлисең, язмыш аны әдәбият дөньясына алып кереп киткән. Бер үк вакытта математик булып, иҗат белән дә шөгыльләнү минем өчен гаҗәеп күренеш. Равил Бохараевка иҗат итү күбрәк ошаган, әти-әнисе дә аны яхшы аңлап, беркайчан да ниндидер киртәләр куймаган. Равил Бохараев һәрвакыт үзенең йөрәгенә буйсынган. Талантлы шагыйрьләр математика фәненә беркайчан да битараф булмаганнар. Күрәсең, шигърият үзе үк математика ул. Математика – шигърият. Чөнки математика ул коры саннар, формулалар гына түгел. Ул – фәлсәфә, образлы фикерләү. Математика кешене бу дөньядан әллә нинди үлчәмнәргә алып китә.

Равил Бохараевның «Мәгариф» нәшриятында дөнья күргән китабының исеме белән әйтсәк, «Очсыз-кырыйсыз поезд» аны нинди гомер маршрутлары буйлап йөртте икән? Ул Мәскәүдә аспирантурада укыган. Шунда 17 ел яшәгән. Ике елга якын СССР Язучылар берлегендә әдәби консультант булып эшләгән. Башта Идел буе төбәге буенча, соңрак, Калмыкияне дә, Себер ягын да аңа йөкләгәннәр. Аның бөтен максаты иҗат итү була. Күп яза, тәрҗемә итә. Курчак театры һәм Рус яшь тамашачылар театры өчен пьесалар яза. Мәскәүдә яшәгәндә аңа еш кына: «Син татар фамилиясен йөртеп ерак бара алмыйсың, әйдә, язучы буларак, үзеңә берәр тәһәллүс ал», – дигәннәр. Ә аның җавабы катгый булган: «Татар булып тудым, татар булып үләчәкмен!» Равил Бохараев әйткән бу сүзләрне укыгач, татарлыгым өчен горурландым!

Равил Бохараев студент елларында ук татар тарихы, аның тамырлары белән кызыксына башлаган. Әлеге кызыксынуы аны Дәрдемәнд эзләре буйлап Урал якларына алып киткән.У л вакытта әле Дәрдемәнднең балалары да исән булган. Әлеге сәяхәттән ул бик күп фотолар, документлар, шагыйрьнең кайбер шәхси әйберләрен алып кайткан.

Равил Бохараев Татарстан хөкүмәте һәм татар ПЕН-үзәге ярдәме белән инглиз телендә «Татар поэзиясенең тарихи антологиясе»н нәшер иткән кеше. «Татар поэзиясе антологиясен» инглиз телендә чыгару аның күптәнге хыялы булган. Бу хезмәтнең тарихи антология дип аталуы әлеге хезмәткә кергән барлык шигырьләрнең дә тарихи документ итеп карала алуы белән аңлатыла. Әйтик, Болгар, Казан ханлыкларына бәйле тарихи чыганыклар бик аз сакланган, әмма шигырьләр исән. Әлеге антология Кол Галидән башлап бүгенге поэзиягә кадәр булган чорны колачлаган. Әлбәттә, тарихи бүлеккә шактый зур урын бирелгән. Шигырьләрне инглиз теленә юлын-юлга Равил әфәнде үзе тәрҗемә иткән, сәнгати тәрҗемәне исә Лондон университеты профессоры, ариенталистик поэзияне тәрҗемә итү өлкәсендә зур тәҗрибә туплаган белгеч Девид Меттьюс башкарган. Татар шигыре инглиз телендә яңгырыймы? Инглиз укучысы аны ничек кабул итә? Тәрҗемә мәсьәләсендә нинди кыенлыклар булган?

Татар шигърияте белән беренче мәртәбә очрашкан тәрҗемәче Девид Меттьюс өчен көтелмәгән зур ачыш булган. Аеруча ул дөньякүләм әһәмияткә ия булган Кол Гали, Сәйф Сараи, Хисам Кятиб кебек классикларның мирасларын күреп таң калган. Равил Бохараев фикеренчә, Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил, Хәсән Туфан кебек шагыйрьләребез инглиз телендә тулы көчендә аһәңле яңгырыйлар. Ә менә бүгенге заман шагыйрьләре белән кайбер кыенлыкларга да юлыккан. Чөнки күп кенә шигырьләр татар телендә гаҗәп дәрәҗәдә хисле, моңлы, матур яңгырыйлар. Ә тәрҗемә итә башласаң, коры хәбәргә әйләнә дә кала икән. Бу хәл татарга гына түгел, ә бөтен төрки шигърияткә хас, чөнки инглизләр моң, сагыш дигән нәрсәне белмиләр. Аларга коры информация дә җитә. Иҗаты катлаулы, киләчәктә балаларга кирәге чыкмаячак дип, Шекспирны да мәктәп программасыннан кысрыклап чыгарган мәдәният хакында ни дип әйтерсең… Кайчандыр, Равил Бохараевта бүгенге бик күп яшьләр кебек, үз ана телен начар белгән, әмма ул аны яңадан өйрәнгән. «Рус телендә язсам да, шигырьләрем татарча минем. Нәфесемдә, кальбемдә татар каны ага» – дип язган XXI гасыр мәгърифәтчесе.

**Әдәбият**


1. Соложенкина С. Разлуки нет... // Литературное обозрение. 1986, – № 7.
2. Шевелёва И. О книге Р. Бухараева «Редкий дождь» //Новый мир. 1982, – №1.

# НӘФИС ГИМНАСТИКА БАШЫНДА ТАТАР КЫЗЛАРЫ

*Шириева А., Казан, 181 нче мәктәп, IX сыйныф*
*Җит. – Вәлиуллина Ә.Ф.*

Татар милләтенең асыл егет һәм кызлары спортның кайсы гына өлкәсенә карама, шунда зур нәтиҗәләргә ирешәләр, тамашачы ихтирамын казаналар. Милләттәшләребезнең спортның кайсы төрләрендә аеруча зур уңышка ирешүләрен карый башласаң, бик тә кызыклы фактларга тап булабыз. Хоккей, футбол, баскетбол кебек республикабызда аеруча популяр булган спорт төрләреннән түгел, ә татар спортчылары иң күп медальне көрәш һәм гимнастика буенча яулаган икән. Бу фактларга таянып, шуны әйтә алабыз – безнең ир-егетләр элек-электән таза, көчле, ә кызларыбыз чибәр, зифа буйлы булган. Шул чибәр, зифа буйлы кызларыбыз турында нәрсәләр беләбез соң? Кемнәр соң алар? Милләтебезнең абруен күтәрүчеләр, дан-шөһрәт казанган бу спортсменнарны хәзерге яшьләр беләме соң? Без бу хезмәтебездә шул абруйлы берничә спортчыларыбыз турында сөйләрбез. Нәфис гимнастика дигәч бик күпләрнең күз алдына чибәр, мөлаем Алина Кабаева, нәфис, гүзәл кыз Ләйсән Үтәшева, Әминә Зарипова кебек туташлар килеп баса. Ә менә Галимә Шөгерова, бертуган Нәҗметдиновалар турында күбебез белми дә әле. Мин нәфис гимнастиканы бик яратканга һәм аның данын дөнья биеклегенә күтәргән, танылган татар кызларының спортка керткән өлешләрен күрсәтүне бурычым итеп алдым.

«Татар кызлары минем маңгаема йолдыз уйдылар». Әлеге сүзләр Ирина Александровна Винер тарафыннан әйтелгән, ул үзе тәрбияләгән татар гимнасткалары белән чиксез горурлана, гимнастикада татар тамырлары булуына соклан: «Татар кызлары кебек сыгылмалы, зифа кызлар беркайда да юк, Казанда уза торган барлык ярышларга да килергә тырышам, чөнки монда гимнастиканың киләчәк йолдызларын күрергә мөмкин», – ди ул. Бу чынлап та шулай. Универсиада вакытында нинди мәһабәт гимнастика залы ачылды. Йөзләгән балаларга чиксез мөмкинлекләр дигән сүз бит бу. Озакламый «яңа Нәҗметдиновалар», «яңа Кабаева», «яңа Үтәшевалар» кебек нәфис гимнастика йолдызлары кабыныр.

Нәфис гимнастика чагыштырмча яңа спорт төре. СССРда нәфис гимнастика буенча беренче чемпионат 1948 нче елда үткәрелә. Узган гасырның илленче-алтмышынчы елларында гимнастика күгендә балкыган Свердловск (хәзерге Екатеринбург) шәһәреннән дүрт бертуган Нәҗметдиноваларны могҗизага тиңлиләр.

Иң олылары – Лилия Билал кызы Нәҗметдинова 1936 нчы елда Свердловск шәһәрендә туган. Лилия Нәҗметдинова нәфис гимнастика буенча СССРның беренче спорт остасы (1954), СССРның атказанган спорт остасы (1964).

Бу чорларда нәфис гимнастиканы чит илләрдә белмиләр дә әле. Лилия Нәҗметдиновага бу спорт төрен башта Европада, соңрак дөнья күләмендә пропагандалау миссиясе йөкләнә. 1958 нче елда Штутгардта үткән гимнастика конгрессында һәм шул ук елны Брюссельдә уздырылган Бөтендөнья күргәзмәсендә Урал кызы, әлеге спорт төренең киләчәге зур булуын күрсәтеп, тамашачыларның ихтирамын яулый. Гимнастка 1951-1971 нче елларда 15 тапкыр СССР чемпионы, 12 тапкыр РСФСР чемпионы исеменә лаек була. Үзенең спорттагы уңышлары өчен – 20 ел буе РСФСР һәм СССР җыелма командасында чыгыш ясаганы өчен Лилия Нәҗметдинова Гиннесның рекордлар китабына кертелә. Россиянең атказанган физкультура һәм спорт хезмәткәре (1992). Лилия Нәҗметдинова 2006 нчы елдан – Екатеринбург шәһәренең Мактаулы гражданкасы.

Розалия Билал кызы Нәҗметдинова 1946 нчы елда туган. Апасы Лилиянең гимнастика буенча шөгыльләнүләрен күреп, ул да спортка тартыла, шулай ук зур җиңүләргә ирешә. Розалия Билалова нәфис гимнастика буенча СССРның спорт остасы (1963), Россия һәм СССР чемпионы (1962, 1963) Россиянең атказанган тренеры (1995).

Әлфия һәм Илмира Нәҗметдиновалар да апалары юлыннан атлый. Әлфия Билал кызы Нәҗметдинова 1949 нчы елда туган. Спортка 1957 нче елда килә. Нәфис гимнастика буенча СССРның спорт остасы (1965), Халыкара класслы спорт остасы (1970), Республиканың категорияле судьясы (1986), 1966-1975 нче елларда СССР җыелма командасы составында чыгыш ясый. Шунысы кызык: мәртәбәле тренерлар кечкенә кызларның гимнастикага сәләтен күрмиләр. Лилия һәм Розалия Нәҗметдиновалар үзләре сеңелеләре белән шөгыльләнә башлыйлар. Озакламый «өметсез» дип табылган кызларны тренерлар һәм тамашачылар аягүрә басып алкышлыйлар. Шулай итеп, судьяларның да, тренерларның да ялгышканын исбатлыйлар. Миңа калса, бу татар кызларының зифа буйлы, матурлыгын гына түгел, ә характер ныклыгын, ихтыяр көченең ифрат дәрәҗәдә күп булуын һәм иң мөһиме туганнарның бердәм икәнлеген исбатлый торган милли сыйфатыбыз.

Илмира Билал кызы Нәҗметдинова нәфис гимнастика буенча СССРның спорт остасы (1967). Күп тапкырлар Россия һәм СССР чемпионы (1967-1975), шулай ук республиканың категорияле судьясы. Бертуган Нәҗметдиновалар берничә мәртәбә Гиннеслар китабына

кертелгән иң яшь спорт остасы да (12 яшьтә ), иң күп медаль, кубок яулаучылар да.  Алар ил өчен бик күп данлыклы спортсменнар тәрбиялиләргә дә өлгерәләр.

Омск шәһәрендә туган гүзәл татар кызы Галимә Шөгерова җитмешенче елларда Европаның да, дөньяның да абсолют чемпионы була һәм берничә ел дәвамында бу исемнәрне үз кулларында тота. Ул 15 яшендә Болгариянең Варна шәһәрендә дөнья чемпионатында катнашып, дөнья чемпионы дигән мактаулы исемгә ирешә.

Галимә Шөгерова нәфис гимнастика буенча дөнья күләмендә ун еллап җиңелү белми. Аның җиңүләре турында аерым язма гына түгел, китап язарлык. Гүзәл татар кызы беркайчан да үзенең милләте турында, тамырлары турында онытмый. Бервакыт чемпион калгач, ялгышыпмы, әллә белепме аңа «Галина Шөгерова» дип язылган грамота бирәләр. Әмма кыз аны алмый. «Исемемне дөрес языгыз!» дип таләп итә. Ярыш судьяларына яңа грамота табып, кызның исемен дөресләп язып бирүдән башка чара калмый. Бу инде аның үз милләте белән горурлануы, башка халыклар белән бертигез хокукта булуын бик яхшы белүе турында сөйли.

1972 нче һәм 1976 нчы елларда спорт гимнастикасы буенча СССР командасы составында Олимпия уеннарында җиңү яулаган Эльвира Саади – кайчандыр Казаннан Ташкент якларына күчеп китәргә мәҗбүр булган галим Габдрахман Сәгъдинең оныгы. Монреаль һәм Мәскәү Олимпиадаларының 5 алтын медаленә хуҗа булган Казахстан гүзәле Нелли Кимның да әнисе татар хатыны.

Гомумән, нәфис гимнастикадагы татар канлы кызларны санасаң, йөздән артык спортсменкага тап буласың. Алар турында горурланып сөйләп була.

**Әдәбият**

1. Нәбиуллина Н. Ләйсән – язның яңгыры // Идел. – 2010. – № 3. – Б. 60-64.
2. Рәкыйпова Р. Ялгыз чыгышларга кайтыр идем// Татарстан. – 2012. – № 1. – Б. 60-61.
3. Спортивная гордость Татарстана. – Казань: «Идель-Пресс». – 2007. – 368 с.
4. Шакир С. Чемпион кыз Галимә // Казан утлары. – 1979. – № 5. – Б.129-135.

## ҚАЗАҚ ЖӘНЕ ТАТАР ТІЛДЕРІНДЕГІ «АЙ» ЛЕКСЕМАСЫНА ҚАТЫСТЫ АНТРОПОНИМДЕР

*Сыздықова А., ҚазҰУ, ІІІ курс студенті*
*Ғыл. жет. – филол. ғыл. канд. Қортабаева Г.Қ.*

Әр халықтың есімдерінің өзіндікқызықты әрі бай тарихы, өзіндік салт-дәстүрі мен пайда болу мотивтері бар. Ұсынылып отырған мақалада қазақ және татар тілдеріндегі «Ай» лексемасына қатысты

антропонимдер атап көрсетіледі. Түркі халықтарындағы «Ай» символының мәні сұлулық екені мәлім болды. Мақалада қазақ және татар тілдеріндегі ортақ және ерекше «әйел есімдері мен ер есімдері салыстырылады, олардың мағынасы ашып көрсетіледі.

Түркі халықтарының тіл білімінде жан-жақты зерттеліп, ғылыми негізі қаланған ономастиканың күрделі бір саласы – антропонимика. Антропонимика кісі аттары, әке аты, фамилиялар, лақап аттар, бүркеншік аттарды зерттейтін ономастиканың бір саласы.

Антропонимдер жүйесі адамдардың өткендегі тұрмысын, қоғамдық-әлеуметтік құрылысын және материалдық әрі мәдени өмірдің құбылыстарын да көрсете алады. Олардың кейбір топтары қазақ ауылының ертедегі тіршілік, іс-әрекетінен және шаруашылық күйінен мағлұмат береді.

Ономастиканы зерттеудің теориялық-әдістанымдық негіздері мен тілмен сабақтастықта қарастырылатын ұлттық этномәдени, әлеуметтік сипатын анықтаудың қажеттілігін В.В. Радлов, В.В. Бартольд, Н. Катанов, А.Н. Самойлович, Қ. Жұбанов, Ш.Ш. Сагаутдинов, Г.Ф. Саттаров, Т. Жанұзақов, Г. Қортабаева т.б. ғалымдар өздерінің еңбектерінде жан-жақты көрсетті.

Ай – түркі халықтарының өмірінде салт- ғұрыптар мен наным-сенімдер жүйесінде ерекше орны мен мәні бар аспан денелерінің бірі. «Ай – ең алдымен, қазаұтардың исламға дейінгі байырғы дүниетанымындағы киелі руз иесі ретінде мінажат еткен аспан денесі» [2: 75]

Ғалым Т. Жанұзақов өзінің «Қазақ есімдерінің тарихы атты еңбегінде былай дейді: «Бұл дәуірде үй хайуандары мен жабайы аңдардың, табиғат атаулары мен өсімдіктердің және қымбат металдардың атаулары кісі аты ретінде қойылып отырған. Мысалы: *Айкүн, Айжарық, Айтолық, Айтолды, Күнай, Күнсұлу, Күнтуар*» [3: 24].

Г.Ф. Саттаровтың еңбегінде мынандай есімдер беріледі: *Айбаш, Айбек, Айбикач, Айбул, Айгына, Айгул, Айдай, Айдак, Айзада, Айзак, Айдаш, Айзухра, Айназ* және т.б.

Ш.Ш. Сагаутдинов өзінің «Татарские имена: происхождение, значения, примеры» атты еңбегінде «Ай» лексемасына қатысты мынадай анықтама береді: «В древнетюркском языке слово ай (месяц) имело следующие переносные значения: «красивый, ценный; святой; чистый, светлый, лучистый; умный; дорогой; обильный; счастливый; полный» и др. По древнему обычаю, ребенку, родившемуся во время сияния луны или полнолуния, давалось имя, в состав которого входило слово ай. Компонент ай часто встречается в именах со сложной структурой» [4: 27]

Фольклорлық дәстүрде нәрестенің немесе сұлу қыздың жүздерін жаңа туған Айға немесе толған Айға балап айту ең көп ұшырайтын дәстүрлі теңеу (*туған Айдай, туған Айдай иілу, туған Айдай балқу, туған Айдай толқу, он бестегі Айдай, толған Айдай толықсу, Ай дидарлы және* т.б.).

Қазақ халқы ерте кезден-ақ аспан жұлдыздарын бір-бірінен ажырата білген, әрі мифтік танымға сәйкес табынған. Осымен байланысты аспандағы ай сияқты жарық болсын деген мағынада кісі есімдері қойылған: *Айсұлу, Айжарық* т.б. Осы құбылыстың болуына бастама болсын деген мағынаға байланысты: *Айтуар, Күнтуар,* т.б.

Зерттеуде қолданылған еңбектерге сүйене отырып екі тілде де кездесетін және ерекше есімдерді төменде жазып көрсеттік.

Екі тілде де кездесетін ер есімдері: *Айзат, Айкын/Айқын, Айморат/Аймұрат, Айморза/Аймырза, Аймөхәммәт/Аймұхаммед, Айташ/Айтас, Айрат, Айтимер/Айтемір, Айтуган/Айтуған, Айтуар, Айчуак/Айшуақ, Айбар, Һәйбәт/Айбат, Айбаш/Айбас, Айбул/Айбол, Айбек, Айбулат/Айболат, Айдар, Айегет/Айжігіт, Айдан, Айгали/Айғали, Айдин/Айдын.*

Екі тілде де кездесетін әйел есімдері*: Айбану, Айбикач/Айбикеш, Айгөл/Айгүл, Аййолдыз/Айжұлдыз, Айзада, Айҗамал/Айжамал, Айниса, Айнура/Айнұра, Айсара, Айсылу/Айсұлу, Айназ*.

Тек татар тілінде кездесетін есімдер: *Айбак, Айгиз, Айгизәр, Айбуга, Айбүләк, Айваз, Айвар, Айгужа, Айгына, Айдай, Айдак, Айгол, Айзәк, Айкай, Айсар, Айсаф, Айтирәк, Айчура, Айшат, Айшөһрәт, Айтулы, Айдынбикә, Айзифа, Айкаш, Айсабах, Айсөяр, Айсунә, Айчәчәк, Айчибәр, Айчирә, Айшөһрәт, Айбанат, Айдарсылу, Айсолтан, Айзирәк, Айсурат, Айлы, Айсың, Айзөһрә, Айбүләк, Айгизә*.

Тек қазақ тілінде кездесетін есімдер: *Айжарқын, Айжас, Аймат, Аймағамбет, Аймақ, Аймауыт, Айсауыт, Айымбет, Айқыз, Айман, Айкенже, Айғаным, Айдай, Айдара, Айдария, Айжайна, Айдана, Айдәния, Айжақсым, Айым, Айшолпан, Айпара, Айнақан, Айсәуле, Айсипат, Айтолды, Айтолқын, Айтолыс, Айша.*

Қорытындылай келе, «Ай» лексемасына қатысты атаулар түркі халықтарының ежелгі дәуірінде наным-сенімдерге байланысты пайда болып, одан келе-келе түркі халықтарының фольклорлық шығармаларында көрініс тауып, күні бүгінге дейін антропонимдерде кездеседі.

**Әдебиет**

1. Қортабаева Г.Қ. Түркі ономастикасы. – Алматы, «Қазақ университеті», 2017.

2. Жанұзақов Т. С. Қазақ есімдерінің тарихы. – Алматы, Қазақ ССР-ның «Ғылым» баспасы, 1971. – 215 б.

3. Сагаутдинов Ш. Ш. Татарские имена: происхождение, значения, примеры. – Алматы, 2011.

# ФОАТ ГАЛИМУЛЛИННЫҢ ӘДӘБИ-ТӘНКЫЙДИ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ РЕЗЕДА ВӘЛИЕВА ИҖАТЫ

*Тимофеева Т., КФУ, Алабуга институты, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Габидуллина Ф.И.*

Күренекле әдәбият галиме, тәнкыйтьче, язучы, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Фоат Галимуллин әдәби тәнкыйть мәйданына узган гасырның җитмешенче елларында килеп керә, әлеге өлкәдә актив эшчәнлек алып бара һәм иң оста тәнкыйтьчеләрдән берсе булып танылa.

Ф. Галимуллин тәнкыйди мәкаләләрендә XX һәм XXI гасыр татар сүз сәнгатен үстерү һәм саклауга зур өлеш керткән әдипләрнең, шагыйрьләрнең иҗади эшчәнлекләренә үзенең бәясен бирә. «Һәр кеше үзе бер дөнья тәшкил иткәндәй, һәр шагыйрь бары тик үзенчә булганда гына сәнгатьчә яңа дөнья тудыра ала» [1: 316], – дип яза тәнкыйтьче. Әлеге мәкаләбездә Ф. Галимуллинның танылган татар шагыйрәсе Резеда Вәлиева иҗатына багышлап язылган мәкаләләренә тукталып үтәрбез.

«Шундый киң күңелле, искиткеч затлар була: аларның иң асыл сыйфаты – кешеләрне ярату» [2: 105], – дип башлый Ф. Галимуллин үзенең «Шагыйрә йолдызлыгы» дип аталган мәкаләсен. Тәнкыйтьче фикеренчә, Р. Вәлиева – тормышны үз итүче, яшәешнең яхшы якларын күрә белүче шәхес. Ул һәр күренешне күңеле аша үткәрә, башкаларның хис-кичерешләрен сизгер тоемлый; тирә-як, табигать биргән гүзәллекләрдән тирән ләззәт алып кына калмыйча, үзе дә матурлык тудыра, шуңа омтыла. «Р. Вәлиева үзе килеш-килбәте, йөз сызыклары, күз карашы, сөйләме белән нәкъ менә лириканың кешедәге гәүдәләнеше булып тоела... Әйе, ул, – кеше буларак та, бөтен барлыгы белән лирика гәүдәләнеше» [1: 373].

Р. Вәлиеваның иҗатында да әйдәп барган тема ул – мәхәббәт, туган җиргә, табигатькә, телгә, хезмәткә, кешеләргә карата ихтирамлылык, миһербанлылык. Мөгаен, шуңадыр аның шигырьләре халык тарафыннан яратып укыла, көй-моң чыгаручыларны да җәлеп итә. Ярату, мәхәббәт хисләре белән сугарылган шигырьләрне һәркем үзенчә кабул итә, чөнки әлеге хис-кичерешләр һәркемнең күңелендә урын алган. «Тик теләсә кайсы кеше аларны шушылай матур, камил итеп кенә әйтеп бирә алмый. Резеда Вәлиева исә – шуларны шагыйранә бер хозурлык белән бәян итү остасы», – дип югары бәяли Ф. Галимуллин шагыйрәнең иҗатын.

*Җырлап киләм мәхәббәтем – җырларымны,*
*Күңелемә сарган шатлык-моңнарымны.*
*Бүләк булсын сиңа сулмас йөрәк җырым,*

*Әй кадерле, әй сөйкемле Туган җирем!*

Фоат Галимуллин шагыйрәнең язу стиленә дә игътибар итә. Тәнкыйтьче фикеренчә, Р. Вәлиева катлаулыны үтемле, гадәти, аңлаешлы итеп укучыга җиткерә белә, шуңа күрә дә аның әсәрләре ансат укыла, хәтердә кала. «Алар ак болыт кебек җиңел, саф тоела. Рифмаларына төгәллек, иплелек хас... Бу – чын талант галәмәте» [2: 106].

Р. Вәлиева – барыннан да элек балалар язучысы. Татарстан китап нәшриятында балалар өчен китаплар чыгару редакциясендә эшләү аның иҗатында эзсез калмый. Шагыйрәнең садәлеге, күңел сафлыгы, тормышны, кешеләрне яратуы, киләчәккә өмет белән каравы аның дөньяны сабыйларча самимилек белән күрүче булып калуына зур йогынты ясый. Тәнкыйтьче «Сүз сәнгатебезнең матур бер бизәге» мәкаләсендә Р. Вәлиеваның балаларга һәм яшүсмерләргә атап чыгарылган «Йолдызстан батыры» исемле китабын анализлап уза.

Китапның «Без – беренчеләр!» дигән бүлеге балалар өчен язылган шигырьләрдән тора. Шагыйрә балаларның саф күңелендә мәгънәле уйлар, изге ниятләр барлыкка китерергә омтыла. Ул балаларны турыдан-туры нәрсәгә дә булса өндәми, игелекле гамәлләрне үрнәк рәвешендә генә әйтә. Р. Вәлиеваның лирик геройлары чәчәкләр тәрбияләп үстерәләр, әниләренә җырлый-җырлый чәчәкләр алып киләләр, иң кадерле кешеләрен туган көннәре белән котлыйлар.

Китапта шагыйрәнең Муса Җәлилнең батырлыгын сурәтләүгә багышланган «Шагыйрь турында җыр» исемле поэмасы да урын алган. Тәнкыйтьче Р. Вәлиеваның поэмасын М. Җәлилнең шәхесен һәм батырлыгын тасвирлаган әсәрләрнең беренчеләреннән һәм уңышлыларыннан саный. «Кылган гамәлләре белән үк үлмәс җырга тиңләшердәй бөек хәтер калдырган шәхесебез Муса Җәлилгә карата шундый дулкынландыргыч поэма язган Резеда Вәлиева иҗаты да сүз сәнгатебезнең бер матур бизәге булып әверелде» [1: 377], – дип яза Ф. Галимуллин.

Р. Вәлиева каләменең зурлар күңелендә урын алырлык күп кенә матур-матур әсәрләр иҗат итүен дә билгеләп үтә тәнкыйтьче, чөнки «чын талант иясе үзен барлык буыннар алдында да җаваплы итеп тоючан була» [2: 107]. «Якты йолдызым», «Язгы сулар», «Шиңмәс чәчәкләр», «Якты яр», «Китмә, сөю» кебек китаплар нәкъ менә зурлар өчен язылган.

Ф. Галимуллин Р. Вәлиеваның иҗаты популяр булуның тагын бер сәбәбен, аудиторияне сизгер тоеп, аның игътибарын җәлеп итеп шигырь укуында, әсәрләрен яттан сөйләвендә күрә. Шагыйрә очрашуда катнашучыларны шигырьләрен тыңлата белә, шул рәвешле укучы

белән үз арасын якынайта. «Ышанам, Резеда Вәлиеваның әдәбият күгендә үз йолдызлыгы бар һәм аның гомере озын булыр» [2: 107], – дигән яхшы теләктә тәмамлана Ф. Галимуллинның «Шагыйрә йолдызлыгы» дип аталган мәкаләсе.

Шулай итеп, Ф. Галимуллин әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлын яктыртып язган мәкаләләре белән хәзерге әдәбият фәнен, тәнкыйтен үстерүгә, баетуга зур өлеш кертә. Аның әдәби, фәнни һәм тәнкыйди хезмәтләре бүгенге буынга да, киләчәк буыннар өчен дә XX гасыр татар әдәбиятының үзенчәлекләре, хәзерге заман әдәби хәрәкәте, иҗат атмосферасы хакында шактый бай мәгълүмат бирүче кыйммәтле мирас булып тора.

**Әдәбият**

1. Галимуллин Ф.Г. Рухи хәзинәләр гасыры: фәнни, публицистик мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 399 б.

2. Галимуллин Ф.Г. Эзләнү вакыты. – Казан: Мәгариф, 2005. – 247 б.

## ҖИРЛЕГЕБЕЗ СӨЙЛӘШЕНДӘ ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕ

*Фәхртдинова Р., КФУ, I курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. доц. Юсупова А.Ш.*

Мәкаль – хикмәтле сүзгә йомгакланган, тирән фикергә корылган тотрыклы образлы гыйбәрә, вакыйга яки ситуацияләргә охшашлык һәм тәңгәллек нигезендә бәя бирүгә хезмәт итә торган фәлсәфи-дидактик хөкем. Урынлы кулланганда бу хөкем кире кагылгысыз хакыйкать һәм бәхәскә урын калдырмый торган өлге-норма буларак кабул ителә, чөнки мәкальләр – халыкның күп буыннар тарафыннан сыналган акыл һәм тәҗрибә җимешләре.

Дөньяда телсез яки җырсыз-моңсыз халык булмаган кебек, мәкальсез халык та юктыр. Һәркайда, һәр халыкта үз мәкальләренә хөрмәт бар, аларга ышану, таяну бар. Безнең халыкта да шундый ук хәл: татар сөйләшкәндә сүз арасында урынына карап, фикерне куәтләү өчен кыска гына һәм килешле генә итеп, хикмәтле бер мәкаль әйтеп куя. Ул моны әйтеп җибәргәнен кайчак үзе дә сизми кала. Шуның белән безнең халкыбыз арасында да саны әлегә кадәр беленмәгән күп төрле мәкальләр йөри. Һәр халыкның мәкале үзенчә. Аның кайчан туа башлаганы билгесез, авторлары исемсез. Тормыш булган һәм халык яшәгән җирдә аның тууы гаҗәп түгел, чөнки кеше үзенең табигате буенча шагыйрь, үзе тәҗрибә һәм иҗат иясе.

Чүпрәле төбәгендә кулланылышта булган мәкальләр бихисап. Җирлегебез сөйләшендә әлеге тапкыр сүзләрне урамда да, өйдә дә, мәктәптә татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә дә еш ишетергә туры килә. Мисал өчен, хезмәт сөючеләргә, тырышып эшләүчеләргә

багышланган бик күп мәкальләрне генә алыйк: “*Ике бите белән йир себерә”, “Кенне тенгә йалгап эшли*”. Шулай ук теләмичә эшләүче кешеләр, башкарылмаган эшләренә сәбәп табучылар, ялкаулар турында да үзенчәлекле мәкальләр яшәп килә: “*Бии белмәгән айуга урын тар”, “Херәсән ялкаwы”, “Эшсез кеше эш калдыра”, “Әлкән-сәлкән эшләүце”, “Йукны бушка тияүце”. Араларында* ялкау кешеләрнең үзләрен аклау өчен кулланыла торганнары да бар: *“Укып мулла булмассың, цукып карга булмассың*”.

Туганлыкка, дуслыкка, гаилә мөнәсәбәтләренә кагылышлы мәкальләребез дә шактый күп. Туганлык авыр минутларда үзен күрсәткәндә – *“Йан тартмаса, кан тарта”*, туганнарның ярдәмгә килергә әзер торуларын – *“Ике бармак арасына ит үсми”, “Үзеңнеке үз итмәсә, ятлар бигрәк үз итмәс*” дигән мәкальләр, баҗалар арасында татулык булмаганда – *“Кәзә хайван тигел, баҗа туган тигел”* кебек мәкальләр кулланыла. Ике арада нык дуслык булганда *“Кыл да сыймый, кисап та тукрамый*” диләр. Гаилә корырга ниятне, өйләнүне – *“Башлы күзле булу*” дип, ир белән хатынның бер-берсенә тәңгәл килүен – “*Цәйнегенә күрә капкацы*” дип әйтәләр.

Сүзнең нинди зур мәгънәгә, тылсымлы көчкә ия булганлыгы һәркемгә мәгълүм. Яхшы сүз кешегә яшәү дәрте бирә, яман сүз авыруга да сабыштыра. Һәрбер сүзне белеп файдалануның, дөрес куллануның ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеген шуннан аңларга буладыр. Мәсәлән, безнең төбәктә бер-ике сүз урнына озак итеп җавап бирүне – “*Бер ылау сүз*” сөйләде дип, сүзне сөйләгәндә чамасын белеп сөйләргә кирәк булганда “*Кеше ышанмаслык сүзне дөрес булса да сүләмә”* дип, аңлап булмаслык сөйләшүне “*Кирле-хутлы сүләшү*”, бер сүзне дә төшереп калдырмыйча сөйләп бирүне *“Цәцми-түкми сүләү”* дип әйтәләр. Бер үк сүзне ничә тапкыр сөйләгәндә “*Хаман бер балык башы цәни*” диләр, көченнән килмәгән килеш зур вәгъдәләр биргәндә “*Суга алмаган зур күтәргән”* дигән мәкальне файдаланалар, чамалап кына әйткән сүзнең дөрес булып чыгуын “*Кыйык атып туры тиде*”дип әйтәләр, ә кешеләрнең авыр сүзне озак хәтердә саклаулары турында сүз барганда – “*Кул йарасы китә, сүз йарасы китми*” мәкален кулланалар.

Рухи сыйфатлар, холык-гадәткә кагылышлы мәкальләр да җирле халкым тарафыннан еш кулланыла. Нинди генә холыклы кеше булмасын: игелеклеме-усалмы ул, тырышмы-ялкаумы ул, кыяфәте матурмы-ямьсезме – бөтен кешегә дә төгәл һәм җитди итеп бәя бирә ала торган мәкальләр бар. Мәсәлән, төрле кешедә төрле холык булуны – “*Биш бармак та тигез тигел*” дип, бик бәйләнчек кешегә “*Чыршы цәере”* дип, географияне яхшы белмәсә дә, бүтәннәргә киңәш бирергә

яратучыга "*Мунчалидан Буа туры*" яисә "*Әндридән кала туры"* дип, гәүдәсен туры тотучыга "*Уклау йоткан"* дип, гау чыгаручы кешене "*Кыткы башы кыдагый*", бар нәрсәгә битараф кешене "*Ике ден'йа бер мерзә*" дип, ә яхшы кеше турында "*Асыл кеше цырайыннан билгеле*" дип әйтәләр.

Мәкальләр халыкның бөеклеген, акыл иясе булуын, зирәклеген күрсәтә. Халыкның тыйнаклык турында да зирәк мәкальләре шактый күп. "*Үзеңне үзең мактама, сине кеше мактасын". "Кешедән келмәк, үзеңә килмәк".* Туган ил-халыкның бишеге ул. Аның белән кешенең бөтен тормышы, гомере бәйле. Шуңа күрә туган ил халык өчен бар нәрсәдән дә кадерле, газиз. Бу гасырлар буе телдән-телгә, буыннан-буынга күчеп килгән мәкальләрдә дә тирән чагылыш таба. Мәсәлән, "*Алтын-кемеш йауган җирдән туган-үскән ил артык*", "*Сыйр да үз ашаган урнына кат'а", "Үз илендә чыпчык та үлмәс*", "*Иленнән айрылган-канаты кайрылган", "Рахат' булса да торган җир, сагындыра туган ил".* Халыкта: "*Кәгазьгә язылмаган гыйлем югала"* дигән мәкаль дә бар. Безнең борынгы бабаларыбыз моны яхшы аңлаганнар. Башта телдән телгә сөйләп, аннары кульязма китапларга язып, "фикер җәүһәрләре" булган мәкальләрне безнең көннәргә кадәр китереп җиткергәннәр.

Халкыбызның гап-гади сүздән мәкаль рәвешендә шундый бизәк ясый алуына мин ихлас сокландым. Бөек шагыйребез Г. Тукай: "Халык – шагыйрь ул", – дип юкка гына әйтмәгән икән. Чыннан да, халык авыз иҗаты әсәрләре бервакытта да искерми. Ул халыкның җанлы сөйләмендә хәзер дә кулланыла, безгә акыллы киңәшләр бирә, дөрес фикер йөртергә өйрәтә; туган җиребезгә мәхәббәт, эти-әнигә, олыларга хөрмәт, сабырлык, тыйнаклык кебек күркәм сыйфатлар тәрбияли. Минемчә, мондый зур хәзинәле халыкның киләчәге якты.

**Әдәбият**

1. Ахатов Г.Х. Мишарский диалект татарского языка: Уч. пособие. / Г.Х. Ахатова. – Уфа: Изд. Башкирского гос. Ун-та, 1977. – 76с.

2. Гафаров И.Ә. Мишәрләр.Тарих һәм тел. – Казан: Идел-Пресс, 2011 ел. – 256 бит.

3. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казань. Татарское книжное издательство, 1987.

# СХОДСТВА И ОСОБЕННОСТИ РАЗНЫХ ЛИНГВОКУЛЬТУР И НАРОДОВ

(на примере иранской, татарской, русской культуры и народов)

*Фороутан Гхазвини Саба, КНИТУ им. А.Н. Туполева, студент 1 курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Зиннатуллина Г.Ф.*

В иранском обществе, в разных городах, есть возможность посмотреть разные культуры и даже языки, которые их география влияла на людей, на их культуру и на то, как они думают. Город Йезд находится в центре Ирана, в пустыне Йезд-Ардакан. В 2016 году традиционная текстура Йезда зарегистрировано ЮНЕСКО. Цивилизация Йезда восходит к третьему и четвертому тысячелетиям до Рождество Христова. Он второй исторический город в мире после города Венеции. В древние времена племена мигрировали из Балха в Персию, назвали город Йезд, это означает Бог.

Йезд – первый кирпичный город. Погода Йезда очень жаркая. Там бывает только лето и весна, максимум 50 градусов и минимум 15-20 градусов по цельсию. Погода влияла на архитектуру. Двор находится посередине дома и ниже уровня улицы. В центре двора есть большой бассейн, вокруг деревья, которым нужно немного воды, например, гранат, виноград, инжир и фисташка. Архитектура двора и деревья играют важную роль в охлаждении воздуха. Центральный двор показывает, что жители Йезда интроверты. Семья собирается во дворе и дети играют. На самом деле двор похож на зал. Гости относятся с большим уважением к культуре Йезда, поэтому у них есть отдельный зал для гостей.

Механизм охлаждения воздуха в архитектуре Йезда называется “Бад гир” на персидском языке. Прежде чем рассказать о “бад гир”е, я должна объяснить “Аб анбар”: Это большой подземный бассейн, окружающий весь дом. Чтобы пропускать воздух и сохранять воду прохладной, на нем построили от одной до шести “бад гир”. Ветер попадает в “бад гир” и проходит через бассейн, затем входит в дом. Погода в Йезде сухая и жаркая, поэтому механизм бад гира охлаждает и увлажняет воздух.

В городе Йезде дожди бывают редко. Поэтому предыдущие поколения доставали воду очень трудно. Несколько тысяч лет назад древние иранцы изобрели механизм акведука (за тысячу лет до Рождества Христова). На персидском языке называется “Ганат”. Вдали от городов находился подземный источник воды. Пробурена первая скважина на подземном источнике. Затем нужно продолжать бурение скважины пока вода не достигнет земли. Акведук “Ганат” Зарча в Йезде – самый длинный акведу в мире, его длина сто километров с 2115 скважинами. Ему более 2000 лет.

В Йезде можно посмотреть много ремесел. К сожалению, некоторые искусства были забыты на протяжении истории. Ковровое искусство – самое важное, потом кашемир «Терме» – очень красивое и популярное искусство. Искусству «Терма» 500 лет. Первый раз

зороастрийцы использовали «Терме» для костюмов в счастливых торжествах. Мотивы, использованные в «Терме» - это цветы, называются “Джеге”. Искусство живописи “Джеге” началось в Ассирийскую эпоху и закончилось в эпоху Ахеменидов (3000-5000 лет до Рождества Христова). Многие верят, что в “Джеге” показан персидский кипарис. Зороастрийцы использовали этот кипарис, и он является символом свободного и скромного Ирана. Гончарное дело – еще одно процветающее искусство Йезда.

В Татарстане шьют красивую национальную обувь, называется «Ичиги». Мастерами ичигов знаменит маленький город в Татарстане – Арск. Их узоры очень красивые, похожи с иранскими.

Традиционное и очень популярное блюдо в Йезде – щули. Сначала нарезаем свеклу кубиками и варим. Когда она сварится добавляем чечевицу, затем – зелень со шпинатом. В это время смешаем муку с холодной водой и добавляем в щули, постоянно помешивая. Щули подается с уксусом или гранатовой пастой.

Я немного знакома с русскими блюдами, как например, борщ. Борщ – разновидность супа на основе свеклы, которая придает ему характерный красный цвет. Это традиционное блюдо восточных славян. Очень люблю его готовить. Это любимое блюдо нашей семьи.

Справа от Йезда находится пустыня Йезд-Ардакан, а слева горный массив Ширкоох. По этой причине Йезд имеет разную и противоречивую природу. Природные достопримечательности Йезда очень редки, например:

1) Дерево кипариса, которому, по словам ученых, более четырех тысяч лет. Высота этого дерева 25 метров и диаметр ствола дерева 4.5 метра. Этот кипарис – второе живое существо на земле.

2) Ступенчатые пружины: из-за различных солей, серы и железа в воде, со временем и из-за седиментации, она сформировалась в ступенчатые бассейны.

3) Река Мортеза Али: вода из трех источников смешалась и это река вытекала из него. Первый источник – холодная вода, а второй источник – горячая вода. Очень интересно: холодная и теплая вода не смешиваются через реку.

4) В конце реки находится исторический памятник, назвали плотина Шах Аббас. Это плотина восходит к эпохе Сефевидов, ей 500 лет. В дороге вы увидите дыры в горе, которые соединены туннелем. Эти дыры, назвали Дом Габера. “Габер” – это зороастрийское слово. Они относятся к эпохе Сасанидов, и ей 1500 лет. К сожалению, об этом мало написано.

Из детства, мои родители любили путешествовать, поэтому мы ездили по городам Ирана. А Россию я видела два раза: первый раз в феврале 2016 года, а второй раз в декабре 2017 года. Путешествия и культура – мои любимые интересы. Я закончила химико-технологический университет в Иране и решила поступить в аспирантуру в России, потому что мне очень нравится русская культура. Сейчас я изучаю русский язык в Международном подготовительном отделении Института международного образования Казанского национального исследовательского технического университета имени Андрея Николаевича Туполева. Наконец, у меня будет возможность больше узнать о культуре России и их народов.

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МӘДӘНИЯТАРА КОМПЕТЕНЦИЯ ФОРМАЛАШТЫРУ

*Хәмзина А., КФУ, III курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сибгаева Ф.Р.*

Хәзерге вакытта җәмгыять һәм мәгариф өлкәсе үсеше тенденцияләре кеше тормышында мәдәниятара бәйләнешләр көчәюгә юл ача. Мондый шартларда без башка тел вәкилләре белән үзара яхшы элемтә булдырырга тиешбез. Ләкин һәрвакытта да моны уңышлы башкарып чыгып булмый. Шуңа күрә яшь вакыттан ук мәдәниятара компетенция булдыру бик мөһим. Мәктәп укучыларында әлеге компетенцияне формалаштыру хәзерге көндә педагогик теория һәм практиканың актуаль соравы булып тора.

Мәдәниятара компетенция мәсьәләсе татар, рус һәм чит ил галимнәренең күпчелек тикшеренүләрендә өйрәнү предметы булып тора. К.С. Фәтхуллова, Э.Н. Денмөхәммәтова, И.И. Халеева, Н.В. Черняк, Н.М. Громова, Н.Д. Гальскова, Ю. Рот, Р.Д. Льиюс хезмәтләрендә, И.А. Зимняя, И.Л. Бим, А.А. Леонтьев, Е.С. Полат һ.б. тикшеренүләрендә мәдәниятара компетенцияне өйрәнүе чагылыш таба.

Мәдәниятара компетенцияне өйрәнү АКШта 1950 елларда башлана [4: 7]. Чит ил мәдәният вәкилләре белән аралашканда барлыкка килгән коммуникатив уңышсызлыклар галимнәрдә әлеге компетенцияне өйрәнү өчен сәбәп булып тора. 1957 елда Тьюксбери тарафыннан мәдәниятара компетенция термин буларак гамәлгә кертелә [4: 8]. 1960-70 елларда аның методларын һәм формалашканлык дәрәҗәсен бәяләү актив эшләнелә. 1984 елда Б. Шпицберг һәм У. Кьюпач компетенцияне беренче тапкыр эффектив һәм яраклы тотыш дигән караштан тасвирлыйлар. 2010 елга хәтле мәдәниятара компетенция чит тел мәдәниятенә кергәч, үзеннән үзе үсә дигән

карашлар яшәгән. Ләкин П. Педерсен бу процесс белән генә компетенцияне формалаштырып булмый дигән карашын эксперимент белән дәлилли [4: 12]. 2000 еллар башында бөтен илләрдә университетларда мәдәниятара аралашу проблемаларына багышланган курслар ачыла [4: 16]. Шушы ук елларда мәдәниятара компетенция безнең илдә дә актив өйрәнелә башлый.

Мәдәниятара компетенция – ул булган белемнәрне, күнекмәләрне, мәдәниятара багланышлар вакытында эффектив куллану һәм яраклы рәвештә үз-үзеңне тоту [4: 37].

Татар теле дәреслекләрендә мәдәниятара компетенцияне формалаштыру һәм үстерү өчен күнегүләр шактый аз күләмдә бирелгән. Турыдан-туры мәдәниятара компетенцияне булдыру өчен аерым күнегүләр юк диярлек. Шуңа күрә кутучы күнегүләргә үзе өстәмә биремнәр кертергә дә мөмкин.

9 сыйныф дәреслегендә 19 нчы күнегүдә “Татар халкының нинди милли уен кораллары булган? Синең дәү әтиең, карт бабаң берәр уен коралында уйный белгәнме? Синең курайны, гармунны тотып караганың бармы?” дигән сорау куела. Бу рус балаларында татар халкының сәнгатенә кызыксыну уятырга тиеш, шул рәвешле алар мәдәниятне дә өйрәнәләр [3: 13].

Уку әсбапларында башка халыкларның холкын, тәрбия моментларын, мәдәниятен чагылдырган текстларны очратырга мөмкин. Бу укучы балаларда чит ил вәкилләре белән яхшырак элемтә корырга этәргеч бирә [1: 41].

7 нче сыйныф дәреслегендә 229 нчы күнегү укучыларга толирантлык турында текст бирелә. Биредә телләрнең тигезлеге, милләтара ихтирамлылык турында сүз бара. Тексттан соң балаларга “Үзара татулык, ихтирам нәрсәдән башлана?” дигән темага әңгәмә оештырырга тәкъдим ителә [2: 126].

Ләкин мәдәниятара компетенцияне үстерү өчен бу күнегүләр генә җитми. Шуңа күрә укытучы үзлектән биремнәр, грамматик уеннар уйларга мәҗбүр.

Укытучы дәрес үткән көн белән бәйле берәр төрле халыкта нинди бәйрәм үткәнен сөйләп китергә мөмкин. Мәсәлән, 23 апрельдә Төркиядә Балалар яклау һәм милли бәйсезлек көне билгеләп үтелә. Бу көнне балалар дәүләт хезмәткәрләрен эш урыннарында алмаштыралар. Шул рәвешле укучылар төрекләрнең генә түгел, башка халыкларның милли бәйрәмнәре белән танышырга мөмкин.

Балаларга мәдәниятара компетенцияне формалаштырыр өчен грамматик уеннар бигрәк тә ныграк тәэсир итәргә мөмкин. Төрле милләт исемнәрен һәм уен коралларын карточка формасында эшләп,

укучыларга таратырга кирәк. Аларның максаты – кайсы уен коралы нинди халыкка туры килгәнлеген билгеләү. Шундый ук биремне тарихи истәлекләр, танылган кешеләр белән дә башкарырга мөмкин.

Компетенцияне үстерү өчен диалог та мөһим роль уйный. Туристлар, чит ил кешеләре, башка халык вәкилләре белән әңгәмә корырга, итәгатьлелек, ихтирамлык белдерергә өйрәтүне шулай ук читләп узмаска кирәк.

Һәрбер халыкның үзенең ишарәләре бар. Бер мәдәнияттә кулланылган ишарә, башкасында гомумән башка мәгънә белдерергә мөмкин. Шул рәвешле аларны бераз булса да өйрәтү шулай ук комачауламас.

Шулай итеп мәдәниятара компетенцияне формалаштыру һәм үстерү укучыларда кызыксынучанлыкны үз милләтенә түгел, ә башка мәдәниятләргә дә уятуга нигез булып тора. Алар шул рәвешле чит халыкларның вәкилләре белән аралашырга, аларны хөрмәт итәргә өйрәнәләр.

**Әдәбият**

1. Закиев М.З., Ибрагимов С.М. Татарский язык. Учебник для общеобразовательных организаций с обучением на татарском языке 9 класс. – Казань: Татарское книжное издательство, 2015. – 135 с.

2. Максимов Н.В., Набиуллина Г.А.Татарский язык. Учебник для общеобразовательных организаций с обучением на татарском языке 7 класс. – Казань: Татарское книжное издательство, 2015. – 159 с.

3. Сагдиева Р.К., Кадирова Э.Х. Татарский язык. Учебник для общеобразовательных организаций основного общего образования с обучением на русском языке (для изучающих татарский язык как родной) 9 класс. – Казань: Магариф-Вакыт, 2017. – 143 с.

4. Черняк Н.В. Межкультурная компетенция: история исследования, определение, модели и методы контроля. – М.: Флинта, 2016. – 264

## ФАТИХ КӘРИМ ИҖАТЫНДА СӘНГАТЬНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

*Хәмидуллина Э., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Йосыпова Н.М.*

Әдәбият белән мәдәният, сәнгать гасырлар буена бербөтен булып торган. Юкка гына әдәбиятны матур сүз сәнгате димиләр. Әдәбият үз эчендә халык казанышларына таянып, аның традицияләрен дәвам иттерүне күз уңаенда тота. Бу, әлбәттә, мәдәният һәм сәнгать белән бергә үрелеп барганда гына уңышлы була. Әдипләр дә, үз әсәрләрендә халыклар мирасын, аларның үзенчәлекләрен, аерым бер элементларын оста итеп файдаланалар.

Фатих Кәрим – татар әдәбиятында, гомумән, әдәбият өлкәсендә, үз юлын, үз кыйбласын булдырган шәхес. Бөек Ватан сугышы

чорының күренекле вәкиле. Шушы аз вакыт эчендә ул бик бай мирас калдырып китә.

Үзе исә: "Әдәби әсәрләр язу теләге бала чагымнан ук йөрәгемә кереп урнашты. Егет чагыннан ук тома сукыр этиемнең үзе өчен язган шигырьләрен безгә укыштыргалаганын ишетү, апам Мәрьямнең үз дәфтәренә Дим буе табигатен тасвирлап язган күп кенә шигырьләрен башкалардан яшереп миңа гына укуы, абыем Ярлы Кәримнең матбугатта чыгып барган шигырьләрен уку – болар минем әдәбият өлкәсенә табан юнәлеш ясавыма төп һәм башлангыч этәргеч булдылар…" ди [3: 6].

Әтисе үлеменнән соң, ул әдәбиятка тагын да якыная, әнисеннән "Сак-Сок" бәетен укыта торган була. Кече яшьтән үк үз халкының тел үзенчәлекләрен, фольклорын белеп-күреп үсә, күңеле белән шуңа тартылучан була. Әлбәттә, бу аның яшәешенә дә, иҗатына да тирән эз сала. Шагыйрьнең бик күп кенә әсәрләрендә татар халкының “йөзек кашы” булган уен коралы гармун чагылыш тапкан. Татар халкында гармун сүзенең күп кенә сининомнары, төрләре яшәп килә: гармун, тальян, баян, аккордеон. Гармун - күреге, ике якта клавиатурасы булган, тартып уйнала торган тынлы уен коралы [4: 51]. Халкыбызга ничек якын бит ул гармун. Фатих Кәрим дә үз иҗатында татар халкының бар җанын чагылдыра алган бу уен коралын читләтеп үтми. Аның гармунга кагылышлы әсәрләрннән 1929 нчы елда язылган "Гармун турында" шигыре, 1942 нче елда язылган "Кыңгыраулы яшел гармун" поэмасы, 1936 нчы елда язылган "Гармунчы аю белән җырчы маймыл" шигъри әкияте бар.

"Гармун турында" шигырендә лирик герой гармунның ролен югарыга куя, аның кеше язмышында аерым бер үзенчәлекле урын алуын билгели.

*Кайда минем шагыйрьлегем,*
*Тальян гармун моңын сизмәгәч* [1: 219].

Әлбәттә, йөрәк түрендә булган моңнан, көйдән ул биргән илаһиликтән башка шагыйрь чын була алмый, аның шигырьләре мәгънәсез була.

*Гармун безгә күп җырлады,*
*Аз җырладык аның турында,*
*Тукай мәрхүм онытмандыр.*
*Һади Такташ әйтә: – Ерунда* [1: 219].

Әйе, гармун гасырлар буена татар халкының юанычы, сердәшчесе, җан дусты, киңәшчесе була. Гармунның бәясе, кыйммәте, югала баруын күреп әрни шагыйрь. Шагыйрь алга таба үзе гармун турында "җырлый".

*Гармун,*
*Үпкәң зурдыр,*
*Үпкәң зурдыр бик күп кешегә.*
*Чөнки әле Нечкә серләреңне*
*Тик бер Туиш ага төшенә* [1 :220].

Әйе, гармун турында аз язганга күрә, аның барлык нечкәлекләрен белми кеше. Монда лирик герой татар халкының беренче профессиональ баянчысы Фәйзулла Туишевны телгә алып үтә. Ахырда исә лирик герой дусларын, танышларын гармун кебек якын күрүен бәян итә.

"Кыңгыраулы яшел гармун" үзенчәлекле һәм әдип иҗатында якты эз калдырган лиро-эпик поэма булып санала. Яшел төснең яшәү мәгънәсен аңлатуы, дини күзаллаулар белән бәйле булуы күренә. Әсәрдә лирик герой Фазылның бер кызга карап гармунда уйнавы аның эчке тойгыларый, уй-фикерләрен, бар хисләрен, теләкләрен чагылдыручы төп чара булып тора.

*Саратский яшел гармун,*
*Көмеш кыңгыраулары,*
*Бу көмеш кыңгырауларның*
*Кичке яңгыраулары* [2: 85].

Һичшиксез, гармунның үзенә генә хас булган моңы бар. Кеше сүз белән әйтә алмаган хисләрен җыр аша бирә ала. Шуның белән бәхетле гармунчы.

"Гармунчы аю белән җырчы маймыл" шигъри әкият зур игътибарга лаек. Шагыйрь үзе балаларның аңлап белү дәрәҗәсен бик яхшы белеп төзи әсәрен.

*Аю гармун уйный, ди.*
*Юл буйлап киләләр, ди,*
*Буылып көләләр, ди* [2: 49].

Маймыл белән аю образлары аша бер-берсенә охшамаган, төрле типлы, характерлы кешеләрне дә гармун моңы, көе аша дуслаштырып торуы ачык күрсәтелә. Урмандагы башка хайваннар да маймыл белән аю дуслыгына кызыгып карап торуы исә гармунның берләштерү көченә ия булуын күрсәтә.

Йомгаклап әйткәндә, әдәбият белән мәдәният һәм сәнгать һәрвакытта бер система хасил итә. Татар халкының үзенчәлеге булган мәдәни, сәнгати бизәкләр, әлбәттә, әдипләр иҗатында да чагылмый калмаган. Татар халкының бөек улларыннан булган Фатих Кәрим иҗатында да бу шулай ук. Милләтебезнең "йөзек кашы" булган гармун уен коралы да биредә зур урын алып тора. Шуның белән шагыйрь үзенең халкына, милләтенә, аның традицияләренә, аерым бер

бизәкләренә ихтирам белән каравын, аны кадерләвен, аның белән соклануын һәм чиксез горурлануын бәян итә.

**Әдәбият**

1. Мәҗитов З.М. Фатих Кәрим: Әсәрләр. 3 томда, 1 нче том – Казан: Татар. китап нәшр., 1979. – 319 б.
2. Мәҗитов З.М. Фатих Кәрим: Әсәрләр. 3 томда, 2 нче том – Казан: Татар. китап нәшр., 1980. – 327 б.
3. Мәҗитов З.М. Фатих Кәрим: Тормыш һәм иҗат юлы турында очерк – Казан: Татар. китап нәшр., 1963. – 171 б.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: II том: Г – Й. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – 748 б.

## НАСРЕТДИН РАБГУЗИНЫҢ “КЫЙСАСЕЛ-ӘНБИЯ” (XIV г.) ӘСӘРЕНДӘ САННАР КУЛЛАНЫЛЫШЫ

*Хәсбиуллина Г., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Нуриева Ф.Ш.*

Саннар сөйләмебездә актив кулланыла. Алар күләм-чаманы белдерүдән тыш күп халыкларда символик мәгънәгә дә ия. Саннар халыкның легенда, риваять, поэтик һәм тарихи хикәяләр, гореф-гадәтләр, канатлы гыйбарәләр, мәкаль һәм әйтемнәрендә теркәлеп, аерым мәгънәгә ала. Кайбер саннарның сакраль мәгънәгә ия булулары хакында күп халыкларның динендә күрсәтелә. Бу мәкаләдә Насретдин Рабгузиның “Кыйсасел-әнбия” әсәренең “Адәм ата – Һава ана” дип аталган бүлекчәсендә “бер”, “ике”, “өч” саннарының кулланылыш үзенчәлекләре тикшерелә. Бу саннар төрки халыкларның мәкаль һәм әйтемнәрдә еш очрый, һәм алар төрки халыкларда сакланып, дини күзаллаулары хакында мәгълүмат бирә.

“Адәм ата – Һава ана” – дини эчтәлекле хикәя. Ул “Кыйсасел-әнбия” әсәренең бер өлешен тәшкил итә. “Адәм ата – Һава ана” хикәясе Рәхимле һәм Бар нәрсәне гафу итүче 18000 дөньяны, үзенә табынырга Адәмне барлыкка китерүче Аллаһыга рәхмәт сүзләреннән башлана. Адәмнең барлык кешелекнең нәсел башлыгы икәнен истә тотып, әсәрдә җентекле тасвирлама бирелә. Хикәя Аллаһның гөнаһсыз фәрештәләр белән әңгәмәсеннән башлана. Мисалларга мөрәҗәгать итик.

Бер саны.

“Мин җирдә бер башлык тудырырмын. Аны бөтенесе арасында сайланган итәм!” – дип әйтелә әсәрдә [3: 235]. Мондагы “бер” саны бөтен кешелекнең башлангычы бер кеше булуына ишарә итә.

Яшерен дини мәгънәләр төрки халыкларның ышануыннан барлыкка килә. Галәмдә барысы да “бер"дән башлана һәм "бер" белән тәмамлана. Структур компонентында “бер” саны булган мәкальләр һәм әйтемнәр төрки халыкларның мәдәниятләрендә шул рәвешле кешегә аңлаешлы мәгънәне – галәмне, бар булганны яки когнитив аңда

Аллаһы Тәгаләне чагылдыруны күз алдында тота. Ислам динендә “бер” саны Аллаһы Тәгаләне – Бер Алла дип белдерелә.

Мәсәлән, татар халкы сөйләмендә еш кулланыла торган “Бер һәм бар Аллаһы Тәгалә” дигән гыйбарә бар. Шулай ук “Барысы да бер Аллаһтан тора” дип әйтә татар халкы.

Казах теленнән мисаллар: «Жалғыздық бір Құдайға ғана жарасқан» (Ялгызлык бер Аллаһка гына килешә) [4: 39]; «Кірсіз күн мен ай, мінсіз бір Құдай» (Керсез кояш белән ай, кимчелексез бер Алла) [4: 223]; Төрекләрдә дә татар халкында кебек әйтәләр: «Bir kararda bir Allah» (Бар нәрсә дә бер Алладан тора) [5]; Шулай ук төрекләр мондый әйтем дә бар: «Allah isterse bir kulun işini, mermere geçirir dişini; istemezse işini, muhallebi yerken kırar dişini» (Аллаһ теләсә бер колыннан, аның кушуы буенча, йомшак ашаудан да тешне сындырып була) [5]. Әлеге мисаллардан күренгәнчә, ислам диненә бәйле “бер” саны сакраль мәгънәгә ия.

Ике саны.

"Ике" саны “бер” санына хас булган бердәмлекне күплек мәгънәсенә әверелдерә. Аллаһ башкаларны парлап яраткан. Насретдин Рабгузи әсәрендә Аллаһы Тәгалә тарафыннан ике төрле халык яратылганы языла [3: 233].

Төрки телләрдәге “бер” саны кергән мәкальләр “ике” саны белән тулыландырыла. Мәсәлән, татарларда “Бер димичә ике диелмәс” мәкале бар [6]. Көнкүреш тормышның нинди тәртиптә баруы хакында “ике” саны кергән “Бер елда ике яз булмый” мәкалендә әйтелә. Казах телендә “ике” белән бик кызыклы гыйбарә мисалы: Алладан сұрағанның екі бүйірі шығады, адамнан сұрағанның екі көзі шығады (Алладан сораганның ике ягы чыгадыр, адәмнән сораганның ике күзе чыгадыр) [4: 65]; Шулай ук төрек телендә татар халкы куллана торган мәкальләргә охшаганнары бар. Birtaşla iki kuş sürün (Бер таш белән ике кошны сөрү) [5]; İkiölç, bir biç (Ике үлчә, бер кис) [5].

Өч саны.

"Өч" - еш кына мәдәнияттә, бигрәк тә дини ышануларда кулланыла торган мөһим сан. Хикәядә “өч” саны түбәндәге сюжетларда кулланыла: Аллаһы Тәгалә кешене барлыкка китерергә карар кылгач, Газраил өч тапкыр Җир янына килгән, соңгысында исә болай дигән: “Син Аллаһка өч тапкыр каршы килдең. Синнән килеп чыккан бөтен нәрсә тиздән гөнаһлы булачак". Шул сүзләр белән ул Җир өстеннән бер уч җир ала [3: 240]. Шулай ук Аллаһ Тәгалә Адәмгә тормыш биргәч, ул өч тапкыр "Кер!" дип әйтә. Монда без Насретдин Рагбузиның "Адәм ата - Һава ана" хикәясендә "өч" санын актив кулланылуын күрәбез.

Татар һәм төрек телләрендәге шушы мәкальләрдә "өч" саны очрый: "Үлгәннән соң өч көнлек эш кала" [1, 281], "Кунак – өч көнгә кунак" [2, 629], Misafir üç gün misafirdir [5] (кунак өч көн була); Ölüsü olan üç gün ağlar, delisi olan her gün ağlar [5] (Кеше үлгән йортта өч көн елыйлар, акылсыз булган йортта көн дә елыйлар).

Әлеге мәкальләр "өч" санының чикләү мәгънәсендә булуын күрсәтә, ягъни бу дөньяда һәр нәрсәнең чиге бар.

"Кыйсасел-әнбия" әсәрендә "бер", "ике", "өч" саннары аларның төрки халыкларның диннәре һәм карашлары белән тыгыз бәйләнештә булуын күрсәтә. Без тикшергән татар, казах һәм төрек телләрендә мәкальләрдә һәм әйтемнәрдә саннарның халыкларның гамәли яшәешендә һәм мөселман диненә бәйле яшәешләрендә урын алуы ачык чагыла.

**Әдәбият**


1. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре 3 томда: Том 1. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1959. – 915 б.
2. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре 3 томда: Том 2. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1959. – 915 б.
3. Сагындыкулы Б. Удивительные тайны Вселенной//Хисса Адам ата-Хауа ана- Алматы: Ғылым, 1997. 171-292 б.)
4. Слова предков: Сто томов. – Астана: «Фолиант», 2010. Т. 65: Казахские пословицы. – 488с.
5. https://www.nkfu.com/allah-ile-ilgili-atasozleri-deyimler-ve-anlamlari/


## ТАТАР БАЛАЛАРЫ СӨЙЛӘМЕНДӘГЕ ЛЕКСИК ИНТЕРФЕРЕНЦИЯ КҮРЕНЕШЕНЕҢ ПСИХОЛИНГВИСТИК АСПЕКТЫ


*Хафизова Я.А., КФУ, IV курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Галиуллина Г.Р.*


Хәзерге тел белемендә татар балаларының сөйләмен өйрәнү аеруча актуаль мәсьәләләрнең берсе санала. Сөйләм теле икетеллелек даирәсендә формалашуга бәйле, татар балалары кечкенәдән рус һәм татар тел системаларын үзләштереп үсәләр. Шул рәвешле билингв баланың сөйләмендә телләрнең бер-берсенә тәэсире барлыкка килә. Әлеге үзенчәлек сөйләм теленең фонетика, грамматика, лексика кебек катламнарына да йогынты ясый. Нәкъ менә билингвның бер телнең икенчесенә тәэсире һәм моның нәтиҗәсе интерференция дип атала. Интерференция күренешенә аңлы алынмалар керми, ә бары тик контрольдә булмаган күренешләр генә керә. Кайсы тел төп функциональ тел булуына карап, аның тәэсир көче дә арта [1: 20].

Татар һәм рус телләре арасындагы интерференция күренешенең асылы туган һәм чит телнең аермалы билгеләре буталып, сөйләүче аңында өченче система барлыкка килүдән гыйбәрәт, ягъни туган тел

һәм рус теленең берәмлекләре арасында чынбарлыкта булмаган аналогия урнаштырыла. Бу, үз чиратында, билингв балалар сөйләмендә төрле фонетик, лексик, грамматик һәм башка төрле хаталарга китерә.

Интерференция күренешен тикшергәндә аңа төрле яклап карарга була. Аерым психологик аспектны алганда, С.Л. Рубенштейн аңа мондый билгеләмә бирә: “Интерференция – ул моңа кадәр барлыкка килгән күнекмәләрнең яңалары барлыкка килүне тоткарлый яки аларның нәтиҗәлелеген түбәнәйтә торган очрак” [5: 54].

Моннан да төгәлрәк билгеләмәне А.Е. Карлинский бирә. Ул болай дип яза: “Чит телне үзләштерү автоном рәвештә бармый, ә туган тел белән үзара бәйләнештә уза. Башка бер охшаш эшчәнлеккә өйрәнер өчен кеше һәрвакыт моңа кадәр барлыкка килгән күнекмәләрне кулланырга омтыла. Билгеле, чит һәм туган тел арасында ике телле кешенең сөйләменә уңай яки тискәре тәэсир итә торган үзара бәйләнеш бар” [4: 53]. Психолингвистика күзлегеннән, интерференция барлыкка килүнең төп сәбәбе булып тискәре күчерү тора. Бу күренеш ике тел күнекмәләренең ныклыгы төрле дәрәҗәдә булганлыктан барлыкка килә. Гадәттә, беренче (туган) телгә кагылышлы осталык һәм күнекмәләре икенче, соңрак өйрәнелгән телдәгеләргә карый ныклырак [5: 54].

Лексик интерференция күренеше – иң киң һәм тиз арада таралыш тапкан күренеш. Моның төп сәбәбе: телнең лексик катламына, башка катламнардан аермалы буларак, экстралингвистик факторлар күбрәк тәэсир итә, чөнки лексик катлам ачык система тәшкил итә, шуңа бәйле аның составы даими үзгәреп, тулыланып тора [2: 30].

Лексик интерференция турында Е.М. Верещагин “Психологическая и методическая характеристика двуязычия (билингвизма)” дигән хезмәтендә мондый фикергә килә: нормаль сөйләм өчен темп факторының мөһимлеген игътибарга алганда шул ачык күренә: билингвның сөйләм барышында чит тел сүзен “эзләп табу” авырлыгы туганда, ул – аңлы яки аңсыз рәвештә – барлыкка килгән “бушлыкны” беренче (туган) телдә актуальләшкән лексема белән ябарга тели [2: 86].

Югарыда әйтеп кителгәнчә, чит телдә туган тел интерференциясе көчлерәк, чөнки бала гаиләдә, беренче чиратта, туган телен үзләштерә. Әмма тикшерү обьекты итеп алган 5-9 яшьтәге татар балаларының спонтан сөйләме тупланган аудиоязмалар нигезендә, киресенчә, хәзерге татар балалары сөйләмендә татар телендә рус интерференциясе күбрәк урын алганлыгын, ягъни рус теле күнекмәләре ныклырак, аларны куллану ешрак дигән нәтиҗәгә килдек. Информантларның барысының да сөйләмендә рус теленнән әзер килеш үтеп кергән лексемалар кулланыла. Мисал өчен: ***А ещё*** *бүген минем*

*әбинең туган көне* (6 яшьлек информант); *Бүген Лилианалар белән уйнарга чыкмадым,* ***потому что*** *алар мине чакырмадылар* (8 яшьлек информант); *Хәзер мин* ***куклалар*** *белән уйныйм* (4 яшьлек информант).

Кайбер балалар сөйләм барышында, гомумән, тулысынча рус теленә күчәләр. Мәсәлән: ***Если ты со мной поиграешь****, то мин еламыйчакмын* (4 яшьлек информант); *Ну, белмим инде,* ***просто бывает так, что научилась*** (9 яшьлек информант); ***Да, понятно, понятно!*** (6 яшьлек информант). Әлеге сөйләм фрагментларын анализлаганда, чыннан да, күпчелек бала, нормаль темпта татарча сөйләшкәндә, кайбер сүзләрне онытып яки аларның татарча тәрҗемәсен белмичә, рус сүзләрен, сүзтезмәләрен яисә тулаем русча җөмләләрне кулланганлыгын күзәттек. Ягъни туган телдәге сөйләм барышында балалар сүзне оныткалыктан яки белмәгәнлектән, аңда барлыкка килгән "бушлыкны" икенче (рус) теленең тел берәмлеге белән "ябалар". Моның сәбәбе, үз чиратында, югарыда әйтелгән ике телнең күнекмәләре төрле дәрәҗәдә булудан туган кире күчерүгә барып тоташа. Димәк, хәзерге татар баларының туган телдәге сөйләмендә рус лексик интерференция көчле позиция алганлыгына тап була алабыз.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, хәзерге вакытта иң киң таралган тел күренешләренең берсен – лексик интерференцияне психолингвистик аспекттан караганда, аның кеше аңында барлыкка килү механизмын күрә алабыз. Ул кешенең ике тел системасына караган күнекмәләренә һәм аларның формалашуына барып тоташа. Балалар сөйләмендә туган телдә икенче (рус) тел интерференциясе көчлерәк һәм хәзерге балалар өчен рус теле татар теле белән бер дәрәҗәдә функциональ тел булып тора.

**Әдәбият**

1. Беликов В.И., Крысин Л.П. Социолингвистика: Учебник для вузов. – М.: Рос. гос. гуманит. ун-т, 2001. – 315 с.

2. Верещагин Е. М. Психологическая и методическая характеристика двуязычия (билингвизма). – М., 1969.

3. Галиуллина Г.Р. Хәзерге татар сөйләм телендә лексик интерференция күренеше // Tatarica. 2018. – № 1 (10). – Б. 22-35.

4. Карлинский А.Е. Сравнительно-сопоставительное изучение языков интерференция. – Алма-Ата, 1989.

5. Крутобережская А.С., Я.В. Солдатова Интерференция как объект исследования психолингвистики // Международный научный журнал «Инновационная наука». – 2015 – №7 – с.53-56.

## ИНТЕРВЬЮ ЖАНРЫНДА СОРАУНЫ БЕЛДЕРҮ ЮЛЛАРЫ

*Хөснетдинова А., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нәбиуллина Г.Ә.*

Журналистикада әңгәмәләшү аерым урын алып тора. Кешеләр белән аралаша белү зур осталык һәм тәҗрибә сорый. Әңгәмә корганда, тиешле җавапны дөрес сорау биреп кенә алырга мөмкин. Ул сорауны ничек, ни рәвешле бирергә?

Интервью алу – тулы бер фән һәм шул ук вакытта бик кызыклы сәнгать төре дә. Шул сәбәпле бу үзенчәлекле жанрны өйрәнгән хезмәтләр күп. Без фәнни - методологик нигез итеп Г. Шәйхи, В.З. Гарифуллин, Г.В. Кузнецов хезмәтләрен алдык. Чыганак итеп “ТНВ” каналындагы “Ком сәгате” һәм “Кунак бит Шоу”, “Шаян” каналындагы “Шаян балалар”, “ТМТВ” каналындагы “ШоуБез”, “Мәйдан” каналындагы “Ачыктан-ачык”, “Татар Радиосы” станциясендәге “Менә мондый кич”, “Болгар Радиосы” станциясендәге “Иртәнге чәй” тапшырулары алынды.

Телерадиоинтервьюның үзенчәлеге шунда – аңа тере сөйләшү хас. Газета- журналларда урнашкан әңгәмә өчен журналист алдан ук текст яза, әдәби материалны эшкәртә, әңгәмәдәш әйткән фразаларны редакцияли ала, ә телерадиоинтервью әңгәмә уздыру вакытында ук туа.

Беренче чиратта, сораулар *ачык* һәм *ябыкка* бүленә. *Ачык* сораулар – еш кына сорауны белдергән сүздән башланган (нәрсә, кем, нинди һ.б.) һәм тулы җавапны таләп иткән сораулар.

*Ябык* сораулар исә “әйе” яки “юк” дигән җавапларны таләп итә. Күпчелек очракта ачык сорауларны бирү кулайрак, чөнки алар әңгәмәдәшне күбрәк сөйләргә мәҗбүр итә.

*– Бизнес-леди булып китүең мөмкинме?* (“Мәйдан” телеканалы, “Ачыктан-ачык” тапшыруы).

*– Син хәтта хәзер Татарстанның атказанган артисты да*? (“ТНВ” телеканалы, “Кунак бит Шоу” тапшыруы).

Ачык сорауларны биргәндә, *үтенечне* еш кулланалар. Үтенеч сүзләре аша журналист интервью бирүче белән контактка керә һәм үзе турында уңай фикер калдырып, кешене гадел җавап бирергә этәрә. Монда түбәндәге чаралар кулланыла:

1. *-чы/-че, -ыгыз/-егез* кушымчалары;

*– Әйтегезче, сез анда [Евровидениега] барырга теләр идегезме*? (“ТНВ” телеканалы, “Кунак бит Шоу” тапшыруы).

*– Әйтегез әле, Сез балачакта нинди малай идегез: шук идегезме, тыйнак идегезме? (*ТНВ” телеканалы, “Ком сәгате” тапшыруы).

2. *Әле, икән* кисәкчәләре;

*– Раяна, әйт әле, нинди стильдәге җырлар яратасың? (*“ТМТВ” телеканалы, “ШоуБез” тапшыруы).

*– Әдәби суд бик кызык әйбер икән, сөйләп китегез әле* (“Шаян” телеканалы, “Шаян балалар” тапшыруы).

3. *Зинһар* кереш сүзе.

*Әйтегез әле, зинһар, әгәр дә читтә яшәргә туры килсә, Сез кайсы илне сайлар идегез?* (“ТНВ” телеканалы, “Ком сәгате” тапшыру).

Шулай ук ачык сорауларда ***гипотетик ситуация*** тасвирланырга мөмкин. Журналист андый сорауларны биргәндә, интервью бирүчегә уйлап чыгарылган ситуацияне тәкъдим итә һәм әлеге хәлгә җавап итеп аңлатма бирүен сорый. Түбәндәге сүзләрне кулланып була: әгәр дә, әйтик, күз алдына китерегез.

*– Әйтик, сезне иртәгә Австралияга гастрольга чакыралар һәм иртәгә үк сезнең гаиләгез белән Маврикийда ял итү мөмкинлеге бар. Сез кайсысын сайлыйсыз?* (“ТНВ” телеканалы, “Кунак бит Шоу” тапшыруы).

Ачык сорауларның тагын бер төре – *юнәлтүле сораулар*. Әлеге төрдә җавап инде сораудан ук билгеле. Сорау шундый итеп төзелгән, интервью бирүче журналист өчен кирәкле җавап кына бирә ала. Телерадиожурналистикада түбәндәге мисаллар очрый: дөресме, шулай бит, бәлки, инде.

*– Белүемчә, бүгенге көндә дә җырлар яздырасың. Шулай бит?* (“Татар радиосы” радиостанциясе, “Менә мондый кич” тапшыруы).

*– Бәлки сиңа шул үз юнәлешеңдә барыргадыр: юмор, тертмәле җырлар шундый?* (“Болгар радиосы” радиостанциясе, “Иртәнге чәй” тапшыруы).

*– Юмор кешесе инде ул?* (“Мәйдан” телеканалы, “Ачыктан-ачык” тапшыруы).

Шулай итеп, интервьюда сорауны белдерүнең ачык һәм ябык төрләре булганын аңладык. Телерадиожурналистикада мәгълүмат чыганагы булып интонацион һәм эмоциональ байлыкка ия булган сөйләм тора, шуңа күпчелек очракта ачык сораулар кулланыла, чөнки алар әңгәмәдәшне сөйләшергә, фикер йөртергә һәм теге яки бу ситуациягә мөнәсәбәтен, фикерен белдерергә ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Гарифуллин В.З. Язар сүзең булса... (Журналист текстын оештыру ысуллары). – Казан: “Школа” нәшрияты, 2000. – 172 б.

2. Кузнецов Г.В., Цвик В.Л., Юровский А.Я. Телевизионная журналистика. – М.: Высшая школа, 2002. – 304 с.

3. Шәйхи Г. Күңел – дәрья. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2006. – 174 б.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СПОРТ ТЕРМИНОЛОГИЯСЕ: ӨЙРӘНЕЛЕШЕ ҺӘМ КУЛЛАНЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Хөснетдинова Р., КФУ, III курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Йосыпов А.Ф.*

Татар телендәге тел белемендә монографик планда хәзерге көнгә кадәр татар теленең физик культура һәм спорт терминологиясе буенча тулы монографик тикшеренү юк дәрәҗәсендә. Шуның белән бәйле рәвештә, татар телендәге физик культура һәм спорт терминнарын тирәнтен һәм күп аспектлы өйрәнү ихтыяҗын барлыкка китерә.

Д.С. Лотте терминологик лексикада аңлатмаларның дүрт категориясен аерып күрсәтергә тәкъдим иткән: 1) предметларны, 2) процессларны, 3) үзлекләрен(свойств), 4) зурлыгын [3: 45]. Соңрак Т.Л Канделаки аларга тагын биш категория өсти: 1) халәт, 2) режим, 3) үлчәү берәмлеге, 4) фәннәр (һәм тармаклар) [2: 127]. Күрсәтелгән категорияләр нигезендә татар телендә спорт терминологиясенең тематик төркемнәрен чагыштырып карарга мөмкин.

1. Спорт төрләренең исемнәре һәм төрле төркемчәләре. Бу – татар теленең терминологиясендә иң күп санлы төркемнәрнең берсе: берничә мең спорт төре бар, аларның һәркайсының үз исеме бар. Мисал итеп, ишкәк ишү спорты (гребной спорт), суга сикерү (прыжки в воду), футбол (футбол). Төрле дисциплиналарның нинди дә булса спорт эчендәге төрен спорт төркемчәсе дип атыйбыз. Мәсәлән, ишкәк ишүнең төркемчәсе – академик ишкәк ишү (академическая гребля), байдаркаларда ишкәк ишү (гребля на байдарках) һәм каноэда ишкәк ишү (гребля на каноэ). Әлеге тематик төркем фәннәр категориясе һәм тармаклар белән бәйләнештә.

2. Спорт эшлекләренең исемнәре. Бу төркемгә катнашучыларның спорт эшчәнлеге атамалары керә: спортчылар, тренерлар һәм хөкемдарлар. Спорт төренең һәр атамасына спортчының исеме туры килә, мәсәлән: *хоккейчы (хоккеист), волейболчы (волейболист), дзюдочы (дзюдоист), шахматчы (шахматист), суга сикерүче (прыгун в воду), футболчы (футболист)* һ.б. Мондый исемнәр якынча спорт төрләренең исемнәре ничә булса, шулкадәр үк төрле исемнәр бар. Кайвакыт бер термин спортның төрле төрләрен билгеләгәндә кулланыла: *хоккейчы (хоккеист), хоккейдагы уенчыны туп белән билгелиләр (туплы хоккей) һәм шайба белән (шайбалы хоккей).*

3. Техник-тактик алымнар исемнәре. Бу – татар телендәге спорт терминологиясенең иң күп санлы тематик төркеме, ул төрле хәрәкәтләрне башкаруга нигезләнгән спорт эшчәнлегенең үзенчәлеге белән аңлатыла. Мисаллар булып түбәндәгеләр тора: *атып керту (вбрасывание), кысу (зажим), блокка кую (блокировка), һөҗүм (атака), маневрлау (маневрирование), контралым (контрприем).*

Төрле спорт төрләре аерым затларның яки спортның аерым төркемнәренең аерым дисциплинасында катнашу нигезендә түбәндәге тематик төркемнәргә бүленә:

1. Индивидуаль спорт төрләре: *ике төр ярыш (двоеборье), һава спорты (воздушный спорт), роликлар спорты (роликовый спорт), скейтбординг (скейтбординг)* һ.б.

2. Коллектив спорт төрләре: *өстәл теннисы (настольный теннис), пляждагы волейбол (пляжный волейбол), су полосы (водное поло), чирәмдәге хоккей (хоккей на траве)* һ.б.

Татар теленең спорт терминологиясен шулай ук В.Д. Бояркина классификациясенә таянып бүләргә мөмкин [1: 48]:

1. Спорт инвентаре атамасы: *йөгерү өчен тар паласа (бегущая дорожка), ныгытма (крепление), парус тактасы (парусная доска), бутсалар (бутсы), чаңгы роллерлары (лыжероллеры)* һ.б.

2. Спорт оешмалары исемнәре: *Экстремаль спорт төрләре Федерациясе (Федерация экстремальных видов спорта), Халыкара скибоб федерациясе (Международная федерация скибоба)* һ.б.

3. Төрле спорт төрләре белән шөгыльләнү урыннары, ярышлар урыннары атамалары: *ишкә ишү каналы (гребной канал), фитнес-үзәк (фитнес-центр), хоккей тартмасы (хоккейная коробка), гольф өчен кечкенә мәйданчык (миниплощадка для гольфа), запаста торучылар эскәмиясе (скамья запасных), сноуборд паркы (сноуборд-парк)* һ. б.

4. Күнегүләр процессының атамасы: *аэроб тренировкалар (аэробная тренировка), сузылу өчен күнегүләр (упражнения на растяжку).*

5. Спортчыларның торышлары һәм үз-үзләрен тотышы атамалары: *штраф тибүен тормышка ашыру (реализовать штрафной удар), тупны югалту (потеря мяча), допинглау (допинговать), алмашка чыгу (выйти на замену), ярты учеттан сугу (удар с получёта), капкачыны кыр уенчысы белән алыштыр (замена вратаря полевым игроком)* һ.б.

6. Хаталар, хокук бозулар, җәзалар: *уеннан чыгару (удаление с поля), ярышта катнашудан мәхрүм ителү (попасть под дисквалификацию), яклаучы уенчының фолы (фол защищающего игрока)* һ.б.

7. Спорт ярышларының исемнәре: *Дэвис Кубогы (Кубок Дэвиса), кубокияләренең Кубогы (Кубок обладателей кубков), Европа чемпионаты (чемпионат Европы), Параолимпиада (Параолимпиада), финал матчы (финальный матч), иптәшләрчә матч (товарищеский матч)* һ. б.

Шулай итеп, татар теленең спорт терминнарын төрле тематик төркемнәргә бүләргә мөмкин. Шунысын да әйтергә кирәк: терминнар – теге яки бу телдәге сүзләрне махсус төркеме генә түгел, алар шулай ук халыкның мәдәни дәрәҗәсенең күрсәткече, фәннең үсеш дәрәҗәсе һәм теге яки бу илнең техниканы үстерү дәрәҗәсе буларак игътибарга лаек.

**Әдәбият**


1. Бояркина В.Д. Неологизмы спорта и их отражение словарями русского языка. – М.: Наука, 1998. – 164 с.
2. Канделаки Т.Л. Семантика и мотивированность терминов. – М.: Наука, 1977. – 169 с.
3. Лотте Д. С. Основы построения научно-технической терминологии: Вопросы теории и методики. – М.: Изд-во Академии наук СССР, 1961. – 156 с
4. Рамазанова Д.Б. О терминологической работе в Республике Татарстан в 90-х годах / Проблемы совершенствования терминологии татарского языка: Материалы научно-практической конференции «Проблемы совершенствования терминологии татарского языка» (22 апреля 2005 г.). – Казань, 2006. – С. 120-155.


## ФОРМЫ ПОДАЧИ ЛЕКСИКИ В ТУРЕЦКОМ ЯЗЫКЕ


*Шаехова Р., КФУ, студент III курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, ст. преп. Латыпов Р.И.*


Лексика является одной из самых важных элементов при изучении языка, потому что словарный запас имеет огромное значение в общении и письме. Слова они как формулы, без которых решение математических задач невозможно. Также и люди, у которых недостаточно знаний о лексике, не смогут эффективно пользоваться языком. Именно поэтому целью современной методики преподавания иностранного языка является формирование лексических навыков учащихся. В формировании языковой базы важную роль играет лексикон, лексические единицы.

В конце XX и в начале XXI века в отечественной методике произошли значительные перемены, повлиявшие на обучение лексике. Верещагин Е. М. говорит, что в процессе обучения лексике происходит также и изучение культуры страны: «за языковой эквивалентностью лежит понятийная эквивалентность, эквивалентность культурных представлений» [1: 21].

Также И.В. Рахманов отмечает огромное значение упражнений, как для усвоения языкового материала, так и для развития речевых умений [2: 235]. Усвоение лексики становится одним из способов формирования речевой деятельности. Разрабатываются специальные лексические упражнения: дифференцировочные, в группировке материала, в заполнении пропусков в предложении или в дополнении предложений, связанные с работой над синонимами, антонимами и омонимами,

связанные с работой над многозначностью слова, направленные на усвоение словообразования и словосочетания, в переводе с использованием определенного лексического материала [2: 236].

Пол Нейшен (Paul Nation), лингвист-исследователь в области методики преподавания иностранных языков, выделяет четыре принципа обучения лексике [3:129-152]:

1) Принцип минимизации языка.

2) Принцип дифференцированного подхода в зависимости от цели усвоения лексики.

3) Принцип взаимосвязанного обучения лексике и видам речевой деятельности.

4) Принцип сознательности, включающий в себя рефлексию

Ниже будут представлены способы преподавания лексики турецкого языка.

Презентация слов. Kelimelerin sunumu.

1. Изучение слов с использованием изображений. Resimleri kullanarak anahtar kelimeleri tanıtma. Предположим, тема - животные: учитель находит фотографии на эту тему, рассказывает ученикам про них. После начинает спрашивать: "Какое это животное? Что он делает?".

2. Учитель говорит слово, а ученики выбирают картинку, связанную с ним.

Практика слов. Kelimelerin pratiğinin yapılması.

1. Рассказывать картину через жесты и мимики. Jest ve mimikler yoluyla resmi anlattırma. Учитель показывает одному из учеников картинку и говорит объяснить его друзьям с помощью тела, жестами и мимикой.

2. Знающий садится. Bilen oturur. Эта игра может быть использована для обучения пословиц, идиом, синонимов, антонимов и многих других тем. Сначала все ученики встают, затем учитель записывает слово на доску и просит найти синоним, антоним к этому слову. Ответивший правильно садится.

3. Поймай мяч и ответь. Topu al cevabı ver. Учитель бросает мяч, говоря слово, связанное с темой урока. Ученик говорит значение данного слова и бросает его другому проговаривая новое.

4. Текст с пропусками. Boşluklu hikaye. Составляется текст, вместо пройденные слов ставятся пропуски. Ученики самостоятельно работают, затем учитель читает текст, а учащиеся проверяют.

5. Теннис словами. Kelimelerle tenis. Учитель определяет тему и каждый ученик проговаривает связанные с ним слова.

6. Половина головоломки. Yarım bulmaca. Учитель готовит головоломки. Ученики из двух команд просят друг друга объяснить слова, которых нет у них.

7. Мозговой штурм. Kelimelerle beyin fırtınası. Учитель пишет на доске слово и просит учеников найти связанные с ним понятия, высказывания.

8. Слова, начинающиеся с ... . ... ile başlayan kelimeler. Учитель пишет букву на доске, ученики должны искать слова, которые начинаются на эту букву.

9. Вопрос и ответ. Soru-cevap. Учитель раздает ученикам карточки с вопросами и ответами. Учащиеся должны сопоставить ответы с вопросами [4: 9-24].

Обобщая вышеизложенное, следует отметить, что лексика является крайне важным аспектом языка, и от уровня сформированности лексических навыков и умений зависит способность общения на иностранном языке.

Изучение лексики – это продолжительная задача, и правильное применение обучения ей гарантирует положительный результат.

**Литература**

1. Верещагин Е. М. Лингвострановедческая теория слова / Е. М. Верещагин, В. Г. Костомаров – М.: Русский язык, 1990 – 254с.

2. Миролюбов А.А. История отечественной методики обучения иностранным языкам. – М.: СТУПЕНИ, ИНФРА-М, 2002. - 448 с.

3. Nation, P. Vocabulary. In D. Nunan [Text] / P. Nation // Practical English Language Teaching. – New York: McGraw Hill, 2003 – P. 129-152.

4. Taşdemir Ercan, Nesrin Bilkan, Hüdai Can; Pratik Türkçe Öğretim Teknikleri, Zambak Yayınları, İstanbul 2004

## ТАТАР ЭКСПЕРИМЕНТАЛЬ ФОНЕТИКАСЫНДА КУЛЛАНЫЛГАН МЕТОДЛАР

*Шаһабиева Й., КФУ, IV курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Һадиева Г.К.*

Кеше сөйләме авазлардан тора һәм алар сүзнең мәгънәсен аеруда катнашалар. Аваз – сөйләмнең таркалмый торган иң кечкенә берәмлеге. Авазлардан башка сөйләм барлыкка килә алмый. Сөйләм авазларын тикшерү һәм өйрәнү тел белеменең иң мөһим бурычларыннан санала, чөнки сүзне иң әүвәл аның авазлары хасил итәләр. Ә шул авазларны, алар арасындагы үзгәрешләрне, аваз кушылмаларын өйрәнүче фән ул – фонетика.

Татар фонетикасы буенча иң беренче фәнни мәгълүматлар К. Насыйриның “Кыскача татар грамматикасы” китабында бирeләләр. Соңрак “Әнмүзәҗ” китабында исә, авазларны төркемләү принциплары да

карала. Шулай ук, Г. Нугайбәк, Г. Алпаров, Җ. Вәлидиләр тарафыннан төзелгән дәреслекләр дә була. В. Радлов, В.А. Богородицкий, Г. Шәрәф тә фонетика өлкәсендә күп хезмәтләр язалар.

Эксперименталь фонетика – иң беренче чиратта төрле максатларда кулланылган приборлар белән эш итә. Алар аерым бер телләрнең, яисә бу тел гаиләләрендә булган авазларның акустик төзелешләрен өйрәнергә ярдәм итәләр. Сөйләмнең эчке төзелешен тикшерү өчен аерым җайланмалар кирәк. Төрле җайланмалар ярдәмендә үткәрелгән тәҗрибәләр үз эксперименталь (собственно экспериментальные методы) методлар ярдәмендә башкарылалар. Әлеге төр методлар үзләре берничә төргә бүленәләр. Алар түбәндәгеләр:

Эксперименталь фонетика өлкәсендәге беренче метод – соматик метод. Бу метод сөйләмдә катнашучы органнарга бәйле күренешләрне һәм үзгәрешләрне фонетикага бәйләп өйрәнә. Мәсәлән, сулыш алу рәвешенә карап, фразаның ритмнарга бүленүен тикшерергә була. Соматик методлар, гадәттә, палатограммаларны төшерү һәм сулыш алуны төрле пневматик җайланмаларда теркәп кую белән оештырылалар.

1. Паллатограмма алымы. Моның өчен алдан ук сөйләүченең аңкавы үлчәвенә һәм формасына туры килә торган итеп ясалма аңкау эшләнергә тиеш. Әлеге аңкауда махсус тишекләр ясарга кирәк. Әзер аңкауны куеп, диктор сөйли, шуннан соң аны алып, махсус карточкаларга урнаштыралар. Селәгәй тигән һәм тимәгән урыннар билгеләнеп куела. Шулай итеп, авазларны әйткәндәге тел торышы билгеләнә. Палатограмма алымы артикуляция урынын билгеләүдә зур әһәмияткә ия.

2. Артикуляция органнарын фотога төшерү алымы. Тышкы органнарны сурәтләү өчен гадәти фотоаппарат кулланалар. Ә эчке органнарны төшерү өчен авыз эченә дезинфекция ясала һәм Фельдштейн-Максутов уйлап тапкан микрофотоаппарат куела һәм фотога төшерелә.

3. Пневмографик алым. Пневмографик алым бурычы булып сөйләм барышында сулышны үлчәү. Пневмограф резин торба ярдәмендә зур диаметрлы мареев барабаны белән тоташтырыла. Система һава белән тутырыла һәм резин торбаны урталайга кисеп, вентиль белән тоташтыралар. Сәгать механизмы белән эшләүче кечкенә кимографка кәгазь ябыштырла. Кәгазьнең бер башына клей сылана һәм икенче башы белән тоташтырыла. Кимографның цилиндры тип-тигез урнашкан булырга тиеш. Кимограф барабанында язылган сулыш алу язмасында сөйләүченең номеры һәм фамилиясе теркәлә.

Шуннан соң лента алына һәм билгеле бер эздән киселеп, канифоль ярдәмендә теркәлә.

4. Рентгенографик алым. Әлеге алымның бурычы – киммограф һәм палятограммада күренмәгән сөйләм органнарын күзәтү. Сөйләүче үзе рентген аша төшерүче җайланманы кабыза һәм башын туры тотып, авазларны ачык һәм аңлаешлы итеп әйтә. Сөйләүченең аппаратны нәкъ вакытында кушуы бик мөһим. Дикторның башының йөз өлеше һәм муены рентгенга төшерелә. Шул рәвешле билгеле бер авазны әйткәндә сулыш һәм сөйләм органнарының торышы ачыклана.

Эксперименталь фонетиканың чираттагы методы – пневматик. Сөйләм материалы физик күренеш буларак тирбәлеш санына, амплитудасына һәм билгеле бер вакытта бердәмлек тудыручы обертоннарга бәйле. Һәм югарыда әйтелгән күренешләрнең барысы да, махсус лабораторияләр оешканчы, пневматик метод белән өйрәнелгән. Пневматик метод белән аваз әйтелеше вакытында сулыш алу рәвешен күзәтәләр, һава агымы тәэсирендә шаулар барлыкка килүне тикшерәләр.

Электроакустик метод. Бу метод беренче тәҗрибәләр вакытында осциллограф ярдәмендә гамәлгә куелган. Катодлы осциллографта урнашкан электр-нурлы торба аша тиз арада үтүче электр процессларын тикшерергә мөмкин булган. Эксперименталь фонетикада ул катлаулы тавыш күренешләрен гармоник тирбәлешләр барлыкка китереп өйрәнергә ярдәм иткән. Һәм бу прибор ярдәмендә сөйләм үзенчәлекләрен электрик күренешләргә әйләндереп карау һәм визуаль күзәтү мөмкинлеге туган

Экспрессив метод. Бу метод сөйләм вакытында булган мимика һәм жестлар тикшерелә, синхрон рәвештә фото, видео материалларга төшереп аңлатыла.

Әлеге методлардан тыш, эксперименталь фонетика өлкәсендә төрле үлчәмнәрне билгеләүдә кулланылган методлар да бар: тензопалатография, электромиография, глоттография, электромиография

Бүгенге көндә әлеге приборлар һәм алымнардан тыш эксприменталь фонетикада компьютердагы төрле программалар да мөһим урын алып торалар.

Speech API – бу программада сөйләм кире тәртиптә синтезлана. Башта сүз фонемаларга бүленә, аларның саны һәм пунктуациясе аерым эшкәртелә. Соңыннан аваз ясала һәм әйтелә.

Speech Analyzer – программа бер визуализацияләнгән аваз өстенә икенчесен дә куеп булу мөмкинлеге белән башкаларыннан

аерылып тора. Бу бигрәк тә дикторның чит тел сүзләрен әйткәндәге кимчелекләрен ачыкларга ярдәм итә.

Эксперименталь фонетика бүгенге көндә акустика, психоакустика, информатика һәм сөйләм психологиясе өлкәсендәге белемнәрне берләштерә. Әлеге фәннәр белән бергәлектә, ул сөйләм мәсьәләләрен төрле аспектларда өйрәнә.

**Әдәбият**


1. Артемов В.А. Экспериментальная фонетика. – М.: Литературы на иностранных языках, 1956. – 226 с.
2. Богородицкий В.А. Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. Под. ред. чл.-кор. АН СССР проф. Н.К. Дмитриева. – 2-е изд., испр. и доп. – Казань: Татгосиздат, 1953. – 220 с.
3. Бондарко Л.В. Экспериментальная фонетика в Санкт-Петербургской государственном университете: вторая половина столетия // 100 лет экспериментальной фонетике в России. Материалы международной конференции. СПб., 2001. – С. 3-15.
4. Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 108 б


## К ВОПРОСУ ОБ ОСОБЕННОСТЯХ ПРЕПОДАВАНИЯ ИНОСТРАННОГО ЯЗЫКА В РАМКАХ КУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКОГО ПОДХОДА


*Науманова Э., Баишев Университет, магистрант I курса*

*Науч. рук. – PhD Садыкова С.А.*


Роль английского языка в современном казахстанском обществе значительно возросла в связи с внедрением модели трехъязычного образования, согласно которой обучение в учебных заведениях должно осуществляться на трех языках: государственном – казахском, официальном – русском и английском, имеющим статус международного языка. При этом стали учитывать и необходимость знания культуры народа – носителя языка при формировании полиязычной личности, что является важным для установления диалога и избегания конфликтов.

Как известно, язык и культура находятся в тесной взаимосвязи и выполняют две функции воздействия на социум: функцию воздействия языка, реализуемая с помощью образно-выразительных средств и функцию воздействия национальной культурной среды.

Диалог культур может быть установлен только при наличии знания специфики разных компонентов культур, к которым относятся традиции, обычаи и обряды, художественная культура, национальное сознание и национальный характер.

Общепризнанным фактом является значимость языка в межкультурном общении. Язык служит проводником культурных ценностей для передачи их последующим поколениям. Он отражает

мироощущение конкретного народа, его менталитет, национальный характер, нравственные принципы.

Культурологический подход в дидактике и методике преподавания иностранных языков получил развитие в трудах Л. Уайта, Э. Сепира, Н.С. Трубецкого, В.Ф. Сидоренко, Е.М. Верещагина, В.Г. Костомарова, В.А. Масловой, Г.В. Елизаровой, А.Т. Хроленко, В.П. Фурмановой и др. Осуществление данного подхода возможно при соблюдении взаимосвязи компонентов учебной деятельности на основе соединения обучения профессиональному языку с индивидуальными потребностями и ценностными ориентациями обучаемых [1: 76].

Реализация культурологического подхода позволяет переосмыслить специфику обучения иностранному языку. Важными проблемами методики преподавания иностранного языка являются вопросы определения целей и содержания обучения, адекватного им, при разработке которых наиболее эффективными представляются идеи обучения не просто языку, а иноязычной культуре в широком смысле этого слова.

М.А. Суворова в своем исследовании пишет, что система преподавания иностранного языка в рамках культурологического подхода представляет собой единство целей и содержания, методов и средств, и взаимодействия преподавателя и студентов, а также социокультурного фона, среды обучения, обусловленных социальным заказом общества на подготовку специалистов [2: 64].

Использование культурологического подхода на уроках английского языка предусматривает применение следующих методов:

– частично-поисковый, проблемный и исследовательский методы;

– творческий метод;

– натуральный метод;

– контент-анализ и лингвокультурологический анализ пословиц, поговорок, фразеологизмов и характерных для англичан высказываний.

Изучение иностранного языка и иностранной культуры требует от учителя подбора лингвистического материала, имеющего межкультурную направленность, с целью формирования у учащихся достоверных представлений о стране изучаемого языка. Для наиболее полного погружения в культуру иностранного языка необходимо ознакомление с культурным фоном, который стоит за единицами языка и позволяет соотнести поверхностные структуры языка с их глубинной сущностью [3: 87].

При изучении фонетического строя английской речи ученикам можно дать задание выучить текст английской народной песни «Jingle, bells», которая содержит также культуроведческую информацию.

Большие возможности для изучения иностранного языка и культуры предоставляют мультимедийные средства, используя которые учащиеся могут работать со справочной литературой и энциклопедиями, расширяющими их кругозор относительно истории, экономики, искусства, литературы англоязычных стран.

Таким образом, обращение к культурологическому подходу в иноязычном образовании способствует сознательному усвоению материала, обеспечивает повышение познавательной активности учащихся, благоприятствует созданию положительной мотивации, развивает образно-художественную память, речевое мышление, логику.

**Литература**

1. Гальскова Н.Д. Современная методика обучения иностранным языкам: Пособие для учителя. – М.: АРКТИ-ГЛОССА, 2000. – 189 с.

2. Суворова М.А. Лингвокультурологический подход в обучении иностранным языкам студентов старших курсов языкового вуза: Дис. ... канд. пед. наук. – Улан-Удэ, 2000. – 158 с.

3. Фурманова В.П. Межкультурная коммуникация и лингвокультуроведение в теории и практике обучения иностранным языкам. – Саранск: Изд-во Мордовского ун-та, 1993. – 122 с.

## Ф. ӘМИРХАН ПЬЕСАЛАРЫНДА ОБРАЗЛАР СИСТЕМАСЫ

*Хәбибуллина А., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гыйлаҗев Т.Ш.*

Ф. Әмирхан – татар сәхнә әдәбияты үсешенә зур өлеш керткән талантлы драматург. Аның “Яшьләр”, “Тигезсезләр”, “Фәхулла хәзрәт” драмалары – татар сәхнәсендә күп уйналган, төрледән төрле бәяләргә ия әсәрләр. Шулай ук, Ф. Әмирханның тәмамланып бетмәгән пьесаларыннан өзекләре бар.

И. Нуруллин билгеләп киткәнчә, Ф. Әмирхан беренче пьесасында ук әһәмиятле типлар, кызыклы характерлар белән зур мәсьәләләр күтәрә [5: 288]. Р. Ганиева Ф Әмирханның“Фәтхулла хәзрәт” һәм башка әсәрләре белән XX гасыр башы татар әдәбиятына яңа, моңа кадәр милли әдәбиятта күренмәгән геройлар алып килүен билгели. “Болар – яңа чор рухында тәрбияләнеп үскән европача карашлы, зыялы яшьләр. Алар узган гасырның традицияләрен яхшы беләләр, дөнья мәдәниятен югары бәялиләр” [1: 101]. Аның фикерен Д Заһидуллина да яклый. Модернизм фәлсәфәсе йогынтысында XX нче гасыр башы татар әдәбиятында интеллегент һәм интеллектуаль үскән, татар җәмгыятендә үз урынын табарга омтылган яңа герой мәйданга чыга. Яңа герой үзен милләтнең өлеше итеп хис итә, аның вәсвәсә-кайгыларын авыр кичерә. Милли үзаңны торгызу белән беррәттән, татар мәдәниятен Европа үрнәгендә үстерүгә омтылыш тенденциясе

билгеләнә [3: 85]. Экзистенциаль компонент җәмгыятьнең һәм милләтнең торышы эчтәлегендә бирелә. Шунлыктан, күп кенә әсәрләрдә этник үзаңны уяту концепциясе үзәккә чыга, татар җәмгыятенең яшәеше экзистенциаль сыкрану сәбәбе була. Әдәби герой татар җәмгыятенең чын торышын аңлау процессында бирелә.

“Яшьләр” драмасында образлар ике төркемгә бүленә: “балалар” һәм “аталар”. “Балалар” – югарыда галимнәр характер сыйфатлар билгеләгән яңа типтагы геройлар. Ә “аталар” ягына кергән образлар арасында бозык Рәхимҗан да, чит кешеләр сөйләвенә ышанган, ләкин күпмедер дәрәҗәдә алдынгы карашлы Хөсәен дә керә. Хатын-кызлардан Мәрьям, Фәхернисалар да “аталар”га керә. Әмма аларның “аталар” төркеменә керүе тигез хокуклары булмаудан гына. Зәйнәп образы да шуны ук дәлилли. Каршы кую алымы ярдәмендә язучы контраст образларны сурәтли, һәм милләтнең бәхетле яшәеше “яшьләр”нең кулында дигән фикерне үткәрелә.

“Фәтхулла хәзрәт” комедиясендә образлар мәгърифәтчелек реализмындагыча уңай һәм тискәрегә төгәл аерыла. Сәхнә әсәрендә без ике тискәре геройны күрәбез. Болар – Фәтхулла хәзрәт һәм Миңлесылу. Уңай персонажлар исә Әхмәт, Нәфисә, Зыя, Ләйлә, хадимә Сәгъдия, мөхәррир, имам, Чыңгызлар. Р. Ганиева да хезмәтендә Ләйләнең, Әхмәтнең яңа чор рухында тәрбияләнеп үскәнлеген, яңа геройлар икәнлеге ассызыклана [1: 101].

Фәтхулла хәзрәт – XX гасыр башындагы кара көчләрнең, кадимчелек тарафдарларының тискәре сыйфатларын үзенә туплаган җыелма образ. Әлеге герой көлке дә, җирәнгеч тә, кызганыч та итеп эшләнә.

“Тигезсезләр” драмасындагы образлар тирәнрәк итеп эшләнгән. Әсәрдә аларның хис-кичерешләренә, башка персонажлар белән мөнәсәбәтләренә күбрәк урын бирелә.

Ф. Әмирхан импрессионистик әсәрендә зәвыклы, эмоциональ, матурлыкка сокланучы, хискә бай кызны – Рөкыяне тасвирлый. Рөкыя һәрвакыт хәрәкәттә, нинди дә булса эш белән мәшгуль. Ул сәнгати яктан да үсеш алган: милли һәм чит ил көйләрен пианинода уйный, рәсемнәр ясарга ярата. Рөкыя балаларча ихлас һәм чиста күңелле: алдый да, начарлык та эшли белми.

Психологик драмада кызыклы Иванушка-Абдулка образы бар. Дөресрәге, Рөкыя белән Сөләйман Габдулланы Иванушка-Абдулка дип атый. Бу исем аңа үз милләтеннән ваз кичүе өчен бирелә. Герой татарча яза белми, татар әдәбиятын түбән саный. Аның карашынча, татар милләте бетүгә йөз тота. Ф. Сәйфи-Казанлы билгеләп киткәнчә, Габдулла “татар хәятын яратмыйча, аларның мәдәни хәрәкәтләренә дә көлеп кенә карый торган бер мәсләктә хезмәт итүче, татарның

киләчәгенә өметсез караучы бер татар яше генә түгел, бәлки идиот, җүләр студент булган да чыккан” [2: 98].

Әлеге геройга үз сыйфатлары белән Закир, Галиев якын тора. Закир кеше көлдерәм дип, төрле уйдырмалар сөйләргә яратучы булса, Галиев үз матурлыгына һәрвакыт үзе сокланып йөрүче. Әлеге геройлардан да милләткә карата шелтә ишетелә.

“Яшьләр” һәм “Фәтхулла хәзрәт” әсәрләрендә кебек үк “Тигезсезләр”дә дә яңа чор геройлары урын ала. Алдынгы карашлы, оптика сәүдәсе белән шөгыльләнүче эшкуар Гомәр шундыйлардан. Ул сәүдәсе белән Европага чыгарга һәм немец, яһүдиләргә көндәш булырга тели. Гомәрнең моны уңышлы гына башкаруын без алдагы пәрдәләрдә күзәтәбез. Ул хатын-кызларның хокукларын яклау турында да уйлый. Сеңелләренә немец телен өйрәнергә, сәүдә, бухгалтерия эшенә керешергә тәкъдим итә. Аныңча, икътисади яктан тәэмин ителгән хатын-кызлар гына гаиләдә дә, җәмгыятьтә дә азат һәм бәхетле була алалар [1: 105].

Шулай итеп, Ф. Әмирханның драма әсәрләрендә зәвыклы, алдынгы карашлы персонажлар алга чыга. Әлеге геройлар милләт өчен җан атучы, аны үстерергә зур өлеш кертүче буларак тәкъдим ителә. Яңа георойларга милли чынбарлык яңарышын, үсешен тоткарлаган кадимче образлары, искелек вәкилләре каршы куела.

**Әдәбият**

1. Ганиева Р.К. XX гасыр башы татар модернистик әдәбияты һәм Фатих Әмирхан. – Казан: Тат. Респ. Фәннәр академиясе нәшр., 2016. -29-36 б.
2. Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 254 б.
3. Загидуллина Д.Ф. Модернизм в татарской литературе первой трети XX века. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. – 207 с.
4. Мәһдиев М.С. Сызып ак нур белән...: шәхесләребез тарихыннан: фәнни-публицистик мәкаләләр / Мөхәммәт Мәһдиев; [төз. Г.Хәсәнова; кереш сүз авт. Д.Заһидуллиа]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 583 б.
5. Нуруллин И.Ш. XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1982.

## КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ ТАТАР В ЭТНОЛИНГВИСТИЧЕСКОМ АСПЕКТЕ

*Хузиахметова Г., КФУ, магистрант II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, ст. преп. Тухватова Г.Ф.*

Говоря о культурном наследии, следует начать с определения понятия. Культурное наследие — представляет собой широкий спектр ментального и телесного освоения опыта предков, включающее в себя памятники духовной и материальной культуры, способствующие

просвещению и обогащению молодого поколения. Памятники духовной, а в особенности материальной культуры имеют очень большое значение, т.к. именно они являются напоминанием человечеству о богатой истории их предков. Благодаря им, мы можем познакомиться и изучить повседневность и культуру определенного этноса в различные исторические периоды. Как уже говорилось ранее, культура той или иной нации находит свое воплощение в языке. Поэтому уместно изучать культуру и наследие культуры в аспекте этнолингвистики. Этнолингвистика представляет собой широкий спектр научных знаний о связи языка и культуры. В поле ее исследований входят проблемы взаимодействия языка этнической группы и ее культуры, способы сохранения культуры через язык и влияние языка на развитие культуры.

Какую роль играет язык татарского народа при сохранении и передачи его культурного наследия последующим поколениям? Культура татар представляет собой очень обширную, разнообразную и богатую область для изучения современным ученым тюркологам. Следует начать с духовной культуры, т.к. именно она напрямую связана с языком татар. Нами было выявлено, что духовная культура включает в себя менталитет, традиции, мифологию и религию народа. Издавна у татар, как и у других народов, существуют пословицы, поговорки, загадки и сказки, которые передавались из поколения в поколение посредством устного народного творчества. Давно известный факт, что устное народное творчество и традиции в целом отражают национальный характер народа. Предания и легенды, сказки и мифология могут наглядно показать отношение татар к той или иной ситуации в жизни, т.е. в сущности раскрыть их философию жизни. Это можно проследить в сказках о героях (батырах) и их возлюбленных, где можно увидеть типичные черты характера присущие мужчине, такие как – храбрость, живой ум, доблесть, почитание и уважение старших. А их возлюбленным характерны такие черты, как – скромность, трудолюбие, терпеливость и достоинство. Нередко, в сказках рассказываются истории и девушках, которые жертвуют собой ради благополучия своей семьи. Не только сказки, поговорки и пословицы отражают менталитет и национальный характер татар, но и песни тоже могут многое сказать нам. Даже в современных песнях отражается национальный колорит народа, который включает в себя специфику исполнения, восхваление родных просторов, съемка традиционных татарских деревень и соблюдения правил ношения традиционного национального костюма татар. Такое почитание своей культуры происходит через язык. Сказки и пословицы рассказывают из

поколения в поколение уже на протяжении многих веков, национальные песни исполняются артистами и запоминаются народом. Также, сюда можно отнести традиции татар при рождении, смерти и бракосочетаний. Те или иные обряды сохраняются и почитаются по сей день, благодаря языку или письменному источнику. Мы узнаем особенности наших традиции и порядки их исполнения (например, порядок проведения никаха) от наших родителей и бабушек. Многие праздники, такие как сабантуй, навруз, рамадан, ураза-байрам, отмечаются на протяжении многих веков, что говорит нам о связи поколений. Мы узнаем об особенностях проведения данных праздников посредством слова, языка и письменных источников. Язык здесь выступает не только в качестве передачи важной информации, но и неким объединяющим механизмом молодого поколения и его истории, культуры и традиций. Говоря о духовной культуре татарского народа не следует забывать о его менталитете. Менталитет отражается в культуре речи, в манерах общения и психологических факторах передачи информации собеседнику. Т.к. татары в большинстве темпераментны, энергичны и открыты, при общении можно заметить их эмоциональность и доброжелательность.

Помимо духовного наследия татар, огромное значение для языка имеет и материальная культура. Материальная культура включает в себя памятники истории и архитектурные сооружения, которые несут в себе не менее значимую информацию из прошлого. Каждый материальный объект, будь то памятник (стела Кюль-Тегину в музее), предметы быта, сохранившиеся с прошлых столетий, фрагменты национальной одежды или древнейшие архитектурные постройки, предстают не просто как вещи, на которые можно посмотреть и полюбоваться. Любой памятник не имел бы своего полноценного значения без информации о нем, т.е. без устных и письменных источников – это был бы просто предмет обихода. К материальному культурному наследию татар можно отнести – национальные блюда, национальный костюм, ювелирные изделия, религиозные постройки и сооружения для жилья. Рецепт национальных блюд мы узнаем, как уже говорилось ранее, от старшего поколения или письменных источников, это касается и особенностей национального одеяния. Со значимостью того или иного архитектурного сооружения мы знакомимся через коммуникацию со специалистами или опосредованно, через книги или другие источники.

Таким образом, в ходе нашего исследования было выявлено, что язык играет важнейшую роль для культурного наследия. Нами были проанализированы такие ключевые понятия как – культурное наследие

и этнолингвистика. Были рассмотрены элементы духовной и материальной культуры татар и их роль для татарского этноса в целом. Неугасающее развитие культуры татар связано с их языком. Именно язык обеспечивает преемственность поколений, посредством сохранения, передачи и приумножения наследия культуры. Язык выступает важнейшим связующим звеном молодого поколения с его предками. Популярность татарской культуры для других народов напрямую связана с развитой межкультурной коммуникацией.

**Литература**


1. История татарского народа (Этнические корни, формирование и развитие) / Закиев М.З. – М.: ИНСАН, 2008. – 560 с.
2. Сагдеева Ф.К., Гайнанова Д.Р. Татарский концепт как объект лингвокультурологического анализа. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – 248 с.
3. Этнография татарского народа / науч. ред. Д.М. Исхаков. – Казань: Магариф, 2004. – 287 с.


## АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ПЕЙЗАЖ БИРЕЛЕШЕ


*Хөсәенова Р., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гайнуллина Г.Р.*


Хәзерге әдәбиятта традицион татар хикәясен үстерүдә үз сукмагын тапкан, лирик-эмоциональ дулкынны дәвам иттерүче язучыларның берсе Айгөл Әхмәтгалиева иҗаты күпләребезгә таныш. А. Әхмәтгалиева әдәбият мәйданына XXI гасырның башында килеп кергән яшь әдибә. Аның әсәрләрендә күпмедер дәрәҗәдә XX гасырның икенче яртысында иҗат иткән авторлар тарафыннан күтәрелгән темалар да очрый. Табигатьне саклау, авылның бетүе, кеше холкының кырыслануы, эчүчелек, эшсезлек, ятимлек, тормышның үзгәрүе кебек мәсьәләләр авыл яшәешен прозада чагылдыручы язучылар иҗатында кат-кат күтәрелгән.

Айгөл Әхмәтгалиева хикәяләре беренче тапкыр укуда ук тормышчан, гади, аңлаешлы телдә язылуы белән аерылып торалар һәм үзләренә җәлеп итәләр. Бигрәк тә табигать сурәтләнеше, пейзаж лирикасы ярдәмендә автор геройларның хис-кичерешләрен дә, алга таба вакыйгалар агымының нинди булуын да оста итеп күрсәтә белә. Пейзаж – әсәрдә җанлы һәм җансыз табигатьне сурәтләү [3: 31]. Фәндә пейзажның төрле вазифалары аерылып чыгарыла:

- вакыйгаларның урынын, вакытын билгеләү;
- сюжетка катнашу яки аны үзгәртү;
- әсәрне кабул итәргә көйләү һәм геройларның психологик халәтен ачу;
- автор фикерен белдерү.

Пейзаж, хикәяләрдә иң актив һәм киң таралган деталь буларак, әсәрнең идеясен укучыга образлы һәм кыска юл белән ирештерергә мөмкинлек бирә. Хикәяләрдә пейзаж әсәрнең эчтәлеге, идеясе белән бәйләнгән булырга тиеш. “Күп очракта пейзаж – урынны күрсәтүче” [1: 51] дә.

А. Әхмәтгалиеваның күп кенә әсәрләре табигать күренешен сурәтләү белән башланып китә. “Кайтаваз” хикәясенең башлам өлешендә бирелгән пейзаж ярдәмендә автор укучысын билгеле бер дулкынга көйләп куя. Сылу каеннар шавы белән инеш агышы кешенең гармониясен тәшкил итүче образлар кебек укыла. Символ булып килгән моң әлеге образларны бербөтенгә туплый, тормышның көйләнгән булуына ишарә итә: “...Колакны иркәләгән әлеге моң таң калырлык иде” [2: 160]. Шулай ук: “Урал тауның ташлы итәгендә мәгърур кыяфәтле сылу каеннар шавында идеме ул, әллә инде тау күкрәген ярып, кылтык кызлар тавышы белән челтерәгән инеш агышында идеме...” [2: 160] дигән беренче юлларын укуга ук вакыйгаларның, алга таба булачак хәлләрнең әйбәт булачагына ышанасың, өметләнәсең. Шулай сурәтләп, автор укучыны искиткеч матур табигатьле сихри дөнья эченә алып кереп китә.

Ләкин алга таба елганың “дуамалланып, ярсып” агуы, суы “боздай салкын” [2: 161] булуы әлеге елганың куркыныч тудырырга мөмкин икәнлеген күрсәтә, сак булырга куша. Табигатьне төрлечә сурәтләп, автор вакыйгаларның үзгәрәчәгенә ишарә итә.

Пейзаж ярдәмендә автор ана кешенең бөеклеген дә ачык күрсәтә, “...болытларга түбәләре тигән мәгърур таулар...” [2: 164] кешенең халәтен сурәтләүдә катнаша, ана кешенең горурлыгын чагылдыра. “Гүя барысы да каяндыр ишетелер-ишетелмәс кенә булып агылган, колакны иркәләгән моңга, җил канатында тирбәлгән кайтавазга мөккибән иде” [2: 164] дигән юллар алда тынычлык, рәхәтлек көткәнен күрсәтә.

Пейзажның әсәрне каймалап алуы хикәянең тәэсир көчен арттыра һәм төп мәгънәсен җиткерә. “Колакны иркәләгән моң”ның кабатланып килүе укучыны да шул дулкынга көйләп куя һәм буыннардан килгән гомумбилгеле хакыйкатьнең – яхшылыкның, мәрхәмәтлелекнең һәрвакытта да кешенең үзенә кайтаваз булып әйләнеп кайтуын раслый.

“Тау итәгендә” дип исемләнгән хикәядә дә пейзаж алымнары зур урынны алып тора. Башлам өлештә бирелгән пейзаж укучыны геройның күңелендә борчу булуын, ниндидер сынау алдында калганлыгын тоюга әзерли. Тау итәге никадәр генә матур булмасын (“зәңгәр кыңгыраулар, бер-берсенә сарылган кәрешкә, күкчәчәк, тагын

әллә нинди, әллә нинди чәчәкләр, үләннәр, төсләр белән чуарланган”), ир нәкъ менә сары күзле ромашкалар алдында туктап, уйланып калырга мәҗбүр була. Сары күзле ромашкалар биредә кешенең күңелен ачып бирүче, гармониясен тәшкил итүче символ буларак киләләр [2: 212].

Алга таба авторның әйтергә теләгән чираттагы фикере әсәргә килеп кергән болыт һәм кояш образлары аша җиткерелә: “...Менә бу иркә болытларның бер кучкә җыелып караңгылануы, кояшның шул болыт юрганы астына кереп югалуы, күк йөзенең мизгел эчендә яшь коя башлавы астагыларның тормышын төбе-тамыры белән үзгәртергә сәләтле икәнен аңласалармы...” [2: 215].

Шулай итеп ул кешеләрнең алны-артны күрми тормыш куулары, тормышның Аллаһ кулында икәнен онытып җибәрүләре турында искәртә.

Язучы әлеге хикәяләрендә геройларның хис-тойгыларын, эш-гамәлләрен табигать сурәтләнеше белән тыгыз бәйләнештә үреп бара һәм төп фикерне дә шуның аркылы җиткерүгә ирешә. Табигать белән геройлар арасында бәйләнеш урнаштырыла. Бу А. Әхмәтгалиева хикәяләрендә үзенчәлекле күренеш булып тора.

Айгөл Әхмәтгалиева пейзажны ничек кенә, нинди вазифалар йөкләп тасвирламасын, аны һәрвакыт теге яки бу күренешкә үз мөнәсәбәтен белдерүнең үтемле чарасы буларак та аның иҗатына шәхеснең “күзгә күренми торган, җисемсез, предметсыз хәят – күңел дөньясы” белән тирән кызыксыну хас. Кеше күңеле хәрәкәтен дөрес сурәтләп бирү аның осталык арсеналының төп хасиятләреннән берсе.

**Әдәбият**

1. Алексеев В.А. Очерк. Спецкурс для студентов заочного отделения. – Изд. Ленингр. ун-та, 1973 – С. 84

2. Әхмәтгалиева А.Г. Таллыкүлдә былбыл бар. – Казан: Татар. кит. нәшир., 2016. – 287 б.

3. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М.,Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004 – 247 б.

## ТЕКСТТА МӘГЪНӘВИ БӨТЕНЛЕК ТУДЫРУ ЧАРАЛАРЫ

*Хөсәенова Э., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Кузьмина Х.Х.*

Текстны өйрәнү төрле-төрле фәннәрнең уртак бурычына әверелә бара. Бу хәл текстны төрле яклап өйрәнүгә һәм аның күп төрле билге-үзенчәлекләрен ачуга китергән.

Лингвистик категория буларак текстның асыл сыйфатлары түбәндәгеләр:

1) текстның мәгънәви бөтенлеге;

2) текстның коммуникатив бөтенлеге;

3) текстның структур бөтенлеге;

Текстның мәгънәви бөтенлеге буенча тоташ текст эчтәлек ягыннан бербөтен төзелергә тиеш, ягъни андагы мөстәкыйль җөмләләр тыгыз мәгънә бәйләнешендә торырга һәм барысы да бер уртак теманы ачуга ярдәм итәргә тиешләр. Бу уртак тема текстның мәгънәви үзәге була [2: 21].

Тулаем текстның мәгънәви бөтенлеге, кисәкләренең бердәмлеге бигрәк тә матур әдәбият әсәрләре өчен хас. Синтаксик бөтен фикернең бердәмлеге белән генә түгел, аның төгәлләнгән булуы белән дә аерылып тора. Аерым җөмлә бик сирәк мөстәкыйль була, ул бары тик синтаксик бөтен эчендә генә тулы канлы тормыш белән яши башлый, шуңа күрә синтаксик бөтен фикернең тагын да тулырак үстерелеше белән характерлана.

Мисалга Г. Әдһәмнең "Наласа авылы көе" хикәясен алыйк. Әсәрдә Бөек Ватан сугышы елларында авылда булган вакыйгалар сурәтләнә. Хикәя базга салынган бәрәңгенең череп чыгу күренеше белән башланып китә: "*Баз капкачын ачып җибәрүгә, түбәннән күтәрелгән әллә нинди чиркаfamiliar ачы ис, ни заманнан бирле җүнле ризык күрмәгән ашказанын ертып үтте дә бөтен эчен умырып алды. Хатын, укшып, җиргә чүкте. Бераздан кап-кара булып ыржаеп торган баз авызына тагын башын сузды, тагын тыны буылды. Эшләр харап иде: берәмтекләп чүпләп, симәнәгә дип сайлап кына салынган унөч чиләк бәрәңге, череп, сасы тирескә әйләнгән* [1: 209]."

Бүгенге көн күзлегеннән караганда, бу әллә ни игътибар җәлеп итәрлек вакыйга да түгел төсле, тик сугыш чоры өчен ул иң зур фаҗигаләрнең берсе. Биредә бәрәңге язга кадәр тамак туйдыру чарасы, ачлыктан коткаручы гына түгел, хәтта төп геройларның язмышын хәл итүче вакыйгага әверелә. Әсәрнең буеннан-буена вакыйгалар әнә шул бәрәңгегә бәйле рәвештә ачылалар, гаилә өчен иң кадерле ядкарьләрнең берсе – тальян гармунның сатылуына да шул гына сәбәпче төсле.

Бер яктан, башламның әсәр исеме ("Наласа авылы көе") белән һич бәйләнеше булмас кебек. Тик укый башлагач, аның әсәрнең төп герое – ире сугышта үлгән Сәкинәнең бөтен язмышын, хис-кичерешләрен, әрнү газапларын нигезләүче, хикәянең бөтен барышын билгеләүче ачкыч булуына инанасың.

Әсәр, бу вакыйганың фаҗигасен тагын да куәтләндереп, хатынның күңел халәтен билгеләүче атау һәм тойгылы җөмләләр белән дәвам итә: "*Бетте, барысы да бетте. Үзем генә гаепле, үзем генә...*

*Күзләр тидердем лә... Никләр генә шулай шатландым да, никләр ашкындым икән!* [1: 210].*””*

Әсәрдәге вакыйгалар бәрәңге, гармун һәм төп геройлар язмышын чагылдырган җыр (“Наласа”) тирәсендә. Безнеңчә, текстның мәгънәви үзәге – нәкъ менә әлеге җыр. Бу җырда Сәкинәнең яшли тол калып, мең газаплар кичкән авыр тормышы да, ятим үскән Әнвәрнең фронтта ятып калган әтисен сагыну хисләре дә, әнисенең соңгы амәнәтен үти алмау үкенече дә чагыла төсле. Шуңа күрә дә бу геройларның күңелләре моң белән, җыр белән тулы.

Мәгънәви үзәкне, икенче төрле әйткәндә теманы, тексттагы аерым җөмләләр эчтәлегенең механик җыелмасы итеп кенә карарга ярамый, ул тоташ текст эчтәлегенең гомумиләштерелгән үзәге була. Шул үзәк бөтен бер тексттагы мөстәкыйль җөмләләрне, хәтта абзацларны мәгънәви яктан бәйли, нәтиҗәдә текстның мәгънәви бөтенлеге тәэмин ителә.

Тормышны, кешеләр психологиясен яхшы белеп язылган бу хикәядә Г. Әдһәм җыр образына бәйле рәвештә сугыш чорнының бөтен газапларын, ятим малайның балачагын һәм бүгенгесен, сугыш чоры газаплары һәм тыныч тормыш ләззәтләрен, кеше язмышларын сурәтләгән тетрәндергеч вакыйгалар аша ача.

Иншалау рәвеше ягыннан караганда, анда тасвирлау һәм фикер йөртү элементларын күрергә була. Чөнки риториклар билгеләп үткәнчә, тасвирлау – тышкы хис, ә фикер йөртү – ул акыл белән хисләр бердәмлеге нәтиҗәсе. Биредә күбесенчә, хис өстенлек итә [4: 64].

Шуңа күрә төп геройларның эчке дөньясын (Сәкинә һәм улы Әнвәр) реалистик сурәтләү, хатын күңелендә кайнаган хисләрнең серенә төшенү, уй-фикер һәм кичерешләргә үз мөнәсәбәтен белдерү өчен автор әсәрдә еш кына уртак сөйләмгә күчә: *“Дүрт ел буе барган рәхимсез сугыш өй эчендәге һәрнәрсәгә эзен салып өлгергән иде. Сугыш алдыннан гына салып кергән яңа нарат йортның почмаклары да дымланып, күгәреп чыккан әнә. Сатарга мөмкин булган һәрнәрсә сатылып, азык-төлеккә алмаштырырлыгы күптән озатылып, диварлары шып-шыр калган өе хатынга бик кызганыч булып тоелды”* [1: 211]*”.*

Күргәнебезчә, хикәядә һәр абзац, һәр җөмлә тыгыз мәгънә бәйләнешендә торып, бер уртак тема – сугыш фаҗигасен ачуга юнәлдерелгән. Арага геройның үткәндә калган әрнү-сагышларын яңартып җыр – Наласа җыры килеп керә. Җыр әсәрдә вакыйгалар алмашын барлыкка китерү чарасы да: Сәкинәнең яшьлеге, иренә ияреп, Күмер шахталарында йөргән чакта гармунда уйнарга өйрәнүе, сугыш чоры газаплары, гармунны ике капчык бәрәңгегә алыштыру өчен, чана тартып, ун чакырым юл узулары; Әнвәрнең ир-ат булып җитеп, әнисе

теләге буенча гармун эзләве, соңыннан тыныч көннәрдә, очраклы рәвештә,“Уйнагыз, гармуннар!” концертында әнисенең тальян гармунын алган кулсыз ирне очрату күренеше. Беренче карашка, хикәя өчен шактый күп тоелган бу вакыйгалар, җырга бәйләп, хәтер-хәтирәләр кебек кучеп, ничектер җиңел һәм табигый кабул ителәләр. Бу авторның хикәя остасы булуын күрсәтүче тагын бер дәлил. Әсәрнең бетеме дә шактый отышлы: *“Халык тантана итте, үзләре дә сизмичә, кулсыз гармунчының көенә кушылып җыр суздылар:*

*Үсеп җиткәч, чит җирләрдә*
*Йөртә безне язмышла-а-ар...*

*Мәйданда патшалык иткән шушы моң агышында әнисенең тавышы да яңгырап киткәндәй тоелды Әнвәргә* [1: 223].*”*

Нәтиҗә ясап әйткәндә, текстта, абзацтан башлап, әсәрнең исеме, башламы һәм бетеме кебек көчле позицияләренә кадәр – барысы да текст структурасының әһәмиятле компонентлары булып саналалар. Бары шул очракта гына без текстны (әдәби әсәрне) мәгънәви бөтенлеккә ия дип әйтә алабыз.

**Әдәбият**

1. Әдһәм Г. Наласа авылы көе: повестьлар, хикәяләр – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 224 б.
2. Гальперин И.Р. Текст как объект лингвистического исследования. – М.: Комкнига, 2007. – 144 с.
3. Низамов И.М. Татарча әдәби редакцияләү: Югары уку йортлары өчен дәреслек.– Казан: КФУ нәшр., 2012. – 159 б.
4. Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше. Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 264 б.

## ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ ТЕКСТ: ЯЗМА ҺӘМ СӨЙЛӘМӘ ФОРМАЛАР

*Хөсәенова Э., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Кузьмина Х.Х.*

Тел белемендә текст теориясе 70 еллардан башлап махсус рәвештә эшкәртелә башлый. Шул вакыттан бирле текстка дистәләрчә билгеләмә бирелгән. Ул билгеләмәләрнең һәрберсен карап чыгу мөмкин дә түгел. Әмма барысында да элементларның билгеле бер максатлы төзелешенә ия булу, алар арасында мәгънәви, структур, композицион, шәкли бәйләнешләр булу, мәгънәви төгәлләнгәнлек, тәмамланган булу кебек билгеләр урын ала. Әмма тел белемендә текстның язма яисә сөйләмә булуы турында фикерләр каршылыклы. Бер төркем галимнәр текст язма да, сөйләмә дә булырга мөмкин дип исәплиләр. Мәсәлән, И.Р. Гальперин текст язма формада гына яши дигән фикер әйтә. Безнең карашыбызча, монда зур каршылык юк кебек. Тел сөйләмдә реальләшә. Сөйләмне җентекләп өйрәнер өчен,

аны язуга күчерәләр. Дөрес, сөйләмнең аерым параметрлары, мәсәлән, басым, интонация, тембр һ.б. язуда тулысынча чагылыш тапмый, ләкин шулай да без язганнар аша автор әйтергә теләгән фикерне төгәл аңларга тырышабыз. Галим, телче буларак, текстны структур яктан тикшерә. Аныңча, текст бары язма материалларны гына анализлый, текст ул чынбарлык кисәгенең график (ягъни язма) чагылышы [25: 58].

Гомумән, текст турындагы өйрәтмә тел һәм сөйләм дихотомиясен төгәл күз алдына китерү нигезендә барлыкка килә. Тел һәм сөйләм арасындагы мөнәсәбәт сөйләмнең аралашу чарасы буларак яшәешенә бәйле. Тел кеше аңында даими яши торган системаларның җыелмасы булса, сөйләм тел формаларын вакыт эзлеклелегендә реализацияли. Тел без ишетеп һәм күреп кабул иткән сөйләм агышындагы структур элементлар нигезендә барлыкка килгән абстракция булса, сөйләм телгә бәйле була, чөнки сөйләмдәге күренешләр тел системасына бәйле булалар һәм сөйләүче үз фикерләрен нәкъ шул системага нигезләнеп әйтә [17: 4].

Шулай итеп, сөйләмә һәм язма формалары арасында аерма шактый зур. Сөйләм теле һәрвакыт конкрет әңгәмәдәш белән бәйле. Язма телдә әңгәмәдәш юк, ул укучы рәвешендә күз алдында тотыла. Сөйләм телендәге интонация, ымнар, йөз хәрәкәтләре, диалог үзе сөйләүчене әйтергә теләгән фикерен төгәл белдерүгә ярдәм итәләр. Ә язма телдә болар юк, шуңа күрә әйтергә теләгән фикерне адекват кабул итү өчен, шактый күп көч сарыф итәргә кирәк. Язма текст һәрвакыт функциональ юнәлгән була, ягъни ул һәрвакыт сөйләмнең алдан билгеләнгән максатын күз алдында тота. Әмма ул максат ап-ачык һәм турыдан-туры билгеләнми.

Сөйләм – эзлекле, сузылган хәлдәге күренеш. Ул һәрвакыт хәрәкәттә. Шуңа күрә ул стабиль, тотрыклы була алмый. Тасмага язып алганда да, ул текст була алмый әле, чөнки спонтан, самими сөйләмнең чагылышы гына булып кала.

Сөйләм теленең төп билгесе итеп галимнәр диалогны саныйлар, ә монолог язма телнең төп билгесе дип исәпләнә. Алар бер-берсеннән лексик, фразеологик, грамматик, структур, композицион яктан, җөмлә күләме һ.б. яктан гаять нык аерылып торалар.

Прагматик яктан да телнең сөйләмә һәм язма вариантлары арасында аермалар бар. Сөйләм теле конкретлыкка, бермәгънәлелеккә, интонацион төгәллеккә омтыла һәм ачыктан-ачык ышандырырга тырыша. Язма тел абстрактрак, бер мәгънәгә генә ия түгел, төрле интонация белән әйтергә, төрлечә уйларга урын калдыра.

Шуңа күрә текстны өйрәнү язма әдәбият нигезендә алып барыла һәм аның төрле типологик калыпларына хас төзелеш кануннары ачыклана.

И. Низамов текст төшенчәсен ике тармакта – телдә һәм сөйләмдә кулланылучы тел фәне берәмлеге һәм ул фикерләмәне белдерә торган чара дип белдерә һәм аңа хас билгеләр дип түбәндәгеләрне күрсәтә: “Текст – сөйләмнең бөтен үзенчәлекләрен үзендә туплаган сөйләм берәмлеге. Һәрбер текст билгеле бер хәбәр алып килә. Бу хәбәр билгеле бер конкрет факт рәвешендә булырга мөмкин. Газетлардагы кыска хәбәрләр – шуның ачык мисалы. Бу хәбәргә язучының үз фикерләре, уйлары кушылган булырга мөмкин [14:12].

Сибгаева Ф.Р. һәм Хөснетдинов Д.Х. хезмәтендә билгеләп үтелгәнчә, сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрнең стилистик билгеләре бары тик текст бердәмлегендә генә ачыла. Һәрбер текст – ул иң элек җөмләләр һәм хәбәрләмәләр җыелмасы. Соңгыларыннан мәгънәви һәм структур элемтәләр нигезендә фраза берләшмәләре оеша, ә алардан тулы канлы сөйләм әсәре барлыкка килә [18: 58].

Хәзерге вакытта текстны саф сөйләм категориясе дип карап, шушы тармак кысаларында гына тикшерүче галимнәр булса да, без элек-электән текстны, чыннан да, язуга бәйле төшенчә дип күзалларга күнеккән. Татар лингвистикасында да ул шулай береккән.

“Өйрәнү өчен алынган, эчтәлек һәм структур яктан оешкан тоташ сөйләмне текст дип атыйлар, – ди М.З. Зәкиев, – мондый тоташ сөйләм (ягъни текст) буларак, соңгы елларда зур әсәрләрнең аерым бүлекләре, кыскарак хикәя һәм нәсерләр, аерым мәкаләләр, эш кәгазьләреннән гариза, белешмә, ышаныч язуы, беркетмә һ.б. тулысынча алыналар һәм текст дип йөртеләләр. Шуның белән бергә мондый тоташ сөйләмнең аерым өлешләре дә текст итеп өйрәнелергә мөмкин. Беренче төр тоташ сөйләмне, гадәттә, макротекст дип, икенче төрен – кыскарагын микротекст дип атау кабул ителгән [8: 199-200].

Татар тел белемендә М.З. Зәкиев, беренчеләрдән булып, текст синтаксисы турында сүз башлап җибәрә. Аның җиңел кулыннан хәзер татар теле фәнендә шушындый исемдә махсус тармак яшәп килә. Без дә текстны хәзер тел гыйлеме категориясе буларак, ягъни фикерләмәне оештырыр өчен чара буларак анализлыйбыз һәм сөйләм оештыру өчен телнең иң эре чараларыннан берсе булган текстны махсус өйрәнү зарур дип саныйбыз, чөнки сөйләмнең бөтен үзенчәлекләрен үзендә туплаган текст җентекләп өйрәнүне сорый.

**Әдәбият**

1. Гальперин И.Р. Текст как объект лингвистического исследования. – М.: Комкнига, 2007. – 144 с.

2. Зәкиев М.З. Синтаксис һәм пунктуация. – Казан, 1965. – 147 б.

3. Низамов И.М. Татарча әдәби редакцияләү: Югары уку йортлары өчен дәреслек.– Казан: КФУ нәшр., 2012. – 159 б.

4. Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше. Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма.–Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993.–264 б.
5. Сибгаева Ф.Р., Хөснетдинов Д.Х. Әдәби текстка филологик анализ. Югары уку йортлары өчен укыту-методик кулланма. – Казан: Отечество, 2013. – 78 б.

# ФӘНИС ЯРУЛЛИН ӘКИЯТЛӘРЕНДӘ ПРОБЛЕМАЛАР ЧАГЫЛЫШЫ

*Шадманова Г., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – фил. фән. докт., проф. Минһаҗева Л.И.*

Әкият – халык авыз иҗатының борынгы, шул ук вакытта киң таралган һәм мавыктыргыч жанрларыннан берсе [2: 7].

Әкиятләрдә халыкның күп гасырлык тормыш тәҗрибәсеннән туган зирәклеге, тапкырлыгы, яхшылык һәм явызлык турындагы төшенчәләре тупланган, киләчәккә өмет һәм хыяллары чагылган. Әкият явызлыкны гаепли, гаделлекне, хаклыкны яклый, кешеләрне игелекле, тугры һәм мәрхәмәтле булырга өйрәтә.

Ф. Яруллин бик күп әкиятләр авторы. Мәсәлән: “Йолдыз тапкан кыз”, “Урман әкияте”, “Яз кайда кышлый”, “Рәссам кыз”, “Салпыкикрик һәм велосипед”, “Тылсымлы ачкыч”, “Акайкүз”, “Ике чәчәк”, “Шушылай яшәргә ни җитә” һ.б.

Ф. Яруллин әкиятләрендәге эчке рифмалар, вакыйгаларның үсә барып, герой рухы белән укучы җанының берләшүе әкиятләргә сихри күтәренкелек бирә. Ә инде әкият геройларының тышкы кыяфәтләрен сурәтләгәндә, образлылык өстенлек ала. Әдип үз әкиятләрендә тел белән ювелирларча эш итә [3: 115].

“Кояштагы тап” әкиятендә язучы балаларны алдашмаска, олыларны тыңларга, әниләрне хөрмәт итәргә өйрәтә, балаларда кешелекле, намуслы, ярдәмчел, тәүфыйклы, миһербанлы кебек сыйфатлар тәрбияли. Биредә кояш – символик образ. Ул – яктылык, матурлык, җылылык билгесе. Кояш җиргә, хайваннарга, үсемлекләргә көч, җылылык биргән кебек, әни дә безгә көч, җылылык, рәхәтлек бирә. Шулай итеп, кояш җылысы – әни җылысы белән чагыштырыла:

*Малай мөлдерәмә яшьле күзләре белән әнисенә караган. Әнисе улын күкрәгенә кыскан. Шулвакыт кояштагы караңгылык кими башлаган. Дөнья әкренләп яктырган, кошлар кереп поскан ояларыннан чыгып, агач ботакларына кунганнар, этләр елый-елый өрүләреннән туктаган. Бар нәрсә элекке хәленә кайткан, бары тик кояштагы тап кына бөтенләй бетеп җитмәгән* [4: 260].

Күргәнебезчә, тапның бетмәве, әнинең йөрәгендә яра калуын күрсәтә. Әлеге әкият әни белән бала мөнәсәбәтләренең эчкерсезлеккә корылуының бер чагылышы. Шулай да:

*Әйе, дөньяда бер генә ялган да эзсез калмый шул. Яманлыкны хәтта кояш та яндырып бетерә алмый икән,* - дигән нәтиҗә чыгара автор [4: 260].

“Йолдыз тапкан кыз” әкиятенең төп герое – Таңсылу. Ул әбисе белән яши. Әбисе авырып киткәч, аңа сихәтле җиләк эзләп Таңсылу урманга китә. Җиләк җыя-җыя кич җитә, төн җитә, ул анда адаша. Шулвакыт мәрхәмәтле кызның үз Йолдызы кабына, аңа юл күрсәтә. Йолдызның тылсым көче аша, ул кешеләрне дәвалый башлый. Әмма кызда бераздан комсызлык хисе уяна, шул сыйфаты аркасында өенә ярдәм сорап кергән, хәерчене дә куып чыгара.

Әкияттә “байлык артыннан куа торгач, кешелек абруеңны югалтканыңны сизми дә калырсың” дигән фикер гаять мавыктыргыч, үтемле-тәэсирле вакыйгалар тезмәсенә салып бирелә. Зирәк әбисенең сүзен тыңлаган Таңсылу урманнан якты йолдыз ташы табып кайта, шуның белән чирле, зәгыйфьләрне дәвалап, күп рәхмәтләр ишетә. Әмма бераздан моның үзенә акча чире йога һәм кыз бүгенге экстрасенслар сыман акча җыя башлый – буш кул белән килгәннәрне авыр сүз әйтеп, рәнжеткәләп тә чыгаргалый. Шунда хикмәтле ташның сихәтле нурлары сүнә. Әбисе дә үлеп китә. Клиентлар да юк, бай кияүләр дә ишек шакымый... Зиннәтле келәмнәрне тузан баса, татлы ризыклар да күптән ашалып беткән... һәм кыз әле күптән түгел генә куып чыгарган хәерче кыяфәтендә, ил буйлап хәер сорашырга чыгып киткән, ди [1: 136-137].

Әкият Таңсылу сүзләре белән тәмамлана: *“Кешеләр, бер-берегезгә мәрхәмәтлерәк булыгыз. Дөнья малы – дөньяда кала. Гомер – аккан су, байлык – бер айлык. Мәр-р-хә-мәтле бул-ы-гыз* [4: 26].

Биредә хыял һәм чынбарлыкны тоташтыручы предмет – ул йолдыз. Әсәрдә ул хикмәтле итеп бирелә: *“Ул үзенә кагылган кешеләрне яшәртеп кенә калмаган, ә барлык чирләреннән дә арындырган. Моны белеп алгач, Таңсылуларга иртәдән алып кичкә кадәр кешеләр агылган. Аларның кайберләре таякка таянган, кайберләрен балалары җитәкләгән, кайберләрен бөтенләй күтәреп алып киләләр икән. Таңсылу һәр авыруга үзенең тылсымлы йолдыз кисәге белән кагылган. Ул кагылуга күзсезләр – күзле, аяксызлар – аяклы, телсезләр – телле, бөкреләр тураеп киткән* [4: 22]. Әмма әлеге йолдыз Таңсылуны, киресенчә, авыруга сабыштырган. Ул аңа мәрхәмәтсезлек, комсызлык сыйфатларын бирә.

Әлеге йолдыз аша күп кенә кешеләрнең хыяллары чынга аша, ә менә чынбарлыкның кадерен белмәгән Таңсылу, шул хикмәтле ташның уты сүнгәч, тормыш мәгънәсен югалта, хәерчегә әверелә.

Ф. Яруллин әкиятләре – безнең татар әдәбиятында яңа күренеш. Аның әкиятләрен укыганда шуны күрәсең: һәр вакыйга баланың үсү

процессын күз алдында тотып, күзгә күренмәслек, ләкин сизгер йөрәк тоярлык итеп катламнарга бүленеп бирелә. Әйтик, бала кечкенәрәк чакта әкиятнең мавыктыргыч сюжетын, әкият геройларының явыз көчләрне җиңүен хәтеренә сеңдереп калса, тора-бара, үзенең аң үсешенә карап, әсәрнең эчке фәлсәфәсенә, фикер тирәнлегенә төшенә башлый.

**Әдәбият**


1. Сверигин Р. Аны беләбезме? // Казан утлары. – 2003. – Б. 130-137.

2. Татар халык иҗаты: Әкиятләр. Беренче китап / төз.: Х. Гатина, Х. Ярми. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1977. – 482 б.

3. Хәкимова С. Әдип иҗатына бер караш // Казан утлары. – 2018. – №2. – Б. 113-120.

4. Яруллин Ф. Зәңгәр күлдә Ай коена: әкиятләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 272 б.


## Ф. ЯРУЛЛИН ӘКИЯТ-ПЬЕСАЛАРЫНЫҢ КОНФЛИКТ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ


*Шадманова Г., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – фил. фән. докт., проф. Минһаҗева Л.И.*


Ф. Яруллин әдәбиятка шактый ук тормыш тәҗрибәсе туплаган, зур фаҗигаләр кичерергә өлгергән шәхес булып килеп керә. Ул беренче әсәрләрендә үк үзенең эчке дөньясын: шатлык-кайгыларын, сагыш-моңнарын, уй-гамьнәрен, җиңү-җиңелүләрен яшермичә укучысына ача.

Фәнис Яруллинның балалар өчен иҗатын әкият-пьесаларсыз күз алдына китереп булмый. Аның “Исемсез кыз”, “Әмәк белән Шәмәк”, “Хәзинә”, “Каракның бүреге яна”, “Баз бакасы”, “Ак яфрак” кебек әсәрләре, үзләрендә әкият һәм драма әсәрләренең куәтен туплап, үсеп килүче буында әдәбиятка мәхәббәт, гаделлеккә омтылыш, тырышлык, намус кебек сыйфатлар тәрбиялиләр. Әсәрләренең мондый көче әдипнең осталыгы, таланты көче турында да сөйли, шул ук вакытта күтәрелгән проблемаларның актуальлеге, әһәмияте белән дә бәйле. Шунысы кызык: язучы хайваннар, әкияти персонажлар дөньясына мөрәҗәгать итә, әмма бу дөнья да кешелек күнеккән проблемалар белән яши икән.

Әлеге мәкалә кысаларында без язучының әкият-пьесаларының конфликт үзенчәлегенә игътибар итәрбез.

Ф. Яруллин драматургиясенең төп яңалыгы тормышчан конфликтка йөз тоту белән бәйле. Ул пьесаларында, каршылыкның бихисап төрләрен үзәккә алып тасвирлап,вакыйгаларның кызыклы, мавыктыргыч булуына, драматик хәрәкәтнең җанлы, тыгызбирелүенә ирешә. Яшәешнең шактый якларына мөрәҗәгать итеп, тема һәм проблема киңлегенә омтыла [1: 122].

Мәсәлән, язучының “Әмәк белән Шәмәк” әсәренә игътибар итик. Әсәрнең беренче битләрендә аларның хан уллары булуын

беләбез, алга таба әсәрнең төрле урыннарында автор безне хан сараендагы тәртипләр белән таныштыра. Укучы хан балаларына көчләп диярлек тагылган кыйммәтләр системасына игътибар итә.

Икенче күренештә дә хан сараендагы тәртипләр, Әмәк белән Шәмәкнең ни дәрәҗәдә аңсыз, чикләүләр эчендә яшәгәннәре ассызыклана бара. Ханлык инде таркалган. Сарай да юк. Тамаклары ачып беткән хан варислары, мәсәлән, үсеп утырган җиләк күреп шаккаталар: "*Ә нишләп алар көмеш табакта түгел? Безгә вәзирләр көмеш табак белән китерә торганнар иде"* [2: 251]. Экспозиция шуны күрсәтә: конфликт хан балаларының чикле, аңсыз, үзсүзле булып үсүе шартларында, тирәлектә дә аларга чын тәрбия, киңәш бирүче булмаган, бүген – бер, иртәгә – икенче ханга тәлинкә тотарга әзер вәзирләр генә булу шартларында барлыкка килгән.

Алга таба әсәрдә ике туган арасында шунда ук тәхет өчен көрәш башлана. Вакыйгалар үстерелешендә әлеге тәхет өчен ярыш кына булып түгел, ә юләрлек, аңсызлык бәйгесе булып та аңлашыла башлый. Әмәк белән Шәмәк бер-берсен һәм башкаларны җәзалауда, күбрәк ашауда, катырак кычкыруда ярышалар. Вакыйгалар үстерелешендә пьеса конфликтының Әмәк белән Шәмәкнең тарткалалушыннан гына тормавы, бу – ярдәмче конфликт булуы ачыклана, асылда бу ханлыкта каршылык дуамал хакимият белән халык, хезмәтчеләр арасында булуы аңлашыла. Ханнарның башбаштаклыгы мәңге дәвам итә алмый, әлбәттә, ханлык та, хан сарае да хәрабә хәлендә кала, сугышчылар ачтан кырыла, сарай байлыгы вәзирләр тарафыннан урлана.

"Ак калфак" әсәрендә төп конфликт буыннар каршылыгына бәйле. Төп геройлар булып, Убырлы (әниләре) һәм Җилбикә белән Йокыбикә (кызлары) бирелә. Аларның каршылыгы мөнәсәбәтләр характерына бәйле. Әсәрдә Убырлы әлеге каршылыкның ахырын ачык күрә. Иркә кызларның эшләмичә, әниләре карамагында гына торуларын күрү Убырлы җиңел түгел. Икенче яктан, әлеге кызлар әниләрен санга сукмыйлар, тәкәббер сөйләшәләр:

*Йокыбану: Әй, Убырлы! Чык әле монда!*

*Җилбикә (почмакларны караштырып): Чык, диләр сиңа!*

*Йокыбану: Әгәр хәзер үк чыкмасаң, үзебез өеңнән чыгып китәбез.*

*Җилбикә: Картайган көнеңдә яшәрсең берүзең.*

*Йокыбану: Без булмасак, пешергән ашларыңны кем ашар?* [2: 303].

Пьеса-әкият геройлары Убырлы, аның кызлары, йорт иясе, сихерләнгән егетләр булуга карамастан, без әлеге персонажлардан хәзерге тормыштагы гади кешеләрне күрә алабыз. Мәсәлән, Йокыбикә белән Җилбикә – башкалар хисабына гына ирешергә омтылучы замана

кызлары. Алар рухи азык турында уйлап та карамыйлар, ә *“Тамак тук, өс бөтен булса, җан азыгын хаҗәтемә кирәк?”*[2: 299], дип фикер йөртәләр. Шулай итеп, кызлар сихер эшенә өйрәнергә теләмиләр, кияүгә чыгып, ир җилкәсендә яшәргә телиләр.

Әсәрдә буыннар каршылыгына гына түгел, яхшылык һәм явызлык конфликтына да урын бар. Мәсәлән, Убырлы карчыкның сихерләрендә кызлары белән мөнәсәбәтләрне җайлау мәсьәләсе генә түгел, ә аларга күңел сафлыгын кайтару проблемасы да ята:

*Күңлем изге ниятле, тфү, тфү,*
*Сихерем булсын сихәтле, тфү, тфү,*
*Кайгы аша шатлык килсен, тфү, тфү,*
*Күңлегезгә пакьлек килсен, тфү, тфү* [2 306].

Ф. Яруллин каләме белән тудырылган геройлар арасында рухи-әхлакый кануннарны бозучы, аларны исәпкә алмаучы, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүче, милләтебезнең яшәү рәвешенә салынган рухи кыйммәтләрне санламыйча, матди байлыкларга табынып яшәүчеләр кискен тәнкыйть ителә, әхлакый кануннарны саклаучылар авторда симпатия уята. Драматург идеалы буларак, күпчелек әсәрләрдә олы буын кешеләре – зур тәҗрибә туплаган, катлаулы тормыш юлы узып та, гомумкешелек кыйммәтләрен югалтмаган геройлар бирелә[1: 125].

Әдипнең балаларга багышланган экият-пьесаларында милләтебезнең киләчәген дөрес юнәлешләрдә, гомумкешелек, милли кыйммәтләр үрнәгендә тәрбияләү максаты куела.

**Әдәбият**


1. Миннекаева Д. Фәнис Яруллин драматургиясендә әхлак тәрбиясе // Казан утлары. – 2018. – №2. – Б.121-125
2. Яруллин Ф. Әсәрләр. Өч томда. 3 т: экиятләр, экият-пьесалар, повестьлар, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 431 б.


## XX ЙӨЗДӘ ТАТАР БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ТӨП ҮСЕШ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ, ӘКИЯТ-ПЬЕСА ЖАНРЫНЫҢ ФОРМАЛАШУ ТАРИХЫ


*Шадманова Г., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – фил. фән. докт., проф. Минһаҗева Л.И.*


Шәхеснең рухи дөньясын формалаштыруда, аны яшәешне, тормышны күзалларга, бәяләргә өйрәтүдә матур әдәбиятның роле зур. Ә инде формалашып килүче кешегә, ягъни балага багышланган балалар әдәбияты бу җәһәттән аеруча игътибар таләп итә.

Ул үзенең бөтен барлыгы белән универсаль жанр. Балалар әдәбиятының төп үзенчәлекләреннән берсе – баланың эчке дөньясы, кичерешләре олы кеше тарафыннан сурәтләнә. Сабыйлар өчен иҗат

итүче, беренчедән, тормыш вакыйгаларын балаларча кичерә белергә тиеш. Шуның белән бергә талантлы әдип, тормышны берьюлы ике яссылыкта күрә: балаларча һәм өлкән кеше буларак. Нәтиҗәдә, зурлар яшәеше аңлатмаларын балалар теленә күчерү урынына, тормышны аларча күрү һәм шуны сәнгатьчә ачу мөмкинлеге туа. Чынбарлыкны алдарак әйтеп үтелгән яссылыкта күрә алмаган очракта инде балалар тормышын, телен "охшатып" бирү, нәтиҗәдә мораль уку, "төссезлек" алгы планга чыга. Чөнки бу очрата, балалык яшеннән чыккан язучының герое һичничек "язучының әдәби чагылышы" була алмый.

Балалар әдәбияты хакында әле 1983 елда ук Р. Миңнуллин болай дип яза: "Бәхетебезгә каршы, бүгенге көндә балалар әдәбияты зур әдәбиятыбыз белән бер сафта атлап бара. Һәрхәлдә, артка калмаска тырыша. Аңа булган мөнәсәбәт тә акрынлап әйбәт якка үзгәрә бара шикелле. Шулай булырга тиеш тә. Чөнки балалар әдәбияты да башка жанрлар белән бер хокуктагы, тулы вәкаләтле әдәбият. Хәтта әйтер идем, кайбер яклары белән, мәсәлән, педагогик яктан, шулай ук әдәбиятыбызның киләчәген кайгырту җәһәтеннән караганда, ул икеләтә отышлы әдәбият дияргә була аны" [2: 4].

Татар балалар әдәбияты формалашу тарихы шактый озын һәм катлаулы. Әлеге процесс гомуми әдәбият, җәмгыятьтәге карашлар, педагогик һәм фәлсәфи фикерләр белән тыгыз элемтәдә бара.

Балалар әдәбиятын төрле яклап, төрсе аспектта өйрәнгән галимә Минһаҗева Л.И. фикеренчә, бүгенге көн татар балалар әдәбиятын төп дүрт юнәлештә үсүен күзәтергә мөмкин:

- татар балалар әдәбиятында үз йөзен тапкан, билгеле авторлар иҗаты һәм яңа авторлар иҗаты;
- моңа кадәр дөнья күргән уңышлы әсәрләрне кабат нәшер итү;
- тәрҗемә әсәрләрен нәшер итү аша соңгы дәвер татар балалар әдәбиятын баетырга омтылыш;
- татар, рус, инглиз телләрендә татар әдәпләренең әсәрләрен бастыру, шулар аша балаларның аң-белем үсешенә тәэсир итү омтылышы [1: 350].

Татар балалар әдәбиятын баетуда һәм үстерүдә вакытлы матбугатыбыз бик зур өлеш кертә ("Салават күпере", "Көмеш кыңгырау", "Ялкын", "Сабантуй", "Мәйдан") (журналларда балалар өчен махсус кушымта бар).

XX йөз татар балалар әдәбиятында жанр төрлелегенә баювы да күзәтелә. Шундыйлардан, мәсәлән, балалар әдәбиятында әкият-пьеса жанрының формалашуы һәм үсешен әйтергә була. Әкият – пьеса – ул әкияткә нигезләнеп, драма әсәре формасында язылган арадаш жанр төре. Бу жанрның барлыкка килүе татар балалар театры һәм курчак

театрының популярлашуын да әйтергә кирәк. Моннан тыш, узган гасыр ахырында һәм бүгенге көндә дә мәктәпләр һәм балалар бакчалары өчен төрле сәхнәләштерүгә бәйле конкурслар да булдырылуы бу жанрның үсешенә этәргеч бирде.

XX йөз башында әкият-пьеса жанрына нигез салып, балалар әдәбиятының бу жанрын үстерүгә Туфан Миңнуллин, Фәнис Яруллин, Рабит Батулла, Мәгъсүм Латифуллин һ.б. зур көч куйды.

Мәгълүм ки, әкият-пьесаларның, шул исәптән балалар әдәбиятының төп үзенчәлекләреннән берсе – баланың эчке дөньясы, кичерешләре олы кеше тарафыннан сурәтләнә. Сабыйлар өчен иҗат итүче, беренчедән, тормыш вакыйгаларын балаларча кичерә белергә тиеш. Шул очракта гына үзенчәлекле фикер агышы, чагыштыру ярдәмендә романтик, беркадәр сәеррәк тә тормыш картинасы барлыкка килә. Икенчедән, язучы фантазиясе ярдәмендә реаль тормыш материалын танымаслык итеп үзгәртә белергә тиеш. Шул рәвешле тормыш чынбарлыгыннан аермалы булган хыялдагы күренешләр әдәби әсәрдә сурәтләнеш табачак.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар балалар әдәбияты бүгенге көндә дә үсеш-үзгәреш кичерә. Буыннар үзгәреп торган саен, балаларның да ихтыяҗлары үзгәрә, шул исәптән, уку материалына карата да таләпләр үзгәрә. Бары тик заман белән бергә атлаучы һәм үзгәрешләргә сизгер булган язучы гына балалар аудиториясе өчен кызыклы булган әдәби әсәрләр язарга сәләтле. В. Нуриев әнә шундый язучыларыбызның берсе.

**Әдәбият**

1. Минһаҗева Л.И. Татар балалар әдәбияты: Урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку ярдәмлеге. – Казан: ТаРИХ, 2003. – 350 б.

2. Миңнуллин Р. Башкаларга бер караш. – Татар.кит.нәшр., 2017. – Б. 4.

## ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ НИКАХ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ТУГАНЛЫК АТАМАЛАРЫНЫҢ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Шәйхетдинова Р., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд, доц. Җамалетдинова Г.Ф.*

Никах нәтиҗәсендә барлыкка килгән туганнарга мөрәҗәгать итү формаларының барлыкка килүендә яңа сүзләр ясау, яшь киленнең туганнарына олылап, иркәләп, шигъри һ. б. рәвешле мөрәҗәгать итү сүзләре уйлап табуы зур роль уйный, бу формалар гореф-гадәтләр, үзара аралашу кагыйдәләре, яшәп килә торган традицияләр белән алшартланган була.

Билгеле булганча, кан туганлык атамалары телнең иң борынгы һәм т атамаларына түбәндәгеләрне кертеп карарга мөмкин: *koca (ир), karı (хатын), gelin (килен), damat (кияү), enişte (җизни), yenge (җиңги),*

*döner (кода), kaynata (кайната), kaynana (кайнана), baldız (балдыз), bacanak (баҗа) h.б.*

Төрек телендә ир лексемасын *koca* сүзе аңлата. Зур төрек-рус сүзлегендә әлеге туганлык атамасына түбәндәге аңлатмалар бирелә:

I ир, хатын ире: kocaya gitmek или kocaya varmak – кияүгә чыгарга; kocaya vermek – кияүгә бирергә

II 1) зур: koca memleket – зур ил

2) карт, өлкән

